ISSN 0206—4189

# КАЗАН УТЛАРЫ

9.2000



# YAZUÇILARIBIZ ÇİT İLLƏRDƏ



Tatarstan wəkillərе Fransiədə. Şagir **Robert Minnullin**, rəssam **Abrek Abzgildin**. *Parij, iyün, 2000 yıl.*



Tənyaq Kipr Tərek respublikası Prezidentı **Rəüf Denktaş** belən oçraşu waqıtında yazuçı **Marsel' Ğəliev** avtograf ala. *Noyəbr, 1999 yıl.*

# Казан утлары
# Qazan utları

*2000*

**9**

**(935)**

ОЕШТЫРУЧЫЛАРЫ:

***Татарстан хөкүмәте,***
***Татарстан Язучылар берлеге,***
***редакциянең хезмәт коллективы***

*БАШ МӨХӘРРИРЕ*

**Равил Фәйзуллин**

*ИДАРӘ:*

**Харрас Әюпов,**
**Зилә Вәлиева,**
**Фоат Галимуллин,**
**Тәлгат Галиуллин,**
**Миркасыйм Госманов,**
**Аяз Гыйләҗев,**
**Алмаз Гыймадиев**
*(җаваплы сәркәтип)*
**Флүс Латыйфи**
*(баш мөхәррир урынбасары),*
**Салих Маннапов,**
**Туфан Миңнуллин,**
**Хатип Миңнегулов,**
**Ринат Мөхәммәдиев,**
**Гәрәй Рәхим,**
**Булат Солтанбәков,**
**Ренат Харис,**
**Розалина Шаһиева.**

---

*Мөхәррирләр:* **Мансур Вәли, Наис Гамбәр, Рәдиф Гаташ, Шамил Маннапов, Марс Шабаев.**

*Гамәли хезмәткәрләр:* **Альбина Әхмәтова, Гөлзадә Бәйрәмова, Лилия Гатауллина, Флера Сабирова, Тәслимә Сибгатуллина, Тәгъзимә Шиһабиева.**
*Исәп-хисап бүлеге:* **Эльвира Камалова, Асия Рәхимова** (баш бухгалтер).

---

✉ 420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.
☎ Баш мөхәррир — 49-36-60.
Баш мөхәррир урынбасары — 49-36-09.
Җаваплы сәркәтип һәм компьютер үзәге — 43-56-12.
Бүлекләр: шигърият, фән, сәнгать — 49-36-61,
чәчмә әсәрләр, хатлар, әдәби тәнкыйть — 49-36-63,
гамәли хезмәткәрләр — 49-36-65.
Исәп-хисап бүлеге — 43-56-12.

# КАЗАН УТЛАРЫ

*ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ*

*1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА*

## Бу санда

**ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР**

Зиннур МАНСУРОВ. Бәгыремдә өннәр бәргәләнә. *Шигырьләр* ..... 5
Рауль МИРХӘЙДӘРОВ. Иртәләгән сагыш. *Роман.* Дәвамы ..... 13
Айдар ХӘЛИМ. Казыктагы итальян. *Хикәя* ..... 99
Рафис ӘХМӘТ. Гомер уртасы. *Шигырьләр. (Р. Гаташ кереш сүзе белән)* ..... 126

**ХӘСӘН ТУФАННЫҢ 100 ЕЛЛЫГЫНА**

Клара БУЛАТОВА. Тәнәкә хатлары. *Шигырьләр* ..... 94

**ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ**

Рафаэль СИБАТ. Прозабыз Ахуны ..... 131
Поэма турында сөйләшәбез ..... 148
Илгизәр СОЛТАН. Йөрәк тибеше *(Рецензияләр конкурсына)* ..... 160

**ДИН ҺӘМ ТОРМЫШ**

КОРЪӘН татар телендә ..... 163

**ФӘН**

Равил ӘМИРХАН. Чишмәләрдәй чылтыраган иҗат ..... 168
Damir ĞARİFULLİN. Tarixi xəterebez ilçese ..... 176
Җәүдәт МИҢНУЛЛИН, Раиф МӘРДАНОВ. Мирас бөртекләп җыела ..... 182
Айсылу ВӘЛИЕВА. Тел дәрьясының ике ярында ..... 186

**КИТАП КҮЗӘТҮ**

Равил ФӘЙЗУЛЛИН. Бөек төркилектә без олуг ..... 180

Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан ..... 190
Тышлыктагы сурәтләр ..... 192

## В НАШЕМ НОМЕРЕ:

*Журнал выходит один раз в месяц*

«Проза и поэзия»: продолжение романа Р. МИРХАЙДАРОВА «Ранняя печаль», рассказ А. ХАЛИМА «Тальянка на шесте»; стихи З. МАНСУРОВА, Р. АХМЕТА.
«К 100— летию Х. Туфана»: стихи К. БУЛАТОВОЙ.
«Литературная критика»: статья Р. СИБАТА «Классик татарской прозы Г. Ахунов».
«Беседа за круглым столом»: роль и место поэмы в современной литературе.
«На конкурс рецензий»: И. Султан рецензирует новую книгу стихов Р. КУРБАНОВА.
«Жизнь и религия»: Коран на татарском языке.
«Наука»: статья Р. АМИРХАНА о творчестве известного ученого Ф. Гариповой; Д.ГАРИФУЛЛИН: «Посланник памяти истории»; статья А. ВАЛЕЕВОЙ посвящена сравнительному анализу турецких и татарских пословиц и поговорок.
«Книжное обозрение»: Р. ФАЙЗУЛЛИН рецензирует книгу «Древняя и средневековая татарская литература».
«Наследие»: статья Дж. МИННУЛЛИНА, Р. МАРДАНОВА «Из крупиц прошлого».
Дневник общественно-культурной жизни.
На наших обложках: фоторепродукция триптиха Ш. Нигматуллина «Родники-источники»; писатель Ахат Сафиуллин.

## IN OUR ISSUE:

*The magazin edits monthly*

"Prose and poetry": continuation of R. MIRHAIDAROV'S novel «The early grief» A.HALIM'S story «Talian accordion on the pole»; the verses of Z. MANSUROV, R.AKHMET.
"Commemorating the 100 anniversary of H. Tufan": K. BULATOVA'S verses.
"Literary criticism": SIBAT'S article «G. Ahunov is the classic of Tatar prose».
"Round-table discussion": the role and place of a poem in the modern literature.
"Review competition: I. SULTAN'S review of R. Kurbanova's new book.
"Life and religion": Koran in Tatar language.
"Science": R. AMIRHAN'S article creative works of the known scientist F.GARIPOVA; D. GARIFULLIN «The Envoy of memoir of a history»; A.VALEEVA'S article devoted to the comparative analysis of Turkish and Tatar proverbs and sayings.
"Book review": R. FAIZULLIN'S review of the book «Ancient and medieval Tatar literature».
"Heritage": J. MINNULIN'S and R. MARDANOV'S article «From the grain of the past».
The diary of social and cultural life.
In our covers: Sh. Nigmatullin's photo-reproduction «Springs - sources»; the writer A.Safiullin.

★Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
★Редакциягә килгән кульязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
★Басмаханә гаебе белән киткән җитешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 49-36-62 телефоны белән басмаханәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.

Журнал редакциянен компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды.
Басарга кул куелды 18.08.2000 ел. Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70Х108 1/16.
Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12 (16,8). Тиражы 7542 Заказ Э-336
Журнал Татарстан Республикасының Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгында теркәлгән.
Теркәлү таныклыгы № 7.

«Идел—Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды.
Казан, Декабристлар урамы, 2

© «Казан утлары», 2000 ел.



## Зиннур Мансуров

### БӘГЫРЕМДӘ ӨННӘР БӘРГӘЛӘНӘ...

### Аллаһ бүләге

**Азга гына сорап торам Күктән**
**ерак малай чакның бар көнен.**
**Төшләремне ялгап өннәремә,**
**хәтер сурәтләрен барлыймын.**

**Төенләнгән җете тасмаларның**
**тартыйм икән кайсы очыннан?**
**... О Илаһым! Печән олаулары**
**чыгып килә буран эченнән.**

**Җәйге болын үзе күчеп кайта,**
**саклап кара аны халыктан —**
**яшеллеккә сусар яшьтәшләрем**
**печән йолкып кала һәр йөктән.**

**Могҗизага ничек ымсынмыйсың,**
**җәннәт үләннәре каршыда!..**
**Олаучыдан ертлач оланнарга**
**эләккәли ачы камчы да.**

**Ә мин... эчтән генә әйтәм шуны:**
**"Баскын дуслар"ымнан ваз кичәм;**
**дөньяныкын талап алуларда**
**түгел бугай минем вазифам..."**

**Ап-ак көрттән калкып дәште кебек**
**Хозыр пәйгамбәргә тиң кеше:**
**"Борылмада печән олавыннан**
**төшеп калды... сиңа тиеше!"**

Ишарәгә бик үк ышанмадым—
нинди мәгънә мине алдауда?!
Кабатлады: Аллаһ бүләкләре
булыр әле, имеш, алда да...

... Төшләремә өннәр төшендерде,
аныклады Картның тел-ымын.
Карда яткан учма акбаш[1] өчен
сабыр гомрем буе түлимен.

## Сихерләнү

Беләсеңдер Нократ болынының
хәтерендә шундый җәй барын:
җәннәт сые итеп эчкән идек
җанга тансык үлән чәйләрен.

Төклетура безнең төнәтмәне
киткән иде таңда әфсенләп...
Сөйләшкәнсең үлән телләрендә —
аңлаганмын шуны, ах, соңлап!

Сине туган иткән сихри дәрья
минем өчен йөзеп чыкмалы.
Учактагы кара чиләкләргә
ява иде төнлә чык балы.

Онытылдык антлар әйтешмичә,
көнләшкәндер күктән Ай кызы.
...Йолдыз кебек сүнде безнең учак,
төнәтмәләр инде айныды.

Сөю катыш сихер генә үтми —
әфсен кайтарырдай җәй бармы?
Үзем һаман дисбе тартып саныйм
синсез үтеп киткән җәйләрне.

## Яшен язуы

Яшен язып куйсын күккә
исемнәрне янәшә,—
ярәштырып ярәшмиләр,
кушылулар—җан аша.

Минем сөннәт каным белән
гыйффәт каның кушылсын,—
яшеннәрнең ялгышуын
ике җан да хуш кылсын...

[1]Акбаш — пәйгамбәр чәчәге

## Ату

*Фәниягә*

Улларыңны үсендереп,
әйдә, татар, әйтә тор:
"Ир-егетнең эчендә,—дип,—
иярләнгән ат ятыр".

Кайчак гамьсез күзләреңә
читтән карап ал, татар!
Үзәгеңне эзләгәндәй,
кемдер төби алтатар...

## Илаһи кызгану

Әгәр дә михнәттән укмашып,
күкләргә тоташкан тау булса,
һәм шунда Аллаһның бәллүргә
әйләнгән күз яше табылса (?!)

Тынгылык бирмәстер бер сорау:
"Ни өчен тамган ул, кем өчен?"
(Көфер сүз сөйләсәм, истигъфар—
гөманым бәгырьне кимерсен.)

Вәләкин уй-исәп йөртүдән
ничекләр тыелып калыйм мин?!
...Аллаһның күз яше тамгандыр
кызганып бәхетсез кавемен...

## Замана кайтавазы

Үзгәргәнме җир-күк үзәннәре—
кара көзгә охшап кайта яз.
Бәгыремдә өннәр бәргәләнә,
дөрес яңгырамый кайтаваз.

Карурманга кереп, каруымны
белдергәндәй дәшәм: "Иләмән!"
Адаштырып йөрәк авазымны,
ишеттерә шаңдау: "Ул яман!.."

Антлар эчә кемдер: "Тазиз халкым,
бары сиңа гына мин гашыйк".
Кыйтгалардан тавыш кайтарыла,
чын-хак җавап төсле: "Мөнафыйкъ!"

Чукрак кебек китеп барган затка
ялгыш кычкырганмын: "Аксакал!"

Әллә күкме күкрәп бүлә мине,
Төзәткәндәй итә: "Аһ, шакал!.."

Үзгәргәнме җир-күк үзәннәре—
кара көзгә охшап кайта яз.
Сәхраләрдә өннәр сихерләнә,
алдый сыман мине кайтаваз...

## Хөкемдар

Курай моңнар чәчсен өчен
кирәк түгел зур әфсен:
бары... артык тишекләрне
каплап кына торасың.

Халык өнсез торсын өчен
нигә уку кү-үп ясин?!
Шагыйрьләрнең авызларын
каплап кына куясың.

Туфрак белән...

## Екатерина II каретасы

*(Антигид монологы)*

*Әби падишаның арт җылысын*
*хәтерләгән затлы карета...*
*Р. ЗӘЙДУЛЛА.*

Мәскәүнең яулыклы патшасы
ул нинди кадерле тутаң соң?
Ыргытып калдырган арбасын
түреңдә өф итеп тотасың.

Күкләрдән Илаһың иңдергән
яшенле фаэтон түгел лә.
Татарым, тәлинкә тотканда
никадәр йөз суың түгелә!..

Тел төбен аңлыйсың киләме—
нигә ул калдырган арбасын?
Эшсөяр татарга алманча
боерган: җигелеп arbeiten[1]!

"Чыңгызхан токымы", хезмәттә
шулкадәр басымчак, юаш син;
балалар сабынын күбекләп,
падишаһ арбасын юасың.

Юасың гөнаһлы әбине,
(гашрәттә таплана алтын да).
Кемнәрнең пычрагын көрисең
син... сират күпере алдында?

[1]Arbeiten—эшләргә *(немесчәдән)*

Балалар сабыны юармы
көпчәккә чәчрәгән кан табын?
Карета эзеннән үткәнгә
ничә кат әйләнеп кайтамын...

Йә, җитәр. Үчләнмим. Калганы
хакында авыртсын ар башы.
...Болытлар өстендә каңгырып
йөрәдер Акмуллам арбасы...

## Бүре чакыру

...Тавыш бирә Шагыйрь еллар аша:
"Карсак япон анда исәнме?"
— Учта туфрак ташып, җирен сипли
һәм китәрә безнең ис-аңны!

Сорый Тәкъсир: "Җайлы яһүд ничек?
Бирмәс идем берсен мең ятка!.."
— Дәүләт саен дәүләт төзеп яши,
холкын сала һәрбер милләткә.

Сорау арты сорау: "Инде хәзер
чәйле кытай хәлен әйт, туган!"
— Көнләштереп кечек кавемнәрне,
иза чигә... халкы артудан...

Белә торып, газиз әһле белән
кызыксына Шагыйрь сак кына.
— Ничек итеп әйтим, татар һаман
ил-йортына бүре чакыра...

## Аерымлык

Горурланып төшендерә аталар:
"Татар" дигән сүздә, улым, "ат" та бар!

Эшли-эшли "ат казанган" татарга
ат эзеннән су да язган татырга.

Һәм азактан, менеп ап-ак пырак[1]ка,
парлап очу насыйп булган бер якка..."

Ах, шул юаш, үтсез малкай янында
йөрәк сызлый, әрни башлый җаным да.

Татар тарткан зәһәр кинә ягына —
көтеп тора үтен сытар җай гына...

---

[1]Мөселманнарны күккә очырта торган канатлы ат.

## Үкенеч

Хәйямнардан калган гамәлендә
бармак түгел, башы шешсә дә,
көне-төне, бахыр, көне-төне
шигырь язып салды ... шешәгә.

Киләчәккә агып китүләрен
теләгәндер инде бичара.
(Богауланган шампан бөкесенә
ирек бирү кебек буш чара...)

Шешәләргә салып шагыйрьлеген
агызучы синме бер садә?!
Фәрештәбез ап-ак канатыннан
язар өчен каурый бирсә дә...

## Сыналган шайтан

*(Борынгы хикәяттән)*

—Илдә шау-шу—Хаким, сине
без ничек тыңлый алыйк?!
Һәйбәт кенә ханны тагын
шайтанга тиңли халык.

—Имеш, кылган һәммә эше
җинаять, язык имди.
Мәдәт бирче, Хакның туры
юлыннан язмыйк инде.

—Таҗга нәфес сузган мәкер
иманга үтеп керә.
Һәрбер ''олтан'' үзен солтан,
фәрештә итеп күрә...

Бәргәләнгән бәндәләргә
Баш хаким әйткән актык:
''Сыналмаган фәрештәдән
сыналган шайтан артык''.

## Сәер карт

Гасыр карты, иртән торгач,
мыгырдап бер сан әйтте...
Бераз артка калган икән
иске дивар сәгате.

Ничек инде гомер бакый
төгәл йөр дә аксап ал?!
Угын борып дөресләргә
ашыкмады аксакал.

Соңгы патша сәгатенең
күтәрмәде телен дә...
Ясаучысы әйләнгәләп
ятсын, әйдә, тегендә.

Төпченүче карчыгына
кычкырды ир: "Бар, кортка!
Кыяматтә куып җитәр—
вакыт кирәк вакытка..."

## XX гасырның унөч елы

*Мин сыялмыйм... фани дөнья вакътына...*

*Г.ТУКАЙ*

...Ана җаны очып йөри күктә,
ятим улы өчен түр эзләп.
Кыска гына гомер шәме яна
йолдыз җилләрендә дерелдәп...

Җәрәхәтле үҗәт йөрәгенә
иблис груһ тора "көч" биреп.
Өлгерергә кирәк Аллаһының
вәхиләрен акка күчереп.

Унөч (!) кенә елын биргән гасыр
тупса аша аяк басканда.
Шундый кыска гомер шәме яна,
яна, яна ике баштан да!..

## Үрмә гөл җебе

Әгәр төштә упкын йотса,
өстән сихри өн иңә;
үрмә гөлнең җебе буйлап
күтәреләм өнемә.

Кысылудан, киселүдән
бәгырь өшеп, кан катса,
үрмә гөлнең җебе белән
ямау салам канатка.

Пыран-заран килсә дисбе,
өзде, димен, җен генә.
Тезәм "Аллаһ исемнәре"н
үрмә гөлнең җебенә.

Кайчак тау-тау уйлар изсә,
бушанырга телим мин,
ялгап ... яшен тамырына
җебен үрмә гөлемнең.

... Әнкәй! Рәхмәт юлларында
катлы-катлы үр күрәм.
Кабреңдәге үрмә гөлгә,
килеп, янә үреләм...

## Көлү

Гомер бакый тыеп тотты
тәнгә сыймас хөр җанын.
Хәтта аның авыз ачып
көлгән чагын күрмәдем.

Артык җитди, уйчан булды—
коеп куйган чын гарип[1].
Әйтә иде: "Көлгән саен
җитмеш шайтан чыгар",—дип.

Көлми торсаң, яман көчләр
калыр читлек эчендә (?!)
...Шулчак иблис каршы төште
һәм белгертте үчен дә:
"Гарип затым, гарешеңә
шуны белеп бара бир—
баш сөягең, күккә карап,
көлеп ятыр барыбер..."

[1]Сирәк очрый торган кеше мәгънәсендә.

## НӘСЕР ӘСӘРЛӘР

# Рауль Мирхәйдәров

# ИРТӘЛӘГӘН САГЫШ

РОМАН

## XVII

Тимерюлчыларның кырык бишенче мәктәбе. Яңа ел кичәсе. Шунда көтмәгәндә генә Рушанның Светлана Резникова белән «мәхәббәт уены» башланып киткән иде. Аңа кадәр Рушан инде өч ел ярымлап Томочка Давыдычеваны яратып йөри һәм, әлбәттә, кечкенә генә шәһәрчектә бу хакта күпләр белә иде. Һәммәсе дә күз алдында, кызыксынучан карашлардан качып та котыла алмыйсың. Хәер, Рушан качып йөрмәде дә, аннары шундый чибәр кызга гыйшык тоту күзгә аеруча ташланып тора бит ул.

Ул заманнарда укучылар хәзерге балаларга караганда җанлырак, кызыклырак яшиләр, атна саен теге яки бу мәктәптә яхшы уйланылган шау-шулы кичәләр оештырыла, аларга башка районнардан да өлкән сыйныф укучылары чакырыла иде.

Андый кичәләргә гел генә бер үк егет-кызлар диярлек дәшелә, шулар арасында—Тамара, ә инде ул кайда булса, Рушан да шунда. Кичә хуҗалары кунаклар арасыннан Тамараны шунда ук искәреп алалар һәм биергә бертуктаусыз чакырып кына торалар, әмма ничектер бик тиз, үзеннән-үзе кыз белән аңа яңа табынучылар арасында киртә барлыкка килә—зал буйлап бер дулкын тәгәрәп уза: «Рушанның кызы». «Тимерлек»тә дә, җәйге бию мәйданчыгында да, өлкә мәдәният сараенда да шулай була иде. Тамара моны белә, Рушанның үзен болай кайгыртып-күзәтеп йөрүен кайбер көннәрдә ошатып та куя.

Унҗиде без барыбыз да кемгәдер гашыйк, ул еш кына җавапсыз мәхәббәт була, яшьлек эгоизмы белән без кемнең кемне яратканын абайлап та бетермибез, ә инде күп еллар үткәч тә шуны хәтердә тоту... Ай, һай ла! Әмма Рушан белән Тамара арасындагы мөнәсәбәтләр кемнәрнеңдер күңелендә калган, ун елдан соң, Актүбәгә кайтуларының берсендә Рушан моңа раслау тапты.

Бу юлы ул «Казакьстан» кунакханәсендә тукталган һәм, үзенең «Бродвей» дигән купшы-яңгыравык исемен күптән җуйган Карл Либкнехт урамына еш кына йөрергә чыга иде. Көнгә берничә мәртәбә Пушкин паркыннан кырык бишенче мәктәпкә кадәр күтәрелә, мәктәп янгын

---

Дәвамы. Башы 8 санда.

сүндерүчеләр бинасы каршындагы тау башында, Рушан үзен яшь, дәртле, унга-сулга баш иеп, елмая-елмая сәлам биреп баручы егет итеп күрә—ул бит Бродвейда үз кеше иде. Шулай хатирәләренә бирелеп йөрүләренең берсендә аны ике кулына ике авоська тоткан яшь бер ханым туктатты да уңайсызланып кына сорады:

—Гафу итегез, әйтегезче, Тамара белән араларыгыз ничек булып бетте?—диде.

Рушанның гаҗәпләнүен күреп, ханым бөтенләй югалып калды, өстәп:

—Белмим, ни өчендер, мин сезне бик еш искә төшерәм. Мәктәптәге кичәләрдә аны күзегез белән гел эзләгәнегезне һич онытасым юк, күз карашыгыз аның янына бару юлындагы һәр нәрсәне көйдереп үткән кебек була иде. Ышаныгыз, бу минем хыял җимешем генә түгел, дус кызларым да шулай сөйлиләр иде, без сезнең өчен борчыла-кайгыра идек, Рушан,—диде.

—Рәхмәт!—дип җавап кайтарды күңеле йомшап киткән Рушан.— Нишлисең бит, ул башка кешегә кияүгә чыкты, хәзер Черновцыда яши.

Ханым бер чаттан кереп югалганчы, ул аның артыннан карап торды, хәзер дә хәтерендә бик ачык сакланган мәктәп кичәләрендәге кызларның кайсысы икәнен чамаларга тырышты, әмма... юкка гына... Ул үзе таный алмаган бу ханымның таушала төшкән төссез генә күлмәктән, үкчәләре тапталган туфлидән булуына, бәрәңге тутырылган авыр авоськаларыннан уңайсызлануын сизде, аның соравын да ни өчен кыенсынып кына биргәнен аңлады—күренеп тора: ханымның үз тормыш мәшәкатьләре дә башыннан ашкан, ә менә кирәк бит...

Гомумән, Рушан кайда гына бармасын, аның үз вакытында кемгә гыйшык тотуын беләләр, аның турылыклы булуы күңелләренә хуш килә иде. Хәер, ул заманнарда турылыклы булу батырлыкка саналмый, ә үзеннән-үзе шулай булырга тиешле гамәл итеп кабул ителә, шулай дип бәяләнә иде. Әмма ул чагында Рушанның үз хәле хәл иде. Ярты елдан техникум тәмамлап чыгасы, ә юл эшчесен нәрсә көтә? Берәр разъезд яки берәр кечкенә тимер юл станциясе—полустанок. Тамараның шунда барып яшисенә ышану бөтенләй файдасыз, хәтта хатлар алышуга өмет тә бик аз иде. Тамара аның барлыгын, үзен яратканлыгын да белә, моны шулай булырга тиеш, дип кабул итә иде бугай: кайчакларда мәктәптәге кичәләрдән үзен озатып куярга да рөхсәт итә, аның белән бии, ара-тирә чытлыкланып та ала, көтмәгәндә Рушанның бокс ярышларына да килеп чыккалый һәм бик дәртләнеп аның җиңүен теләп утыра. Ләкин боларның берсе дә Рушан көткәнчә түгел, ул бит үзенең дуслары Валька Бучкин, Ленечка Спесивцевларның, шул ук Робертның ничек итеп кызлар белән яратышып йөргәннәрен күреп тора. Аңа күз төшергән кызларга да дуслары шунда ук әйтә иделәр: ташла, аны Давыдычевадан башка беркем дә кызыксындырмый, өметсез берсөяр ул, диләр. Ул елларда аның абруе менә шундый иде.

Теге Яңа ел кичәсе Актүбәдә соңгысы булды. Җәен ул эшкә юллама алып китеп барырга тиеш һәм ваемсыз студент тормышыннан аерыласын аңлый иде. Ул инде, мәсәлән, юл мастерының, үзен кайдан табарга мөмкин булганлыгын әйтми торып, төн булсын, бәйрәм булсын—участогын ташлап китәргә хакы юклыгын белә иде. Һөнәренең үзенчәлеге шундый. Шуңа күрә, мәктәптәге кичәдән соң Жорка Стаин бер кызыклы компаниядә утырырга чакырса да, әлеге бәйрәм кичендә ул монсу-күңелсез булды.

Жорик, үзен мәхәббәт язулары белән күмеп ташлаган «14»ле саны артына кем яшеренгәнен белергә тырышып, залда әрле-бирле йөренә, ә Рушан, Тамараны биергә чакырырга кыймыйча, уйга чумып, зал колоннасына терәлеп басып тора, Тамара исә ул көнне ни өчендер аеруча көйсез-капризлы иде. «Ак бию» игълан иттеләр дә Рушанны Светлана Резникова чакырды. Аны егетләр үзара «Леди» дип йөртәләр иде. Светланка

үткен телле, тәкәббер кыз, шәһәрдә билгеле гаиләдән булып, күпләргә ошый һәм ул үзе моны белә иде.

Аны байтактан бирле күрмәгән Рушан, «Һөҗүм итеп килүче» Яңа ел белән котлады да:

—Ә Славик кайда соң?—дип сорады.

Ул мединститутта укучы егет белән бу кызның күптәнге ныклы мәхәббәтләре барлыгын белә иде. Светланка, аның иңнәренә ике кулын да салып,—элекке биюләрдә бу рөхсәт ителә иде,—шукланып әйтеп куйды:

—Ә ул мине ташлады...—диде.

—Синеме, гүзәл Леди? Моңа ышануы кыен,—дип, Рушан аның шаяртып сөйләшүенә яраклашырга тырышты.

—Чынлап әйтәм. Минемчә, без синең белән менә дигән пар. Син Давыдычевага кирәкмисең, мин—Мещеряковка, кире кагылган ике бәхетсез җан без. Йә, Рушан, ничек, гыйшык-мыйшык башлап җибәрикме әллә?—кыз ана елмаеп карый һәм муены тирәсенә бармакларын ныграк батыра иде. Аның тәненең якынлыгы, кулларының кайнарлыгы, хушбуй исләре Рушанның башын әйләндереп җибәрде.

Әллә шаяртып, әллә чынлап сөйләгәнен Рушанның төшенеп җитмәгәнен күреп, Светланка чыршы тирәсендәрәк вальска бөтерелүче парга ымлады: Славик аның күптәнге көндәше Верочка Осадчая белән бик мавыгып бии иде. Бию тәмамлангач, Светланка Рушанны култыклап алды да колонна янына китеп, аның белән торып калды. Әле монарчы бер кыз да алай карамаганча сөйкемле карап, ул Рушанның галстугын төзәтеп куйды, егет югалып китәрлек итеп, сокландыргыч елмайды да тәвәккәл генә әйтте:

—Телисеңме-теләмисеңме, Рушан, мин сине бүген әсир итәм. Кичәгә килгәндә, радиодан ишеттем: «Мәхәббәттә кимсетелгәннәр—берләшегез!»—диделәр.

Рушан, үзен шаяртумы бу, әллә җитди сөйләшүме икәнен аңламыйча, уңайсызланып елмаеп тик тора. Ярый әле, янәрына килеп чыккан Жорик коткарды—Светлана аларның бу кичәдән соң кайдадыр җыеласыларын белеп алган икән, аптырап калган Стаинга әйтеп салды:

—Жорик, Рушанга өметеңне сузма, ул бүген минеке,—диде.—Мин аны урларга карар кылдым. Бокс буенча чемпион булган егетне үземә Яңа ел бүләге итеп ала алмыйммыни мин?

Шунда гына Рушан Светланканың шаяртмаганын аңлады. Стаин кызга гаҗәпләнеп карап тора иде, үзсүзле Резникова кәефе килгәндә әле болай гына да кыланмаска мөмкин, аңа күп нәрсәләр гафу ителә. Жорик бик һаваланып: «Светлана җәмгыятьтә үзенең тоткан урынын белә»,—дип бер генә әйтмәгәндер һәм юкка да түгел: кайчандыр бу кыз артыннан байтак чабып йөрде ул, тик эше генә пешмәде.

—Курыкмыйсыңмы? Ачуы килгәндә, Славик бик усал кылана бит.—Жорик кызга сокланып карый һәм аны бераз үртәргә тели иде бугай.

—Курыкмыйм. Рушан Давыдычеваны Мещеряков ишеләрдән хәтәррәкләрдән дә саклап йөрде әле,—дип җавап бирде Светланка һәм кыланчыкланып Рушанга сыланды.

—Ну, алай булгач, мин киттем, үз йөрәк мәсьәләләрем дә бар. Яңа елны күңелле каршы алыгыз!—диде Стаин, аннары Рушанны кочаклый төшеп, өстәде:—Онытма, Татар бистәсенекеләр үзенекеләрне кыерсытырга бирмәс,—диде. Славикның Курмышта яшәгәненә ишарәләде бугай, анда да, Татар бистәсендәге шикелле үк, җыен башкисәрләр яши иде.

Яңа ел кичәсе отыры кызганнан-кыза бара, шаулашу көчәя, иркенәеп киткән егет-кызлар, курантларның төнге сәгать уникене сукканын кемнән дә булса өендә каршыларга җыенып, соңгы төркемнәргә оешалар. Әлбәттә, көтелмәгәндә барлыкка килгән Резникова-Дасаев парына игътибар итми калмадылар, әмма ул кичтә аларның мөнәсәбәтләрен кем дә булса җитди кабул иттеме икән? Резникова Славикны үртәргә тели, ә Рушан рәхәтләнеп аңа кушылып, үз ролен уйный, дип кенә уйладылар булса кирәк.

Тышта кар ява, бизәлгән чыршы әкрен генә әйләнеп тора, залда халык күзгә күренеп кими. Вакыт тыелгысыз рәвештә төн уртасына якынлашып килә, Рушанны кич буена үз янынннан җибәрмәгән Светланка боеручан итеп:

—Әйдә!—диде.—Безгә дә Яңа елны һәм «мәхәббәтебез» башлануын каршы алырга вакыт.—Шундый сүзләр белән, Рушанны гардеробка төшә торган баскычка таба йөгертеп алып китте.

Рушан Светланка аны берәр компаниягә чакырыр дип уйлаган иде,—Стаингa шатланган шикелле үк, «Леди»га да һәркайда шат булыр иделәр,—әмма кыз, күптән хәл ителгән кебек, кинәт кенә:

—Ну, хәзер безгә кайтабыз, анда әзер өстәл безне көтеп тора...—диде.

Рушанның йөзендә гаҗәпләнү күргәч, елмаеп аңлатты:

—Әйе-әйе, әзер өстәл. Яңа елны синең белән каршы алачагыма ышандым, син минем анлы рәвештә һәм күптән сайлап алган корбаным! Кызганмыйсыңмы?

Рушанның каушап калуыннан тәм табып, өстәде:

—Вөҗданың газапланмасын өчен әйтеп куям—төгәл беләм: Давыдычеваның Яңа ел планнарында сиңа урын юк. Шушы көннәрдә ул миңа шылтыраткан иде, бер сәгать буе сөйләштек. Дөрес, мин аңа Славик белән ачуланышканыбызны да әйттем, әмма үземә кирәклесен дә сөйләштем. Хәзер аның җен ачулары чыкканын күз алдыма китерәм—сине бит әле беркемнең дә алып китә алганы юк иде. Әмма безне мәктәптә: «Тормыш—көрәш ул»,—дип өйрәтәләр бит. Син мине гаепләмисеңме, Рушан?—Шул сүзләрдән соң, ул салкынча куллары белән аның башыннан тотып алды да кайнар итеп үпте.

Резниковлар мәктәптән ун минутлык юлда торалар иде, болар, Карл Либкнехттан Орджоникидзе урамына борылып, вокзал ягына таба түбәнгә ашыктылар, шунда «Тимерлек» каршысында, бер нәрсә дә күренмәслек биек койма артыннан күзгә бәрелерлек аерым бер йорт күтәрелеп тора. Искиткеч Яңа ел төне—бераз салкын да, йомшак кына кар да ява, Светланка юл буе шаярып кайтты: Рушанны әле көрткә төртеп аудара, әле кар атыша башлый, әле кардан кеше сыны ясарга азаплана. Һәр агач яны саен диярлек туктап үбешәләр, үбешкәндә Рушанга кызның газетка төрелгән лаклы биек үкчә—«шпилька» туфлиләрен кар өстенә куеп торырга туры килә. «Тимерлек» ишегалдындагы шугалакта бизәлгән чыршының аллы-гөлле утлары балкый, төрле төстәге матур-матур спорт костюмнары кигән үсмерләр төркеме шуның тирәсендә ипле генә итеп тимераякта шуа, бу күренешкә бары тик музыка гына җитми, әмма үсмерләрнең шатлыклы көлү тавышлары, чыркылдашулары, якынлашып килүче Яңа ел куанычыннан әсәрләнеп кычкырынып куюлары ерактан ук ишетелеп тора иде...

Яңа ел төнендәге шул матурлыкны-рәхәтлекне Рушан йөзләрчә мәртәбә исенә төшерә, төшергән саен янадан-яңа ваклыкларын ача. Кайвакытларда кешенең барлык гомере берничә минут эчендә күз алдыннан үтеп китә икән, дип сөйлиләр—бәлки, шулайдыр да, әмма Рушанга шул унбиш минутлык юл әкренләп бөтен гомере озынлыгына сузылган шикелле тоела иде.

Ул саташкан кеше төсле атлый, кайчагында Светланкага әйле-шәйле җавап кайтара, бу иркәләүчән-ягымлы сүзләрнең, кайнар үбүләрнең үзенә икәнлеген ахырынача аңлап та бетерми иде бугай. Ул бервакытта да мондый гамәлләрдән баш шулкадәр әйләнер, йөрәк кагар, дип уйламаган иде, вакыт-вакыт аңа болар барысы да матур төш кебек тоела: тәкәббер Светланка, күпләр хыялланган, буй җитмәс Леди аның белән бит...

Кыз, ишекне үзендәге ачкыч белән ачып, аны өйгә керергә чакырды. Рушанның ишек төбендә югалыбрак торганын күреп, әйтте:

—Без ялгыз. Әти-әниләр кунакта, иртән генә кайтачаклар, Яңа

елны бабайларда каршы алу—гаилә гадәте. Ут әйдә,—дип, ул залның пыяла ишеген ачып җибәрде.

Рушанның каршысында, нәкъ бизәлгән чыршы турысында биек түшәмгә эленгән авыр люстра балкып кабынып китте. Түшәмдәге меңләгән бәллүр кояшлардан чыршы өстенә җем-җем нурлар коела шикелле иде— тәүге мизгелдәге бу сихри күренеш тә аның хәтерендә озакка уелып калды.

Гаҗәп, диварлардагы шәрекъчә авыр келәмнәре, карала төшкән кызыл агач корпуслы галәмәт зур идән сәгате,—ул тавышсыз йөреше белән, мөгаен, бу йорттагы ритмны озак еллар саклап тора торгандыр,— үзенә таныш булмаган сирәк китапларның алтын хәрефле төпсәләрен ялтыратып утырган китап шкафлары, ике тәрәзә арасында бәллүр бокал һәм фужерларда люстра утларын һәм җинел чыршы уенчыкларының елтыравын чагылдырып, чәй сервизы көмешенең тоныи җемелдәвен үзенә җыйган серванты булган бу залны Рушан минут эчендә тулысы белән күздән кичереп өлгерде.

Чыршыдан бераз арырак крахмалланган ак эскәтер ябылган өстәл өстенә матур итеп табын әзерләнгән, анда салаттыр-кабымлыклардыр тезелгән. Әмма Рушанның күзенә иң элек биек ике ваза ташланды: берсендә—эре-эре алтынсу мандариннар, икенчесендә—Алма-Ата апорты, шулай ук эреләр, кып-кызыллар! Шуннан бирле Рушан Яңа елны гел алма исенә охшатып күзаллый. Ул инде дүрт ел буе Депо урамындагы тулай торакның сигез кешелек бүлмәсендә тора, шәһәрдә ул барып йөри торган бердәнбер йорт Почта урамындагы 72 нче йорт—анда аның дусты яши иде. Шуннан башка йортларга аның кереп караганы да булмады.

Беренче минутлардан ук ул Резниковлардагы ямьлелек-унайлыкны, җылыны һәм ышанычлылыкны тоеп алды, Светланканың нәкъ менә шундый тормышта, сирәк очрый торган нәфис чәчәктәй, сөенеп һәм кайгыртучанлыкка төрелеп яшәгәнен алдан фаразлаганда үзенең ялгышмаганын күреп, куанып куйды. Ул заманнарда үзең яратып йөргән кызның өендә булу яхшы гамәлләрдән санала—кечкенә шәһәрнең гөнаһсыз элекке гадәтләре иде ул. Рушан үзенең бәхет сәгате сукканын аңлады, аны бит «1905 ел» урамындагы ялгыз йортка беркем дә, беркайчан да чакырмады һәм бу хәл әлеге төн өчен шактый әһәмиятле иде. Бу бәхет бик кинәт, көтмәгәндә һәм күз ачып йомган арада бик тиз ишелеп төште, чынлап та—Яңа ел сюрпризы!

Ул әле барысын да күздән кичереп, күнегеп тә өлгермәгән иде, Светланка кинәт кенә әйтеп куйды:

—Залның иркенлеге дә, бу галәмәт зур өстәл дә минем эчемне пошыра. Әгәр дә без минем бүлмәгә күченсәк, син каршы килмәссеңме?..— диде.

Әле һаман да аңына килеп җитмәгән Рушан, зиһенсез калгандай, баш кагып кына куйды һәм утырган кәнәфиеннән кузгалды.

Кызның бүлмәсе дә шактый зур, тәрәзәсе ишегалдына карап тора икән, ул зал белән тоташкан булып, ярым ачык калган ишектән караңгыда гирляндаларын җемелдәтеп балкып утыручы матур бизәлгән чыршы бик яхшы күренә иде. Тәрәзә каршындагы диварны биләп торган китап шкафлары арасына уңайлы почмак итеп күн тышлы ике тирән кәнәфи һәм яшел постау белән тышланган тәбәнәк өстәл куелган. Борынгы кәнәфиләрнең берсенең баш очында бронза торшерның гаҗәеп нәфис пыяла абажуры бөгелеп төшкән. Рушан шунда ук Светланканы шул иркен кәнәфигә, кулына китап тотып, аякларын бөкләп менеп кунаклаган һәм хәтта тәбәнәк агач караватына ябылган авыр шотланд шәленә төренгән итеп күз алдына китерде.

Әмма Рушанны ниндидер бер эчке сиземләү сагаерга мәҗбүр итте. Кызның күпертеп-кабартып ике мендәр куелган урын-җиреннән үзенең хәвефле карашын өскәрәк күтәргәч, ул шунда елмаеп торган Мещеряковның диварга кнопка белән генә кадап куелган зур фоторәсемен күреп

алды. Ул шулкадәр югалып калды ки, күзләрен шул фоторәсемнән һич ала алмый торды, шул минутта бүлмәгә эскәтер тотып килеп кергән Светланка, аның каушап калуын күргәч:

—Анысы әни эше, аның мәкерле гамәле. Кайдандыр үзе яраткан Славикның рәсемен табып алган бит. Күрәсең, миңа Яңа ел сюрпризы ясарга теләгәндер инде,—дип аңлатырга кирәк тапты һәм, фоторәсемне шунда ук йолкып алып, ерткалап ташлады.

Аннары, Рушанның иңнәреннән кочып, хәйләкәр генә елмаеп карады да:

—Синең шундыйрак фоторәсемең булмавы кызганыч, юкса мин дә әнигә җавап сюрпризы ясаган булыр идем,—диде.

Кыз теләсә нинди киеренке хәлне йомшарта белә иде һәм Рушан ул әйткән сүзләрнең дөреслегенә тамчы да шикләнмәде—Леди ихлас туры сүзлелеге белән аерылып тора, аның ягымлылыгы да шунда иде. Алар бит еш аралашалар, бер-берсен яхшы беләләр һәм Светланканың Рушанны сайлап алуы да минутлык каприз гына булмагандыр әле, бәлки.

Биек идән сәгатенең саңгырау-тоныклык итеп сугып куюы Яңа ел җитәргә чирек сәгать кенә калганын искәртте, Светланка Рушанның үзенә булышуын үтенде. Алар икәүләп залдагы бәйрәмчә өстәлдән сый-ниглъмәтләрне тиз-тиз генә кызның бүлмәсенә ташыдылар, уникe тулырга биш минут кала Светланка торшер кебек үк авыр бронза шәмдәлдәге шәмнәрне кабызып җибәрде, күзләре белән шампан шәрабенә ымлап, дулкынланып әйтте:

—Моннан бер атна элек мин нәкъ шушылай булыр дип уйлаган идем, хыялым тормышка ашканына шатмын. Яңа ел котлы булсын, Рушан!—диде.

Алар бокалларын чәкәштергәндә, бәллүр чынына караңгы залдагы сәгать суккан тавыш кушылды.

## XVIII

Ул Яңа ел төне, Резниковлар йортына кайту юлы еллар аша Рушан тормышының зур һәм мөһим бер өлеше булып кабул ителә. Үзенең анда алты сәгать булганын хәтерләсә дә, әмма бусагадан атлап кергәненнән алып чыгып киткән минутына кадәр ул кичне истәлекләрендә Светланка белән үткәрә алмый интегә ул. Барыбер ул очрашуны тасвирлап бирү өчен бөтен бер роман кирәк булыр, ул бернинди телесериалларга да сыймаячак, чөнки ул төннең онытылган сүзләре, төсләре һәм төсмерләре, ымнары һәм карашлары, тавышы һәм кыштырдаулары, исләре һәм музыкасы хәтердә еллар аша калкып чыга тора. Ләкин кем дә булса берәр вакыт гүзәл Леди йортында үткәргән Яңа ел төненең хронологиясен язарга мәҗбүр итә башласа, Рушан булдыра алмас иде... Тик ни өчен? Бөтен вак-төягенә кадәр хәтерли, ул сихри очрашуны гомере буе күңелендә йөртә икән, ни өчен яза алмый? Нәкъ менә шунысы сер дә инде, мәхәббәтнең теләсә кемгә ачылмый торган тылсымы, шул мәхәббәтнең сихри сулышын тоярга насыйп булса да, Рушанга да ачылмады ул. Күңеле каткан берәрсе, мөгаен, әйтер: агуланган бу, дияр. Гел шулай булсын. Яки алай булмасын. Яки бөтенләй алай түгел...

Ничектер бер җыелышып утырганда мәхәббәт турында сүз чыкты, Рушан бу сөйләшүгә катышмады. Әмма кайтып барганда, күрәсең, әле кайнар бәхәстән суынып җитмәгән булгандыр, иптәше кызыксынып сорады:

—Ә синең тәүге мәхәббәтең нинди иде?

Рушан шунда ук «1905 ел» урамындагы яшәүче кызны исенә төшерде һәм уйлап та тормыйча:

—Матур. Бик матур!—дип җавап бирде.

—Җавап түгел бу, артык гомуми,—дип көлеп җибәрде иптәше.—Аяклары нинди иде аның, күкрәкләре?

Рушанның озакка тынып калганын күргәч, иптәше, Дасаев үпкәләде, ахрысы, дип уйлады, әмма Рушан үпкәләмәгән, ә бөтенләй башка сәбәп белән җавап бирмәгән иде.

Рушан ул кызның аяклары, күкрәкләре нинди булганлыгын әйтә дә алмый, ул турыда бервакытта да уйлаганы да булмады. Дөрес, ул аның зур, дымлы назлы күзләрен хәтерли, тагын матур авызы читеннән аз гына өстәрәк, уң ягындагы мөлаем мине турында әйтә ала, аның ничек көлгәне, карашларының нинди уйчан булганы, кашларын ничек итеп җыерганы, нинди серле елмайганы турында озаклап сөйли ала, әмма аяклары, күкрәге турында... Юк, ул аларны хәтеренә төшерә алмый, «Тимерлек» каршындагы ялгыз йортта үткәргән төнне дә тулысы белән хәтерли алмаган шикелле, хәтеренә төшерә алмый—монысы да мәхәббәтнең серләреннән берсе булса кирәк.

Һәркем Яңа елдан уңышлар, шатлык-куанычлар, күптәнге теләкләренең үтәлүен көтә, бигрәк тә мөстәкыйль зур тормыш бусагасында—Рушан ул елны диплом, Светланка аттестат аласы иде. Шулай килеп чыкты инде, нindидер сихри серлелек төсмере булган һәм кешеләр өметләрен баглый торган шул бердәнбер бәйрәм төне алдыннан алар икесе дә, Светланка әйткәнчә, «кире кагылган ике бәхетсез җан» иделәр. Әйе, ничек кенә сәер тоелмасын, шулай килеп чыкты, юкса Рушан белән дә, Светланка белән дә танышырга, дуслашырга тырышып йөрүчеләр күп иде. Юк, Резникованың ул төнне Рушанны сайлавы да очраклы түгел, Яңа ел кичен Леди белән үткәрүдән, аңа әсирлеккә төшүдән баш тартучы бер генә егет тә табылмас иде.

Светланка Резникова бер генә нәрсәне исәпкә алып бетермәгән бугай—Давыдычевага өметсез гашыйк булган Рушан Дасаевның әле моңа кадәр бервакытта да андый дулкынландыргыч сүзләрне ишеткәне, үзенә төбәлгән ягымлы күз карашларын тойганы булмады, әле бервакытта да кайнар кулларның иркәләвеннән кызлар кебек кызарынганы, татлы иреннәрнең үбешеп алуыннан тынсыз калганы юк иде.

Кыз күңелендә озак өлгергән, инде артык саклап булмый торган ул сүзләрнең, үбешү-кочышуларның үзенә түгел, ә бөтенләй башка берәүгә багышланган булуын Дасаев бер мизгелдә дә уена китерә алмый иде. Башкаларга бәхет һәм мәхәббәт вәгъдә иткән бу бәйрәм кичендә сагыштан һәм ялгызлыктан кызның йөрәге өзгәләнә иде, шунда менә Рушан килеп юлыкты—таныш, кайгылы-моңсу, ялгызы. Мөгаен, аның белән булган бу «мәхәббәт уены» төрле сүзләр китереп чыгарыр һәм Светланканы кызганудан туктарлар... Бәлки, бу хәлләр бөтенләй алай да булмагандыр, әмма Рушан хәзер, нәкъ менә шул сәбәп Резникованы үзенә этәргәндер, дип уйлый.

Светланканың сүзләрен, ым-хәрәкәтләрен, үбү-кочуларын барыннан да бигрәк озак һәм мул яуган карлы тауларда кычкырып җибәргән тавышка яки кайнап торган мартен мичен кисәү тимере белән бәреп ачуга тиңләп булыр иде—һәр ике очракта да ташкын хасил була: кар ташкыны яки ут-ялкыннар бөркеп торган кайнар металл ташкыны, аларны беркем дә тыя-туктата алмый. Рушан белән дә шундый хәл булды: еллар буе җыелып, чыгар урын тапмый яткан теләк-дәрт, татлы наз, сөю хисе шул төндә бәреп чыкты, йөрәге яралы Светланка сызланган күңеле ишетергә-тоярга ашкынган сүзләрне ишетте, хисләрне тойды. Кыскасы—мәхәббәт өчен ачык ике йөрәк очрашты.

Алар шампан шәрабеннән исермәделәр, ул төбенә кадәр эчелеп тә бетмәде бугай әле, аларны бер-берсенең ягымлы сүзләре, эчкерсез карашлары, ым-ишарәләре, саф уй-теләкләре, күңелләренең көтелмәгәнчә якынлыгы исертте. Мөгаен, моңа музыка да ярдәм иткәндер. Ул Яңа ел төнендә караңгы чия төсендәге шотланд шәлле, кайнарланып эреп аккан шәмнәр белән генә яктыртылган бүлмәдә төрле музыка яңгырады, әмма еш рак минор-моңсу музыка иде, алар яраткан Элвис Пресли ул кичтә кирәк булмады.

Ул төннең иң асыл мон-аһәне дә табылды: ул кыш тормыштан иртә киткән легендар Батыр Закировның атаклы «Гарәп тангосы» кышы булды. Алар залдагы жем-жем итеп торган чыршы тирәсендә әнә шул көнелләрне өзгәләндерерлек сагышлы тангога кушылып биеделәр, мәхәббәт алиһәсе Афродита үзе аларга елмаю бүләк итә шикелле иде, ул төндә, мөгаен, алардан да бәхетлерәк гашыйклар булмагандыр.

Һәммәсе дә, махсус сценарийдагы шикелле, алар арасындагы мөнәсәбәтләрнең бик тиз тирәнәеп үсүенә булыша, күтәренке бәйрәм хисе әле бик озакка сакланып калган иде. Мәктәпләрдә каникуллар башлана, димәк, ике атна рәттән «Тимерлек»тә, Өлкә мәдәният йортында, бертуган Лариннарның джаз-оркестры уйнап торган «Большевик»та, һәрбер мәктәптә Яна ел бал-кичәләре дәвам итә, дигән сүз. Алар бөтен гыйнварны диярлек бәйрәм итеп, жырлап-биеп, күнел ачып уздырдылар, чөнки әле өч-дүрт туган көнгә дә чакырулы иделәр, Стаин да үзләрендә үткәргән мәжлесләргә ике мәртәбә дәшеп алды.

Алар һәр көнне күрешеп, бик озак сәгатьләрен бергә үткәрделәр. Кайвакытларда тулай торакта телефон шылтырый, Светланка дулкынланып әйтә: «Кил, сагындым...»—ди. Рушан, диплом эшен бер якка ташлап, яшел такта коймалы ялгыз йортка чыгып чаба. Сүз уңаеннан әйтеп үтик, үз гомерендә ятлап алган беренче телефон номеры Резниковаңыкы иде, ул аны хәзер дә хәтерли әле: 3-32.

Ул чагында Рушан өчен күп нәрсәләр беренче булды. Февраль башларында аларның шәһәренә беренче мәртәбә Әзәрбәйжанның Рәүф Гаджиев житәкчелегендәге Дәүләт эстрада оркестры гастрольләргә килде. Артистлар килеп бик узындырылмаган шәһәрнең халык күп йөри торган урыннары ачык төсле буяулы матур афишалар, оркестрның, жырчыларның, биючеләрнең, ул заманнарда танылган конферансье Лев Шимелев һәм Гаджиевның фоторәсемнәре белән бизәлде. Концертка эләгеп булмас шикелле иде, әмма Роберт ярдәм итте—аларга билетлар табып бирде, әле житмәсә беренче рәткә үк, ә ул үзе инде дүрт концертка да барып, оркестрантларның барысы белән дә танышып беткән иде.

Рушан телиме-юкмы, Резникова белән булган «мәхәббәт уены» аның хәтерендә гел бәйрәм генә булып яңара—шулай килеп чыккан инде. Алар Өлкә мәдәният йортының концерт залында беренче рәттә утыралар, ә алар каршысында сәхнәдә ярым түгәрәкләнеп, түшәмгә кадәр үк диярлек дүрт катланып зур оркестр урнашкан—бәйрәм түгелмени бу? Бик оста яктыртылган сәхнә, караңгыда юпитерларның жемелдәве, көмешсу трубалар, оркестрантларның күз явын алырлык жилетлары һәм кара фраклары, саксофоннарның алтынсу авызы, иң югарыдагы уен коралларының елык-елык килеп торган жизе һәм барабаннарның утлы перламутр кысалары. Һәр бүлектә алышынып торган үз пәрдәләре, һәр яңа артист чыккан саен шулай ук алышынып торучы матур рәсемнәр, концерт программасындагы чын театраль декорацияләр—дөнья эстрадасы йолдызлары аларга бүген генә ирештә әле.

Фантастикамы? Хәзерге бөтен нәрсәне артык гадиләштереппримитивлаштырып бетергән заманда, әйе, шулайдыр. Әмма Рәүф Гаджиев оркестры, аннан кала тагын соңрак Рушан үзе тыңлаган, үзе күреп белгән берничәсе, мәсәлән, Әрмәнстаннан Орбелян, Тбилисидән Гобискерия, Мәскәүдән Лундстрем, Ленинградтан Вайнштейн оркестрлары, Кроллның теләсә кайсы джазы профессиональлыкта, осталык-маһирлыкта Поль Морианың иркә артистларыннан, ай-һай, калышырлармы икән?

Бу шулкадәр күптәнге хәл, әле ул чакларда хәзер инде байтак еллар элек таралып юкка чыккан «Гая» вокаль квартеты да юк, ә Тимур Мирзоев, Рәүф Бабаев, Левка Елисаветский, Ариф Гаджиевлар бары тик бергә жырлыйлар иде. Ул вакытта әле, мөгаен, Лева да үзенең жырларында данлаган, яраткан Бакуын кайчан булса да ташлап китәчәге турында уйлап та карамагандыр. Ә хәзер оркестрның төп жырчысы Октай Агаевның лирик тенор тавышын кем генә хәтерли икән?

Ләкин Рушан һич оныта алмый: ул вакытта Михаил Винницкий: сәхнә кырыена ук якынаеп, залга таба аз гына иелде дә, туп-туры Светланкага карап, моңлы җырның кушымтасын кабатлады: «Килерсеңме син?.. Килерсеңме син?...», ә кыз үзе дә белештермәстән Рушанга сыенды, җырчының партердагы тамашачылар арасыннан нәкъ менә аны аерып алып җырлавы дулкынландырган булгандыр...

Дасаевның студентлык елларындагы соңгы кышы шулай тәгәри бирде һәм ул, ниһаять, бәхетле иде. Март башында ике атналык диплом алды практикасы башланасы һәм ул әле җәйдән үк аны үзләрендә, Мартукта үткәрәсен белә иде. Хәер, шәһәргә ул бер атнадан кайтырга тиеш—Казакъстан тимерюлчылары җыелма командасы составында Мәскәүгә, «Локомотив» беренчелегенә бокс ярышларына китә иде.

Китәр алдыннан сөйләшенеп-килешенеп куйдылар: Светланка һәр кичке поезд белән хат биреп җибәрәсе булды—ул заманнарда һәр пассажир поездында почта вагоны бар һәм түземсезләр шуннан файдалана иде.

Дымлы март ае, тып-тып тамган тамчылар, күзгә күренеп басылаиңә барган кар көртләре, урамда хат ташучыны көтеп торулары хәтеренә уелып калган. Почтальоншаны еракган ук күреп алып, ул аның каршысына йөгерә, озак көтелгән хатны бер минут булса да алданрак алырга тели иде. Әмма... әмма...

Ничек сөйлим ерак калган,
Онытылган ул язымны?
Ничек онытыйм синең йөзне?
Онытып булмас ул назыңны...

Белмим инде, белмим, нигә
Салкын бу яз? Юеш, төксе.
Яз булса да, миңа әле
Һаман озын кышлар төсле.

Язгы сулар ташып агар,
Шатланышып кошлар кайтыр...
«Синең дә язың кайтыр,»—дип,
Миңа инде кемнәр әйтер?

Хәтерлимен паровозның
Озын, моңсу тавышларын...
Без ул язда сөешсәк тә,
Үкенеч шул—кавышмадык...

Ә Рушан үзе, килешенгәнчә, көн саен төнге поездга йөгереп бара, йокылы почта вагонының ярыгына хатын төшереп җибәрә дә, паровозның салкын төнге караңгы күккә очкыннар сипкәнен карап тора.

Төн, буш перрон, кешесез урамнар, әкрен генә кузгалып киткән поездның якты тәрәзәләре... Шул төнге сәгатьләрдә нәрсәләр генә уйлап бетермәде икән Рушан!

Шәһәргә китәр алдыннан соңгы көнне ул, гадәтенчә, почтальоншаны көтеп тора иде, тегесе, аны ерактан ук күреп, кулындагы ак конвертны болгады. Рушан сикеренә-сикеренә аның каршысына чапты. Түземсезлек белән көткән хат дигәне телеграмма бланкысы булып чыкты—«Локомотив» аны ашыгыч рәвештә үз байрагы астына чакыра, Мәскәүгә китү өч көн алданрак буласы икән.

Мөгаен, Мәскәүгә китеп барганчы, шәһәрдә берничә сәгать буш вакыты табылу яхшы да булгандыр—Светланка белән телефон аша сөйләшеп, ул аның тәки Мещеряковка кияүгә чыгачагын белде. Кинәт кенә башланган «мәхәббәт уены» шулай ук көтмәгәндә генә өзелде дә куйды...

Бүген Дасаев үзе саксыз үпкәләткән бик күп кешеләрдән, «Локомотив» беренчелегендә чемпион булып, үзе рингта җиңгән егетләрдән, соңлап булса да, гафу үтенер иде. Тимерюлчыларның спорт сараенда үткәргән ике атна эчендә аңа усал кушамат тактылар: «Кансыз»... Ярый әле, бәхеткә, ул кушамат шунда Мәскәүдә үк үлеп калды. Ул бит анда һәркемгә дә йөрәге өзгәләнгәнен сөйләп йөри алмый иде инде... Кемдәдер аның турында «тумыштан рәхимсездер бу» дигән тәэсир калган булса, бик кызганыч.

Алар Мәскәүдән апрельдә генә әйләнеп кайттылар. Инде яз тулы хакимлек итә, Бродвейгә җан кергән, шунда һәр көнне Стаин Никанор атакай белән һава суларга чыгып йөри иде.

Аның «Локомотив» беренчелегенә ярышлардагы уңышын шәһәрдә

инде беләләр, Резникова белән кинәт башланып, көтелмәгәндә өзелгән гыйшык-мыйшыклары да онытылган, күләгәдә калган иде. Рушанны беркем дә юатмады, кайгысын уртаклашкан булып кыланып маташмады, барлык танышлары да ул «мәхәббәт уенын» Резникованың капризы яки Мещеряковны үзенә кайтару өчен ясалган бер адымы дип кенә кабул иткәннәр, күрәсең. Ә бәлки, Светланканың булачак табиб белән ике арадагы мөнәсәбәтләренә дә, Рушанның Давыдычева белән булган дуслыгына караган кебек, житди караганнардыр. Гомумән, һәммәсе дә бу хәлне бернәрсә дә булмаган шикелле кабул иттеләр. Ә Рушанның мәхәббәт сулышын тойган йөрәге сызланып өзгәләнә, әле шуның өстенә ул, яшьлеккә хас югары таләпләрдән чыгып, үзен Тамарага хыянәт иткән кебек тә сизә иде. Кыскасы, Рушан бөтенләй буталып бетте, бервакыт тулай торакка кайтып барганда, уйларына батып, онытылып, ул хәтта янадан «1905 ел» урамындагы йортның тәрәзәсе каршысына барып чыккан иде...

Вакытны «бишьеллыкны—өч елда», «бер ел—ике елга» дип исәпләү дөньяда беркайда да юктыр, мөгаен. Беренче очракта бу гыйбарә идеологик мәгънәгә, ә икенчесендә—җинаятьләргә карата әйтелсә дә, совет кешеләре өчен асылы ачык иде. Ул язда Рушан белән аның дуслары өчен дә шундыйрак хәл туды: алар бик тыгыз, тулы тормыш белән яшиләр, һәр көн ниндидер ачышлар китерә, кайбер көннәрне айга тиңләргә дә булыр иде. Алар үзләре өчен дөньяны да, үз-үзләрен дә ача торалар һәм ул вакытта барысы да тәүге тапкыр иде.

Светланкадан бер сыйныф түбән укучы Тамара көтелмәгәндә Резникованың сыйныфташы Наил Сафин белән очраша башлады. Наилнен—бик тыныч-иплe, чирләшкә, «йорт куяны»ның кинәт кенә Тамараны мәктәптән озата кайтып йөрүен сәгате-минуты белән Рушанга җиткерделәр.

Әмма хәзер, Резникова белән булган «мәхәббәт уены»ннан соң, ул үзен, моңа кадәр кыланган шикелле, алар арасына тыкшынырга хаклы түгел дип санады, аннары Наилне дә житди кабул итү көлке булыр иде, монда да, мөгаен, Резникова белән булган очрактагы кебек, берәр төрле сер, табышмак булгандыр.

Вакыйгалар бик тиз үзгәреп тора, ул бары шуны гына абайлап алды—Светланка Рушан булырдай компанияләрдән бик оста гына кача белә, ул үзе дә ни өчендер кыз белән очрашудан курка иде. Аның кәефе бик начар, «гүләйт итеп» йөрерлек түгел, шунлыктан, тырышып-тырышып диплом эшен эшли, бокс буенча шәһәр беренчелегенә ярышларга әзерләнә, финал уеннары, элекке күпьеллык гадәт буенча, парк ачылган көнне үтәргә тиеш иде.

Шәһәр боксчылары җиңү яуларга омтылган мондый ярышлар башка юк. Теләсә кайсы данлыклы спорт җәмгыятенең—«Спартак»ныңмы, «Динамо»ныңмы чемпионы бул, республикада һәм хәтта илдә призлы урыннар яула—барыбер, шәһәр бары тик үз чемпионнарын гына таный. Җиңүчеләр бөтен җәй буена кумирга әйләнәләр, ә парк администрациясе һәр җиңүчегә бию мәйданчыгына сезон беткәнче бушлай кереп йөрү хокукы бирә торган жетон тапшыра. Оркестр аларның күнеленә хуш килгән көй-музыканы кабатлап уйный, ә кырыс вахтерлар, жетон иясе унайсызланып кына: «Бу кыз—минем белән...»—дигәндә, кунакчыл елмаеп каршы алалар иде...

## XIX

Әйе, ул язда һәртөрле вакыйгалар күп булды—шатлыклылары да, моңсулары да, кирәге дә, кирәкмәгәне дә.

Бервакыт Рушанга шәһәр уртасында бер сугышта катнашырга туры килде. Кирәк бит, нәкъ шул чакта алар өстенә тыкрыктан Тамара белән Наил килеп чыкты. Соныннан, куркып калган кызый Наилгә: «Шушы бандит минем арттан йөреп маташты бит әле...»—диган, имеш.

Рушан үзен гаепле итеп тоймаса да—чөнки сугышмыйча булмый иде,—Тамараның күзенә күренергә бик озак куркып йөрде. Шулай да...

Ул елны урысларның пасха бәйрәме апрель азагына туры килгән иде. Ә аннан бер ел элек кенә аларның мәхәлләсенә—урысча әйтсәк, приходларына яна поп билгеләгәннәр иде, монысы элгәренә караганда яшь һәм чибәр генә түгел, бик эшлекле дә булып чыкты—шәһәр приходына җан керде, әлеге дини бәйрәмне беренче мәртәбә шулай зурлап үткәрделәр. Ул якшәмбедә Рушан «Тимерлек»тәге китапханәгә кереп чыккан иде, шуннан Орджоникидзе урамыннан Бродвейга күтәрелергә булды. Менә шунда ул бертуган Дроголовларны очратты, аларны «дроголята» дип кенә йөртәләр, Мәскәү бистәсенен башкисәр ышпаналары инде, Рушаннарның тулай торагы да шул төбәктә бит. Билгеле, алар бер-берсен яхшы беләләр иде.

«Дроголята» инде иртәдән үк дуслары һәм танышлары белән бераз төшереп өлгергәннәр, кәефләре әйбәт. Рушанның кая юл тотканын белгәч, үзләре дә Бродвейдан бер әйләнеп кайтырга булдылар— ни әйтсәң дә, бәйрәм ич!

«Дроголята»ларның ике өлкәне инде берничә мәртәбә утырып та чыккан, аларны Рушанның Гомәровлар өендә дә очратканы бар, еш кына җәйге ресторанда Шамил һәм Исмәгыйль белән утырганнарын да күргәли иде, алар шәһәр халкына да яхшы ук билгеле. Ә «данлыклы» абыйлары канаты астында үскән кечкенәләре үз урыннарын белә һәм барыннан да бигрәк абруйларын—«репутацияләрен» саклыйлар, вак-төяк белән чуалып маташмыйлар иде.

Кичәге футбол уенында Стаин «Локомотив»ка җавапсыз өч туп керткән, шуның шатлыгыннан Татар бистәсе егетләре төне буе гөр килеп йөргәннәр иде. Шул турыда кызып сөйләшә-сөйләшә, болар Яна ел төнендә Рушан Светланка белән үбешеп торган агачлар яныннан үтеп, Орджоникидзе урамыннан менеп баралар иде. Каршыларына, вокзалга таба төшеп килүче дүрт егетне Дасаев ерактан ук күреп алды. Егетләрнең, кулларын бутый-бутый, шаулашып сөйләшү, кычкырып-кычкырып көлүләреннән пасханы билгеләп «авыз ачканнары» күренеп тора. Үзләре шактый өлкән дә күренәләр.

Әгәр бер-беренә юл сапмасаң, тар тротуардан үтеп китәрлек түгел, әмма Рушаннан кала ни теге яктан, ни бу яктан берсе-бер андый адым ясарга уйлап та карамады, алай гынамы әле, әллә ялгыш, әллә юри тегеләрнең берсе Дроголовларның кайсынадыр җилкәсе белән төртеп тә узмакчы булды. «Дроголенок»нын усал ялтыраган күзләрен күреп, әлеге егет мәсхәрәле итеп, теш арасыннан сыгып чыгарды:

—Нәрсә, козел, карап каттын? Өлкәннәргә юл бирә алмыйсыңмы?

Әгәр дә җинаятьчел дөньяда иң мыскыллау сүзе булган «козел» сүзе урынына теләсә нинди башка сүз әйтсә дә, бәйләнешеп китмәсләр иде шикелле. Әмма мондый сүзне үткәреп җибәрергә, әйтүчесен җәзасыз калдырырга мөмкин түгел иде.

Шулай да, эшне зурга җибәрмәскә теләп бугай, Дроголов сорап куйды:

—Кабатла әле, ишетеп житкермәдем...

Теге егет, төшереп алган дусларының гайрәтләндерүен сизенеп, «козел» сүзенә басым ясап, әйткәнен кабатлады. Дроголовларга гына түгел, Рушанга да ачык иде: бу мәсхәрәле җавап сугышчан быргы сигналы булып янгырады—мондый мыскылны, әле житмәсә кешеләр алдында, алар күтәрә алмадылар.

Нәкъ менә шул, сөйләшеп-нитеп тормастан, үзләрен мыскыл итүчеләр өстенә ташланган минутта гына чаттан Тамара белән Наил килеп чыкты...

Сугыш тротуардан юлга күчте, сан ягыннан да артык булып, бу манка малайларны тиз генә акылга утыртачакларына ышанган таза егетләр хурлыклы төстә бик каты кыйналдылар.

Бөтенесе дә бик тиз, берничә минут эчендә булды. Дроголовларның берсендә күзгә ташланмый торган җинел плексиглас кастет бар икән, шунын белән китереп суккач, тегеләрнең берсе дә аягында басып кала алмый. Тротуарга һәм урам чатына җыелып, авыз ачып карап торучылар үтә күренмәле тар гына кастетны абайлый алмаганнардыр, ләкин Рушан андый көчле сугунын сәбәбен шунда ук анлап алды.

Аларга теләктәшлек белдереп торган кемдер: «Атас! Милиция!»— дип кычкырды. Рушаннар күрше ишегалдына кереп югалдылар.

Сугышкан чагында Рушаннын күзенә Тамараның куркынган йөзе чагылып китте, ә анын үзен таза гәүдәле егет кысрыклый иде, Рушан аны, сугып, бер-бер артлы егып торса да, һич кенә дә нокдаунга җибәрә алмый интекте. Ә якын килеп сугышырга,—анысына үзе бик тә маһир булса да, теләмәде—бәйрәмнәр алдыннан берәр жирен күгәртеп чыгарырлар дип шикләнде.

Ул көнне «мәскәүнекеләр» алдында анын абруе күтәрелде, ана әле мона кадәр сагаебрак карыйлар иде—ул бит һәрвакыт үз эшләре белән генә йөри, Исмәгыйль бәккә дә туган тиешле, Стаин белән дә дус. Шикләнерсең дә...

Җинаятьчел тормыш романтикасы Рушанны кызыктырмый, Исмәгыйльнен үз итүе яки Дроголовлар белән дуслык анын өчен Давыдычеванын бер елмаюына да тормый иде. Кыз алдында бөтенләй дәрәҗәсе төшкәнен анлап алды ул, кызнын «бандит» дип әйткәнен Рушанга шул кичтә үк җиткерделәр...

Кайвакытларда Рушаннын башына юләр уй да килә, бәхетенә, ул аны беркем белән дә уртаклашмый: Светланканы «урлаган» Мещеряковка барып «анлашырга» тели, «1905 ел» урамына юлны гомерлеккә онытылырлык итеп Наил Сафинны да өркетеп куймакчы була... Әмма мәхәббәткә сусаган җаны балигъ була, акыл керә, күзе ачыла бара иде инде.

Менә әле Мещеряков белән дә... Рушан үзенен чит кешенекенә нәфесен сузганын анлый иде. «Сталин чоры балалары», ни әйтсәң дә, күнелләренә иманлы әби-бабалары салган, әле «КПСС Программасы» битләренә язылмаган «Үтермә», «Урлашма», «Күршеңнекенә кызыкма» дигән васыятьләрне хәтерләрендә тоталар, мораль кодекс аларнын каннарына сеңгән иде...

Наил белән дә шул ук хәл. Резникова белән «мәхәббәт уены» булмаса, гәрчә яшь акылы көчләп яраттыра алмаганын анласа да, Рушан аны, бәлки, кыйнап та ташлар, өркеткән дә булыр иде.

Гомумән, ул үзендә ниндидер бер күнел китеклеге тоя һәм кайвакытларда хәтта үзенең мәхәббәт хыяллары тормышка ашмаган бу шәһәрдән ике ай ярымнардан китеп барачагына шатланып та куя, яна урында бөтенесен дә янабаштан башларга өметләнә иде... «Күзен күрмәсен—йөрәккә кермәсен»,—диде ул үз-үзенә һәм башы-аягы белән диплом проектына чумды, хәер, шунысын да билгеләп үтәргә кирәк—ул җинел укыды һәм, анын карашынча, диплом эшенә вакыт артык күп бирелгән иде.

Ул яз, әйтеп киткәнебезчә, гомумән, сәерлекләргә бай булды. Әгәр дә мәхәббәттә бөтенләй эше унмаса һәм ул моны берничек тә анлый алмаса, ул менә-менә спорт мастеры булырга тора, үзенә бокснын күп кенә яна серләрен ача килде.

Монын башы пасха бәйрәме көнне урамда сугышуга барып тоташа иде. Теге егетләрнең берсен сугып екканда, ул кече «дроголенок»ка ярдәм итеп тә өлгерә. Рушан үз дошманын бәреп ега да, икенчесенә кыска һәм кискен итеп китереп кундыра, егет сыгылып төшә, әмма үҗәтләнеп янадан аягына баса, янә, үгез кебек, алга ыргыла. Егетләр таза-тазасын, ләкин мингерәүләнгәч,—бокста ул «грогги» дип атала,— куркыныч түгел иделәр. Хәер, бөтенесе дә бик тиз эшләнә, Рушан салкын канлылык белән чамалабрак кына суга—бармак сөякләрен бирттерүдән саклана. Элек болай саклану башына да килмәс, мавыгып-кызып китү

акылны томалый торган иде. Әле ул гынамы: ул ике егетне дә күз унында тота һәм, инде бөтенләй анлатып булмастай хәл—юл чатындагы Тамараның куркынган йөзен дә һәрвакыт диярлек күреп тора. Аның көче дә, үҗәтлеге дә, техникасы да бар, шуңлыктанмы, кинәт кенә боксның асылын тирәнтен аңлап алды: үзендә ышаныч, салкын канлылык һәм уйлап-исәпләп суга белү барын тойды, күрү сәләте, голография шикелле, күләмлегә әверелде—ул бөтенесен дә үтәдән-үтә күрә башлады һәм дошманының хәйләле уйланган һөҗүмен алдан кисәтә барды. Үзендәге шушы сыйфатларны ул, шәһәр ярышларына әзерләнгәндә, беренче күнегүләр вакытында ук аңлады...

Рингка чыккач, көтмәгәндә үзенә килгән ышанычтан рухи тынычлык тойды, күңеленә жиңеллек тапты. Ә бит әле пасха бәйрәме иртәсендә генә, «Тимерлек» ишегалдында Резниковларның йорты каршысында басып торганда, ул тыкрыктагы биек яшел койма ягына борылып карарга да курыккан иде—юксыну-ямансулаудан йөрәге сызлана иде.

Аның рингта үзгәреп китүен, кызмыйча, салкын канлылык белән уйлап-исәпләп кенә, үзен иркен тотып сугышуын шунда ук күреп алдылар, әмма моны «Локомотив» беренчелегендә туплаган тәҗрибәсе дип кабул иттеләр: башкалада мастерлар белән аралашканнан соң, өлгергәнлек килгән дип уйладылар булса кирәк. Моның чынлыкта нәрсәгә бәйле икәнен үзе генә белсә дә, гәрчә ул аны башкаларга аңлатып тормады. Дөрес, бу көннәрдә монаеп үз-үзенә әйтеп тә куйды: «Дүрт ел эчендә бары тик рингта гына унышка ирешүем кызганыч...»—диде.

Әйе, бары тик рингта гына ул үз язмышына үзе хуҗа була ала, көндәшләрен үз ихтыярына буйсындыра, үз алымнары белән сугыша, ләкин болар Рушанны артык куандырмады—кызыктырырлык тәкъдимнәр булса да, ул үз тормышын спорт белән бәйләргә теләми иде.

Шулай итеп, бөтен шәһәр парк призына буласы ярышларны көтә, бигрәк тә жиңел үлчәүдәгеләр ярышын: анда катнашучылар иң күбе—ул заманнарда тәвәккәл егетләр житәрлек, илнең жыелма командасының чиреге казакъстанлылар, Казакъстанда бокс озак еллар буе спортның беренче төре булып саналып килде.

Рушан исә шәһәр тормышы инде үзен читләтеп ага, ул монда кирәксез хәзер, дип уйлый иде. Ул иләп кенә хәрби учеттан да төшеп куйды, үзендә булган китапларны һәм спорт инвентарен илтеп тапшырды, үз катнашыннан башка үтә алмый торган ике генә эше калды: диплом яклау һәм шәһәр беренчелегенә бокс ярышларында катнашу. Бродвейда һәркемнең телендә бокс кына иде.

Ләкин язмышка шулай кирәк булгандыр: калган шул ике ай эчендә Рушанның тормышын янача яктыртып жибәргән хәлләр килеп чыкты һәм, теге Яңа ел кичәсеннән алып аннан соңгы барлык көннәр бергә кушылып, еллар үткәч, аның гомер юлында рухи терәк булып калдылар. Хәзер, дистә еллардан соң, һәр нәрсәгә: «Вакыт сынавын үткән»,—дигән юылмас мөһер сугылгач, ул аңлый инде: очраклы, вакытлы, үтеп китәрдәй тоелган, онытылган нәрсәләрнең һәммәсе дә илаһи мәхәббәт балкышы белән өртелгән бүләк булган икән, кешеләр бу дөньяга сөяр һәм сөелер өчен килә икән.

Бәхетле заман...

Кызганыч, тылсымлы ожмах кошының янәшәдә генә,—башынны гына бор!—кул сузымы гына жирдә булганлыгы ул вакытта аңланмаган. Ә бәлки, сөю бәхете шуны белмәү, аңламаудадыр, ожмах кошының тоттырмас булуындадыр?

Парк ачылырга бер атна кала башланып киткән бокс ярышларында катнашу Рушанга жиңел бирелмәде. Бигрәк тә беренче сугышы. Аны карарга гажәп күп халык жыелган, чөнки жиңел үлчәүдә чемпион исеменә дәгъва кылучы төп ике боксчыны—Дасаев белән Кружилинны сукыр шобага беренче сугышта ук очраштырган иде. Ул елларда судья беркетмәләрендә бу пар еш кына финалда катнашучылар буларак билгеләнә иде.

Беренче раунд бетәргә берничә секунд калганда, Рушан рингка иң якын урыннарда утырган тамашачылар арасына Тамара белән Наил килеп кергәнен күреп алды. Ул хәтта күнеленнән генә баш кагып кыз белән исәнләшкәндәй дә булды һәм шул мизгелдә Кружилин аңа бик көчле итеп уң яктан китереп тә сукты, Рушан чак кына нокаутка егылмый калды, ярый әле, гонг коткарды: беренче раунд тәмамланган иде. Ул ант итеп әйтә ала, аңа турылыклы табынучылар шул чагында Тамарага дәррәү карап алдылар: алар нәрсә булганын аңлаганнар иде. Ләкин калган ике раундта ул инде бүтән андый ялгышлыклар җибәрмәде.

Тамашачылар күңеленә аның яңача сугышу алымнары хуш килде, ә Кружилин өчен бу көтелмәгән хәл булды. Аны-моны уйлап тормастан, һәр даим һөҗүмгә ташланучы үҗәт һәм усал Дасаев кая киткән, диярсең... Аның урынына рингта мәче кебек йомшак кына басып, фехтовальщикны хәтерләткән җиңел-хәрәкәтчән боксчы йөри. Аның сугулары яшен тизлегендә һәм төгәл, алар кинәттән генә булалар, аларны күреп-чамалап бетерергә дә мөмкин түгел шикелле, ә үзе көндәшенең һәр һөҗүмен алдан күрә, алдан сизенә һәм әле читкә тайпылып, әле кинәт кенә иелеп суктырмый кала, каршыга көчле сугып, тегенең һөҗүмен өзә. «Мәче-тычкан уены кебек булды бу»,—дип бәяләде Стаин Рушанның бу беренче җиңүен.

Дасаев ул язда чемпион исемен яулап, әлеге кадерле жетон иясе булып кына калмады, бик оста техникалы боксчы призын да алды. «Шәһәребездә «матур» бокс аңардан башланды»,—дип сөйлиләр икән хәзер Актүбәдә. Әмма Актүбәдә Рушанның ул соңгы чыгышы булды.

Грамоталар, жетоннар, бүләкләр тапшырган тантана беткәннән соң, башкалар сизми дә калган бер вакыйга булып алды, Дасаевның тагын бер яңа мәхәббәте башлануын шуннан башлап исәпләргә кирәктер, мөгаен.

Юан арканнар тарттырып ринг ясалган җәйге биек сәхнәдән төшүгә, аны таныш һәм таныш булмаган тамашачылар урап алды, ләкин аңа иң якында тимерюлчылар мәктәбендә укучы егетләр-кызлар булып чыкты, Рушан алар өчен икеләтә үз кеше, чөнки аларга «Локомотив» командасы да кадерле иде.

Әйе, җирле патриотизм ул заманнарда буш сүз генә түгел иде шул. Шуңа охшашрак күренеш соңгы дистә елларда Америкада да шәйләнә, әмма андагы патриотизм илне сөюгә генә кайтып кала—АКШның дәүләт флагы эленмәгән бер генә йорт та юк анда. Мәгәр ил сөючәнлек, мөгаен, гап-гади шәһәр беренчелеген яулап алган үз егетләреңне менә шулай яратудан башланадыр да инде.

Егет-кызлар аны тыгыз боҗра белән уратып алгач, үзенә иң якын торган Ниночка Новова аның финал сугышында каралып-күгәреп чыккан күз төбенә ягымлы бармаклары белән сак кына кагылды да дулкынландыргыч кайгыртучанлык белән:

—Авыртмыймы?—дип сорады.

Рушан җавапка елмаеп кына куйды һәм, уйлап та тормастан, кинәт кенә аңа үзе алган призны—зур бәллүр вазаны сузды. Ул заманнарда, күрәсең, муллык-байлыктандыр—җиңүчеләрне шулай бәллүр әйберләр белән юмарт бүләклиләр, ул бәллүрләр бары тик Гусь-Хрустальныйныкы гына була торган иде.

—Ә бу минем иң гүзәл тамашачыма бүләгем...—диде Рушан.

Кемдер җыелышып истәлек өчен фоторәсемгә төшәргә тәкъдим ясады, Ниночка вазаны Стаинга тоттырып, кечкенә сумкасыннан матур кершән савыты чыгарды һәм Рушанның кабарып янып чыккан күз төбен кершәнләп тә куйды. Яшереп торасы юк, аның шулай кайгыртуын тою Рушанга бик рәхәт иде...

Чемпион белән фоторәсемгә төшәргә теләүче дуслар-танышлар шулкадәр күп булып чыкты, фотограф аларны рәтләп утырта-тезә башлады, Рушан белән Нина иң уртада калдылар.

Кемне кайда утыртырга, кайда бастырырга дип, мәш килгән арада

Мещеряков белән янәшә басып торган Светланка, бер җай табып, Рушанга сирень чәчәге ыргытты—аның бу ишарәсен үзләреннән башка берәү дә сизмәде шикелле. Паркта инде бөтен көченә джаз-оркестр дөмберди иде. Сезонның беренче бию кичәсе башланып килә, күпчелек тамашачылар җәйге эстрада театрының бию мәйданчыгына күчтеләр. Зур вазаны кысып кочаклаган Ниночка кинәт кенә Рушанга:

—Синең бүләгең миңа Троя атын хәтерләтә,—диде.—Ышанам, берәр төрле уй-ният белән бирелмәгәндер бит? Мин синең янына көч-хәл белән генә үтеп керә алдым, кызганыч, парк ачылган көнне чемпион жетоны белән, үз гомеремдә бер генә булса да, биюгә керергә тырышып, ничек этешкән-төртешкәнемне күрмәдең. «Бүген—яки һичкайчан»,—дидем. Менә шундый инде мин, Дасаев, дан яратучан.

Алар заманында шулай читләтеп, кинаяле-шаян манерада сөйләшергә остарганнар, әйтергә теләгән сүзнең мәгънәсен шактый купшы-кабарынкы төсмерләргә төреп аңлата беләләр иде. Сөйләшүнең мондый төрен Рушан соңыннан беркайчан һәм беркайда да очрата алмады.

—Ни өчен әле ваза синең теләгеңә комачау ясар дип уйладың?—диде Рушан.—Без аны, бөтенесенә күренерлек итеп, музыкантлар янына куеп торырбыз. Ә сине, көтелмәгән шәфкатьчем, бик теләп биергә чакырам...

Нина елмаеп, тагын шаяртып әйтте:

—Биергә кергәндә генә—анда бүген галәмәт чират, сине күргәч, мөгаен, юл бирерләр, контролерга кычкырыбрак әйтерсең әле, яме: «Вазалы кыз—минем белән!»—диярсең.

Яннарында торучылар аңлап көлеп җибәрделәр. Бер атна элек кенә шәһәрдә Феллининың гомерлеккә данлыклы булып калган «Кабирия төннәре» фильмын күрсәткән иделәр. Анда шундый күренеш бар: Джульетта Мазинины ниндидер бер танылган артист ресторан яныннан үзенең өсте ачык зиннәтле машинасына утыртып алып китеп барганда, кыз, куанычыннан йотлыга-йотлыга, калган кызларга кычкырып уза: «Күрегез, күрегез әле, мин кем белән барам!» Истә калырлык мизгел. Ниночка шул күренешне бераз үзгәртеп кабатлагандай итеп, башкалар алдында Рушанның дәрәҗәсен тагын да күтәреп җибәрде.

Биюләр беткәч, финал сугышлары турында сөйләшә-сөйләшә, алар бер зур төркем булып тимерюлчылар бистәсенә кайтып киттеләр—Ниночка Новова шунда Кызыл урамында тора иде.

Ниночка белән Рушанның дуслары-танышлары, Стаинның күпертеп әйтүе буенча, «күренекле» бер үк кешеләр—хәер, бу төшенчә аларның кечкенә шәһәрләрендә телдә киң таралган—һәм алар, әлбәттә, бер-берсе турында барысын да беләләр иде.

Аннары ул заманнарда яшереп-нитеп тору юк, һәммәсен дә эчкерсез, ачыктан-ачык сөйләп бирү бик табигый сыйфат иде.

Билгеле, Ниночка Рушанның Давыдычевага өметсез гашыйк булганлыгын да, Резникова белән «мәхәббәт уены» уйнап алганнарын да белә—алар беренче сыйныфтан ук дуслар һәм күптән укмашкан бер үк кызлар төркемендә иделәр. Рушан да Ниночка турында шактый мәгълүматлы: Стаин шикелле үк, аның да Ленинград белән хыялланганын белә, табибә булырга теләгәнен дә ишеткән. Аның икенче мәктәптә укучы, борыны бик югары Ренат Кутуевка гыйшык тотып йөргәненнән дә хәбәрдар, ә ул малайның бар яратканы—джаз, тәгәлрәге—саксофон икән. Аны хәтта кайсыдыр бер атаклы оркестрда уйнарга да чакырганнар, имеш, дип сөйлиләр иде. Чытлык-чибәр, кешедән көләргә яратучан Нововага бик күпләр күз төшереп, яратулы караш ташлап йөрсәләр дә, ул әле үзе беркем белән дә очрашмый-йөрешми, әмма мәгәр соңгы мәктәп язы иде бит инде. Берәр айдан Ниночка, үзе хыялланганча, Нева буйларына бөтенләйгә китеп барырга ниятли иде.

Әгәр дә икенче көнне тулай торакка Стаин шылтыратмаган булса, парк ачылган көндәге ул кич, мөгаен, шулай бәллүр ваза һәм Новованың

күнелне эретерлек игътибарлы булуы белән генә бәйле бер вакыйга булып калыр иде. Жорик унөченче мәктәптә укучы Галочка Старченконың Рушанны Туган көненә чакыруын хәбәр итте, барудан баш тартмавын бик үтенде, анда кызыклы кешеләр җыелачагына ышандырырга тырышты.

Беренче Май бәйрәме киче булса да, Рушанның аерым планнары юк иде һәм ул барырга ризалык бирде. Андый мәҗлесләргә Стаинның борыны бик сизгер аның. Сөйләп тә торасы юк, Жорик күнел ачарга бик маһир: шәһәр яшьләренең «асыл затларча» тормышы аның тирәсендә генә кайнап-гөрләп тора да инде.

## XX

Дулкынландыргыч, күнелле туган көннәр, алар Туган көн үткәрүчеләргә дә, кунакларга да әллә ничаклы шатлык-куанычлар китерә иде. Хәзер, үткәннәр белән бүгенгене ирексездән чагыштырып, Рушан ул вакытларда бәхетле гаиләләрнең никадәр күп булганлыгын анлый инде, ызгыш-талашлы, низаглы җирләргә кунак чакырмыйлар бит. Игътибарлы ата-ана мәхәббәте белән чолгап алынган, Стаин әйтүенчә, шулай ук «күренеклеләр»дән булган бер гүзәл кыз үсеп килгән Старченколар гаиләсе дә шундый бәхетле-имин гаиләләрдән иде.

«Күренеклеләр» төшенчәсенә күп сыйфатлар керә: яхшы уку, спортта югары уңышларга ирешүдән алып үзеңчә матур итеп киенә белү, үткен сүзләр әйтү, биюләргә кадәр—кыскасы, үз йөзен булу. «Күренеклеләр» үз буынының «катализаторы»,—ди Стаин. Алар яшьләрне үзара якынайтып-аралаштырып тора, алар йогынтысында мәктәпләр арасында дуслык күпере салына. Юкка гынамыни, икенче мәктәптә—борыны югары, әмма талантлы Ренат Кутуев, кырык дүртенчедә—чибәр, акыл иясе Давыдычева белән шәһәрдә иң танылган шагыйрь Валька Бучкин укый, ә яшьләрнең модаларын канунлаштыручы һәм бөтен яхшы гамәлләрнең башында торучы кырык бишенче мәктәпнең лидеры Жорик Стаин, шул ук мәктәпне Светланка Резникова белән Ниночка Новова тәмамлап килә, ә ул язда, Галочка Старченко булганга күрә, унөченче мәктәп тә танылып өлгергән иде инде. Рушанга хәзер үзе берьюлы тимерюлчыларның ике мәктәбен—кырык дүртенчене дә, кырык бишенчене дә тәмамлаган шикелле тоела—аның мәнфәгатьләре, күнеле ятып, яратып йөргән кызлары шул ике мәктәп белән бик тыгыз бәйләнгән иде бит.

Ул заманнардагы Актүбәнең дүрттән өч өлеше төрле-төрле шәхси йортлардан тора иде. Стаин шаяртып: «Безнең шәһәр инглизләр манерында—гел хосусый биләмәләр»,—дия иде. Старченколар да икмәк заводы артындагы үз йортларында яшиләр икән.

Гаҗәпләнерлек бар: Рушаннарны Галочканың әтисе үзе каршы алды, ул спорт уеннарын карарга бик хирыс икән—Стаин уйный торган «Спартак»ның бер уенын да калдырмый карап бара, кичә паркта Дасаев өчен дә янып-көеп утырган, егетләрнең бүген кызының Туган көненә киләселәрен белгәч, бик шатланган.

Рушан белән Жорик иркен бүлмәгә килеп кергәндә, кунаклар «П» хәрефе шикелле итеп куйган өстәлләр тирәли утырыша башлаганнар иде инде. Һәр тарафтан аларны чакырып, исемнәрен атап торсалар да, күбесе Стаинга да, Рушанга да таныш түгел иде—күрәсен, җай чыкканда, Галочка үзенең унөченче мәктәбендәге дуслары белән иркенрәк таныштырырга ниятләгәндер. Кинәт кенә бер читтән Рушанны дәшкән таныш тавыш ишетелде. Борылып караса—Ниночка Новова икән!

—Синең бирегә чакырулы икәненне белгән минуттан бирле бу урынны синең өчен саклап торам,—дип елмайды Ниночка.—Син бу турыда кичә бер сүз дә әйтмәгән идең бит. Старченко өчен генә сюрприз түгел бу, дип уйла...

Шулай шаяртып сөйләнә-сөйләнә, ул Рушанга шундый ягымлы

итеп төбәп карады ки, егет ирексездән Яна ел кичен, колонна янында басып торганда Резникова әйткән сүзләрне исенә төшерде: «Син минем әсирем, без бүген кире кагылган ике бәхетсез жан...»—дигән иде ул.

Күп еллардан соң, Мәскәүнен эстрада театрында Аркадий Райкинның «Светофор—2» дигән программасы премьерасында булган иде Рушан, шунда аны бөек артистка хас булмаган мизанцена—сәхнә күренеше таң калдырган иде. Сәхнәдә, ярым карангыда чиратлашып ун кеше басып тора: ир кеше—хатын-кыз, ир кеше—хатын-кыз, ләкин аларны парлылар дип әйтеп булмый, юкса барысы да бер-беренә гашыйклар, әмма ялгышып гашыйклар—бу хакта аларның хатлары, телефоннан шылтыратышулары, сөю, наз, дәрт-теләк тулы ялварулары, үзләрен корбан итәргә әзер торулары сөйли. Аларны башкача тезеп, телефоннарын алмаштырып ялгап куйсаң, һәркайсысы бәхетле булыр иде төсле, аларның һәркайсысы мәхәббәткә сусаган, мәхәббәткә лаек, газаплана, ләкин бөтен фажига да шунда шул, бу хәлне үзгәртерлек көч юк—һәм алар унысы да бәхетсезләр.

Берсенев яр буе урамындагы театрның ярым караңгы залында утырганда, Галочка Старченконың күптән үткәрелгән Туган көне искә төшеп, шундый ук бер рәт тезелгән иде: Ниночка Нововага гашыйк Наил Сафин Тамара Давыдычева белән очрашып йөри, ә Давыдычеваның күнелен яулый алмаган Рушанга Ниночка мөкиббән китеп карый. Язмыш аларның урыннарын алыштырып куйса, барысы да менә дигән булыр иде төсле, Рушанның Нововага кирәге булмаган кебек, Наилнең дә Тамарага кирәге юк бит. Ләкин бөтен бәла шунда, бер нәрсәнең дә, беркемнең дә урыннарын алмаштырып куеп булмый—менә шунда ахырына кадәр ачылып бетмәгән тагын бер сер...

Еллар үткәч, инде яшисе яшәлгәч, әлбәттә, Рушанга барысы да ачык шикелле, ә теге вакытта...

Телгә оста Стаин нинди матур тостлар әйткән иде! Беркемне дә игътибарыннан читтә калдырмады шикелле: Туган көн хужабикәсен дә, кешелекнең гүзәл яртысын да, Дасаевның кичәге жиңүен дә, бокска, бокстан бигрәк чемпионга ихлас мөкиббән Ниночканы да—һәммәсенә дә жылы һәм ягымлы, шаярулы һәм купшы-күперенке сүзләр әйтелде. Читтән карап торганда, бу, бәлки, ясалма боргалау-сыргалау, кылану булып та күренгәндер, әмма яшәү рәвешләре шундый—аларның ул чагында ничектер башкачарак тормышта гомер кичерәселәре килә иде...

Жылы май киче. Киереп ачып куелган тәрәзәләрдән кергән фарсы сирене белән шау чәчәктәге алмагачларның исе шәрабсез дә исертә иде шикелле. Яшереп торасы юк, кызыл аракысын да, шампан шәрабен дә эчтеләр. Ихтимал, бу көнне өстәл тирәсенә бары тик гашыйклар гына жыелган булгандыр, өстәл өстендә дә, залда да, Галочканың йокы бүлмәсендә дә кайнар мәхәббәт сулышы тирбәлә, күптән вәгъдә ителгән үбешүне алыр өчен кемнәрдер әлеге бүлмәгә шыпырт кына кереп югала да иде инде. Егетләрнең күзләре яна, кызларның яңаклары матур алсуланып чыккан!

Берьюлы һәркемне дә чолгап ала торган нинди дер хис-тойгылар барлыгын фән күптән исбат иткән. Әлеге шул май кичендә андый халәт бары тик сөю хисеннән генә була ала иде, сөю хисе сихерли, хәтта әле үзенең канаты кагылмаган егет-кызларны да өметләндерә иде. Элвис Пресли рок-н-ролларыннан алып Джонни Холлидей буги-вугиларына кадәр төрледән-төрле музыка яңгырый; аларны ни өчендер моңсу-минор көйләр алыштыра, ә соңыннан залга танго аһәңнәре агыла. Һәм янә, Яна ел төнендәге шикелле, Батыр Закировның моңлы-сагышлы жыры ишетелә, аның атаклы «Гарәп тангосы» бу.

Әле ярый, залдагы утны күптән сүндергәннәр иде, Ниночка, Рушанның дулкынлануын, тәне калтырануын сизенсә дә, бу минутларда аның күзләрен күрә алмый, һәммәсе дә әле кайчан гына булып узган иде бит, Батыр Закировның жыры кабат-кабат шуны Рушанның исенә төшереп тора иде...

Рушанның кәефе китте, биюләр туктап торган арада ул Стаинга «инглизчә» югалырга—ягъни сиздерми генә чыгып сызарга тәкъдим итте. Әмма Жорик ул кичнен ачышы булган ниндидер Зиночка янынннан һич китә алмый. Ул кыз өчен бу кичә, Наташа Ростованың беренче мәртәбә балга килүе кебек үк, егетләр-кызлар арасына беренче чыгуы иде һәм кинәт кенә шундый уңыш—егетләрнең күбесе анардан күзләрен ала алмый.

Әмма Стаин, дустының төшенке кәефен чамалап алып, әйтеп куйды:

—Китәрбез, ләкин берәр сәгатьтән, кичәнең шигъри бүлеге беткәч,—диде, Бучкинның, яңа шигырьләрен укып, тыңлаучыларны таң калдырырга җыенганын ишеткән иде ул. Кичәләрдә шигырьләр уку күптән гадәткә кергән, һәр төркемнең танылган үз шагыйрьләре бар, алар арасында Валентин Бучкинга тиңнәр юк иде. Башка шагыйрьләрнең шигырьләрен уку да гаепкә саналмый, әмма автор лирикасына өстенлек бирелә, бу мизгелләрне бигрәк тә кызлар түземсезләнеп көтә, чөнки кайвакытларда шигырьгә яшерен мәхәббәттә аңлашулар да салынган була иде...

Шигърият өчен гаҗәеп игелекле заман иде ул. Хәтта Стаин да танылганлык ягыннан Бучкин белән ярыша алмый—шигъри сүз, рифма тылсымлы көчкә ия иде. Валентин ул кичтә Старченколарга Верочка Фролова белән килгән иде, аның белән дуслашып йөрүе әллә ничек шаушулы, борчылулы кичерешләр тулы, юкса, араларына кереп, бозылыштырырга тырышучылар да күренми иде кебек. Бучкин Верочканы үзенең Беатричесе дип атый, кайда гына барса да, башка кызларның үзенә төбәлгән сокланулы карашларын күрми дә, ул бит мәхәббәт турында шундый матур шигырьләр яза—башкаларны күрерлек дәрәҗәдәме соң монда?

Ул кичне Валентин моңсу күренә иде, әмма хуҗабикә, кинәт кенә радиоланы туктатып: «Шигърият сәгате сукты!»—дип игълан иткәч, Бучкин шигырьләрен сөйләп кунакларны куандырудан баш тартмады. Гадәткә кергән тәртип буенча, беренче булып ул сөйләде, аның моңлы карашы ярым караңгы зал аша Верочкага төбәлгән, ә кыз, ни өчендер ачык бизәкле чегән шәленә төренеп, голланд миче тирәсенә елыша төшеп утырган иде.

Моңлы Валентин кунакларга дөрестән дә искиткеч матур шигырьләр бүләк итте, ә Верочканың ачык тәрәзәдән кергән ай яктысы белән яктыртылган йөзендә ни сөю, ни шатлык чагылмады. Дасаевка бу күренеш чын түгелдер кебек, сәер тоелды, аның кычкырасы: «Сез бит бергә, нигә моңаясыз, нигә бу күзләрдән яшь китерерлек сагышлы шигырьләр?»—дип сорыйсы килде. Моңысы да Рушан өчен гомерлек сер булып калды—Валентин белән алар бүтән беркайчан да очрашмадылар, озак еллар газет-журналлардан аның исем-фамилиясен эзләсә дә, Бучкинның басылган шигырьләре дә күзенә чалынмады. Ул кичне Валентин аңа үз һәм кадерле иде—бәлки, шигырьләре, бәлки, суынып беткән мич янындагы кызга төбәлгән моңсу карашы моңа сәбәпче булгандыр.

Бу елларда без күп сөйдек,
Безне генә сөймәделәр...

Залдагы берләнбер кәнәфине биләп алган Ниночка ишек уемына каршы утыра, коридордан төшкән яктылык аның йөзен бик ачык яктыртып тора иде. Кыз, вакыт-вакыт әсәрләнеп, чәчләрен төзәтеп куя, нечкә җепкә төзелгән энҗе муенсалы озын муеныннан аларның авырлыгын алып ташларга тели төсле иде. Валентин шигырь укый башлагач, ул бөтен гәүдәсе белән алга таба авыша төште, аның бар игътибары шигырьдә—сылу гәүдәсеннән нәфислек, гүзәллек, яклаучысыз гаҗизлек бөркелеп тора иде. «Аккош,—дип ирексездән уйлап алды Рушан.—Аккош-кәләш...»

Рушанга аны күзәтеп утыру рәхәт иде, әмма кыз һәр шигырь саен урынына сеңгәннән-сеңә төшә, хәрәкәтләре борчылуын сиздерә, сокланулы карашы күз алдында тоныклана-сүнә бара иде. Бу минутларда Рушан шигъри сүз сәнгатенең тылсымлы көчен җаны-тәне белән тойды.

Монсу шагыйрьнең тынлаучылар белән уртаклашкан хисләре кызга да таныш, аңлаешлы һәм ул хисләрнең үз исеме бар—җавапсыз мәхәббәт.

Валентин соңгы шигырен тәмамларга җыенганда, Ниночка кәнәфиенә бөтенләй сеңеп беткән иде, Рушан аның дулкынланудан агарып калган бармаклары белән кәнәфигә чытырдап ябышканын күрде. Аның янына барып, ниндидер ягымлы сүз әйтәсе, өметләндерәсе, нәфис муеныннан үбеп аласы килде. Эх, әгәр дә ул, Стаин кебек, дулкынландыргыч сүзләр әйтә белсә икән! Мисал өчен шундыйрак сүзләр: «Бүген нинди гүзәл сез, мадемуазель Новова!» яки: «Матур ягымлылыгыгызның серләре белән уртаклашыгыз әле, сылу Нина, сез һәрвакыт шундый сөйкемле...» Ләкин Рушан андый сүзләрне әйтә алмый, әйтә дә белми, кая инде башка берәүнең күңелен күтәрү, бу мизгелдә сагыштан аның үзенең дә күзләре дымланган иде. Юкса, Нововага карата сөйләп биргесез якынлык тоеп, аның гүзәл йөзендәге сагышны юып алу өчен теләсә нәрсә эшләргә әзер иде ул.

Дивар буенда Зиночканың артында басып торган Жорик, вакыт-вакыт кызга таба иелеп, аның колагына нәрсәләрдер пышылдый, әмма Нинадан күз сүзмыйча гына ераклыкта утырган Зиночка Стаинның кайнар пышылдауларын ишетми дә иде бугай. Ул да мәктәп кызлары арасында данлыклы булган шагыйрьдән күзләрен ала алмый, аны ошатканлыгы күренеп тора. Күпләрнең йөрәген яндыручы Стаин аны бу тылсымнан араларга тели, ләкин хәтта Жорик та шигърият белән, шагыйрь белән ярыша алмый иде шул.

Валентин шигырь сөйләүдән туктагач, залда бер кавымга каушап-аптырабрак калган шикелле булдылар. Стаин тиз генә коридорга чыкты да Рушанга ымлый-ишарәли башлады, ул Старченколардан шыпырт кына чыгып китәргә җыенганнарын исендә тота иде. Шул чагында көтелмәгән бер хәл булып алды, Рушан аны соңыннан гомере буена аңларга тырышып караса да, хәтта бүген—«хризантемалары чәчәк койгач» та—аңлап бетерә алмады—монысы да, мөгаен, мәхәббәт серләренең берсе булгандыр. Әле күптән түгел генә, март аенда көн саен почтальоншаны көтеп торган һәм Светланкага хат салыр өчен төнге поездга йөгереп төшкән көннәрдә аның кулына ничектер Лермонтов томы килеп кергән иде. Шул еллардагы дус-ишләренең күпчелеге шикелле, ул да шигърияткә яратып өлгерде, гомерлеккә шигъриятка гашыйк булып калды һәм бүген ышаныч белән әйтә ала: «Шигърияткә яратыгыз, ул, чынлап та, күп кенә бәлаләрдән, авырлыклардан качарга булыша. Коръәндәге шикелле үк, шигърияттә дә тормышның барлык сорауларына да җавап табарга була, бары тик үз шагыйрегезне, үзегезгә ярашлы шигырьләрне генә эзләгез, алар бар...» Шуна күрә, Светланканың Мещеряковка кияүгә чыгарга җыенуын белгәч, шунда ук кайдандыр тирәннән күңеленә шигырь юллары килүе бер дә гаҗәп түгел иде:

Шундый озын кыш булды бу,
Шундый озак аерылу.
Кар астында калдык бугай,
Карасак та каерылып...

Гафу сорап кул сузудан
Җинелрәктер, мөгаен,
Кирегә бер борып кую
Озын-озак кыш аен.

Гореф-гадәт диеп торма,
Җыештыр фатирынны...
Сибереп түк кар өстенә
Сагышлы хәтеренне...

Китапның ахырына таба беренче ачылган биттә үк Арбенинның «Маскарад» поэмасындагы таныш монологы Рушанның күзенә ташланды:

Тыңла, Нина, көлке мин, билгеле,
Сине үлеп сөю көлке түгелме?...

Бу юллар шулай ук Рушанның шул вакыттагы кәефен тулысынча чагылдыра иде, бары тик «Светлана» исеме генә шигырь ритмына ятмый-ябышмый, ә болай—әйтерсең, күңеле кушып язылган, дөресрәге, үз шигыре

кебек яңгырый иде ул юллар. Һәм алар үзеннән-үзе бик җиңел генә хәтергә сеңеп калган, ятланган, Рушан аны, очрашкач, ничектер бер җаен китереп, Резниковага укырга да җыенган иде, әмма аралары көтмәгәндә өзелде дә... бу шигырь юллары яңадан бервакытта да кирәк булмастыр төсле иде инде. Һәм менә...

Кызлар, этешә-төртешә, Валентиннан соң бер-берсен шигырь сөйләргә кысташкан арада, Рушан Стаинга ымлады да ишеккә юнәлде һәм кинәт бусагада тукталып, борылып карады. Нина аның чыгып китәргә җыенганын сизенде шикелле, моңсу күзләре белән аңа күтәрелеп карады, ул күзләр: «Син дә мине ялгыз калдырып китәсеңмени инде?»—дип сорыйлар төсле иде. Рушан хәтта кыз аны туктатырга теләп, үзенә таба кулларын сузгандай итеп тә тойды. Шуннан ул тәкәллефле итеп капылт кына артка чигенде, ячтыртылган ишек уемында һәркемгә дә яхшы күренеп торган килеш, бары тик Нинага гына карап, Лермонтовның шул атаклы шигырь юлларын сөйли башлады:

Тыңла, Нина...

Рушан ниндидер бер сәер халәттә иде—рингта каты китереп суккаННан соң оста саклана белү хәрәкәтләре үзен нокауттан коткарып калган шикелле, шигырь юллары да бер-бер артлы аңа ышаныч өсти, үзен тынычландыра һәм чынбарлыкка кайтара иде.

Шулай ук рингтагы шикелле, тирә-юньне күләмле итеп күрү сәләте кинәт кенә ачылып китте. Ул әүвәле, нәрсә булганын аңламыйча, авызын кызык кына итеп ачып катып калган Стаинны күреп алды—тегесе мыштым Дасаевтан, әлбәттә, моны көтмәгән иде (Соңыннан Жорик Рушан булып кыланып, бу күренешне бик озак кабатлап күрсәтеп тә йөрде әле).

Әмма бер мизгелгә генә күзенә чалынган Стаин өчен Рушанның исе китми, ул Нованың могҗизаи рәвештә күз алдында үзгәрүен күрә. Кыз кәнәфидән күтәрелә төште, матур канатларын кагып очып китәргә әзерләнгән аккош төсле, ягымлы карашы белән егеткә тартылды, йөзенә сөйкемле алсулык таралды. Җанланган моңсу иреннәре нәрсәдер пышылдый, Рушанны хуплап дәртләндерә иде шикелле.

Барлык кунакларның да шигърият сәгатенең иң югары ноктасы, сюрпризы, шигырь белән аңлашу мизгеле шушы икәнен төшенеп, тын да алмыйча үзләренә карап торганнарын сизенсә дә, бу минутларда кыз өчен бу дөньяда башка беркем дә юк, алар икәүдән-икәү генә кебек иде. Ул, кичә башлангандагыча җиңел генә матур хәрәкәт ясап, калын-авыр коңгырт чәчләрен янә муеныннан алып, артка чөеп җибәрде—үз бәясен белгән бу иркен хәрәкәт: «Менә мин нинди! Миңа менә нинди шигырьләр багышлыйлар!»—дигәнне аңлата иде.

Хәзер, еллар үткәч, Рушан ул гамәленең гүзәл Ниночка белән мәхәббәттә аңлашу булып яңгыраганын кире какмый инде, ләкин теге чакта булса...

Лермонтов шигыренә ул барлык газапланган күңел авыртуларын, мәхәббәтенә җавап ала алмаган йөрәгенең өзгәләнүен салган иде. Бу аның менә-менә гомерлеккә аерыласы дус-ишләренә соңгы хушлашу сүзе кебек булды. Юкса, ул үзе кунакчыл Старченколар йортында бу матур май кичендә Нина белән икесенең бер үк төсле бәхетсез һәм ялгыз икәнлекләрен генә аңлатырга теләгән шикелле иде.

Әмма хисләрне, бигрәк тә менә шундый көтелмәгән гамәлләрне тикшерү—катлаулы эш. Рушан хәзер дә берничек тә аңлата алмый һәм аңлату кирәкмидер дә.

Кинәт кенә бәреп чыккан шигырь юллары шулай ук көтмәгәндә генә бетеп тә куйдылар, Рушан, ни үзен ишек янында көтеп торган Стаинга таба атларга, ни артка чигенергә, ни Нинага кулларын сузарга кыймыйча, аптырап калды. Биек түшәмдәге люстраның балкып кабынып китүе һәм урыннарыннан күтәрелгән кунакларның көтелмәгән кул чабулары коткарды.

Шуннан ары беркем дә шигырь сөйләргә базмады. Элеккечә тирә-

юнендәге берәүне дә күрмичә, Ниночка ана таба күтәрелгәндә генә залда янадан ут сүнде, шул мизгелдә үк «Гарәп тангосы» янгырады. Кыз, Рушанның иннәренә ике кулын куеп, дулкынланган йөзен ана якынайтты һәм әкрен генә пышылдады:

—Мин шундый бәхетле, рәхмәт, сөеклем...

Рушанның яна мәхәббәтен,—юк, бу юлы «мәхәббәт уеныи» түгел,— ә нәкъ менә мәхәббәтен Галочка Старченконың шул Туган көненнән башлап исәпләргә кирәктер дә.

## XXI

Май ае алар ягында, һичшиксез, ин матур ай. Дала кинлекләренә яз сонлап килә, табигать май аенда гына көч-куәт ала, агачлар яшелләнеп яфрак яра, һәр түрбакчада сирень-сәрби куаклары чәчәк ата, ә Кызыл урамындагы кечкенә бакча, шау чәчәктәге алмагачлар чатырыннан төтенгә уралгандай, ап-ак булып утыра. Сонрак, тормыштан иртә киткән жырчы композитор Евгений Мартыновның «Алмагачлар чәчәктә» дигән мәгълүм жыры килеп чыккач, Рушан күптәнге шул май аен еш кына хәтеренә төшерә иде.

Шул май ае ахырларында бит инде, бервакыт Нина ана:

—Без синен белән—хөкем ителгән кешеләр шикелле,—диде.

Рушан анын нәрсә әйтергә теләгәнен анлап алды.

Әйе, хөкем карарын белгән тоткыннар ирексездән көннәрен санап барган кебек, үзләренен китәсе көннәрен белгәнлектән, алар да аны киртләп-билгеләп торалар иде. Ул вакытта инде Рушан Ходай каргаган Кызыл-Ордага эшкә билгеләнгән, ә Нинаны, Стаин сүзләре белән әйткәндә, Төньяк Пальмирасы—Ленинград көтә иде.

Шуна күрә, алар, кулдан ычкынган элекке көннәрен кайтарырга теләгәндәй, һәр көнне күрешеп тордылар. Ничектер зурларча теләк-дәрт белән, ярсып-өзгәләнеп, бер генә күнел ачудан да баш тартмыйча, очраша иделәр. Алар үзләрен «дроголята»лар арасында да, парктагы жәйге ресторанның верандасында Исмәгыйль бәк һәм анын дуслары янында да, Стаинның нәзакәтле-зыялы дус-ишләре белән дә иркен хис итә иделәр. Ул язда аларның сөйләп анлатып булмастай ниндидер тарту көчләре бар иде, алар тирәсенә һәрвакыт дус-иш, таныш-белеш, спорт сөючеләр, аларга табынучылар жыела, ваемсыз-чая күнел ачулар башлана, шаяртулар, уен-көлке ишетелә. Мөгаен, күпчелек егет-кызларнын да бер-берсе белән һәм Актүбә белән гомерлеккә хушлашачакларын күнелләре тоя-анлый иде.

Күнел ачуларда Ниночка тыелгысыз булып чыкты, дәрт-жегәре ташып тора, фантазия дигәндә, Стаиннан кала һәммәсе дә анардан калышалар. Парктагы биюләрдән кайтып килешли, берәр тын скверда яки берәрсенен түрбакчасында кинәттән генә нинди генә уен-көлкеләр оештырылмый, уйлап чыгарылмый да гитарага кушылып нинди генә жырлар жырланмый иде! Элекке мыштым, уйчан Нованы беркем дә таный алмый, мәсәлән, бервакыт ул бию мәйданчыгына билет тикшереп торучы контролерны үртәп:

—Бу яшь егет—минем белән,—дип, гәүдәсен нәкъ Дасаевча хәрәкәтләндереп, анынча кыланып куйды, керергә чират көтеп торучылар дәррәү кул чаба башладылар.

Кыскасы, алар тәүлекләрне озынайтырга тырышып, иртә танга кадәр аерылышырга куркып, күнел ачып йөрделәр, ә вакыт дигәнен ага, шагрин күндәй кыскара-кысыла торды. Һәм менә Ниночканын Ленинградка китәренә дә өч кенә көн калды.

Рушан эшсезлектән бөтенләй гажиз булып, тулай торактагы караватында аунап ята иде. Диплом яклау артта калган, бер атнадан аларның чыгарылыш кичәсе, шуннан сон ул да хыяллары тормышка

ашкан һәм ашмый калган бу шәһәрне ташлап китәчәк.

Һәм ул, моннан нәкъ дүрт ел элек техникумга керер өчен документларын Актүбәгә китергәндә, шушындый ук эссе июньнен көн уртасында, тиз йөрешле Ташкент поездынын вагоны түбәсендә барганын исенә төшерде. Авыл малаена бу шәһәр нинди зур, серле, ымсындыргыч булып күренгән, уку әйтеп бетермәслек кадерле булып тоелган иде—һәм менә барысы да бер көн шикелле генә үтте дә китте, янә тормышнын яңа йомгагын сүтәргә, янә бөтенесен дә янадан башларга кирәк.

Комнарга күмелеп утырган Кызыл-Ордада аны ни-нәрсәләр көтә? Нинди дуслар табылыр, нинди күнел ачулар булыр? Бу сәгатьтә аның күнелен шундый монсу уйлар биләп алган, әмма шулай булса да, ирексездән вакыт-вакыт Нина белән алда торган очрашуны күзаллап, йөзенә елмаю да куна иде.

Соңгы көннәрдә җәйге төн аларга шундый кыска тоела, бигрәк тиз яктыра башлый, Алма-Ата экспрессынын озын-озын гудок тавышлары очрашуларны өзә. Ниночка авыр көрсенеп әйтеп куя:

—Хушлашырга вакыт, сөеклем! Июньдә соң караңгыланып иртә яктыруы бик кызганыч, әмма без синен белән табигатьне буйсындыра алмыйбыз...—ди.

Рушаннын аллагы күрешү турындагы татлы уйларын алар бүлмәсенә болай гына башын тыккан күрше бүлмә егете бүлдерде. Рушанны күргәч, ул гаҗәпләнеп сорады:

—Нишләп ятасын, Ниночканны озатмыйсынмыни? Мин әле генә вокзалдан кайттым, аны перронда әти-әниләре белән күрдем, китеп бара...

Рушан караватыннан ничек атылып торганын сизми дә калды.

—Ничек китеп бара?—дип кабатлап сорады ул, көтелмәгән хәбәрнен асылына төшенеп җитә алмыйча.

—Бик гади генә,—дип көлемсерәде күрше егет.—Сигезенче купе вагонында. Ашык, Мәскәү поезды кузгалырга әле ун минут бар, мин вокзалдан велосипедта...

Рушан, аның соңгы сүзләрен тыңлап та бетермичә, ачык тәрәзәгә ташланды һәм күз ачып йомганчы урамга сикереп төште. Юлда очраган ялгыз кешеләрне куркытып, әлсерәткеч эсселекне дә тоймыйча, юл буендагы карагачлар күләгәсенә дә ышыкланмыйча, бар көченә йөгерде ул, аның шашкан йөзенә карап, кемнәрдер, берәр бәла-каза бардыр, дип уйлаганнардыр.

Тимер юлга йөгереп килеп җиткәч, ул вокзалга таба тәгәрәгән так санлы составны күреп алды. Егылып төшү куркынычын да уйлап тормастан, йөгергән уңайга нефть цистернасынын баскычына сикереп менә алды. Товарнякны әй ашыктырды да соң! Пассажир поездынын соңгы вагоны артындагы сигнал утларын бик яхшы күреп алды—экспресс кузгалмаган иде әле.

Товарняк, йөрешен әкренәйтеп, йөк составлары куела торган ян юлга борыла башлагач, Рушан юл арасына сикереп төште һәм янадан йөгереп китте, перронга барып җитәргә берничә дистә метр гына калган иде.

Ул ничек тә өлгерергә тиеш! Кызның йөзен, күзләрен күрергә тели, булдыра алса: «Ни өчен әйтми-нитми китәсен? Ни өчен шундый рәхимсез, кешелексез адым ясыйсын?!»—дип сорамакчы була. Әйтерсен, шушы сорауларның үзен гомер буе газаплаячагын шул вакытта ук тойган...

Рушан перронга йөгереп менгән иде инде, койрыктагы вагон калтыранып тартылып куйды да кузгала башлады, егет соңгы көченә алга ыргылып уникенче, унберенче, унынчы вагоннарны артта калдырды. Бу сәгатьләрдә вокзалда озатучылар күп иде, аларны аралый-аралый йөгергән Рушан тизлеген киметте. Тыны кысыла-кысыла, ул тәгәрәп барган тугызынчы вагон янәшәсеннән йөгерә һәм төшерелгән тәрәзәдән башын тыгып, кул болгаучы Ниночканы да күрә иде. Кемгә кул болгый ул? Рушан һич югында аның күзенә чалынырга теләп, бар көченә алга

ташланды, әмма тугызынчы вагон аны узып бара иде инде, аннары унынчысы, унберенчесе... Һәм ул, әле һаман да кемгәдер кул болгап баручы кызның нечкә кулларыннан күзен ала алмыйча, хәлсезләнеп туктап калды.

Нинаның әти-әниләре аны шунда ук күреп алдылар һәм, мөгаен, поездның тизләгәннән-тизли баруына шатланганнардыр да әле. Бу башсыз егетнең китеп баручы поездга сикереп менүеннән дә курыкканнардыр, бәлки. Ләкин ул минутларда Рушанның башына андый уй килмәгән иде шул.

Соңгы вагон күздән югалгач, Рушан борылып карады һәм үзенең Ниночканың әти-әниләре янында басып торганын күрде. Елаган йөзен күтәреп карарга оялып, картларча бөкрәя төшеп, ул әкрен генә китеп барды. Ул аларга нәрсә әйтә ала иде соң? Алар үзләре дә барысын да күреп тордылар бит.

Шул кичтә ул гомерендә беренче мәртәбә Стаин һәм Татар бистәсе малайлары белән исергәнче эчте. Парктан тулай торакка кайтып барышлый, Бучкин белән Фролованы очратты.

Валентин көндез вокзалда булган хәлне ишеткән иде инде, станция янәшәсендә яшәүче Верочка, Мәскәү поездына китерелә торган яңа пешкән ипи алырга дип, перронга килгән икән дә барысын да күреп торган. Валентин Рушанны үзләренә алып китте, алар төне буе сөйләшеп чыктылар. Иртән кухняда чәйләп утырганда, Валентин кинәт әйтеп куйды:

—Синең бу тарихың шигырь сорый, тыңла әле менә...

Үбешүләр түмен татыдым мин,
Бәхетем чиксез ташып тора иде...

Ләкин Рушан кул гына селекте:

—Тукта, кирәкми, синнән башка да эчем поша...

Хәзер, күп еллар үткәч, Дасаев шагыйрьне ник туктатканына үкенә. Алга таба нинди шигъри юллар булды икән? Чишелеше табылмаган сер. Ә теге ике юл гомергә истә калган: үбешүләр түмен татыдым мин...

Диплом тапшырыласы чыгарылыш кичәсенә кадәр калган көннәрен ул, шәһәргә чыгып та тормыйча, тулай торакның сәгать саен бушый барган бүлмәләрендә бер эшсез-максатсыз буталып тик йөрде. Ниночка киткәндә күз алдыннан вагоннар ничек тиз йөгереп узса, көннәр дә шулай тиз уза торды: биш, дүрт, өч... Ә ул исә аларны һаман да ашыктыра—биредәге тормыш аңа хәзер түзә алмаслык булып тоела иде.

Әгәр дә Резникова белән аралары өзелүне ул әле үзенә ничектер аңлатырга тырышып караса, Нованың качып китеп баруын ул котылгысыз явыз язмыш, үзенең... хыянәтенә җәза дип кабул итте. Ул бит кайвакытларда, барыбер йоклый алмасын белеп, төн уртасында үзе өчен куанычсыз «1905 ел» урамына әкрен генә барып чыга иде дә Тамараларның йокылы йорты тәрәзәләре каршында озаклап басып тора иде... күңеленнән кыздан гафу үтенә, йөрәгендә нинди утлар кайнаганын аның сизенмәвенә офтана. Ул көннәрдә нинди дә булса берәр җирдә кемнәрдер, кыз күңеленә тияргә, аны чәнчеп алырга теләп, кайчандыр аңа турылыклы булган Дасаевның хәзер бик еш гашыйк була башлаганын телгә алсалар, Тамараның горур гына:

—Әгәр дә бу шәһәрдә кемне дә булса яраткан икән, ул бары тик мине генә чынлап яратты. Бу хакта ялгышмагыз...—дип җавап биргәнен дә белә иде Рушан.

Кайвакытларда ерактан күзәтеп йөрсә дә, ул аның күзенә чалынырга базмый иде. Аның караңгы тәрәзә төбен саклап торган төннәрнең берсендә Рушанның башына бер уй килде: Тамара белән хат аша булса да саубуллашырга кирәк, араларында ни мәхәббәт, ни дуслык барып чыкмаса да, бу шәһәрдә аларның исемнәрен яшьләр гел янәшә куеп йөрттеләр ич, уен-муен түгел бу сина!

Көтмәгәндә күңеленә килгән карар аның тормышын вакытлыча

гына булса да никадәр мәгънәле иткән иде. Ул, көннәр буе өстәл яныннан кузгалмыйча, ачык почеркы белән өч дәфтәрне язып тутырды, әмма аларны хат дип әйтүе кыен иде, дөресрәге—газапланган, буталып беткән күңелен яшермичә ачып салу иде ул. Кызның үзе өчен кем булганын һәм хәзер дә кем булып калганын аңлатырга тырышу иде. Димәк, тормышының кояш баешы алдыннан бүген тәүбәгә килергә, барысын да чын күңелдән әйтеп бирергә теләве—беренче генә түгел...

Ул заманнарда иске акча белән биш сумга сыра да алып әбәт ашарга мөмкин булган һәм әле күпмедер көмеш тиеннәр дә кайтарып бирелә торган депо ашханәсенә ашарга барган арада гына Рушан Давыдычевага язган «хатларыннан» өзелеп тора иде.

Бер көнне әбәт ашап кайткач, ул Моряк кушаматлы бүлмәдәше Юрий Калашниковка тап булды, тегесенең күзләре елаудан шикле рәвештә кызарынып чыккан иде.

Тулай торакта бу егетне Рушанның адъютанты дип кенә йөртәләр, ул аңа мөкиббән киткән егетләрнең берсе иде.

Рушан:

—Кем рәнжетте?—дип сорады.

Моряк борынын мышкылдатып читкә борылды да өстәлдә яткан дәфтәргә ымлады:

—Син Томканы шулкадәр яратасың икән... Синең язганнарыңны укыгач, тәннәрем чымырдап китте, кызгандым үзеңне. Беркайчан да шулай өзгәләнергә мөмкиндер, дип уйламаган идем. Укыганым өчен гафу ит инде, өстәлдә ачык килеш ята иде бит...—дип, аптырашта калган Дасаевны кочып алды.

Күңеле бик үк йомшак булмаган Моряктан Рушан мондый гамәлне һич көтмәгән иде.

—Әйдә, мәхәббәт өчен, Тамара өчен эчәбез! Мин инде бер шешә дә алып кайтып куйган идем,—дип, көтелмәгән тәкъдим ясады Калашников.

Шәраб эчеп утырганда Моряк кыз янына хушлашырга Рушанның үзенә барырга, билгеле инде, хатны да үз кулына тапшырырга кирәклегенә ышандырды.

Рушанның Актүбәдәге соңгы киче, чигенер урын юк—иртәгә кич белән ул бу шәһәрне бөтенләйгә ташлап китәчәк. Әбәттән соң, язылган дәфтәрләрен кыстырып, ул «1905 ел» урамына китте.

Кыңгырау тавышына Тамара үзе килеп чыкты һәм шунысы сәер, Рушанның килүенә бер дә гаҗәпләнмәде. Гүя көтеп торган шикелле елмаеп, өйгә керергә чакырды, әмма Рушан кереп торырга кыймады. Кичә диплом алганын, бүген үзенең соңгы киче икәнен, иртәгә бөтенләй китеп барачагын әйтте һәм үзе белән хет бер киногა баруын үтенде. Дәфтәрләрен сузып, өстәде: «Ә монысы минем сиңа әллә кайчан әйтәсе килгән сүзләрем...»—диде. Тамара дәфтәрләрне илтифатлы гына кабул итеп, аның үзен кич кино-фәләнгә алырга кайчан килерен сорады.

«Өнемме бу, төшемме?»—дигәндәй, моның чынбарлык икәненә һаман да әле тулысынча ышанып җитмәсә дә, күңеленнән акыллы киңәше өчен Морякка рәхмәтләр укый-укый, ул килер вакытын билгеләде. Моряк аның «хатларына» күз төшермәгән булса, Дасаев Тамара янына килергә базыр идеме икән? Ай-һай!..

Тулай торакка кайтып барышлый, юлда ул Наил Сафинны очратты, тегесе Рушан әле генә китеп барган йорт ягына таба атлый иде. Рушан аның белән баш кагып кына исәнләште, үзенең шатлык-куанычын сиздереп тормады.

Мескен Наил, Рушанның Резникова яки Новова өчен кирәге шулкадәр генә булган шикелле, Тамара өчен аның да кирәге шулкадәр генә булганлыгын аңлый идеме икән? Алар икесе дә, әлеге кызларның нindидер хәйлә-мәкерле уеннарында билгеле бер роль башкарганнан соң, кызларга кирәкләре калмагач, сәхнәдән куылып төшерелмәделәрме?

Моның шулай булганлыгын Рушан әле шул чагында ук аңлаган иде.

Билгеләнгән сәгатьтән күп алда килеп, кыз йортының каршысында, инде чәчәген койган сәрби куаклары күләгәсендә басып торганда да, ул әле, янкапка ачылыр да аннан Тамара килеп чыгар дип, бөтенләй ышанып бетми иде. Шунда ул кинәт кенә теге еракта гы кызны хәтерләп алды: шәһәргә килүенен беренче көнендә үк Рушан бит, кулына ноталар папкасы тоткан ул кызны «Тимерлек» янында очратып, сихерләнгән кебек, аның артыннан ияреп китеп барган һәм нәкъ менә шушы урында, ачык тәрәзәдәге челтәр пәрдә артында кыз шәүләсе күренүгә өметләнеп, бик озак басып торган иде. Һәм менә бүген—беренче сүз куешып очрашу, бу очрашуга юл бик озын—дүрт елга сузылган булып чыкты.

Тамара билгеләнгән минутның минутында күренде, еракта н ук сокландыргыч елмаеп, инде күптәннән очрашып йөргән шикелле итеп, табигый генә сорап куйды:

—Йә, бүген без кая барабыз, Рушан?

Рушан парк янындагы «Культфронт» кинотеатрына билетлар алган иде, «Адские водители» (татарчасы «Тәмуг шоферлары» буладыр инде) дигән инглиз фильмына керергә тәкъдим итте, ә аннары, кәефләре булса, бию мәйданчыгына да сугылып чыгарга мөмкин. Шул җәйге кичтән соңгы бөтен гомере буена Рушан ул мавыктыргыч фильмны кайчан да булса бер янадан экранда күрергә хыялланды, Тамара белән бердәнбер очрашып, аның янында утырганда, кызның кайнар кулларын үзенең кайнар учларына алып тотканын, кызның исә аларны тартып алырга тырышмаганын—икесенең дә бармаклары кушылып-үрелеп, берберсен танып иркәли-иркәли, ниндидер тылсымлы сүзләр сөйләшкәнен янадан кичерәсе килә иде. Ул әлеге фильмны да, шул ук вакытта, кызның үзе янында икәнлегенә һаман да ышанып җитмичә, аның гүзәл йөзеннән күзен ала алмыйча диярлек утырганын да яхшы хәтерли иде.

Кинога кадәр дә, кинодан соң Бродвейда икәүләп йөргәндә дә, ул кичтә Рушанның кайчандыр Феллини фильмындагы Кабирия шикелле:

—Күрегез, мин кем белән барам! Мин Давыдычева белән барам! Тамара минем янымда!—дип, шар ярып кычкырасы килә иде.

Әлбәттә, җәйге кичтә аларның бергә күренүләрен шәйләми калмадылар—мәктәпләрдә чыгарылыш кичәләре шаулап үткән генә, студентларның имтиханнары тәмамланган чак, озын-озак җәйге каникулларны алдан ук сизенеп ләззәтләнгән-кинәнгән яшьләрдән урамнар гөрләп тора, алар да үзләренең күп кенә дус-ишләрен һәм танышбелешләрен очратып йөрделәр. Рушан беркемнең дә гаҗәпләнмәгәненә янадан таң калды: аның Бродвейда Тамара Давыдычева белән күренүе, әйтерсең, көн дә була торган бер эш иде.

Кинодан соң паркта йөргәндә Рушан кыздан биергә керергә теләге юкмы икәнен сорады. Тамара:

—Билгеле, биисем дә килә,—диде.—Ләкин бигрәк тә синең белән буласым килә, син бит иртәгә китеп барасың. Аннары без ике авыз сүз дә алыша алмаячакбыз, егетләр бер-бер артлы килеп, синең белән хушлаша башлаячаклар. Безнең бердәнбер кичебез монсу-күнелсез үтмәсен иде, һаман да синең китеп барачагыңны искә төшереп торуларын теләмим. Иң яхшысы, әйдә, бакчадан чыгып китик тә, тын урамнарда йөрик, безнең сөйләшер сүзләребез байтак бит...

Тамара белән бергә үткәргән бу кичен дә Рушан һәрьяклап җентекләп күз алдына китерә алмас иде, ул кич, дистәләрчә вак кисәкләргә бүлгәләнеп, аның хәтерендә аларның һәркайсысы ниндидер сагышлы, аерым-аерым нәрсәләр булып тезелә, бөтенесен дә бер төнгә сыйдырып бетереп тә булмый иде бугай.

Алар Тамара белән таң атканчы, Алма-Ата экспрессының гудок тавышларын ишеткәнче йөрделәр. Икесе өчен дә сонлап килгән бу очрашу Резникова белән үткәргән Яна ел төненә бик охшаш иде: шул ук көтелмәгәнлек, шул ук мәхәббәттә аңлашу, көтелмәгән үбешүләрдән

шулай ук тетрәнү-калтырану һәм хәтта шундый ук күз яшьләре...

Саубуллашканда алар үз бәхетләренә чынлап ышанганнар, әйтелеп-сөйләнеп бетмәгән сүзләр, анлашылмаулар һәм бозылышулар артта калган дип өметләнәләр иде.

Шактый вакытлар үткәч, шигърият белән мавыгуы рәсем сәнгатенә китереп чыгарып, ул үзе өчен импрессионист рәссамнар дөньясын ачканнан сон, Рушанны Клод Моне хезмәтләре таң калдырыр. Мәсәлән, бу рәссамнын, көн яктылыгы үзгәреп торуына карап, бер үк ноктадан торып, тәүлекнен төрле мизгелләрендә Нотр-Дам күренешен сурәтләгән рәсемнәре. Менә шунда Рушан үзенең сокландыргыч өч кыз, гүзәл затлар— Светланка Резникова, Ниночка Новова һәм Тамара Давыдычева белән мөнәсәбәтләренә кагылышлы билгеләмәләр табар, чөнки анда да, Клод Моне рәсемнәрендәге шикелле, бер үк башлангыч нокта булыр, ул да булса—мәхәббәт. Чикләнмәгән саф композицияле һәм көтелмәгән ракурслы ул рәсемнәрдә Нотр-Дам иртән дә, көндез дә, кичен дә нинди гүзәл һәм кабатланмас бер иҗат җимеше булса, Рушаннын хисләре дә бер яктылык, бер нур белән өртелгән—ул мәхәббәт нуры иде. Ул үзе онытылып-мавыгып йөргән әлеге кызларның бирсен дә, беркайчан да начар итеп хәтерләмәде, хәтта кайчандыр йөрәгендә мәхәббәт очкыны кабызган «1905 ел» урамында яшәүче кыз белән үткәргән бердәнбер кыска төн дә хәтерендә язмышынын иң бәхетле бүләге булып калды. Болар берсе дә арттырып әйтү түгел иде...

Яшьлегендә мәхәббәт үзенә мәңге килмәс кебек тоелган, бөтенләй өмете өзелгән бер мизгелдә анын башына хәтта: «Әллә бу тормыштан китәргәме?»—дигән ямьсез уй да килгән иде. Ләкин ул үзе сөйгән кызлар белән хушлашмыйча китеп бара алмый иде, шуна күрә, һәрберсенә хатлар язды, хатларында алар белән кичергән, алар бирсп өлгергән шатлыклы-бәхетле минутлары өчен рәхмәт әйтте, алардан башка бу дөньяда яшәүнең бер мәгънәсе дә калмаганлыгын бәян итте. Һәр хаты, күчергеч кәгазе куеп язган шикелле, бер үк сүзләр белән тәмамланган иде: «Хушыгыз, мин Сезне яраткан идем...» Анын кул астында бер адрес юк булып чыкты, Давыдычеваның яңа адресы. Ул аны эзләп-белешеп маташкан арада, үз-үзенә кул салу уе да үзлегеннән юкка чыкты. Димәк, тормышы белән дә ул «1905 ел» урамында яшәүче кызга булган мәхәббәтенә бурычлы иде. Шунысы гаҗәп, бу вакытта ул әле атаклы Жан Коктонын мәхәббәт хатлары белән таныш түгел иде...

Алга таба тормыш үзгәрде, илленче еллар азагында тимерюлчыларның ике мәктәбенә кичәләргә йөрүчеләрдән Актүбәдә берсе дә калмады. Язмыш аларны ил буйлап чәчеп-сибеп бетерде, күпләренен туган-тумачалары да күченеп китеп беттеләр. Туган якларында Рушан гына, мөгаен, ешрак була торгандыр. Кайткан чакларында, ул джаз яратучы мәрхүм прокурорнын каберен зиярәт итә, искереп барган Бродвейдан үтә, монсу «1905 ел» урамына һәм Кызыл урамына барып чыга, анда инде күптән чит кешеләр яшәсә дә, Рушанны бик теләп йортка үткәрәләр. Әлбәттә, анда хәзер ерак калган бәхетле көннәрне бернәрсә дә искә төшереп тормый, тәрәзә каршындагы колач җитмәс чал тупыллар белән кыргыйланып беткән фарсы сирене куаклары булса гына инде.

Кайчагында ул үз-үзенә: «Җитәр, сонгы мәртәбә»,—ди, әмма һәр кайтуында, йөрергә чыккач, «1905 ел» урамындагы шул йортка барып төртелә. Нәрсә бу—йөрәк хәтереме?

Бервакыт Валя Домарова ана үзенен студентлык елларында бәйрәмнәргә кайтып йөргәндә төнге поездларда һәрвакыт бер сары чәчле егет белән Тамараны очратканын сөйләгән иде. Рушан Тамаранын Оренбург пединститутында укыганын, хәтта анын Совет урамы, 100 нче йортта фатирда торганын да белә иде. Бер шулай ул әлеге фатирга да барып чыкты, хуҗабикә үзендә кайчандыр фатирда торган чибәр кызны бик тиз исенә төшерде.

—Ә сезне мин хәтерләмим,—диде ул, кинәт күнелсезләнеп.

Рушан үзенең биредә беркайчан да булмавын әйткәч, хуҗабикә монсу гына өстәп куйды:

—Димәк, сез дә аны яратып йөрдегез, Тамараны, дим...

Ялгызлыктан туйган булгангамы, әллә башка сәбәп беләнме, ул Рушанны чәй эчәргә утыртты. Аннары сөйләп китте:

—Беләсезме, ул һәрвакыт үзен яраталармы-юкмы дип шикләнә, борчыла торган иде. Ана табынып йөрүчеләр күп булды, һәммәсе дә менә дигән егетләр иде, әмма ул ниндидер аңлашылмас мәхәббәт көтә: үлгәнче бары тик аны гына сөюләрен тели иде... Шул кадәр вакыттан соң менә сез килеп чыктыгыз, ә бит ул миндә биш ел торды, беркем дә аны искә төшереп янадан килеп күренмәде, димәк, сез аны барысыннан да ныграк яраткансыз...

Байтак еллар элек үзенең сөеклесе яшәгән бүлмәне күздән кичергәч, Рушан дөресен әйтүне кирәк тапты:

—Әйе, мин аны бик ярата идем...—диде.

## XXII

Тормыштагы бөтен хәлләрне дә алдан күреп бетереп булмый, кайбер серләр хуҗалары белән бергә гомерлеккә китеп баралар, ә кайберләре, әйтик, Рәшит абыйның Туган көне шикеллеләре, соңлап булса да, ачылалар.

Бервакыт, эш белән Кавказга командировкага баргач, Дасаев үзен борчып торган тагын бер тарихның серен көтмәгәндә генә ачкан иде, дөресрәге—шуна дәлилләү тапкан иде. «Баку-Тбилиси» поездында барганда, бер кызыклы мажарага тап булды ул.

Тбилисидә ул Гобискерия джаз-оркестрын, ә Бакуда шул елларда джаз музыкасын аранжировкалаучы атаклы Кальварский эшләгән Рәүф Гаджиев оркестрын тынларга өметләнгән иде. Поездга алданрак төште—кузгалып китәр алдыннан була торган ыгы-зыгыны яратмый иде, йомшак урынлы буш вагон купесыннан ашыкмый гына үз урынын эзләп тапты да коридордагы тәрәзә буена чыгып басты.

Вагон әкренләп тула торды, тәрәзә буендагы Рушан берәүгә дә комачауламый иде. Поездга ул туп-туры концерт залыннан чыгып килгән һәм эш белән командировкага баручы инженерга бик аз охшап тора иде.

Перронны, шәһәрне артта калдырып, поезд кузгалып китте...

Эңгер-меңгер карангылана-куера барганлыктан, коридорда ут кабыздылар. Пассажирларның кайберләре ресторанга юл тотты, кайберләре купедагы өстәлчеккә ашамлыклар тезә башлады, ә Рушан, кешеләр ниндидер кабатланмас, шул ук вакытта һәммәсе өчен дә бер төрлерәк тормыш белән яшәп яткан авылларны игътибар белән күзәтә-күзәтә, тәрәзә буенда басып тора бирде, фараларын кабызып, авылга ашыгып кайтып баручы ялгыз машинаны да искәртте, мөгаен, шоферны гаиләсе, балалары көтә торгандыр, ә бәлки, сөйгән кызы белән очрашасы бардыр, ул кызның таныш булмаган йорты берничә минуттан тәрәзәләрендәге якты утларын балкытып күренер дә менә-менә төн карангылыгында эреп югалыр.

Рушанның юлдашлары шунда ук кичке ашка утырдылар. Вагонга кофе, кыздырылган тавык, яна пешкән хачапури һәм ләваш исләре таралды, кайдадыр инде жырлаган тавыш та ишетелде.

Алар купесы белән янәшәдәге купеда чуар публика иде: яшь кенә бер егет, чәчләренә чал төшсә дә, яшь чырайлы бер карт, берничә ир кеше һәм хәтта бер сөйкемле генә кыз. Кыз, Рушан кебек үк, гел генә тәрәзә янында басып тора, әмма, аннан аермалы буларак, үз теләге белән тормый иде шикелле. Карт, ихтимал, урыстыр, яшь егет белән кыз—әрмәннәр, калганнары—грузиннар яки осетиннар. Аларның киемнәре дә бер-берсеннән аерылып тора: ике ир кеше һәм мөгаен, карт та

Тбилисинең Руставели проспектында борын чөеп, кыланып йөрүче көязтәти егетләрдән калышмаслыклар, ә калганнары йомшак урынлы вагон пассажирлары дип кабул итәрлек тә түгел иде.

Поездга бернинди багажсыз, хәтта сумка-портфельләрсез дә утырган бу төркем шулай ук кичке аш дип мәш килә башлады. Яшь егет белән кыз ресторанга барып килергә теләделәр һәм купе эченнән кемнендер хуплау сүзен ишеттеләр. Дасаев яныннан үтеп киткәндә, яшьләр аңа кызыксынып карап уздылар, ә кыз хәтта елмайган сыман да булды әле.

Тәрәзә артында бөтенләй карангыланды, тәрәзә янында басып торунын кызыгы калмады. Анын юлдашлары күптән ашап туйганнар, Рушан исә купега кереп утырыргамы, әллә ресторанга барыргамы дип, уйланып тора иде, шунда кинәт кенә әлеге күрше купедән берсе, Рушан осетин дип чамалаганы, әдәпле генә, хәтта бары тик Кавказ халыкларына гына хас дип әйтерлек түбәнчелек белән аны үзенең тыйнак табынын уртаклашырга чакырды. Рушан да әдәпле генә итеп рәхмәт әйтте, апетиты булмау, башы авырту һәм ялгыз каласы килүне сылтау итеп, сыйдан баш тартты.

Бер минут та үтмәгәндер, тегеләрнең икенчесе күренде һәм шулай ук әдәпле, әмма катгыйрак итеп чакырды. Аларның бәйләнчекләнеп дәшүләренә Рушан үртәлә башлаган иде, шуңа күрә, үз купесына кереп китәргә ашыкты. Ул кереп утырырга да өлгермәде, ишек ачылып китте дә яшь чырайлы картның чал чәчле башы күренде, ул Дасаевның бер генә минутка коридорга чыгып керүен үтенде.

Карт теләсә кайсы грузин тамадасына биргесез тасма телле булып чыкты. Ул кунакчыллык кануннары турында, юлда барганда яңа кеше белән шәраб уртлап сөйләшеп утыруның күңеллелеге турында сөйли башлады. Кыскасы, Рушан үзенең бу картның көчсез, әмма каты кулларыннан ычкына алмасын аңлады,—карт, чынлап та, әле анын пинжәк төймәләрен бөтерә, әле жиненнән тотып тарткалый иде,—Рушан бирелде. Георгий Павлович белән—карт үзен шулай дип таныштырды,—күршеләргә барып кергәч, анда ихластан куанып, шундый итеп кычкырып җибәрделәр, мөгаен, бу тавышны күрше вагоннарда да ишеткәннәрдер. Рушанны тәрәзә янынарак, Георгий Павлович каршысына утырттылар. Өстәлдә оста гына ботарлап куелган күркә ите өелеп тора, янәшәсендә—үләнсәлән, әче борыч, помидор, әрмән сыры, грузин брынзасы һәм йомшак Баку чурегы иде.

—Нәрсә эчәбез?—дип сорады карт, Рушан ак абхаз шәрабе «Бахтриони»га ымлады.

Кемдер юллар уң булсын өчен тост тәкъдим итте, мәҗлес башланып китте. Стаканнарны бер дә буш тотмадылар, өстәлдән бик оста гына итеп, сиздермичә генә кирәкмәгән нәрсәләрне алып, әле ветчина, әле кыздырылган ит, әле тиз бетә барган үлән-сәләнне өстәп кенә тордылар. Рушан икенче каттагы киштәдә зур бер кәрзин шәйләгән иде, сыйнигъмәтне шуннан алалар, анын бетәсе юктыр, ул кәрзин тылсымлыдыр төсле тоела башлады.

Баштарак сүз һич тә ялганып китә алмады. Бер-бер артлы тостлар әйтелә, «сал», «алып бир», «капкалап куй» кебегрәк сүзләр ишетелә, аннары урыс һәм грузин телләрендә рәхмәт сүзләре яңгырый иде. Ләкин шушы аз сүзле әңгәмәгә хуҗалардан бары тик өч кенә кеше катнаша: Дасаевны башта чакырган икәү белән Георгий Павлович кына, картның болар өстеннән аксакалларча хакимлек иткәне күренеп тора. Калган икесе, юньләп кырынмаган йөзләренә тавыш-тынсыз соклану төсе чыгарып, өстәл өстен карый, стаканнарны бер дә буш тотмый, бик оста гына итеп теге тылсымлы кәрзиннән сый-нигъмәт ала тора. Көтмәгәндә генә сүзләр тынып калды, әллә махсус шулай эшләнде, шул арада карт:

—Кая барасыз, нәрсә белән шөгыльләнәсез, яшь кеше?—дип кинәт кенә сорап куйды.

—Инженер мин, Тбилисига командировкага барышым,—дип, сүрән

генә жавап бирде Дасаев. Ул, аның гади инженер гына икәнлеген белгәч, тегеләрнең кызыксынуы шунда ук юкка чыгар дип уйлаган иде.

—Инженер?... Командировкагамы?.. Мин бит сезгә әйткән идем,— Георгий Павлович үзенең юлдашларына карап сөйли башлады.—Өйрәнегез: менә нинди мәктәп, югары пилотаж, мин аның яшендә андый данны белми идем әле. Ә коридорда ничек басып торды ул! Сокланырлык бит: турист, артист инде, чын менә... Пейзаж, кояш баешы, пленэр... Ә Дато һәм Казбек белән ничек сөйләште, әйтерсең, аларны үз гомерендә бер дә күргәне булмаган! Бу бит искиткеч! Станиславский! Әгәр теләсәгез— Мейерхольд!...

—Минем, чынлап та, ни сезне, ни сезнең юлдашларыгызны бервакытта да күргәнем юк,—дип, картның сүзен бүлдерде Рушан.

—Бөтенләй күргәне булмаган,—дип елмайды Георгий Павлович, купе эче бер биш минут көлү тавышларыннан тетрәнеп торды.

Дасаев, бернәрсә дә анламыйча, табындашларын күзәтә, бу сәер юлдашлары аның һәр хәрәкәтен хәтерләрендә калдырырга тырышып, үзенә сокланып карап торганнарын күрә иде. Мондый илтифатны ул әле беркайчан да тоймаган иде.

—Әйе, Марсель Марсель шул инде, аның турында зонада да, иректә дә юкка гына легендалар йөрми,—дип сүзгә кушылды Дато дигәне.

—Сез нәрсәнедер бутыйсыз, мин—Дасаев, Ташкенттан инженер,— үзен әллә шаярткannарын, әллә, чынлап та, ниндидер Марсель белән буташтырганнарын анламыйча, айный төшеп җавап бирде ул.

Купе тагын шырык-шырык көләргә тотынды. Георгий Павлович, яшьләнгән күзләрен юка батист кулъяулыгы белән сөртә-сөртә:

—Бәлки, ксиваңны күрсәтерсең, Дасаев...—дип сорады.

Мартукта яшәгәндә үк Рушан жинаятьчел жаргонны яхшы ук белә иде. Пинжәгенең эчке кесәсеннән паспортын алып, аны өстәл аша Георгий Павловичка сузды.

Купеда тынып калдылар, картның паспортны оста-житез бармаклары белән әле тегеләй, әле болай әйләндергәләгәнен игътибар белән карап тора башладылар. Георгий Павлович паспортны хәтта борынына якын китереп, жентекләп иснәп карады—тешләп караса да, беркем дә елмаеп та куймас иде шикелле.

—Һәйбәт ксива, исе дә чын,—диде, ниһаять, Георгий Павлович, паспортны кайтарып биреп.—Димәк, кәгазьләрең тәртиптә, тиз булдыргансың... Дато сине ксивасыз дип уйлаган иде. Ул бит соңгы мәртәбә синең белән бер зонада матавыкланды. Исенә төшер әле, аның кушаматы—Лорд, ә фамилиясе—Гвасалия. Ул хәзер әнә нинди франт, нәкъ сиңа ярдәмче булырлык, «интеллигент». Ярдәмче кирәкмиме, Марсель?

—Гафу итегез, арыдым мин, иртәгә минем мөһим эшләрем бар, мин сезнең шаяртуларыгызны анламыйм,—дип, Дасаев урыныннан күтәрелә башлады.

Карт аны йомшак кына, әмма таләпчән итеп кире урынына утыртты.

—Утыр, Марсель. Безнең белән аралашырга телисеңме-юкмы, анысы синең эш. Әйе, дөрестән дә, син хаклыдыр, синең кебек житди кошка бирсдә таныш түгел йөзләр артык күп. Син мин картны гафу ит инде, шатлыктан бит—синең хакта күп ишеттем, Дато да синең ничек юкка чыгуынны сөйләгән иде. Димәк, зур эш майтарырга барасың, уңышлар сиңа. Әгәр ярдәм кирәк булса—акчамы анда, хазамы... Менә, Тбилиси һәм Орджоникидзедагы адреслар, телефоннар...—карт оста хәрәкәт белән Рушан пинжәгенең күкрәк кесәсенә алдан ук әзерләп куелган кәгазь кисәген тыкты.

Алар шулай аерылыштылар.

Иртә белән поезд Тбилисигә килеп туктаганда, әлеге сәер юлдашлар юк иде инде—әллә төрле вагоннарга таралганнар, әллә башкалага житәрәк төшеп калганнар. Ләкин алар әле үзләрен тагын бер кат искә төшерделәр...

Тбилиси кунакларына Мтацминдада булырга киңәш итәләр, аннан аста җәйрәп яткан шәһәр манзарасы бик матур күренә, шунда ук—искиткеч гүзәл бакча, җәйге кинозаллар, ресторан. Йөреп арыгач, таулардан искән җилдә туныш калтырана башлаган Рушан Мтацминдада ашап чыгарга булды.

Залда һәм ачык верандада шаулашып кәеф-сафа корып утыралар иде. Ул яраткан «Регина» рестораныныкыннан ике мәртәбә зур оркестр уйнап тора, ике җырчы, берсен-берсе алыштырып җырласалар да, төрле яктан ишетелеп кенә торган заказларны башкарып бетерергә өлгерә алмыйлар. Һавада кыйммәтле хушбуй, затлы сигарет һәм өстәлләрдә кукраеп утыручы шәраб исләре эленеп тора, дәртле бәйрәм хисе ташып чыккан иде. Рушан үзе шикелле үк командировкага килгән кешеләр җыелышып утырган өстәл яныннан көч-хәл белән генә бер буш урын тапты.

Официантның бөтен кыяфәте дамаларсыз ялгыз гына килгән кунаклардан риза түгеллеген анлата—үз ихтыярында булса, ул Дасаев һәм анын ишеләрне бусагадан да үткәрмәс иде. Тулышып торган тук янакларын ялкау гына тартыштыргалап, ул заказны, ни өчендер авыр көрсенә-көрсенә, теләр-теләмәс кенә тынлый, сүзләрен дә теш арасыннан кысып кына чыгара:

—Юк... юк... бетте... булмый... бервакытта да булмаячак...

Рушан, каршы килеп, көйсезләнеп азапланса, үзенең ышанычсыз чакырылмаган кунак хәлен тагын да катлауландырачагын анлый иде, шуна күрә, буйсынып ризалашты:

—Ярар алайса, нәрсә калган булса, шуны китерегез,—диде. Аннары:—Бер шешә ак шәраб тә...—дип өстәде.

Официант шактый озак югалып торды. Шиңеп беткән үлән-сәлән, кипшенгән сыр кисәге, салкын хачапури белән бер шешә шәраб китерде. Шашлыкны сонрак китерәчәген мыгырданып кына әйтте дә икенче өстәлгә—шау-гөр килеп типтерүчеләр янына китеп барды.

Кирәгеннән артык әчегән шәрабка авызын тигереп тә өлгермәде, әйтерсен, җилләр ташлады, Рушан янына метрдотель белән теге официант килеп житте—әле генә үзе белән шактый озак һәм бик «эчтәлекле» сөйләшеп торган официантны башта Дасаев танымый да торды, тегенен йөзе төче елмаюдан шулкадәр үзгәреп киткән иде.

—Гафу итегез, хаталык килеп чыкты,—дип, официантка усал караштыргалап, сөйли башлады метрдотель, ә тегесе, бер гөнаһсыз кеше кыяфәтендә корсагын җыя төшеп, шундый үкенгән төс белән басып тора иде, аны кызганудан елап җибәрерсен, билләһи!

Алар Рушан кулындагы фужерны көчләп диярлек тартып алдылар, эчендәге эчемлекне чәчәкләр куя торган вазага җирәнеп, чырай сытып кына түктеләр, әйтерсен, ул шәраб түгел, агу иде.

—Бәлки, аерым өстәл әзерләргәдер?—дип Рушаннын колагына пышылдады зал хуҗасы, анын күршеләренә карана-карана, ләкин Дасаев бу тәкъдимне кире какты.

Күз ачып йомган арада арба белән тәгәрәтеп җиләк-җимеш, сусыл үлән-сәлән, чикләвекле лобио, сулугуни һәм Рушанга таныш булмаган башка грузин ашамлыклары китерделәр, метрдотель әллә каян гына килеп чыккан авыр бәллүр бокалга үз кулы белән алтынсу «Твиши» салды. Циркка тин булырлык бу тылсымлы үзгәрешне күргәч, өстәлнен икенче башында утыручылар Рушанга кызыксынып караштыра башладылар.

Дасаев бу кадәр сый-нигъмәтнең үзе уйлаганнан бер биш тапкырлар артыграк бәягә төшәсен чамалап алды, әмма шәраб искиткеч, ризыклары менә дигән булып чыкты, оркестр да шәп уйный, Рушаннын күнеле күтәрелеп китте. Әллә башына шәраб йөгергәнлектән, әллә күнелендә кузгалган шуклыктан, әллә залнын аргы башында бер өстәл тирәсенә утырган Казбек белән Датоны күреп алганлыктан, ул ниндидер бер кызны биергә чакырды да үзен... Марсель дип таныштырды.

Бәлки, кыз аны ошаткандыр, ә бәлки, исемен яраткандыр, ул кич буе: «Марсель... Марсель...»—дип сайрады. Ят исемгә Рушан үртәлмәде, исем вакыт-вакыт хәтта ягымлы булып та ишетелде, ә әллә нинди гайре табигый хәлләрсез генә үтеп киткән бу кичтә чит исем белән яшәп кенә калмады, үзен алдына юмарт өстәлләр куела һәм илтифатлы-ягымлы йөзле официантлар күз ачып йомганчы хезмәт күрсәтә торган шул серле Марсель итеп тә тойды...

Иртәнгә кадәр кайнап-гөрләп тора торган Руставели проспектына фуникулерга утырып төшкән чагында ул, гел урынсыздан гына, кинәт Валя белән Мартуктагы күптәнге очрашуны хәтерләп алды. Менә сина—Лорд!..

Тирә-якта төнге Тбилиси шаулый, гөлт итеп яктыртылган проспекттан Рушанның каршысына матур киенгән кешеләр килә, алар әледәнәле үзләренең таныш-белешләре белән нәзакатле генә баш иеп исәнләшеп узалар, шәһәр гел шул дус-ишләрдән, таныш-белешләрдән генә тора, диярсең. Рушанның бер генә дә сагышлы-моңсу уйлар уйлыйсы килми иде. Әмма сабына ачык кызыл ефәк «күбәләк» куелган гитарасын тоткан Валя башыннан чыкмый гына бит! Ул хәтерендәге бу күренешне тырышып-тырышып куып җибәрмәкче була, ләкин булдыра алмый, Валя сурәте, күз алдыннан китмичә, һаман комачаулап, күңелне борчып тора.

Кинәт кенә һәммәсе дә урынына утырды. Дато Гвасалия... Дато Гвасалия! Валяны шампан шәрабендә коендырган, аңа энже муенса бүләк иткән Лорд!

«Булмас!»—дип, үз уйларын кире какты Рушан. Әмма хәтере, ялагайланып, Георгий Павловичның тавышын яңгыратты: «Аның кушаматы—Лорд, ә фамилиясе—Гвасалия...» Юк, хата булу мөмкин түгел иде, һәммәсе дә туры килә.

Рушан Мтацминдага кабат барырга дип, кире борылып, фуникулерга ашыкты—грузин ресторанннарыннан кунакларның иртә таралмаганнарын белә иде ул.

Ул әйләнеп килгәндә, залда әле күңел ачу дәвам итә, ләкин Лорд үзенең дуслары белән кәеф-сафа корып утырган өстәл буш иде инде.

Әлеге таныш метрдотель, кунакның дулкынланган йөзен янадан күреп алып, шунда ук аның янына килеп җитте, илтифатлы итеп сорады:

—Нинди ярдәм кирәк?

—Лорд күптән киттеме?—дип, игътибарсыз гына сораган булды Рушан.

—Юк, күптән түгел, сез, мөгаен, фуникулерда аймылыш булгансыздыр. Әгәр берәр проблемагыз булса—биредә Датоны яхшы белүче кешеләр бар, алар Марсельнең дә һәр теләген үтәргә әзерләр. Дато үзе дә мина сезне һәрвакыт патшаларча каршы алырга кушты...

—Рәхмәт, мина Лорд кына кирәк иде,—Дасаев инде саубуллашып чыгып китәргә җыенган иде, ләкин метрдотель, әгәр дә кунак кичтән булган хөрмәтсезлекне кичерсә, үзе белән берәр шешә шәраб эчүен үтенде. Эчәргә туры килде.

Фуникулерның ярым буш вагонында кайтып барганда, Рушан уйлап куйды: «Әгәр дә Лорд кушаматлы Дато Гвасалияне залда очраткан булсам, нәрсә әйткән, нәрсә сораган булыр идем икән? Минем яшүсмер чагымдагы мәхәббәтем булган Валя Домарованы шампан шәрабендә коендырдынмы, аңа энже муенса бүләк иттеңме, дипме?» Бу уйларының мәгънәсезлегеннән ул кинәт эчкерсез көлеп җибәрде, кайчандыр Мартукның төнге тын урамында, санузелы да шул кысан бүлмәдә булган пычрак ваннада шәраб эчендә чупырдап ятучы Валентинаны күз алдына китереп тә шулай көлеп җибәргән иде ул...

Хәзер инде Валентинаны сирәк искә төшерә, күңелендә аңа карата нәфрәт тә сакламый, гаепләми дә. Тормыш тәҗрибәсе биеклегеннән карап, һәркемнең үз юлын үзе сайлаганын аңлыйсың. Ләкин Рушан шунысын һич төшенә алмый: йөз миллионлаган кешеләр арасыннан

кайчандыр балерина булырга хыялланган кызны җинаятьчел романтика белән мавыктыра алган ниндидер Лорд кушаматлы карак белән үзен очраштыру язмышка нигә кирәк булды икән? Ихтимал, әлеге сорау да аны гомеренең соңгы көннәренә кадәр бимазалап торыр әле...

## XXIII

Бала һәм яшүсмер чагындагы, аннары үсеп житкәч тә, үзе күргән-белгән кешеләрне хәтеренә төшергәндә, Рушан еш кына күңеле белән туган йортына, димәк, әти-әниләре янына әйләнеп кайта. Хәтерендә гадәттә ике вакыйга янара. Берсе—алар гаиләсенә Исмәгыйль абый әле килеп кермәгән чагында әнисе белән булган хәл, икенчесе—гомер кояшы баеп барган үги әтисе Исмәгыйльгә бәйле вакыйга.

Ул кышта Рушан әллә беренчедә, әллә икенче сыйныфта укый иде...

«Поезд соңлагандыр»,—дип, Рушан бозланып каткан тәрәзә пыяласын сулышы белән өреп эретмәкче була, әмма күпме генә тырышмасын, бозны эретерлек түгел. Суык бабай булдырган, хәтта ике рам арасына да боз таулары күтәрелгән, иске одеал кисәкләре белән ярыкларын, шадра бусага тирәләрен ничек кенә тыгызласаң да, һаман салкын керет тора, тәрәзәдән дә шундый ук салкын бәрелә иде.

«Кертеп тутырган»,—дип уйлады малай, «ишекне юньләп карамагансың, землянканы суытып бетергәнсең», дип, әнисе ачуланудан куркып, ул җир идәндәге карны себереп алды. Мич җылымса гына иде, ләкин Рушан тирес кирпечен өстәргә кыймады: ягар әйбер бөтенләй юк диярлек иде. Сентябрьдән үк жилләп, янгырлар явып торды, хәзер инде ярым җимерек сарайның бер почмагында гына бераз тирес кирпече калган иде.

Сәкегә менеп утырып, мичкә елыша төшкәч, Рушан мамык тутырылган төенчекне үзенәрәк тартты һәм, әнисе кушканча, мамыктагы йон кисәкләрен чүпли башлады. «Тизрәк мәктәптән Сания кайтсын иде инде»,—дип, күңелсезләнеп уйланды ул, юкса, сигезенче сыйныфларның икенче сменасы бөтенләй караңгы төшкәч кенә беткәнен дә белә үзе.

Чистартылган мамык тавы бик әкрен үрчи-үсә, малай, тәҗрибәле күзе белән карап, бу төенчек белән әле тагын берәр атна чиләнәсе барын чамалый.

«Синең, улым, күзләрең яшь, үткен,—дигән иде әнисе.—Мартукта беркем дә мамыкны синең кебек әйбәт итеп чистарта алмый»,—дип мактап та куйган иде әле. Кем инде мактаганны яратмасын?!

Кышкы озын төннәрдә алар, зур керосин лампасы тирәсенә сырышып, сәкедә утыралар, һәркем үз эше белән мәшгуль. Сания җеп эрли—әнисе: «Аның бармаклары мамыкны әйбәт тоя, анардан менә дигән шәлче чыгачак»,—дип, кызын да мактарга онытмый. Чынлап та, кызның эрләгән җебе тигез, нечкә була. Әнисе улы чистарткан мамыкны ике рәтле, биек-озын энәле куркыныч тарак аша тарап үткәрә, ни өчендер аны «чегән тарагы» дип йөртәләр. Әнисенең куллары тарак өстеннән очынып-очынып китә, Рушан һәрвакыт тарак тешләренә тиеп, аның кулы җәрәхәтләнер дип курка.

Әнисе балаларын «оста-житез ярдәмчеләрем» дип ничек кенә мактамасын, үзеннән дә остарак, унганрак шәлче Мартукта юк иде. Һәр өченче кеше шәл бәйләү белән туенып торган Мартукта Гөлсем апага тиңнәр, дөрестән дә, юк иде шул, аның шәлләре тиз һәм җинел мамыкланалар, озакка чыдыйлар, каймалары күз явынны алырлык кин, берсе икенчесенә биргесез тигез тешле, һәр шәлнен кабатланмас үз бизәге булыр иде.

Мамык тутырган төенчек хуҗабикәсе, кызыл битле юан кибетче Кожемякинага шәл бәйләп бирүдән Мартукта берәү дә баш тартмас иде—Нюрканың талканы коры, пай кенижкәсенә тиешле әйберләрне дә

ул үзе ничек теләсә, шулай гына биреп җибәрә. Поселокның ин беренче фырт киенеп йөрүчесе булса да, ул да Гөлсемгә килгән.

Рушан аларның сөйләшүләрен тыңлап утыра.

—Нюра, мамыгынның төсе бик матур,—ди әнисе.—Минем ана яраклы җепләрем дә бар, ләкин йоннары бик күп икән, ике атнада гына чүпләп бетерешле дә түгел. Әле өч шәлне бәйләп бетерәсем дә бар, рәхмәт яхшы кешеләргә—акчасын күптән биргәннәр иде.

—Гөлсем апа, мине вакыты борчымый—Аллага шөкер, бәйләп йөреремә бар. Узган ел бәйләп биргән шәлегезгә күпләр кызыгып карый, минем менә караңгырак төсле шәлле буласым килә...

Әнисенең «яхшы кешеләрне» телгә алуы тикмәгә түгел—Кожемякина да Мартукта төшеп калганнардан саналмый бит.

—... Сезгә аванс итеп бер пот он әзерләп куйдым,—ди кибетче. Аннары почмаклары сыкыланып торган дымлы землянканы күздән кичереп чыккач:—Кичләтеп Рушанка сельмагка кереп чыксын әле. Сабыннан бушаган әрҗәләр булыр, кызганып тормам, биреп җибәрермен,—дип өстәп куя.

Кожемякинаның юмарт булмаганлыгын белгән әнисе:

—Бер ярты кило такта чәй белән шикәр дә өстә инде, Нюра,—ди.—Йонын бик тә...

—Ярар, ярар, килештек. Онга хәзер үк барасынмы?

—Хәзер, хәзер,—дип, кабалана башлады әнисе, чыгып киткәндә улына елмаеп карап та алды.

Алар артыннан ишек ябылуга, шатлыгыннан Рушан биеп җибәрде: ул инде кайнар көлчәнең исен тойгандай булды.

Кожемякинаның заказ алып килгәненә куанган әнисе ялгышкан булып чыкты—менә өченче атна инде Рушан Нюрка түтиенең мамыгын чистартып изалана.

—Нюрка булсын да, оттырсынмы?! Ул бит бу мамыкны безнең авыл казакъларыннан чәй белән хәлвәгә алмашып алган!—дип тузына хәл белешеп чыгарга кергән Науша апа.

Әнисе авыр көрсенеп кенә куя, дәшми. Тиктормас Науша апа озакламый чыгып китә, әнисе, аның артыннан ишекне ныграк ябып, мич янына килеп утыра. Аның кулындагы бәйләү энәләренең ялт та йолт итеп җитез йөргәннәренә Сания сокланып карап тора: «Мин дә кайчан да булса шулай әнием кебек тиз һәм матур итеп бәйләргә өйрәнә алырмынмы икән?»—дип уйлый, ахрысы.

—Тагын картлар шикелле бөкрәйгәнсең. Кара аны, кызлар яратмас үзенне,—дип, улын ачусыз-нисез генә кисәтеп куя әнисе.—Ие, яратмаслар...

Рушан кызарынып, күпмедер вакытка арка-җилкәләрен турайтып ала, ләкин күп очрап торган вак йоннар аны янадан лампага таба иелдерә.

Менә хәзер дә әле ул, җилкәләрен турайтып куеп, борылып карады: начар ягылган тәбәнәк землянка эчендә эңгер-меңгер куерып килә, әнисе исә һаман да юк әле.

«Дәресләрем дә әзерләнмәгән...»—дигән уй чагылып үтте дә югалды. Әнисе өчен борчылып, әледән-әле урамга йөгереп чыга-чыга, землянканы бөтенләй суытып бетерде ул. Башына әллә нинди куркыныч уйлар килде.

«Әгәр дә поезд соңга калып, туктап тору вакытын кыскарткан булсалар, әнисе вагоннан-вагонга шәлен күрсәтеп йөри-йөри, алдагы станциягә чаклы ук китеп барса... Әгәр кулындагы шәлен тартып алсалар?..» Сугыш күптән беткән булса да, җылы Ташкент якларына һәртөрле ышпананың бик теләп җыелышканын Рушан ишетеп белә иде инде. «Ә бәлки, милиция алып калгандыр. Ничек әле, теге... консиф... конфис... кон—фис—каци-я...» Бала теле өчен әйтергә авыр булган ул сүзне дә белә иде Рушан. «Станциядә бүген Велигданов абый дежур торса гына ярар иде»,—дип ялвара ул. Рабига әби шикелле итеп, кулларын бергә кушып күтәрә дә, гадәттә йоклар алдыннан укый торган кыска гына догасын укый: «Сөбхан Аллаһы вә әлхәмдел иллаһи...»

Күптән түгел генә, Велигдановны эштән куалар икән, дигән сүзләр дә таралган иде—имеш, станциядә спекуляция таралуга юл куйган. Кем инде хәзер Рушанның әнисен дә, башка әби-апаларны да: «Облава булачак, шәлсез, мамык перчаткаларсыз яки берәр дистә йон оекбашсыз каласыгыз килмәсә, берничә көнгә түзеп торыгыз, станция тирәсендә чуалмагыз»,—дип искәртер? «Ә бәлки, әнине эләктергәннәрдер? Аны бит поездларга шәл күтәреп килеп йөргәне өчен кисәткәләгәннәр иде инде...» Рушанга бик куркыныч булып китте, ул елап җибәрде.

—Улым, нәрсә булды?—ниндидер төенчекләрен ишек янында калдырып, әнисе аңа ташланды.

Рушан, әнисенең шыңгырдап каткан кыска сырмасына борынын төртеп, салкынны да сизмичә, кычкырып елый башлады.

—Йә, житәр, син зур бит инде, өйдә бердәнбер ир кеше. Эшләрең ундымы дип сора, ичмасам...—әнисе аның күптән алдырылмаган чәченнән сыйпап куйды.—Хәзер лампаны кабызырбыз, мичкә ягып җибәрербез, чәй куярбыз. Кара әле, нәрсәләр алып кайттым мин...—ул идәндә таралып яткан төенчекләрен җыештырырга тотынды.

Капкачын шыңгырдата-шыңгырдата, плитә өстендә чәйнек кайный, әнисе казанда сарык маенда гына бавырсак кыздыра. Муенына кадәр керосин салып, яңа филтә куелган лампаның яктысы землянканың иң ерак почмакларына кадәр төшә. Мул итеп тутырып ягылган мичтән җылы бөркелә.

—Саттыңмы?—дип сорады мәктәптән кайтып кергән Сания, бусагадан атлап керә-керешкә үк.

—Саттым, кызым, саттым. Чишен, бар нәрсәм дә әзер.

Сания тиз генә киез итекләрен салып, мичкә терәтеп куйды да Рушан янына сәкегә менеп утырды.

—Син бүген озак кайтмадың, мин сагынып беттем,—диде Рушан әкрен генә, үзе апасына сырышты.

Әнисе сәкегә эскәтер җәйде.

—Йә, әни, сөйлә,—дип ашыктырды аны Сания.

Телеңне өтәрдәй кайнар бавырсакларны агач савытларга сала-сала, әнисе сөйләп китте:

—Перронда басып торабыз шулай, бер сәгать, ике сәгать торабыз, ә Мәскәү поезды юк та юк. Шулкадәр туңган идем, китәргә җыенган идем инде, шул чакта еракта, семафор янында ук паровоз гудогы ишетелде. Безнең колаклар сизгер бит. «Пассажир поезды»,—дип уйлап та бетермәдем, килеп тә туктады. Вагоннардан ник бер адәм заты күренсен! Күрше урам Нәгыймәсе әйтә: «Әйдә, Гөлсем, алдагы стансыга кадәр утырып барыйк, вагоннарның яртысын йөгертеп узарга өлгерербез»,—ди.

Шунда кинәт кенә безнең каршыдагы вагон ишеге ачылып китте дә бер яшь кенә хәрби кеше миннән: «Шәлеңне күпмегә бирәсең, анакай?»—дип сорады. Аның җилкәсе аша чибәр генә бер туташ карап тора, ул минем шәлемне тәрәзәдән үк күреп алгандыр, мөгаен. Мин арзан гына хак әйттем, шәлемне тотып поездлар каршысында бер атна йөрим бит инде.

—Ә сез бире күтәрелә алмыйсызмы?—диде чибәр туташ, ә хәрби кеше шундый илтифатлы, вагонга менәргә ярдәм итеп, хәтта кулын сузды. Туташ шәлне иннәренә салды да ишекне тутырып торган көзгегә капланды. «Нинди нәфис! Нинди матур!»—дип соклана үзе, сайрамый гына инде менә! Ә шәл, дөрестән дә, үзенә бик килешеп тора. Аннары, поездның кузгалып китүен уйлапмы, исенә килеп, гаҗәпләнеп сорады: «Жиде йөзме?»

Мин каттым да калдым. Сатулашыр микәнни? Ә мина бер тиен дә киметергә ярамый. «Жиде йөз»,—дидем дә шәлемне төрә башладым. «Вадим, сигез йөзне түлә әле, зинһар, шәле бигрәкләр дә әйбәт! Апа да безне онытмасын»,—дип, мине кочаклап алып, матур итеп көлеп җибәрде туташым. «Рәхмәт, кызым,—дим.—Рәхмәт!»—күзләремә яшь бәреп чыкты,

Вадимы санаган акчаны да күрмим. Карап та тормыйча, алып кесәмә тыктым. Инде чыгып бара идем, мине әлеге Вадим куып житте дә бер тартма сузды. «Ал әле, анакай,—ди.—Минем паегым бу. Галетлар, тушенка...»

Ул галет дигәннәре сохари икән, Рушан аларны бик яратты.

—... Ә тушенка салып иртәгә мин сезгә аш пешерермен. Нинди матур, бәхетле кешеләр, Ходаем, үзен сакла аларны!

Әнисе сырмасының ярдәмчеләрем кесәсеннән төенчеген чыгарып чиште дә эскәтер читенә бер төргәк акча куйды.

—Поезддан сикереп төшүем булды, иптәшләрем йөгерешеп килеп життеләр. Бигрәк тә мин әжәткә акча алып торганнары кабаланатүземсезләнә иде. Бер-ике унлыкны бурычка да биреп торырга туры килде. Бүген бер мина гына мач килде бит. Якшәмбе көнне, Алла боерса, Рушан белән базарга барырбыз, казакълардан берәр йөк тирес кирпече алырбыз,—дип, әнисе булган акчаларының яртысын бер читкә алып куйды.—Ә монысы сезгә киногa,—әнисе өчлекне Рушанга сузды.—Хәзер үк аерып бирмәсәң, соныннан бер сумны да арттырып булмый...

Рушан шатлыгыннан чак кына чәен түгеп жибәрми калды.

—Монысы—керосинчыга, монысы—радиога түләргә, монысы—Матвей бабайга итекләр өчен, инде өч мәртәбә акча алмыйча гына олтан салып бирде, ә монысы—Нюркага иске бурыч, бигрәк кырын карый башлады, кибетенә бармассың, валлаhи...

Өелеп торган акча төргәге эреде дә бетте: әнисе алдында бөгәрләнеп беткән берничә берлек белән вак акчалар гына торып калды.

—Ә болары вак-төяккә.

Рушанның ашыга-ашыга өчлекне кесәсенә яшерүен күргәч, әнисе елмаеп куйды:

—Борчылмагыз, балалар. Куллар исән, аяклар сау, ничек тә яшәрбез. Сезнең кебек ярдәмчеләрем булганда, югалмабыз...—дип, улының башыннан сыйпап алды да табынны жыештыра башлады.

Кич белән янадан лампа тирәсенә түгәрәкләнеп утырыштылар да Нюрканың төенчегенә тотындылар. Әнисе әкрен тавыш белән генә «Кара урман» жырын көйли:

Кара да гынай урман, каранғы төн,
Яхшы атлар кирәк үтәргә...
Заманалар авыр, еллар ябык,
Дус-иш кирәк тормыш күтәргә...

Вакыт-вакыт ул тынып кала: шәл бәйләгәндә күзләрен төгәл санап барырга кирәк бит. Санап-барлап алгач, янә жыр башлый:

Агыйделкәй алкын, суы салкын,
Каз-үрдәкләр каршы йөзәлми...
Шатлыкларга гына, hай, түзсә дә,
Хәсрәтләргә кеше түзәлми...

—Әни, инде икенче чирек бит, ә минем укуым өчен түләнмәгән әле, мәктәптән кумаслармы икән мине?—дип кинәт кенә сорап куйды Сания.

—Кайгырма, юләркәем. Кузнецов директор чагында, андый хәлнең буласы юк. Әле жәй көне дә, мине урамда очратып: «Гөлсем апа, Саниягез бик сәләтле кыз, унны бетергәч, үзегезгә бер ярдәмче, бер таяныч булыр, укыган кеше беркайда да югалмас. Кием-салым белән булышырбыз, мәктәп фондыннан нәрсә булса да юнәтербез. Сугыш бетте инде, хәзер жинелрәк булыр»,—дип сөйләп торды. Дөрес әйткән бит. Сина жидене бетерсәң дә, бик житкән—шәл бәйләргә күп акыл кирәкми, түземлелек-осталык дигәндә, Аллаhы Тәгалә сине өлешсез калдырмаган, дип уйлана идем. Мәктәпкә нәрсә киеп йөрерсен, дип тә баш вата идем.

Формасын да, йон күлмәген дә, пәлтә-итекләрен дә бирделәр

мәктәптән. Кузнецов үз кабинетына чакырып алды да: «Менә, Гөлсем апа, киемнәр—кызыгызга болар»,—диде. Урындыкларда башка укучылар өчен дә киемнәр ята, төрле төстәге, төрле фасондагы пәлтәләр... Директорыгыз бик сизгер кеше, бөтенесен уйлап-исәпләп эшләгән, мине кызыксынып күзәтүчеләрдән һәм усал телләрдән саклаган. Бүләкләрен пөхтәләп төреп, бәйләп бирде дә сезгә бу киемнәрнең кәҗүннәй икәнен әйтмәскә кушты: «Балалар күнеле—бик нәзберек... Исегездә тотыгыз»,—диде. Шулай булгач, тынычлап укы, кызым, сезне бер мин генә кайгыртмыйм. Ә укуың өчен ничек булса да түләрбез.

Әнисе мичнең төннек тишеге эшермәсен ябып куйды да сүзен ашыкмый гына дәвам итте:

—Әтиегез өчен сезгә тиешле пенсия аз-азын, шул ук Кузнецов йөреп, алып бирмәсә, анысы да тәтемәс иде әле. Ана елап бардым. «Ярдәм итегез, Юрий Александрыч,—дидем.—Собеста буташтырмак булалар: иремнең үле хәбәре турындагы кәгазь андый булмаска тиеш, имеш. Ничек инде андый булмасын? Мартуктан киткән ир-атның бөтенесе дә диярлек Мәскәү тирәсендәге сугышларда бер көн эчендә ятып калган. Почта безнең барыбызга да ул кайгылы кәгазьләрне бер үк көнне китереп тоттырды. Ул кичтә елашкан авазларыбыз Оренбургның үзенә хәтле ишетелеп торгандыр әле»,—дидем. Директор аны белмиме инде: икенче көнне үк мәктәптә матәм митингысы үткәргән иделәр бит. Безгә килгән берданбер кара кәгазьгә «Хәбәрсез югалды» дип язылган икән. Ә кайда югалырга тиеш сезнең әтиегез? Мартук ир-атлары гел аның тирәсендә булган бит. Әтиегез бик уен-көлкечел, һәр эштә башлап йөрүче кеше иде, өстәвенә партиәнный да иде әле. Поселокта бер сәгать торып киткән эшелонда да әтиегез вагонда башлык булган.

Шунда ук директорыгыз белән собеска киттек. Дөрес, мин ишегалдында калып тордым: инде тәмам гаҗиз булган идем, сугыша башлармын, дип курыктым. Бер сәгать көтәм, ике сәгать—кинәт кенә Юрий Александрыч атылып чыкты да, чыга-чыгышына борылып, тиргәнергә тотынды: гел дә укытучыларча түгел инде: «Кабахәтләр! Бюрократлар!»—дип кычкырына. Аннары бераз суынгач, миңа әйтә: «Син, Гөлсем апа, түземлегеңне җый да көт инде,—ди.—Ә мин Мәскәүгә язармын» ,—ди. Ярты ел көттем, ә Кузнецов шул вакыт эчендә әллә кайларга язып бетерде, тәки пенсияне юллап алып бирде бит. Игелекле эш-гамәлләр, игелекле кешеләр белән яши дә инде бу дөнья дигәнең, бервакытта да шуны онытмагыз, балалар...

## XXIV

Кар күмеп киткән Мартукка декабрь, юнәлешен көнгә берничә мәртәбә үзгәртә торган, кешеләрне аяктан егардай көчле салкын җилләре белән килде. Күз ачкысыз бураннар башланды, мәктәптә укуларны туктаттылар.

Җил моржада улап, землянкага бәреп керергә тырыша, әйтерсен, аны астын-өскә китереп, туздырып ташларга тели иде. Тәрәзә артындагы җәя кереше шикелле тартылган, бәскә төренгән электр чыбыклары тынмый, көн-төн гүләп торалар. Мичнең туймас корсагына тирес кирпече тутыра-тутыра, Рушанның әнисе борчылып сөйләнә: «Бу якшәмбедә базар булмас инде, мондый буранда юл йөрергә кемнең кыюлыгы җитсен?»

Рушан белән сатып алып кайткан тирес кирпечләре көнләп түгел, сәгатьләп, күзгә күренеп кими. Әнисе, өстенә сырмасын элеп, тирә-күршеләргә йөгерә: сатып алып булмаса, әҗәткә биреп тормасмармы, берәр дистәсен генә булса да берәр әйбергә алмашмасмармы? Кайвакытларда эше уңып та куя.

«Якшәмбегә бураны гына тынсын иде, Ходаем!»—дип ялвара әнисе, бер йөк үк алырлык акчасы булмаса да, казакъларның беренче генә

ярдәм итүе түгел, бу юлы да бурычка бирерләр әле, дип өметләнә.

Ишектән башны тыгып карарга да куркыныч булган шундый кичләрдә кунак килеп керә. Ул һәрвакыт көтмәгәндә килә, шыгырдавык ишек тавыш-нисез генә ачыла. Башта ачык ишекне тутырып, иләмсез пычрак капчык күренә, ана ямаулыклар салып бетергәннәр, аны кунак шунда ишек төбендә калдыра да, үзе өйалдына чыгып, кайры кыска туны белән малахай тумык казакъ бүреген озаклап кага, аларны шунда элеп, землянкага гимнастеркадан гына килеп керә.

—Гыймай абый, авылның аргы очыннан, станция артыннан ук киләсез, буранда адашудан курыкмыйсызмы? Ишекне шулай тавыштынсыз оста итеп ничек ача беләсез?—дип сорый Сания.

—Мин, кызым, сугышның беренче көненнән башлап дивизия разведкасында булдым, ә сугышны дошман тылына йөреп бетердем.

—Ә нигә әтине дә үзегез белән алмадыгыз?—дип, Рушан кунак янынарак елыша.

—Сугышта, Рушан батыр, кем кем белән барырга тели икәнен сорап тормыйлар. Мине эшелонда ук ниндидер бер майор искәреп алган, мин Мәскәүгә дә барып житмәдем, Мирсәет белән, әтиегез белән, дим, аерылыштым.

Әниләре дәшми-тынмый гына мич янында кайнаша. Чәй эчәргә утыргач, кунакка ул:

—Гыймай, син ул капчыгың белән бер бәлагә тарырсың әле,—дип куйды.

Гыймай чапайча мыегын сыпыргалап көлде генә:

—Сина күпме аңлатырга була, миндә эшкәртелгән тире генә бар санала, ә вагоннарга төяп безгә йоны кыркылмаган тире жибәрәләр. Безнең заводның исеме генә—кожзавод, чынлыкта ул—кустарь артиле генә. Йонын кырку түгел, тиресен иләп тә өлгертә алмыйбыз. Йонлы килеш кайнап торган зур чаннарга ыргытабыз, ә каустик сода ашаган йон бернигә яраксыз була. Аны чаннардан сәнәк белән сөзеп ала-ала эчләр төшеп бетә... Дөресен әйткәндә, сина кыркыганың өчен түләргә дә кирәк иде әле: кыркылган тиреләр чанга икеләтә күбрәк сыя, чан чистартасы да юк—бер көн янга кала, сода эретмәсен дә саклыйбыз. Барысы да файдага дип исәплә.

—Шулаен шулай да...—дип ризалаша әнисе, үзе һаман үз сүзен тукый:—Ә йон барыбер дәүләтнеке.

—Шуңа күрә, бураннарда гына йөрим дә бит, кешеләрне котыртмыйм, дим. Ә куркыр нәрсәм юк. Карак-угыры түгел, мошенник түгел, фронтта да башымны югары тотып йөрдем...

Гыймай бер талпынуда капчыгы янында була, аның көчле куллары землянка уртасына бер-бер артлы тиреләр ыргыта башлый.

—Шушындый байлыкны әрәм итеп буламы соң? Кара әле, менә берничәсе кәҗәнеке, йоны мамык кына. Шәлгә баруын бармас, әмма пирчәткәләргә—үтергән инде!

—Меринос...—ди әнисе әкрен генә. Ул идәндәге тиреләр өстендә үрмәләп йөри, жае килгән төшләреннән берәр учма йон йолкып ала.—Пәрәвез челтәрләр бәйләргә була...

—Ә мин ни сөйлим?!—Гыймай соңгы тиреләрен алып ыргыта, буш капчыгын кайры туны эченә фокусчы кебек оста гына итеп яшереп куя. Кай арада туны кереп житкән, диярсең!—Менә, кайрадым, әйткәнемчә...

Тун кесәсеннән ул чүпрәккә төрелгән үткен авыр кайчы чыгара. Икенче кесәсеннән бер зур кисәк ябышкак сабын алып, кульюгыч янына бара. Сабынны да шул ук кожзаводта кайнаталар икән.

Гыймай кулын сабынлап юа-юа:

—Сабынны гына кызганмаска кирәк,—ди.—Юкса, бу тиреләрдән теләсә нинди шакшыны йоктыруың бар.

Үз эшеннән канәгать Гыймай тиреләр өстеннән атлап туп-туры самавыр янына килә...

Ничек кенә котырынмасын-шашынмасын, кыш кәтмәгәндә генә тынып калды, моржаларына кадәр карга күмелгән кечкенә Мартукны җинә алмасын аңлады шикелле. Туздырып ташланган бозлы печән кибәннәре, кешесез урамнардагы учма-учма саламнар, юеш-дымлы салкын землянкалар, үтәли җил уйнап торган сарык абзарларында бер көн дә яшәми катып үлгән бәрәннәр, ач-ялангач станцияләрдә тәртелеп туктап калган поездлар өчен гафу үтенгәндәй, поселокта шундый тын матур көннәр урнашты. Андый көннәрне карт-карчыклар бары тик бик күптән, сугышка чаклы имин заманнарда гына күргәннәрдер.

Һавада гына түгел, тормышта да ниндидер җылы үзгәрешләр булды шикелле, инде онытылып бетә язган «өмет» сүзе ешрак ишетелә башлады.

Дөрестән дә, озакламый килеп җитәсе Яңа елга юл ачып дигәндәй, Нюрканың кибете янында игълан-белдерү пәйда булды: беренче гыйнвардан күп кенә товарларга бәя төшәсе икән! Авыл кешеләренә кирәклесен дә, кирәксезен дә санап, шул товарларның озын исемлеген элгәннәр.

Кояшлы бер көндә Мартук буйлап тагын да шатлыклырак хәбәр йөгереп узды: өйдә утырып бәйләүчеләр әртиле ачарга вәгъдә биргәннәр, ди! Авансын да, хезмәт хакын да түләүле, ди! «Авансы да, хезмәт хакы да! Авансы да, хезмәт хакы да!»—бу сүзләр йорттан-йортка кереп йөрде.

Салкын бураннарда тукталып торган мәктәп ачылды, киез итекләренә тимераякларын боргычлап бәйләгән малайлар авылның аргы башыннан да, бирге башыннан да дәрескә чабыша башладылар. Тәнәфес вакытларында мәктәп ишегалды шау-гөргә күмелде. Бәс-бозлары эрегән электр чыбыклары гүләүдән тынып калды, кышкы ачлыктан вә салкыннардан исән чыккан чыпчыклар чыркылдашырга тотынды. Шундый күнелле көннәрдә Рушанның күптәнге хыялы тормышка ашты: әнисе аңа станциягә, поездлар тирәсенә күмер калдыгы җыярга барырга рөхсәт итте.

Әнисе бөтен поселокны ашатып-эчертеп торучы станцияне үзенең буш ишегалды кебек яхшы белә иде: ул күмер шлагы дигәненең дә тимерюлчыларның, яшь булсалар да, ертлач-бердәм малайларыныкы санала, алар шунда, станция янындагы кызыл кирпеч йортларда торалар, йортлары исә ут сулап утырган галәмәт зур тау-тау күмер шлагы артында. Рушан кайнарланып-ышандырып әнисенә сөйли: тимерючыларның Кожедуб атлы иң башкисәр малае минем белән бер сыйныфта укый, ди, алар һәркемгә дә тими, күмерне комсызланып күп җыючыларга гына бәйләнәләр, ди. Ә Рушан буржуй түгел, аңа башкалардан артык кирәкми. Аның соңгы сүзләре әнисенә кызык булып тоелды, ул рәхәтләнеп көлеп җибәрде.

—Без буржуйлар түгел, дисең инде?

—Буржуйлар түгел...

Мәктәптән кайткач, Рушан чанасына нык-таза кәрзин беркетте, аның эченә яньчелеп, чегәннәр ямап бетергән иске чиләген салып, вокзал ягына ашыкты.

Станциянең үзенә генә хас кабатланмас исе бер квартал кала ук сизелә, Мартукның саман кирпечләрдән салынып, җиргә чүккән йорт-куралары белән чагыштырганда, янган күмер таулары чын-чынлап мәһабәт булып, һәр ишегалдыннан күренеп тора. Ул таулар эчендә көйрәп-тәтәсләп яткан шлак, паровоз, топкаларын чистарткан төшләрдә өтелгән креозотлы шпаллар, икеләп тоташтырган паровозларның машина исләре, алар тирәсендә бөтерелеп-ургып торган пар болыты—болар барысы да Рушанны һәрвакыт дулкынландыра, ымсындырып тора иде. Ул белә: шушыннан нечкә ике җеп булып сузылган тимер юллар кайдадыр еракка, башка дөньяларга алып китә. Шул яклардан, шул дөньялардан җылы җәй, кызыл апорт алма, сары мандарин исләре аңкытып поездлар килә; ул поездларда, әнисе сөйләвенчә, ишекләре көзгеле һәм идәненә чын келәм җәелгән коридорлы вагоннар икән, шул вагоннарга әдәпле хәрбиләр, чибәр туташлар һәм тагын әллә кемнәр утырып йөри икән.

Эше булган кеше килеп туктаган состав янында тәртелеп, вагоннар янындагы сәүдәне күзәтеп, җете ачык төстәге кытай халатлары өстеннән

җилкәләренә авыр тун салган юан-юан хатын-кызларның соклануы:
—Нинди матур бизәк! Нинди нәфис челтәр!
—Ә мамыкланып ничек очып тора!—кебек сүзләрен тыңлап торамы соң?!

Үтеп барышлый, Рушан, шаян балаларны күзләп узган аксакал карт шикелле, елмаеп, ачусыз-нисез генә уйлап алды: «Мамыкланып очып тора... Мамыкланмыйча тагын!» Шәлнең берәр калтыранып туңып торган хатын-кыз иңенә менеп кунаклаганчы нинди озын-авыр юл үткәнен белә шул ул. Ул казакъ авылларында нәни шук кәҗә бәтиләрен карап үстергән үз яшьтәшләрен күрә, җәен-кышын әче җилле, үлән-үсемлеккә ярлы далаларда көннән-көн, елдан-ел, салкында да, чиллә эссесендә дә көтү көтеп, күченеп йөргән чабаннарны күрә иде. Ул матур, очып торган шәлләргә күпме балаларның, хатын-кызларның, кырыс ирләрнең кул җылысы ингәнен, күз нурлары түгелгәнен ишетеп кенә белми, үзе эшләп-татып белә; ул салкын абзарларда яки керосин лампасы янында шул шәлләр өчен күпме күз яше түгелгәнен дә белә—менә шуннан соң гына сезнең иңнәрегезгә кунаклый ул шәлләр, чибәр апалар-туташлар...

Тиз йөрешле Ташкент-Мәскәү поездыннан бушатылган шлакны хатын-кызларның носилкалар белән ташып бетергәнен көтеп, Рушан шлак тавы өстеннән аста яткан Мартукны беренче мәртәбә күздән кичерде. Еракта мәктәп күренеп тора, аның янәшәсендә—яшел калай түбәле авыл советы йорты, аның кыегына беркетелгән кызыл флаг шәлберәеп тора. Калган йортларны нечкә генә сызылып чыккан төтеннәреннән генә шәйләргә була, ул төтеннәр туп-туры кар астыннан ук сузыла шикелле. Тимер юл буенда еракта бер өркәчле дөягә охшаш элеватор калкып тора. Аның каралган цинкланган калай түбәсенең сыртында ямьсез итеп кыек-мыек язылган язуы да бар: «1927 ел».

Элеватор күренешен пар болыты белән каплап, Мәскәү ягына таба тиз йөрешле поезд чаптырып узып китте. Болыт таралгач, Рушан тимер юл эшчеләренең рельслар өстенә мадерон—махсус юл эшләре арбасын күтәреп куйганнарын күрде, күтәреп куйдылар да шул арбага үзләренең авыр эш коралларын—лом, кәйлә, чүкеч, кувалда ишеләрен төяи башладылар.

Рушан тимер юл эшчеләрен һәрвакытта да башка кешеләрдән аерып куя, чөнки һөнәрләре ни ел фасылларына, ни һава хәлләренә, ни авыл советына, ни башка бер нәрсәгә дә бәйле булмаган берданбер шул һөнәр кешеләрен генә белә иде.

Үзен хәтерли башлаганнан бирле, авылдагы һәр тимер юл эшчесен танып белә, аларның һәрвакыт эшләре бар, димәк, аванс һәм получкалары да һәрвакыт бар. Ул әле тагын шунысын да белә: аларга чын ташкүмер тиешле, алар иске шпалларны үзләренә яздырып ала алалар һәм шулардан таза-нык җылы сарайлар төзиләр. Ә иң мөһиме—анысы инде Рушанга бөтенләй тылсым булып күренә!—аларның һәркайсына ел саен Советлар Союзының теләсә кайсы почмагына түләүсез билет бирелә, кайту өчен дә инде, билгеле. Теләсә кайсы почмагына! Шуларны уйлаганда малайның күз алдында һәрвакыт иске генә мәктәп глобусы җанлана иде.

Әле менә хәзер дә: «Үскәч, тимер юл эшчесе булам!»—дип уйлап куйды Рушан һәм рельслар буйлап йөгертеп ерагая барган мадерон артыннан карап, озак кына елмаеп торды...

## XXV

Икенче вакыйга үги әтисе белән бәйле иде, төгәлрәге, ул аларның соңгы очрашулары булды.

Әнисенең хаты ялга китеп барыр алдыннан гына килеп төште, юллама Рушанның кулында һәм билетка заказ да бирелгән иде инде. Бервакыт дингез буеннан ялдан кайткач, картларга телефон куйдырткан

иде, шуннан бирле әнисеннән хат-хәбәр алмады. Авылда телефон куйдырту шәһәргә караганда да авыррак, әмма аңа җай чыкты: телефон үзәгенең башлыгы аның күптәнге сабакташы икән.

Кичкә кадәр Рушан хатны ачып укымады. Башына хәтта: «Әллә ашыгыч сөйләшүгә чакыртып, сорыйммы икән—хатында ни-нәрсәләр язганын?»—дигән юләр уй да килеп китте.

Әнисе үги әтисенең пенсиягә китәргә җыенганын язган икән, ә хезмәт кенәгәсендә ниндидер язулары җитенкерәми, ди, әтисенең исемен бутаганнар диме шунда. Татар исемнәрен буташтыру урыслар өчен һич кыен эш түгел, шундый исем-фамилияләр очрап куя—хәрефләр бутау гынамы соң, теленне сындырырсың, валлаһи! Үги әтисе йөргән-йөргән дә,—бер ишектән икенчесенә куалар, бер кантордан икенчесенә озаталар икән үзен,—үпкәләгән карт. «Кирәкми миңа пинсәгез, кул-аякларым исән-сау булганда—югалмам, ниндидер язулар җитми, имеш, минем эшем—хезмәт, ә кәгазьләрне башкалар язып тутырган бит, мин түгел»,—дигән.

Әнисе ул кәгазьләр-документларның инде ничәнче ай хәрәкәтсез ятканнарын язган, ә үги әтисе аның эшенә тыкшынмаска, гомумән, пенсия турында сүз кузгатмаска кушкан икән. «Ә карт кызганыч бит, улым, үз гомерендә күпме эшләгән кеше, күреп торам: бик тә рәнҗи инде...» дип тәмамлаган әнисе үзенең ашыга-ашыга язган хатын.

Гөлсем апа улының ялга өйгә кайтуын сораган, ял итеп алгач, шул пенсия мәсьәләсен кузгатып җибәрүен үтенгән—ни әйтсән дә, улы укыган кеше бит, законнарны белә, начальниклар, бәлки, картка ярдәм итәрләр, гомере буе халык күз алдында булды бит, качып-посып йөрмәде, шушы Мартукта эшләде дә эшләде, дигән.

Авылга кайтуны кичектереп тору турында сүз дә булырга мөмкин түгел иде. Берәр атнада, ну, күп дигәндә, ун көн эчендә үги әтисенең эшен җайлап, аннары дингез буена китәргә дә өлгереп булыр шикелле тоелды. Шундый уйлар белән Рушан туган якларына юл тотты.

Вагон тәрәзәсеннән эссе кояш көйдереп бетергән иксез-чиксез казакъ далаларына карап бара-бара, Рушан уйларында әледән-әле үги әтисенә әйләнеп кайта. Ул бер дә алда торган пенсия мәсьәләләре турында уйламый. Менә хәзер генә, вагон көпчәкләренең тек-тек текелдәүләрен тыңлап барганда гына, ул кинәт кеше гомеренең бик кыска булуын тоеп-аңлап алды. Аның кыска икәнен ул, билгеле, белә иде, әмма менә шушылай үзәк өзгеч итеп, дулкынлану кичереп тоюы хәзер генә булды.

Ничек болай соң әле? Әле кайчан гына яшьләрчә төз буй-сынлы бу ир-егет станция өчен, тимерюлчылар өчен волейбол уйнап йөри, Рушаннарга хромы-никельләре ялтырап торган трофей «Диамант» велосипедына атланып килә,—сугыштан соңгы елларда велосипед күз күрмәгән, колак ишетмәгән зур байлык!—әнә шул кеше хәзер пенсиягә дә чыксын, имеш. Тагын да аңлашылмаганы шунысы: унган-булган, көчле-кыю, авылда барысыныкыннан да күбрәк орден-медальле үги әтисе хәзер Рушанның ярдәменә мохтаҗ. Ничек инде?..

Ә бит кайчандыр малай чагында, ул өметсезлеккә бирелеп, үзенең бәхетсезлеге турында уйлана, үги әтисе шикелле тормыш сөючән, шат күңелле, дуслары да, дошманнары да хөрмәт итәрлек гадел булуны гомерендә дә булдыра алмас, бу мөмкин түгел кебек тоела иде. Ул вакытларда үзенең кайчан да булса Исмәгыйль абыйга ничек тә ярдәм итә алачагы турында уйлый ала идемени ул? Әлбәттә, юк! Хәтта хәзер дә, инде ничә еллар үткәч, Дасаев вагонның буш коридорында үз-үзенә нык ышанган көчле кешенең шатлыклы көлү тавышын ишеткәндәй булды—шулай яңгыратып әле һаман да зәңгәр «Диамант»ына атланып йөрүче үги әтисе көлә иде.

Аны әнисе каршы алды. Рушан аны бер биш еллап күрмәгән иде инде, ә Гөлсем апа соңгы елларда бик бирешкән икән...

Рушанның әнисе үзенең матурлыгын-сылулыгын бик озак саклады,

һәр йортта теләсә нинди яшьтәге кәләш булырлык чибәрләр табыласы булса да, күрекле кияү Исмәгыйль юкка гына ике балалы Гөлсемне алмагандыр инде. Сугыштан Мартукка бары өч, нибары өч кенә ир-ат әйләнеп кайтты. Ә киткәннәре... Иң яхшысы, исәпләп-санап, йөрәкләрне әрнетмәскә генә кала.

Рушанның дөньяга аваз салган туган йорты юл буенда ук булып, тәрәзәләренә тикле җиргә ингән иде, шуның ишегалдына үзенең «Диамант»ына атланган Исмәгыйль абый җилле генә килеп керер иде. Хәзер бу урында кыргыйланып үскән роза куаклары күтәрелгән, ул элек бакча иде, аны мартуклылар розалар белән мавыккан бер заманда ясаганнар иде, аннары ул мавыгу узды да, бакчаны караучысыз калдырдылар. Ни хикмәттер, шуннан соң анда һәр нәрсә иркенләп гөрләп үсеп китте, куаклары җәй саен аллы-гөлле шау чәчәк була. Чәнечкеле куакларга терәлеп үк кызыл-ак-зәңгәр төсләре чиратлаштырып буялган тәбәнәк рәшәткә койма тора. Аны үги әтисе һаман шулай чиратлаштырып буйый иде, хәзер дә шулай икән әле. Бу койманың һәр ике ягына да җиргә беркетелеп утыргычлар куелган. Алар урталай гына ярылган бүрәнә—яркадан ясалган, аларга кемнәрдер сөйгәннәренең исемнәрен тырнаштырып язган булган, хәзер ул язулар каралып тоныкланган, танылмыйлар да, ә бер ярка бераз ярылып-чатнап та киткән. Дасаев бу утыргычларны бик яхшы хәтерли. Алар да, розалар, ә соңрак фарсы сиреньнәре кебек үк, мавыгучан Мартукның бер заман мавыгып алуының нәтиҗәсе иде. Һәр йорт янында, һәр өйтүр бакча алдында шундый утыргычлар-эскәмияләр булыр иде. Әгәр язын син ясап куйган ояга сыерчыклар ояласа, сезнең утыргычны берәр гашыйк пар үз итсә—бу яхшы фал саналыр иде. Рушанның да шундый истәлекле утыргычы бар иде. Комсомол урамында, итекче Вася дәдәй йорты янында.

Рушаннарның яңа йортын кеше яллап эшләттеләр. Саман кирпечне чегәннәрдән сатып алдылар, алар җәйләрен шул авыр эш белән шөгыльләнә иде. Үги әтисе әле ул чакта әйбәт кенә күренсә дә, авыр эшкә ярамый иде инде. Аның каравы, архитектор, прораб, бригадир, тәэминатчы сыйфатында аңа тиңнәр булмады. Кешеләр яллаганда да, кемнең нәрсәгә сәләтле-яраклы икәнен яхшы белә иде. Балта эше сынар аяклы Гани абый Кадыйров өстендә булды. Беркайчан да күңел төшенкелеген белмәс, күкрәп торган тавышлы, бөтен авылга бердәнбер бу башкортның эшли-эшли җырлаганын тыңлап торсагыз икән! Вәт җырлый тек җырлый иде! Рушанның әнисе, кайчакларда аның җырлаганын онытылып тыңлап, ашын йә артык тозлы итә, йә токмачлары куерып бетә иде.

Ярый әле вакытында өлгертеп калганнар ул йортны. Юкса, хәзер, сатириклар әйтмешли, атаклы сынчы Бенвенуто Челлини үзенең бер һәйкәле өчен дә бүгенге балта остасы бер ишек яңагына каерган хәтле хак ала алмагандыр. Ә Гани абыйның челтәр-челтәр, кәрәз-кәрәз ишек-тәрәзә йөзлекләре, өй түбәсенә бастырып куйган күнелле-шаян әтәче истәлек итеп кенә тотарлык иде. Әле хәзер дә, алар йорты яныннан үтеп-сүтеп йөрүчеләр тукталып, сокланып карап торалар, ә бит үги әтисе җырчы башкорт белән «архитектур бизәкләр» ясату турында сөйләшмәгән дә иде...

Улына әйтеп бетергесез шатланса да, Гөлсем апа вокзалдан кайтышлый, аны нигә чакыртканына үкенә дә башлаган кебек булды, Рушанны өйдә пенсия турында бер кәлимә сүз дә ычкындырмаска дип, кисәтеп куйды, ә инде ул эш белән йөрисе була-нитә калса, сак булсын, үги әтисе берүк белә күрмәсен! Сизенмәсен...

Алар ишегалдына кайтып кергәндә, җылы, тын, кичке шәфәкъ, иртәгәге көннең аяз булырын вәгъдә итеп, бәрәңге бакчалары артындагы күкне яртылаш алсуга манган иде инде. Рушанның үги әтисе, күрәсең, әле генә яшелләкләрне, чәчәк түтәлләрен, кыргыйланган роза гөлләрен шлангтан су сиптереп коендырудан туктаган гына булгандыр. Озын көн

буена эссе кояш астында ятып кызган асфальт сукмактан пар күтәрелеп тора. Һавада җир исе, бакча исе, мондый тәмле исләр авылда бары тик янгыр явып үткәннән соң гына була. Үги әтисе, соскыдагы көйрәп торган кызыл күмерләрне сикерткәләп, самавырга өстәп тора—Рушаннар кайтып кергәндә җиз чибәркәй җырлап утырсын, дип, мөгаен, әнисе кушып калдырган булгандыр әле, чөнки шунда ук җәйге ачык веранданың бер почмагына өстәл дә әзерләп куелган, сый-нигъмәтләр өстенә чебен-мазар кунмасынга ике катлап марля ябылган иде.

Үги әтисе болай беренче карап торышка артык үзгәрмәгән, гомере буена гел бер төрле йөртә торган «керпе» чәчләре тагын да чалара, тагын да сирәгәя төшкән—бары шул гына шикелле. Әмма Рушан бары тик хәзер генә аның ябыгып, яшүсмер малайлар шикелле кечерәеп калганын шәйләп алды. Аннары үги әтисенең чыраенда, сөйләшүендә дә ниндидер сизелмәслек кенә үзгәреш бар иде, Рушан моның хикмәтен шунда ук аңлады: ниһаять, үги әтисе ясалма тешләр куйдырган икән.

Алар ничектер уңайсыз гына, бер-берсеннән тартынган кебек кенә итеп кочаклашып күрештеләр, Рушан аның җылы бумази күлмәге астындагы очлы калак сөякләренең ябыклыгын тойды. Әнисе ул арада өстәлдән тиз генә нәрсәнедер алып, нәрсәләрнедер өстәде дә аларны чәйгә чакырды.

Исмәгыйль абый, килешли, су колонкасы янындагы чиләктән салкын тир бәреп торган кечкенә бер чәкүшкә аракы эләктереп алды. Рушанның кайтуы хөрмәтенә берне тотып куйдылар да тозлы кыярдан авыз иттеләр. Телләре языла төште, сүз арты сүз, дигәндәй, үги әтисе сорап куйды:

—Озаккамы соң? Әллә элеккечә бер-ике генә көнгәме?

—Озаккарактыр,—диде Рушан һәм үзе дә көтмәгәндә:—Йорт сагындырган...—дип өстәде. Болай әйтүендә бернинди алдау да юклыгын, дөресе шулай икәнен үзе дә аңлады.

Аңа әнисенең яратып карап торуларын, үги әтисенең дә күзгә бәрелмәстәй игътибарлы карашын тоеп утыру рәхәт иде. Көйрәп-сүнеп барган самавырның онытыла төшкән күмер исе белән тәбәнәк сарай түбәсенә киптерергә җәелгән яңа чабылган печән исе бергә кушылып, тагын шуларга авыл мае, авыл сөте хуш исләре дә өстәлгән шушы туган йорт һавасын сулавы әйтеп бетергесез бер куаныч булды. Кайчандыр бер ара бөтенләй кайтырга җыенып та кайтмый калынган, хәзер инде сирәк-мирәк кенә сугылгалап кителә торган үз йортында озаграк торасы килә иде аның.

Элек Мартукта мондый йортлар юк иде, дип әйтергә була, немецлар килгәч кенә шундый иркен-зур, пыялаланган верандалы йортлар төзелә башлады. Дөрес, хәзер инде тагын да арттырып җибәрделәр: верандаларны җылытыла торган иттеләр, йортлар эченә суын да керттеләр, кайбер таза тормышлы хуҗаларның йортларын пар белән җылытулары да сирәк күренеш түгел.

Картлар Рушанны өйнең «аныкы» саналган ягына—матур фикус гөлле зал белән карангырак йокы бүлмәсе булган якка керттеләр, ул як баштан ук шулай уйланылып төзелгән, чөнки Рушан, укып бетергәч, өйгә кайтыр, киленнәрен дә яна йортта каршы алырлар, дип өметләнгәннәр иде. Диңгез буеннан ял итепме булсын яки командировкадан кайтышлыймы, бер-ике көнгә кереп чыкканда Рушан гел уйлана иде: әгәр дә ул Мартукка бөтенләйгә кайтса, тормышы ничегрәк булыр иде икән? Һәм кайчакларда ул тормыш әкияткә охшаш тыныч, бер кайгысыз, рәхәт булып күзаллана иде. Әмма Рушан үзен мондый уй-хыяллардан тиз айныта, чөнки әти-әниләренең җайлы-уңайлы таза тормышында аның өчен иң мөһиме—һөнәренә ярашлы эш юк иде. Шуннан егет тынычланып кала.

Әлбәттә, Мартукка кайтырга да булыр иде, берәр эше дә табылыр иде әле. Ләкин ул чагында Рушан диңгезсез капитан яки зәңгәр күксез очучы хәлендә калыр, ә ир-ат өчен яраткан һөнәр-шөгыль кирәк, моны

ул бала чагыннан ук үзләштереп үсте.

Әмма дүрттән өче, Дасаев шикелле үк, кечкенә авыл-поселоклардан килеп укып чыккан дипломлы белгечләр белән шыплап тутырылган Ташкентта ул кайвакытларда бу инженер кисәкләрен кызганып та куя иде: бахырлар күпсанлы төрле бүлек-бюроларда, өсте-өстенә өелешеп дигәндәй, бушка гомер уздыралар—ыштан туздыралар бит. Үз туган җирләрендә, бәлки, аларның белемнәренә, сәләтләренә тиң килердәй эш-шөгыль табылган булыр иде. Асылда зур эшләргә сәләтсез бу кешеләр кечкенәрәк урында, мөгаен, үзләрен күрсәтә алыр иделәр, илнең кай ягына барма—һәркайда төзелешләр бит, чат саен кран манаралары калкып тора. Тик юк, белем ягы да такыррак бу инженерлар шулай күнеккән, зур шәһәрләрдә чын-чынлап шәһәр кешесе булып китә алмыйча, шулай ышкынып яши бирәләр һәм еш кына тирән сагышка баталар—кышлагы-утары, авылы-поселогы—кыскасы, туган яклары сагындыра...

Рушан иртән уянганда, үги әтисе өйдә юк иде инде—Исмәгыйль абзый утыз елдан артык гомерен биргән промкомбинат сигезенче яртыдан ук эшли башлый.

Чәйне тәрәзәләре бакча ягына киереп ачып куелган верандада эчтеләр. Дасаевның кәефе күтәренке иде, әйбәт йоклады, хәтта матур төшләр—малай чакларын күрде. Моны сизенгән әнисе дәртләнебрәк китте, юкса, кичә вокзалда каршы алганда, улы йөрәк кушуыннан битәр бурыч үтәр өчен генә кайткан шикелле тоелган иде ана. Хәзер ул күреп тора: улы бакчаны нурга күмгән кояшка да, җырлап утыручы самавырга да шат, сагышлы карашы койма аша күрше ишегалларын капшый, әледән-әле казакъ Мостафа агайның ишегалдында уйнаклап йөргән колынга күз ата.

Алар озаклап-тәмләп сөйләшеп утырдылар, Гөлсем апа көзгедәй ялтыратылган, сигез литр сыешлы самавырның җыры тынмасын өчен ана соскы белән ике рәт күмер дә өстәде.

Улының сораулары, әнисенең җаваплары гел дә бетмәс төсле иде—һәр сорау, һәр җавап кемнеңдер тормышына кагыла, ә ул, үз чиратында, Рушанның ерак үткәннәренә барып тоташа. Әмма, ике казакъ хатыны кереп, аларны бүлдерделәр, әнисе ул хатыннарны шунда ук чәй эчәргә утыртты. Өлкәнрәгенә, үз яшьтәшенә карап, горурланып:

—Менә, Ташкенттан улым ялга кайтты әле, ул анда бәк зур инженер булып эшли,—диде.

Казакъ хатыны исә Рушанны кечкенә чагыннан ук белгәнен әйтте, башка малайлар белән бергәләп гает бәйрәме белән котларга кергәч, аларга күчтәнәчне бик муллан бирә алмавын исенә төшереп, көрсенеп куйды:

—Ә хәзер, рәхим итсен, тәкә суярбыз, кунак булыр. Аллага шөкер, тормыш безгә дә битен күрсәтте,—диде.

Дасаев алар белән дә тагын бер пиала чәй эчте дә урыныннан кузгалды. Аннары алсу бәрхет камзул кигән бу пөхтә казакъ карчыгы көне буе башыннан чыкмады: кем ул? Утары кайда, кайсы якта икәнен тәки исенә төшерә алмады, ә бит аның балачактагы Мартугы ул кадәр зур да түгел иде.

Соңгы биш елда күп нәрсә үзгәргән: Украин урамына асфальт түшәлгән, иске йортлар беткән диярлек, барысы да яна йорт житкереп кергән. Анда-санда калган саман йортларны да яндырылмаган кирпеч белән тышлап куйганнар—урам күнеллеләнеп, матураеп киткән. Бала чагында бакчаларына кыяр-фәләнгә төшкәләгән, үсеп житәрәк кача-поса гына кызлар өчен чәчәкләрен өзгәләгән күршеләренең ишегалларын таный да, таный алмыйчарак та тора торгач, Рушан түбәсе күтәреп беткән «Собес» йортын үтеп тә киткән икән, ана шунда керергә кирәк иде бит. Бу йортның ике кечкенә бүлмәсендә элек ул белә-белгәннән бирле районо иде. «Ярар, өлгерермен әле»,—дип уйлады Рушан, кире борылып тормыйча гына.

Промкомбинат янынннан үткәндә Дасаев адымнарын әкренәйтте,

аннары, хатирәләргә бирелеп, бөтенләй туктап калды. Юл аша чыгып, сарыга буялган такта белән тышланган күрекле йорт буендагы сәрби куаклары күләгәсенә чүгәләде.

Мартукның төп туендыручысы булган промкомбинат бик озак, чирәм жирләр көч алып киткәнче, поселокта эш табып була торган бердәнбер урын иде. Рушан аның ул чагында галәмәт зур булып күренгән ишегалдына керер-чыгар барлык ишек-капкаларын, хәтта койма тишекләренә чаклы белә, чөнки үги әтисе төн уртасына хәтле тоткарланган көннәрдә ул аңа кичке эңгер-меңгердә, аз-маз булса да, ашарга илткәли иде. Ә бәйрәмнәрдә инде әйбәтләп юынып, киенеп-ясанып бирегә утренникка килә. Промкомбинатны халык «артель» дип кенә йөртә, менә шул артель балалар өчен әкәмәт матур чыршы бәйрәмнәре үткәрә иде. Ә «чыпчын» Кыш бабайның күчтәнәчләре-бүләкләре хәзерге белән чагыштырганда да әйбәт. Яңа ел бүләге булыр иде, чөнки, балаларны ничекләр итеп куандырырбыз икән, дип, ике-өч ай алдан баш вата башлыйлар, бу эштә бер генә түң йөрәк тә булмый, балалар өлешенә кереп, катып беткән перәннек-конфет тутырып, яхшысын үзенә умырырга сәләтле кешеләрне бу күнелле бәйрәм тирәсенә якын да җибәрмиләр иде.

Дасаев комбинатның өч-дүрт катка күтәрелеп үсеп киткән яңа цехларына караштырып алды. Ул әнә теге ерак почмактагы бинаның икенче катында үги әтисенең мамык юрганнар сырганын белә, чәчәкле ситсы һәм төрле төстәге атласларны матур чигешле җөй белән атлатып сырылган ул юрганнарның нинди йомшак, җылы булганын да белә, кичә дә шундый юрган ябынып йоклады. Юрганнар әйбәт сатыла, хәзер инде башка өлкәләр дә сорыйлар, сырып өлгерт кенә. Цехка менеп, үги әтисенә комачауламыйча, беркая ашыкмый гына аның янәшәсендә утырасы килеп китте Рушанның. Аннары урам буйлап бергә кайтырлар иде—әбәткә күп калмаган бит инде. Әмма янә ул, монысына да өлгерер әле, ашыгасы юк, дип хәл кылды.

Кинәт кенә башына бер уй килде: әгәр комбинат парторгына кереп, үги әтисенең пенсиясе белән килеп чыккан буталчык турында сөйләшсә—үги әтисе, партийный булмаса да, хезмәт кенәгәсе чуарланып беткән шаталак адәм дә түгел, ветеран, өстәвенә—фронтовик, күкрәге тулы орден-медальләр.

Дасаев урыныннан күтәрелде дә элек заманнардан үзгәрешсез калган цинк калай түбәле бердәнбер бинага—бер катлы флигельгә юл тотты. Элек-электән комбинат житәкчеләре—администрация шунда була торган иде. Әмма партком ишеге бикле булып чыкты, ә кемнән булса да ни өчен бикле икәнен сораштырасы килми, хәзер Исмәгыйль абзыйга җиткерерләр: улың парторгны эзли, диярләр.

Ул инде карангы тар коридордан урамга чыгып бара иде, кинәт кемдер артыннан эндәште. Борылып караса, элек үзләренә каршы гына яшәгән Катя түти икән. Белә-белгәннән бирле ул шушы комбинатның бухгалтериясендә эшли иде.

Катя түти Рушанны кочып алды, ишегалдына бергә чыктылар.

—Сине күрмәгәнгә ни гомер... Өй туена Төньяктан ялга кайтканың истә, ул чакта мин әле биюче дә, жырчы да идем. Алексей (ул Рушанның үги әтисен шулай урысчалатып, исемен бозып атый) бик шәп йорт житкезде, сине өйләндерәм, озакламый бу бүлмәләрдә оныклар чабышып йөрер, дип мактанган иде... Ничек соң, балаларың бармы?

—Юк, буйдак әле мин...

—Безгә бит тимер юл аръягында казна йорты бирделәр, без картларның үзебез йорт житкезерлек көч-жегәребез дә, акчабыз да юк. Ә балалар, синең кебек үк, очып, таралышып беттеләр. Синнән ешрак күрмимдер үзләрен... Әниең ни хәлләрдә? Аны да байтактан күргәнем юк, йә Хода, бер поселокта яшибез, диген инде. Элегрәк мин сездә еш була идем бит, самавырыгыздан чәй эчүнең кирәген бирдем инде! Шикәрләп тә, корылай гына да—булды инде, булды. Кайчагында искә төшерергә дә

куркыныч хәтта. Аллага шөкер, картайган көнебездә без дә кешечә яши башладык. Үзен сон артельгә ничек килеп чыгасы иттен әле?

—Менә, парторгны күреп сөйләшмәкче идем, сез инде, Катя түти, зинһар, бу хакта әтигә әйтә күрмәгез!

—Ә-ә-ә, анлыйм-анлыйм. Алексейнын холкы чакматаш кебек шул анын. Ике сорамас. Собеска үпкәле, дип ишеткән идем. Картка булышырга алынуын яхшы булган, хәзер кәгазь заманы шул инде: һәр белешмәгә тагын белешмә кирәк, ә кайбер кәгазьне алу өчен ялварып, билгә кадәр бөгелсән дә таман гына. Ә синен үги әтиен яшьлектән үк шундый: ачка үлсә үләр, түбәнсенеп мескенләнмәс. Анын холкыннан әниен дә интегәдер инде, ә? Яшәвен дөрес яши ул, башкалардан да шуны таләп итә, тик кешеләре төрле бит анын. Картка ярдәм ит инде син. Ә мин ана тиешлесен күптән санап-исәпләп куйган идем инде, дөрес, әллә ни күп чыкмый чыгуын, әмма бөтенесен тиенен тиенгә хәтле кырып-себереп җыйдым, өч рәт санадым, бер нәрсәсен дә онытып калдырмадым. Безнен якларда элек акчалы эш юк иде бит, җиде кат тир түксән дә, юк иде, хәер, аны син үзен дә беләсен булыр...

Дасаев ризалашып, баш кагып куйды.

—Мин сина, Рушан, анын кәгазьләре салынган папканы биреп торыйм, үзен кара, үзен сана, дигәндәй, авыр эш түгел. Тиеш булмаса да, бирәм. Алексей белән бәйләп торган җепләр бар бит, анын белән бергә сугышка китеп, анын күз алдында һәлак булып, анын кулы белән җирләнгән Дмитрием бар иде бит, киявем буласы кешем... аерылмас дуслар, районда бер волейболчылар иде алар Алексей белән... Егет чакларында...

Катя түти көрсенеп куйды:

—Син үзен кәгазьләрен карап чык инде...

## XXVI

Тасмалары бәйләп куелган юка гына папка эчендә үги әтисенен пенсиясе күләмен билгеләү өчен кирәкле кәгазьләр—күп еллык боерыкларнын күчермәләре, хезмәт хакы ведомостьлары һәм башка шундый документлар гына түгел—бу кәгазьләрдә алар гаиләсенен бөтен тарихы саклана иде. Исмәгыйль абзыйнын утыз елдан артык гомер юлы шунда, шул саргайган кәгазьләр Рушанны бала чагына, үсмер чагына алып кайтып киттеләр. Язу өстәле янында ул шуларны караштырып утырган бүлмәгә сиздерми генә ара-тирә әнисе килеп керә дә, аз белемле кешеләргә хас бер саклык белән, рәсми кәгазьләр арасыннан берәрсен кулына ала, үзләренен элекке күршесе Катя Панченконын почеркын таный, нечкә генә итеп шәмәхә кара белән сырланган язуларнын әле төсе дә унмаган.

Әнисенен моннан егерме еллармы элек ире эшләп алган тиеннәр-сумнар язылган берәр кәгазьгә каравы була, укып та тормастан, Исмәгыйленен ул вакытта нинди эш башкарганын шунда ук исенә төшерә—Рушаннын баштарак мона исе китә иде: менә хәтер тек хәтер икән! Әнисе исә, әгәр берәр эше көтеп тормаса һәм кәефе килсә, шул ерак калган еллардан берәр истәлекле вакыйга сөйләп ташлый. Сөйләгәндә, күрсәтмәскә тырышып кына, башындагы яулык чите белән яшьле күзләрен сөрткәләп ала, ә Рушан күз алдына онытылып беткән диярлек ул вакыйгалар аша үз гаиләләренен тарихы гына түгел, ә артель тарихы, бөтен Мартукнын тарихы килеп баса.

Әнисенен хәтеренә ис китәрлек тә бар шул: гел шул бер промкомбинатта күп еллар эшләсә дә, үги әтисе дистәләрчә һөнәр алыштырган икән—исендә тотып бетереп кара әле! Юк, Исмәгыйль абзый шаталак яки һөнәр белмәс адәм булмаган. «Алтын куллы, алтын башлы»,—диләр иде анын турында, мондый сүзләрне Рушан да бер генә ишетмәде.

Эш башкада: артель озак еллар хәлсез-көчсез булып килде, дөресен әйткәндә, эшләренең дә рәте-чираты юк иде, ел саен диярлек бер цех ачыла, икенчесе ябыла, дигәндәй. Урысча әйтсән—чехарда...

Эшчеләр туплап, аларны өйрәтеп, көч-хәл белән планны үти генә башлыйлар, халык инде әйбәт хезмәт хакы булыр дип өметләнә генә—артельнең алыштыргысыз рәисе Ильяхин күнелсез хәбәр алып кайта: өлкәдә фәлән цехны ябып, төгән цех ачарга боерып җибәргәннәр икән. Ә бер ел үткәч, эшчеләрне һәм эш коралларын таркатып бетергәч, узган ел ябылган цехны ашык-пошыктан яңадан ачарга кирәк була. Ул еллар эчендә нинди генә цехлар ачылып ябылмаган да, ябылып ачылмаган, диген: каеш сбруй цехы, тегү цехы, кондитер цехы... Хәтта бөтен өлкәнең колхоз рәисләре утырып йөри торган җинел-җитез кошевой чаналарга хәтле ясыйлар иде Мартуктагы бу артельдә. Бай да инде безнең җиребез оста куллы, зиһенле халыкка! Шул зур да булмаган поселокта итеген дә басалар, тунын-толыбын да тегәләр, пәрәвездәй җинел-очалак шәлләрен дә бәйлиләр—нәрсәгә генә тотынмасыннар—булдыралар, тел шартлатып карап торырга гына кала. Ул заманнарны һаман да искә алып сөйлиләр шул... Ә цех ябулары исә кешеләрне эштән чыгару белән башлана иде. Әмма Исмәгыйль абзыйны бу афәтләр читләп үтә торды: теләсә нинди эшкә кулы ята иде анын, үзе тагын сүз тыңлаучан, кушканнарын бер карусыз үти, шуңа күрәдер, бәйрәмнәрдә һәрчак урыны түрдә—президиумда түше тулы орден-медальләрен балкытып утырыр иде. Шундый унган-булган фронтовикны ничек эштән кусыннар, ди инде. Яхшы булмас иде ул. Күзен идәнгә текәп яки читкә карап кына Ильяхин әйтер иде: «Син, Алексей, гаеп итмә инде, кабаттан яңа цехка өйрәнчек итеп җибәрергә туры килә үзенне, син булдырырсың». Шуңа күрә дә кайбер ведомостьларның битләренә әтисенә шул замандагы акча белән нибары 280-320 сум гына язылган, ә бит юкса, шимбә ялсыз гына түгел, еш кына якшәмбесен дә эшләтәләр иде әле.

Ләкин әнисе күнелсез хәлләрне генә түгел, кинәт кенә башкаларын да исенә төшерә, менә ул, шул ук кәгазьләргә карап, гел уйламаганда, шул айда сайлаулар булганын әйтеп куйды. Анын йөзе яктырып китте, якты киләчәктән башканы вәгъдә итмәгән, үзенә бер яхшылык та китермәгән, хәзер инде онытылып беткән яки онытыла язган юлбашчыларны исем-фамилияләре белән җылы итеп телгә алды. Ә Рушан, әнисенең сүзләрен тыңлар-тыңламастан, Мартуктагы бәйрәмчә күнелле сайлау көннәрен күз алдына китерде.

Сайлау мәктәптә үткәрелә, шунлыктан, төп агитпункт та шунда, сайлауларга бер ай кала ул инде кичләрен балкып тора, шаулатып радиола уйный иде. Ә сайлау көнне әти-әниләре кара таңнан ук сайлап кайтырга китәләр, Рушан әле йоклап калган була. Алар дуслары, хезмәттәшләре, туган-тумачалары белән бер-ике рюмка төшереп,—бөтенхалык бәйрәмендә анысы да гаеп эш түгел,—әнисе әле урысча хромкага «барыня»ны, кыңгыраулы татар тальянына «Әпипә»не дә биеп, күнелләнеп кайтып керерләр иде. Буш кул белән кайтмыйлар, нинди дә булса сайлау күчтәнәче—тәмле әйбер күтәреп кайтырлар иде: әфлисун, хәлвә, арыш перәннекләре, йә булмаса, ысланган корбан балыгы—анысы инде бигрәк сирәк эләгә торган ризык, шуңа күрә, бәйрәмнәрдә генә истә калган да...

Шулай истәлекләргә бирелеп, аналы-уллы икәү—алар кайчакларда сәгатьләр буе утыралар, ә бер көнне әбәткә кадәр утырганнар, янкапкадан әтиләре кайтып кергәнне күргәч кенә исләренә килделәр. Рушан югалып калды, өстәлдәге кәгазьләрнең бөтенесен дә яшереп тә бетерә алмады, әнисенең куанычына, ярый әле, Исмәгыйль абзый аларга игътибар итмәде.

Өстәл янында булсын, соңрак кичләрен үги әтисе белән бакчага су сипкәндә яки берәр хуҗалыкта кирәкле әйбер ясаганда булсын,—һәр йортта эш житәрлек була,—Рушан анын белән ара-тирә бер-ике сүз генә алыша, сөйләшсәләр дә, кирәклесен генә сөйләшәләр иде.

Дасаев шуны шәйләп алырга өлгергән иде: еллар үткән саен ир

балаларга әтиләре белән сөйләшү-гәпләшү кыенлашканнан-кыенлаша, катлаулана бара шикелле, ә менә кыз балаларга әниләре белән сөйләшү һич тә алай түгел. Аларның киресенчә була: кызлар елдан-елга әниләренә якыная баралар, чөнки үз балалары үсә, ана мәшәкатьләрен үзләре дә күтәрә башлыйлар.

Рушанның һәм аның яшьтәшләренең балачагы аерым иркәләү-назлау күрмичәрәк, ташбаш малайларның шуклыкларына әти-әниләре «ах-вах» килмичәрәк үтте. Ата-аналарның кайгысы башка иде—ничек ашатырга да, ничек киендерергә кирәк ул балаларны? Ул заманнарда төп хәсрәт шул иде. Эшкә таң белән чыгып китәләр, караңгы капкач кына кайтып керәләр, әмма эшләгәннәре көчкә-көчкә генә очын-очка ялгап, җан асрарга җитә. Кая инде анда иркәләп-иркәләнеп торулар?! Менә Рушан да, әле үзенә алты яшь кенә тулган булса да, үги әтисенә «әти» дип әйтә алмады, чөнки үз әтисенең танкист булганын, Мәскәү тирәләрендә ятып калганын белә иде инде. Соңрак, үсә төшкәч тә, үги әтисенә ул бары тик «абый» дип кенә эндәшә торган булып калды, «әти» дип әйтергә теле әйләнмәде. Юкса, баштарак Исмәгыйль абый, малайны үзенә ияләштерергә теләп, күп вакыт сарыф иткән иде. Хромнары ялтырап торган «Диамант»ын да ватар-җимерер дип, курыкмады, аны велосипедта йөрергә башка малайларга караганда иртәрәк өйрәтте. Рушанның чанасы да, тимераяклары да үги әтисе ясап биргән әйберләр иде, ә инде ул ясаган чаңгы авылда бер генә иде, ләкин барыбер Исмәгыйль абый улыннан үзе көткән «әти» сүзен ишетә алмады.

Хәзер шуларны исенә төшергәндә, Рушан үзенең бала чактагы ул кирелеген һаман да аңлый алмый әле. Бик күп балаларның әтиләре бөтенләй юк иде бит, ә аның, үги булса да, бар, шундый әйбәт, шат күңелле, җитмәсә әле ул орден-медальләре генә дә ни тора! Рушанга бөтен малайлар көнләшеп карый, Алексей дәдәйне Мартукта иң көчле кеше дип саныйлар, юкса, үги әтисе Петька Васятукның әтисеннән күпкә тәбәнәгрәк тә инде. Ә менә тәки бер генә мәртәбә дә Рушан аны «әти» дип атамады...

Әнисе өйдә юкта Рушан аркылы-торкылы җиз калайлар сугып эшләнгән иске кытай сандыгын ача, анда кайчандыр әбисенең бирнә әйберләре сакланган. Сандыкның тар гына ян бүлемтегендә Исмәгыйль абыйның орден-медальләре ята. Сугыш исен татымаган, бер нәрсәгә дә ышанмаучы хәзерге скептиклар күзлегеннән караганда да, үги әтисенең бүләкләре шәп иде, алар, чынлап та, күп—тугыз. Беренче орденын Исмәгыйль абый әле утыз тугызынчы елда ук, Хәсән күле өчен сугышларда алган. Бала чагында үзен магнит кебек тартып торган орденнарны яңадан караганда, Рушан ул заманнарда, ярлы яшәсәләр дә, еш кына кунаклар чакырганнарын, бәйрәмнәрдә үги әтисенең орденнарын тагарга онытмаганын исенә төшерде.

Аракы дигәнең зур бәйрәмнәрдә генә өстәлгә менә, бер-ике шешәне иң дәрәҗәле, иң кадерле кунаклар алдына гына куялар, шуннан артыгын мартуклыларның кесәсе күтәрә алмый иде. Ә кунак көтүче хуҗалар бәйрәмнәргә берничә атна кала әче бал куялар. Бу әчемлек алай каты түгел, әмма исертә, аны һәр йортта үзләре белгәнчә ясыйлар. Андый әчемлекне сатуга ясаучылар юк иде, шунлыктан, хакимият кешеләре «үзе өчен генә» әче бал ясаганнарга бармак аша гына карый иделәр. Рушан, орден-медальләрне берәм-берәм караштырганда, үги әтисенең кунак җыйган көннәрдә хәрби кителенә гадәттә ике генә орден—икесе дә «Дан ордены»—такканын хәтерләп алды. Хәзер инде Рушан ул орденнарның бәһасен белә. Әмма бу хәлләр бик күптән, Исмәгыйль абый үз әнисе Зәйнәп әби белән икәүләп Рушаннарга күчеп килгән, Исмәгыйль абый «Даимант»ына атланып йөргән һәм «Локомотив» командасының бер генә волейбол уенын да калдырмаган заманнарда ук булган иде инде. Үги әтисе ул команда данын яклап әле сугышка кадәр ук уйнаган икән.

Элек,—моны Рушан яхшы хәтерли, чөнки ул хакта малай-шалай да, күрше хатыннар да сөйләнә иде,—орден-медальләр өчен күп булмаса да, акча түлиләр иде. Үги әтисенең бүләкләре байтак, Мартукта һәр тиен исәптә, аны эшләп алыр жире дә бик күренеп тормый. Шулай булгач, шул аз акча да ярап куя иде. Әнә шул бүләкләре өчен бирелә торган акчага Исмәгыйль абый кайчакларда гаиләсен дә сыйлаштыра иде. Ләкин озакламый ул түләүләрне ни өчендер бетерделәр. Дөрес, Мартукта бу хәл үги әтисеннән башкаларга кагылмады да диярлек, әмма Исмәгыйль абыйның моңа бик эче пошты. Ул түләүләр гаиләгә бераз ярдәм генә түгел, авылдашлары алдында аның абруен да күтәрә иде бит. Гади фронтовик кына түгел, ә кирәгенчә сугыша да белгән, шуңа бүләкләре дә күп, хөрмәте дә зур иде—һәм менә шуны кистеләр дә куйдылар.

Үги әтисе әле тагын шуңа да гарьләнә, кайберәүләр аны юри үртиләр, орден-медальләрен «тимер-томыр» дип кенә жибәрәләр иде. Рушан аның Оренбургтан вак-төяк сатарга килгән берәү белән Октябрь бәйрәмендә шуның өчен сугышып киткәнен хәтерли.

—Провокатор, сволочь!—дип кычкыра котырынып киткән Исмәгыйль абый, аның жирән сипкелләре үлектәй агарынган йөзенә чәчрәгән кан тамчылары төсле янып тора иде.—Синең ишеләрне мин баскан жирендә атып үтерер идем, гнида, спекулянт...—дип тагын да кыза ул, дусты Васятукның көчле кулларыннан ычкынырга талпынып.

Ә теге бәндә, арты белән ишеккә чигенә-чигенә, кәжә тоягы күрсәтеп, усалланмакчы булып маташа:

—Хәсрәт сугыш чукмарлары... Казакъ хатыннары шикелле, түшләренә тимер-томыр такканнар да, монда да фронт тәртипләре урнаштырмакчылар... Үзегезнең намусыгыз, дөреслегегез белән кайгы шулпасын эчәрсез әле... Еларсыз, ыштансыз генераллар...

Шул вакыйгадан соң үги әтисе сандыктан орден-медальләрен сирәгрәк ала, сирәгрәк тага башлады. Әмма ызгыш-талашлы, сүгенү-сугышлы башка мәжлесләрне Рушан хәтерләми.

Аларда күбрәк бер үк кунаклар була иде. Васятук, күрше Панченколар, үги әтисе туган Оренбург якларыннан берничә татар, әнисенең ахирәт дуслары—бер-ике тол хатын-кыз һәм һәрвакыт Гани абый, аның сул аягы урынына үзе әтмәлләп куйган агач аяк булыр, үзе мәжлесләрдә беренче жырчы һәм гармунчы булыр иде. Ә ул мәжлесләрдә нинди генә жырлар жырламыйлар—татарныкы, башкортныкы, казакъныкы, урысныкы, украинныкы, немецныкы—һәммәсе дә жырланыр иде. Рушанның күңелендә иң калганы Гани абыйның көр, күкрәктән чыккан тавыш белән жырлавы, хәтта кайбер сүзләре дә истә әле:

...Кынгыр бога, һау-һау,
Кынгыр бога, һау-һау...

Күп еллар үткәч, Рушан белде: бу «бога» үгез дигән сүз икән, шуннан урысларга да кереп киткән дә, «бога» сүзе «бугай»га, аннары «бык»ка әйләнгән икән! Бугай—иң усал, иң сөзгәк үгез инде ул. Хәзерге урыс үгезе...

Рушан кунакларны әнә шул жырлары өчен ярата да иде. Ә кайвакытларда кунак ир-атларның күпчелеге үзләре үткән солдат юлларын искә алалар, ул заманнарда әле яңарак кына булып узган сугыш һәр даим үзен сиздереп тора иде. Гадәттә «ә менә Германиядә...», яки «ә Польшада...» дип сүз башлыйлар да, аннан китә инде! Шулай да күбрәк тыныч тормышны ничек көйләү, мал-туар, игеннәр, хужалык итү, гореф-гадәтләр һәм башкалар турында гәпләшәләр... Әмма юк-юк та, янә канкойгыч каты сугышларга барып төртеләләр. Соң, шул ук «ә менә Германиядә...», «ә менә Польшада...» күпме гомерлек дус-ишләр, якташлар башын салган, ятып калган ич... Онытырга мөмкинме шуларны?..

Ничек кенә сәер тоелмасын, үги әтисе андый әңгәмәләрдән качарга тырыша, әмма мәжлестә һәрвакыт берәр яна кеше була һәм ул аның

бүләкләрен сораштыра башлый: бу орден нәрсә өчен бирелгән дә, бу медаль ни өчен тагылган? Исмәгыйль абый бер-ике сүз белән саран гына җавап бирә: мөһим махсус бурыч үтәгән өчен, ди. Бетте китте! Әмма, сирәк кенә булса да, кәефе килепме, әллә дусты Васятукның хатирәләреннән кабынып китепме, үзе дә кайбер нәрсәләрне сөйләп ташлый иде ул.

Шул сөйләшүләрдән әкренләп Рушанның аңында үги әтисенең сугыш елларындагы сурәте-образы ачыкланды. Хәзер инде яшенә караганда артык картаеп киткән, аз сүзле, тын гына кыштырдап йөрүче бу картка карап, кайчандыр аның кыю солдат булганлыгын күз алдына китерүе дә кыен иде. Дасаев хәзер, аның орден-медальләрен карый-карый, бала чагында хәтерендә калган солдат образына әйләнеп кайтты.

Исмәгыйль абый сугышта разведкада, ә төгәлрәге—разведчикларның элемтәчесе булган. Дошман тылына үтеп керә икән дә, немецларның телефон чыбыгына ялгана икән, ә немец телен яхшы белгән безнең бер офицер тегеләрнең бар сөйләшкәнен тыңлап тора икән. Билгеле инде, шундый шартларда немецлар белән күзгә-күз очрашулары бер генә булмаган, ул бит бөтен сугышны дошман җирләрендә, бик күп чакрым нейтраль җирләрне дә артта калдырып,—ә аларны үтүе җиңел булганмы?—сугышып йөргән. Үги әтисе ут кебек җирән һәм, чынлап та, немецка охшаган булгандыр. Полк тегүчеләре бик пөхтәләп тегеп биргән вермахт солдаты формасы киеп йөргән ул. Бу кием елның барлык фасылларына да яраклы булган, хәтта көндез дә, төнлә дә аерылмас автоматы да немецларның «шмайссер»ы икән.

Бала чагында үги әтисе авызыннан ишеткәннәреннән Рушанның күңеленә аеруча берсе сеңеп калган... Исмәгыйль абый немецларның борын төбендә генә баганага менеп, тегеләрнең телефон чыбыгына үзенекен ялгап азаплана икән. Кием-салымы, коралы, наушниклары—барысы да немецныкы, койган да куйган немец элемтәчесе инде менә! Әерак та түгел куаклыкта—иптәшләре, сержантның багана буйлап сиздерми генә чыбык сузып, җиргә төшкәнен, аны немец телен белгән офицерга хәтле сузганын көтәләр. Кирәк бит, нәкъ шул чакта бер унбишләп немец солдаты килеп чыкмасынмы! Багана башындагы элемтәчене күреп, алар үз телләрендә нәрсәдер кычкырыналар, көлешәләр. Сержант, алардан уздырып, бердәнбер мөмкин булганны эшли—чыбыкларның ике очын да ашыга-ашыга авызына каба да, шулай ук күңелле елмаеп, тегеләргә кул изәп җавап бирә. Җиннәре терсәгенә кадәр сызганылган, бит-куллары җирән сипкелле—яз бит. Шат күңелле, батыр Ганс, нечкә муенына «шмайссер» автоматы асылган, ә багана төбендәге бозау тиресеннән тегелгән ранецында, кем дә булса карый-нитә калса—һәр нәрсә немецныкы, хәтта авыз гармунына чаклы бар. Разведкада һәммәсе дә уйланылган, әмма төп ышаныч—түземлек, салкын канлылык, ихтыяр көче...

Хәтта еллар үткәч тә Рушан үги әтисенең аякларының, менә-менә «тырнаклары» ычкынып китәрдәй булып, хыянәтчел калтырануын, кулларының авыраеп калган «шмайссер»га ирексездән ябышуын күргәндәй була, әмма ярамый, ул, бөтен тәненә салкын тир бәреп чыккан килеш, озын-озаклап үзен үзләренеке итеп таныган немецларга елмая һәм кул изи...

## XXVII

Үги әтисенең пенсия мәсьәләсен хәл итәргә атна да, ун көн дә житмәде, ләкин, дөресен әйткәндә, бу вакыт эчендә Дасаев Алушта ял йортына юлламасы барлыгын исенә дә төшермәде. Берсекөнгә ул Оренбургка барырга ниятләде, юк, яшьлеге үткән шәһәрне күрү өчен түгел, хәер, бу бару ул ягы белән дә күңелле иде, ә иң мөһиме—үги әтисенең метрикә язуына әтисенең исемен төзәтеп язарга һәм собес өчен туган елын ачыкларга кирәк иде.

Собестагы яшь кенә кызлар һәм аларның башлыгы—шулай ук шактый яшь бер маржа белешмәләр актарып утырырга да, Дасаевның дәлилләрен тыңларга да теләмәделәр. Рушан аңлап алды: бередә, гомумән, беркемне дә юньләп тыңлап тормыйлар, көнгә әллә ничәшәр кабатлап торган яраткан әйтемнәре бер генә: Мәскәү күз яшьләренә ышанмый. Дасаев берсендә тыелып кала алмады: «Мартук Мәскәү түгел әле»,—дип бәреп әйтте. Мондагы хәлне тиз генә төшенеп, бу ваемсыз битарафлыкны бәреп ватып булмаслыгын, ниһаять, аңлады ул, һәр очракта да бу маржалар хаклы булып калачак, зарланып шикаять язсаң—шелтә алырлар да котылырлар, ә ул шелтә алар өчен, маржаларча әйтсәң, «до лампочки». Рушан буйсынырга мәҗбүр булды һәм Исмәгыйль абзыйның әтисе исемендәге «в» хәрефен «ф» ка, ә метрикә язуындагы «5 март» урынына «9 март» дип алыштырылган рәсми документлар алып кайтып бирергә карар кылды. Үги әтисенең утыз елдан артык күрше урамнан бер үк промкомбинатка эшкә йөрүе исә беркемне дә кызыксындырмый иде.

Ул иң иртәнге поезд белән юлга чыкты. Поезд Оренбургка элекке шикелле биш сәгать түгел, ә алты сәгать бара икән, хәзерге тизлек заманында бөтенләй аңлашылмаслык хәл иде бу. Ул вагонга үтеп тормады, юкса буш урыннар да бар, бер-ике сәгать черем итеп алырга да булыр иде, яшь кенә проводница кыз да керергә кат-кат үтенеп карады, әмма Рушан тәки шалтыр-шолтыр бәргәләнеп-суккаланып бара торган тамбурда басып калды.

Күптән юылмаган тамбур тәрәзәсен кулъяулыгы белән ышкып сөртеп, Рушан каршыга йөгереп килгән станцияләр, разъездларны күзәтеп бара башлады. Бу юлдан аның күп тапкырлар үткәне бар, кайчандыр ул Мартуктан Оренбургка кадәрге юлдагы һәр станцияне, һәр разъездны берсе артыннан берсен, ялгышмыйча, балалар санагычындагы шикелле итеп санап чыга һәм шуны ук тиз-тиз генә кире тәртиптә дә әйтеп бирә ала иде. Ә менә хәзер ул аларның кайберләрен генә таный: Яйсан, Акбулак, Сагарчин... Боларны татарча-төркиләштерсәң, ничек булыр иде икән? Таныш җирләрнең күп кенә исемнәре хәтердән чыккан, җилгә очкан, аннары, үзгәрешләр дә бик күп, киңәйгән-үскәннәр, бары тик исемнәре генә сакланып калган шул. Тамбурда басып торганда, аның күңеленнән кичә булып узган вакыйга һич китмәде, юкса, әллә нинәрсә дә түгел иде инде.

Иртән әнисе, орден-медальләр саклана торган шул сандыктан мең тугыз йөз кырык җиденче елгы бер төргәк заем облигацияләре тартып чыгарды да, улына шуларны саклык кассасына кереп тикшертеп алырга кушты: кем белә, отмасалар да, бәлки, кире кайтарылган—погашение акчасы чыгар, хәзер күпләргә чыга икән.

Рушан бер-ике сәгать китап кибетендә юанды, гаҗәбенә, анда ана кирәкле бик күп техник китаплар һәм белешмәләр табылды. Үзләренең трест китапханәсе өчен дә дип, һәркайсысын берничә данә алды, шунда әнисенең гозере исенә төште, саклык кассасына сугылган иде, бәхетенә, утыз сум акча отып чыкты. Аның әбәткә кайтырына өметләрен өзгән карт белән карчык инде чәйгә утырганнар иде, шунда Рушан кайтып керде, тантаналы кыяфәттә елмаеп, әнисенә шытырдап торган өч яна унлык тоттырды. Сәер, кинәт килеп кергән бу акчаларга ни әнисе, ни үги әтисе шатланмады. Дасаев гаҗәпләнеп, шаярткандай итеп сорап куйды:

—Бик баедыгызмы соң, инде утыз сум да акча түгелмени сезгә?—диде.

Әмма аның шаяртуы урынсызрак булып чыкты. Рушанның тамагыннан ризык үтмәде, ашаса ашады, ашамаса—юк, дигәндәй булды. Әле менә хәзер дә, бер кешесез буш тамбурда басып торганда да, шуны исенә төшергәч, оятыннан йөзенә кызыллык йөгерде.

—Их, улым,—дигән иде әнисе, авыр сулап.—Кырык җиденче елда бу кәгазьләрнең һәркайсысы әтиеннең чирек эш хакына тиң иде, ә хәзер аңа нибары бер шешә аракы тия. Ул заманнарда йөз сумы түгел,

ун сумы да алтын бәясе иде безгә, хәтеренә төшер әле...

Вагон көпчәкләренең текелдәвен тынлый-тынлый, иртәнге салкыннан куырыла төшеп, Рушан хәтере белән кырык жиденче елга кайтып китте. Кыш азагында үги әтисенең әнисе Зәйнәп әби үлде. Ул, ничек тавыш-тынсыз яшәгән булса, шулай сизмәгәндә генә, кинәт дөнья куйды. Аны мөселманча итеп, ак кәфенгә төреп жирләргә кирәк иде. Өйләрендә дә, таныш-белешләрендә дә бер метрлык та яна ак ситсы-фәлән табылмады, алай гынамы соң, урын жәймәсе дә юк иде—ярлылык чиктән ашкан булгач, анысы да ярап торыр иде әле. Кибетләрдә дә чүпрәк-чапрак бик аз була, булганы да пай кенижкәләренә генә, ә Рушаннарның андый кенижкәләре юк, иң зур бәла—өйдә бер тиен акча да юк чак иде. Кыш бик салкын булып, тирес кирпеченә генә дә Исмәгыйль абыйның ярты эшләп алганы китә, житмәсә әле, ай саен заемга басып калалар... Әнисе кемнән нәрсә сорарга да белми, аптырашта калды, ә үги әтисе... Улмы соң кемнән булса да берәр нәрсә сорар кеше? Күрше Васятуктан сораса гына инде, алай дисәң, анысы болардан да хәерчерәк...

Исмәгыйль абый пошаманга төшеп, кашларын жимереп, бик озак уйланып утырды, аннары кинәт кенә торды да тиз-тиз киенде, кышлыкка әйбәтләп майлап, бүлмәдә үк элеп куелган, йортның бердәнбер бизәге һәм горурлыгы булган, сугыштан трофей булып кайткан «Диамант» велосипедын күтәрде дә буран эченә чыгып югалды. Берәр сәгатьтән соң ул төргәге белән әйберләр күтәреп кайтып керде, өйдә бер чеметем чәй, бер шакмак шикәр юк чак иде. Үги әтисе ике шешә аракы да кыстыра кайткан, калган акчаларын ул сүзсез-нисез генә хатынына сузды. Рушанны шул буранда, өйдән-өйгә йөреп, әбиләренең үлгәнлеген хәбәр итәргә чыгарып жибәрделәр. Һәм шул күз ачкысыз буранда зиратка барырга яше-карты кузгалды, күпчелеге эшсезлектән интегүчеләр иде. Ничек кенә сәер тоелмасын—зыкы салкын булуга да карамастан, каберне тиз һәм жиңел казып куйдылар. Әнисе исә, кулында акча була торып та, егерме метр марляны бары тик көн уртасында гына таба алды. Зәйнәп әбине шуңа төреп, кәфенләп жирләделәр.

Күп еллар үткәч, Дасаевка ишеттерделәр: кемнендер купшы-бай женазасы вакытында кемдер орденлы батыр Исмәгыйльгә төрттереп, әнисен марляга төреп күмде, ун метр бәзгә дә акчасын кызганды, дигән, имеш. Үги әтисе бу юлы сугышып тормаган—буласы булган, туны тузган, дигәнмедер, ояты-хәсрәте дә басыла төшкәндер, бәлки. Ә язын Рушан кемнәрнендер малайларында көнләшеп тә, уңайсызланып-оялып та «Диамант»ны күрермен, дип йөрсә дә, шуннан соң Мартукта ул велосипед юк булды...

Тар һәм кысан тамбурда таптангалап торган Дасаев үги әтисе белән бәйле тагын бер вакыйганы исенә төшерде. Ул вакытта инде ни Зәйнәп әби, ни зәңгәр «Диамант» юк иде, Рушан үзе әллә икенчедә, әллә өченчедә укып йөри иде.

Яз башында артельнең итек басу цехын яптылар. Анда итек кенә түгел, бик тыгыз зур-зур киез тулалар да басалар иде. Жилле-далалы бу якларда казакълар аны бик яратып ала һәм келәм урынына кулланалар иде. Исмәгыйль абый шуларны да баса, киез итекләргә дә кулы житә, ап-ак меринос сарык йоныннан, нигездә, хатын-кызлар өчен жиңел-нәфис «чәсүнкә» итекләрне дә коеп кына куя иде. Бу һөнәренә ул башкаларына караганда озаграк өйрәнгән—итек йә тула басу гади генә, жиңел генә эш түгел икән ул. Көннәр буена тавыш, гөрелте астында күзләрне әчеттерә торган тузанлы, түбән сортлы йон арасында утырып кара әле! Иң авыры шунда: түшәлгән йонның ни калынлыгын, ни тыгызлыгын-тигезлеген үлчәгеч нәрсәләр юк, барысын да бармакларың белән капшап чамаларга туры килә. Кулың тоймый, сизми икән—димәк, брак китә, ә бернинди эшнең рәтен-чиратын белмәгән һәм эшләргә яратмаган, колакка катырак Шәйхи ОТК, ягъни техник тикшерү бүлеге «башлыгы» бигрәк явыз, шул явызлыгы белән генә урынында утыра да.

Исмәгыйль абый бу һөнәрне дә үзләштерә, шул кышта әнисенең аяклары күз явын алырдай «чәсүнкә» итеккә тиенә, ә Рушанга—йомшак, жылы, кара киез итекләр. Менә шул цехны ни сәбәптәндер япканнар бит. Бик күп эшчеләрне шунда ук эштән чыгарып ташлыйлар, дөрес, Рушанның үги әтисен калдыралар-калдыруын, ләкин бер эш тә тәкъдим итмиләр, бу юлы «өйрәнчек булырсын» дигән коткаручан сүз дә ишетелми...

Исмәгыйль абый көн саен эшкә бара, анда нәрсәләрдер майтара—кыскасы, һәрвакыт түрәләр, башлыклар күз алдында була. Менә шулай йөргән көннәрнең берендә кожзаводнын,—«кожзавод» дип шул артельнең бер кечкенә цехы атала,—тире иләүчесе Гыймай абый Рушаннын үги әтисенә сабын кайната башларга тәкъдим итә. Тирeләрдән кырып алынган әшәке майдыр-ярыдыр артыгы белән житеп ашкан, ә каустик сода һәм башка химикатларны табу артельнең көченнән килмәслек эш түгел икән.

Поселокта эш таба алмый йөрүчеләр арасында да «төнге алтын» түгүче яки сабын кайнатучы булу иң соңгы һөнәрләрдән санала иде, әмма утыз тулып кына узган яшь ир, уйлап та тормыйча, бу эшкә риза була, юкса, мөгаен, белгәндер: моннан соң ни волейбол мәйданчыгына, ни кино-фәләнгә йөреп булмаячак, сасы сабын исе әллә кайлардан анкып торачак бит.

Ул елны өйләренә тулган сабын исен Рушан бик озак оныта алмады, хәзер дә, кер сабыны күрсә, күнеле болгана башлый.

Үги әтисе шул сабын кайнату фикере белән Ильяхинга да барып керә. Жавап кыска була: өлкәдә дә күрсәтерлек бер әржә сабын ясап бир, калганы—минем өстә, ди. Директор, үз жаваплылыгына алып, тәвәккәлләп, кожзаводнын ике бүлмәсен боларга бирә, кайнату казаннарын, күмерен, содасын да кызганмый—складта бу эш өчен яраклы нинәрсә бар, һәммәсен дә яздырып алырга рөхсәт итә. Юкса, тиеш эш тә түгел инде. Әмма...

Сабынны Мартукта кайнатып та карамаганнар, өйрәтер-күрсәтер кешесе дә юк. Бу фикерне биргән Гыймай абый үзе дә эшнең нечкәлекләрен белми, Оренбургка барырга киңәш итә, анда сабын кайнатучы татарлар бар, алар киңәшләрен кызганмаслар әле, ди, алайболай кирәк булса, дип, бер тире иләүченең адресын да тоттыра.

Күңеле күтәрелеп киткән Исмәгыйль абый шул көнне үк саубуллашып вокзалга төшеп китә. Урамда инде май ае, жылы, рәхәт. Исмәгыйль абый, вагон түбәсендә генә оеп, тиздән Оренбургка да барып житә. Бары тик вокзалга житәрәк «Меновой двор» дигән тирәдә сикереп төшеп калырга гына кирәк була—вокзалда билетсызларны милиция тотып ала икән.

Үги әтисе бу шәһәрдәге эшләрен тиз башкарып чыга. Шадра битле, пеләш сабын кайнатучы: «Күрәсен, тормыш бик тә китереп кыскандыр, юкса шушындый яшь һәм унган кеше сабын эшенә алынмас иде»,—дип әйткән, ди. Ә Исмәгыйль абыйның фронтовик һәм үзенә якташ икәнен дә белгәч, сабын кайнату серләрен яшереп тормаган, сөйләгән дә биргән. Башлап жибәрергә кирәк булыр, дип, бер ярты капчык төрле химикатларын да кызганмаган әле, отставкадагы жирән сержантның «хәлләнә төшкәч, түләрмен» дигән сүзләренә ышанып калган.

Үги әтисе, ничек килгән булса, шул ук юлдан кайтып та киткән, бары тик тиз йөрешле поезд түбәсенә бер потлы капчык белән менеп утыру гына кыенгарак килгән. Һәй, юкка разведчик булганмыни ул? Йокы вагоннарынын баскычлары ул заманнарда эчкә батырып эшләнгән булган. Үги әтисе, бара-барышлый, капчыгын бер вагон баскычына ыргытып өлгергән, янәшә икенче вагон баскычыннан үзе сикереп менгән дә, түбәсенә үрмәләп, шуннан капчыгын үрелеп алган, үз уңышына куана-куана, сызгырынып кайтып та бара икән.

Бар иде заманнар: Урта Азиянен жылысына һәртөрле әтрәк-әләм, угрысы-фәләне тартыла-елыша иде. Алар да, Рушанның үги әтисе шикелле үк, вагон түбәләренә утырып киләләр, юл унай, станцияләрдә авылкалаларга сугылып, берәр төрле «гамәл» дә кылып өлгерәләр, әмма аларнын

төп максаты—ерактагы икмәкле Ташкент каласы була иде.

Менә берзаман шундый башкисәрләрнең бер төркеме кайсыдыр станциядә Исмәгыйль абый барган поезд түбәсенә дә үрмәли бит. Үги этисе аларны тиз генә абайламаган—очраклы гына әйләнеп карагач, вагон түбәләрендә халык сирәгәйгәнен күргән: тегеләр, үзләрен яклап кала алмастай кешеләрнең барлы-юклы төенчек-фәләннәрен талап, үзләрен куып төшереп киләләр икән. Үз вагонына бер дүрт вагон кала Исмәгыйль абый, тегеләр күзенә чалынмаска уйлап, поездның баш ягына—паровоз тирәсенә үк елышырга ниятли, анда, торбадан чыккан төтен-корымнан бик пычрак булгач, берәү дә ул тирәгә утырырга тырышмый. Инде көймәсе бик комга терәлсә, ревизорларга эләгү куркынычы булса да, түбән төшеп, вагонга керергә чамалый ул.

Үги этисе, шәһәргә барып кайтырга дип, Гыймай абзыйдан алып торган өр яна, таза сүс капчыгы өчен борчыла. Теге башкисәрләр, капчыктагы бөтен бар булганын селкеп ташлап, бер нәрсә алмасалар да, пычрак-каты вагон түбәсендә аска җәеп куяр өчен бу капчык менә дигән инде. Исмәгыйль абыйның урыныннан кузгалып, ашыга-ашыга поездның аргы башына китеп барганын тегеләр шәйләп тә алганнар, шәп капчыгын да күргәннәр һәм, куып тотарга исәпләп, артыннан чаба да башлаганнар. Үз әйберләрен югалтасы килмәгән Исмәгыйль абый да йөгерергә тотынган. Шунда кинәт исенә төшергән: бер йөз метрлардан соңгы борылышны үткәч, Илек суы аша сузылган озын Каратугай күпере буласы бит. Ул, капчыгын ташлап, үзен куып килүчеләргә таба борыла да, кулын болгый-болгый: «Күпер! Күпер! Күпер!»—дип акырырга тотына. Үзе түбәгә ятып өлгерүгә, состав күпергә барып та керә.

Күпернең ике торыгын үтеп, аргы якка барып чыккач, Исмәгыйль абый башын күтәреп карый, теге чукынмышлар да өс-башларын каккалап, аякланып азапланалар икән. Барысы да агарынып калган. Исмәгыйль абый янына килеп, папирос тәкъдим иткәннәр.

—Нәрсәң бар, абзый?—дип сорый икән, аны «Казбек» папиросы белән сыйлаганы.

—Алтын,—дигән Исмәгыйль абый, ваемсыз гына итеп.

Егетләр дәррәү көлеп җибәргәннәр, йөзләрендәге агарыну-курку билгеләре дә юкка чыккан, ә тегесе, атаманнарыдыр,күрәсең, тагын сорый икән:

—Миллионер булгач, кызык өчен вагон түбәсендә кайтып барасыңмы?

—Йокы вагонында бөркү,—ди Исмәгыйль абый.

—Кая, капчыгыңны карыйк әле,—шул капчык аркасында чак кына үлемнән калган егетләргә шулай да кызык бит.

—Ә син, абзый, җебек түгел икәнсең, куркудан һушың китмәгән, күпер турында искәрттең. Гомер онытмабыз, рәхмәт!—дип, Исмәгыйль абыйга үзләренең киселеп-тырналып беткән, рәтләп юылмаган катыкытыршы кулларын бирәләр.

Капчыкны актара башлаганы:

—Фу-у-у, исе!—дип, борынын җыера.

Исмәгыйль абыйга үзенең тормышы-көнкүреше турында да, Оренбургка ни өчен килгәнлеге турында да сөйләп бирергә генә кала.

—Әй, ташла бу мәшәкатьләреңне, сабының белән сасып кына бетәрсең, рәтле акчасы да булмас, киттек безнең белән. Башлы абзый күренәсең, Ташкентта берәр җаен табарбыз әле,—ди атаманнары.

Ләкин Исмәгыйль абый, рәхмәт әйтеп, ул тәкъдимнән баш тарта. Поезд барган уңайга тегеләрнең берсе, вагон-ресторанга төшеп, аракы-шәраб, төрле кабымлыклар алып менә, Исмәгыйль абыйның андый затлы ризык-нигъмәтләрне күрмәгәненә дә биш былтыр була инде. Шулай итеп, вагон түбәсендә тегеләр белән кәеф-сафа корып, өенә кайтып җитә ул. Саубуллашканда, тегеләр аңа бер бөтен ак күмәч белән утыз сумлык кызыл акча тоттыралар.

## XXVIII

Оренбургта Рушан дүрт көн булды. Исмәгыйль абый туган Заһид хәзрәт мәхәлләсендәге архив кәгазьләренең бер өлеше гражданнар сугышы елларында, әлеге кварталда ак генерал Дутов гаскәрләре торган чакта ук юкка чыккан, калганнары да, бер бинадан икенчесенә күчерелә-күчерелә, шактый сиекланган-сирәгәйгән. Юкка гына: «Ике күченү—бер янгынга тиң»,—дип әйтмиләрдер инде. Кая ул әллә кайчангыларны эзләп табу! Әнисенең моннан өч ай элек язган ике үтенеч хаты җавапсыз калган булган, шулары да көчкә-көчкә генә табылды. Ләкин биредә Дасаев төрле ишекләрне шакып кына калмады, күп кенә кабинетларда өстәлгә суга-суга да сөйләште.

Оренбург бик нык үзгәргән, бу тирәләрдә газ чыгару эшләре башлангач, халкы да икеләтә арткан. Шәһәрнең кайсы башына гына барып чыкма, шул ук бер калыптан сугылган шөкәтсез йортлар тырпаеп утыра—Ташкентта да, Тулада да шулар ук. Үз йөзе, үз төсмере булган тагын бер борынгы шәһәр юкка чыккан, аның урынына «индустриаль гигант» калыккан дигән сүз. Дасаев бик ярата торган Җаек суы да саеккан, яр буендагы ямь-яшел урманнарына карарга да кызганыч. Рушанның бердәнбер юанычы бик кыенлык белән алынган ике белешмә кәгазе булды.

Ял көннәре эреп югалгандай кимеп барса да, Дасаев, үзенең уллык бурычын үтәгәннән генә түгел, ә үз туган тамырларына, үз ыруына якынлыгын тоюдан, үз ягы, кешеләре, йортлары, елга-күлләренең шушы өч атна эчендә үзенә тагын да кадерлерәк булуларын аңлаудан күңелендә бер рәхәт тынычлык хасил булганлыгын сизде. Күптән инде аның мондый халәттә булганы юк иде.

Алып кайткан кәгазьләрен собеска илтеп биргәч, ул еш кына велосипедка атланып йә җәяү генә Илек суы буена төшеп китә: су коена, кызына, балык тотып маташкан була иде. Әмма, юмарт итеп җим сибеп торсаң да, хәтта иң симез суалчаннарга да вак-төяк маймычлар гына каба—балыкларны да агулап-нитеп бетергәннәр икән инде.

Кичләрен ул өйдә булырга тырыша, озын көннең көн буена эшләп арыган үги әтисе белән ашыкмыйча гына ашап-эчеп, сөйләшеп утырырга ярата иде. Шуннан соң алар бакчага су сибәләр, берәр кирәк-яракны ясап йә төзәтеп-рәтләп куялар, аннары, бер-берсенә булыша-булыша, самавыр үрләтеп җибәрәләр.

Катя түти биргән кәгазьләрдән укып, Дасаев үги әтисенең озын-озак хезмәт елларында җәйгелектә кепка, кышлыкта колакчынлы бүрек, күнитек теккәнен, камыт-ияр ише сбруй әйберләрен дә оста әтмәлләгәнен, сабын гына түгел, конфет та кайнатканын, ә бер җәйдә артель бакчаларында су сиптерү буенча механик та булганлыгын, аннары тегермәндә эшләгәнен һәм хәтта бер ярты ел түрә булып, авырып киткән кладовщик урынына эшләп йөргәнен дә белә иде. Үги әтисе бары тик такта яру һәм балта эшләрендә, аннары кое өчен бетон бөҗралар коюда гына катнашмаган икән. Дасаев аңа карап болай дип уйлый иде: «Мартукта шахта булса—үги әтисе шахтер, завод-фәлән булса—завод эшчесе булыр иде. Әнә бит, ул үзе дә бу якларда берәр зуррак завод-фабрика булмаганга уфтана, анда аның зиһенле башына һәм оста кулларына яраклы эш табылмый калмас иде әле...»

Су буенда йөргәндә Рушан үги әтисенең тормышы турында озаклап уйланды. Исмәгыйль абзыйның тормыш юлы аллы-гөлле чәчәкләр сипкән юл булмаган, күбрәк чәнечкеле-тырнаулы булгандыр, әмма иң өметсезлеккә бирелерлек көннәрдә дә үги әтисе берәүне дә тиргәмәгән-каргамаган, хакы булса да: «Без ни өчен сугыштык соң?»—дип күкрәк какмаган. Мондый сүзләрне ул аек баштан гына түгел, бераз төшереп алганда да әйтмәгән.

Элегрәк, йә Ялтадан, йә Сочидан кайтышлый гына, Рушан әти-

әниләре янына бер-ике көнгә сугылып чыга иде. Тегеләр инде, билгеле, ул Сочи вә Ялта дигәннәрендә ни-нәрсәләр бары белән кызыксыналар. Ул шәһәрләрне алар шул Рушан җибәргән открытка рәсемнәреннән һәм кинолардан гына күреп беләләр бит. Ләкин ни әнисе, ни үги әтисе бервакытта да үзләренең гомер буе баш күтәрми эшләп тә, беркая да бара алмаулары, бер җирне дә күрмәүләре турында авыз ачып сүз әйтмәсләр иде. Бу хәлне Рушан үги әтисенең пенсия өчен исәп-хисап кәгазьләрендә егерме бер мәртәбә «файдаланылмаган ялы өчен компенсация» дигән сүзләрне укыганнан соң исенә төшерде. Баштарак ул бу еш очрап торган сүзләрне игътибарсыз гына укып киткән иде, аннары аңына килеп җитте: үги әтисе егерме бер ел буена ялсыз-нисез эшләгән бит! Аның, әтисеннән ничек шулай булганын сорыйсы килде. Әмма шунда ук үзен тыеп калды—нигә кирәк, ди, инде картларны ул күнелсез заманнарга кайтарырга?

Үз ачышыннан үзе әсәрләнеп, Рушан әлеге кәгазьләрне берничә мәртәбә кире кайтып укыды, шик юк иде—егерме бер ел! Рушан туган йортына кайткач, чәй янында үзенең бик арыган-талчыккан булганлыгын, икенче ел инде ялсыз эшләгәнлеген әйтеп, зарланып утырганын исенә төшерде. Ә алар, ягымлы вә кайгыртучан карт белән карчык, ник берәр мәртәбә ана каты сүз әйтсен, үз тормышларын мисалга китереп, төрттереп куйсын, юк, алар аңа теләктәшлек белдереп, көрсенеп кенә утыралар иде.

«Нинди пижонлык! Нинди ахмак тәти егетлек! Кемнәр алдында бит әле? Үз әти-әниләрең алдында!»—дип, оялып уйланды хәзер Рушан.

Кичләрен ул кайбер көннәрдә су буена атка атланып килә иде. Күрше Мостафа агайның Мукаш исемле улы колхозда бригадир булып эшли, һәр казакъ шикелле, ат ярата, хәтта бәйгеләрдә катнашу өчен дә үз чабышкы юртагы бар иде. Өлкә ат чабышларында аның Каракүзенә чабаннар, теләсә кайсын сайлап ал, дип, «Жигули» машиналары тәкъдим итәләр, әмма Мукаш атыннан да төшми, елык-ялык килеп торган машиналарга әйләнеп тә карамый икән. Мостафа агай менә шул Каракүзне кичләрен су буена алып төшәргә Рушанга ышанып тапшыра, чөнки, урак өсте башланып, Мукаш үзе куна-төнә кырда-басуда була—анарда ат кайгысы калмый иде.

Рушан китәр алдыннан гына Мукаш аларга кайгылы хәбәр белән килеп керде. Әнисе сыер сава, ә йокыдан иртә торган Рушан сыерны көтүгә куарга ниятләгән иде—соңгы көннәрендә картларга ни беләндер булса да ярдәм итәсе килә иде аның.

—Әти үлде...—диде бер көндә ничектер каралып, ябыгып калган Мукаш. Һәрвакыт шат күнелле, чибәр егет Мукашның кайгылы хәбәре авыл борынча чыгып китте.

Әнисе ирен уятырга өйгә юнәлде. Рушан Таҗйолдыз кушаматлы сыерны көтүгә куып кайтып кергәндә, Исмәгыйль абзый ишегалдында ике көрәген кайрап тора иде инде. Шунда ук җирдә ломы да ята. Мостафа агайның каберен казышырга Рушан да барырга булды.

—Бар, улым, бар,—диде Гөлсем апа, улына өчлек-бишлекләрдән торган егерме сумлап акча биреп.—Бар, безнең соңгы картларыбызны син күреп, хәтерләп калырга тиеш. Әтиең белән яшьтәшләр иде бит... Тагын кайчан кайтырсың әле... Аксакаллар белән хушлашып кал... Акчаларны дога кылганнан соң өләшерсең, йоласы шулай, улым. Мостафа агай бик кешелекле, бик әйбәт кеше иде, урыны җәннәттә булсын!—дип, сөйләнә-сөйләнә, Рушанны капка төбенә кадәр озатып калды ул.

Тыкрык-урамнардан чокыр аръягы зиратына таба көрәктер-ломдыр күтәргән кешеләр агыла башлады. Аксакаллардан кемдер Мостафа агайның кабере урынын тәгаенләгән, каберне казый башлаганчы, картларның намаздан чыгып килүләрен көтәләр икән. Әле мулла абзый да,—элеке бухгалтер, пенсионер Миңлегали бабайны шулай дип йөртәләр,—ул да килеп җитмәгән. Кем генә булмасын, ничек кенә яшәмәсен, кешене тын гына, шау-шуларсыз гына, оркестр-музыкаларсыз гына җир куенына салу

кирәк—Мартукның мөселман аксакаллары бердәм шул фикердә иделәр.

Зиратка жыелган картларның—кечәге көнлекчеләр, төрле эштә йөрүчеләр, көтүчеләр, ерак-ераклардан Семипалатка ит комбинатына мал куучыларның һәммәсе дә Аллаһыга ихластан ышанадыр дип әйтеп тә булмый. «Мулла абзый» Минлегали бабай да бер-ике догадан артыгын белмидер, анысын да, иң укымышлы кеше итеп, җәмәгать үзенә шул вазифаны тапшырганнан соң гына ятлап алгандыр әле.

Каберне яшь-таза егетләр һәм ир-атлар казыды. Эшне тиз тоттылар, чөнки халык күп җыелган иде. Кабер авызын алганда гына, картлар йола өчен дип, иң җинел көрәкләр белән берәр көрәк җир алган булдылар. Рушанга да, кабер янында ук торса да, күп казырга туры килмәде.

Исмәгыйль абзый яңа казылган кабер янында укылган догаларның бетүен көтеп тормады, улына көрәк-фәләннәрне алып кайтырга кушып, тын гына китеп барды—аның эшкә чыгасы бар иде. Рушан азакка кадәр булды, Мостафа агайның ак кәфенгә төрелгән гәүдәсен Мукаш белән бергәләп, аска төшеп, кулларына алды, ләхеткә индерде, махсус такталар белән томалап куярга булышты.

Барысы да таралып беткәч тә, Рушан зиратта тоткарланып калды. Мөселман зиратлары артык тәртибе-пөхтәлеге белән аерылып тормый, гомер итәргә дучар булып калган туганнарына бик авырга килгәнгәме, үлгәннәрне артык кадер-хөрмәтләү дә юк шикелле, нигездә, буялган тимер чардуган яки күбесенчә, гадел вә акыл иясе Барый абый Шакиров исән чагында ул ясаган, бушлайга куя торган бетон кабер ташы булыр иде.

Зират үзе дә чәчәк-ниләрсез, гадәтләнелгән яшел агач-куакларсыз, котырынып үскән көлсу төстәге әрем һәм чәнечкеле шайтан таягы белән капланган. Рушан, кабер ташларындагы язуларны укып, таныш исем-фамилияләргә тукталыбрак, үзләрен дә хәтерләргә тырышып, шактый озак йөрде. Инде чыгып барганда, янтаеп-инеп калган бер ташка күзе төште, бәлки, килеп карар кешеләре дә юктыр, дип, аны төзәтеп куймак булды.

Бик кыенлык белән булса да, ташны турайтып, кабер өстен тигезләп-рәтләбрәк куйгач, уелып-коелып беткән бетон өстендәге язуны кыенлык белән генә укыды: «Кашшаф Вәлиев. 1923-1949 е.е.», аз гына астарак тагын әле «Онытмагыз безне...» дигән язуы да бар иде. Хәзер инде утызга житкән Рушан белән чагыштырганда нибары егерме алты ел гына яшәп дөньядан үткән бер егет гүя Рушанга дәшә иде: «Онытмагыз безне...»

Кашшаф Вәлиев... Кашшаф... Рушан сугыштан исән-сау кайткан өч егетнең берсен шунда ук исенә төшерде. Димәк, Кашшаф та, бәхетле көннәр күрә алмыйча, үлеп киткән икән, сугышларда йөреп, исән-сау кайтканнардан хәзер нибарысы икәү генә—үги әтисе белән күрше Васятук кына калган икән... Әйтерсең лә, еллар аша монсу сагышлы күзле Кашшаф илереп кычкыра иде: «Онытмагыз безне... онытмагыз безне...»

Кичләрен Рушан белән үги әтисе уллары үзбәкчәләтеп ясап куйган айванда—урысча әйтсәк, беседкада утыргалыйлар, аны Рушанның ясаганына үги әтисе белән әнисе гажәпләнеп һәм куанып бетә алмаган иделәр. Үги әтисе, сиздермәскә тырышса да, эштән бик арып кайта: көне буе аяк өстендә—уенмыни сина! Ни әйтсәң дә, картлык—шатлык түгел шул инде. Бу үзбәк айваны бик кулай булып чыкты—әтисе баш астына бер кечкенәрәк мендәр салып, арзанлы «Прима» сигаретын мөштегенә утыртып, шунда ятарга ярата иде. Аның тартуы да картларчарак, төтенен суыра да уфылдатып чыгарып өскә өрә. Шундый мизгелләрдә Рушанның күнелендә әле монарчы булмаган хисләр кузгала, аның, үги әтисе янына килеп, нининдер ягымлы-жылы сүзләр әйтәсе яки берәр яхшылык эшлисе килә башлый иде.

Ул электән, Исмәгыйль абзыйның һәрвакыт ирләрчә горур булып, озын хезмәт юлында үз абруен югалтмыйча, тамчы да түбәнсенми-тезләнмичә яшәгәнен анламаган да, ул хакта уйлап та карамаган булган

икән. Үзе дә түбәнсенмәгән, мөмкин булса, башкаларны да түбәнсетергә юл куймаган ул.

Бу кайтуында әнисе Рушанга моннан бер ун еллар элек булган бер вакыйганы сөйләп алды. Ул елда печән ягы бик начар булган икән—сәбәбе корылык-фәләннән генә түгел, колхоз үз вакытында әзерли алмаган: эшләргә кешеләре җитми, ә өлешкә—пайга кереп чабарга рөхсәт юк икән, печән бәяләре бик тә үсеп киткән. Кем яшьрәк тә, кемнен транспорт-фәләне бар, шулар күрше район һәм өлкәләрдән алып кайтып әзерләгәннәр ул печәнне. Шул чагында Рушанның әнисенә кемдер: «Син военкоматка язып кара әле»,—дип киңәш биргән, нәкъ шул елларда фронтовикларга ниндидер өстенлек—льготалар була, дигән сүзләр чыккан чак була бу. Әнисе язган инде, шулай да шулай, күп орденлы фронтовик, хәзер инде сәламәтлеге дә нык какшаган карт кешегә ярдәм итә алмассызмы, янәсе. Әлбәттә, бу хакта Исмәгыйль абзыйның үзенә—ләм-мим инде! Чөнки әнисе белеп тора, әйтсә, тегесе: «Мин льготалар белән печән алыр өчен сугышып йөрмәдем, туган илемне якладым»,—дип кенә җибәрәчәк, картның талканы коры.

Күпмедер көннәр үткәч, кичләтеп боларга бер капитан килеп керә, хәрби комиссариатның яна хезмәткәре икән. Әлбәттә, өстәлгә җырлап торган самавыр да менеп кунаклаган инде. Капитан Исмәгыйль абзыйдан, энәсеннән җебенә чаклы төпченеп, барысын да сораштыра икән: ничек яшисез, ничек эшлисез, улыгыз кайда, нинди бүләкләрегез бар? Һәм башкалар, һәм башкалар... Исмәгыйль абзыйның кәефе күтәрелеп киткән, Гөлсем апага бөркет булып кына карый икән: күрдеңме, карчык, янәсе, мине ничә елдан соң да онытмаганнар. Кунак капитан сүз арасында гына сыер-печән якларын да сораштыра икән. Карт белән карчык, бу игътибарлылыктан биһуш булып, икесе бер авыздан әйтеп ташлаганнар: «Ул сыерга хәзер печән өчен машинасына өч йөз илле сумны каян алып чыгарып бирмәк кирәк!»—дигәннәр. Шунда капитан әйтә: «Телисезме, без Ташкент хәрби комиссариаты аша сезнең улыгызны кысыйк, әти-әнисенә ярдәм итсен, дип эш урынына хат җибәрик»,—ди. Бу «ярдәмче» капитанның ни өчен килгәнлеген Исмәгыйль абзый шунда гына аңлап ала. Хакимият башындагыларга хөрмәт белән карарга өйрәнгән булып, үзен кулда тота алса да, бу юлы ул түзеп кала алмаган, аптыраштa калган капитанның өстенә кила башлаган һәм ишеккә ымлаган: исән чакта чыгып кит! Хәтта теге адәмнең эчеп бетерелмәгән чәйле пиаласын да кулыннан йолкып алган. Шуннан соң әнисенә эләккән сүзләрне сөйләп бетерерлек түгел инде—шуңа да ул бу пенсия эшләрен дә бик саклык белән генә кузгаткан булган икән...

Исмәгыйль абзыйның пенсия мәсьәләләре ничек хәл ителеп беткәнен көтмәстән, Рушанның китеп барасы килми иде, шуңа күрә, ул эш урынына берничә көнгә тоткарланачагы турында телеграмма да җибәрмәкче иде, әмма өйлә вакытында Исмәгыйль абзый бик әсәрләнеп-куанып кайтып керде. Өстәл янына ашарга утыргач, ул, суыткычка таба ымлап, берәр нәрсәң бармы, әнисе, дигәндәй, баш какты. Әнисе баштарак аңышмый да торды: ире алай эш вакытында бер дә эчми иде ләбаса! Шуңа күрә, мунча көннән калган «Пшеничная» аракысы шешәсен китереп куйганда, шуны искәртергә кирәк тапты.

—Әнисе,—диде Исмәгыйль абзый, дәртле-шук елмаеп,—бетте! Эшемне бетереп кайттым. Шабаш!—Ул шешә төбендә калганын рюмкаларга бушатты.

Шул бар булганын тотып, күтәреп куйгач, тәмләп сөйләп бирде: нәкъ әбәт алдыннан аны кадрлар бүлегенә чакырып алганнар икән дә пенсия билгеләнүен хәбәр иткәннәр һәм аны айның икесе көнне алачагын да әйткәннәр. Димәк, тагын бер атнадан... эшләми-нитми генә... кулга акча үзе килеп керәсе икән!

—Җитмеш ике сум бит, әнисе, җитмеш ике сум!—дип куана үги әтисе.—Һәрхәлдә Шәйхинекен төкереп салдым бит, аныкы алтмыш сигез

сум гына чыккан иде... Ә безгә, әнисе, житмеш икесе дә бик житкән, безгә күп кирәкми бит, шулаймы, әнисе?—дип, шатлыгын кая куярга белмәгән Исмәгыйль абзый һаман да карчыгына кабат-кабат сөйләнә иде.

Өйләдән соң, шул ук күтәренке күнел белән Исмәгыйль абзый эшенә китеп барды, соңгы эшләрен бетереп, үзендәге эш коралларын тапшырып кайтасы бар иде аның. Картлач шулай да эт булып арыганлыгын һәм пенсиясенә бик шатланганлыгын әйткән иде. Рушан, әнисенә күз кысып, чемоданын тутырырга, алып китәсе китапларын рәтләргә кереште. Ташкентка иртәнге поезд белән үк китәсе итте. Әнисе исә күршеләргә ярдәмгә йөгерде—кичкә кунаклар жыеп, әтиләренең озак көтеп алган пенсиясе хөрмәтенә дә, улы китү сәбәбе белән дә утырасылары бар иде.

Алдагы көндә кибеттән сорап алган, Болгария шәрабеннән бушаган картон тартмаларга алып китәсе китапларын рәтләп тутыра-тутыра, Рушан кинәт уйга калды: ни өчен әле үзенең шундый истәлекле көнендә үги әтисе Шәйхинең пенсиясен искә төшерде икән?

Рушан Исмәгыйль абзый белән Шәйхи арасындагы астыртын көндәшлекне, әлбәттә, ишетеп белә иде. Дөресен әйтергә кирәк, бу көрәш тигезсез иде: алар икесе ике дәрәжәдәге баскычта торалар: үги әтисе шикелле үк, башлангыч белемле генә булса да, кесәсендә партбилетлы Шәйхи гомере буе «түрә кисәге» булган, Исмәгыйль абзыйның эшенә «бәһа биргән», «тикшергән», «карап торган» һәм аны «эшкә алган» кеше, имеш.

Гомере буена бер эшнең рәтен-чиратын белмәгән, акылга таманрак Шәйхи жирән Исмәгыйльнең алтын кулларына һәм зиһенле башына гел генә көнләшеп яшәгән. Ул, Исмәгыйль менә-менә сыгылыр-сынар, чал башы белән бер цехтан икенчесенә яна һөнәргә өйрәнеп йөрмәс, эчүгә сабышыр, менә шунда «эчкече һәм эш калдыручы» мөһере сугып, артына тибеп куып чыгарырга хыялланган Шәйхи. Шундый «ярамаган эшләрне» карый торган комиссиянең житәкчесе дә булган әле ул. Үзе чукраграк, надан булса да, «партийонный» бит... Әмма, юк, Исмәгыйль солдат зарланмаган, түрәләргә чабып йөрмәгән, кайда гына куйсалар да, эшләвен белгән.

Ә шул ук Шәйхи Исмәгыйль абзый теккән ничәмә-ничә кепканы, ул баскан ничәмә пар итекне йә «өченче сортлы» дип, йә бөтенләй бракка чыгарып утырган бит әле. Исмәгыйль баш иеп килер, явызланма дип, ялварып-үтенер, кызган мине дип, аяк астына тезләнүен көткәндер. Күпме пар итек-башмак, кепка-бүрек, янәмәсе, тикшерергә дип алынган да, шулай юкка чыккан, аларны Шәйхинең туган-тумачаларында күреп, үзе теккән нәрсәләрне алганын Исмәгыйль абзый үзе генә белә. Әмма үги әтисе ул кабихнең йөзенә бәреп, бервакытта да «карак» яки «жулик» дигән сүзләр әйтмәгән. Ләкин Шәйхи үзе Исмәгыйльнең пычрак эш тузанына баткан, арып-талып кызарынган күз карашларыннан һәрвакыт бер үк сүзләрне укыган: кабәхәт, надан, карак син... Шуңа күрә дә явызлыгының чиге булмаган тегенең.

Бары бер генә мәртәбә Исмәгыйль абзый аның өстеннән жинү хисе кичергән, әмма бу жинү бик кыйммәткә төшкән аңа.

Ул вакытта Рушанның үги әтисе тегермәндә эшли, төгәлрәге, икмәк киптерү-тартуда—кечкенә генә тегермән кисәге кожзавод белән янәшә иде. Шунда колхоз икмәген киптерәләр дә, тарталар да, аерым хужалыклардан килгәннәрен дә кире борып жибәрмиләр. Мескен халык еш кына тегермәнгә бер-ике пот ашлыгын күтәреп килә, берәр капчык белән килүчеләре бик сирәк була иде. Тарттырып биргән өчен бер өлеш онны хөкүмәт исәбенә басып та калалар бит әле.

Ничектер бервакыт, олы улларын ияртеп, тегермәнгә Шәйхи дә килеп керә. Әлбәттә инде, юньле кешеләр кебек, беркем белән дә исәнләшеп тормый, ни «исәнмесезе», ни «әссәламәгаләйкеме» юк—бу хәл Яңа ел алларыннан булып, шактый озын чират тезелгән икән, Шәйхи ул чиратка күз дә салмаган, алга үткән. Һәркем бодаен-мазарын бункерга

үзе сала, лардан агач соскы белән жылы онны капчыгына тутыра. Исмәгыйль абзый тартылган онны тикшереп-күзәтеп тора, тегермән ташларының тизлеген йә киметә, йә арттырып жибәрә, квитанцияләр дә язып бирә, милиция урланган-фәлән түгелме дип бәйләнмәсен өчен инде монысы, тарттырган өчен өлеш онын дәүләт ларына да сала бара.

Чираттагы берәүнең барлы-юклы бодае тартылып бетүгә, Шәйхи анын артыннан торган казакъ агаенын капчыгын читкә кагып кына жибәрә дә, малайлары бункерга авыр капчыкларны бушатып та куялар. Рушанның үги әтисе, чираттагы квитанция язып торган арада, ул, әлбәттә, тегеләрнен кыланмышларын күрә, ә чиратта торучылардан ник берәрсе берәр сүз әйтсен! Шәйхи капчыкларын да үлчәтеп тормыйча, бункерга аударттыра бит, квитанция дә яздырттырмый, димәк, билгеле инде, оннан хөкүмәткә тиешле онны да чыгарырга уйламый.

Ярар, бодае салынган, тегермән ташлары матур гына әйләнә, он да әйбәт кенә ага, тартылуы да менә дигән. Тук-симез йөзенә канәгатьлек чыгарып, Шәйхи елмаеп тора, малайлары капчыкларга он салырга дип, аларны әзерләп тотканнар, әтиләре, һаман авызын жыя алмыйча, ашыгып-ашыгып соскы белән капчыкларына он тутырырга тотына.

Исмәгыйль абзый бу очракта көчсезлегеннән гажиз булып һәм бу хурлыкка үзе өчен дә, башкалар өчен дә гарьләнеп утыра, анын ут булып янып чыккан кызыл йөзен бары тик он тузаны гына каплап тора. Менә ул өстәле яныннан кузгала, кемнендер капчыгын үлчәп куйган була, аннары әкрен генә өскә менеп китә. Анда нәрсәнедер караштырган-төзәткән кыланып, төшә дә янадан өстәле янына утырып язуларына иелә. Он тигез генә, куе булып ага тора. Кинәт ниндидер шытырдау-шыгырдау тавышы һаваны яра, бункердан тегермән ташы өстенә шунда ук калган бодай бөртекләре коела, он урынына малларга ашатырга ярарлык кына ниндидер катнаш, анламаслык нәрсә ага...

Шуннан соң! Әлегә кадәр тегермәндәге халыкка бер кәлимә сүз дәшми торган Шәйхи Исмәгыйль абзый өстенә, карчыга шикелле ташланмакчы була, кычкырынырга-акырынырга керешә, йодрыкларын төйнәп, яный башлый, зыянны түләргә боерып азапланмакчы була. Исмәгыйль абзый түләргә риза булганлыгын әйтә, башта Шәйхи квитанциясен күрсәтсен, күпме капчык алып килгән дә ана нәрсә түләргә кирәк икән?

Шәйхи, шулай итеп, үз гомерендә беренче мәртәбә авызы пешеп кайтып китә, шул бодайларын Исмәгыйль абзыйга бик озак исенә төшереп йөри әле ул. Үги әтисенә исә Яна ел бәйрәмендә тегермән ташларын янадан көйләп-төзәтеп йөрергә туры килә.

Рушан бу хәл-әхвәл бик күптәннән булган, шунлыктан инде онытылгандыр дип уйлаган иде, юк икән—онытылмаган, Исмәгыйль абзыйның үзегенә үткән теге юньсез Шәйхи белән көрәше дәвам итә, кем белә, аны әле Рушанга да үги әтисе эстафета итеп тапшыргандыр, бәлки. Әле күптән түгел генә дус-ишләреннән кемдер Шәйхинең бер улы Ибрайның, комсомол райкомы секретаре булып эшләгәндә, авыл китапханәләрен талап-урлап бетергәнлеген, чирәм жир колхоз-совхозларына да, хәтта иң ерак казакъ авылларына да кулы сузылгалаганын сөйләгән иде. Менә шундый «мәгърифәтче» икән ул Шәйхи малае!

Ярар, буласы булган, тузасы тузган, дигәндәй...

Иртәнге кояш белән үк өчәүләп вокзалга юл тоттылар. Алар капкадан чыгуга, никель рамнарын һәм төрле төсле буяуларын ялтыратып, үги әтисенен теге хәсрәтле көндә юкка чыккан «Диамант»ын хәтерләтеп, Украин урамыннан боларны бәреп егардай булып, чылбыр кебек тезелешкән велосипедчылар узып китте, Рушан ачынып-сызланып, тагын бер мәртәбә, бәлки, соңгы мәртәбәдер, үги әтисенен, Зәйнәп әбине жирләргә кирәк булгач, зәнгәр трофей «Диамант»ын каядыр илтеп сатканын исенә төшерде.

Поезд озак көттермәде, анын тукталышы өч кенә минутлык

булганлыктан, Рушан әйберләрен тиз генә вагонга кертеп куйды. Аннары тамбурның ачык ишегеннән карап тора башлады: әнисе әле, Аллага шөкер, карты янәшәсендә калкурак та, нык та, яшьрәк тә күренә, ә үги әтисе Рушан бүләк иткән ачык төстәге свитердан, кыска бобрик—керпе итеп алдырган чал чәчләре белән яшүсмер шикелле генә, ярдәмчесез-яклаучысыз бер кеше булып күренә иде. Ирексездән Рушанның тамагына төер утырды, күзенә яшьләр бәреп чыкты...

Станция кыңгыравы, гадәтенчә, поезд кузгалып китәсен белдереп, кагып куйды, ә состав ни өчендер кузгалмый тора иде. Шунда кинәт кенә Исмәгыйль абзыйның артындагы ташландык станция бакчасы ягыннан моңсу күзле Кашшафның эте өреп куйды. Әйтерсең ул тоныку тавыш «Онытмагыз безне... онытмагыз безне...» дип кабатлый иде.

Тепловоз дерт итеп тартылып куйды, поезд шунда ук йөрешен тизләтте. Рушан тамбур ишеге тоткасына ике куллап ябышып, гәүдәсен яртылаш чыгарып сузылды да, көпчәкләрнең көчәеп килгән дөбердәвен басарга теләгәндәй, әтисен соңгы мәртәбә күргән шикелле, гаҗизләнеп кычкырып җибәрде:

—Әти!... Әти!...

Ничәмә-ничә еллардан соң йөрәк түреннән үзе дә сизмәстән бәреп чыккан сүзләр иде бу... Һәм әтисенә соңгы эндәшүе иде...

## XXIX

Үткән тормышында казына-казына, Рушан шундый ачыш ясады: язмыш дигәнең кешеләргә очраклысын да, күп төрле иш-тиң килүләрне дә бик юмарт өләшә икән.

«Ул кеше үз урынында түгел» дигән сүзләр дә мең төрле булырга мөмкин, анысы да хәзер Рушан өчен бик кызыклы. Иң өстә яткан гап-гади төшенчәсе бу сүзләрнең шулдыр: бу урында башка кеше булырга тиеш, яки—бу кеше башка кеше урынын биләп, үз тормышы белән яшәми. Яки, мисалга: кемдер бик тар даирәдә, тар мохиттә бөтерелә, хәзер бу сүзләргә, әлбәттә инде, «элита» дигәнен дә өстиләр, ягъни сайлап алынган, иң шәп шәхесләр инде, әмма ул кеше үзенә бер зыянсыз, кимсетүләрсез, башкаларга да зыян китермәслек булып, ул «элита»га кермәскә дә мөмкиндер бит. Ә кемгәдер ул даирә, ул «элита» мохите һава кебек кирәк, аңа ул зарури, үзе теләгәненә ирешер мөмкинлеге булмагач, аңа сулыш җитми башлый, ул буылган кебек була.

Житмешенче еллардагы Ташкент яшеллеккә төренгән, күбесенчә бер катлы кечкенәрәк кенә йортлардан тора, базарда әйбер гаҗәп арзан, халкы искиткеч киң күңелле иде, миллионер шәһәр булу өчен аңа әле үсәргә дә үсәргә кирәк иде. Яшь-җилкенчәк берсен-берсе белә, бер үк урыннарда ял итә, күңел ача, бер үк паркларга, концерт залларына йөри. Алар яшь, әле өйләнешмәгән, барысының да бер уртак мавыгуы бар—футбол, шуңа күрә алар еш, көн саен диярлек күрешә иде.

Һәр юньле-рәтле шәһәрдәге шикелле, Ташкентның да шау-шуы, гөрләп торган тормышы белән җәлеп итә алырлык «Бродвее» бар иде. Ул Революция бакчасыннан башлана, анда үз заманында Сталинга Азиядә куелган иң зур һәйкәл күтәрелеп торган, аннан ары, подноска салынган кисекбаштай, Карл Маркснең сакаллы-чәчле зур башы булган, алар урынында хәзер горур кыяфәттә аргамакка атланган Бөек Аксак Тимер һәйкәле, аны элекке заманнарда рәсми даирәләр «илбасар» дип кенә йөрткәннәр. Урам, сузыла-сузыла, киштәләре товарлардан сыгылып торган дүрткатлы универмаг янынннан, аннары, непманнар заманыннан ук атаклы «Солей» һәм «Арс» кинотеатрлары яныннан уза,—алары хәзер, һәркайдагы шикелле, стандарт исемнәргә алыштырылган: «Чаткы» һәм «Яшь гвардия». Аларны артта калдырып, урам «Мәскәү» һәм «Фирганә» кафеларын буйлый—шунысын да әйтеп үтик: болары тирәсенә Ташкентта тәки

тернәкләнеп китә алмаган шәраб автоматлары куелган иде, аларны ватып-җимереп бетерделәр, ә урамның каршы ягында кичләрен балкып-яктырып торган галәмәт зур гастроном кибете иде. Төп ташкентлылар ул кибетне, мәскәүлеләр кебек үк, «иске Елисеев кибете» дип кенә искә алалар, кибетнең балык бүлегендә мичкә-мичкә уылдык—карасы да, кызылы да өзелмәгән, затлы балыклар да торган. «Бродвей», шулай килә торгач, «Ташкент» кунакханәсенә төртелеп туктый, анда әле тагын беренче даруханә дә бар, анысында Рушанның тагын бер танышы эшли—Нариман. Опера театры исә алгы ягы белән фонтанлы мәйданга карап тора. Атаклы архитектор Булатов проекты белән төзелгән «Ташкент» кунакханәсе янына футбол көннәрендә галәмәт күп халык җыела, алар «Пахтакор» командасының чираттагы көндәшләре стадионга барасы автобуска чыгып утырганны көтәләр. Хәзер мондый күренеш берәүне дә дулкынландырмый инде, хәзер: «Кара, кара—Воронин!.. Месхи! Метревели! Стрельцов! Хөсәенов!...» дигән сокланулы тавышларны да ишетмисен.

Хәзер инде ни универмаг, ни бер кварталга кадәр шоколад-кофе исләре аңкытып утырган гастроном, ни шәраб автоматлы «Мәскәү» белән «Фирганә» кафелары, ни «Солей» белән «Арс» кинотеатрлары, ни Нариман эшләгән беренче даруханә юк. «Чаткы» кинотеатры белән «Фирганә» кафесы арасында почмактагы менә дигән комиссион кибетләр дә, «Бродвей» үзе дә, аның башланган-беткән урыннары да юк. Һәммәсен дә бер көндә—1966 елның 26 апрелендә коточкыч дәһшәтле җир тетрәү йотты аларның...

Җир тетрәүдән соң Ташкентта күп нәрсәләр—барыннан да бигрәк, үзенә генә хас рухы-җаны, шәрекъ шәһәрләрендә генә була торган европача мәдәният катнаш аерым бер зыялылык та юкка чыкты.

Мәңгегә кире кайтмаска «Бродвей» да югалды, ул үзенә күрә теләсә кем кереп йөрерлек, шул ук вакытта билгеле бер абруй-дәрәҗәле клуб шикелле иде һәм анда күздән югалган кызны да һәрвакыт эзләп табып була иде. Рушаннар заманындагы кызлар: «Сезне кайда очратырга мөмкин?»—дигән сорауга: «Бродвей»дан эзләгез»,—дип кенә җавап бирәләр иде. «Арс» белән «Солей» кинотеатрларында киносеанслар алдыннан уйный торган оркестрлар да гомер кире кайтмастыр инде, аларның берсендә хәзер танылган җырчы Роксана Бабаянның әнисе Сәйдә Бабаева җырлый иде. Бүгенге кинотеатрларның иденнәре төкерек-какырык белән тулган булыр, фойэлары шакшы, шуна күнеккән хәзерге буын тамашачылар элекке хозурлыкларны күз алдына да китерә алмый. Ләкин Рушаннар яшь, үзләренә бик тә ышанган буын иде, алар элеккесеннән дә гүзәлрәк шәһәр төзиячәкләренә ихластан ышанып-инанып яшәделәр. Шулай булып чыкты да, әмма ул инде,—исеме Ташкент булып калса да,—башка шәһәр иде, ул башка кешеләр өчен булды.

Ә үз заманнарында алар көн саен диярлек «Бродвей»да очраша, бихисап кафе-ашханәләрнең ачык верандаларында кәеф-сафа корып утыра, «Ак мусалас», «Баян Ширей», «Хосилот» дигән бик затлы, үзе искиткеч арзан ак шәрабләр генә эчә, Үзбәкстан дәүләт эстрада оркестрының яңа программасы турында кызып-кызып бәхәсләшә иделәр. Анда ул елларда үзенең кабатланмас «Гарәп тангосы» белән танылган атаклы җырчы Батыр Закиров җырлый, хәзер дә джаз музыкасы иҗат итүче мәшһүр композитор һәм дирижер Анатолий Кролл эшли, Ташкент урамнары буйлап ул аклы-каралы сәер «Волга»сында гына чаба иде.

Яшьләр «Пахтакор» футбол командасының шул көннәрендә булачак уенын түземсезләнеп көтә, көндәшләре өчен дәһшәтле пар Красницкий—Стадник, искиткеч оста капкачы Коля Любарцев, бик үҗәт-ябышкак уң сакчы Ревал Закировлар өчен җаннарын бирергә әзер иделәр. Горький паркында әле ул вакытта яшь шагыйрь Александр Файнберг оештырган шау-шулы шигърият кичәләре үзләре генә дә ни тора иде!

Рушан ниндидер бер мәҗлестә, очраклы рәвештә генә, Мәскәүнең Театр сәнгате дәүләт институтын (ГИТИСны) тәмамларга әзерләнүче

һәм шәһәр опера театрында үзенең диплом спектаклен куярга йөрүче Ибраһим Юнысов белән танышты. Диплом спектакле—Кара Караевның «Яшен сукмагы» балеты икән. Балет труппасынын төп биючесе һәм шул ук вакытта спектакльне куючы да Ибраһим белән шулай тиз генә башланып киткән дуслык Рушанга театрга арткы ишектән генә кереп йөрү мөмкинлеген дә бирде, ә мондый форсат ул кырыс заманнарда бик әзләргә генә эләгә иде. Ул бик күп репетиция, спектакльне буеннан-буена куып карау—прогон дигәннәрен, аны абруйлы комиссиягә тапшыруларны күрде, спектакль премьераларын сөйләп тә торасы юк инде. Рушан ул репетицияләргә махсус йөрмәде, билгеле, ул дусты Ибраһимнын эшенә килә дә аның бушаганын көтеп утыра. Әлбәттә, бер елдан ул бөтен балет труппасын, бигрәк тә кордебалеттагы кызларны исемләп белеп, алар белән танышып та өлгерде, Нариман белән икәүләп, Ибраһимга сиздерми генә, кызларны Нариманнарга кофе эчәргә чакыра иделәр. Нариман театрга янәшә генә Үзбәкстан урамындагы бер карт яһүднең иске генә йортында бер бүлмәдә тора, ишегалдында су колонкасы, аның янында һич тә кибә белмәс күлләвек тә бар иде. Хәзер ул урында Дәүләт банкының саркофагка охшаш шөкәтсез мәрмәр бинасы кукраеп утыра.

Кайвакытларда Рушан Ибраһимны эзләп Педагогик урамындагы балет училищесына да барып кергәли иде, чөнки дусты анда дәресләр алып бара, бу училище хәзер илдә иң өлкәннәрнең берсе санала. Хәтерендә әле, Рушан анда шулай бер тапкыр иртәрәк килде дә, балет сыйныфында дәреснең ахырына кадәр утырды—аңа яшь кенә бер кыз бик ошап калган иде. Ул кызга бөтенләй башка максатлар өчен алынган чәчәкләрен бүләк иткәнен сизми дә калды, аңа зур сәхнә йолдызы—балерина язмышы юрап, кызны кызартып оялткан да иде.

Ул кыз Киров шәһәре балетының булачак йолдызы Валя Ганнибалова иде. Күп еллар үткәч, үзенең туган шәһәренә гастрольгә кайтып, ул Рушанны хәтерләвен, күрәзәлек кылуының рас килүен, балерина буларак беренче чәчәкләрне аның кулыннан алуын сөйләп, Рушанны да куандырды.

Бәлки, балетны шулай эчтән күреп белүе, сәхнә артыннан күрүе, биюче гүзәлләрнең репетицияләрен йотылып каравы Рушанның рәссам Дег картиналарын ярата башлавына сәбәпче булгандыр да әле. Юк, ул, танылган архитектор Шусев проекты белән сугыштан соң әсир японнар салган гүзәл театр бинасына рәхәтләнеп йөрсә дә, балетоман булып китмәде. Аңа спорт залларына охшаш репетиция заллары ошый, декорация исләре ошый, театр рәссамнары һәм костюмерларының эшләре ошый—читтән күзәтеп торучылар булса, ул аларга, мөгаен, узып ашкан театр сөюче булып күренгәндер.

Ул елларда Арам Ильич Хачатурян «Спартак» балеты музыкасын язып танылган, кайчандыр Ибраһим стажировка үтеп йөргән Григорович исә аны Зур театрда куеп та өлгергән иде инде, Ибраһим да шул уй белән яна башлады. Ул Мәскәүгә дә берничә мәртәбә барып кайтты, тәки композитордан үз музыкасына балет куярга хәер-фатихасын алды.

Әйтергә кирәк, «Бродвей»да очрашулар ул заманнарда «Спартак» балетын кую эшләренең ничек барышын сөйләшүдән башлана иде. Спектакльнең бизәлешен Ереваннан килгән атаклы рәссам Мирзоян эшләде. Рушан да бу вакытка Мәскәүдә булып, Григорович куйган балетны карап кайткан һәм андагы спектакльгә рәссам Сулико Вирселадзе ясаган гаҗәп матур декорацияләргә, артистларның костюмнарына сокланып туймаган иде. Ибраһим үзенең кордебалеты кечкенә булганга бигрәк тә көенә, Григоровичтагы шикелле, төп сәхнә күренешләренә ярашлы матур бизәлеш юклыктан зарлана. Рушан белән Нариман, бер-берсен аңлап, карашып алалар—алар да кордебалетны икеләтә-өчләтә арттырырга кирәк дип исәплиләр! Анда бит шундый гүзәл кызлар бии! Аларны соңыннан Нариманга кофе эчәргә чакырырга да була.

Бөтен шәһәр булачак премьераны көтеп яши башлады, маэстро

Хачатурян үзе дә киләчәк иде. Ибраһим, якын дусты буларак, Рушанга танылган композиторны һәр жирдә озатып йөрү бурычын йөкләде—алар, премьерадан соң булган банкетта да, Хачатурян белән янәшә утырдылар.

Язмышның менә шундый капма-каршылыклары һәм борылышлары да була икән: прораб белән балетмейстер, кордебалет белән аптекарь, маэстро Хачатурян һәм Сулико Вирселадзе эшләре...

Тормыштагы, язмыштагы мондый көтелмәгән борылышлар—бетмәс-төкәнмәс уйлануларга азык, ул борылышлар сине теләсә кайсы якка алып китәргә дә мөмкин: зурлыкка да, хурлыкка да. Менә әле күптән түгел генә газетлардан укып, Мәскәүдәге актерлар йорты, ягъни икенче төрле ВТО (Всесоюзное Театральное Общество—Бөтенсоюз Театр Җәмгыяте) дип йөртелә торган йорт янганын белгәч, Рушан аны торгызу фондына зур гына сумма акча да жибәрде, фамилиясе янына үзенең һөнәрен дә язып куйды—прораб.

Бу зур сумманы алгач, Мәскәүдәге кешеләр гаҗәпләнгәннәрдер: прораб һәм Актерлар йорты, аларны нәрсә берләштерергә мөмкин? Ә менә һаман да шул язмыш шуклыгы—кайчандыр Рушан да ул йортның бусагасын атлап кергән, аны матур итеп, киң күңеллелек белән каршы алганнар, ул анда бик тә истәлекле кич үткәреп чыккан иде... Менә ни өчен, егерме биш еллап вакыт үткәч, шундый җавап ясалды, кем әйтмешли, яхшылыкка—яхшылык...

Хәзер генә ул «барлык флаглар да бездә кунакта» булуга ничектер күнегеп киттеләр: Италиянең «Ла Скала»сы да, Штутгарт балеты да, «Кабуки» театры да, Лондон симфоник оркестры да, Шекспир король театры да... Ә бит барысы да теге чакта ук, анда да әле бик кыюсыз гына, алтмышынчы еллар уртасында башланып киткән иде. Менә ул чагында, чынлап та, һәммәсе дә беренче тапкыр иде: Мәскәүдә «Ла Скала» да, Герберт фон Караян да, данлыклы мим Марсель Марсо да һәм тагын бик күп-бик күп данлыклылар, мәшһүрләр...

Бервакыт шулай алар Ибраһим белән икәүләп «Ташкент» кунакханәсенең җылы барында Нариманны көтеп утыралар иде, кинәт Ибраһим, һәрвакыттагыча кайнарланып, әйтеп ташлады:

—Сиңа иң кызыклы яңалыкны әйтергә онытканмын—Мәскәүгә француз балеты килә,—диде.—Берәр пәрдәле ике спектакль алып киләләр: «Ак сюита» белән «Коппелия»не. Театр белән минем институттагы курсташым Вера Бокадоро да килә икән, анардан телеграмма алдым.

—Барасыңмы?—дип сорады Рушан.

—Бармыйча соң! Гомергә бер тапкыр француз балетын күрү мөмкинлеге ич,—дип жанланып китте Ибраһим. Аннары бер-бер артлы тезә башлады: Петипа, Фокин, Дягилев... Рудольф Нуриевны да телгә алды, анысы ул вакытта Көнбатышта торып калган иде инде.

Берниндн кучешсез-нисез Ибраһим сорап куйды:

—Ә син Мәскәүгә командировка ала алмыйсыңмы соң?

Рушанның бәхетенә, Мәскәүгә бару ихтыяжы бар икән, ул бер авырлыксыз гына «Минмонтажспецстрой»га командировка алды, үзенә «Пекин» кунакханәсендә урын калдырылачагын да Ташкентта чакта ук тәгаенләде. Бер көннән соң алар салкын Мәскәүгә очып килеп төштеләр, бер калдырылган урынга кунакханәгә дә икәү бергә урнаштылар—Ибраһимның балетмейстер булуы һәм килү максаты «Пекин» администрациясенә аңлаешлы иде.

Спектакльдән соң Ибраһим сәхнә артына үтеп керә алды һәм, үзенең курсташ француженкасы янына тагын кордебалетта биюче бер кызны да ияртеп, килеп тә чыкты, алар атлый-йөгерә Зур театрдан Столешников тыкрыгы аша Пушкин мәйданына—әлеге дә баягы ВТОга юл тоттылар. Аларны суык кына кумый, Мәскәүне яхшы белгән Ибраһим да ашыктыра, чөнки тиздән театрдан тарала башлаячаклар һәм ярты сәгатьтән соң Актерлар йортына эләгеп булмаячак иде. Алар өлгерделәр һәм Рушанның күңелендә гомерлеккә уелып калган гаҗәеп матур кичне

шунда үткәрделәр. Барысына да өстәп, шуны да әйтергә була: нәкъ менә шунда ул беренче һәм соңгы тапкыр француз шампаны «Гордон Верт» шәрабе эчкән иде.

Ул кичтә Рушан бик күп сәхнә йолдызларын «тереләй» күрде: актерлар, рижиссерлар, эстрада җырчылары, дирижерлар, киночылар, дисеңме... Аннары аларның өстәле янына да байтак кына танылган шәхесләр килеп-килеп киткәләде—Ибраһимны бу йортта да яхшы беләләр иде. Кунакчыл йорттан алар ярты төн узгач кына китеп бардылар. Әле күңел ачуны дәвам иттерү өчен тагын каядыр юнәлделәр, Рушан хәтерли, Актерлар йортыннан ул, француз кызлары хөрмәтенә дип, тагын бер шешә шампан да кыстыра чыкты. Ул вакытта «Гордон Верт»—«Яшел Тасма»ның бер шешәсе ничә сум тора иде дип сорагыз? Җиде сум! Ышана торган түгел! Чынлап та, искиткеч заман иде ул...

Ибраһим, ташкентлылар француз балетын күрми калалар инде, дип борчылды. Алай да төп биючеләре Клер Мотт белән Пьер Бонфуны, Ташкентка килеп, үзенең «Жизель» балетында төп партияләрне биеп китәргә күндерә алды. Әлеге биючеләр икенче сезонда Ташкентка килделәр һәм балет сөючеләрне куандырып, биеп тә киттеләр. Шулай итеп, ике яшь егетнең Мәскәүгә барып кайтулары Терпсихорага табынучылар өчен бәйрәмгә дә сәбәпче булды.

Үткән вакытларны исенә төшергәндә, Рушан әллә кайчангы вакыйгаларның тоныкк кына гөрелтесен, онытылган тавышларның аңлаешсыз пышылдаштыруларын ишеткәндәй була, аның өчен бүген алар һәммәсе дә кадерле һәм әһәмиятле. Бәлки, шунлыктандыр да, аның күңелендә тигез-тәңгәл булмаган, кемнәр өчендер әһәмиятсез күренгән хәлләр-вакыйгалар яңара. Аннары ул бит артта калган, бер генә төрле булмаган вакытларның барысын да колачлап бетерергә җыенмый да, моңа аның көче дә җитмәс иде. Ул бит, меңнәрчә башкалар шикелле, билгесез бер төзүче генә, аның танышларын, дусларын-туганнарын да язмыш иркәләп тормаган—менә шуларга һәм үзенә кагылышлы нәрсәләрне генә хәтерендә тергезеп, сөйләп бирә алса да, ул Аллаһы Тәгаләгә рәхмәтле булыр иде...

## XXX

Күнелленнән үзенең студентлык чорына һәм Актүбәдә яшәгән беренче елларына кайтып, Рушан тагын бер адресны читләтеп үтә алмый: Почта урамы, 72 нче йорт. Бер Яна ел кичендә шәм яндырып багу баккан, аллы-гөлле чегән шәлле, яшел күзле кызны озата киткәч, адашып йөргән Роберт исемле егет шул йортта яши иде.

Кызыл шампан шәрабле ул Яна ел төне исенә төшкәч, Рушан «юраганы юш килгән» тагын бер нәрсәне хәтерендә яңартты. Тамара бер-бер артлы һәрберсенә дә бер үк төрле юрамышлар әйткәч, үткен телле Вуккерт төрттереп әйтеп куйган иде: «Син, мадам, мөгаен, юрый белмисеңдер»,—дигән иде. Тамараның хәтере калды, ул гөлт итеп кабынып китте, күзләре шикле ялтырый башлады. Кулындагы кәртләрен бер читкә атып, шәмнәрен сүндерде дә, еламсырап әйтте: «Сезнең һәркайсыгызга да ерак юллар, иртәләгән сагыш чыкканга мин гаепле түгел...»—диде.

Вакыт ул яшел күзле кызның күрәзәлек итә белүен раслады.

Робертларның кунакчыл өендә Рушан Дасаев, икенче курстан башлап техникумны тәмамлап чыкканчыга кадәр, еш кына була иде. Робертның фамилиясе европалылар, аерым алганда, урыслар колагы вә теле өчен бик авыр яңгырашлы-әйтелешле—Телиүмөхәммәтов. Әтисе—эре гәүдәле, чал чәчле, картаеп баручы казакъ, әнисе—татар кызы, әтисенең икенче хатыны иде. Аларның яшь аралары шактый икәне дә, иренең хатынына карата игътибарлы булуы да сизелеп тора. «Мәхәббәт булса—матур балалар туа»,—ди борынгылар сүзе. Менә аларның уллары да күркәм бала булып үсте, холкы-табигате белән дә алдырган иде ул.

Робертка Ходай Тәгалә спортчы һәвәслеген вә осталыгын кызганмаган, егет ул заманнарда әле янарак мавыгу булган баскетболны да шәп уйный, Рушанны бокска тартучы да ул булды. Ин кызыгы шул—Роберт кечкенә Актүбәдә беренче һәм озак вакытлар бердәнбер стиляга—гайре табигый фырт киенеп йөрүче дә иде. Хәзерге кием-салымда һәм әхлактагы иркенлек-»ялангачлык» чорында моны аңлау шактый кыен, әлбәттә. Әмма дөресе шулай. Биредә шунысын да әйтеп үтәргә кирәк, Телиүмөхәммәтовлар гаиләсе Актүбәгә күптән түгел генә Урал якларыннан күчеп килгән иде. Үзләре элек яшәгән Магнитогорск шәһәре, Робертның сөйләүләре буенча, Рушанга озак еллар әле ниндидер Чикаго сымаграк булып күзалланып торды, чөнки сүз гел генә джаз музыкасына барып бәйләнә иде. Илленче елларның урталарында, илгә беренче мәртәбә рок-н-ролл үтеп кергәч, яшьләр ана шундук гомерлеккә гашыйк булдылар. Алар Армстронг, Эллингтон, Дези Гилеспи, Глен Миллер исемнәрен сихерләнгәндәй кабатлыйлар иде. Рок-н-ролл кайчан да булса үләчәк, дип, аларны ул вакытта беркем дә ышандыра алмас иде һәм бүген, бу музыка икенче кат туып, аның әлеге беренче табынучылары инде пенсиягә китәргә җыенганда, рок-н-роллны аларның балалары һәм оныклары биегәнне-тыңлаганны күргәч, алар, соңлап булса да, яшьлек мавыгулары белән горурланалар иде. Дөнья кичә генә яратылган дип уйлый торган берәр мышык борын яшүсмер әтисеннән Элвис Пресли исемен ишеткәне бармы-юкмы икәнен сораганда, әтисе эчке бер горурлык белән тыныч кына җавап бирә: «Әйе, улым, моннан утыз еллар элек ишеткән идем»,— ди. Әйе, дөньяда һәр нәрсә кабатлана...

Үз заманы турындагы күңелендә йөрткән «мәңгелек китап»ка нәрсәләр кертергә теләгәннәрен уйланып утырганда, Рушан, чынлап та, дөньяда һәр нәрсәнең кабатланганын, үзенең берниндиi дә яңалык әйтә алмаячагын төшенде. Һәммәсе дә ышанмаслык дәрәҗәдә гап-гади. Һәммәсе дә ана кадәр дистәләрчә-йөзләрчә мәртәбә булган, аңардан соң да булачак, теләсә кайсы китапның эчтәлеге берничә сүзгә сыеп бетә: зәңгәр бантик-«күбәләк»ле яки «күбәләксез» генә ниндидер бер кызга ниндидер бер малай гашыйк була. Һәм, гадәттәгечә, андый мәхәббәт җавапсыз кала—бәхетсез мәхәббәт... Аннары һәр икәүнең вакытлары, борынгы сәгатьләрдән ком агып беткән шикелле, агып беткәндә генә, тормыштан арыган-талчыккан, картаеп әбигә әйләнгән хатынга вакыт галиҗәнапләре соңлап кына бер хакыйкатьне раслаячак: шул синең илаһи көчләр индергән бердәнбер мәхәббәтең булган, ә бердәнбер шаһзадәнне һәм әкияти дәрт-ымсынуларыңны эзләвең—мәгънәсез, бер нәтиҗәсез буш хыял гына.

Американың атаклы әдибе Курт Воннегут юкка гына: «Барлык китаплар да бары тик бер хатын-кыз хакына гына языла»,—димәгән. Шулай, яки якынча шулай. Әлбәттә, башка вариантлар да булырга мөмкиндер. Боларның һәммәсе аралыгында Россиянең, һәрвакыттагыча, рәхәте-бәхете булмаган тормыш, агымлы җылы карашларсыз, бары тик салкын һәм шыксыз, үтеп йөри алмаслык сукмак юллары гына булган һәм шул юл-сукмакларга гомереӊ буе түгелгән иртәләгән һәм соңлаган сагыш-моңнарың гына тулган булыр...

Бу ачыштан башта Рушан Дасаев күңел боеклыгына, кайгы-хәсрәткә тарды, ул күпмедер вакытка үзенең үткәннәрдә казынуын куеп торды. Әмма күңегелгән ул шөгыльдән алай җиңел генә котылып, аны ташлап калдырып яки онытып булмый иде шул. Ул бөтенесен дә онытыр, хәтерендә янартмас, шул чагында инде аның үткәннәре бөтенләй онытылыр-үләр, дигәндәй, шул ук үткәннәре бүгенге көн аша үҗәт бер әрсезлек белән кайтып керә тора. Әйе, әйе, шулай үҗәтләнмәсәләр, барысы да үләр, тормышның һәр көне узган шикелле, эреп бетә барыр. Шуннан соң Рушан яңадан хатирәләренә әйләнеп кайтты, күңелендә уелып калган һәр нәрсәне бөртекләп җыя, исенә төшерә башлады...

Рушан бу тормыштан сизелерлек эз калдырмыйча китеп барачагы

белән килешкән-ризалашкан иде инде—аның хезмәте һәрвакыт коллектив белән берлектә булды һәм бер дә алай күренекле түгел иде. Мисалга, ул бит, Заркент кургаш-цинк комбинатын төзедем, дип әйтә алмый, чөнки аны меңләгән эшчеләр, йөзләгән прораблар бергәләп төзеде. Рушан да шулар арасында бер ком бөртеге генә иде. Ком бөртеге генә...

Әмма аның, Рушан Дасаев дигән шәхеснең үз шәхси тормышы да бар иде: ул да сөйде, хыялланды, көтте—менә шул тормышка ашкан һәм ашмаган өмет-хыялларның һәммәсе хакында да сөйләп калдырасы килә, алар аның белән бергә юкка чыкмасыннар иде. Шуңа күрә ул, беraз өзелеп торганнан соң, кичләрен янадан озаклап тәрәзә буенда басып тора башлады, башы да, азагы да булмаган «мәңгелек китабын» бер үк вакытта укый да, яза да барды, ул китапта барысы да дөньяның үзе кебек үк иске, анда һаман да кулына ноталар папкасы тоткан зәңгәр бантик-«күбәләк»ле кызга бер күрүдә үк авыл малае гашыйк була...

Ах, беренче мәхәббәт хисе, җавапсыз калган мәхәббәт хисе! Нигә син шулай татлы да, газаплы да икән дә, нигә гомер буе йөрәкне өзгәләп, сызып-сызланып яшәргә дучар итәсең икән?!..

Почта урамындагы 72 нче йортта исә Рушан укуының соңгы ике елында, Роберт белән бик якынаеп киткәч, бигрәк тә еш була башлады. Ихтимал, үзен тәрбияләүдә, дөньяга карашларын калыплауда, тормышны танып-белүдә бу йорт аз роль уйнамагандыр. Ә инде спортны, джаз музыкасын яратуы, зәвыгы һәм үз-үзен тотышы-рәвеше өчен ул, әлбәттә, Робертка бурычлы булды.

Робертның әнисе йорт эшләрен генә алып бара, кияүгә чыкканчы әдәбият укыткан булса да, хәзер эшләми иде. Өй эче ялт итеп тора, тәрәзә төбендәге гаҗәеп матур, сирәк очрый торган гөлләр кунакларны таң калдыра, әмма барыннан да бигрәк Рушанның хәтерендә пирог исләре калган. Мартукта ачлы-туклы үскән бу яшүсмергә ни кирәк тагын? Боларда һәрвакыт нәрсә булса да пешерәләр-төшерәләр. Өй эченә кем генә килеп кермәсен—иң элек барысын да өстәл янына утырталар: күрәсең, Робертның әти-әниләре дә үзләренең ач студентлык елларын бер дә онытмаганнардыр. Күп кенә бәйрәмнәр, Туган көннәр дә шушында үтә, сәбәп белән дә, сәбәпсез дә яшьләр гел шунда җыела иде. Йортта бәхәсләр тынып тормый, яңгыратып көлү тавышлары ишетелә һәм, әлбәттә, иртәдән кичкә кадәрле диярлек музыка уйнап тора. Джаз музыкасы. «Бу Армстронг дигәнегез безгә бөтенләйгә күчеп килгән бугай»,—дип шаяртыр иде Робертның әтисе Бертай әкә. Ул үзе дә еш кына яшьләрнең бәхәсләренә кушылып китә, әмма бервакытта да үзенең абруе белән аларны кысмый, үзенең яшенә-тәҗрибәсенә яки белеменә таянмый, юкса ул сугышка кадәр үк Ленинград университетын тәмамлап, кандидатлык дәрәҗәсен дә якларга өлгергән кеше иде инде.

Бертай әкә улының джаз белән фанатикларча мавыгуын өнәп бетерми, шулай да аның теләкләренә каршы да килми иде. Ә Рушаннар, Робертның буржуаз культура белән мавыгуы өчен, әтисен партиянең шәһәр комитетында бер генә тәпәләмәгәннәрен беләләр иде.

Үзләрен шәһәрнең аталары итеп тоючы кемсәләр ул заманнарда барлык стиляргаларның да чәчләрен ялтыратып кырып алу турында хыялланалар иде! Шәһәрдә башка прокурор булса, мөгаен, кыркыган да булырлар иде...

Рушан кайвакытларда, бигрәк тә курс эшләрен тапшырырга бик күп сызымнар сызып иртәнгә кадәр утырырга туры килгәндә, аларда куна да кала иде. Бервакыт ул Бертай әкәнең төн уртасында: «Кылычларыгызны—кынысыннан! Эскадрон, һөҗүмгә!»—дип кычкыруыннан сискәнеп китте. Рушанның гаҗәпләнеп зур ачылган күзләренә карап, Роберт аңлатырга кирәк тапты: аның әтисе гражданнар сугышында атлы эскадрон командиры булган икән, шул вакыттагы дәһшәтле сугышлар һаман да аның төшенә керә икән. Менә шулай итеп, картаеп барган кешенең төнге кычкыруы егетләргә кинәт кенә тарих сулышы булып тоелды.

Соңрак, улының дуслары гражданнар сугышы турында сөйләткәндә, Бертай әкә, кылыч сугышында җайдак сугышчылар, ягъни ат менгән сугышчылар гына сугышмый, хәтта атлар да бер-берсен тешләшә-сугыша, дип сөйләгән иде.

Күп еллар үткәч, кайсыдыр бер җирле профсоюз санаториендә ял иткәндә, бервакыт Рушан кинәт куркынып кычкырган һәм дөбердәп урындык ауган тавышка уянып китте. Сикереп торып, ут яндырса, күрше тимер караваттагы өлкән яшьләрдәге абзый бәрелгән аягын уып утыра. Абзый, гаебен сизеп, акланып алды:

—Гафу ит, энекәш. Янә сугыш төшкә керде. Патроннарым беткән, имеш тә, мин күнитекләрем белән бәрә-бәрә сугыша башлаганмын...

Менә шулай соңлап булса да, ике сугышның кайтавазы кушылып, Рушанның тормышында чагылып үткән иде. Шул чагында Рушан беренче мәртәбә уйга калды: ана, сугышлар күрмәгән кешегә нинди куркыныч төшләр керер икән картлыгында? Бала чагыннан тулысынча татыган озын ипи чиратларымы? Әллә үлгәнче бер-берсенә каршы торган балаларга тәки тәтемәгән каһәрләнгән ташкүмер өемеме? Әллә әнисенең кушучына немец Тилковски кесәсеннән бушаттырылган бер кушуч бодаймы, шуның өчен Тилковски унбиш ел утырып кайткан иде бит? Ә бәлки, өметсезлек-гаҗизлектән үз илен ташлап китәргә мәҗбүр булган кешеләрнең Көнбатыш илләренең илчелекләре янындагы чиратларда торганда күрелгән хәсрәтле күз карашларымы?

Бертай әкә эштән бик соң кайта, еш кына арыган, үртәлгән була,—ә ни-нәрсәләр өчен үртәлеп кайтып керә ул, анысын үзеннән башка кем белә?—әмма, өйдәге егетләрне күрүгә, шундук үзгәрә, ачылып китә, йөзе яктыра. Хатынына ул, шаяртып, еш кына:

—Йә, кадерлем, бу йортта джаз-клуб ябылып, бөркетләребез төрле якларга очып таралышкач, тынычлап яшәрбез әле бер!—дияр иде.

И Бертай әкә, шул джаз музыкасын сагынудан киләчәктә синең кабергә керәчәгеңне ул чакларда кем уйлаган?!..

Бертай әкәнең әлеге шаян сүзләре, уннарча вариантларда кабатланып, йортта шул ук усал телле яшьләр тарафыннан гел сөйләнә торган булып китте. Ул гынамы, хәтта киләчәктә—яшьләр таралып беткәч, өйдә урнашачак тынлык өчен тостлар да әйткәлиләр иде.

Ах, ул чакларда бу бер кайгысыз-уйсыз яшьләр, уен-көлкеле тостларның нинди фаҗигагә китерәчәген белгән булсалар икән!.. Әмма... юк шул, язмышны алдан язып куеп булмый...

Студентлык еллары бик тиз үтеп китте, чыгарылыш кичәсе дә шаулап-гөрләп узды, кичәгә,—алар группасындагы барлык яшьләрне дә диярлек белгәнгәме,—Робертның әти-әниләре дә килгән иде. Ничәмә-ничә еллар Уралын сагынып яшәгән Роберт, диплом алып өч көн үтүгә, Магнитогорскига китеп барды, ниһаять, Почта урамындагы 72 нче йортта сәер тынлык урнашты.

Бервакыт Рушан Робертның әнисеннән хат кисәге алды, һәр җөмлә аралаш диярлек бер үк сүзләр кабатлана иде: әле киткәнегезгә, төрле шәһәрләргә таралышканыгызга берничә ай гына бит, ә без инде сезнең барыгызны да бик сагынабыз...

Техникум тәмамлаганнан соң Рушан тимер юлда, Кызыл Ордага якын гына булган Кара Үзәк станциясендә эшләде. Янә елга аның бер атналык ял көннәре җыелган иде. Ленинград театрының элеккеге костюмеры тегеп биргән смокингын да алып, бәйрәм көннәренә,—юк, Мартукка түгел!—Актүбәгә кайтып китте. Әлбәттә, беренче эше итеп, ул Почта урамындагы 72 нче йортка юл тотты, әмма йортта бәйрәм кәефе юк иде—прокурор Бертай әкә йөрәк өянәге белән хастаханәдә ята икән.

Ой эче искитәрлек булып үзгәргән, элеккечә ялт итеп, һәр җирдә тәртип булса да—бу йорттан тормыш киткән шикелле... Юк, бу—Рушанның үз сүзләре түгел, Робертның әнисе әйтте бу сүзләрне: «Йортыбыздан яшәү яме китте...»—диде.

Соңыннан ачыкланганча, Бертай әкәгә тынлык ярамый икән, ул аны күтәрә алмаган, авыруга сабышкан. Менә сина Армстронг... Бертай әкә эштән кайта икән дә, бер максатсыз бүлмәдән бүлмәгә йөри икән, аннары кухняга хатыны янына кереп, гел бер сорау белән тинтерәтә: хәзер безнең балалар нишләп ята икән? Юк, ул Робертын истә тотып кына әйтми—Юра Лаптев, Петя Мандрица, Ефим Ульман, чечен Ломалиларны да һәм, билгеле инде, Рушанны да истә тота бу очракта.

—Бервакыт,—дип сөйләде Робертның әнисе,—төн уртасында куркынып уянып киттем, колагыма, бөтен кәчәнә кычкыртып, Армстронг трубасы уйный шикелле ишетелде. Чынлап та, шулай икән... Мин йокылыуяулы килеш шатланып, Робертыбыз кайткан икән дә безгә шул музыка белән аваз сала икән, дип уйладым. Әмма ялгышканмын... Йокысызлыктан интеккән Бертай, сагыштан үзенә урын таба алмаганга күрә, бераз гына булса да элекке тормышыбызны хәтерләтсен, дип, уйната икән ул патефон тәлинкәсен... Уйналып беткәч, мин караңгыда иремнең караватына килеп утырдым. Бертай күз яшьләрен яшермичә елый иде...

Аннары Робертның әнисе Бертай әкәнең, төннәрен улы бүлмәсенә кереп, Эллингтон яки Эльвис Пресли белән Джонни Холлидей рок-н-ролларын уйнатып, иртәнгә кадәр коньяк йоткалап утыруына күнеккән. Шундый утыруларының берсендә иренең йөрәгенә бәргән.

Тагын ярты елдан, жәй көне Бертай әкә үлгән. Аның җеназасына кайткан Рушанга Робертның әнисе: «Аның йөрәге сезне сагынуны күтәрә алмады, сезнең бәхәсләрегезне юксынды ул, сез уйнаткан музыкаларны бик яраткан икән...»—дип сөйләде.

Шул кайгылы матәм көнендә алар Роберт белән соңгы тапкыр очраштылар. Соңрак Роберт Мартуктагы бер әйбәт татар гаиләсеннән Клара исемле кызга өйләнде. Әмма Рушан алар белән ни Актүбәдә, ни Мартукта кабат очраша алмады. Соңыннан ишетеп кенә белде: Роберт аерылган икән. Әнисе озакламый, йортын сатып, улы янына Магнитогорскига китеп барган. Шулай итеп, аларны бәйләп торган соңгы җепләр дә бөтенләйгә өзелде...

Кайчакларда кайткалап йөргәндә, Рушан Актүбәнең мөселман зиратына бара, джаз яраткан прокурор Бертай әкә кабере янында басып тора, Почта урамындагы 72 нче йортта үткән бәхетле көннәрен исенә төшерә иде.

Соңгы кайтуында ул үзе өчен көтелмәгән ачыш ясады. Күзе Бертай әкә кабере янәшәсендәге күркәм һәйкәлгә төште—прокурор күршесендә кәрт уены шулеры, законлы карак Шамил Гомәров ята икән. Йа Хода, тәкъдиреңне белеп бетерерлек түгел шул!

Рушанга әле илле тулмаган булса да, кызганыч ки, ул инде бик күп өметләрнең сүнүенә, язмышларның сынуына шаһит иде. Һәм кешеләрнең генә дә түгел. Аның хәтерендә—юкка чыккан шәһәрләр, кварталлар, яраткан биналар һәм вокзаллар... Мартук тирәсендәге казакъ авыллары һәм урыс бистәләре дә әллә кай арада эределәр дә беттеләр. Аларның исемнәре генә дә җанга якын иде: Кызыл күл, Ак хатка, Покровка. Аның балачак елгасы Илек тә харап булып ята. Кая аның искиткеч комлыклары, биек яр өстендәге лалә чәчәге басулары? Шау печәнле болыннардагы чикерткәләре ник сайрамый? Күбәләкләре, энә караклары ник уйнаклап очмый? Кәрәкә балыклы, энже чәчәкле күлләре ник корыды? Күзләрен ул күлләрдә үрдәк атып йөрүче аучылар ник күренми?

Кая карама—югалтулар, нәрсә турында уйлама—һәлакәт... Ул манаралары киселгән мәчетләр, җимерелгән чиркәүләр турында ни-нәрсә сөйләмәк кирәк? Хәзер яңадан иманга кайта башладылар шикелле башлавын: мәчетләр калка, чиркәүләр төзекләндерелә, яна гыйбадәтханәләр ачыла. Әмма болары да бер мавыгу, шаукым гына булып калмасмы? Изгелеккә, иманга күңелендә ихтыяҗ тумаса, ул синең калбең өчен зарури булмаса, монафикъ дөньяви хаҗәтләрең белән генә Аллаһы йортына аяк басма...

## XXXI

«1905 ел» урамында яшәүче кыз укыган мәктәп кичәләрендә Рушан еш була, анда үзеннән бер-ике яшькә өлкәнрәк Жорик Стаин барысыннан да аерылып тора иде. Дасаев беренче барган кичтә үк аны, Исмәгыйль бәкнең туганы, дип, Стаин белән таныштырдылар. Жорик та Татар бистәсендә тора, Исмәгыйль бәк исеме аның өчен буш аваз гына түгел, үзенең дә ана мөрәҗәгать иткәләгәне бар иде. Шунлыктандыр, бик якын дуслар булып китмәсәләр дә, Рушан белән мөнәсәбәтләре тиз урнашты һәм һәрвакыт әйбәт булды. Әмма кечкенә шәһәрдә аларның юллары еш кына кисешә дә иде...

И, ул ерак шәһәрчектә үткән яшьлек елларында Жорик Стаин иң атаклы шәхесләрдән санала иде. Аның мажаралары турында әллә ничаклы хикмәти риваятьләр сөйлиләр, ә күпсанлы жан дуслары, аның жирле философ данын күпертеп, ул әйткән-сөйләгән сүзләрне һәр жирдә китереп кыстыралар. Хәзер ничек кенә көлке тоелмасын, яшьләр арасында үз-үзенне тоту рәвешендә «а ля Стаин» дигән нәмәрсә таралган иде. Стаинның шау-шу кузгаткан һәр адымын яшь-жилкенчәк шәһәрчектәге эчпошыргыч күнелсез тормышка үзләренең дә протесты итеп карый, яшьләр генәме сон, бервакыт Жорик Стаин бөтен шәһәрне үзе турында сөйләргә мәжбүр итте.

Күпләрнең, шул исәптән, Жорикның үзенең дә гажәпләнүенә карамастан, институтка ул беренче талпынышыннан ук кереп китә алмады—күрәсең, үз-үзенә артык ышанып масаюымы йә булмаса, имтиханда киртәгә сыймаслык берәр кыланышымы комачаулагандыр, әмма бу кешеләр өчен гомерлек сер булып калды, ул әти-әниләренә дә ни өчен имтихан бирә алмаганын аңлатып торырга теләмәде. Ә мәктәптә Стаин менә дигән итеп укыган иде, аның хәтере искиткеч яхшы иде.

Жорик Стаин атаклы модельер булырга хыяллана, мөгаен, хыялына ирешкән дә булыр иде—зәвык дигәненнән Ходай аны мәхрүм итмәгән, тегү машинасында да кызлар көнләшерлек итеп тегә, әмма анысы турында бик сөйләнеп йөрергә яратмый: көяз-фырт киенгән Стаин—бер хәл, ә тегүче Стаин—бөтенләй икенче. Һәрхәлдә, ул вакытта бу ике төшенчәнең буталуы-кушылуын Жорик теләми, ә фырт-көяз исеме белән ул бик горурлана, аны тырышып саклый иде. Шулай бервакыт мәктәп кичәсендә ул, бер гүзәлкәйнең үзенә сокланып карап: «Бу Жорик матур да киенә инде!»—дигән сүзләренә каршы бер сыйныфташ егетнең саксызлык белән: «Тегүче дә киенмәгәч...»—дигән сүзләрен ишетеп, тегене кыйнап ташлаган иде.

Әле мәктәпне тәмамлаганчы, тугызынчы сыйныфтан ук, күпләр Стаинның тормыш программасын белә иде инде: башта барып укырга, ә соңрак, ирләр киемнәре модельеры булып, үзе яулап алырга жыенган Ленинград аның теленнән төшми иде. Ул жәйге каникулларын да ике мәртәбә Питерда үткәреп кайткан иде. Һәм кинәт кенә—бөтен хыяллары, планнары жимерелсен әле! Аның—үзенчә мәшһүр һәм үз-үзенә чамадан тыш ышанган кешенең! Үзе гашыйк булган Төньяк башкаласында калырга да була иде ана—зур заводлар берсеннән-берсе уздырып эшкә чакырып торалар. Ләкин андый хезмәт юлы Стаин өчен түгел иде шул, ул бу хакта уйлый да алмый, шунлыктан әле бер ай элек кенә, ничек тизрәк ычкынырга, дигән шәһәренә кире әйләнеп кайтты.

Шунда ук һәр жирдә: «Стаин кайткан! Стаин кайткан! Жорик кайтты!» дигән сүзләр таралды. Бу хәбәр бигрәк тә кызларны куандырды.

Рушан шул кичтә үк Стаинны үзәк урамда очратты, ул урамны шул ук Жорикның жинел кулыннан «Бродвей» дип йөртә башлаганнар иде, шуннан бирле яшьләр телендә ул—«Бродвей». «Бродвей»да күптәннән үзенең көязлеге белән аерылып торган Жорик ул көнне барлык пижон вә стилягаларның һушларын алырлык итеп киенгән иде: тар балаклы аксыл-сары чалбар, вак шакмаклы көрән-сары твид пинжәк, ул бер

капламлы һәм киң җилкәле, тар кайтарма якалы һәм бер генә төймәгә каптырылган, калын ак каучук табанлы, бер кырына ялтыр тимер аел куелган туфлиләр... Бу купшы көязлекне карангы-куе чия төсендәге күлмәк һәм пальма янындагы маймыл алдында акшарланган-бизәнгән, сары чәчле ярым ялангач кыз рәсеме төшерелгән алтынсу-сары галстук тулыландырып тора иде.

Әйтергә кирәк, озын буйлы, килешле гәүдәле, шунын өстенә бик тә пөхтә һәм кигән киемнәрен иркен-иреклә йөртә белә торган Стаин өстендә бер әйбер дә карикатурачылар ясарга тырышканча ямьсез-гарип булып күренми иде. Ә бит Жорик ул заманнарда бик популяр булган һәртөрле сатирик листокларнын даими яраткан мишене дә иде. Шәһәрнең чит буржуаз модаларга каршы галәмәт зур көрәше дә Стаин булганга күрә генә шундый югарылыкта тора иде. Рушан, ничә еллар үтсә дә, әле хәзер дә шәһәр паркының үзәк аллеясындагы төсле буяулы «Сатира тәрәзәләре»н күз алдына китерә. Шуларның берсенә җирле рәссам Жорикны коточкыч ямьсез акшарланган кызый белән зур патефон тәлинкәсе өстендә рок-н-ролл бии итеп сурәтләгән. Астына җитмәсә хурлап шигырь дә чәпәгәннәр:

Жора, Фифа ял иткәндә
Әй бииләр буги-вуги!
Кигәннәре бик килбәтсез—
Буржуаз мода кием бугай.

Жорик парктан ерак булмаган Татар бистәсендә яши иде, шунда ук—гомер-гомердән шәһәрнең башкисәр ышпаналары, алар үзләренең начар гадәтләрен буыннан-буынга мирас итеп тапшыра торалар, шунда ук Рушанга хәзер туган тиешле абыйлы-энеле Гомәровлар—Шамил белән Исмәгыйль бәк гомер сөрә. Бистәнең өлкәннәре: итчеләр, тиречеләр, казылык пешерүчеләр, сабын кайнатучылар һәм башкалар—һәммәсе дә шәһәрнең иң зур предприятиесе булган ит комбинатында эшли, аның директоры Маркел Осипович Стаин иде. Комбинатта эшләү дәрәҗәле санала, ә өлкән Стаинны хөрмәт итә иделәр. Шуңа күрә горур Татар бистәсенең бер сугуда үгез үтердәй ир-атлары да Жорка белән беренче булып исәнләшә, кечкенә Стаинны җәберләмәскә, аны якларга, аның белән дус булырга өйрәтеп, үз малайларының колакларын бора иде. Жорка үзе дә, әгәр дә табигате шундый булмаса, ваемсызлыгы белән юмарт һәм бистәдә шунын өчен аны яраталар, кесәсендә һәрвакыт акчасы бетеп тормый, аны кызганып тотмый, белгәннәрен дә кызганмый—сыйныфта кем сораса, шуңа күчерергә дәфтәрләрен дә бирә, син белмәгәндә, арттан пышылдап әйтеп тә утыра иде. Ә инде үсә төшеп, «Спартак» командасында футбол уйный башлагач, тиз арада иң яхшы уенчы, иң күп туп кертүче дә булып танылгач, Татар бистәсенең олысы-кечесе аңа табына башлады, аның даны тагын да артты.

Стаинның бер кырын карап алуы җитте, шул кичне үк парктагы теге шигырьле карикатура юкка чыкты. Ләкин Жорка үзенең шәһәрдә шундый гаугалар белән танылуына көлебрәк кенә карый иде шикелле, шуңадырмы, парк администрациясенең чираттагы шедеврын ут төртеп яндырырга тәкъдим иткән башкисәрләрне тыеп калды:

—Ә нигә?—диде ул ялкау гына.—Торсын эленеп. Кызганыч, кызы гына минем зәвыкта түгел, ә болай ярыйсы. Һәркемгә яшәргә кирәк бит: миңа—рок-н-ролл биергә, комсомолга—Көнбатышның чит һәм черек йогынтысыннан коләргә. Французларча әйтсәк—се ля ви яки тагын да гадирәк: һәркемгә үз өлеше. Бу—тормыш диалектикасы...—шуннан соң ул, үзенә табынучыларның югалыбрак та һәм сокланулы да карашлары астында ваемсыз гына атлап, бию мәйданчыгына таба китеп барды...

Ленинградтан борылып кайткач, сентябрь башларында Стаин дусларын һәм сыйныфташларын шул ук паркның җәйге ресторанына чакырды. Кече Стаинга ярарга тырышып, чабыша-чабыша, официант кызлар аяктан калдылар, әле җитмәсә, залның аргы башында үзенең фикердәшләре белән өлкән Стаин да кәеф-сафа корып утыра иде.

Мәҗлес Дасаевнын исендә калды. Кунакларнын һәммәсе дә көтелмәгән хәл килеп чыкканын, Жорканын Ленинградта яшәү хыялы чәлпәрәмә килгәнен аңласалар да, Стаин үзе бер дә алай борчылган яки югалып калган шикелле күренми иде.

Беренче тостны Жорик янында утырган дуслары хөрмәтенә күтәрде, Жирле мединститутка укырга кергән кайберәүләрне котлады, көлемсе-рәбрәк кенә, булачак табиблар анын сәламәтлеге турында кайгыртырлар, ул-бу була калса, харап итмәсләр, дигән өметтә калганлыгын әйтте—кыскасы, һәммәсе дә бик күнелле һәм шаяру катыш иде. Мәҗлес азагына якынлашып килгәндә, әле берсенен дә китәргә теләге юк, чөнки күпләрнен, менә шушылай зурларча итеп, шәһәрнен ин яхшы ресторанында утырганы, аларнын һәр теләген шунда ук үтәргә атлыгып торган официант кызларны күргәне юк иде әле. Күп эчсә дә, исермәгән Стаин кинәт кенә ярып салды:

—Беләсезме, минем тагын бер тостым бар, дуслар! Мин каттый рәвештә карар кылдым: дөнья ыгы-зыгыларыннан ваз кичеп, духовная семинариягә укырга керергә уйлыйм... Ләкин ана чаклы әле бер ел бар һәм мин шул вакыт эчендә тормыштан бөтенесен дә алып калырга телим... Бөтенесен дә! Әйдәгез, типтереп күнел ачу һәм кызларнын елмаюлары өчен күтәрик әле!—диде.

Өстәл тирәсендә гаҗәп шау-шу күтәрелде! Һәммәсе дә, берсен-берсе бүлдерә-бүлдерә, Жорикка шаяртып кинәшләр бирергә тотынды: үзенне тегеләй ит тә болай ит, догаларынны яхшы ятла һәм башкалар, һәм башкалар... Көтмәгәндә генә дин турында кызып киткән бу кайнар бәхәс ни-нәрсә белән беткән булыр иде икән—билгесез, әмма кемдер кинәт шаркылдап көлеп әйтә куйды:

—Сон сез Жорикны руханиларнын озын җинле җиләнен—рясасын кигән итеп күз алдыгызга китерә аласызмы?

Башкалар да көлешә башладылар, чынлап та, священниктыр-поптыр килеш-килбәте Стаинга һич ябыша торган түгел шикелле иде. Шуна күрә барысы да Жорикнын бу хәбәрен дуамаллыкларга хирыс шаталак күнеленен чираттагы юләрлеге дип кенә кабул иттеләр.

Стаиннын Ленинградтан кайтуы хөрмәтенә ясалган мәҗлескә җыелган кунаклар анын киләсе көздә духовная семинариягә укырга керергә җыенуы турында, һичшиксез, шунда ук оныттылар да. Әле таралышканчы ук оныттылар, аны үткен һәм кызык бер шаярту дип уйладылар. Ләкин бер атнадан шәһәрдә төрле имеш-мимеш хәбәрләр таралды: гаепләп тә, сокланып та, хуплап та, хурлап та сөйләнделәр Стаин турында. Кыскасы, гаугасы җитәрлек булды...

Әле язын ук, Стаиннын Ленинградтан хурлыклы кайтуына ярты ел кала, алар шәһәренә, төгәлрәге, чиркәү мәхәлләсенә кинәт кенә үлеп киткән поп урынына яна священник билгеләнгән иде. Дөресен генә әйткәндә, ни ул чиркәү, ни Татар бистәсендәге мәчетнен шәһәр тормышында бер әһәмиятләре дә юк, алар тын гына, сиздермичә генә көн күрәләр, аларны бары тик дини бәйрәмнәрдә кайберәүләр генә искә ала иде. Анда да гыйбадәтханәләргә карт-коры гына җыелыр иде...

Ни чиркәү, ни мәчет үзенчәлекле архитектур бизәлешләре белән дә аерылып тормый, тарихи кыйммәтләре юк, шунын белән булса да үзләренә игътибарны җәлеп итә алмыйлар. Икесе дә бер үк вакытта диярлек, гасыр башында ук калкып чыккан бу биналарны бары тик нык һәм ышанычлы булганнары өчен генә мактарга мөмкин иде, ә урыс чиркәвенен төп мактанычы бакча-парк архитектурасынын бар кагыйдә-ләренә туры китереп тирә-ягына утыртылган зур гына бакча паркы иде.

Элекке атакай күбрәк бикләнеп яшәде, аны шәһәрдә кем дә булса күрүче-белүче булдымы икән, сирәк-мирәк карт-корылар булса гына инде. Шәһәр ыгы-зыгысыннан ул таза таш койма белән аерылган, авыр челтәрле чуен капкасы елга бер-ике мәртәбә генә кунакчыл ачыла, ә башка көннәрдә чиркәүгә биек коймага уеп ясалган имән ишек аша гына йөриләр, ишек артында һәрвакыт төксе кыяфәтле тәбәнәк кенә бөкре карт тора. Элекке

священникны махсус бакчачы һәм мәхәллә халкы карап-тәрбияләп торган бакча паркы да шатландырмый, ул аның кызгылт ком сибелгән күләгәле аллеяларында хәтта озын, матур җәйге кичләрдә дә бик сирәк йөри. Изге атакай яшереп кенә эчә, шунлыктан кешеләр белән артык аралашмый, дип сөйлиләр иде. Атакайның шундый булдыксызлыгы болай да аз санлы мәхәллә халкын ишәйтми, чиркәү көннән-көн үлеп-бетеп бара иде.

Һәм менә яңа священник килде. Ул яшь, мөгаен, аңа утызлар тирәседер, шуннан артык булмас. Әлбәттә инде, руханиларны күрәк кадәр чал сакаллы, балавызлар тамып, катып-пычранып беткән, итәкләре үкчәсенә кадәр төшкән сутана кигән һәм һәрвакыт калтырап торган кәҗә тавышлы хәлсез картлар итеп күз алдына китерергә күнеккән халык өчен бу яшь атакай сәеррәк тоелгандыр. Ул озын буйлы, спортчыларча төз гәүдәле, берәр кинофильмда священник ролен башкаручы артист кыяфәтле иде. Куе кара сакалы аңа зыялы төс бирә, эчтән һәрвакыт тел-теш тигезмәслек чиста ак күлмәге күренеп торган утыртма якалы кара муар сутанасы-җиләне дә кичке фракны хәтерләтә. Бу тәэсирне бик модалы тар балаклы буй-буй чалбары белән елык-елык килеп торган озын кунычлы кара туфлиләре тагын да көчәйтә иде.

Кайбер көннәрдә яшь атакай яланбаш йөри, аның бераз гына чал керә башлаган куе чәчләрен хәтта шәһәргә көнчыгыштан, кайнар казакъ далаларыннан килеп кергән җил дә туздыра алмый. Әмма ешрак ул киң кырлы йомшак кара эшләпә кия, эшләпә аның, тазалыгы күренеп торса да, ак чыраена бик килешә. Йөзенең аклыгы, бәлки, шуңа да күзгә ташланадыр әле, аның кызларча озын керфекләр белән каймаланып алынган зур күзләре ниндидер эчке ут белән янып тора һәм ирексездән игътибарны үзенә тарта иде. Бу төс-кыяфәтне, килеш-килбәтне атакайның кулында һәрвакыт була торган, бик матур бөгелгән озын муенлы көмеш ат башлы тоткалы, сирәк очрый торган күп ботаклы агачтан эшләнгән таягы тагын да тулыландырып тора. Кайчандыр ниндидер байныкы булганлыгы шиксез, бик оста зәвык белән ясалган ул таяк та рухани кешегә ятышмый шикелле үзе.

Кыяфәт кыяфәт белән, әмма яңа атакайның тормыш тәртибе дә үзенең элгәреннән бик нык аерылып тора иде. Ялтырап торган кара лакка яңа буялган чуен челтәр капка якшәмбе көннәрендә киереп ачып куела, иртәнге тынлыкта борынгы чаң авазы яңгырый: дан-доң, дан-доң!.. Дөрес, бик үк төзек булмаган бакыр чыны әллә ни еракка китә алмый, чөнки карап тәртиптә тотыла торган бакчаның агачлары илле елдан артык вакыт эчендә мәһабәт үсеп, аларның ябалдашлары күптән инде иң биек чиркәү манарасын да узып киткән, шунлыктан чаң авазы, тумас борын шул ябалдашларга егылып төшә дә, шунда бакча эчендә үк тына, мәхәллә халкына барып ирешә алмый кала.

Шимбә-якшәмбеләрдә атакай көне буе үзенең биләмәләрендә була, ә менә башка көннәрдә... Нәкъ иртәнге сәгать унда бөкре карт түбәнчелек белән имән янкапканы ача, атакай ашыкмый гына, дәрәҗәсен белеп кенә атлап чыга да шәһәр бакчасы ягына юл тота, ярты сәгатьтән ул инде «Бродвей»да була, үзәккә юлны кыскартып, кешесезрәк, таррак-тынычрак урамнан барып булса да, ул һәрвакыт медицина институты яныннан үтеп йөри.

Баштарак руханиның урамнарда йөрүен кызыксынып күзәтәләр иде. Атакай, адымнарын бутамыйча, ашыкмый гына тигез атлап, як-ягына карамастан, үз уйларына чумган төсле итеп, аны дәшми-тынмый кызыксынып күзәтүче шәһәр халкы яныннан узып китә. Әмма аны баштарак кына шулай каршы алалар иде—тиздән аның бу иртәнге йөрүләренә күнектеләр һәм аңа игътибар итми башладылар.

Бәлки, ул укыган семинария яки духовная академиядә актер осталыгы шикеллерәк фән дә укытыладыр, иллә дә мәгәр ул үзен теләсә нинди артисттан да остарак тота иде. Аңа беренче гаҗәпләнүләр вакыты узды, үтеп-сүтеп йөрүчеләр ялгыш бәрелеп киткәндә дә һәрчак түбәнчелек белән гафу үтенми башладылар, әмма тыштан атакай боларга берничек тә әһәмият

итми иде. Аны тирән уйларыннан бернәрсә дә аерып ала алмас шикелле, бары тик бик игътибарлы кеше генә кайчакларда аның авыр таягын кысып торган көчле кул бармакларының агарынганын күрә алыр иде. Ул үзәк урам буйлап эреле-ваклы кибетләр, киосклар яныннан уза, бер вакытта да аларның берсенә дә кереп чыкмый, ни киосклардан, ни лотоклардан бер нәрсә дә сатып алмый, Орджоникидзе урамына житкәч, һәрвакыт сулга, базар ягына борыла.

Татар бистәсенә илтә торган урам буйлап күтәрелгәндә, базарга якынрак тыкрык чатларында хәерчеләр очрый башлый, атакай аларның һәркайсына—носарымы ул, мөселманмы икәненә карамыйча, сүзсез генә көмеш тиен суза һәм адымнарын әкренәйтми генә юлын дәвам итә. Базарда ул шулай ук сүзсез-нисез, бернәрсә дә сорашмыйча, бәяләрен белешмичә һәм сатып алмыйча, рәтләрне карап йөри, хәтта суелган кош-корт ите һәм сөт азыклары сатыла торган ябык бинага да кереп чыга, әйтерсең лә, санитар табибы, тик кулында бер әйбере дә юк. Базарның бөтен почмакларын йөреп чыккач, шәһәр эчкечеләре жыелып тора торган чәйханә янында гына адымнарын әкеренәйтә төшеп, ул китеп бара. Атакайны күргә, исерекбашлар жәлт кенә чәйханә эченә шылалар, хәтта ишекне үк ябып куялар, юкса ул анда кереп торырга һич ниятләми инде.

Мөгаен, бу яңа рухани, һәрбер яшь кеше шикелле, зур планнар корадыр, ә бәлки, хәтта масаючан, дан сөючәндер, шуңа күрә, бөек казакъ далаларыннан жил себереп китергән комга әкрен генә күмелеп баручы шәһәрчекне тулаем үз мәхәлләсе итеп саныйдыр, якшәмбе көннәрендә дә чиркәүгә йөрүчеләрнең бар булганы бакча эчендә югалып бетәрлек кенә булганга пошынадыр. Шулай көн саен ул ышанычлы адымнар белән шәһәрне әйләнеп чыга, әйтерсең, шәһәр аның чиркәү биләмәләре, әйтерсең, ул үзенең чиркәвенә гыйбадәткә йөриячәк мәхәллә халкын күзәтә һәм аларны өйрәнә.

Шунысы сәер, еш кына иртәнге шул йөрүләрендә атакайга гел бер урында жирле драматик театрның баш режиссеры очрый, менә ул инде үзенең тамашачылары саны ягыннан чиркәү белән ярыша алыр иде.

Дөрес, кыйшаеп-тапталып беткән ботинкалы, майланып каткан чалбарлы, тормышта инде шактый кыйналган һәм еш кына иртәннән үк салмыш бу режиссер—Мельпомена хезмәтчесе тышкы кыяфәте белән һич тә үзендә көч һәм ышаныч ташып торган атакайга тиңләшә алмас иде. Ләкин очрашкан минутларында икесе бөтенләй ике төрле бу кешеләрнең башларына: «Бу минем шәһәрем, мин аны яулап алачакмын! Вакыт кына бирегез! Сез әле, рухи чистарыну тоеп, рәхмәтле күз яшьләрегезне коячаксыз!»—дигән бер үк уй кермидер дип әйтеп булмас иде. Һәм, бәлки, һәркайсысы үзенең алтарен, театрга да, чиркәүгә дә битараф шәһәрнең икесе ике башында торган изге йортларының киерелеп ачылган ишекләрен, шыгырым тулы залларын күрәдер.

Шулай йөргән вакытларында изге атакай бер мәртәбә дә туктап, беркем белән дә сөйләшмәс, бары тик хәер бирер дә, бик сирәкләрне генә чукындырып китәр иде.

Ул арзанлы үгет-нәсихәтләр укымый, чиркәүгә йөрергә өндәми, әмма аның үз-үзен тотышы, бар кыяфәте әйтеп тора шикелле: «Мин сезнең рухи атагыз, мин килдем, мин сезнең ничек яшәгәнегезне, ни-нәрсәләр өчен шатланганыгызны, сезнең өчен бәхет ни-нәрсә икәнен күзәтәчәкмен...»

Үзенең вәгазьләрендә дә ул чиркәүгә юлны онытучыларны шелтәләми, үзегез белән күршегезне дә ияртә килегез, дип үгетләми, ләкин аның нотыкларында нindидер хикмәт бар, күрәсең, юкса карт-карчыклар гыйбадәт кылырга ишелеп-ишелеп йөри башламаслар иде, ә атакайның яшь тә, чибәр дә икәнлеге турындагы хәбәр еракларга таралгач, якшәмбе көннәрендә якын-тирә авыллардан да шәһәр чиркәвенә халык агыла башлады...

Изге атакайның иртәнге якларда ялгызы гына йөрүләренә күнеккән шәһәр халкы, аның көннәрдән бер көнне урамда Стаин белән йөргәнен күреп, шаккатты. Әйе, әйе, Жорик белән! Шаккатарсың да, кодагый! Алар

атакайның гадәтләнгән юлы белән базарга барды, анда бераз озаграк торып, һәрвакыттагыча, медицина институты янынннан әйләнеп кайтты. Алар, очраган кешеләрнең гаҗәпләнеп карап калуларына да игътибар итмичә, күптәнге дуслар шикелле, нәрсәдер турында бик җанлы сөйләшеп кайта иде. Алар авызларын ачып катып калган халык төркеме аша уздылар. Хәтта үсмер малайлар да ерактан үртәп: «Поп, поп—акылың юк»,—дип кычкырып калмады. Шәһәр Жорик Стаинның кем икәнен яхшы белә, шуңа күрә берәүнең дә аның белән бәйләнешәсе килми иде.

Әгәр дә жирле театрның баш режиссерын үз актерлары һәм шәһәр комитеты мәдәният бүлегеннән башка күреп танучы булмаса, Никанор атакайның кем икәнен әйтеп торуның хаҗәте юк иде инде—шәһәргә бик тә үзенчәлекле яна рухани килгәнлеген һәркем ишетеп белә иде.

Никанор атакайның хәзер һәр көнне Жорик Стаин белән йөрергә чыгуы ана карата булган кызыксынуны янадан уятып җибәрде. Илленче еллар азагы иде, чынлап та, йокымсырап яткан бу шәһәр кисәгендә мөһим вакыйгалар сирәк була, шунлыктан шәһәргә яна рухани килү буш кызыксыну булса да тудырмый калмады. Бер үк вакытта бер үк юлдан һәркөнне иртән шулай йөрүләре, аларның башка яшьләрдән нык аерылып торулары, әлбәттә, игътибарны тарта иде. Стаин белән Никанор атакайны һәр иртәдә очраткан режиссер ирексездән тәкәллефле генә итеп исәнләшеп уза, мөгаен, артларыннан карап калганда, пошынып уйлыйлар: «Их, аларны безнең театрга тартасы иде, халык агылып кына торыр иде...»

Жорик Никанор атакай янында бер дә аңардан ким күренми, аңа хәтта руханидан артык аерылып тормас өчен дә бик көчәнергә туры килмәде, чуар галстук урынына ак күлмәк астыннан муенына кара яулык кына салды, тәти егетлегенең бердәнбер билгесе булып ак оекбашлары белән ялтыр кара мокасин туфлиләре генә калды. Бер-ике атна чәчтарашка бармый торган иде, Жорикның дулкын-дулкын куе чәчләре җилкәсенә төшеп тә житте, ул яшь семинаристларга искиткеч охшый башлады.

Икәү шулай йөргәндә, Стаинның бөтен үзен тотышы-кыяфәте үзгәрә: ул атакайны бик игътибар белән тынлый, буйсынучан, итагатьле, юаш, басынкы, сабыр... Әмма кичкә аның бөтен тышкы кыяфәте сәер рәвештә янадан элекке Жорикка әверелә дә куя, көзге алдында берничә минут бөтерелеп, тегеләй-болай итсә, басынкы семинаристан җилләр исә—үз-үзеннән бик канәгать, чибәр-ягымлы йөзен бозып һәрвакыт елмаю кунган пижон, стиляга егет була да кала иде ул. Режиссер аңа юкка гына игътибар белән карамыйдыр шул—Стаинда, мөгаен, гаҗәп талантлы актер үлгәндер.

Жорик Стаин үскәндә үк үсмерләргә хас килбәтсез-килешсезлекләрсез, ябыкмыйча-суырылмыйча, битен бетчәләр басмыйча үсә торган егетләрдән булды. Унҗиде яшендә ул инде коеп куйган килешле гәүдәле чибәр егет иде, аның ничә яшьтә икәнен дә әйтеп бирерлек түгел, ә ул чорда әле ничек тә өлкәнрәк буласы килә һәм Жорик шулай күренергә бик тырыша иде.

Ул сыйныфташларыннан беренче булып кинога кичке сеанска керде, беренче булып кырына башлады, беренче булып, койма тишегеннән түгел, ә билет алып, парктагы бию мәйданчыгына йөри башлады. Кыскасы, ул һәр нәрсәдә беренче иде, юкса өлкәнәя төшкәч, анлыйсың—бию мәйданчыгына яз йөри башладың ни дә, көз ни, кинога соңгы сеанска үҗәтләнеп майда ук бардың ни дә, июльдә ни—барыбер бит, ә менә егет булып килгәндә барыбер түгел шул, беренче адым иң әһәмиятлесе, дәрәҗәлесе шикелле тоела.

Ана, кемнәрнедер кара яндырып көнләштереп, һәрчак беренче булу ошый иде. Әлбәттә, ул яшьтәшләреннән иртәрәк тарта башлады: өлкән Стаинның өйдәге «Казбек» капларын санап бетерешле түгел, берсен алсаң, кем дә сизми. Мөгаен, әчүен дә беренче булып башлагандыр, тәгаен раславы кыен-кыенын, әмма анда да аның башкалар белән чагыштырганда үз өстенлекләре бар иде.

Элек икътисады бөтенләй бетәшмәсен өчен һәр өлкәгә үз аракы заводы

булдырырга рөхсәт ителә иде. Аракы эшләп чыгару катлаулы нәрсә түгел, бик гади генә, шуна күрә ул заводлар һәркайда гөмбәләрдәй калкып чыкты. Жорик беренче сыйныфка укырга кергәндә, алар шәһәрендә дә шундый завод пәйда булды, жирле сыра заводы житәкчесе булган әнисен аракы заводы директоры итеп күтәрделәр. Стаиннарнын подвалында аракынын бетәсе юк иде һәм ул кибеттәге ише генә дә түгел, әнисе еш һәм даими кунакларына мактанганча, чистартылганы иде.

Өйләрендә исәп-хисапсыз булган аракы өлкәннәр тормышына тизрәк керергә ашкынган Жорик өчен иң көчле пропуск иде: паркта болганып йөргән башка яшүсмерләргә беркем дә игътибар итми, аларны беркайда чакырмый торган бер заманда Жорикка һәркайда ачык йөз иде.

Егетләр өчен, биюләр башланганчы, кафенын җәйге верандасында сыра эчеп яки берәр стакан шәраб салып утыру бер дәрәҗә санала һәм ул егетләр Жорикны еш кына сыра белән сыйлыйлар, чөнки анын жавапсыз калмаячагын беләләр иде. Сонга табарак ул үзе дә, паркка килгәндә, газетка төреп, бер-ике шешә аракы белән бер түгәрәк ысланган казылык кыстырып килә башлады, килә дә Татар бистәсенең житкән егетләре арасына кыю гына кереп тә утыра иде. Мондый күрелмәгән дорфалыкны хәтта, шешә кыстырып килеп тә, һәркем булдыра алмас, тәвәккәллеге житмәс иде, әмма Жорик Стаин аерым бер шәхес иде шул. Татар бистәсенен иң башкисәр атаманы—күкрәгенә тушь белән канатларын җәйгән бөркет татуировкасы ясалган Исмәгыйль бәкнең кайвакыт биюләрдән соң: «Жорик, коткар, бер шешә тап!»—дип үтенүе анын күнеленә бик хуш килә. Жорик, әлбәттә, коткара, чөнки горур Исмәгыйль нәрсәне булса да сирәк үтенә, ә анын сүзе һәм абруе кире каккысыз иде...

Бик күп кешеләрнен ял итүе, күнел ачуы гел генә шәраб һәм аракы белән буталып бетүенә Рушан бик гажәпләнә иде, әле бит шул ук вакытта әллә ниләр кыланалар, башсыз бер кыюлык белән, купшы-фырт итеп эчә белү дәрәҗә санала. Бервакыт Жорик паркка өч шешә аракы алып килгән, мөлдерәмә тутырылган стакандагы аракыны кем дә кем кулы белән стаканга кагылмыйча, тамчысын да түкмичә төбенә кадәр эчеп бетерә, шуна—бер шешә, ди икән. Һәм үзе шунда ук мисалга эчеп тә күрсәткән, тамчысын да түкмәгән. Аннары стакан төбен үпкәч, пакеттан тозлы кыяр алып чәйнәп куйган—монын барысын да ул ашыкмый гына, елмаеп эшләгән. Кыскасы, Стаин югары класс күрсәткән.

Тончыкса да, бушка эчәргә теләүчеләр, әлбәттә, табылган. Әгәр дә башкаларны ничек тә мыскыл итмәсә, Жорик Жорик буламы соң?! Ул бер дә шунда ук аракы салып бирергә ашыкмаган, ә су кранына күрсәтеп, башта су эчеп күнегүләр ясарга кушкан. Газлы су сата торган киоскыдан стаканнар алып әй тотынганнар барысы да, түгә-түгә, тончыга-тончыга, Стаин алдында осталыкларын күрсәтергә! Ә Жорик шаркылдап көлә-көлә, мыскыллап, булдыра алмаганнарны сүз белән чыбыркылап утыра икән.

Ул кичтә берәү дә бушка аракы эчә алмаган—үз егетләре белән Исмәгыйль бәк килеп чыккан да: «Аракы белән кәмит ясап утырма, әйдә, башка эшең булмаса, безнең янда утырырсың...»—дип, Жорикны шешәләрене белән ияртеп алып киткән.

## XXXII

Көн саен бер үк вакытта Стаин Никанор атакай белән сөйләшеп йөрүләрен дәвам иттерә. Рухани—тирән гыйлемле, күп укыган кеше, Стаинга семинариядә һәм духовная академиядә укыган еллары, философия, теософия буенча сирәк очрый торган китаплары булган китапханәләр турында сөйли, Киевтагы тормыштан алган тәэсир-ләре белән уртаклаша.

Бу яшь егетнен үзен шулай бирелеп тыңлавы Никанор атакайда ышаныч тудыра, бу Ходай каргаган Алласыз мәхәлләдә үзенә уң килде дип саный.

Семинариядәге рухи остазларын шушы бик сәләтле егетне чиркәү канаты астына алуларын үтенеп язган үзенең хатын тегеләр куана-куана укыйлар итеп күз алдына китерә. Яшь рухани Никанор аңлый: яхшы гаиләдә үскән, шәһәрдә бер дигән егетнең, дөньяви вәсвәсәләрне жинел генә ташлап, дин юлыннан китүе синодта иң өметсезләр рәтеннән саналган үз мәхәлләсе өчен унай нәтиҗәләр бирүе мөмкин—килеп беренче ел эшләвендә үк семинариягә үзе әзерләгән шундый егетне җибәрүе остазларының өметләрен аклавын искәртергә тиеш.

Жорик атакайның нотыкларын тыңлавын тынлый, ләкин, шулай булса да, һәр кичне шәһәр бакчасына биюләргә йөри, үзен тотышында һәм тышкы кыяфәтендә дә үзгәреш күренми шикелле, бары тик изүләре ачык кызыл күлмәге астыннан күкрәгендә бик сирәк очрый торган авыр алтын тәре артты, ул тәре кызыл рубин эмаль белән аркылы-торкылы ырмаулап та алынган әле—Никанор атакайның юмарт бүләге иде бу. Жорик кызып китеп, аерым бер дәрт белән рок-н-ролл биегәндә тәре һәркемнең күзенә ташлана иде.

Бер атнадан чиркәүдә дистәләрчә еллар тузан жыеп яткан арзанлы бакыр тәречекләрне кырып-себереп алып бетерделәр, бию мәйданчыгына жыела торган яшьләрнең яртысы аларны күрсәтеп куеп, көязләнеп йөри башлады. Кайберәүләр бронзадан яки жиздән кисеп, бизәкле һәм авыр тәреләр дә ясарга өйрәнде. Күп еллар үткәч тә әле, яшьләрнең муенында асылынып торган тәречекләрен күргәндә, Рушан, беркатлыланып, бу шаукым Жориктан чыкты, дип уйлый иде.

Шәһәр комсомол комитетында, билгеле инде, көтмәгәндә килеп туган бу дини тайпылышлы хәлгә җавап бирүне кирәк таптылар һәм шәһәр бакчасында янадан Стаинга карикатуралар пәйда булды: берсендә ул сутана-жилән кигән килеш буги-вуги бии, икенчесендә Никанор атакай белән тәүфыйклы гына сөйләшеп йөри. Карикатураларның астына кыска гына, әмма киная белән язылган иде: «Карагруһчылыкка юл» һәм «Бу юл түгел».

Никанор атакай шәһәр хакимиятенә барып, үзенең шәхесен хәкарәтләү, мәсхәрә итүләре турында зарланды, шуннан соң аңа бүтән кагылмадылар. Ә Жорик мыегын да селкетмәде, карикатуралар янына дуслары белән килеп, рәссамнарның эшләренә көлешә-көлешә бәя биреп кенә узды. Дөрес, «Карагруһчылыкка юл» дигәнендә аны артык кыска аяклы итеп ясаганнарына тузынган булды, ул рәсем гадәттәгедән азрак эленеп торды.

«Бу юл түгел» дигәнендә Стаин бик мәһабәт итеп сурәтләнгән, әйтерсең, рәссам алдында үзе басып торган, диярсең—киеменең һәр өлеше бик жентекләп ясалган. Дуслары Жориктан: «Рәссамга бер-ике шешә аракы куймагансыңдыр бит? Бигрәк тырышкан»,—дип сорыйлар. Әмма ул аларның сүзләрен расламый да, кире дә какмый, бары тик серле итеп елмая гына, шуның белән үз шәхесен тагын да томанга төрә төшә. Шунысын да әйтергә кирәк, бу рәсем шәһәр бакчасында тиешле вакытын эленеп торгач, юкка чыкты һәм тиздән кыйммәтле рам эчендә Жорикның бүлмәсендә пәйда булды, ә соңрак Стаин аны Дасаевның бер курсташ кызына туган көнендә бүләк итте.

Стаинны комсомол шәһәр комитетына да чакырып карадылар, ул ялындырмады, бер дәшүдә үк барып житте. Инде шул чагында ук конституцион ирекләр һәм гарантлар турында сөйләшкәндә демагоглыкта шомарып-каешланып беткән, шуның өстенә, житмәсә, идеологик бәхәсләрдә тәжрибәлерәк атакайдан да күп нәрсәләр өйрәнгән Жорик, ихтимал, бу очрашу-сөйләшүгә бик житди әзерләнгән булгандыр, сүзләрен бер-бер артлы тезә-тезә, ул пропаганда бүлегендәге кызларны тәмам тирләтеп-кызартып бетерде. Ул хәтта аларга, семинарияне тәмамлап кайткач, һичшиксез, шушында калачагын, менә шул чагында яшьләр өчен комсомол белән дә тиешенчә көрәшәчәген әйтеп, янап та куйды. Жорикның бу оятсызлыгы да шәһәр халкына билгеле булды.

Стаинның гаугачыл жәнжалчы булып танылуы ул көздә үскәннән-үсә барды. Бервакыт Стаин медицина институтында ел саен үткәрелә торган

кичәгә бара икән дә, юлда аны бер кибешеп беткән карчык очратып, Жорикның алдына тезләнгән: «Фатиханны бир, атакай!»—дип такмаклый башлаган. Жорик бер дә югалып калмаган, тыныч кына һәм бик эшлекле кыяфәт белән карчыкны чукындырып киткән, имеш. Моны бик житди итеп, ышанып сөйлиләр иде.

Бертуктаусыз озын-озак көзге янгырлар башланып, аннары янгыр кар буранына әйләнеп, кыш кергәнче, Жорик белән Никанор атакай көн саен иртән йөрүләрен дәвам иттерделәр, әмма хәзер алар еш кына юлларын үзгәртәләр, бары тик мединститут янышнан үтү генә шул килеш кала бирде.

Стаинның әти-әниләренә дә уллары өчен эшләрендә күнелсезлекләр булганын, аларны кайларгадыр чакыртып, улларына чара күрүләрен таләп иткәннәрен Рушан белә иде. Өйдә Жорик белән кат-кат сөйләшеп карыйлар, житди итеп тә, күз яшьләре белән дә, әмма бернәрсә дә үзгәрми, ул һаман рухани белән очрашуларын дәвам итә, анардан еш кына бүләкләр—изгеләр тормышына багышлап, бик зиннәтле итеп чыгарылган китаплар күтәреп кайта. Ул бигрәк тә көмешләр куеп эшләнгән кыйммәтле күн тышлы Тәүрат китабын кадерләп саклый—сирәк очрый торган ул фолиантны Никанор атакай белән йөргәндә кайвакытларда кулына да тотып йөри.

Кыш кышлыгын итә, шәһәр тормышы тына төшә, яшьләрнең күнел ачып йөрүләре дә сизелерлек басыла. Кыш бу юлы бик карлы, салкын, кешеләрне кайчакларда аяктан егардай көчле жилле-буранлы килде. Шәһәр уртасында бакчадагы юкә, тупыл агачларының ябалдашлары шәрәләнеп-каралып калды, бию мәйданчыгын һәм жәйге кафены кар күмеп китте, шуна күрә бакча шәһәр уртасында бер зур кар өеме кебек булып күренә башлады. Сон яктыра, иртә карангылана, кышкы йокының иге-чиге булмас төсле.

Алай да, салкын һәм бураннар булуга карамастан, кичке тормыш дәвам итә, бары тик аны яхшы шәйли белергә генә кирәк, ә моны һәркем дә булдыра алмый. Джаз-оркестрлар белән мавыккан Рушан кышын да һәр вакыйгадан хәбәрдар иде.

Кыш көне институтлардагы кичәләрнең бәһасе бермә-бер арта, программалары озаклап, жентекләп әзерләнә, яшереп торасы юк, уку йортлары бер-берсе белән ярыша, бер-берләренә көндәш була, шунлыктан андый кичәләргә эләгүе дә бик жинелдән түгел. Нинди генә концертлар куелмый, нинди генә оркестрлар ничек кенә тырышмый! Атнага ике тапкыр, шимбә һәм якшәмбе кичләрендә, шәһәр Мәдәният йортында джаз музыкасына биюләр оештырыла, анда саксофончы Эдди Костаки котырына. Зур булмаган зал керергә теләүчеләрнен яртысын да сыйдырмый, ләкин, шуна карамастан, анда һаман да гел шул бер үк егетләр-кызлар жыелыша иде.

Башка төрле аралашу мөмкинлекләре дә бар,—хәзерге яшьләр өчен кафе, дискотека, яшьләр йортлары ише урыннар күп булганлыктан, алар белми дә инде,—теге заманнарда, берәр сәбәп тапкан булып йә гел сәбәпсез дә, кемнен дә булса квартирында яки йортында үзара акча жыеп йә кем ни-нәрсә алып килә, шуна риза булып, мәжлесләр үткәрәләр иде. Андый кичләр яшьләр телендә «бәлешкә» дип йөртелә һәм еш кына алдан уйланмыйча, үзеннән-үзе оеша иде.

Институтларның кереп булмастай кичәләренә дә, Мәдәният йортына да, ин кызыклы «бәлешкә» дә Стаинга юл ачык, аны һәркайда көтәләр, һәркайсына билеты, пропускысы, чакыру кәгазе бар.

Биюләр арасындагы тәнәфесләрдә, оркестр ял иткән арада, Стаин еш кына сәхнәгә менеп, яна жырга заказ бирә яки яна композиция уйнау турында сөйләшеп төшә. Кайвакытларда оркестр төн уртасына кадәр репетицияләр ясый, нәрсәдер яңаны әзерли, андый урыннарда Рушан да еш була, Жорик исә буш кул белән килми инде, бер-ике шешә аракы һәм әйбәт казылык күтәреп килә—оркестрда уйнаучы студент халкы аппетит юклыктан зарланмый.

Әмма ул кышта Стаин еш кына музыкант дусларына дәгъва белдерә: эчпошыргыч күнелсез сезнен янда, Никанор атакай янына барыйм әле,

рухым-җаным өчен файдалырак кич үткәрим, дигән була. Шунда ук фойэдагы телефоннан руханига шалтырата, тегесенен төннәр буена утыра торган гадәте барын белә, рөхсәтен алгач, хушлашып, чиркәүгә китеп бара.

Стаинның кайгы-хәсрәтсез, ваемсыз кышы шулай әкрен генә тәгәри тора. Аның хәзер инде сәер карарыннан кире кайтуын берәү дә үтенми, һәммәсе дә шуңа күнеккән һәм, дөресен әйткәндә, җилкуар Стаинны кызганалар гына иде. Дөрес, аңа сокланып караучылар да бар, ә инде болай да алар алдында уныш казанган Жорикка шәһәрнең гүзәл кызлары Аллаһының хак юлында газапларга да әзер изге җан итеп карыйлар иде.

Өйләрендә дә тынычландылар шикелле, һәрхәлдә әти-әнисен шәһәр комитетына чакыртып борчудан туктадылар. Георгий Стаинны Киев духовная семинариясенә кабул итү мәсьәләсе карала, дигән рәсми кәгазь дә килде.

Алай да Жорикны милиция бимазалап тора: ни өчен шундый саутаза егет беркайда да эшләми? Никанор атакай ярдәмгә килде—Стаин чиркәүдә хуҗалык эшендә эшли, дигән белешмә язып бирде. Стаинның чиркәүдәге бар «эше» төннәрен Никанор атакай белән сөйләшеп утырудан гыйбарәт иде, ләкин хезмәт хакы вакытында килеп тора, аны дъяк айга бер мәртәбә биреп бара. Акча алган көннәрендә Жорик аеруча юмартланып типтерә, үз хәләл акчама кәефләнәм, дип көлә генә.

Никанор атакай белән төннәрен озаклап сөйләшеп утырулар, көндезләрен икәүләп урам әйләнүләр, дини әдәбият һәм теология буенча сирәк очрый торган китаплар уку Стаин өчен файдасыз үтмәде. Әле алкоголь тарафыннан җимерелеп өлгермәгән яшь хәтере һәммәсен дә йотып кына барды, Жорик, бернинди авырлыксыз-нисез, Тәүратны бите-бите белән яттан сөйли иде. Ул шулай ук чиркәү тәгълиматына һәм мистицизмга тартым философик әдәбият белән дә мавыга башлады.

Бию залларында, кичәләрдә яки репетицияләрдә булганда да, ул һәрвакыт бик урынлы гына итеп берәр изгенең яки дин галименең хикмәтле сүзен кыстырып куя, яттан Тәүратның берәр шигырь юлын укый, аның кайсы бүлектән, нинди шигырьдән икәнен әйтеп бирә. Бәлки, Жорик үзенә кирәк булганда, теге яки бу шигырьнең берәр сүзен төшереп калдырып, йә аңа үзеннән берәр сүз өстәп, эчтәлегенә зыян да китерә, яңа мәгънә төсмере бирәдер—тик аны кем тикшерә ала да, кем кире кага ала? Андыйлар юк иде бит.

Стаин теләсә нинди сөйләшүгә—кызлар турында булсын, музыка, джаз турында булсын, мода турында—кыскасы, һәркайсына шундый оста итеп өзекләр, хикмәтле сүзләр, мәкальләр-әйтемнәр китереп кыстыра ки, тәҗрибәсез яшьләр ирексездән аның рухи өстенлеген, белеменең тирәнлеген тоялар. Хәтта кемнедер эчәргә мәҗбүр иткәндә дә, ул һәрвакыт берәр төрле дини эчтәлекле дәлил таба, аңа каршы торырга мөмкин булмый, юкса чиркәү бер дә эчкечелекне хуплап тормый инде. Хәтта аның бик кыю, үткен әйтелгән тостлары да дини мистицизм белән өртелгән була башлаган иде.

Исмәгыйль бәк компаниясеннән алып саксофончы Эдди Костакига кадәр даирәдә иркен аралашып яшәп, юмарт рәвештә тел тегермәнен әйләндерә белү үзенең нәтиҗәләрен бирми калмады: шәһәр яшьләре арасында, хәтта еллар үткәч тә, чиркәү сүзләре, Тәүрат, Инҗил кебек изге китап сүзләре бик еш кулланыла, ул югары дәрәҗәдә зыялылык, яхшы гамәл саналып киленде. Жорикның сүз боткасы бигрәк тә кызлар халкына искиткеч тәэсир итә, аларга, оста сайлап әйтелгән сүзләрнең эчтәлегеннән бигрәк, егетнең артистларча матур итеп әйтә белүе ошый иде, ул елларда һәрбер кыз-кыркын истәлек дәфтәре тота, ул дәфтәрләрдә, башка төрле акыллы-хикмәтле сүзләр арасында, алдый-җолдый Стаин авызыннан чыккан Тәүрат-фәләннән өзекләр, дини кануннар да бардыр әле, мөгаен.

## XXXIII

Шәһәр озын һәм авыр кыштан тәмам арый-талчыга, тәүлекләр буе мич ягулардан жык була—ул заманнарда йортларның өчтән бере төрле-төрле шәхси йортлар иде бит әле, кайчакларда өйләдән үк энгер-менгер башланып китә торган кыска көннәрдән халык туя, гыйнвар-февраль буе котырынган жил-давыллы бураннардан гарык була, рәтле-юньле транспорт булмаудан жәфа чигә—кырыкмаса кырык ямалган иске автобуслар сирәк йөри, шәһәр халкы ана бик өметләнми дә, шунлыктан, бик тә ихтыяжы төшмәсә, озын юлга сәфәр чыкмый иде.

Әнә шул кырыс кышны түземлек белән үткәргәннәренә бүләк булып, ул төбәкләрдә яз искиткеч матур килә. Ашыкмый килә яз: жепшетә, тамчылар тама башлый, анда-санда сулар тибеп чыга, жылы жилләр исә. Шулай килә дә, кыштан үрнәк алыпмы, шактый озак тора, бары тик май ахырларында гына, сирәк-мирәк булган бакчаларда алмагачлар чәчәк атып бетергәч, шау сиреньнең хуш исләре яшьләрне исертми башлагач, шунда гына, анда да ашыкмыйча гына вәкаләтләрен жәйгә тапшыра. Һәркемнең тизрәк авыр-калын, унайсыз-килбәтсез кышкы киемнәрен салып ташлыйсы килә, төрле төстәге шәлләр чишелә, теләсә кайда йонын коеп калдыра торган куян бүрекләр салып ыргытыла, иң көяз кызлар да кышын кимичә котыла алмаган киез итекләр киләсе кышка кадәрле мич башына йә чоланга ук чыгып кунаклый.

Март азакларында, даладан искән дымлы жилләрдән көртләр инә, шәһәр бакчасы өстендәге кар өеме астыннан исән-сау кышлаган куак ботаклары күренә башлагач, үзәк урамга—Карл Либкнехт урамына урам себерүчеләр чыга, үзләренең озын кыш буе эшсез ятуларыннан акланган-дай, жәһәт-жәһәт кенә, тырыша-тырыша, калган кар белән «сугыша» башлый алар. Әгәр дә көтмәгәндә мул гына кар явып китмәсә,—март аенда анысы да була,—бер атнадан шәһәрдә берданбер булып, әлеге урам чистартылган асфальт юллары һәм тротуарлары белән каралып, күзгә бәрелеп тора.

Кыштан туйган шәһәр халкы үзәк урамның чокыр-чакырларын, уемты-сикәлтәләрен күрми дә—асфальт чыккан, димәк, яз һөжүм итә, яздан сәлам килгән.

Апрельдә әле чиркәү бакчасы эчендә кар ята, сукмаклар иртәнге якта юка боз белән каплана да көндез эреп, күлдәвекләргә әверелә, менә шундый көннәрдә Никанор атакай белән Стаин яңадан шәһәргә чыгып йөри башладылар, аларның юллары әле көз көнгеләрдән кыскарак, чөнки Карл Либкнехт белән алар элек йөргән күрше урамнарда пычрак әле.

Язгы салкынча һава торгангадыр, Никанор атакай жиләне өстеннән дөньяви тегелешле кара кастор пәлтә киеп куя. Стаин шулай ук кара, ике капламлы, жилкәләренә үк менгән биек якалы, пинжәкнеке шикелле тышкы күкрәк кесәле яңа демисезон пәлтә киеп, көязләнеп йөри, күкрәк кесәсеннән ак кульяулык күренеп тора. Аның башына киң кырлы, кара велюр эшләпә дә менеп кунаклаган, ул аны кигән саен янача кия, руханидан башка гына йөргәндә, эшләпә бигрәк тә фырт киелә иде.

Алар бер-берсен шундый тулыландырып, тутырып тора, әйтерсен, бербөтеннәр, әйтерсең, Стаин хужалык эшчесе түгел, ә чиркәү рухание. Шуңа күрәдер, Жорик урамга шулай киенеп ялгыз гына чыкса, юлында очраган карчыклар туктальп кала, әгәр дә Стаин шундый кырыс һәм буй житмәс күренмәсә, аны уратып алырлар, йөрергә дә ирек бирмәсләр иде. Әмма Жорик кирәк чакта ара саклый белә. Ул берәр әби житәкләп барган баланың башыннан сыйпап үтәргә мөмкин, әмма шуннан артыгы—юк, аның ул гамәле мәрхәмәтлелек итеп кабул кылына, аннары аны ниргә буйларында утырган карчыклар тәмләп сөйлиләр. Әлбәттә, шулай да булгалый—берәр карчык, хәер-фатиха алырга теләп яки кулын үпмәк булып, аңа ташлана, әмма Жорик андый унайсыз хәлләрдән дә абруен саклап кына чыга белә, ул карчыкларның берсенә дә үзенең дини бернинди дәрәжәсе дә юклыгын, хәер-фатиха бирергә хокукы булмавын әйтеп тормый. Ул

кешеләргә нәрсәнең булса да эчке мәгънәсе, асылы кирәкмәгәнен, тышкы рәвеше килсә, шул житкәнен тиз аңлап алган иде. Шуңа күрә дә аларның шул зәвыкларын канәгатьләндереп тә килде. Халыкның көен күрә белү, халыкка ярый алуда ул әллә нәрсәләр уйлап таба ала, чөнки табигать аңа күпне биргән иде.

Шәһәргә чыгып йөрүләрне тиздән туктатырга туры килде—үзәк урам көннән-көн жанлана бара, халык ишәя, аларны ерып үтү, базардагы кебек этенеп-төртенеп йөрү бер дә рәхәт түгел, гафу үтенергә, уй-фикерләреңне ташлап торырга мәжбүр буласың. Шуңа күрә Стаин белән Никанор атакай чиркәү бакчасының инде кибеп өлгергән төп аллеясында гына йөри башлады.

Шул ук язда шәһәрне янадан шаулаткан хәлләр булды.

Май аенда кышның эзе дә калмады. Иртә яздан йөреп хасил булган уемты-сикәлтәләрне ямаштырып куйдылар, жыелып торган сулар кибеп бетте—рәхәтләнеп йөр дә йөр генә! Чәчәк атып утырган юкә, тупыл, зәңгәр сиреньнәрдән аңкыган хуш исләр теләсә кемне тыелгысыз рәвештә урамга тартып чыгара иде. Карл Либкнехт урамында, бигрәк тә эштән соң, кичке якта халык шулкадәр күп була, әйтерсең лә, Беренче Май бәйрәмендәге демонстрациядән кайталар, диярсең. Инде шәһәр бакчасы да ачылган, кысан биналардан иркенгә чыккан труба, саксофоннар шашынып уйный-кычкырта—шәһәр елның иң матур фасылына керә, елмая-көлә, өметләнә-хыяллана.

Бу берьюлы дәррәү уяну шаукымы белән актүбәлеләр ничектер сизмичәрәк тә калдылар бугай, Стаин Никанор атакай белән шәһәргә чыгып йөрми башлады, рухани үзе дә язгы урамнарда байтактан бирле күренми иде. Менә сәбәп тә бар шикелле: май аенда урысларның уразасы, ә ай азагында—Пасха, чиркәү тормышында иң зур вакыйга. Бу—яңа мәхәлләдә Никанор атакай өчен беренче Пасха...

Стаинның үзенә дә әллә нәрсә булды, юкса ничек яшәсә, шулай яши бирә иде кебек. Сезонда беренче футбол матчында уйнап, «Локомотив» капкасына өч туп «сылады», менә кадәр Бразилия торсидасы белән Италия тиффозилары турында ишетеп тә карамаган Татар бистәсе ул шимбә кичендә шәһәр бакчасына ишелеп төште һәм төн уртасына кадәр типтерде дә әйттерде. Кафеның һәм жәйге ресторанның һәр өстәле тирәсендә кәефләнүчеләр, бакчадагы утыргычларда урнашып, өеннән алып килгән кабымлыкларын чәйни-чәйни, ашарга житмәсә, аяк астында чуалган малай-шалайны янадан өйдән нәрсә дә булса алып килергә куа-куа эчүчеләр бихисап иде. Һәм һәркайда, һәркемнең телендә бер генә сүз: «Стаин... Стаин... Жорик...»

Жорик бию мәйданчыгында һаман да элеккечә игътибар үзәгендә булды, үзен урап алган яшь-жилкенчәк аның һәр сүзен йота бара иде. Ул элеккечә үк купшы-көяз киенгән, бары тик кинәт кенә чәчен китәргән—алай бик кыска итеп тә түгел үзе, әмма карчыкларның күнелен эретә торган, попларныкыдай озын ялы жилкәләреннән юкка чыккан, шунлыктан егетнең йөзе тагын да сөйкемлерәк күренә иде. «Футбол уйнарга уңайлырак булсын өчен чәчен алдырган»,—дип фаразлады кемдер.

Көннәрдән бер көнне, атна уртасында, Жорик оркестр музыкантларына үзенең иртәгә китәсен әйтте.

—Киевкәме?—дип сорадылар, аның тормышы-язмышындагы көтелмәгән борылышларга күнеккән музыкантлар.

—Юк, Кырымга, жәй буена ял итәргә,—дип жавап бирде Стаин һәм теләр-теләмәс кенә өстәп куйды:—Дин белән араны өздем, туйдырды...

Музыкантларга уйнарга кирәк иде, сүз шунда өзелде. Әмма, алар уйлаганча, Стаин хушлашырга янадан килеп тормады һәм икенче көнне, чынлап та, юкка чыкты. Жәй буена күренмәде.

Ә бер атнадан жирле газетта телгә керердәй, истә калырдай бер мәкалә басылып чыкты. Аның исеме озын һәм дәгъвалы иде: «Чиркәүдән йолып алынган тагын бер яшь язмыш». Мәкалә үзе дә бик озын-буталчык, анда Стаинның үзе белән әңгәмә дә кыстырылган, ул исә чиркәү һәм дин турында сафсата сата, хәзер инде цитата һәм хикмәтле сүзләрне башка чыганаклардан, нигездә, марксизм-ленинизм классикларыннан алган иде.

Әле бер ай гына элек чиркәү кануннарын нинди кайнарланып-дәртләнеп яклаган булса, хәзер шундый ук кайнарлык белән аларны җимерергә тырышкан иде ул. Әмма Стаинны якыннан белүчеләр бу мәкаләдәге һәр сүзгә дә ышанып бетмәделәр, аның ихласлыгына, инанып сөйләнүләренә ничек ышансыннар, ди—һәр юлыннан мыскыллы елмаеп Жорик үзе карап тора шикелле ич! Мәкаләсен йомгаклап, журналист яшь егеткә үзенен шәхесен раслау өчен шундый авыр-катлаулы юлында уңышлар теләп, кешеләр һәм оешмалар аның гадәти булмаган язмышын аңларга тырышырлар, дигән ышаныч белдерә. Шулай итеп, Жорик Стаин мәкерле чиркәүнең корбаны һәм, үзен богаулаган чылбырларны өзеп, дин сазлыгыннан котылып чыккан герой булып танылды.

Әгәр дә, Пасхадан соң бер ай үткәч, Никанор атакайны биредән чакыртып алмаган булсалар, бу мәкалә дә, башкалары шикелле үк, тиздән онытылган да булыр иде. Шәһәрдә янә имеш-мимеш сүзләр таралды: әллә Никанор атакай Жорик белән бергәләп ниндидер акчаларны туздырып, чиркәүнең зиннәтле әйберләрен югалтып-таратып бетергән, әллә аларны Стаинга кәрт уенында оттырган, ди, шунда. Аннары, кышкы озын кичләрдә рухани янына Жорик һәрвакытта да берүзе генә барып йөрмәгән икән, аның белән Татар бистәсенең атаклы шулеры, колакка саграк Шамил Гомәров та булгалаган, ди, Стаин артыннан утка-суга керергә әзер кызлар да баргалаган, ди, әле анда. Соңгы фаразлауларга нигез дә бар шикелле: Рушан Дасаевның курсташы, чибәр, әмма җинел-җилбәзәгрәк Ниночка Кабанова, Никанор атакай китеп барганнан соң ук, кинәт кенә техникумнан документларын алып, билгесез тарафка китеп югалды. Менә шул рәвешле, ирекледәнме-ирексездәнме, Стаин торгынлыктан чыгып, аякка басып килә торган чиркәү мәхәлләсен яңадан егып салды, алар шәһәрендә хәзер чиркәү беркемне дә кызыксындырмый инде.

Техникум тәмамлап, берничә ел үтте, Рушанның юллары Стаин белән аерылгач, ул, очраклы гына туры китереп, «Крокодил» журналыннан бер фельетон укыды. Анда Аллага табынучыларның яшерен тәүбә серләрен үз мәнфәгатьләрендә оста файдаланучы ниндидер бер бозык рухани турында язылган иде. Бу руханиның күпсанлы корбаннары арасында Нина Кабанова исеме дә телгә алына, атакай аны, укуыннан аерып, элекке мәхәлләсеннән алып киткән дә, сөяркәсе иткән, ә соңрак үз афераларына ярдәмче ясаган.

Рушан Дасаев җәй көне бию мәйданчыгында оркестр музыкантларыннан ишеткән сүзләрен исенә төшерде: исерек Шамил аларга Жорик белән икесенең ничек итеп Никанор атакайны кәрт уенында бик нык «шартлатканнарын» мактанып сөйләгән, бу эшне ул үзе түгел, Стаин башкарып чыккан икән, руханиның ачылмаган борынгы кәрт колодасын сиздермичә генә алып киткән дә, Шамилгә тоттырган, ә инде аның өчен кәртләргә үзләре генә аңларлык тамгалар салу: тишкәләү, юкарту...—пүчтәк кенә. Менә шул тамгалы кәртләр белән уйнап янган да инде изге атакай—мәхәлләсез калган. Әмма бу сүзләр музыкантлардан ары китмәде, Шамилнең кыланмышлары турында шәһәрдә бик сөйләнеп йөрү гадәте юк иде.

Шулай итеп, Рушан ирексездән Көнбатыш Казакъстанның Актүбә шәһәрендәге чиркәү мәхәлләсенең яңарып терелүенә һәм озакламый түбән тәгәрәвенә шаһит булды, әмма ул вакытта бу вакыйгага ни ул, ни өлкәнрәк буын кешеләре артык әһәмият бирмәде—партиянең каты кулы белән кертелгән дәһрилек—атеизм җимешләре көчле иде.

Чиркәүне хурлыкка калдырганы өчен Стаинга рәхмәтле кешеләр дә булмый калмагандыр, бигрәк тә өлкә һәм шәһәр комитетларында: аларны, чынлап та, Никанор атакайның абруе арта баруы борчый, дин белән ачыктан-ачык намуслы көрәштә үзләренең көчсезлеген тою гаҗиз итә иде—һәм кинәт шундый уңыш! Димәк, тыелгысыз-йөгәнсез дәрт-теләкләргә ия җилкуар Жорик Стаин, телиме-теләмиме, дәүләт аппаратына әйтеп бетермәслек зур хезмәт күрсәткән булып чыга...

*Ахыры киләсе санда.*

# ШИГЪРИЯТ

*Хәсән Туфанның 100 еллыгына*



**Клара Булатова**

## ТӘНӘКӘ ХАТЛАРЫ

«ИСКӘНДӘР КЫЙССАСЫ»НЫҢ ИКЕНЧЕ ЯГЫ

Хәсән абыйның үземдә сакланган шигъри хатларын «Сөембикә»гә җибәргәндә мин аңа үзем язган кайбер әйберләрне дә хәтеремнән барлап чыгарга тиеш булдым.

Дөрес, аларның күбесенең күчермәләре юк, ләкин шигырь булып туган һәм минем шигырь китапларыма теркәлеп калганнары да байтак кына. Бүген мин Сезнең журналга шуларны тәкъдим итәм.

Хәсән абый аларның үзенә барып житкәннәрен чын сөю хатлары дип кабул иткән, һәм аларга җавап рәвешендә үзенең искитмәле нечкә зәвыклы интим—лирик шигырьләрен тудырып калдырган иде. *(Аларның байтагы Туфанның «Гүзәл гамь» исемле китабында дөнья күрде.)* Алай да минем Хәсән абыйның үзенә атап язган беренче хатым тезмә рәвештә түгел иде. Мин аны балаларча беркатлы шаяру белән, бары тик олы шагыйрь алдында үземнең гарәпчә яза белүем белән мактаныр өчен генә язып җибәргән идем. Менә ул!

«Хәсән абый сине яратам, сагынам кайт Клара».

Күрәсез, бернинди тыныш билгесе куелмаган. Өстәвенә әле гарәп әлифбасын язуда куллану да бик аксый.

Хәсән абый, әле Искәндәргә әверелеп житмәгән Туфан бу хат кисәгенә ук җавапны шигырь белән җибәрде. Анысы түбәндәгечә иде:

*(Хәсән абый аны минем хатның астына—шул мин җибәргән кәгазь кисәгенә язып озаткан, монда ниндидер эчке мәгънә булгандыр, күрәсең...)*

«Һай Клара маладис!
Гарәпчә дә яза ич!
И нәнүсем, гүзәлем,
Үсәсеңдер, күрәсең!

«Яратам»ны, «сагынам»ны да
Яза инде беләсен!

Сәлам белән Хәсән абый

Әлмәт».

Әйе, әйе! Эчке мәгънә һәм бик житди «яратам», «сагынам»ны әле яза гына белгән кызыйдан тайпылырга тырышу, «уйнап сөю»не кире кагу булган аның болай җавап бирүендә.

Ә менә соңрак мин аңа язган «Ерак ярларны чорный һәр төнне» дигән шигырьгә каршы Хәсән абый олы бер дастан-шигырь тудырып калдырды.

Гәрчә, аның минем тарафтан иҗат ителгәне дә җыр булып яшәрлек иде бугай инде. Алтмышынчы еллар азагында Равил Вәлиев көйгә салган ул әсәрне безнең татар бүлеге студентлары яратып җырлыйлар иде.

Ерак ярларны чорный һәр төнне
Томан да сыман, төтен дә сыман
Якын кешенне сагынып көтүе
Рәхәт тә сыман, читен дә сыман.

Ап-ак шәлемне салып иңемә
Юлларга чыгам—юк шул беркем дә.
Тик салкын нурлар айдан сибелә
Җыр булып калган күпер өстенә.

Белсәң иде син, сизсәң иде син
Үзәкне өзгеч сагыш моңымны,
Ничек көткәнем белсә иден син—
Кайтыр идең бит, ишетеп җырымны.

Ерак ярларны чорный һәр төнне
Томан да сыман, төтен дә сыман.
Кайтыр көненне сагынып көтүе
Рәхәт тә сыман, читен дә сыман.

Икенче бер шигырь (анысы инде Тәнәкә исеменнән язылган хат иде аның) шулай ук җыр булып яши башлады.

Ерак юлга чыгар көннәреңдә
Әллә инде вакыт җитмәгән,
Башларымны салып иңнәреңә
Сөйләр сүзләр әле бетмәгән.

Уралдан да алып кайт син чорның
Җыр тудырыр яңа сулышын.
Илкәенә сакла көчле җырын—
Тәнәкәнә йөрәк җылысын.

Мин дә синең йөрер эзләреңә
Җырлар сузам моннан, Искәндәр,
Башларымны салып иңнәреңә
Сөйләр сүзләр әле никадәр.

Сөйләр сүзләр сөйләнеп бетмәде, гаҗәеп якты, матур кыйсса ахырына җитмәде, өзелде.

Өзелү сәбәпләре гомер белән гомер арасы гына да булмагандыр инде. Үзеннән соң язылган шигырьләремнән берсендә мин, мөгаен, аны дөрес танып ачарга тырышканмындыр.

* * *

Озатырга сине—дәшмәделәр...
Әйе, шулай кирәк булгандыр.
Мин артыктыр,
анда бердәнберен—
Луиза апа көтә торгандыр.

Андагылар көндәш түгел иде,
Мин өйдәш тә була алмадым.
«Ул нәкъ минә синең шикелле»,—дип,
Вакытлыча гына алдандың.

Ул бердәнбер мәхәббәтең иде,
Тиң булмады аңа Тәнәкә...
Сез бергәдер анда,
урыныгыз
Янәшәдә булсын җәннәттә.

Хәсән абыйның Искәндәргә кучеп янып-яратып яз ясаган көзләреннән соң инде байтак еллар үтте. Төп-төгәл 40 ел. Үзе бер олы кеше гомере.

Минем өчен ул дәресләремдә Аксакал шагыйрь, ә күңелемдә иң саф хисләргә генә баш ия торган романтик Искәндәр булып яши.

Бүген сезгә тәкъдим ителгән шигырьләр шуның чагылышы.

## Сөю мәңге яшәр кебек иде...

**Җәй азагы...
Август киче иде,
Бүлмә тулы алма исе иде.
Алмаларда яшәү төсе иде,
Йөрәкләрдә сөю хисе иде.
Һәм ул мәңге яшәр төсле иде.**

**Алмаларың минем өчен иде,
Шагыйрь җаның минем өчен иде,
Шигырьләрең минем өчен иде,
Мине сөюең нинди көчле иде—
Мәңге-мәңге сүнмәс төсле иде.**

**Ул мәңгедә бары җыр бар иде,
Бөтен Дөнья, гүя, җырлар иде.
И хыялый, и әкияти өнем:
Син—Искәндәр, мин—Тәнәкә идем.**

**Дөньясында икәү генә идек,
«Мәкер безгә кагылмас та»,—дидек.
Шул Дөньяны кемнәр көл иткәннәр?
... Мин Тәнәкә идем,
Син—Искәндәр.**

**Шул дөньяны кемнәр көл иткәннәр?
Шуңа кемнәр җөрьәт иткән инде?
Кемнәр кара яла йөрткән иде?
Кемнәр көнгә агу сипкән иде?**

Алмаларның төсе киткән иде.
Күптән инде,
Әйе,
Күптән иде,
Тик әкияттә яши шул үткәннәр:
Мин—Тәнәкә анда,
Син—Искәндәр.

* * *

Күптән инде хатлар килми миңа
Син яраткан зәңгәр букчада.
Килми хатлар Яңа ел туса да,
Язлар алмашынып торса да,
Килми хатлар синнән.

Элек-элек, байтак еллар элек
Синең кулың белән язылган
Шигырьләрне, догалыклар кебек,
Калдырмыйча йөртәм янымнан,
Әйтерсең лә алар тапталудан
Мине саклый торган талисман.

* * *

Моңа кадәр басылмаган
Шигырьләрең теркәгәннәр...
Тик күбесен тапмаганнар,
Яки табып кертмәгәннәр.

Керткәнен дә, Раббым-Аллам,
Кыскартканнар, талаганнар,
Үзгәрткәннәр, «төзәткәннәр»,
Өстәгәннәр, ямаганнар—
Тик барыбер Тәнәкәдән
Арындыра алмаганнар.

* * *

Язларда моңайган бу җанымнан
Ниндидер кара сер эзләмә.
Кирәкми, үткәннән көнләмә син,
Син Аңардан мине көнләмә.

Ул башка,
Ул шашып сөйгәндә дә
Сак иде, саф иде ни чаклы!
Ул хәтта төшемә кергәндә дә
Фәрештә шикелле инсафлы.

Кирәкми, Аңардан көнләмә син,
Син үткәннән мине көнләмә.
Язларда яктырган моңлы җаннан
Ниндидер кара тап эзләмә,
Кирәкми,
Үткәннән көнләмә!

## Эчтән генә көйли...

Ничә тапкыр яфрак ярды каен,
Ничә тапкыр койды яфрагын,
Ничә тапкыр синең каеныңа
Ялгыз гына килдем мин тагын.

Ялгыз гына килдем, ишетим дидем
Яшерен серен үткән елларның...
Каеның да эчтән генә көйли
Ил яңгыратыр сөю җырларын.

## Сәвәләйдә казаяклар үсә

Сәвәләйдә казаяклар үсә,
Әби чәче тузгып утыра.
«Әби чәчен» берүк җыя күрмә,
Кара кайгы килер йортыңа!..»—

Нурлый карчык шулай дигән иде,
Өзмәгән дә идем кылганны.
Кайгы килгән, йортым гына түгел,
Каплап бөтен якты дөньямны.

Кара кайма белән уратылган
Рәсем ята өстәл өстендә.
Казаяктай чиста җан шагыйрьнең
Ак чәчләре—кылган төсендә.

Ап-ак чәчле кылган өзелә—сибелә,
Казаяклар үкси туктаусыз,
Ярый әле чын шигърият үлми,
Нишләр иде дөнья Туфансыз?!

---

## Киләсе саннарда укыгыз:

Журналның алдагы саннарында да редакция укучыларга әдипләребезнең иң кызыклы һәм үтемле язмаларын тәкъдим итәргә ниятли. Октябрьдә, мәсәлән, **Рауль Мирхәйдәровның** "Иртәләгән сагыш" романының ахыры, **Фәнзаман Батталның** "Сабакташ" дигән сатирик хикәясе, **Илдар Юзеевның** "Эзләдем, таптым, югалттым" исемле пьесасы, шагыйрь **Ренат Харисның** "Һарут белән Марут" поэмасы дөнья күрәчәк.

Ноябрь санында күренекле әдип **Аяз Гыйләҗевның** әдәбиятыбыз һәм бүгенге чынбарлык хакында тирән уйланулар белән сугарылган "Күңелем серләре" язмасы басылачак. Фантастика жанрында уңышлы эшләп килүче **Радик Фәизов** үзенең "Галеллек иясе" исемле яңа хыялый повестен тәкъдим итә.

Журнал битләрендә шулай ук заманыбызның үткен мәсьәләләрен күтәргән публицистик язмаларга, хәзерге заман әдәбиятының халәтен анализлаган тәнкыйть мәкаләләренә дә урын мулдан биреләчәк.

**Исегезгә төшерәбез: сентябрь аенда яңа меңъеллыкның беренче елы—2001 ел өчен журналга язылу башланды. Подписка барлык элемтә бүлекләрендә кабул ителә. Журналның индексы—73210.**

*Яңа меңъеллыкта да бергә булыйк, дуслар! Вакыт дигәнең гаҗәеп тиз уза бит ул. Күп тә үтмәс, өченче меңъеллыкның беренче елы да тарихи хатирә генә булып калыр. Ә шул елның беренче аенда килгән "Казан утлары" шул истәлекле чорның мәңгелек хатирәсе булып китап киштәләрегездә урын алсын.*

# ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР



## Айдар Хәлим

## КАЗЫКТАГЫ ИТАЛЬЯН

ХИКӘЯ

*Халык гармунчысы Фәйзи Биккинин истәлегенә*

I

Казуыннан туктап, ул билен турайтты. Аннан, иелә биреп, башын какты: кабадагы көнҗәләгә охшап тузгыган чәчләреннән энҗе тир бөртекләре сибелде. Бу тир, үзәккә төшеп, күзләрне кисә, каһәр. Әгәр хәзер көзгегә караса, йөзенең тартылып, хәнҗәр йөзе сыман көмеш төссезләнеп калганлыгын абайлар иде ул. Әйе, җир эше—ир эше. Димәк ки, тир эше. Көрәгенә таянган хәлдә кайчандыр колагына чалынган бер юләр мәзәкне дә исенә төшереп, авыз чите белән генә елмайгандай итте. "Әтиенне җирләргә нигә кайтмадың?"—дип сораганнар, имеш, Донбасста яшәгән бер зимагур шахтердан. "Ә нигә кайтып азапланырга?—дип җавап биргән, имеш, теге.—Беләбез без җир эшен."

Уйлап чыгарса, чыгара да куя инде безнең халык. Татарда була торган хәлме инде шушы?

Маңгаеннан саркыган тозлы тирен җиң очлары белән сыпырып, кояшка күз салды. Ярыйсы гына үрмәләп өлгергән! Һава монда да, кояш әйләнешендә җайлап кына көн ягына чыгып барган абзар күләгәсендә дә, шакты җылына, хәтта бөркүләнә башлаган түгелме?

Ул тегермән ташы сыман шыгырдап кипкән телен чак-чак әйләндерде. Көрәген үзе чыгарган балчык өеменә кадап куйды, һәм эссе капкан чыраен җиләсләргә теләп булса кирәк, янәшәсендәге ат башыдай әрекмән яфрагын өзеп алырга дип үрелгәндә генә агарып утырган пыяла чирекне[1] абайлап алды. Аның йөзендә шатлыклы сискәнү чагылды. Аһ, әйрән!

Ул үңәчләренә кадәр көйрәп сусаган иде.

Кем әйтмешли, "сәтсиәлистик ярыш ялкынында" чамасыз янып һәм ялкынланып китеп, ул картинәсенең борын төбенә генә салкын әйрән

[1]Чирек—өч литрлы шешә. *(Автор).*

чыгарып куйганлыгын да онытып җибәргән ләбаса!..

Аның анкавы татлы селәгәй белән тулды.

Әмма ул ләззәтне үз теләге белән суза иде.

Ул чокыган чокырыннан чыкты, моннан атна-ун көн чамасы гына элек Ихсан дусты белән Имәнлек урманыннан кое баганалыгына дип алып кайткан, әле булса каезланмыйча, кояш кызуында пешенеп, кайры әчесе аңкытып яткан имән агачына килеп утырды, аннан үреләә биреп, әрекмәннәр арасыннан әйрәнле чиреккне эләктереп чыгарды. Савытны сырып алган салкын тир бөрчекләре аның сусавын тагын да үчекли һәм үсендерә иде...

Һәм ул—бугазына, күкрәгенә капкан ялкынны сүндерә алмас сыман ашыгып, чаптыр-чоптыр китереп әйрән чүмерә башлады...

Боз кебек салкын, әремдәй хуш исле, дәрманлы, каймак сыман йомшак, тәмле һәм куе иде бу әйрән!..

Катыгына кашык өсте каймак, чеметем генә тоз, чеметем генә суды салып болгатылган һәм күбекләнеп күпертелгән иде шул бу газизләрдән газиз мал агы!..

Катык, әйрән дигән нәрсәгә бик тә талымсыз, комсыз иде шул ул. Әйрән аның тормышта тойган беренче тәм ләззәте иде. Әйрәннең авыз бозылу һәм күкрәк, ашказаны чирләренә каршы никадәр көчле шифа булуын ул әле бөтенләй белми иде югыйсә. Әйрәнне онытылып эчте дә эчте. Авыз читләреннән саркыла биреп, ачык изүдән иң башта киң, сумитләре бүселеп торган күкрәгенә, аннан күкрәге буйлап кендек чокырына агып төшүен дә сизмәде...

Әйе, үзләренең коесы суында болгатылганга шулай тәмле бит бу әйрән! Әле сез белмисездер дә, аларның бит үзләренең коесы бар! "Үзләренең коесы бар",—дип юкка гына җырламыйлар, әлбәттә. Югыйсә, тәмам җәфаланган аның картинәсе коесыз. Әткәсе фронтка китәр алдыннан казый башлаган булган ла ул коены, әмма казып, эш итеп бетерә алмаган. Авыл җирендә коесыз яшәп буламы? Көянтәне асып, айт диген дә күрше коесына йөгер, тайт диген дә күрше коесына йөгер. Әй куанды картинәсе ул үзләренә кое казыйм дигәч! Ничек элегрәк килмәгән егетнең башына үзләренә кое казыту уе? Хәер, кое казу дигәч тә, ул сиңа онлаган тары коймагын майда йөздереп ашау түгел. Аңа бит дәрт-дәрман, көч, мачтырлык та кирәк. Гыймакай бабасы—Гыйльметдин бабаларын авыл халкы шулай гына атый—һәм Ихсан белән өчәүләп өч көн дигәндә казыдылар да куйдылар. Бура да төшерделәр. Бар тирә-якка даны таралган мич чыгаручы, бура бураучы Гыймакай бабалары яратмаган кешесенә эшләү түгел, сөйләшеп тә тормый. Теле дә аның чалгы кебек: кыеп кына ала. Ә менә Бәгъремне ул кочагын җәеп каршылады дип әйтергә мөмкин.

Юкәсен абзар баганасына чалып аркан ишкән карт белән аның арасында менә шундыйрак сөйләшү булып алды:

—Гыймакай бабай...

—И-и, агач тел! Сөекле Гыймалетдин бабамыз диген!..

—Сөекле Гыймалетдин бабамыз, мин сиңа...

—Мин сиңа, имеш! Нәрсә, без синең белән казлар көтеп үстекме? "Гыймалетдин бабамыз, мин сезгә, рөхсәт итсәгез..." дип башларга кирәк!..

—Гыймалетдин бабамыз, мин сезгә рөхсәт итсәгез...

—Шуннан?!

—Гыймалетдин бабамыз, мин сезгә кое казышырга ярдәм итмәссез микән дип килгән идем...

—Һы. Кем кемгә ярдәм итәр бит әле. Кайсыбыз соң анда нәчәнник булачак, ягъни мәсәлән? Кем кое богазын үткәрәчәк, кем су алкымын эзләп табачак?

—Син, әлбәттә.

—Бәс, шулай булгач, син миңа "Гыймалетдин бабай, сез безгә кое казып бирмәссез микән?" диярргә тиешсең, агач тел!

Үсмер бабасының аның белән шаярып сөйләшкәнлеген аңлап алды.

—Сиңа бит без дә чокышачакбыз!..

—Бәй-бәй, син әле миңа ярдәм итмичә болдырдан гына карап торыр

иденме ни?—Карт эче катып көлә башлады.—Кара син аны, каян килгән гөбернатыр! Ярар, килермен. Рәхмәт чакыруына. Тукта, ничә яшьтә әле син?

—Унбишем тулып, уналтыга чыгып барам.

—Алтмыш алты диген! Малладис, улым! Күп кенә ирләр алтмыш алтыны ваклап та кое казыта алмыйча китеп баралар. Ә син... уналтыда гына! Болай булса, авылда бер жегет кеше туа, димәк. Хәерле сәгатьтә!..—Сугыш һәм сугыштан соңгы чорда ирләрне ифрат та сагынып өлгергән Гыймалетдин карт кәефе килеп сөйләнә иде.—Барам, бармый диме тагын? Ничек кенә барам әле! Син дигәндә—мин идәндә!—Аннан хәйләкәр генә күзләрен кысып алды.—Картинәннең мич башын да караштыргалаштыр. Ачы балы бар микән? Син дигәндә мин... шырпы кабыннан да егылып төшәргә әзер!.. Кхе-кхе...

Эшләре гөрләп барды. Тик шунысы гына, Гыймакай бабайларының хәтере генә тишек иде. Егетләр аның хәтерсезлегеннән яшереп кенә булса да көлгәләштереп алалар. Ничек көлмисең инде: ул бит кое төбендә салган үлчәмен, сикереп жир өстенә чыккач, жир өстендә салган үлчәмен сикереп кое төбенә төшкәч оныта. Бәгърем белән Ихсан булмаса, ул бәлки барлык гомерен шулай өстән аска, астан өскә сикеренеп үткәргән булыр иде. Әйтик, бабалары кое төбеннән "Әһә, бер метр да егерме сантиметр икән" дип жир өстенә чыга да, аннан шундук күзләрен тажырайтып "Мин ничә дигән идем әле?" дип егетләргә уктала. Әкәмәт!..

Бәгъремнәрнең коесына суга елга аша Разия да килә башлады. Үзләренең коесы да бар инде, югыйсә. Ләкин суы татырлы. Бәгърем коесының суы бик тәмле булып чыкты шул.

Үзләренең коесы бар,
Безгә килеп су ала,—

дип ничек кенә жырламассың инде. Разия искә төшү белән Бәгъремнең йөз суы шадраланып куйды. Бер уйласаң, Разия ана беркем дә түгел. Бары тик күрше кызы гына. Каршыда, Өязе елгасы аша гына аларның өйләре. "Разия! Рәкыя! Дарига! Һәдия!" Раһиба жингиненең шулай жәен дә, кышын да, көндезен дә, төнен дә кызларына эндәшкәнен тынлап үсте Бәгърем. Нәкъ аның кебек фронт ятимәләре инде алар. Араларыннан өлкәннәре, Разиялары, кияүгә чыгып маташа бит әле. Менә әле туй мәшәкатьләре бара шунда. Ул шул туйны озатырга чакырылган. Күрше егет буларак кына түгел, күбрәге—гармунчы буларак. Гармун уйный башлаганнан алып аның гомере икегә бүленде бит: гармун уйный башлаганга кадәр һәм гармун уйный башлаганнан соң. Бер кешедә ике кеше яши: "мондый гына кеше " һәм " бик тә кирәк кеше". Әй нәрсәсен сөйләп торасың инде аның!—Егет чәмләнеп китеп, кирәк йөзен сыртына кадәр балчыкка батырды һәм колагын торгызды: таллык аръягында әлегә шылт иткән тавыш та ишетелми иде. Кайдадыр Ашказар, Ишембай якларында яткан авылдан килгән кодакодачалар кунактан соң мырлап йоклыйлар, күрәсең. Егетнең күңелендә ниндидер такмаза да яралып куйгандай итте:

Мырлап йоклап яталар, ди,
Мыр-мыр кодаларыбыз...

Бүген шул кодаларны, ягъни мәсәлән, туйны, ягъни мәсәлән, Разияны озатачаклар, имеш. Разияны кияү егете Агыйделнең аръягындагы авылга алып китә... Гарьлеге ни тора!..

Кайсыдыр күршесе ихатасында аяныч итеп тавык кытаклады. Ниһаять аны чыркылдатып тоттылар. Ул тагын да бер тапкыр, тагын да аянычрак итеп кытаклады да, тынды. Чалдылар.

Әй, алып китмәсә тагы!..

Кемне булсын, шул Разияны әйтә инде.

Уч төпләрен төкрекли салып, янадан казый башлады. Коесының сиртмәле булуын, әллә кайлардан күренеп, чынрау торна сыман сайрап, чакырып торуын тели ул. Атасы да коесын сиртмәле итәргә теләгән булган,

имеш. Шул сиртмәнен баганасы өчен чокыр чокый бит инде. Дөресен әйткәндә, бу эшкә бүген тотынырмын димәгән иде. Үзенә тынгы тапмаганга гына башлады аны. "Корал эшли—ир мактана",—дигәндәй, эше ырамлы гына бара, югыйсә. Болай барса, бер-ике сәгатьтән очына да чыгуы мөмкин.

Балчыгын өскә ыргытудан туктап, чокырны тирәнәйткән арада ул балчык өемен сырып алган чыпчыкларга игътибар итте. Селәүчән эзлиләр. Өемгә көрәктән балчык килеп төшкәндә дәррәү күтәреләләр дә, ул чокырга иелү белән, пырылдап, янадан куналар. Быел балчыкта, ни гаҗәп, селәүчен аз. Табыш аз булган саен мәхлукъләр ерткычлана, берсе икенчесенең өстенә үк менеп бара...

Ул соры туфрак катламын күптән үтте. Кара туфрак катламын да үтеп, кызыл туфракка житкәч, берәр көрәк алганнан соң туктаса да була. Бәгърем белә: чокыр тирәнлеге кендек тәнгәленә житкәч тә житәчәк.

Селәүчен дигәннән. Быелгы ел сәерлекләре анын белән генә чикләнми. Июнь уртасы да үтеп баруга карамастан, мәсәлән, туфракта боз салкыны саклана. Җәй быел, укытучылары Мәхмүт абый әйтмешли, "кискен континенталь" килде. Майда гына түгел, хәтта июньдә дә халык өстеннән бишмәт төшмәде: янгыр яуды да, кар яуды, янгыр яуды да, кар яуды. Авыр кургашын болытлар гел генә жир өстендә асылынып торып, тереклекне өшетте. Баскан жирдә жир лычкылдады. Алмагач, шомырт, чия кебек жимеш агачлары июнь башларына кадәр чәчкә аталмыйча утырды. Чәчкә атарга йомарланган жиләкләрнен жимшән касәләренә кар тулып, төннәрен суык өч-дүрт дәрәҗәгә житсә дә, алар, ни гажәп, өшемәде дә, тунмады да. Кырау да сукмады, хәтта ки! Чәчкәгә йомарланган бөреләр елмаерга дип авызын ачып, елмаюдан тыелып калган тамашачыларны, сабантуйда жинеп тә, бүләк көтеп катып калган көрәшчеләрне хәтерләтте.

Бәгъремнен ин яратмаган фәне—зоология. Аннары биология. Күз алдында кыелып кына очып кереп, туган абзарын бәпкәләренә оя корган карлыгач канатлары, әрекмән яфракларын тикшереп утыр инде шунда! Әмма өниме ул аларны, әллә өнәмиме, егетне кызыксындырган сорау жавабын көтә иде: нишләп үсемлекләрне бары тик алар чәчкә аткан чорда гына кырау суга? Гүяки Суык Бабай аларнын чәчкә атканнарын көтеп кенә тора. Үсемлекләрнен чәчкә ату дигәннәре аларнын шул беренче мәхәббәтләре буладыр бит инде ул? Нәрсә, тереклекне сынап чыныктырумы бу? Ныкларны гына сайлап алумы? Әгәр шулай икән, Ходай Тәгалә тарафыннан артык кансызлык күрсәтү булмыймы бу? "Алмагачлар чәчкә ата майнын унбишләрендә" дип жырласак та, нишләп быел алмагачларны хәтта кар астында да кырау сукмаган, чөнки алар әле чәчкә атмаган иде. Аларга карап, егетнен куркып калган чаклары да булгалады: табигать—бар төр үсемлекләр һәм чәчәкләр чәчкәләнмичә кысыр калса? Бөреләр яфракланмас борын саргайса? Үләннәр үсмәсә, печәннәр булмаса, игеннәр унмаса?!

Әмма юкка гына борчылган Бәгърем. Май азакларында кояш бер-ике көн бу жир кортларын тирләтимме, әллә өшетимме дип килделе-киттеле торганнан сон шундый мөлаем итеп елмайды ки—ышанасызмы, ике-өч көндә һәммә нәрсә аякка басты, тәртәләрен киерде; акланнарда һәм болыннарда юан ботлы балтырганнар, кузгалаклар буынга сикерде, нииндидер эре сабаклы жир жиләкләре хәтта ат юлларыннан төртеп чыкты; ышанасызмы, гомердә чәчкә ата белмәгән кычыткannар ап-ак кынгырау чәчкәләр белән гезгелдәп утырды; жирдән "инде үлде, инде югалды" дип саналган, дистә еллар буе хәрәкәтсез яткан дистәләрчә төр орлыклардан Ходай Тәгалә мәнге күрелмәгән үсемлекләр үстереп чыгарды...

Әйе, быелгы табигать чаманы белмәде. Май уртасындагы биш дәрәҗә суык июнь башларында исә утыз дәрәҗә эсселек белән алышынды, ышанасызмы? Кымызлык сабакларында гөжләп күпереп, кымыз күтәрелде. Тын юлларына кадәр буып, бар дөньяны бал исе басты, монарчы планын үти алмаган бал кортлары төнлә дә, фонарьсез-нисез, вжәткегә ширбәт ташыды. Көн эссесе йөзгә капты. Елгаларда су кайнады, салкын азык эзләгән балыклар ярга сикерде...

Әйе, башта суытса да, өшемәде, аннан ничек кенә кыздырса да,

янмады-көймәде быелгы табигать. Шунысы тагын да кызык, һәркайсы яшел чүмәлә булып күпергән агачларга дикъкать белән карасаң, аларда кара чәчтәге бер учма чал кебек агарган, саргайган, каяндыр килеп чыккан утлы жил тарафыннан көйдерелгән, суык тын жепселләре белән өшетелгән аерым ботак, аерым учма, хәтта аерым яфракларны шәйләргә мөмкин. Язмыш! Агач ябалдашы гөрләп яши, ә менә аның бер тарафы, бер шивәсе йә чирли, йә бөтенләй үлек. "Житмешкә житеп, мондый жәйне күргәнем юк иде,—дип кабатлый иде еш кына Гыймакай карт.—Бер вәхи төш тә керде әле үземә. Өязе буйлары ап-ак шомырт, имеш. Арыш уначак быел, Алла боерса!" Икенче бер чагында карт "Ахырзаман алдыннан табигать шулай үрә басар, дигән китап,—дип тә сөйләнеп ала.—Горур, шагыйрәнә булыр дигән. Игеннәр ифрат та унар, жимешләр ишелеп өлгерер, Дәжжал дөньяга чыгар, дигән..."

Анын Дәжжалы нәрсә икән инде тагын?

Аерым кешеме ул, әллә һәркемдә дә булган бер котырынкы халәтме?

Кинәт тешләрдә кайралып, чыелдап, көрәге нәрсәгәдер төртелеп туктады. "Шушы мәллә Дәжжал дигәннәре?" дигәндәй, егет сискәнеп куйды. Көрәге, аннан бармаклары белән озак кына чокынып азапланганнан соң ул ниндидер чылбырлы тимер тартып чыгарды. Тазарткannan соң аның чүкелеп ясалган борынгы йозак икәнлеге ачыкланды. Богау йозагы булырга кирәк. Бәлки авылларына нигез салган Әкри-качкынга да катнашы бардыр әле аның. Укытучы Мәхмүт абыйларына күрсәтергә кирәк булыр.

Ул елмаеп куйды. Әгәр ул шулай чокына-төртенә жир шарының теге ягына барып чыкса, юлында нинди генә хәзинәләр тапмаган булыр иде икән?! Хәзер инде ул тиле шикелле шаркылдап көлә иде. Күз алдыгызга гына китерегез: менә ул тальянын күтәреп, жирнең аргы ягына барып чыга да, "Сарман"ны уйнап жибәрә. Анда исә казан асканнар. Күз күреме житәр тарафларга кадәр һәркайда казан асканнар. Учаклардан төтен күтәрелә. Ниндидер лампапуду дигән кыргый адәмчекләр ана каурый агачлар астыннан "Әйдә, безнең белән кеше ашарга!—дип кычкыралар.—Казанга якынрак кил, теләгән калжаңны сайлап согын!" Үзләре ят жирләрен яфрак белән дә капламаган, оятсызлар. "Мин бит үзем Казаннан,—ди аларга Бәгърем.— Без, казанныкылар, үзебез кеше буларак, кеше ашамыйбыз".—Ул тагын да тальянында сыздырып жибәрә, имеш.—Әгәр сез, безнең кебек, тальянда уйнасагыз, кеше дә ашамас идегез!" "Казаннармы кеше ашамый?!—дип шаулаша-көлешә, бөтенләй тузга язмаган нәрсәләр сөйли башлый лампапудулар.—Кеше итен кайнатучы казан сезләрдән чыккан түгелме? Ашыйсыз, бер-берегезне яшертен ашыйсыз! Ничек кенә ашыйсыз әле! Кавемнәрегез белән ашыйсыз, исемнәрен дә онытасыз, аннан соң, исерешеп, шушы лыгырдык гармунығызда уйный-уйный, шул йолкыш "Чабата"гызга биисез! Шуна күрә сезләрне дөнья белми. Ә безләрне бар дөнья белә. Чөнки без соклангыч барабаннарда тукылдатабыз!—Тирә-якны тире барабан тавышлары баса.—Без яшермичә кеше ашыйбыз да барабаннарга биибез! Мабимбо-бомбо! Ашаганнан соң барабанга менеп сикерсәң, корсакка күбрәк сыя! Мабимбо-бомбо!"

Брр! Егет үз уйдырмаларыннан үзе үк чирканып куйды.

Аны кемдер чакырган сыман тоелды.

Ул колакларын шомрайтты. Аһәң елга аръягыннан—ул чакыру көткән тарафтан түгел, ә якыннан—үзләренең болдырыннан икән.

—Бәгърем! Канатым!

Чагу-сары күлмәгенең сарысы сыек читән аша саркылган, зәңгәр яулыклы башы исә читән өстеннән зәңгәрләнеп торган картинәсе аваз сала икән аңа.

—Нәрсә, картинәй?

—Туй озатырга барасынны онытып жибәрмәденме дип кыбырсуым. Баярак тагын бер мәртәбә әйтеп чыктылар. Гармунын онытмасын диделәр...

—Онытмадым ла...—Разиянын туен искә төшергән өчен Бәгъремнен картинәсенә ачуы килеп китте. Анардан башка белмиләр иде. Аннан, уч төпләрен төкреклап өстәп куйды.—Аларга шул гармун гына кирәк инде...

Бер үзендә ике кешедән тора бит ул хәзер. Берсе "мондый, прастуй", икенчесе "кирәк кеше, гармунчы".

Ул янадан казырга тотынды.

Анлагансыздыр: Бәгърем исемле ул. Бәгърем исемле бәгърем, димәк. Анлагансыздыр: аның исемендә үк нindидер гүзәл сер, әйтеп бетелмәгән мәгънә, матур шөбһә, хәтта куркыныч фаҗига яшеренгән иде. Уйлап кына карагыз: Бәгърем кадәр бәгъремне яратмаска, инкяр итәргә, аеруча ташлап китәргә мөмкинме? Мөмкин түгел. Шуңа күрә дә Бәгърем бит ул. Син Бәгъремгә "Мин сине яратмыйм, Бәгърем" дип әйтеп кенә кара!..

Үсмерлектән егет корына кереп житмәгән, туп кебек тыгыз, беләкләре, күкрәкләрендәге сумитләре түгәрәкләнеп, бүселеп торган егеткәй әле исеменең мәгънәсен үзе дә анлап житкерми. Әмма ул аның тарихын белә: әнисенең бердәнбер мирасы ул. Алты бала табып, Бәгъремнән башка, берсе дә исән кала алмаган. 1939 елның кышында фин сугышына китеп хәбәрсез югалган аның әтисе. Ул чакта Бәгърем әле карында гына булган. Кызу печән өстендә, урманда, вакытыннан алда дөньяга килгән ул. Каны күп агудан әнисе урманда ук җан биргән, мискинә. "Исән калса, Бәгърем кушыгыз,"—дип әйтеп өлгергән ул. Уйлап тапкач та тапкан инде югыйсә. Хәер, ул аны күптән алдан уйлап куйган булгандыр инде. Аның үз исеме дә бик матур, бик тә жилле булган: Тәнзилә! Ул бу көмеш исемне туктаусыз кабатларга риза: тән-зиллә! Зиллә! Зенлә! Жиллә! Таң җиле! Зилләр, жилләр, кыллар!.. Танда кымыз пешергән сөян гөбе кебек зеңгелдәп торалар алар!..

Аны әнисенең бертуган апасы—Өммегөлсем картинәсе тәрбияләп үстергән. Ул аңа, аларда, көньяк Урал татарларындагыча, "карт инәй" дип әйтергә өйрәткән. Дөрес тә инде. Үз инәсе, "яшь инәсе" булмагач, аны аякка бастырган кеше кем дип аталырга тиеш инде "карт инәй" дип аталмыйча? Өммегелсем картинәсе имезмәгән аны имезүен. Үз инәсен бер генә тапкыр да талкырга өлгермәгән малай актыгын беренче тугыз айда картинәсе имчәк балалары булган хатыннарга йорттан йортка йөртеп имезгән. Исемлек буенча, димәк. Аннан кәжә сөтенә күчергән.

Балчык өеменнән селәүчен бүлешә алмыйча, тагын да чыпчыклар чыркылдашты. "Минем менә шулай бәхәсләшергә, кызык итеп кенә булса да тәрткәләшеп тарткалашырга, тапкан малны бүлешергә сукыр бер туганым да юк бит, ичмасам,—дип уфтанып алды егет.—Тома ятим бит мин. Инде менә Разия да китеп баргач..."

Ана нишләптер үзе казыган чокырдан бихисап хәзинәләр чыгар кебек тоела. Гүяки чокырның теге очында, ягъни аның еракта, бик ерактагы төенендә ул нурлар уйнатып яткан Ак Йолдызга тап булачак. Кәрәк очы шул ул Ак Йолдызга тиеп кайтарылу белән аннан гөрләп саф чишмә ургылачак...

Ул Ак Йолдыз—саф чишмәне кем белән бүлешер соң ул? Разия да китеп баргач...

Ул тирән итеп уфырды. Үзен биләп алган авыр уйларны куарга тырышкандай, ярсып-ярсып казый башлады. Дөп-дөп. Әмма ул мал эзләп һәм мал бүлешү өчен туган эзләп читкә китмәячәк. Авылын ташламаячак. Дөп-дөп. Бу келәт кебек алачыклары урынына ул алты почмаклы, калай түбәле, зәңгәр күтәрмәле йорт бетерәчәк, Алла боерса. Дөп-дөп. Ул Өязе буенда колхозның бер дигән яшелчә һәм жиләк-жимеш бакчасын булдырачак. Самавыр кадәр карбызлар, ат башы кадәр татлы кавыннар, беләк кадәр кыярлар, йодрык кадәр алмалар, бармак башы кадәр карлыганнар, куражиләкләр үстерәчәк. Дөп-дөп. Тукта, тукта. Өйләнәчәк тәме? Балалар да үстерәчәкме? Кит, юләр. Нинди балалар үстерү ди тагын? Ул бит әле үзе бала! Ә менә аның яшьтәше диярлек булган Разия бала түгел идеме ни? Ул менә кияүгә чыкты! Аны бүген жан-фарман китереп каядыр Ашказар буйларына алып та китәчәкләр... Тукта, тукта. Нинди туй? Разия шулай үскән дәме инде?! Картинәсе әйтмешли, өлгермәгән дәмени?! Димәк, ул анардан алда барган, алдынгы кеше? Беренче сорт, беренче кавемнән?!

Ул кәрәк сабына таянган хәлдә башын артка чөйде дә, тешләрен күккә ыржайтып, гадәти булмаган каһкаһә белән көлә башлады:

—Ха-ха-ха-ха-ха!..

Чыпчыклар өркеп һавага күтәрелде.

Бәгърем, көрәген ташлап, чокыр читенә тотынды һәм көлүен дәвам итте:

—Ха-ха-ха-ха-ха-ха!..

—Шашмагансындыр бит, канатым?

Болдырдан картинәсе кычкыра икән. Ул аңа шулай "канатым" дип эндәшә.

—Бисмилла әйтеп, як-ягына төкерен!..

Каһкаһәнең соңгы авазлары кинәт шинде һәм сүнде:

—Ха-ха...

Чынлап та, шашкан мәллә ул? Монда чынлап та уйга калырсың!

"Өйләнү—сөйләнү түгел",—диләр. Нигә алай диләр? Өйләнмичә сөйләнеп, сөйләнмичә өйләнеп булмыймыни? Өйләнү өчен нәрсәләр кирәк? Егет кирәк, кыз кирәк. Бу—бер. Егеткә дә, кызга да мәһабәт буй-сын кирәк. Баш кирәк, әлбәттә. Аннан, ызначитсы, йөрәк кирәктер. Өйләнү дигән нәрсә ике ятып, бер тапкыр да күнеленә кермәгәч, димәк, Бәгъремдә аларның берсе дә юк булып чыга түгелме?! Ә менә кичә генә чикерткә кебек чекерт-чекерт сикеренгәләп йөргән Разияда алар барысы да бар булган булып чыга, имеш.

Буй-сынны, баш дигәнне тотып карап була. Ә менә йөрәк белән нишләргә? Аны бит тотып карап булмый. Нәрсә ул йөрәк? Бәгърем моны тәгаен генә әйтә алмый шул. "Йөрәк" дигәндә аның алдыннан тиен кебек ниндидер йомшак йомгак тәгәрәп киткәндәй була. Бу йомгак каршыдагы таллыклар артына кереп яшеренә, анда шундук йөзен зәңгәр шәл белән каплаган кызга әверелә дә, ягымлы гына итеп эндәшә, имеш: "Мин—мәхәббәт... Мин—ярату... Мин—сөю... Мин—гыйшык...",—ди. Гүяки Бәгърем өчен аларның соңгы өчесе мәхәббәткә кадәр барып житәргә тиешле булган өч баскыч, өч фасыл, кешенең эчендә аның үзеннән бәйсез яшәгән өч аерым кеше иде. Әйе, яратусыз, сөюсез, гыйшыксыз-мәхәббәтсез кияүгә чыгып булмагач, димәк, алар барысы да кешенең үзендә яратыла торган шаукымлы сихәтләр. Менә Бәгъремдә әлегә аларның берсе дә юк. Бәгърем дигән кешенең эчендә әлегә Сөю, Ярату, Гыйшык дигән кешеләре яратылмаган. Гашыйклар аңа калак сөякләреннән канатлары үсеп чыккан фәрештәләр булып сурәтләнә. "Гашыйклар барысы да канатлы халык, аларның канатлары күренми генә,—дип нәтижә ясады егет.—Алар жир буйлап түгел, жир өстеннән бераз гына югары очып йөри торган шаукымлы затлар..."

Гашыйк булган кызың синең өчен үләргә әзер торганда гына жир өстеннән очып йөреп буладыр ул. Кичә генә син бөтенләй белмәгән кеше сиңа бүген гашыйк булсын да, синең өчен шундук үләргә әзер торсын, диген, ә? Менә нинди булырга тиеш ул чын мәхәббәт. Бик кызык бит бу! Бәгъремнең хәтеренә моннан биш-алты ел элек караган "Падение Берлина" дигән кино килеп төште. Әй, аптыраган иде ул чакта. Ничек аптырамыйсың, ди, Гитлерның сөяркәсе Ева Браун дигән туташмы, ханыммы шунда, камалышта калган Берлинның таш базында бер-ике сәгатьтән агу эчеп үләчәген белә торып, Гитлер белән никахка керә. Моның өчен никадәр яратырга кирәк, әйеме? Абау, тәннәрең чемердәп китәрлек, әйеме? Бу бит инде киного төшү өчен генә шулай эшләнмәгәндер, әйеме?..

Бәгърем бармак чуклары белән үзенең калак сөякләрен капшап карады. Канатлар үсмәгән иде әле. Әмма ул моның өчен үкенми дә, гарьләнми дә. Чөнки мәхәббәт ашыктырмыйча үзе килә торган могжиза булырга тиеш. Баш житмәс могжиза. Гарьләнүен гарьләнмәсә дә, аптыравын яшерми. Димәк, Разия Бәгъремгә сиздерми-нитми генә шул канатларга ия булган, ул аларны төннәрен ниндидер шифалы сулар сибеп, яшерен догалар укып үстергән; димәк, Разия, аның балачак дусты, үсмерчак ахирәте—Разия кадерлекәе Бәгъремгә күрсәтми-нитми, әйтми-нитми генә мәхәббәтле булып өлгергән?! Ә менә Бәгърем әле булса мәхәббәтсез кала килә?! Кара әле, бик кызык, бик мәрәкә икән бу кыз-кыркын халкы! Яшерен генә түл жыя, яшерен генә өлгерә, яшерен генә чәчкә ата, яшерен генә канат чыгара

һәм...яшерен генә ярәшелеп, синең борын астыннан гына китеп тә бара! Син исә каласың лышык-лышык танавыңны тартып!..

...Разия кияүгә чыкты да куйды шул. Могҗиза түгелме? Бәгъремне гүяки аяз көндә яшен сукты. Алар бит әле кичә генә бер агачның ике ботагын, бер үләннең ике кыягын, бер атның ике күзен тәшкил иткән, аларның кайсысы малай, кайсысы кыз икәнлеген аерып та өлгермәгән, әле һаман балачакларында каз көткән ике җанның берсе—Разиясы, әйе, шул кара чутыр Разиясы кияүгә чыкты да куйды. Имеш, унҗиде яшен тутырган икән. Нигә, тутырса ни! Тутырса, ташлап китәргә дигәнмени? Ә менә Бәгърем әле уналтынчысына чыгып кына маташа, имеш. Бара шул. Әмма ул авылын беркайчан да ташламаячак!

Сез, җәмәгать, игътибар гына итегез: нindидер эт алып олаккан Ашказар буйларындагы нindидер Аллагуәт авылы тарафларыннан күрмәгән-белмәгән, нindидер почык күзле бер фиргавен токымы нindидер бер чалыш тәпиле яучы җибәрә дә, монарчы күрмәгән-белмәгән кызны алып та китә!.. Иң кызыгы шул бит әле: китә кыз бала, ике дә уйламыйча, үзе теләп китә. Әле курчакларына күлмәк тегәргә тиешле кыз, кичә генә суга барган сукмакларын, чишмәләрен, җиләк җыеп үскән болыннарын мәңгелеккә калдырып, китә дә бара. Бөтенләй белмәгән-күрмәгән якка, белмәгән-күрмәгән авылга, белмәгән-күрмәгән кешегә бит. Шул кадәрле көчле микәнни бу мәхәббәт дигәннәре дә, шул кадәрле татлы микәнни бу кияүгә чыгу дигәннәре?!

Ә син менә көзге яңгырларда бьжыган гөмбә кебек торасың да каласың каеннарың арасында. Гүя күрмәгәнский дә, белмәгәнский. Нигә ул чакта бу кыз бала үзе белән чишмәләрен дә, Бәгъремен дә алмый?

Менә шулай тормышның иң гади, иң катгый канунын аңлый алмый өзгәләнә иде Бәгърем. Бер-береңне белми, йөрешми-күрешми торып, кияүгә чыгып була микәнни, дип аптырый иде ул. Аннан нindидер озын колак Разия киявен мөкиббән китеп яратмый, ә бары тик "ошата" гына, яши башлагач берегеп китәрбез әле, дип әйтә икән дигән сүзләр дә житкереп алган иде. Бу нәрсә аның бавырын тәмам ачытты: әллә шулай яратмыйча да "яшәп киту" мөмкин микән?

Бәгъремнең гармунда уйнавын ярата ул Разия. Уйнап та җибәрә, Разия челт-челт китереп күзләрен йомгалый да башлый. Нигә шулайдыр инде. Моң дигән нәрсә ул бер Бәгъремдә генә түгел инде. Ул һәркемдә бар. Гармунның үзендә дә бар. Гармун дигәнең кем кулга алса да моңланырга гына тора бит ул. Телләренә басу белән яшен сыта. Дөресен әйткәндә, Разия гына дәртләндерде аны гармунчы булырга. "Сугыш авылны гармунчысыз калдырды, әйдә, безнең буынның гармунчысы бул!" дип тәкърарлады ул туктаусыз. Әллә чынлап, әллә юри, "Шәп уйныйсың!"—дип мактады да мактады. Йөккә мендерде. Бер йөккә менгәч, кайсы гармунчының төшәсе килсен? Ә менә беренче көйләрне аңа шахтадан алып кайткан тальянында Карамысла Рәис абыйсы өйрәтте. Кушаматы шундый аның. Ундүрт телле, күрегенең алгы ягына ак буяу белән ромбик төшерелгән гармун әле дә бар ул. Авыл вичырларында Рәис абый уйнап җибәрү белән әнә шул ак шакмактан чәчрәгән нурлар бар тирә-якны яктырта, малайгынам. Көмеш телләрдән коелган моңнардан кыз-кыркынның аслары күл була, мин сезгә әйтим.

Гармун дигәне төшләренә керә, моны тешләренә сылаша башлады Бәгъремнең. Ул, ничек кенә булса да үзенә гармун алырга тиеш иде. Әчтәт Минәхмәтенә рәхмәт: унике яшьлек малай кисәген ялланып урман кисү өчен үз бригатына алды. Стәрлебаш ягындагы Ново-Николаевка урманнарында ай ярым буе черки ашатып, урман кисте, агач ботады, ботак ташыды ул. Учына сайрап торган житмеш сигез сум акчаны да төшерде. Кайтышлый Мулла-Гөлем авылына туктап, гармун ясау остасы Мөстәкыйль абзыйсыннан култык астына унике телле, шыңгыр бакалы тальян да кыстырып чыкты. Калган егерме сигез сумына картинәсенә бумази күлмәклек, бер кила каһвәле кәнфит тә алды. Унике чакрым арада унике тапкыр туктап уйнап карады ул гармунын. Туган Колтамагына арып-талып, сераеп түгел, ә башын югары чөеп, хәрби җинүче адымнары белән кайтып керде. Гармун бит ул, җәмәгать!..

Беренче эш итеп ул гармунының күреген Рәис абыйсыныкы кебек ак шакмаклы итеп буятты. Күрекне сузгач, күрек кабыргаларының кара өслегендә агарып яктыра бу шакмак. Күзгә төртсән күренмәс карангыда да күренә ул. Рәис абыйсы да яратты аның гармунын. Уйнап та карады. "Гармунын настоящный күренә, гомерле булсын",—диде дә көтелмәгән киңәш бирде: "Син яңа көйләр өйрәнәм дип гел генә мина чапма. Иң мөһиме—мин сине уйнарга өйрәттем. Көйләрне үзең өйрән, үз моныңны үзең эзләп тап. Гармуныңны кутәр дә, мунчага сыпырт. Чын гармунчы мунчада туа".

Ифрат та мач булып чыкты бу киңәш. Мунча ләүкәсенә шытыр-бытыр килеп "Ком бураны", "Корт чакты"лар белән менгән Бәгърем озак та үтми аннан "Җанкай-җанаш", "Кара урман", "Вәсби-Камиләкәем"нәр белән баеп төште.

Үзе моңлы булгангадырмы, белми, нәрсәдәндер, моңлы уйныйсын диләр иде ана гармунны. Әмма моңга тирәнрәк кергән саен ул тизрәк арый кебек, күрәсең, моң аның йөрәгенә төшә дә, татлы итеп талый ...

Өч ел эчендә күрмәгәне калмады тальянның. Ташуда да акты. Ындыр табагында бушаткан иген астында да калды. Колхозга яңа рәис булып Мәскәүнең үзеннән үк килгән Хрущев "утыз меңчесе"[1] Айсин абзый аны кырандасы белән дә таптатты. Хәзер юк инде Айсин. Колтамак халкының башын ике ел чамасы кангыртты да, үз башын алып олакты ул. Әллә нинди әкәмәт капма-каршылыклар төене иде ул бәндә: танкка кылыч белән каршы бара торган бер комиссар инде шунда. Ул адәм затына балык кебек ниндидер кызыл күз белән кылыйлатып карый. Белеме белән дә, һөнәре белән дә ат духтыры икән. Аны өлкәннәр фронтка барып житмичә, кайдадыр Рязань тирәсендәге райком мич башында танклар шартлатып майор булган дип тә сөйлиләр иде.

Былтыр урак өстендә булды бу вакыйга.

Ындыр табагына икенче эсминәгә эшкә чыккан яшьләр басудан игеннен агылып килмәгән сәгатен чамалап, булмаса бераз селкенгәләп алыйк, дип клубка төшеп, биешә генә башлаганда кулында зәһәр камчысын уйнатып, Айсин килеп кермәсенме!

Усак яфрагы сыман күкрәгендә саргайган ике медален урын житмәгәндәй кителенең ике як түшенә таратыплар таккан бу. Галифеләрен урамга да сыймаслык итеп жилфердәткән.

Телеграф чыбыкларындагы чыпчыклар сыман тезелешеп утырган яшьләрне чыр-чу китереп, авызларыннан төкрекләрен чәчә-чәчә, камчысы белән каезлый башламасынмы!

—Ындыр табагында иген череп гнить итя, ә сез терәлләлләм?! Адя, марш моннан!..

—Тукта, абзый, иплэп,—диде урыныннан кутәрелә биреп Бәгърем.—Биредә ат абзары түгел!

—Азбар гынамы! Сарай!—дип тартты ул Бәгъремнең жиңеннән.—Адя, марш!.. Әрмийски парядык!

—Клуб бу. Клуб—ул совет халкын тәрбияләүдә...

—Әле син мозга сатасын?—дип жикерде Айсин. Аның күзләре каш өстенә сикергән иде. Ул камчысы белән берне тальян күрегенә тамызып алды.—Циткә бас, уняштан туган!.. Әрмийски парядык!..

Разия аларның арасына керде.

—Сезнең яшьләрне биюдән тыярга хакыгыз юк!

Айсин аны этәреп жибәрде. Кемгәдер орынып булса кирәк, башыннан фуражкасы очып төште, баш түбәсендә авыр хәрби фуражка салган бөжра эзе генә торып калды.

Бәгъремнең эче кайный, айкала иде.

Ул карашын кая куярга белми түбәнгә юнәлтте. Айсин аягының баш бармагы янындагы сөяле, хром итеге эченнән башмак тоягы сыман бүлтәеп тора.

[1]Сүз КПСС Үзәк Комитеты Беренче Секретаре Н.С. Хрущев башлангычы белән илленче еллар уртасында колхоз-совхозларга эшкә жибәрелгән утыз мең партия вәкиле турында бара. *(Автор искәрмәсе.)*

Ниһаять аларның күзләре очрашты.

Айсин аңа балык кебек кызыл күз белән чекрәеп карый иде.

Гармун күтәргән үсмер ике медален ике як күкрәгенә таратып таккан ат духтыры алдында учка кунган сандугачны хәтерләтә иде.

—Мин уйнаштан туган түгел...—диде үзен чак кына тыеп торган Бәгърем.—Син ул! Бу хакта кичә ырадиудан әйткәннәр. Бүген кабатлаганнар...

Айсинның күзләре маңгаена сикереп, әллә ничә тапкыр әйләнеп чыктылар.

Ул Бәгърем тирәсендә өерелә башлады.

—Бакцы, нәстә сүли-и-и? Минне аскарбляdь итәсен! Мин синне авылдан цеберткән, ызбанны зимерткән!—Ул бер омтылыш белән гармунны умырып алды һәм тышка томырылды.—Зиде бабаңны таныткан, авылдан цеберткән!.. Әрмийски парядык!..

Моның юньле бетмәвен сиземләгән яшьләр сарык көтүе кебек дәррәү кузгалып ишеккә ташланды. Иңендәге өзелеп төшкән гармун каешы һәм Разия белән башка бер яклаучысыз калган Бәгърем дә тышка чыкты.

Клубта ут гөлт сүнде. Күктәге йолдызлар тагын да эреләнеп яктырды. Тышта август азагының пар җиренә көзге арыш чәчә торган куе караңгы, әмма йолдызлы-айлы төне иде.

—Вот-та сина гармун!—Күзләре аларган Айсин тальянны капка төбендә тоягы белән җир төйгән айгыр астына ыргытты.—Пущщай поет!.. Уборкада гулять итмәссен!..

Ала каз кебек каралып-агарып һәм каңгылдап тояклары астына барып төшкән тальяннан өркеп, айгыр да күзләрен алартты һәм кырандасны алып олакты. Арткы тәгәрмәч астына туры килгән гармун кыр казы кебек соңгы мәртәбә каңгылдады да тынды. Аның күреге нәкъ ак шакмагы уртасыннан урталай өзелгән иде...

Бәгърем күзләрендә шул минутта яшьтән яшен яралды. Ул шуннан соң елый алмый—яшьни генә ала.

Тальянның өзек гәүдәсен култык астына кыстырып, келәт янына менде ул. Тешен кысып булса да төне буе триерда иген җилгәрде.

Шунысы кызык, ул нишләптер Айсинга кинә сакламады, үч тә йөретмәде. Моңсыз кешегә үпкәли дә, үч тә тота алмый иде Бәгърем. Кызгана гына белә иде.

Тальянга килгәндә, төзәттерде аны Бәгърем. Шул ук Мулла-Гөлемдәге гармун мачтыры Мөстәкыйль абзыйсына, көзге уңыштан биш пот бәрәнге хакына, эшеннән аерылмыйча, төнен барды да, яңа күрек алыштырып, таңында әйләнеп тә кайтты.

—Кайгырма,—диде Мөстәкыйль абзыйсы.—Тальяныңның көмешенә зыян килмәгән. Мин аның телләренә тагын да бераз көмеш сипкелләдем. Син тирә-якта бер дигән итальянчы булачаксың, парин. Сукыр Сәгыйтьтән дә арттырачаксың...

"Сукыр Сәгыйть" күршеләрендәге Яңа Ишле авылыннан атаклы гармунчы. Бар, җиткерерсең җиткерми ни Сукыр Сәгыйтькә!

—Нигә "итальянчы"?—дип сорады аптыраган Бәгърем.—Тальянчы түгел?

—И-и-и, син әле шуны да белмисеңмени?—дип аптыраган булды Мөсәкыйль.—Кара, син бигрәк тә надан икәнсең, парин. Тальян безгә румнар, германнар аша Италия дигән җирләрдән килгән. Башта ул татарларның хәлен белим әле дип итальян булып Донбасс шахталарына төшкән дә, аннан тальян булып җир өстенә чыккан. Шуннан гына таралган ул безгә, татарларга, тальян булып. Ышанмасаң, үзең укып кара. "Кызыл Таң" гәзитәсе дә шулай дип яза...

Очып кайтты егет Мулла-Гөлемнән. Аякларын җиргә тидермичә, гармун очыра иде аны бугай. Юләр дисәң дә юләр инде ул: бар тирә-якка сызылып таң ата, ә ул Карлау Башы яланы түбәсендә, аннан Кыңгырау Чишмә буйларында, кыскасы, кайда тели, шунда туктап, гармунында сыздыра...

Баштарак Бәгърем Мөстәкыйль абзыйсы сөйләгәнгә ышанмыйчарак йөргән иде. Ниткән итальян итальяны булсын инде ул татар тальяны?

Тальян ул мәңгелектән татарның уен коралы булган, чөнки ул, ягъни мәсәләң, тальян—"тал"дан, "тал жан"нан алынган, чөнки Италиядә безнең Өязе буйларындагы шикелле көмеш таллар юк. Һы, әйтерсең, татар мондый уен коралын тудырырга үзе сәләтле түгел. Әйтерсең!.. Безнең халыкның гомергә шул инде аның: башкада, ягъни Шаляпинда, күрсә—котлы булсын, үзендә, ягъни Сәйдәштә, күрсә—каян алдың?

Егет ачуыннан күрәген дөпелдәтеп, үзеләнеп кызара башлаган мәтегә кадады, әрекмән арасыннан пыяла чирекне чыгарды һәм, башын артка аударып, әйрән эчә башлады.

Нинди матур бүген һавалар!

Күк йөзе чәчәк аткан житен басуы кебек жете зәңгәр икән, ләбаса. Бу жете зәңгәрдә ак мамык эскертләре булып болытлар йөзеп йөри икән.

Нинди матур аның туган иле!

Туган нигезе, картнәсе, шундый киң күңелле авыл халкы, ерып чыгалмаслык урманнары, киң иген басулары, якты чишмәләре, инде менә килеп, күз карашларына да сыеп бетә алмаслык ап-ак болытлары булган кешене ятим дип буламы? Бардыр ул ятимнәр, ләкин тик Бәгърем түгел!

Ул тавышсыз-тынсыз гына жырлый, бармаклары зиһененнән генә гармун басмакларыннан йөгерә иде.

Көтмәгәндә ул кычкырып Тукайны укый башлады:

Зурмы?—дисәң, зур түгелдер, бу авыл бик кечкенә;
Халкының эчкән суы бик кечкенә—инеш кенә.

Анда бик салкын вә бик бик эссе түгел, урта һава;
Жил дә вактында исеп, янгыр да вактында ява...

Чокырының тирәнлеге кендеккә үк якынлап бара түгелме? Арытып та килә. Әнә, аның күз алдыннан нindидер кызыл черкиләр очып уза. Әллә аның канын эчеп шулай корсак күперткәннәр, әллә күзгә генә шулай күренә...

Куандырганы тагын да шул булды: Бәгърем гармуны белән Рәис абзыйсының гармуннарының яңгырашы бер-берсенә охшаган булып чыкты. Бәйрәм кәнсиртләрендә алар еш кына бергә парлап уйныйлар. Әле менә үткән май бәйрәме кәнсиртендә "Ай, былбылым" белән "Көймә килә"ләрне шундый итеп урып салдылар, халык аһ итте.

Бәгъремнең башына життем дип уйлаган шул ук гармунында уйнаганын белсә, Айсин нишләр иде икән? Гафу үтенер иде микән? Ай-һай, ай-һай. Айсин дигәннән. Килешә алмады ул халык белән. Китеп барды "утыз меңенче" комиссар. Безнең халык шундый инде ул, аның үз ягына ятмасаң, сине бөгә дә сала. Хәзер ул халык дигәнең үзе дә аңлый: бу якның гадәтләрен белмәгән, чыннан да яхшы эшләргә теләгән Айсинга һич кенә дә жинел булмагандыр. Кайвакыт кызганып та куялар бу партиянең чираттагы корбанын. Кызык телле һәм холыклы, үз бурычын үтәр өчен букка да кереп барган беркатлы, эчкерсез кеше иде ул. Шул беркатлы эчкерсезлеге аркасында кыен хәлләргә дә кала иде. Ачыла алмады ул монда. Аннан еллары нинди булды бит аның. Сталин бабай үлгәннән соң, авыл тарихында сабантуйларны бары тик Айсин килгәч кенә үткәртми башладылар. Хәер, ул югарыдан, халык әйтмешли, "Крючок" бабайлардан, төшкән булгандыр инде. "Халыклар дуслыгына зыян китерә",—имеш. Быел да үткәртмәделәр. Ул ниткән "халыклар дуслыгы" икән? Колтамакта да, барлык колхозда да татарлар гына яши дә бит, югыйсә.

Кайчагында Сталин бабасын сагынып та куя Бәгърем. Аны хәзер хурлыйлар, әлбәттә. Хурлый диме?! Алар бит Сталин бабалары белән жинделәр, Сталин бабалары белән беркемнән дә, бернәрсәдән дә курыкмадылар. Бәгъремгә килгәндә, ул хәтта дөм караңгы төнге мунчага да Сталин исеме белән генә бәреп керде. Әйтик, бәләкәй чагында картинәсе онытылып калдырган тасын, йә булмаса комганын алып кайтырга дип аны төнлә мунчага жибәрсә, ул тәүдә ишекне каерып ачып "Сталин!" дип кычкыра, гүяки граната ыргытып, ләүкә астындагы жennәрне түшәп салганнан соң гына, мунчага атылып керә иде. Гармунда уйнарга төнге

мунчаларда өйрәнә башлагач бу гадәт аеруча ярап куйды Бәгъремгә...

Житмәсә, Айсин гомергә дуңгыз күрмәгән Колтамакка үзе белән егермешәр имчәге булган өч баш ана дуңгыз да алып килде. Мона кадәр мыркылдык күрмәгән халык Сәми картларның ташландык яткан саман өйләрендә мыркылдап яткан чучкаларны карарга килә һәм сасы истән танауларын кысып кире йөгерә иде. "Мин чучкага нераунадушный, минем чучкаларга сабый чактан ук ыслабыс, чучка фермасыз низзя" дип хатын-кызларны өйдән-өйгә чыркылдата-чыркылдата яңа оешып килгән чучка фермасына куа иде Айсин. Тегеләр аннан төн буе ком белән ышкып кулларын юа. Бәлки Айсинның "чучкага ыслабысы" да шул "Микита Крючок" бабайлардан килгән булгандыр әле...

Әйе, эчкерсез ташбаш, сирәк ташбаш иде Айсин. Колтамакнын ул "хәлен белешергә" өлгергән үрге очы аны "әрмийски паррядык" дип атады. Хәл белешергә үзенең хәле житмәгән түбәнге оч ана "олылап" "Дуңгыз Иваныч" дигән ләкап чәпәде. Гыймакай бабай әйтүенчә, ул үзе дә шул "паррядык" корбаны булды. Аны еш кына мәзәк итеп искә алалар. Шулай, авылга килгәч тә, райком кушуы буенча йорттан йортка хәл белеп йөри бу. Мондый төчелекне күрмәгән халыкның күзе маңгайга менә, йоны киредән торып тырпая. "Хәл белүчедән" кызык табып ләззәтләнә болар. Беренче итеп ул авыл башындагы Кылтайган Сабирга керә. Имгәнгән инбашын канаты сынган каз кебек бераз сулга янтайтып, сузылып кына басып тора икән Сабир.

—Халегез ницек?—ди Айсин.

—Шөкерле-бөкерле—бертөрле,—ди Кылтайган.

—Улыцы нәстя?

—Янбашымны әйтәм,—ди Кылтайган.—Чана табаны бөккәндә станга тыгып инбашымны тарттырдым.

—Атя, шылай үзен самоличны тыктын да тарттырдын?!

—Шулай шул,—ди инде кылтая да башлаган Сабир.—Бик кызыксынсаң, әйдә, синең янбашыңны да тарттырып бирәм!..

Шулай ди дә, өенә керә дә китә.

Аннан ул Зимагур Зиннәтуллага юнәлә.

—Халегез ницек?

—Кешедән хәл сораганда кулыңны кесәңнән чыгар,—ди Зиннәтулла.—Нихараша...

—Ницөн?

—Кесәңнән чыгарып, берәр төргәк акча бирерсең кебек,—ди Зимагур.—Аннан синең белән мәжлес корасы булачак...

Бу авылда жыен сукбай-сәрхүш, сәер мәзәкчеләр генә яши икән, дип уйлый башлаган Айсин медальләрен ялтыратып Көнчел Әгъләм ихатасына үтә.

—Хәлләр бик тә хөрт,—ди танавын салындырган, иренен сәлендергән Көнчел.—Әле син ишетмәдең дәмени?!

—Нәстя?—ди коты очкан Айсин.—Адя, сүлә шибык![1]

—Мин булганда печән белән, күршем булган бичәм белән!

—Китце!

—Иске йортта унбер ел яшәп, сүзгә дә килмәдек. Яңа йортка да күчендек—хатын азды!

—Китце!

—Кара тавыштан чыккан юк!

—Китце!

—Син дә минем бичәм артыннан себерелергә кермәгәнсендер бит?!—дип кычкыра аңа яңа рәис икәнлеген дә ишетеп өлгермәгән Әгъләм.—Бар, чыгып тай моннан, мунча төкрегеннән яралган нәрсә!

—Юк-юк, боже паси!—дип чыгу ягын каера Айсин.—Мәтри аны, ызбагызда әрмийски паррядык булсын. Бәхетле катыгыз![1]

—Бәхет ул малай түгел, аны тотып карап булмый!

[1]Ш и б ы к—*("Шибко"дан алынган)*—тиз.

Ниһаять Мәнге Тәшрифун Мөхлискә барып керә бу.

Мөхлис бер ноктага караган да катып калган, имеш.

—Нәстя югалттын?—дип сорый Айсин.

—Кичә башымнан бер шәребем төшеп калган, шуны табалмыйм, —ди хужа.—Әзләш әле.

—Шарик?!—дип кычкырып жибәрә Мөхлисне аңламаган Айсин.—Ышту за Шарик тагин?!

—Эт!—ди Мөхлис тегене үртәп. Аннан эт булып өреп, сикеренә башлый.—Һау—һау! Һау-һау-һау!..

—Мин кочыкца талашуцы[2] адям тигел,—ди икән Айсин.—Мин сезгя яны персидәтель. Вот-та!..

—Бәй-бәй, синмени әле ул,—дип кабынып китә Мәнге Тәшрифун.—Синен кебек персидәтель булмады, булмас һәм булса да кирәге юк!..—Черек тешләрен ыржайтып көлә-көлә Айсинның кесәләрен капшый башлый.—Мин синнән бер бай баш төзәттерүче көткән идем! Ха-ха-ха!.. Ә син персидәтель генә икәнсең... Көтеп көтеп кунагың килмәсә, көтеп-көтеп хатының үлмәсә, шуннан да аянычы юк, малайгынам!..

Тәшрифун Мөхлистә туктатты үзенен хәл белешүен Айсин. Ары таба теләге дә, жегәре дә сүнде Үзәк Комитет жибәргән комиссарның. Ике елга якын халык миен изгәннән соң тайды ул моннан. Шул ук Үзәк Комитет, имеш аны Бәгъремнәрнең Өязе буендагы Буденный исемендәге колхозыннан кайдадыр Ашказар буендагы Ворошилов исемендәге колхозга күчергән. Кемгә кирәк инде аның кая китүе. Иң мөһиме—котылдылар. Колтамак урынында калды. Әмма Айсин, шул Айсин күреген өзгән гармуны исенә төшкән саен Разия да исенә төшеп бәгърен өзә Бәгъремнен.

Их, беләсе иде ничек була икән ул кияүгә чыгу һәм кәләш алу!

Егет тирән итеп уфырды. Разияның чәчләре ак сызык калдырып, бүген дә уртадан ачылган, сул як битендәге уймак чокыры бүген дә елмайган саен чокырая, алтынсу сипкелләре бүген дә сизелер-сизелмәс кенә таралып ята микән? Әллә Разия хәзер бөтенләй елмая белмиме? Әллә киресенчә авызын жыя алмыймы? Килен! Разия килен! Исәнме! Бәгърем аны күнеленнән генә үчекләде. Бәгърем нәзек билләрен тагын да нәзегәйтеп килен-киленчәк алъяпкычын буган, яулыгын колаклары өстеннән генә кыеп, ничектер очыртып бәйләгән Разияны күз алдына китерергә тырышып кеткелди башлады. Кил-лен, имеш. Кет-кет-кет. Разияның кияве, имеш. Кет-кет-кет. Бәгъремнең ул кияү-баланы күз кырые белән бер генә күрәсе итте һәм—яратмады. Яратмады һәм вәссаләм. Кет-кет-кет. Өязебаштан килеп йөри торган Имиле Чуаш кебек жилсенгән йөзле, зур колаклы, юеш, жепшек, пычкылдык, Почык күзле, бер оешмаган нәмәстәкәй шунда. Ияге дә ниндидер дүрт почмаклы. Бу аның теш казнасының азык чәйнәүдәге мөмкинлекләренең чиксез булуын раслый.

Ә менә Разия өчен ул жир шарында иң чибәр кеше ди. Авылда шулай сөйлиләр. Шулайдыр. Шулай булмаса, кияүгә чыга диме кыз кеше. Кызлар бит алар кызык халык: акыллымы дип сорамыйлар, чибәрме диләр. Кеше утырып елар чакта көләләр. Әгәр Разияның бу кешегә кияүгә чыгуы турында уйланса, бөтен жир шары утырып елар иде, биллаһи газыйм!

Бәгърем үз күзләре белән күрде Разияның авызын жыя алмыйча көлгәнен. Шул кияү дигән ишарәте белән урманнан житәкләшеп кайтып килә иде. Нәрсә, житәкләшмәсә, адашыр иде микәнни? Агач мылтыктан атасы килеп китте Бәгъремнең хөрәсән кияүнең түшенә. Шул минутта күрше кызы, якыннардан якын булган, жил-яңгыр тидермәгән, салкыннарда жылыткан Разиясы аңа ниндидер чит-ят кеше булып күренде. Разия бу жавапсыз адымга бару өчен ни өчен Бәгъремнән, аларның серләрен белгән таулардан һәм яланнардан рөхсәт сорамаган? Разияны бит алар да үстерде! Нәрсә, ул Разияны көнлиме? Юк, Алла сакласын! Йөрегән кызы да түгел, ләбаса! Аның әле кызлар белән гомумән дә йөргәне юк. Ул Разияның туен

---

[1]Катыгыз—бу урында "яшәгез" мәгънәсендә.

[2]Кочыкца талашуцы—көчек кебек өрүче. *(Автор искәрмәләре).*

да озатырга бармас иде гармуны белән, тагын да шул авылдашлары, гармунчы булу хакына гына бара...

Егет казуыннан туктады. Чокырының тирәнлеге күкрәгенә житеп килә иде. Тирәнлекнең артыгы кирәкми. Тирәнлекнең һәммәсе таманча гына булырга тиеш. Кешеләрнең үзләрендәге тирәнлек тә. Көрәк сабына таянып, ул бер омтылыш белән чокырыннан сикереп чыкты. Көрәкнең өндәү билгесен хәтерләтеп балчыкка кадалган сабы һәм аның үз гәүдәсе дә бөтенләй дип әйтерлек күләгәсез иде. Кояш нәкъ баш очына кунган да, балавыз булып эри. Төш житкән икән.

Елга аръягында кыңгыраулар чынлап куйды.

Егет сискәнеп китте.

Кузгалырга ниятлиләр булса кирәк.

Ул дилбегә бәйләнгән кое чиләген яндавыннан гына чеметеп алып кое янына килде һәм бурага капланып, чиләкне төшерә башлады. Су көзгесеннән ана зәңгәр күкнең ак мамык болытларын башына чалма итеп чорнаган, табак битле, жиз маңгайлы бер кеше карап тора. Әйе, авылда аны юкка гына "Жиз маңгай" дип йөретмиләр икән шул. Аның маңгае чынлап та гүяки сандалда чүкеч белән чүкелгән жиз кебек эзле һәм батынкы икән. Баксаң, теге зур колаклы, тир тозында жепшегән, Почык күзле кеше һич кенә дә Разия кияве түгел, ул үзе икән! Ияге дә дүрт почмаклы, теш казнасы да бары тик азык күшәү өчен яратылган!..

Менә аның буш чиләге шушы чәчләре тузгыган баш, чүкелгән жиз маңгай, шушы табак бит һәм пычкылдык күзләр чайкалган су көзгесенә төшеп килә... Чиләк төбе су өстенә кагылу белән аның йөзе, килеш-килбәте тынычлыгы бозылган су көзгесеннән таралган түгәрәкләргә төялеп кинәйде, таралды һәм кое бурасына гына сыеша алмый, кайдадыр билгесезлеккә этәрелеп юкка чыкты...

Ул коедан күтәргән суын читән буена алып килде. Чабаталарын, оекларын салып какты, кыска жиңле күлмәген дә салып, читәнгә сөйсен сөяп, элэсен элеп куйды да юына башлады.

—Теге Качаган бадарыннан алган күлмәгеңне киярсең, яме, канатым.

Бөкересен чыгарып болдырда кош-кортка болгау болгаткан картинәсе гүяки ана үзе белеп эшли торган эшләрне дә исенә төшереп тору өчен яратылган жан иясе инде. Ул болгауга чемердәп ачыган катыгын күпмерәк микъдарда салу турында гына уйласа яхшырак булган булыр иде дә бит. Югыйсә, аның тавыклары ачы катык эчеп исерә дә әтәчне талый башлый, йолкышлар.

—Теге Качаган күлмәген киярсең дим, ишетәсеңме...

Егет эндәшмәде.

Бәгъремнең кәеф жепселләре киеренке, кан агышы кызу иде. Үлән сөтендә яшәреп һәм елкылдап шомарган тырма тешен хәтерләткән картинәсе, колакка бераз каткан карчык, бәләген шапылдаткан арада сүзләрен өченче мәртәбә тәкърарлады:

—Качаган күлмәген ки. Чалбарың үтүкләнгән. Урындык өстендә.

—Беләм.

—Кем баласы дигәндә, шуның баласы диярләр. Әтиең дә, әниең дә бик ыспай кешеләр иде, мәрхүмкәйләр. Авыр туфраккайлары жиңел булсын. Яна тәпичкеләреңне ки. Спут башындалар.

—Беләм.

Әле быел язгы карага басу белән генә тегелгән малюскин чалбарын, сөлгелек житен тукыма күлмәген, картинәсе әйткән "тәпичкеләрен" киеп алгач, Бәгърем бөтенләй бөтәеп калды. Ул көзгегә карады. Ул элекке халәтенә кайткан Бәгърем иде. Ияге дә дүрт почмаклы, күзләре дә пычкылдык түгел. Нәкъ үзенеке. Чиста кием эченнән кып итеп торалар. Елга аша әллә ат тояклары, әллә күкрәк читлегендә йөрәге дөпелди. Ул арага кыңгырау чыңнары да сипләнеп алгандай тоела. Тальянын култыгына кыстырып чыгып барганда аның юлына яшел үлән тырмый-тырмый яшәреп беткән тырма теше кебек тагын да шул картинәсе калкып чыкты һәм органик химия буенча соңгы дәресләрен бирел алды:

—Бүген иртән көтү куганда Одын Дәйнәпләр тәнгәлендә...

Анын картинәсе, авыл картларына хас булганча, шулай борынгы Миндәлә типтәрләренчә "з" урынына "д" куеп сөйләшә. Элегрәк барлык авыллары белән шулай сөйләшә иде алар. Хәзер казанча чиста "з" белән генә сиптерәләр.

—Одын Дәйнәпләр тәнгәлендә сеп-сбижи эт тидәге күрдем. Мәтри аны, баса күрмә. Эт тидәге яна эрдинкәне дә эт сигәнче ашый ул...

—Беләм.

—Белсән, бик әйбәт, белмәгәнгә бишәр әйт.

Гармунын аркасына ышырып, Озын Зәйнәпләр тәнгәлендә эт тизәгенә басмаска тырышып, Өязе ярыннан чалулый-чалулый Разиялар турындагы басмага юнәлгән Бәгъремне картинәсенен жилдә өзгәләнгән сүзбәйләнешләре озата килә иде:

—Пәйгамбәребед... ахырдаман алдыннан...

Ул яшь таллыклар яшеленә күмелеп, басмадан чыга башлады.

—Дөнъя... эт вә дунгыз тидәгенә батар дигән!..

Кызык та инде бу картлар. Берсе Ахырзаман алдыннан Дәжҗал чыгара, икенчесе дөнъяны эт-дунгыз тизәгенә батыра.

Сукмак буйлап таллыклар мәгарәсенә баткач кына ишетмәс булды ул картинәсенең фетнәви тәкърарларын. Адәм биеклеге булып үскән әрекмәннәр, шау чәчәккә төренеп, зәһәрләрен коеп утырган жете яшел кычытканнар—әйе, Бәгърем үзенең кыска гына гомерендә беренче тапкыр ап-ак кынгырау чәчәкләргә тиенеп утырган кычытканнарны күреп таңнар калды!—арасыннан килде-килде дә, тар сукмак аны Разияларнын тау күтәренкелеге башланган тәнгәлдәге ихаталарына алып керде.

## II

Кайчандыр серле күренгән йорт-жир—бүрәнәләре муртаеп беткән менә бу дүрт почмаклы өй, менә бу уенчык кебек кенә жыйнак келәт, менә бу янтайган читәннәр, хәтта ихатага яртылаш кереп туктап калган менә бу карт өянкеләр дә ана бүген чит-ят иделәр. Көн кызуында пешенеп әлсерәгән, саф сулышлы жилләр көтеп жәйрәгән ишек алдын ул кешене кызганган кебек кызганып куйды.

Күләгәгә бәйләнгән атлар арба-кырандасларга, читән буйларына андамонда салыштыргаланган яшел печән күбәләреннән үлән берәмтекләгәндә, вакыт-вакыт койрыклары белән чәнчеп-чәнчеп, чебен-черкиләрне кугалаштырып ала.Лапас астындагы арбадан бер исерек коданын гәүдәсе аяклары белән сыер ләпәгенә салынып төшкән. Гайрәте изүеннән эчке ыштаннары күренеп тора. "Моны инде озатасы калмаган",—дип авыз чите белән генә елмаеп куйды Бәгърем. Тәрәзә капкачлары яртылаш ябылган өйнең бүрәнәләре аша чишелеп сөйләшкән, көлешкән һәм жырлашкан тавышлар саркыла.

—Син, күрше, нигә алай сонлап йөрисең?—Ике кулына ике чирек ачы бал тотып келәттән килеп чыккан Мәсгуть абзый—Разиянын әнисенең туганнан туган энесе—аны алдан үткәрде.—Разиянын туе бер генә тапкыр була ләбаса!..

Өйнең алгы, аш-су ягы мунча сыман эсселәнгән булса да, тәрәзәләре ябулы кунак ягы ярыйсы гына чамада жиләс иде. Кояшнын тәрәзә капкачлары ярыкларыннан үтеп кергән нур кылычларыннан телгәләнеп киселгән кунаклар—өч көн буе мәжлестән мәжлескә йөреп таушалган, бүртенеп кызарган кодалар һәм кодачалар, балдызлар һәм кайнешләр, кайнегәч, кайнесенел һәм кайнагалар, туй озатырга дип чакырылган күршетирә, авылдашлар һәм туган-тумача идәнгә жәелгән асалы паласка стена буйлап мөселманча, аякларын бөкләп утырып алганнар да, бербөтен булып укмашып, мәжлес корганнар. Мәжлес исә Бәгъремнен кергәнен абайламады да. Әгәр аны түбәндәге, безнен якларда әйтүләренчә, "шәлия табынында" утырган яшьтәшләре Ихсан белән Сабиржан шәйләп алып:

—Әйдә, безнең янга!—дип аваз салмасалар, бөтенләй күрмәгән дә булырлар иде, биллаһи.

Гыймакай бабай исә бу авазны эләктереп алды. Кулындагы яшел чәйнүгеннән ачы бал коеп, хәтеренең начар булуы аркасында чиратны бутый-бутый кунакларны сыйлаган арада:

—Гармунчының буыннары саен мәхәббәт аның!—дип кычкырып җибәрде.—Бирегә үт, урының уртада, малайгынам! Чират кемдә иде әле?

—Үзеңнән башла, Гыймалетдин абзый,—диде Чулак Гамир.—Ялгышмассың. Ялгышкан саен үзеңнән башла, яме!

Берничә ел элек карчыгыннан ятим калган, бүгенге көндә улы-килене белән бергә яшәп яткан карт яшьләрчә тәвәккәллек белән табынның көрәгәчесе булырга җөрьәт иткән, ә?

Бәгъремнең Гыймакай бабасы тәкъдим иткән түргә үрләргә батырлыгы җитмәде. Гармунчының урыны, ул ничек кенә яхшы уйнамасын, ишек катында. Ул кунак сыйлаучылар исәбеннән. Аннан, моң дигәнең түбәннән күтәрелә. Шулай кирәк. Шулай дөресрәк һәм уңайлырак. Ул мичнең казнасына аркасын терәп, Ихсан белән Сабирҗан арасында урын алды.

—Гармунчыга ыштрафнуй, ыштрафнуй!—дип кычкырды кемдер.

Гармунчыны эчерергә тырышу шушы урында тынды.

Разияның әнисе Раһиба җиңги алгы яктан кереп, Гыймакай бабайдан бал тулы ике көрәгә сорап алды, көрәгәнең берсен Мәсгуть энесенә тапшырып, түр башында утырган төп кодасы белән кодагыена атап борынгы көй—"Зәңгәр капка"ны башлады. Аңа Мәсгуть тә кушылды. Бу йола жыры иде һәм кыз ягыннан ата вазыйфасын Мәсгуть абзый башкара иде. Бәгърем бу көйне белсә дә, гармунын тулы хутка яңгыратмыйча, иплe генә итеп арттан озата барды.

Раһиба җингинең мәкаме бик тә матур. Моңы аның ничектер гел генә өзлегеп тора. Ул кышкы озын кичләрдә еш кына Бәгъремнәргә кич утырырга керә һәм алар, җеп эрләгәндә, картинәсе белән бергә җырлыйлар. Бу юлы моң Раһиба җиңги күкрәгеннән чишмә булып чылтырады. Гүяки ирен сугышларда югалткан, дүрт ятимәсен бер үзе үстергән солдатка турысын әйтмичә, читләтеп кенә, шушы җыры белән баласының язмышын чит кулларга тапшыра һәм аны какмау-сукмауларын үксеп үтенә иде...

Казаннардан килгән күк көймә, ай, кода,
Безләр барыбыз да бер төймә, ай, кодагый,
Җыйдым ла җиләк, койдым как,
Бөрлегәннәре берлән, шул.
Без катнаштык кодаларның
Бер дигәннәре берлән шул,
Бер дигәннәре берлән!..

—Лән-лән-лән!—дип күтәреп алды табын.

—Әфарин! Шулай кирәк, Раһиба кодагый!—дип гөрелдәде кемдер өске табыннан.—Әфарин, мин сиңа әйтим! Таг—гын! Таг—гын!..

Безләр барыбыз да бер төймә лә, ай, кода,
Җырлап кына яшик бер көйгә, ай, кодагый!..
Урман алдында куаклар, шул,
Куакларда күп атлар, ай,
Балларга салдык колмаклар,
Җырлашаек, кода, кунаклар, ай!..

Раһиба җиңги белән Мәсгуть абзый көрәгәләрен кода белән кодагыйга тапшырды.

—Әфарин, кодагый, әфарин, Мәсгуть кода!—диде кәефе килеп төп кода.—Амин, шулай булсын!

—Мондый җыр хакына туң агач та эчәр!—Күзләрен, ата каз кебек, бер ачып, бер йомып утырган бер яшь кода, айнып киткәндәй, аек омтылыш ясап, кулындагы көрәгәне тамак төбенә койды.—Әйдә, хатын, син дә калышма!

Ул да булмады, түр яктагы ун почмактан бик тә таныш аһәң ишетлде:

Кыз баланың назы бар,
Ир баланың мазы бар.
Безгә килгән яучының
Түбәсендә тазы бар!..

Табын гөрселдәп көлде.

—Таз булса ни, булсын!—диде Ихсан да сүзгә кушылып.—Тазга таз килми, кем килсен тагын. Без, колтамаклар, барыбыз да тазлар, шулай бит, Җиз Маңгай?

Бәгърем, ачуы килеп, дустының касыгына каты итеп төртте. Сәбәхетдингә ияреп, ул да шаяра, имеш.

—Ни җитмәгән тагын сина? Авылны яманлап утырасың,—диде ул пышылдап кына.

—Мин бит болай гына...

—Болай гына булса, болынга барып сөйлә...

Ә теге такмакны почмакка урнашып, җәмәгать күзеннән читтә шактый кызып алган Сәбәхетдин җырлаган иде. Халыкта аны кыскартып Сәбәкәй генә диләр. Тагын да кыскарагы Сәбәк. Иң дөресе—Сунарчы Сәбәк. Әнә ул, Сәбәхетдин абзый. Озын, очларын майлап бөтергән каратөрек мыегы чак-чак кына күршеләренә тими тора. Һәрвакыттагыча, Мәстүрә җингине үзеннән калдырмаган, әлбәттә. Исерә, кем әйтмешли, чыгырыннан чыга башласа, "Әйдә, карт, кайтыйк, кайтыйк, буласы булды, буявы сеңде",—дип аны юмалап алып кайтып китә аны бу акыллы хатын. Бер караганда бер дә чыгырыннан чыкмый инде Сәбәхетдин. Рәхәтләнеп, тартынмыйча ашый-эчә, чишелеп сөйләшә, исергәләгәнче озын җырулар да җырлаштыргалый. Шунысы гына: исерә төшсә, аның бер кем дә көтми, беркем белән исәпләшеп тормый торган "энҗеләр", такмазалар ыргыта торган гадәте бар. Менә ул әле дә үзенең күңел хәзинәсеннән бер тамчы "энҗе" сен ыргытты:

Ике төркемгә бүлене-е-е-еп,
Маймылла-а-а-ар күңел ач-ча-а-а-а...

Беркем көлмәде. Хәтта ки ишетмәде дә. Бу "энҗе", беренчедән, шау-шу астында күмелеп калды, икенчедән, аны ишеткәннәргә, мәгънәсен аңлау өчен бик тирән агымсуларга карап уйланырга кирәк иде. Бәгърем бик тә ярата Сәбәкәй абзыйсын. Эчкерсез, рыясыз кеше ул. Мәгәр аны алдамасалар. Алдаганнарын тойса—җенгә әйләнә дә куя. Соңгы елларда кышкы сунарга ул Бәгъремне дә алгалый башлады. Әрлән, йомраннарга язгы-җәйге сунар вакытында яратты ул Бәгъремне. Бу вак "малны" тунарга үзе бер дә яратмый. Ә менә Бәгърем белән Ихсан аларны тунарга шулкадәр остарып киттеләр ки, тиреләрен сыдырып кына төшерәләр. Утильчимал җыючы Суфиян картта бер тире егерме тиен тора, җәмәгать, шаяртмагыз. Шуннан җыела ул. Кайчакларда, сунары уңышлы чыкса, ул үзе тоткан җанварлардан цирк күрсәтеп, халыкны шырык-шырык көлдерә. Былтыр, мәсәлән, ана һәм бала торналарны авылга биетеп алып керде. Бөтен бала-чага терекөмеш кебек урамга эркелде...

—Әйдә әле, туган, монавында кунаклап ал да, "Шомыртым"ны сыздыр!—диде Мәсгуть абзый һәм сорап-нитеп тормыйча, аны көчләп диярлек кулыннан тартып, урыныннан куптарды. Ул аны ишек катындагы артсыз урындыкка утыртты.—Тәүдә менә минем шушы җылы кулларымнан монавы көрәгәне тондыр! Дөрес әйтәмме, кодалар?

—Дөр-рес! Дөр-рес булмыйча ни!

—Юк, юк, этәрмә, парин, утырып эчәсеңме, ятып эчәсеңме,—бу көрәгә синеке! Үзе кызып алмагач, гармунчы башкаларны ничек кыздыра алсын?

Бәгъремнең әле моңа кадәр бер тапкыр да эчкәне юк иде.

—Эчмим,—диде ул Мәсгутнең көрәгәле кулын янадан этәреп.—Эчкәнем юк.

—Син—нәрсә?! Разиянын туе бер генә була!

—Эч тә жибәр инде!—дип пышылдады ана Ихсан.—Менә без эчеп жибәрдек тә—шундый рәхәт!..

—Мәсгуть абзый дөрес әйтә,—дип өстәде Сабиржан.—Безнеӊ яшьтиләрдән беренче туй бу, малай!.. Әйдә, үкенечен калдырмыйк!.. Бәлки Разия белән бүтән күрешеп тә булмас. Озакламый армиягә, аннан кем белгән...

"Разиянын туе бер генә була", "Бәлки бүтән күрешеп тә булмас" дигән гыйбарәләр аныӊ бәгъренә гүя утлы шаукым булып утырды.

—Эчмим.—Ул күрәгәне читкә этәрде—Эчмим дигәч эчмим.

Бәгърем "Шомыртым"ны уйнап жибәрде. Мәҗлес үз агышы белән дәвам итте. Кунак кода белән кодагый, жыр эзләп артык җәфаланмады бугай, алар Раhиба кодагыйлары белән Мәсгуть кодаларына артык көчәнмичә генә "Ал булмый, булмый, булмый" дигән такмакны жырлап, жавап күрәгәсеннән котылдылар.

Бәгърем гүя беркемне күрми, бернәрсә ишетми иде. Аныӊ куллары үзләреннән үзләре мәжлес кушкан ызаннарга алып кереп, "Шомыртым"нан "Донбасс"ка, "Донбасс"тан "Идел"гә күчте. Егетне моӊ шаукымы суккан иде. Аныӊ моӊында йөзгән гадиләрдән гади авыл туенда кодалар кодачаларны, кодачалар кодаларны, кайнегәчләр һәм кайнагалар яшь кодача белән кайнешләргә кадәр берсен дә онытмыйча сыйлады. Монда дус та, дошман да юк, ә бары тик тигез туганлык, бер-беренә изге теләкләр генә хөкем сөргән бу даирәдә беркем дә күрә алмаган, күрү мөмкин дә булмаган бер бөек сәхифә ярала иде: ул да булса Бәгърем дигән егет, гармунын күтәреп, үз гадәтләре, үз холыклары белән үз тормышыныӊ яӊа ызаннарына чыгып килә иде...

...Кинәт аныӊ күз алдына тунган ай хасыйл булды. Айныӊ тирә-ягын вак кына күзле челтәр уратып алган. Аларныӊ айлары да әле, үзләре сыман, күп дигәндә беренче-икенче генә сыйныфта укып йөргәндер. Ул ай Разияныӊ кырпак сибелгән чәчләренә ак калфак булып укаланган. Урыны-урыны белән ямь-яшел үлән сикертеп яшәргән, урыны-урыны белән кары да эреп бетмәгән чокыр-чакырлар аша, бер яшелдән икенчесенә сикерәнләп, алар Питырпаул кахуллары жиренә төштән соӊ гына килеп життеләр. Черек бәрәнге артыннан авылдашларныӊ беркайчан да бу кадәр ерак биләмәләргә кармак салганы юк иде. Әйе, ачлык—картинән түгел, йөгертә бирә.

Ә менә күтәреп кайтачак табышлары белән барысын да аһ иттерергә теләгән Бәгърем белән Разия черек бәрәнге уйдыгы эзләп ун чакрымдагы Питырпаулга киттеләр дә бардылар.

Ни дисәӊ дә, кахуллар иркен яшиләр шул. Моннан нибары илле ел чамасы элек кенә Полтава якларыннан татар-башкорт жирләренә китертеп утыртылган хуторчыларныӊ бакча мәйданнары кырык-илле сутыйдан да ким булмас. Ә колтамакларда ул нибары ун-унбиш сутыйдан да артмый югыйсә. Кахуллар черек бәрәнгене үзләре түгел, малларына да ашатмыйлар. Кәлжемәлек бәрәнге күп иде мондагы бакчаларда. Әмма бирми аны кахуллар. Кызганудан түгел, татарны кимсетеп бирмиләр. Ничәмә-ничә тапкыр кыйналып кайттылар колтамаклар Хлебороб, Будяновка кахулларыннан. Берүк күрәкләрен тартып алып, базга гына ябып куя күрмәсеннәр. Разия белән Бәгърем, мавыгып китеп, караӊгыга калуларын да сизмәгәннәр. Кайтыр якка кузгалырга дип торганда гына йөзе белән татарга охшаган бер кахул дәдәй килеп чыкмасынмы! Хәзер үк базына ябып куя дип шыр жибәрде чакырылмаган кунаклар. Юк, татарга охшаган кахул абзыйларыныӊ аларга бары тик ярдәм генә итәсе килгән икән. Сабыйлар үз күзләренә үзләре ышанмады. Кахулда да бар микәнни татарны яраткан кеше? Ул әллә нәрсәләр сораштыра-сораштыра жирне үзе казып, бәрәнге чыгарышты. "Картушка" дигән сүздән башканы белмәгән кунаклар кахул сөйләгәннәрдән бернәрсә дә анламадылар. Аннан, өенә үк алып кереп, сөт белән белән нindидер сары ипи дә ашатты. "Кукрузный хлепец" диде шикеле ул аны. Аннан, ниндидер фикергә килеп, сикереп торды һәм базын ачты... Андагы бәрәнгеме, андагы бәрәнге! Ул куллары белән боталый-боталый капчыктагы черек бәрәнгене чыгарып

бушатырга һәм баздан яхшысын тутырырга боерды, бугай. Барамы инде татар Колтамагынын баласы мондый әрсезлеккә? Ипи белән сөт тә аша, житмәсә, капчык тутырып бәрәнге дә алып кит! Сабыйлар аптырап калды. Бәгърем бу адымга әзер дә иде бугай, Разия гына “Монавы кадәр һәйбәт черек бәрәнгене чыгарып түгә диме кеше,—дип борынын лышкылдата башлады.—Әйдә, ычкыныйк моннан тизрәк, юньлегә түгелдер бу”.

Кахул дәдәйләре нәүмизләнеп калгандай күренде. Бәгъремнен анын күнелен күтәрәсе килде. Әмма анын күнел күтәрерлек бер генә байлыгы да юк иде. Кахул шуны анлап алгандай, кинәт кенә:

—А ти спивати може?—ул жырлап та күрсәтте.—“Широка страна моя родная...”

—Беләм, беләм!—дип кычкырды Бәгърем һәм кешене шатландыра алу шатлыгыннан үзе белгән бердәнбер “урысча” жырны жырлап та жибәрде:

—Жултый, жултый, жуп-жултый,
Жултый пәке саплары.
Мин жултаймый, кем жултайсын,
Килми привет хатлары...

Дәдәйләре эче катып көлә иде.

Көтелмәгән уңышны ныгыту өчен Бәгърем идән уртасында биеп тә алды:

Сербиянка, сербиянка,
Сербияночка моя,
Кичә ыштанын бар иде,
Бүген ыштанын кая?

—Кит, оятсыз!—Разия оялышыннан үпкәләп, анын аркасына сугып алды.—Шундый жыр жырлыйлармы сөт эчергән кешегә?

—Молодцы, хлопци!—диде кахул аларны аркаларыннан сөеп.—Ваши нашим за рупь пляшем. И завтра приходьте!..

Карыннары тук, капчыктагы черек бәрәнгеләренең туңы, жылыдан эреп, арка үзәгеннән саркып төшкән үсмерләр Имәнлек үренә житкәнче бу кахулның һичшиксез татар булуы-булмавы турында бәхәсләшеп кайттылар.

Күк йөзенә сары май булып туңган ай йомарлагы озата килде аларны. Үрне төшкәндә чак-чак кына үлемнән калдылар. Эрегән кар астыннан барлык урманның күпереп калыккан былтыргы яфраклар юрганын бер юлы хәрәкәткә китереп, шабырдатып һәм дөбердәтеп, арттан аларны нindидер гаммәви гөрелте куып килә иде. Алар төн карасында агарып утырган каенны икесе ике яктан шатырдатып кочты. Һәм үзләре дә сизмәстән күзләрен йомды. Дәһшәтле дөбердәү алар турына житкәч кенә Бәгърем күзләрен ачса—ни күзе белән күрсен!—Имәнлек чокыры язгы өегешүгә чыккан ач бүреләрнен янып торган күзләре белән кайнап тора!.. У-у-у, исләренә төшсә, тәннәре өшеп китә!..

Гүя хәзер шушы мәжлес даирәсеннән, анын бүгенгесеннән нindидер утлы ыргаклар күк гөмбәзенә ыргылды, аннан бу ыргаклар Разия чәчләренә калфак булып кайтарылган ай элпәсен, аннан Разиянын үзен дә упкынга өстери башлады... Бәгърем мондый халәтендә, гадәтенчә, күрмәскә тырышкандай, күзләрен йомды һәм “Сарман”нан “Жомга” көенә күчте. Ана ияргән Гыймакай карт сыек кына тавыш белән такмагын сипләп куйды:

Бульнисләргә барган идем,
Йөрәккә йөрәк, диләр.
Ике йөрәк арасына
Йөз грамм кирәк, диләр, их!..

Һәм менә шушы Разия, Бәгърем белән бергә бүре тамагыннан исән калган Разия, Бәгъремнәрне ташлап каядыр китә... Шул ай артыннан шул ук упкынга түгелдер бит? Ул аны ничек булдыра? Ничек йөрәге житә? Бәгъремнен кинәт кенә Разияны күрәсе килеп китте. Ул Бәгъремнән “Коткар!” дип ярдәм сорый, имеш. “Мине бу Почык Күзгә көчләп кенә

бирәләр бит,—ди ул.—Әле мин курчак уйнап та туймадым!"

Разиянын төсе-сыны сулыгып калган, имеш. Шомырт кара күзләре өстеннән ак яулык бәйләгән нәзек талга охшап калган, имеш. Бит алмаларының алсулары янган, имеш...

Әле Разия кайда икән? Кияве белән келәттә микән?

Ул ток суккандай сикереп куйды. Тәне чемердәде егетнең. Бу чемердәү кан юллары буйлап астан өскә, өстән аска йөгерде.

Бәгъремнең борчулы кичерешләрен тупас бүлеп, кайсыдыр кода каты һәм бик озак итеп кикерде.

—Нәрсәдер жимерелде,—диде янындагы кодачасы унайсызланып—Барыгыз да исән-саулар гынамысыз?

—Аллага шөкер, исәнбез!—диде Гыймакай карт.

Табын тагын да бердәм көлеште.

Бармакларын гармун басмакларыннан йөгерткән арада Бәгърем мәжлестәгеләрне янадан күзеннән кичерде. Ул замандашлары арасыннан матур, таушалмаган, илһамлы йөзле кешеләрне эзләде һәм аларны табалмый жәфаланды. Тыгыз рәт булып тезелеп утырган замандашлары арасыннан илаһияты балкып торган бер генә чырайны да күрмәве гүя ул аларнын үзләренең газабы түгел, Бәгърем газабы, үзләренең фажигасе түгел, бары тик Бәгърем фажигасе иде. Ул үзенең моңа кадәр сизмәгәнчә өлгерә, ничектер нечкәрә баруын тойды. Икенче караганда колтамаклар ана күзгә күренеп матур, затлы, ә менә килгән кода-кодагыйлар ягы күзгә күренеп ямьсез, затсыз иде. Йә, Хода! Әле генә кикергән коданың йөмшек танавын ул озак тапталудан чокыла төшкән тупса тактасына охшатты. Ул килүчеләр арасыннан, гомумән, чибәр кешеләрне таба алмады. Аларнын кайсы чалыш, кайсы чолыш күренде. Гүя алар икенче бер йолдыздан килгән папуаслар. Гүя алар да, нәкъ жиләк-жимеш кебек, берсе саф һава житмәүдән әлсерәгән, икенчесе дымсызлыктан кипшенгән, өченчесе артык дымнан бәлжерәгән, караеп черегән. Күрде инде, аларнын жигеп килгән атларынын янбашлары да, күтәрткән сыман, очланып тора...

Бәгъремгә бу ямьсезлектән куркыныч булып китте. Юк, бәлки алар кайчандыр бик матур кеше булганнардыр да, аларны бу тормыш шулай үзгәрткәндер? Бәлки алар бары тик Бәгъремгә генә ямьсез күренәләрдер? Бәлки бу... аларнын кайгыларын, булган зар-моннарын аракыга батырып булса да онытырга тырышулары, монын исә бер кыргый тәртипкә әйләнеп, чама югалтып эчүләре, шунын нәтижәсендә йөзләренен чөгендер кебек кызарып бүртенүенә генә бәйледер? Бәлки бу ямьсезлек... Вакытлычадыр? Шулай гына була күрсен иде! Бу кешеләр әгәр чынлап та табигый матурлыкларын югалткан булса, бу тигезсезлек даими дәвам итсә, ул алар белән бергә, алар арасындаяши алырмы?

—Эч әле берне!..—Бу юлы Бәгъремне үз итеп карт шайтан Гыймакай белән Күпер Төбе Гыйндулла көчли башлады.—Уйнавынны куеп тор. Мондый көндә утын да эчә!

—Эчмим дидем бит инде...—Бәгърем үзенә дип сузылган көрәгәгә яны белән борылды.—Нәрсә, табын дигәч тә, эчмәгән кеше калмаска тиеш дип социалистик йөкләмә алдыгыз мәллә?

Ихсан белән Сабиржаннын башлары сабагы сынган арыш башагы кебек янтайганнар иде.

Бәгъремгә бу дөнья, бу чынбарлык эчкелеккә күчә барган саен анын күз алдында ямьсезләнгән, картайган һәм тилергән кебек күренә иде. Болай барсак, кая барып, нинди чокырларга очарбыз? Гыймакай карт әйткән Ахырзаман Дәжжалы шушы стаканда түгелме? Дәжжал шушы мөлаем, шаян картнын үзендә, безнен барыбызнын да күнеленда аягын салындырып утырмаганмы?

Анын тагын да Разияны күрәсе килеп китте. Гүя аны ул гына коткара ала: анын кулбашларында канатлары бар! Егетнең бәгърен нәрсәдер бик назлы һәм бик ләззәтле итеп чеметеп алды.

Уйнавын куеп торырга теләмәгән Бәгърем "Агымсу"дан "Баламишкин"га күчте. Анын артыннан табын да "Баламишкин"га сикерде...

Бәгърем тагын да истәлекләр упкынына убылды.

Моннан ике ел элек булды бу хәл. Соныннан ул көн бишенче март—Сталин бабай үлгән көн булып хәтердә калачак. Ягарга утыннары беткән иде. Бәләкәй чаналар өстерәп, алар Каенлык урманына киттеләр. Иртәдән үк жепшек, үтә дә авыр, кара сөмсерле көн иде ул. Көн яктысын тагын да сүрәнәйтеп, иртәдән үк ниндидер кара канатлы, лычкылдык кар яуды. Аяк-куллары урманга барып житкәнче үк лычма су булды. Билдән көрт ерып, эчкә үттеләр. Ничек табасың ди көрт астыннан мич аслык утын? Эре агач аударырга пычкылары, аннан бигрәк палишщиктан рөхсәтләре дә юк. Кая ди ул. Беләк юанлыгындагы нәзек каенны да балта белән кискән хәлдә аның тукылдауы әллә кайлардагы Ырымбурларга ишетеләдер кебек. Шуңа күрә ин кулае—агач башына менеп ботаклар ботау иде. Алар моңа өйрәнеп беткәннәр иде инде. Бәгърем агачка үрләп, тукран кебек тукылдап кына утыра, Разия исә мәтәлеп төшкән ботакларны өстерәп чаналар янына чыгарып тора.

Инде кайтырга дип "Кыргыз юлы"на чыккач, алар палишщик Госманның нәкъ үзенә тап булдылар. Нишлисең инде, черек бәрәңгегә дип барсаң—кахул кыйный, урманга утынга дип барсаң—палишщик кыйный, саламга дип барсаң—пүләвәт кыйный, гармун уйнасаң—персидәтел Айсин кыйный. Тегесе кирәк, монысы ярамый, көн "кирәк" белән башлана, "ярамый" белән тәмамлана. Кая барырга? Авылны корыту, авылны халыксыз калдыру өчен махсус эшләнәме бу?

Авызыннан аракы исе аңкып торган Госман башта чанадагы ботак-сатакны кире урманга ташытты. Үсмерләр хәлдән тайды. Аннан балталарын тартып алды. Ничек яшисең ди авылда балтасыз? Ул бит ирсез ихатадагы бердәнбер дип әйтергә мөмкин булган тимер корал—ирләр коралы! Аннан, әйткәндәй, балтасыз татар—гомер-гомергә хокуксыз татар булган бит инде ул. Шуңа күрә дә бит инде ул бары тик иң мескеннәрне генә балтасы суга төшкән кешеләр белән чагыштырган. Кат-кат сорады, инәлде Бәгърем. Госманны йомшартырлык түгел иде. Ниһаять кузгалып китәм дигәндә генә Бәгъремнең Госман чанасындагы балтасына сузылуы булды, әммә теге имансыз аны шундук жилләп очырды. Чәме килгән үсмер палишщикның өстенә сикерде. Ул да булмый Разия кечкенә йодрыклары белән аның тун кигән симез гәүдәсенең гөбе кебек күпергән аркасын дөпелдәтеп кыйный башлады:

—Балталарны бир! Балталарны бир!

Әмма көчләр тигез түгел иде. Госман исә ерткычларча кыланды. Ул чыбыркысын Бәгъремнең күзендә үк шартлатты. Бер ай буе яшькәзеп йөреде. Ярый әле, ак салып куймады. Шул вакыйга исенә төшкән саен хәзер Бәгъремне бер сорау бимазалый: "Әгәр Госман шул көнне Сталин бабай үлгәнен белгән булса, бу кадәр кансыз кыланган булыр иде микән?" Бәгърем белә, бу сорауның бәлки бөтенләй дә мәгънәсе юктыр, әмма, нишлисең, борчый, бик тә борчый ул аны.

Шушы Разия ташлап китәргә итәме аны? Шушы тауларны, яланнарны ташлап китәргә дип шушы Разия жыенамы?!

Кияүнең атасы—төп кода игълан салды:

—Ягез, туганнар, кода-кодагыйларга рәхмәт әйтеп, юлга кузгалыйк булмаса. Туйның килен төшерү өлеше инде безнең якта дәвам итәчәк, Алла боерса. Әйдәгез, ашка дога кылыйк...

—И кода, сезләрне күргән кебек, кунак иткән кебек тә булмадык,—дип сүз башлады Раһиба жиңги.—Тагын берәр кич кунасыгыз бар иде дә бит...

—Юк, юк, кодагый, рәхмәт. Кунак булмый диме! Туйның кыз ягындагы өч көне бүгенге заманда башыннан ашкан. Калган өч көне бездә дәвам итәчәк бит. Аннан ферсидәтелебез Айсин атларны да өч кенә көнгә дип биргәние...

—Ниткән Айсин ул тагын?!—дип Гыймакай карт танк башнясы кебек йомры башын төп кода ягына борды.—Ниткән Айсин турында лыкылдыйсың син, кода-а-а?

—Габидулла Айсинны әйтүем. Ялгышмасам, аны безгә сезнең яклардан килде дигәннәр иде...

—“Әрмийский паррядык”мы?

—Нәкъ үзе!—Төп кода урынында кыбырҗып алып.—Каян беләсез?

—Белми диме! Тагын да “Дунгыз Иваныч”, шулаймы?

—Монысын әлегә ишеткән юк. Бездә аңа Синтральни Телеграф диләр бугай...

Авызларына капкан ризыкларын да чәйнәргә оныткан колтамакларның йөзләре чалшаеп катты. Гыймакайны очкылык тота башлады. Болай да хәтерсез карт Айсин турында ишеткәч, чиратны тәмам бутады.

—Ә ниг-гә?—дип укталды ул төп кодага күзләрен шар итеп.—Ниг-гә ал-лай дил-ләр???

—Нигә дип. Бер-бер хәл булса, телефунга утырып ала да, “Синтрәльни! Синтрәльни!” дип кычкыра башлый. Аңарчы районны ике урарга мөмкин, мин сезгә әйтим...

Айсин аркасында бер ел төрмәдә дә утырып чыккан Чулак Гамир бу юлы тыела алмады, күрәсең:

—Сез аны берүк безгә кире кайтара күрмәгез инде,—диде.—Киленнәрегез кебек, төшкән җирендә таш булсын...

—Горурланыгыз, аны сезләргә без җибәрдек,—диде почмактан Сәбәхетдин.—Таракан даруы урынына...

Кемдер пырхылдап көлде.

—Бәй, бәй, алай булгач бөтенләй туганлашкан булабыз бит!—диде аңа-моңа игътибар итеп бармаган төп кода.—Безне озата баручы кода-кодачалар, сез Габидулла Солтанморатович белән Аллагуәттә күрешерсез әле!.. Әйдәгез, ашка фатыйха кылыйк, булмаса...

Ишеткәннәреннән Бәгъремнең тыны каткан иде. Гүя кырандас тәгәрмәче астыннан, кыр казы кебек, аның тальяны каңгылдады.

Эчке ашына әйләнгән мәҗлестәшләрнең теләгәне дога кылып, теләмәгәне битен дә сыпырмыйча, урыннан кузгалды. Шундук туйны озату ыгы-зыгысы башланды. Бу ыгы-зыгының нинди вак һәм нинди эре мәшәкатьләрдән торуын бар тирәнлеге белән аңлатып бетү мөмкин түгел. Күрәсең, шуны күздә тотып, борынгылар “Туй үпкәсез булмый”,—дигәннәрдер инде...

### III

Атлар җигелгән иде. Кияү белән кәләшкә тәгаенләнгән кырандас тәртәләре арасыннан кара айгыр тояклары белән җир төеп, дугадагы кыңгырауларны бимазалый һәм йөрәккә әллә нинди моңсулык тамыза. Аш арбасына кызның бирнә җиһазлары салынган ак семәрле сондык, ак җаймаләргә төрелгән мендәр-юрганнар, озата баручы кода-кодагыйларның арбаларына сугыштан соңгы елларда ачлыктан чыга башлаган халыкның затлы азык мөлкәте—мичкә-мичкә ачы бал, шакмаклы ашъяулыкларга төрелгән ак күмәчләр, балга гына катырылган бавырсак һәм атланмайда йөздереп пешерелгән җаймәләр, таба күмәчләре төялә иде...

Чынлап та, ярыйсы ук кызып алган Ихсан белән Сабирҗан шундук Бәгъремгә ябырылдылар:

—Җиз Маңгай! Безне “Бүләк” урманына барып, кодаларны озатып калырга җибәрәләр. Мәсгуть абзый безгә сине дә калдырмаска кушты. Әйдә киттек!

—Юк, мин бармыйм,—диде Бәгърем.—Мин моннан гына озатып калам...

—Син нәрсә, шаштың мәллә? Гармун кирәк бит!—Ихсан аның иңенә сугып куйды.—Үзебезнең Разиябызны соңгы тапкыр тау башыннан да озатып калмагач!

—Гармун гына кирәкмени? Гармун белән Бәгърем аерым булалмый, аңладыңмы? Бармыйм, дигәч, бармыйм.

Егетләр белә: “Җиз Маңгай” ике сөйләми.

—Әллә ничек итеп бозылдың әле син бүген, гадук,[1]—диде аңа үпкәләп өлгергән Ихсан.—Аңламыйм мин сине бүген...

—Бүген аңламасаң, бәлки киләчәктә аңларсың ...—Җанында кайнаган давылларны кеше аңлау түгел, әлегә үзе дә аңлый алмаган Бәгърем сүзләрен теш арасыннан сыгып кына чыгарды.—Аның каравы, мин синең мине аңламавыңны аңлыйм!..

Ул Разияның әтисе Минебай абзый әле сугышка китәр алдыннан урманнан кайтарган, инде яртылаш череп, мүртаеп беткән усак бүрәнәләр өстенә менеп утырды һәм "Их, алмагачлары"н сайратып җибәрде. Әмма шундук кайсыдыр коданың бии башлаганын күреп, "Корт чакты"га күчте. Барлык ишек алды бер булып тузан күтәреп бии башлады.

—Ас-са!

Хатыныннан башка бер нәрсә эшләргә яратмаган Сәбәхетдин абзый түгәрәккә Мәстүрә җингине дә өстерәп чыгарып, тузан күтәрергә тотынды.

—Әйдә, карчык! Өязедә биек тал, мин барында биеп кал!..

Кемдер Бәгъремнәрнең "шәлия" табыныннан шакмаклы сары ашъяулыкны чыгарып җилпеде. Монарчы тузанда коенган чыпчыклар, тагын да тузан пырхылдатып, валчыкларга ташландылар, әләгәсен томшыкларына әләктереп, кабаттан тузан пырхытып һавага күтәрелделәр.

—Бәгърем, "Колхоз бию"ен уйна!

—Бәгърем, "Чабата"ны сиптер, давай!

Әгәр гармун уйный белмәгән булса, ул чабата үреп булса да авыл тарихына кергән булыр иде. Яшь кенә булуына карамастан, чабата үрүдә Колтамакта аңа чыккан кеше юк. Чабата үрү гармун уйнау кебек нечкә нәрсә бит ул. Разия да Бәгърем үргән чабаталарда гына үсте инде югыйсә. Җир йөзендә өч чабата бар: җәелгән мукшы чабатасы, тупас урыс чабатасы, ыспай татар чабатасы. Әйе, теләсә кем әйтер: алар арасында иң матуры—татар чабатасы. Менә шул татар чабатасын Бәгърем абзагыз коеп кына куя. Аның сурәте затлы, атламы вак тешле. Җиде юкәдән. Чәчүргеч кебек нәзек, балавыздай якты сары, озын юкәләрдән тезеп тә җибәрсә, карап кына торырлык була, биллаһи. Разия шуңа күрә дә башкалар үргән чабаталарны яратмады. Бер тапкыр ул хәтта Бәгърем чабаталарыннан да баш тартты. Яңа уку елы иртәсендә булды бу вакыйга.

Бәгърем Разияны алып күрше авыл мәктәбенә юлга чыгарга дип аның артыннан кереп килә иде. Өй эченнән ниндидер үксү тавышлары ишетеп, ул мич ягы тәрәзәчегенә елышты.

—Ән-некәем, ән-некәем! Кимим, үтерсәң дә кимим!—дип бөгәрләнә-бөгәрләнә елый иде Разия.—Чит авылга мин чабата киеп бармыйм!.. Мин хәерче кызы түгел!..

—Канымны кыздырма! Каян килгән хан кызы!—дип каеш белән сыптырып алды аңа әнисе.—Нибуч киярсең!..

—Кимим! Мин чабата киеп күрше авылга укырга бара торган ата баласы түгел!

—Нәрсә, атаң калдырган малың бар мәллә?—дип җикерде җан ачуы чыккан ятимә солдатка.—Сөякләре дә череп беткәндер инде!..

Һәм Раһиба җиңги сәкесенә бөгелеп төшеп үзе дә елый башлады.

Бәгъремнең ике күзенә дә пылт итеп яшь типте.

Ул елга аша бер атлап, ике сикереп чыгып, картинәсенең аягына ташланды:

—Картинәй, бир Сафа абзыйның былтыр Донбасстан сиңа дип җибәргән теге эрзинкәләрен!..

Картинәсе бераз карышып маташса да, артык каршы тора алмады.

Әй, килеште Разияга бу кызыл эчле, хуш исле, ялтыравык эрзинкәләр. Бөтен мәктәпнең күзе анарда гына булды шикелле.

Әле үзенең Разияны бөтенләйгә авылдан озату мәҗлесендә утыруын исенә төшергәч ул яңадан сискәнеп куйды. Нинди киту? Нигә кайту түгел? Менә Бәгъремнең бу гармун моңнарын шушы тал яфракларыннан аерып

[1]Годок *(урыс.)*—кордаш, чордаш, елдаш мәгънәсендә. *(Автор)*

алып китеп буламы? Булмый һәм булмаячак. Егет кеше жаны да, кыз кеше жаны да бер түгел микән ни? Ничек инде ул: шушыннан жан ал да, шул жанны алып, ә менә бар нәрсәне калдырып кит тә бар! Жан калырга тиеш. Хәтта гәүдә китсә дә. Әйбер китсә дә. Чөнки жан барыбер кайтачак. Егет корына кереп кенә барган, кызларның егетләргә караганда иртәрәк өлгерүен, егетләрнең китү-кайтуы белән кызларның китү-кайтуының икесенең ике төшенчә булуын әлегә аңламаган, үзендә булган балаларча якынлык, бергәлек тойгысының нәкъ шул сөюнең, саф сөюнең—ул көткән канатларның үзе икәнлеген һәм нәкъ үзе булачагын әлегә башына да китерә алмаган Бәгърем нindider фәлсәфи кануннар белән жан һәм тән бердәмлеге турында уйланып өзгәләнә иде...

Шат тавышлар белән тулган ишек алды биеп арыган иде.

Бәгърем "Озата барма"га күчте. Кемдер күкрәк киереп, жырлап та жибәрде:

Озата барма, иркәм, озата барма,
Олы юл бит, бәлки адашмам...

Тальян телләре астыннан моң көрәлеп, актарылып чыга иде. Башын бераз читкә борып, Бәгърем уйнады да уйнады. Гүя аның бу моңга бернинди катнашы да юк. Болай да аңлашыла бит: жир йөзендә татар кебек талы һәм тальяны бу кадәр бергә береккән, бер жанны, бер тәнне тәшкил иткән, үзара шул кадәр тәңгәл килгән, бер-берсеннән башка яши алмаган, бер-берсенә кендеккә-кендек, йөрәккә-йөрәк сарышып яшәгән кавем юк. Тальянның талпынуы була—тал хәрәкәткә килеп, аңа таба жилпенә. Тальян бары тик тал көмешеннән генә көмешләнә. Тальянның тал жаны һәм татар жаны. Татарның тальяндагы тал жаны. Тальянның татардагы тал жаны. Татар талларына килеп кунган итальян гармун! Йә Ходай, бу тәгъбирне ничек кенә төрләндереп булмас иде. Кыскасы, татар тальянсыз калса гына бетәчәк.

Туй озатырга дип килгән халык ишек алдына сыеша алмыйча урам буендагы читәннәргә сарылган иде...

Йомшак кына жил исте.

Йөрәктәй тамчылы тал яфраклары шыбырдашып куйды.

Өязе елгасы шадраланып тынычсызланды. Аның өстеннән агымга каршы вак дулкыннар йөгерде.

—Чыгалар!..

Бәгърем керфекләрен сындырырлык итеп каты йомды һәм үзе дә сизмәстән соңгы чорда гына тарала башлаган "Хуш, авылым" көен уйнап жибәрде.

Читәнгә сарылган халык башланган көйне солдатка Раһибаның авылдан китүче беренче ятимәсе һәм чибәре Разия хөрмәтенә кумәкләп жырларга тотынды:

Хуш, авылым, сәламнәр көт,
Таң жилләре искәндә...

Көйнең яңгырашы борылышларга, борылышлары сөзәк кенә итеп агышка әверелеп, Өязе талларыннан кайтаваз булып кайта иде. Аһәңнәр тыела алмыйча үкси-үкси дә, Бәгърем гә буйсынудан туктап, баш түбәсендә тургай булып атылып менә. Бәгърем нең аларны төшерәсе, яшерәсе, сүндерәсе килә, әмма ул аны булдыра алмый, вәкаләте житми. Егет бу авазларны гүя юеш тастымалны сыккан кебек үз тәненнән, үз жаныннан сыгып чыгара, аннан көйнең буыннарында сыгылмаган бер генә тамчысы да калмагандай, калтыранып ала.

Мин кайтырмын сине сагынып,
Өзелеп искә төшкәндә-ә-ә...

—Хәзер чыгалар!..

Ул башын тавыш килгән якка борды, әмма күзләрен ачарга көче житмәде.

Гүя ул үзенең тәнендә үзе әсир, үз жанында үзе мәхбүс иде.

Менә ул, ниһаять авыр йөк күтәргән йөкче кебек, көчәнеп һәм

өзлегеп, аскы һәм өске керфекләрен аера төште, аннан керфекләренен төрмә рәшәткәсе аша күз алмасына сыек кына көн яктысы сирпелде һәм ул бу яссылыкта, еракта-еракта, әллә кайларда булып шәйләнгән келәт ишегеннән чыгып килүче Разияны төсмерләде.

Бәгъремнен карашы торган саен ачыла, офыклары киңәя төште.

Анын артыннан теге Почык Күзнен гәүдә ишарәте дә оешты, бу ишарәт Разияны житәкләп алып, жил капка алдында торган кырандаска таба алып китте...

Разия бәбәй итәкләп тегелгән ак борчаклы яшел күлмәк, күлмәге өстеннән эре чәчәкле алъяпкыч, аякларына яп-яңа эрзинкәләр кигән иде.

Болар Почык Күзнен мәһәре булырга тиеш.

Бәгърем гармун күрекләрен өзәрдәй булып әйләндерә-тулгандыра тартты.

Колтамак таулары артыннан күтәрелгән сүрән кояш кебек, Разия күзләрен жирдән күтәрмичә генә елмая иде.

Ышанасызмы, бераз гына тартылып, агарып калган Разия елмая иде!

Димәк, ташлап китү—бәхет?!

Кучер егет, кырандас кузласына менеп утырган да, дилбегәләрен жәя керешедәй тартып тотып, кара айгырны чак-чак тыеп тора.

Бәгърем мондый хушлашу—кыз озату йоласынын башка бер генә мизгелен дә күрми дә, ишетми дә, анын бар дикъкате бары тик шушы кырандас тирәсенә генә тупланган иде.

Менә Разия Почык Күз ярдәмендә кырандаснын тимер күперчегенә басып, вак кына ак талдан үрелеп, тиз генә черемәсен өчен кара креозитка буялган кырандас үрәчәсенә менеп утырды, анын белән янәшәдә, тирә-ягына каранып баш селкегәннән сон, Почык Күз дә урын биләде. Кичә генә кыз белән егет булган, бүген инде кияү белән кәләшкә әйләнгән яшьләрне туганнары, авылдашлары, күршеләре, ахирәтләре уратып алды. Болар арасында Бәгърем генә юк иде. Хушлашу, теләкләр теләү башланды. Арттагы арбаларга кәләшне озата баручы кода-кодагыйлар, кода-кодачалар утырыша башлады.

Бәгърем уйнавыннан туктады.

Ул галәмәт зур авырлык белән өстерәлеп, урынынннан күтәрелде. Анын үзе, анын гармуны белән, әйтерсен, үз тирәсендә типченгән чыпчыклар гына түгел, гүя барлык жир шары күтәрелә иде. Аһ авыр, шуна күрә авыр иде бу гармун белән бергә күтәрелү!

Ул вак, чеметем адымнар белән кырандас каршысына килеп туктады. Беренче мәртәбә кияү-балага якыннан дикъкать белән карады. Ошатмады ул аны. Чынлап та Почык күзле икән ул. Карабодай орлыгы кебек әллә нинди почмаклы, күп кырлы икән ул чынлап та.

—Хушлашмыйча да китеп барасынмени, Разия?—диде ул чак-чак ишетелерлек итеп.

Разия эндәшмәде. Ул күтәрелеп карарга тартына иде бугай.

Бәгърем соравын тагын да кабатлады.

—Хуш,—дип пышылдады Разия алсуыннан сытылып чыгардай булып.—Хуш, Бәгърем...

—Кем бу?—дип жикереп жибәрде Почык Күз.—Бу нинди Бәгърем ди тагын?! Бу нинди молокосос минем кәләшемнән дапрус ала?!—Ул утырган жиреннән генә итегенен табанын Бәгъремнен күкрәгендәге тальянга терәп, бар көченә этәреп жибәрде. Бәгърем артка аткарылды. Тальян кыр казыдай каңгылдап куйды.

Калганы күз ачып йомганчы булды. Күргәне күрде, күрмәгәне күрми калды.

Почык Күз кесәсеннән бер кушуч тимер акча чыгарып сипте. Ул яңгыр булып Бәгърем өстенә коелды. Бала-чагалар бер-берсен таптый-таптый аяк астындагы тәңкәләрне жыярга ябырылды.

Бәгъремнен жене кузгалган иде.

Анын зиһенендә яшенле тамгалар калдырып, күк белән жир бергә кавышты. Ана күк нәрсәдер пышылдагандай булды.

Бармакларын гармун телләренең, бакаларының төбенә кадәр батырып, күреген чамасыз киереп, иләмсез акырта-акырта тарта, аннан тагын да акырткан унайга, күрекне бер учмага җыя, аннан тагын киерә салып, Бәгърем хәлиткеч адымнар белән ишек алдындагы читәнгә таба бара иде. Күрек уртасындагы ак шакмак, үзенә урын тапмагандай, бер зурая, бер кечерәя иде. Менә ул, ниһаять, читәннең янына ук килеп житте һәм гармун күреген янадан акыртып сузып, көтмәгәндә генә һәм, ике дә уйламыйча, татар итальянын күрегеннән Разиялар читәненең казыгына кидерде.

Күректән пошкылдап һава чыкты.

Халык аһ итте.

Итальян гармун соңгы тапкыр кыр казы каңгылдаган тавыш чыгарды да, канатсыз коштай, казыкта эленеп калды.

Җене котырган үсмерне туктату мөмкин түгел иде. Ул яшен тизлеге белән атылып кырандас янына килде һәм Почык Күзнең изүенә ябеште:

—Измәнне изәм! Бирмим Разияны! Бирмим!..

Ишек алды чайкалды. Кайнешләр белән балдызлар, кодалар белән кодачалар, кайнегәчләр белән кайнагалар барысы бергә буталды.

—Ку атынны, нәрсә карап каттың!—дип җикерде Почык Күз кучер егеткә. Аннан, үрелеп, дилбегәне какты.—На! Әйдәгез, кузгалдык!..

Кара айгыр җилкапка аша урамга ыргылды. Авылны дугадагы кыңгырау чыннары басты.

—Исерек бит ул! Туктатыгыз!..

—Бер стакан балны күтәрә алмаган егет егетмени ул?

—Туйны бозды, манка малай!..

Ишек алдын йөзләгән тавыш басты.

—Тукта, Бәгърем!—Бер төркем ирләр егеткә ташланды.

—Син бит аның белән йөремәдең дә...—Каяндыр килеп чыккан Ихсан дустының иненә асылынды.—Син нәрсә? Шулай ярый диме?!..

Аны җиргә сузып салып, өстенә атланып утырдылар. Авазлар хәзер кайнар җир өстеннән шуышып, туп-туры Бәгърем колакларына савыла иде.

—Үзегезгә җитмәгән акылны кешегә өйрәтмәгез әле!—Гыймакай карт Бәгъремне якларга тырышты.—Йә бөтенләй җинеләеп калырсыз. Яшь чакта алай гына була инде ул... Яшь, тиле, каны кайнар...

—Мондый жегетләр булганда, яшибез әле...—диде берәү тыны кысылып.

Ул читән артында басып торган Зимагур Зиннәтулла булды бугай.

—Көнләшә ул...—диде кемдер ап-ачык итеп.—Балак бете үргә үрләсә, шулай тилерә ул.

—Көнләшмим мин! Көнләшмим!—Нахактан рәнжегән Бәгърем янга бәргәләнде.—Гарьләнәм мин!.. Әрним мин!..

Исрекләр айный, айныклар исерә төште.

—И-и-и, ахмаклар, шуны да анламыйсыз,—диде Сәбәкәй тыныч кына.—Ярата ул аны. Җан сөюе белән сөя, беләсезме! Сез анлый да алмыйсыз мондый сөюне...

—Ә нигә соң аны, алай булгач, Разиясы яратмый?—диде бер чәрелдек тавыш.—Нигә яратмый да, нигә әллә кайдагы әтрәгәләмнәргә тормышка чыга?

—Ахмак син! Бәгъремне яратмау мөмкин түгел...—диде Гыймакай карт. Аннан бериш уйланып торды да өстәде.—Бәгъремгә "Мин сине яратмыйм, Бәгърем," дип әйтеп булмыйдыр ул... Моның өчен нинди йөрәк кирәк!... Мәсьәлә, җәмәгать, монда башкачарак тора шул...

—Бәгъремне... Бәгъремне аны... барлык авыл имезгән!..

Монысын Чулак Гамир әйтте.

—Авылның тарихка керерлек беренче чибәре китә... Шуна жылый жегетебезнең жаны...

Монысын ихластан шул ук Зимагур Зиннәтулла әйтте.

Ул арада булмый, жиргә боргычлап салынган Бәгърем башы белән жирне төя-төя үкси иде:

—Тал жаным китте, талларым да китә! Тал жаным китте, тауларым да китә!..

—Һич тә көтмәгәнне... Берәрсе котыртты мәллә безнен туйны бозарга?—Кызын озата барырга дип менеп утырган арбасыннан кире төшкән Рәһиба жинги оялуыннан нәрсә эшләргә белми бөтерелә иде.—И, Ходаем, нинди гөнаһларым өчен генә... Туйны бозма, Бәгърем, бозма, ишетәсенме!..

—Гафу ит, Рәһиба жинги... гафу генә итә күрче...—дип ялварды Бәгърем анасы сыман якын күрше жингәсенә.—Мин түгел бит! Анлагыз... Күкләр шулай куша!..

—Дөр-рес, туган! Безгә күкләр шулай куша!—дип әйләнеп йөри башлады аларга якын да килмәгән Кое Төбе Гыйндулла.—Мин—исерек, мин—чучка, әтнәке тоям—безгә күкләр шулай куш-ша!..

Инде жилкапкадан туй олавынын башка атлары да чыгып житеп килә иде.

Кызын бирүзе төп кода һәм төп кодагый буларак озата барырга тиешле Рәһиба жинги, олаудан калмыйм, дигәндәй, йөгереп барып, арбасына утырды.

Бәгърем зиһененен бик ерактагы офыгыннан ике медален ике як түшенә таратып таккан, галифе чалбарынын ике як канаты белән бар тирә якны баскан Айсин күләгәсе күтәрелде. Әнә ул, кайдадыр Ашказар буйларындагы Аллагуәт авылы башында авызын ыржайткан да, кабып йотарга дип Разияны көтеп тора...

Гыймакай карт әйткән Дәжжал гүяки хәзер Бәгърем үзе иде.

Ул шайтан көче белән жирдән этәрелде һәм, үзенә менеп атланган авылдашларын иненнән коеп төшереп, туй олавы артыннан йөгерә башлады:

—Кайт! Разия, кайт! Аерылып кайт!..

Кемдер аны сугып екты.

—Авызыннан жил алсын, мәлгунь!..

Бу Разиянын туганнан туган абыйсы Мәсгуть иде.

Бәгърремнен авызыннан кан китте.

Ул берни булмагандай, янадан сикереп торды һәм туй олавы артыннан авыл очына таба йөгерде:

—Разия-я-я!.. Ка-а-айт! Разия-я-я, ка-а-а-айт!..

...Бу вакыйгаларга инде илле ел гомер үтте.

Менә илле ел инде итальян гармун әле һаман да казыкта асылынып тора һәм Ашказар, Ырымбур тарафларыннан искән ярсу жилләрдә чайкалып, ынгыраша, кыр казыдай, кангылдап куя сыман.

Бәгърремгә килгәндә, ул менә илле ел инде туй олавы артыннан йөгерә кебек.

Шул еллар истәлеге булып Бәгърем ихатасыннан әллә кайларга торнадай озын муенын сузып сиртмәле кое баганасы күренә. Гүя ул, үрелеп, офыклар аша кемнедер эзли һәм эзләгәнен табалмагач, алдагы гасырларга үзе дә очып китәрдәй булып талпына.

*1999, июнь-сентябрь.*
*Переделкино—Чаллы.*

# ШИГЪРИЯТ

## МОҢЛЫ, САДӘ ДУСТЫБЫЗ



*Көндәлек матбугатта—журналларда, газеталарда Рафис Әхмәт исеме белән язмалар еш очрый: йә ул әдәбиятыбыз тарихына, унтугызынчы йөз язучыларына, йәки егерменче гасыр башы шагыйрьләренә багышланган була, йә атаклы сәнгать әһелләренә—Сәйдәшкә, Фәрит Яруллинга, Фасил абыйсы Әхмәткә... Рәшит Ваһапов, Илһам кебек җырчыларыбыз турында да яза ул, Муса Җәлил хатларын Уфадан табып, бастыра... Кыскасы, гел әдәби, мәдәни мохитебездә күренеп, матур мәкаләләре—табышлары белән сөендерә. Милләтпәрвәр, белемле, энтузиаст шәхес, эзләнүчән, нечкә җанлы кеше...*

*Рафис Әхмәт—шагыйрь дә. Зур-зур циклларын, хәтта поэмасын да төрле журналлардан укып беләм, матур тәрҗемәләре дә бар.*

*Күмәк китапларда да басылды аның шигырьләре—кыскасы, поэзия сөючеләргә таныш исем дип әйтә алабыз. Менә, ниһаять, журналыбызга да алып килде ул бер бәйләм шигырьләрен: «Казан утлары»нда басылуны иң зур дәрәҗә итеп санавын да әйтергә онытмады.*

*Йә, мондый шәхескә игътибарсыз калу мөмкинмени? Шул ук мәңгелек Моң, музыка, борынгы фән-акыл һәм якты хисләр кушылуыннан туган бит аның бу лирикасы... Анда—шул ук Фасил, Батулар васыяте, аларга тугры булырга антлар эчкән татар зыялысының ихлас яшьләре бар. Мин шулай тоям.*

Рәдиф ГАТАШ

**Рафис Әхмәт**

### ГОМЕР УРТАСЫ

* * *

**Очланамы гомер—узган саен**
**Шомарамы иске юл ташы?..**
**Иярчене микән без Вакытның,**
**Әллә аның тугры юлдашы?**

Бәлки, без дә пәйгамбәрләр түгел,—
Кеше булып калу читенме?..
Тойгыларны тыю читен... Ләкин,
Кыерсыта күрмик зиһенне!

Җавап бирер вакыт килде,—вакыт
Шул сорауга... Гомер уртасы...
Иярчене микән без заманның,
Әллә аның тугры юлдашы?

* * *

Гомерем буе җиңел бәхет,
Арзан шөһрәт көтмәдем,—
Хәләл көчем белән килде
Шәрабым һәм икмәгем!

Сабыйныкы кебек җанны
Нинди ялкын өтмәде?—
Әмма мәлгунь,—көнче дошман!—
Баш июне көтмә әле...

Җитәрлек булды кимсенү,
Җаным барыбер саф минем...
Шөкер, сынады сантыйны
Һәм... санлады тәкъдирем!

Булды тую иҗаттан да,
Язудан да бизүләр:
Бүген—гаҗәп!—илһамлы мин,
Ачык минем изүләр.

Язармын да, сызармын да
Кәгазь-карам беткәнче,
Якты дөнья җасәдемә
Ак кафенлек теккәнче!

Үлгәндә дә тартышырмын:
—Юк әле, мин бетмәдем!
Чөнки җирдә яшәгәндә
Мин буш гомер итмәдем!

## Яңгыр астында

Тәүлек ярым коя яңгыр...
Томан сарган тирә-якны.
Ни юк яшен, ни юк яшем,
Бернәрсәгә күңел тартмый.

Инансам да бу яңгырның
Монда мәңге түгеләнә,
Әллә нинди дымсу томан
Саркып сеңгән күңелемә.

Юсалар да, юатам дип,
Юеш таллар алтын ялын,
Җуйган җаным җәйге ялын,
Тоюларның татлы балын...

Аһ!
Шул чакны табып җаен,
Җилләр тулы тыгыз җилкән,
Җиләс җанлы, ихлас аңлы
Яшьлегеңә кайтсаң икән!

Аһ!
Шул чакны
Тирәктән—чык,
Йөрәктән йөк коя-коя,
Җиләк тулы аланлыклар
Тапсаң икән оя-оя!

... Ямансу шул яңгырлары,
Ява алар, ага алар...
Җанның җылы почмагында
Чәчәк ата абагалар!

## Җепшек кар

Тышта ява җепшек ябалак кар,
Син яраткан кар бу, карачы!
Аның гомере могҗиза күк, кыска,
Болытлы Күк һәм Җир арасы.

Талгын гына җепшек карлар ява,
Күпме наз бар монда, иркәлек,
Иреннәргә килеп куна карлар,
Салмак кына көйгә тирбәлеп!

Әллә ул да күктән сөрелгәнме
Адәм белән Һаува шикелле?
Керфегемә кунып, яшь агыза,
Үзе нәни, үзе сөйкемле.

Күктә генә гүзәл йолдыз бит ул,
Күктә генә—якты бер чәчәк;
Җиргә төшсә, беләм, эри-эри
Күз алдымда агып бетәчәк...

Кышкы кичнең зәңгәр аһәң-моңын
Тыңлап, көрткә чумган бар кала...
Җир белән Күк арасында, гүя,
Безнең язмыш, бәхет чайкала!

* * *

Кабатланмыйм, кызмыйм, кабаланмыйм,—
Менә шундый сабыр адәм мин.
Шушы салкын сабырлыкка, кызый,
Мин күп еллар буе өйрәндем.

Тойдым бугай шашып сөюләрне,
Югалту һәм табу ләззәтен,
Тик күрмәдем көткән бәхетемнең
Елын түгел, көнен, сәгатен.

Мин сөйгәннәр—мине сөймәделәр,
Яратканнар—итте хыянәт,
Күңелем минем—көлләр каберлеге,
Һәм куркытмый аны кыямәт.

Бит миндә дә хыял тулы иде,
Тулган иде фәкать егерме;
Әзер идем, башкаемны җуеп,
Багышларга сезгә гомерне!

Хәзер менә чыраемда гамь юк,
Күзләремдә һаман моңсулык...
Юк, ташымыйм инде, ташулар күк,
Ага алмыйм сиңа кушылып.

Синең янда салкын кофе эчеп,
Син көлгәнгә генә елмаеп,
Утырам мин ялгыз... Вакыт үтереп,
Хистән исереп, уйдан моңаеп.

## Бату ага Мулюковны озатканда...

Ишеттем дә бу хәбәрне,
Җаныма төште кату...
Күзләр тагын корбан алды,
Тагын олы югалту—
Сәйдәшне Фасилгә бәйләп
Торган җеп идең, Бату!

Каргалы биргән асыл зат,
Исемең дә бөек—Бату.
Чыңгыз затын хөрмәт итеп,
Бергә яшәдек тату.
Син юклыкка җан ышанмый,
Ә алда—күмеп яту...

Фасилдәй, казлар киткәндә
Китеп бардың, ах, Бату!
Икеләтә кыен миңа
Абзыкайны югалту.
Туфрагың җиңел булсын, и,
Тыныч йоклый күр, Бату!

«Җырымда юатырмын» дип,
Күпме юаттың, Бату!
«Җырларымнан белерсең» дип,
Хак сүз көйләдең, Бату!
Күз суына, гасыр уза.
Җитми җанга юату,
Бәхил бул, моңлы Бату...

... Зинһар, булчы бу гасырда
Инде соңгы югалту!

## Таң

Күк читендә ярым кояш—
Алтын төскә манган дуга.
Таң нурлары—җирән тайлар—
Томырылып төшә суга.

Ак толымлы болыннарны
Гашыйк караш белән айкап,
Юлга чыга тормыш дигән
Гүзәл җирне сөйгән җайдак!

Күрәсеңме, яшел тутлы,
Җиңел сары тоякларның
Чыклы чирәмнәрдән чабып,
Тирә якны уятканын?

Килер көннәр чабышында
Җиңү вәгъдә итеп, аңа
Кояш коя алмаз чыктан
Балкып торган нурлы дага!

И җан дустым, җирдәшем лә!
Кояш калкып килгән чакта
Сикереп торып, атлана бел
Син дә шушы җирән атка!

* * *

Күпме гомер инде артта,
Әле күпмесе алда?
Ә дөньяны алты көндә
Яраткан, дисең, Алла...

Әллә син үзең—бер дөнья,
Әллә син үзең—Аллам?
Тик мин сине гомерем буе
Яратып туя алмам.

## Чык

Чәчләреңдә уйный-көлә
Иртәнге чык тәлгәшләре...
Ә бит алар—ялгыз Айның
Төнлә койган күз яшьләре.

## ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

**Рафаэль Сибат**

# ПРОЗАБЫЗ АХУНЫ

## Туфан, Хәкимнәр киткәч...

*Коткар безне, Ахун!*
Илдар Юзеев.

Әдәбиятыбыздан соңгы могиканнар китеп бара...
Алар белән бакыйга хушлашу сагышы, йөрәк әрнеткеч югалту, үлемнең без адәмнәр аңламас тирән сере һәм котылгысызлыгы артыннан ук үткен-кискен һәм ачы сорау алга килеп баса:

—Ә кемнәр калды?

—Алар эшен дәвам итәрдәй әдипләр бармы??

—Әлеге аксакалларыбызның әдәби көрсиенә утырырдай гомумхөрмәткә вә олуг талантка ия Ижади Инсан кем??? Гуманлы инсан...

Без, шушы сүзләрне әйткәч, бәгъзе бәндәләр:

—Туктале, нигә бу «соңгы могиканнар» дип, сүз куертып тора? Могикан сүзе үзе үк сүз уйнату яисә пафос өчен өреп кабартылган коры куык кына түгелме??

Җавабым кыска:

—Могиканнар,—дип, мин Тукай Рухындагы, аның Изге Җаны белән, Бөек Поэзиясе, Батыр Иҗаты белән сугарылган Иҗадиларыбызны атыйм. Татары өчен җан аткан язучыларны искә төшерәм...

Дәрдмәнд, Исхакыйлар... Сәгыйть Рәмиев, Такташлар... Туфан, Хәкимнәр... Әнә бит шагыйрь ни ди:

Безне оялтырлык, кызартырлык
Юк шул инде Туфан, Хәкимнәр.

Туктале! Нигә монда «оялту» вә «кызарту»? Әдипләр гомере буе оялып, кызарып кына яшәргә тиешләр микәнни?!

Пәйгамбәребез Мөхәммәт галәйһиссәләм: «Оялу—иманның яртысы ул», дигән. Гомумән, кешелек ояла белгәнгә киенә алган. Бу суыктан гына килми, аңы үскән саен кеше дигән җан иясе яхшыны начардан, караны актан аера башлаган. Әмма...

Бармы соң ул бездә «ярты иман»?

Чын мәгънәсендә ояла беләбезме без? Ояла белү ярты иман гына түгел, ә үзе үк Сәнгать ич ул! Хисләр, зәвык, зыялылык сәнгате. Тулы бер эстетика!

---

Редакциядән:

*Рафаэль Сибатның бу язмасы Татарстанның халык язучысы Гариф Ахуновка 75 яшь тулган айга әзерләнгән иде. Әмма, ни кызганыч, рәхимсез үлем Гариф аганы безнең арадан алып китте... Гариф ага исән чагында ук язылган бу мәкалә үзгәрешсез басыла.*

Инде әдәбиятка килгәндә, бу сүз үзе үк әдәп мәгънәсен белдерә ич! Әдәп тәрбияләүче Сүз Сәнгате ул әдәбият, ә әдәп үзе яхшылык дигән Атадан һәм Матурлык дигән анадан гына туарга мөмкин.

Әдәпле кеше—ояла белгән инсан ул. Ә без?! Ояла беләбезме без? Бу фәлсәфи категориянең укасы купты, тәме бетте, мәгънәсе, көзге сары яфрактай, очып китте түгелме?

Илне оятсызлык басты:

—алдыйбыз—ояла белмибез;

—зина кылабыз—ояла белмибез;

—урлыйбыз—ояла белмибез;

—Кеше үтерәбез...

Кая инде ул кеше кадәр кешене үтерүчегә ояла белү! Оялуны белсә, ул кешегә тырнак белән дә чиертмәс иде.

Алдау-ялган, биргән сүзендә тормау, вәгъдәнне үтәмәү, тоташ зиначылык, караклык-бурлык, юлбасарлык, жанынны малга сату, адәм балаларының гомеренә кагылу—шулкадәрле дә киң диапозонда ки бу эш: мәктәп баласыннан башлап президентларга кадәр сузылган. Ярым чишенеп йөрүдән Чечняга кадәр ул.

Ә без?! Әдәбиятны тудыручылар: әдәбиятчылар, әдипләр үзебез әдәплеме? Бармы ул барыбызда да әдәп дигән нәрсә? Юк, әлеге дә баягы «показной», күргәзмә өчен куелган тышкы әдәп түгел, ә жанына урнашкан, күнелендә бикләнгән, йөрәгең каны белән жылынган эчке әдәп. Без бер-беребез турында гайбәт йөртмибезме? Авторнын әсәрен үз алдында мактап, артында тиргәмибезме? Кайда безнең тәннәребез генә түгел, ә жаннарыбыз да бергә жыелган «Союз-Берлегебез», «Пен Клубыбыз»? Кайда ул?!

Ул бит «Союз йорты»нда, «Пен» клубында түгел, ә жаннын үзенә иман булып урнашырга тиеш. Әдәбият турында сүз барганда без тыштан ялтырап, ә эчтән битарафлык утын калтыратып кына тормыйбызмы? Әдип булу кәсепкә әйләнеп бара түгелме? Кулынны һәм йөз-битенне генә түгел, ә Жанынны юып, Рух утынны кабызып керергә кирәк Әдәбият дигән Гүзәл Сарайга! Ул язучы исемен алу яисә китап арты китап чыгарып яту бинасы түгел, ә Рухият, Гүзәл Хисләр, Әдәби Иман, Яхшылык—Матурлык бакчасы. Ә бит безнең шул бакчабызда бүген бер әйбәткә—бер юньсез дигәндәй, бер талантлыга—бер сәләтсез, бер сәләтлегә—бер кәсепче...

Дөрес, әдәбият—кәсеп мәйданы түгел. Чөнки хәзер бит язучыга түләнә торган каләм хакы—төкерек кенә. Бу—аннан көлү, турыдан-туры мыскыл итү:

—Син, агай-эне, артык туры сөйлисен, күбрәк әйтәсен, кысыйк әле сине азрак, парларынны чыгарыйк!—дип анын борынына чиертү!

Ә беләләрме сон илбашлары әдәп-әдәбиятны? Укыйлармы алар яна чыккан әсәрләрне?

Берсе:

—Укы-ыйм...—дигән була.



*Рафаэль Сибат һәм Гариф Ахунов . 1998 ел.*

Икенчесе:

—Вакыт юк, укырга вакыт калмый...—дип котыла.

Өченчесе:

—Китап укымаудан гына үземне ким хис итмим,—дип, турыдан-туры әдәпсез жавап бирә. Тегеләре дипломат, сонгысы—Лебедь, Руцкойлар сынары.

Кемдер сорау да бирер:

—Ә кая китә микән аларнын вакытлары, кайда үтә икән?

Анар да жавап бар:

—Ипподромнарда...

—Автодромнарда...

—Хоккейда...

Шулай инде, әлеге әфәнделәрнең башларына интернациональ сүз булган иппо-автодромнар һәм «хок»лар тулган. Кая монда милли телгә урын? Кая монда әдәбиятны, сәнгатьне кайгырту, аның киләчәге өчен борчылулар?! Әнә шул хобби булган «хок»ларга, иппо-автодромнарга акчаны һич тә кызганмый алар. Начармы бу? Һич тә юк! Ләкин Сократ: «Софросине»,—дигән. Бу сүз «һәрнәрсәдә чама белү» дигәнне аңлата. Чама белү, шул әдәп инде ул. Әдәпкә күбрәк әдәбият өйрәтә дибез. Ә мең еллар элек ханнар үз яннарында вәзирләр, акыл ияләре белән беррәттән шагыйрьләрне дә тотканнар...

Рус патшаларын кечкенәдән үк әдәп, әдәбият, сәнгатькә өйрәнү өчен махсус укытучылар куелган.

Европа корольләре арасында, үзе кулына каләм алып, әдәби телдә матур хат, очерк, хәтта хикәя язардай кешеләр дә булган. Тарихтан Юлий Цезарьны гына искә төшерик. Бу даһи полководец үзенең данлыклы җиңүләре белән генә түгел, ә әдәби мемуарлары белән дә кешелек хәтеренә кереп калган. Наполеонның хатларын хәтергә китерсәк, алар бит чын мәгънәсендә кайнар хис, акыллы сүз белән тулган эпистоляр әсәрләр.

Шагыйрь Бабурны гына искә төшерик...

Хәер...

Кая инде ул хәзергеләргә!

Җаннары тимер-бетон белән «замуровать» ителгәннәргә. Әнә берсе «Чирәм жир»не дә язды. «Кече жир»не дә язды—тирән, олы әсәр генә тумады. Ник? Чөнки бит ул бу «әсәрләр»ен күнеле аша үткәреп, йөрәк каны белән сугарып язмады. Ана—язып бирделәр...

Югарылар илтифатсызлык күрсәткәндә, түбәндәгеләр нишли? Ленин моны революцион ситуация дип өйрәтте. Әмма... Гел дә гел революцияләр ясап торып булмый шул! Халык болай да туйган инде «революцияләр»дән! Революция юньсезлектән коткару чарасы түгел, үзе үк—афәт ул. Ә халык үзен «Коткаручы»ны эзли.

Югарылар илтифатсызлык күрсәткәндә, түбәндәгеләр үз арасыннан хөрмәтле вә талантлы инсаннарга баш ияләр, аңа иярәләр. Чөнки әлеге Рухи Җитәкче аларга әдәп-иман, ден-дин, тоткан кыйбланны сакларга ярдәм итә.

Туфан, Хәкимнәр киткәч...

Алар киткәч, рухи остазларның берсе булып, татар әдәбиятында Гариф Ахунов калды.

## Ак күбеккә баткан ат...

*Сәйдәш булып һәм Тинчурин булып*
*Иңбашыңа кунган фәрештә.*

И. Юзеев.

Сабан туе...

Унөч өйле өч йөз еллык Өчиле өч мәртәбә арткан диярсең! Ул халыкның күплеге, шагыйрь әйтмешли: «дингез кеби»...

Өчилегә җыеңга җыелган халыкның яртысы колхоз рәисе Ахунҗан йортына төште булса кирәк. Хатыны Бибинур, татарча мөлаем һәм сабыр мөәннәс заты, кунакларга тәм-томны, сый-нигъмәтне ничек җиткереп өлгергәндер, монысын бер Алла гына белә. Әле бит күмәк хуҗалыкларның, яңа гына тәзелеп, тернәкләнеп кенә килгән чагы. Әле бит туфракка тубалдан төшкән сары гәрәбәләр игенченең иң зур өмете—яшел үҗым булып тишелгәненә кайчан да, сабагында башакланып ятуына кайчан! Игеннәр әнә шулай яшәү дәрте, тормыш дәрманы, дәвамлылык көче булып, яз башында гына гөрләп сулар аккан, майда каралып җирләре чыккан басу-кырларда талгын җилләрдә дә дулкын кузгатып утыралар хәзер...

Казан артының даһи шагыйре Тукайча соклансаң, чыннан да:

—Дингез кеби!

Яшел дингез...

Кешеләргә көшелләрен бирәчәк, ашлыкка баетачак иген кыры көнләштерерлек дәрәҗәдә шулай кукраеп-матураеп утыра...

Әле ул күкрәк астындагы газизен—туачак сабыен түземсезләнеп көткән Анадай

хәсрәтсез, жылы, моңлы, якты хыяллы ипле уйларга баткан...

... Кунакларны озаткач, Ахунжан белән Бибинур күз салдылар.

—Кояш батып бара инде,—диде, көне буе йөгереп йөреп, кунакларны сыйлаудан арганга түгел, ә үтелгән көннең сагышына бирелгән Бибинур. Һәр үтелгән көннән кешеләрдә үзләре дә анык тоя алмаган нәни генә моңлы бер сагыш кала. Югалту сагышы...

—Безнең гомер кояшы чыгып кына килә әле, Бибинурым—күз нурым!—диде утыз алты яшьлек Ахунжан, көрәктәй дәү кулларын хатынының жилкәсенә йомшак кына салып.

—Ничек чыгып кына килсен инде ул?—дип көлде яшь хатын, кич тынлыгын бозарга теләмәүдән ак яулык чите белән ап-ак энже тешләре балкыган, кызыл иннек сөртмичә дә кызарган сусыл иреннәрен каплап.

—Мина да, әтисе утыз дүрт тулды ич инде! Син үзең дә хәзер дүрт бала атасы...

—Һә-әй, әнисе!—дип елмайды ире.—Без бит әле кырыкка да житмәгән, кирәксә тагы дүртне алып кайтырбыз!

Яраткан ир сөйгән хатынын кочагына кысты, мәхәббәтле хатын назлы ир куенында, майлы табада йөзгән коймактай, беркавем эреп торды. Рәхәт иде аңа Ахунжаннан әлеге тәмле-җайлы сүзләрне ишетү. Эченнән генә ул Ходайга ялварды:

—Йә Рабби, бәхетебезне артык күрмә! Йә Рабби... Шатлык куанычыннан исереп, ул әле тагы әллә ниләр пышылдады. Ире сискәнгәндәй итте:

—Бибинур, нәрсә үз алдыңа сөйләнәсең әле син, әй-әй?

Хатыны, әйтергәме-юкмы дигәндәй, тутырып аның күзләренә карады, аннан карашын кинәт жиргә төшереп:

—Бүген мин начар төш күрдем...—диде.

—Яле, сөйлә...

—Бәлки ул яманга да түгелдер, тик шулай да...

—Әй-әй!—дип өзде Ахунжан Арча ымлыгы белән.—Һәр төшне начарга юрасаң, аларның барысы да яманга. Син әле төш юраучы әбине дә чакырырсың, ә? Һаман шул дини хорафатлардан арына алмыйбыз! Өчиледә мәчет тә юк, югыйсә...

—Мәчет һәркемнең жанында ул, картым,—диде Бибинур, татар хатыннарына хас булганча тыйнак кына, күп сүзен кискен бүлдерми генә...

—Йә, ярый!—дип килеште Ахунжан көрәк кулларын аның жилкәсеннән аерып.—Балалар барысы да йоклыймы?

Бибинур өнсез калды, ни дип тә жавап бирергә белмәде. Юк, иренә жавабы әзер һәм ул бик тә гади иде:

—Әйе, йоклыйлар...

Рәхәт, тыныч, сабыр, жайлы жавап иде ул. Ә менә...

Ә менә шулай һич тә көтмәгәндә, уйламаганда-нитмәгәндә, Ахунжанның дәү кулын аның жилкәсеннән алуы...

Әйе...

Бу гади бер ирнең кулы жилкәдән аерылу гына түгел, бу—гүя ак фәрештәнең аның бер жилкәсеннән очып китүе иде. Авыр кул салынган ул кулбашы үзен ничек рәхәт, ипле, көйле сизгән иде, дәү кул аңа бетмәс-төкәнмәс жылылык: хатын үзе дә сизмәгән энергия, яшәү көче, дәрт-дәрман бирә иде, хәзер аңа кара ташлы таулар өелгәндәй булды.

—Соң инде, өйгә керик...—диде ул иренә.

—Нәрсә соң?..—дип сорап куйды үз уйларына баткан Ахунжан Бибинурының сүзләрен ишетсә дә мәгънәсенә төшенмирәк калып.

—Кояш батып бара...—диде күз нуры.

—Батса ни!—диде Таяныр жилкәсе кисәк кенә.—Бүген батса, иртәгә калкачак. Кояш бата да калка ул!!

—Кешеләр генә...—дип, әрнүле пышылдады хатын эчке бер авыр ыңгырашу белән.

Ишетте моны Ахунжан:

—Без кешеләр дә шулай: бабайлар гомер диңгезендә баткан, әтиләр калыккан. Әтиләр бата—бабалары калка... Ул балалар да бер батар—оныклар калкыр!

Ул тагы Бибинурының инбашыннан кочып алды:

—Их, күз нурым! Калхузлар төзеп йөрүем әллә юкка гына, эч пошканга, кул

кычытканга гына дип уйлыйсыңмы? Шушы калхузларда минем бар өметем. Без тормышның ачысын күрдек, балаларыбызга хет аның төчесе, ә оныкларыбызга баллысы эләксен! Шуна дип йөрү ич, шуна дип тырышу, әй!

—Бу тырышуларыңны кирегә уйлаучылар да бар...—диде Бибинур.

—Беләм-беләм...

—Астан пычак кайраучылар да юк түгел...

—Пычакларын сугымга дип куйган малларына тотсыннар!

Аннан соң батып баручы кояшка карап алды да, утыз алты яшьлек таза-нык ир икәнен оныткандай, йөзенә туксан яшьлек аксакаллар чырае иңдереп, маңгаена җыерчыклар чыгарып әйтеп куйды:

—Кояш бабай булып бата, онык булып калка...

Алар, яшь чакларын искә төшергәндәй, җитәкләшеп болдырга күтәрелделәр.

Балалары тәгәрәшеп сәкедә йоклап яталар иде: Гайшә, Сажидә... Алар арасында Гарифҗан. Апасы белән сеңлесе арасына кереп яткан шук малай. Тиктормас җан ул аның малае! Беренче улына зур өмет баглый иде Ахунҗан, чөнки беренчеләр—күз уңында. Аннан соң!..

Аның бу малаенда «нидер» бар. Әлеге «нидер»не ата кеше үзе дә аңлап бетерми әле, ләкин сизгер җаны шул «нидер»не тоемлый, акылы ачык бер фикергә килмәсә дә, йөрәге сизенә, аңына дәшә:

—Бу улың буш кеше булмаячак, аннан илгә күренекле инсан чыгачак!

Кем булыр ул Гарифҗан?

Ахунҗанның әлегә кадәр бу сорауга төгәл ачык җавап таба алганы юк.

Чөнкиме? Чөнки аның улы—иң беренче сәерҗан. Аның әлеге сәерлеге хыялый булуында да үтәли күренә кебек. Авыл балалары гадәттә реаль тормыш кысалары эчендә яшиләр: аларга, тәүгедә—ашау булсын, аннан соң—кием-салым, тагы уеннар. Болар өстенә авыл баласы төрле-төрле эшләр белән дә кысылган була. Үзеннән кечерәк энесен яисә сеңлесен—бәби дә карыйсы бар, бәбкәләр сакларга да тиеш ул! Шул бишектәге бәби белән бәбкәләр арасында әллә нинди охшашлыклар таба аның улы. Кирәк икән бәбидән бәбкә ясый, яисә киресенчә—каз, үрдәк бәбкәләренә бишектәге бәбәй-нарасыйга сүз каткан кебек эндәшә. Алар белән пипелдәшә-сөйләшә...

Болар өстенә серлеҗан да Гарифҗан. Кайвакытта аның Күккә карап, йолдызларны багып, үз алдына пышылдап утыруын ни белән аңлатырга?

Әллә инде җиде айлык булып җитлекмирәк тугангамы, аның бу сәер-серле җанлы булуы? Алай дисәң, дөньяга әнә нәкъ ике айга ашыгып килгән бит ул! Әнкәсенең ишеген иртәрәк ачкан... Ызначит, ачар көче булган, әй-әй!

—Йә, ярый...—дип үзен тынычландырды ул.—Иртәрәк ачса да якты дөньяга ишекне, озак яшәп, соңлап япсын аны...

—Ятасыңмы, Ахунҗан? Урын әзер,—диде Бибинур.

—Ятам, күз нурым.

—Ят, картым...

—Валлаһи дим, картайтма әле син мине. Әле миндәге ут! Кочагыма алсам, йолдыз итеп яндырам мин сине!!

... Таң алдыннан Бибинур сискәнеп уянды. Кемдер тәрәзә шакыды түгелме? Ул пыялага бакты. Юк, анда беркем дә күренми. Янә ятты...

Ире тыныч сулыш белән йоклап ята иде. Менә ул, үкенечле аваз чыгарып, кисәк кенә ыңгырашкандай итте. Дөрес, бу ыңгырашуның авазы да ишетелмәде, ләкин ир хатыны аны барлык тән күзәнәкләре, җанының иң нечкә кыллары белән тоеп алды. Сәкедә ятучы балаларның берсе еламсырап куйды...

Бибинур, корт чаккандай, сикереп торды:

—Кайсысы ул?

—Гарифҗан бит?

Монысын да ана йөрәге бер мизгел эчендә, күз ачып йомганчы сиземләде.

Ул сәке янына килде...

Балалар тыныч кына йоклап яталар иде. Иң кечкенәләре Марат бер читтәрәк. Гарифҗанның маңгае тирләгән, шуңа ул өстендәге япмасын бәреп төшергән.

Ана улының өстен япты.

—И-и, балам! Ачлык елдан соң дүрт ел үткәч, бәрәңге алганда тудың бит син. Әтиең, син тугач, ак күлмәкләр тектерде, туган-тумачаны чакырып, зур бер бәйрәм

ясады... Гаиләгә ир бала тууга ничек сөенгәннәребезне күрсәң иде!

Бибинур Гарифҗанының маңгаен сөртеп алды:

—Әтиенә охшагансың! Ә бит биш еллар элек кенә синең баш очында Үлем Фәрештәсе канат кагып кына торды. Күрсәтмәгән врач, өшкертмәгән ырымчы калмады. Инде аптырагач, күрше карчыгы киңәшен тоттым...

Ана эчтән генә уфылдап куйды:

Йә Алла! Аның рәхмәтләре... Ходайның рәхимлелеге...

—Ә күрше карчыгы, улым, изге кеше иде ул. Күпне күргән, күпне ишеткән. Үзенең кәегәеп барган ирен дә дару үләннәре белән дәвалап аякка бастырды бит ул...

—Ә миңа болай диде: «Кызу итеп мич як та, күмерен алып, томалагач, бу баланы, ипи көрәгенә утыртып, мич эчендә җылыт. Ипи булып пешеп чыксын. Ана җылылык житми, эчендә салкын утыра». Нәкъ шулай эшләдем, улым, мичтә җылытып эчендәге салкынынны кудым. Менә хәзер... Аллага шөкер! Ходай саулыкларыннан аермасын!!

* * *

Таң атты...

Өчиле таңы...

Шүрәле каргаган авыл таңы. Чөнки теге Былтыр атлы батыр егет нәкъ шушы авылдан булган бугай. Урмандагы агач ярыгына урман пәриенең опозын бармакларын кыстырып киткән Былтыр. Андый хәйләкәрне Кырлайда да күргән Тукай. Икенчесе әнә Өчиле тирәсендәге шүрәлене капкынга каптырган. Шулай булмаса, Өчилене:

—Шүрәле каргаган авыл,—димәсләр иде.

Каргаганмы, юкмы—унөч йортлы авыл мондагы һәр гаиләгә ифрат якын, уртак урын, шатлык-куанычлар, хәсрәт-сагышлар почмагы. Казан арты дип атала бу! Казансу елгасы да монда ага. Өчиледән өч чакрымда Казанбаш дигән зур гына авыл да бар...

Казанбашның гаярь кешесе Абдулла Заһидуллин белән берлектә Өчиле Ахунҗаны колхоз төзеделәр. Күмхуж төзәргә шул замана җилләре—давыллары этәрде аларны.

... Таң атты... Июнь таңы...

Кояш искиткеч яктылык сипсә дә, аның нурлары үзендә рәхәт бер җылылык, тән эреткеч йомшаклык һәм эчке сихри ләззәт бирә торган чаткыларны китереп житкермиләр әле...

Малай ишек алдына чыкты...

Мәҗүси кебек бер кавым иртәнге илаһи Кояшка карап торды. Ул җиз тәлинкәдәй кызгылт әле. Хәтта...

Кандай кызыл...

Иртәнге салкын чыклар белән битен юган яшел чирәмгә басып, малай бакча ягына чыкты. Уена гөнаһсыз нәни фикер килде:

—Бүген көн нинди булыр? Мансур белән умарталы уйнарбызмы? Шырпы тартмасына япканда, бал корты чакмасмы безне?

Абзарда көр генә итеп ат пошкырды. Ахунҗан үз хуҗалыгыннан күмхуҗга биргән айгыр, йөрәк кагып чаба торган аргамак.

Кара туры айгыр!

Малай аннан бераз шүрли дә. Җайсыз-уңайсыз янына килсәң, колакларын шомарта, кара куе ялларын—оп-озын сачларын!—дулкын-дулкын селкетеп, «йөрмәле мин солы ашаганда» дигәндәй, күзләренә усаллык кертә, борын эче тыгылгангамы, әллә башкагамы—таза гына итеп пошкырып куя.

Малай андый чакларда куркып ук китә. Ат тирәсеннән читкәрәк тая.

Бумы? Тибеп җибәрсә, өеңне аударыр!

Кара туры айгырны ул әкияттәге теге хәтәр атларга ошата. Монын канаты гына күренми. Аны да кагып чапсамы? Очачак бит ул, очачак...

Ул кара айгырга якынрак килде. Ни гаҗәп, ат бүген элек булмаганча юаш иде, акыллы иде. Нигәдер ул арка тирәсенә дулкыннар чыгарып ала. Күзгә дә күренмәс вак-вак кына дулкыннар, гүя кышкы зәмһәрир суыктагы кебек, кара-туры туңа иде.

—Әллә этинең тунын өстенә салыргамы?—дип тә уйлады малай. Үзе шундук бу уеннан кире кайтты:

—Әнә ничек биек ул! Лапас астында тормаса, монын башы күккә тиячәк бит... Ул шундук хыялга бирелде.

—Их! Әти моны тарантаска җиккәч, мине утыртып, бер авыл урамын әйләндереп кайтачак әле. Бәлки... бүген үк... Сабан туе арты көне бит...

Хыялдан чынлыкка кайткан малайның баш чүмеченә кырысрак уйлар да керде:

—Юк... юк... Әти эш вакытында арага кереп, борчып йөргәнне бер дә яратмый. Әнә теге сары кенәгәне ерткан өчен арт ягыма берне кизәнми генә салган иде, егылып ук киттем. Әтинең кулы каты аның. Минем борын канаганны күргән әни әтигә әйтте: «Син нишлисең, Ахунҗан? Үз балаң бит ул! Йөрәк бәгырең»...

Ә әти әнигә әйтте:

—Кысылма, Бибинур! Нәрсә «ярый», нәрсә «ярамый»ны белеп үссен. Иблис-шайтан баласы түгел ич ул, әй!

Ә аннан соң...

Аш табагы кадәр кулын минем башыма куйды һәм йомшак кына сыпырып:

—Елама, улым, елама!—диде.—Тормышта сиңа әле бер генә аяк чалмаслар, бер генә екмаслар. Ә син һәрвакыт аягына басучан бул. Безнең халыктагы әкият Алып булып, аякларына бас һәм алга атла. Бары тик алга!

Аннан ул малайның үзе үк суккан жирен сөйде дә күзләренә елмаеп карап болай диде:

—Мин бит уйнап кына, улым...

—Мин яратып суктым ич...

—Мин сине яратам бит. Күтәреп алган Ак Күлмәкле Улым ич син минем. Әй-әй!!

Шул сүзләрдән соң ике жилкәсеннән тотты да:

—Моннан соң, улым, мин сиңа беркайчан да сукмам. Монысы—беренчесе һәм ахыргысы... Монысы... Истәлеккә...

Бу сүзләрдән һәм әтисенең дәү кытыршы кулын тоюдан хисчән малайның күңеле тагы да нечкәреп, күзләренә яшь бәрде.

—Әтием! Әтием!!—дип пышылдады ул Җанының тавышсыз теле белән эчтән генә. Үзе дерелдәп киткән гәүдәсе белән шушы Ата дигән көчле кешегә сыенды.

Кырысрак әтисенең дә күңеле жебеп юашланып китте, бәгыренә кагылып, башыннан аягына кадәр нәндидер җылы вә дәһшәтле ташкын узды. Ул малайны күтәреп алды һәм күкләргә чөеп, бер генә сүз әйтте:

—И-иһ, улым, ул-лы-ым!!!

* * *

Кояш күк гөмбәзеннән шактый өскә тәгәрәгәч, Өчиленең ике кешесе күмхуж рәисе Ахунжанның өенә аяк басты:

—Сине Төрнәлегә чакыралар...

—Нигә кирәк булдым икән?—дип сорады йорт хуҗасы катгый гына.

—Баргач әйтерләр...

—Сез дә минем белән барасызмы?

—Әлбәттә инде...

Ахунжан үзенең тарантасына кара туры айгырны жикте.

—Бәлки барып йөрмәссең...—диде хатыны Бибинур аның янына килеп.

—Барыйк әле, күрик әле,—дип бүлде ире аны.—Күрәсене күрми, гүргә кереп булмый, дигән бабайлар...

—Күңелем шомланыбрак тора,—диде хатыны.

Өчиленең ике кешесе Ахунжанны ашыктырды:

—Киттекме инде?

—Утырыгыз, түземсезләр!.. Нәрсә сатасыгыз бар? Ник ашыгасыз шул кадәр?

Дилбегә кагуга, кара туры айгыр аждаһага охшаш кара тузан болыты күтәреп Төрнәлегә чапты...

... Малай күршедәге кордашы Мансур белән умарталы уйный иде. Оясына кереп барган бал кортын тоталар да шырпы тартмасына ябалар.

—Менә хәзер ул эченә җыйган балын шушы тартмага салачак,—ди ул, эчтән генә хыялланып.

Ачып карыйлар—бал юк, тартма коры.

—Салмый,—дип бәхәскә кереп китә булачак профессор, еллар узгач, Ленинградта торачак Мансур Ибәтуллин.

—Сала! Баллы булабыз.

Шулчак...

Йөрәк кагып чаба торган кара айгыр гөрселдәп авылга килеп керде. Ә тарантаста малайның әтисе юк. Тарантаста беләгенә кызыл тасма бәйләгән чит кешеләр...

Кара туры айгыр ак күбеккә баткан. Борын тишекләре бәрәңге сыярдай булып киерелгән.

Бибинур ишегалдына утын алырга чыккан иде. Кызыл тасмалы кешеләр, тарантастан сикереп төшеп, аңа нидер әйттеләр. Хатын кинәт кенә агарып китте, аннан йөзенә көл төсе керде. Кочагындагы утыннары дөбердәп җиргә коелды.

Кызыл тасмалар, аны да утыртып, кире Төрнәлегә чаптылар...

Малайларның күзе ак күбеккә баткан атны бер мизгелдә шәйләп кенә калды...

... Авыл купты...

Өчиле гүя бер минутта өч йөз йортлы салага әйләнде...

Күп тә үтмәде, авылның барлык ир-атын җыеп, Ахунҗан амбарына яба башладылар.

Елау-сыкрау... Тиргәү-каргау белән тирә-як тулды.

Мансур белән малай, ни булганны аңламыйча, ак күбеккә баткан туры айгырны кызгандылар:

—Ай-һай, ап-ак булган бу!

—Каян чыккан аңа шул тикле ак күбек?

Сабыйларча беркатлылык белән фаҗиганың үзегеннән читтәрәк йөргән малайга табуттагы әтисен күрсәткәч кенә, йөрәгенә ут чолгап ала:

—Нишләп әтине киендереп агач яшьнеккә салганнар?

—Нишләп күзләрен ачмый ул??

... Аның әтисен Өчиледән өч чакрымдагы Казанбашның Казансу елгасы буендагы таш клубка куйдылар. Кара айгыр сырты төсле кара костюмнан иде ул...

—Кәчтүн ак күбеккә батмаган...—дип, сәер генә уйлап куйды малай.

Ул әтисе йөзенә бакты:

—Йөзе көл төсле ак...

—Күзләрен йомган...

—Дәү кулын күкрәк өстенә куйган...

Аны...

Үлгән диләр...

Ә малай—юк!—ышанмый:

—Үлмәгән ул...

—Пычак ярасын кулы белән каплаган... Менә хәзер сикереп торыр да аңа: «Улым»,—дип дәшәр. Хәтта кочагына да алыр. Кечкенә Маратны да сөяр, Гайшә белән Сәҗидәне дә...

Казанбаш авылының Арча ягыннан керә торган башындагы каберне күргәч, ул кинәт кенә дертсенеп китте:

—Әтисен шушы чокырга күмәчәкләр икән...

—Ник?

—Чөнки бандит пычагы аны һәлак иткән...

—Шушындый матур көндә кешене кабергә күмәләрмени?

... Җавап юк...

Ерак та түгел Казанбашның алма бакчасы шаулап утыра. Аста яшел болыннар хәтфә паластай җәелеп ята. Үзенчә бер иркенлек вә тынычлык белән Казансу елгасы ага...

Кинәт...

Күк йөзендәге алтынсу-сары кояшны каплап каяндыр кара болытлар килеп чыкты. Бу болытлар кай ягы беләндер кара айгырга охшый иде. Өсләрендә аксыл күбекләре дә бар...

... Ахунҗанны күмгәндә яңгыр сибәли иде инде... Халык күп агылды аның кабере янына. Атка атланган кешеләр дә күп иде. Өчиледән Казанбашка аны җиз

торба кычкыртып, барабан кагып алып төштеләр. «Матәм маршы» уйныйлар иде булса кирәк.

Малай гына шикләнеп эчке уйга калды:

—Ник кычкырталар бу торбаны? Әти барыбер ишетми ич... Ишетсә, торып аягына басар иде...

—Нигә кагалар, әни әйтмешли, ул «параман»ны? Әти барыбер ишетми ич...

Ул күтәрелеп, сорауларына җавап эзләгәндәй, әтисенә карый. Малайның күзләрендә яшь бөртекләре, тирән сагыш, кара кайгы...

Күккә карасаң да, болытлар елый сымак...

Нинди көн бу?

Нинди кара көн?

Менә аның әтисен кабергә төшерәләр. Әнә аны күмә дә башлыйлар...

Малай кычкырып елап җибәрүдән чак кына тыелып тора. Егылып китүеннән курыккандай әнисе итәгенә барып ябыша. Ул елап та җибәрер иде, кемнәрдер әнә нидер сөйлиләр, кемнәргәдер яныйлар, кулларын ачулы болгыйлар...

Боларның сүзләре—әтисе белән соңгы тапкыр мәңгегә саубуллашуның үкенечле авазлары.

Яна кабер өстенә кара балчык кечкенә тау итеп өелә...

—Юк!—дип уйлый малай.—Әти хәзер бу балчыкны күтәреп кире чыга алмаячак инде...

—Менә ул суга батсын иде, калкып чыгар иде.

—Өчиледәге җиде чишмә суын бергә кушып, өстенә койсаң да калкыр иде ул...

Күңелен авырту, югалту ачысы юа башлый, ә үзе һаман аңламый:

—Нәрсә соң бу?

—Ни нәрсә икән бу??

Шулвакыт..

Килгән атлы кешеләр, кызыл тасмалылар, мылтыкларын күккә күтәреп, өч тапкыр гөрселдәтәләр. Малай моның Өчиле Ахунҗанына соңгы салют икәнен башына да сыйдырмый, аңа хәзер шушы мылтыклардан әнисен, энесен, Гайшә белән Сәҗидәне... һәм!—үзен атып үтерәләр кебек тоела.

Аның коты ботына төшә...

Ул, куркынып, кычкырып елап җибәрә. Малайның елавы күңелләргә шом кертә. Аны кызганалар...

Инде малай җиргә утырып елый...

Шулчак...

Кемдер аны күтәреп ала...

Шул ук көчле куллар аны үзенең җилкәсенә утырта да кабер яныннан читкә алып китә. Тыныч-ипле сүзләр белән юата-юата...

Малай тынычлана...

Аның күңелендә бер генә уй:

—Кем микән бу яхшы күңелле абый? Ул бит безнең Өчиленеке түгел...

... Еллар узгач кына ул бу кешенең драматург Кәрим Тинчурин икәнен белә. Аның белән рәттән торганы—Салих Сәйдәш.

## Коткаручы...

*Китә күрмә, зинһар, ахунлыктан,*
*ярдәмеңнән безне ташлама!*

И. Юзеев.

Ләүхел-Мәхфүз... Китаплар анасы... Язмыш китабы...

Безнең тормышта ни күрәчәген, ниләр үтәчәгеңнең алдан билгеле булуы, шунын тууына ук язмыш тактасына язылып куюына шикләнеп вә сагаеп караучылар да шактый. Язмышка ышанучылар да аз түгел...

Шәхсән үзем язмышка—Ләүхел-Мәхфүзгә ышанам—һәм...

Әтисен җирләгәндә, мылтык гөрселдәткәннән соң, җиргә утырып елаган малайны җилкәсенә утыртып алып киткән бөек татар драматургы Кәрим Тинчурин бу гамәлне

тикмәгә генә башкармаган ич! Уйлап карыйк әле: нигә аны Өчиледән берәр агай үз җилкәсенә атландырмаган соң? Чөнки...

Фәрештәләр пышылдаган Тинчурин колагына:

—Бу малай киләчәктә синең кебек үк татарның зур язучысы булачак. Ул әтисенең кабере янында күз яшьләрен түгә. Күтәр аны өскә! Юат!! Җилкәңә ал!!!

Яисә менә тагы бер мисал...

Продразверстка гамәле буенча азык җыючылар арасында унбиш яшьлек Мишка Шолохов та була. Батько Махно кешеләре боларны тотып алалар. Приказ—барысын да атарга! Шунда Махно яшь кенә Мишкага карый да:

—Ә монысын җибәрегез!—ди.

Каян килгән аңа бу уй?

Күкләрдән ишетелгән. Күкләр пышылдаган аңа.

—Бу егет-малайны исән калдыр!

Менә шулай итеп Махно булачак бөек язучыны, Нобель премиясе лауреатын саклап калган.

Кемдер әйтер:

—Очраклылык!

Әнә шул очраклылыклардан кануннар туа да инде ул! Шулай итеп бөекләр бөекләрне коткарып кала. Үзләре дә сизмәстән. Күрәсең, монда күбрәк югары көчләр, мистика күп нәрсәне хәл итәдер. Дөрес, кайчак бөек инсаннар бер-берсенә каршы да төшәләр? Наполеон—Кутузов, Гитлер—Сталин... Болар сугыш учагында, явызлык кочагында гамәл кылучылар. Ә инде әдәбият-сәнгать даһиларына килгәндә, алар бит явызлык түгел—ә яхшылык генийлары һәм аларга кешелекне батыручыдан бигрәк инсаниятне коткаручы орлыгы салынган була. Якты утлы Рухларына, җылы-йомшак Җаннарына. Әйе, алар да тән өчен дә хезмәт итәләр, иҗадилыкларын күпмедер дәрәҗәдә шуңа корбан кылалар. Үзебезнең Рудолф Нуриевны гына алыйк, «оча торган татар»ны, XX гасырның иң бөек биючесен. Иксез-чиксез байлыкларга ия булуына да карамастан, әлеге мәшһүр инсан өчен фани дөньяда иң әһәмиятлесе балет булган. Хәтта ул, шактый ук кабаланып: «Минем милләтем—балет!»—дип тә ычкындырган. Гафу итик, хисләр йолдызларга якынайганда, адәм балалары эмоциядән шартлар дәрәҗәгә житкәндә, мантыйкка сыймаган сүзләрне дә әйтеп ташлыйлар. Хәер...

Югары сәнгать бервакытта да логикага буйсынмый ул. Аның яшәеше Туу-Үлү, Тәртип-Хаос, Мәхәббәт—Нәфрәт кануннары. Ул шушы араларда Яхшылык вә Матурлык камиллеген эзли. Кешелек тулы Гармониягә ирешкәч кенә чын Бәхеткә тап булачак. Хакыйкатьне табып бетереп булмаган кебек, инсаният бервакытта да тулы Гармониягә ия булачак түгел, чөнки Алар турыдан туры Галәми Рухка, Тәңрегә тоташкан. Безнең максат—шуларга омтылу, шунсыз Адәм Илен гөнаһлар, җан пычраклыгы, рух сүнүе, явызлык һәм ямьсезлек басып китәчәк. Болар барысы да инкыйразга, бетүгә, бөтенләй юкка чыгуга хезмәт итәләр!

Кеше—иң уникаль җан иясе.

Андыйны галәмдә дә табып булмаячак, чөнки ул—үзе бер галәм...

Инсаннар арасында ике иң көчле бүленеш бар: яхшылар һәм явызлар, коткаручылар һәм батыручылар. Алар арасында соры төркем булып битарафлар тора. Болар бик күп, алда без атап киткәннәрдән меңнәрчә, миллионнарча мәртәбә артык. Бу Олуг Бер Көтүне хәтерләтә, сарык көтүен. Теге ике бүленеш вәкилләре бер төсле үк көчле теләк белән әлеге Көтүнең Көтүчесе булырга телиләр. Библия теле белән әйткәндә, «Пастырь овец...» Сарыкларга ни: ашарга булсын да эчәргә, үрчергә. Тамак туйгач, ял итәргә, кич житкәч—йокларга...

Баш Атабыз Адәм, Баш Анабыз Һаува тормышына күз салсак, ике капма-каршы Көч Һабил белән Хаиннан ук башлана. Адәм, Һаува улларыннан. Бүгенгесе—көтүче. «Көтүче» монда зур мәгънәдә—җирдә җирнеке белән ризалашып, җирдәгечә, табигатьтән узмый гына, аны корытмый-ватмый, борчымый-интектерми генә, булганына шөкерана кылып яшәү.

Икенчесе—игенче... «Игенче» дә зур мәгънәдә—ризасызлык, канәгать булмау, көнләшү, табигатьнекен талап, тартып-йолкып гомер итү.

Беренчесенә Хак риза, рәхмәтле...

Икенчесе Тәңрегә ошамый...

Шулвакыт арага Хөсетлелек килеп керә һәм—Үтерү... Кеше үтерү...

Үз туганыңны...

Инсаниятта әнә шул вакыттан бирле Бәрелеш бара. Кешелекне талкый торган, кан коюларга китергән бәрелеш. Бу—Аллаһының бәндәләр өстенә җибәргән Ачы Каргышы гына түгел, юк! Ә аларны тагын бер сынап каравы. Адәм белән Һаувадан соң...

Бу Сынау—Саваплар һәм Гөнаһлар аша бара. Кайсы үлчәү тәлинкәсе басар? Сорау—Ходайдан, Җавап—бәндәләрдән.

... Бу сүзләрне милләтебезгә борып карасак, безнең татар халкында да аны, олуг бер этник группа буларак, коткаручылары һәм батыручылары бар. Безнең сөйләмдә ул милләтпәрвәрләр һәм манкортлар исеме астында яши һәм бәяләнә.

Шәхсән үзем аерым бер кешене генә телгә алсам, коткаручылар рәтенә Гариф Ахуновны да кертәм. Прозабыз Ахунын...

Тагы бер кечкенә генә экскурс, үткәнне искә төшерү.

... Бер көнне кич Татарстанның Суверенлыгы юбилеен телевизордан карап утырам. Биш еллык!

Нәни дата бу—әмма аның артында шактый эшләр, күп кешеләр, яна көчләр...

Юбилей булгач, чыгалар, сөйлиләр. Менә татар язучылары исеменнән (ә бәлки туган халкы исеменнән?!) трибуна артына Гариф абый чыгып баса...



*Язучылар делегациясен Актаныш җирендә каршылау. Уртада—Гариф Ахунов. 1978 ел.*

Бер генә сүз әйтим—иң шәп чыгыш иде ул! 70 яшьлек ир 17 яшьлек егет кыюлыгы, кайнарлыгы, дәреслеге белән сөйләде. Аннан риза булган Президент Шәймиев тә елмаеп кына утырды:

—Сөйлә, Гариф абый! Мина әйтергә ярамаганнарны да Премьер Черномырдин алдында ярып саласың ич,—дигәндәй.

Ул шулай уйладымы, белмим. Ә менә минем баш миемне ул чакны бер генә уй кисеп үтте:

—И, Ходаем! Күпме гомерем бар, нинди генә матавыклы хәлләргә калсам да, мин бу Инсанга каты бәрелмәм, аның турында начар сөйләмәм.

—Бары менә шушы сөйләге өчен генә дә...

# Китап

*Шайтаннарга каршы, көрәштең син:*
*Гел-гел китап булды кулыңда.*
И. Юзеев.

Прозабыз Ахуны дигәч тә...

Шәхсән үзем прозаны ике агымга бүлеп карарга яратам: беренчесе, булган хәлләрне сөйләп чыгу, ягъни мәсәлән, сюжет җебен нык тотып, вакыйгаларны бәян итү, шуңа да мин аны бәян-проза дип атыйм да; икенчесе, булган хәлләрне сурәтләү, ягъни, сюжет җебен кулдан ычкындырмыйча, вакыйгаларны тасвирлау, шуңа без фәкыйрегез аңа тасвир-проза дигән исем кушты да.

Бәян—хикәя кылу, сөйләп чыгу.

Тасвир—рәсемләү, тасвир (күз алдына китерү).

Бәян тормыштан килә, ул документалистикага, автобиография йә биографияләргә бик якын тора; чын-саф реализм.

Тасвир—хыял, фантазиядә туган тормыш, аңа реализм белән!—бигрәк тә романтизм хас.

Әлбәттә, бәян-проза белән тасвир-прозаны аерып куйган ныклы чикләр, киртәләр яисә диварлар юк. Һәр язучы шушы ике төрле проза арасында адашып йөрергә, берсеннән берсенә күчәргә мөмкин. Хәтта бер үк әсәрдә дә...

Алыйк, Ибраһим Газинең «Онытылмас еллар»ын. Аның беренче ике китабы тасвир-проза, соңгысы—бәян әсәр. Моны укучының нечкә күңеле генә сизә ала.

Инде тәгаен сорау куйыйк:

—Гариф Ахунов язганнар—аның хикәя, повесть, романнары—кайсы прозага керә?

Алыйк аның «Ардуан батыр», «Гомер юл»ы әсәрләрен. Болар конкрет кешеләргә багышланганнар, төп геройлары Мирсәет Ардуанов һәм Фәйзи Галиев. Беренчесе Пермь өлкәсенең Березники каласында химкомбинат төзегәндә хезмәт батырлыгы күрсәткән. Әсәрнең башламы да әчке пафос, чын горурлык хисләре белән сугарылган:

«Березники каласында һәйкәл бар. Дәү такыр башлы бер кеше биек постаменттан уйчан гына карап тора. Һәйкәлне карарга килүчеләр мәрмәргә чокып язылган сүзләрне укыйлар: Мирсәет Ардуанов, 1886—1959.

Укыйлар да уйга калып торалар: Пушкинга һәйкәл бар—шагыйрь. Чайковскийга һәйкәл бар—композитор. Чапайга һәйкәл бар—сугыш герое. Кем ул Ардуанов? Ник аңа һәйкәл куйганнар?»

Менә нинди гаҗәеп башлам! Ул шул мизгелдә үк хис-тылсым белән әлеге әсәрне укырга чакыра. Ә теге сорау «Ник аңа һәйкәл куйганнар?» күңелне гел бимазалап тора: Ник? Нигә?? Ник? Нигә??

Ә җавапны повестьның ахырында гына табасың.

Бәян-проза шундый жанр аерымлыгы ки, әгәр укучыны бер генә минутка истән чыгарсаң, ул туктаусыз «сөйләү»дән арачак, шуңа аны «Ник аңа һәйкәл куйганнар?» дигән сорау-интрига белән гел дә гел кытыклап торырга, йоклатмаска, укыла торган китапны ташламаска кирәк.

Менә повесть ахыры...

Ни өчен Березникида Ардуановка һәйкәл куйганнарын аның белән бергә 40 ел эшләгән карт эшче Коновалов әйтеп бирә:—Ардуан батыр әнә шул Маяковскийлар, Чайковскилар, сезнең милли батырыгыз Җәлилләр кебек иҗатчы иде. Менә шуның өчен аңар һәйкәл куйдылар. Рус шәһәрендә татар эшчесенә беренче һәйкәл.

Эшче—иҗатчы... Хезмәт батыры...

Оныта барабыз түгелме бу сүзләрне? Бары Эш һәм Иҗат кына тота бит кешелек дөньясын! Ә без...

Әле бүгенге бушбугазлардан берәрсе:

—Һәй, Химкомбинат салган ич ул!!—дияр. Әй, андый комбинатлар табигатькә зыян сала, кеше сәламәтлеге өчен дә бер дә файдалы түгел. Ләкин, нишләмәк кирәк, кайсыбыз туфлиен ташлап кире чабатага кайтырга тели?

Менә шундый хәл! Аның монысы да теге Адәм белән Һаува заманыннан килә ич инде. Тереклек итү өчен ике юл бар:

—көтү көтеп кенә яшә дә, чиста-саф табигатьтә хозурлан!

—Иген ик, жирне актар-каер, табигатьне имгәт?!

Кешелек һабил сукмагын түгел, Хаин юлын сайлаган...

... «Ардуан батыр»га килгәндә, мин аны яшьлегемдә бик яратып укыган идем. Татар халкының хезмәт сөюче, үтә тырыш, үҗәт милләт икәнен раслаучы һәм шуна әдәби һәйкәл дә куючы әсәр иде ул. Повесть милләтебезнен ин көчле характер билгесен ачып бирә алган. Бер уйласан, һәр рус шәһәрендә татарга һәйкәл куярга була. Бар андыйлар, хәтта күп алар! Милләткә миллион кешеләр аша түгел, бер шәхеснe күреп бәя бирәләр, шуны онытмаска һәм алар белән горурланып яшәргә иде. Мирсәет Солтангалиевләрне генә түгел, Мирсәет Ардуановларны да һәрдаим искә төшерү кирәктер. Нәрсә ди бит әнә Коновалов:

—Беләсезме... бер кеше бөтен бер милләт турында фикер уята икән.

Повестьнын бүгенге көн күзлегеннән караганда да төп көче—Ардуан батыр кебек милли характерны күрсәтүче герой белән чын мәгънәсендә горурлану. Ә горурлык хисе, милли ан дигән нәрсә безгә һаман да житенкерәми.

Шуна «Ардуан батыр» кебек әсәрләр тиз генә искерәчәк түгел.

Гариф Ахуновнын ин беренче күләмле әсәре «Яшьлек яме» дә—бәян. «Яшьлек яме»нен беренче битендә үк тасвир-проза сизелә сизелүен, ләкин анда алга таба «сөйләп чыгу» манерасы хәлиткечкә әйләнә һәм автор тасвир вә хикәяләү аша укучыны ышандырырлык әдәби тормыш тудыра алган.

Инде «Чикләвек төше»нә килсәк, анын беренче җөмләсе үк баштан үткәннәрне сөйләүгә корылган булуын раслый. Төп геройларның берсе Рокыя менә ни ди:

—«Мин анардан гел аерылам дип яшәдем. Ул хакта бер кешегә дә сөйләмәм дигән идем. Ләкин еллар үтеп, тормыш тәҗрибәм арткач, сөйләргә булдым.

Чөнки ул—кешеләргә кирәк».

Шушы ике-өч җөмләдән соң ук баш миен сораулар күче кимерә башлый:

—Кем ул «мин»?

—Ул кемнән аерылам дип яшәгән??

—Нәрсә ул «кешеләргә кирәк» дигәне??? Гомумән, Гариф Ахуновны һич тә арттырмыйча:

—Башламнар остасы!—дияргә була.

Нәкъ менә Г. Ибраһимовнын:

«Фәхрине үтереп ташладылар»ы кебек башлап җибәрергә ярата ул. Бу сүзләрдән сон, «кемнәр?» дигән сорау туа да туа инде, ә Ахуновнын «Чикләвек төше»ндәге башламыннан сон берьюлы өч сорау (!!!) Шул өч сораугa җавап эзләп укучы күзе



*Сулдан уңга: Зәки Нури, Мөхәммәт Садри, Гариф Ахунов, Мөҗәһит Вәлиев, Давид Көгелтинов. 1981 ел.*

повесть юллары буйлап чаба гына инде! Кая барсын? Сорауларга җавап эзләү—тормыш, яшәү инде ул. Әнә шулай шыксыз Гапсаматлар аша укучы әсәрнен төп герое Халикъ Саматов белән таныша. «Кешеләргә кирәк» дигәнне дә таба укучы:

—Монысы—иман, дөреслек, намус.

Ләкин әсәргә тагы бер идея дә салынган:

—Югарыда кем генә утырмасын, хикмәт утыручыда түгел, фундаментта.

Бүген бик тә актуаль яңгырый бу сүзләр! Югарыга карама, анда хикмәт юк, үз «фундаментыңны үзең рәтлә», «ватык кирпеч яки черек агач эләксә»—алып ташла!

Фундамент—ил нигезе, халык инде ул, Халикъ Саматов кебекләр...

«Яшьлек яме»ндәге кебек тасвир-прозага омтылу авторның «Идел кызы» кебек киң колачлы роман-эпопеясында күренде. Гариф Ахунов аны өч китаплы, ягъни трилогия итеп язарга уйлаган. Әлеге әсәрне язарга аны М. Шолоховның «Тын Дон»ы этәргән булса кирәк. Бердән ул рус язучысын үзенең кумиры санаса, икенчедән «Тын Дон»ны татарчага тәрҗемә иткән кеше дә бит (икенче, дүртенче китаплар).

Дистәләрчә геройлардан торган тасвир-прозада да гаҗәп тә ныклы каләм иясе икәнен, эпик әсәр язганда тасвирлыкка көчлелеген, ә инде рәсемләү буенча чын художник икәнен ачып салды әдип. Димәк—ул зур талант!!

## Гөнаһлылар җире

*Ахуныбыз безнең, хәзрәтебез,*
*Без гөнаһлы, әйтче, нишләргә?*

И. Юзеев.

Әй, яратабыз инде без теге яки бу әсәрне сүтеп-тураклап карарга! Әйтерсең лә, сабый үз уенчыгын кисәкләргә, шөрепләргә аерып карый. Ә бит дөньядагы һәрнәрсә бөтенлеге белән матур. Гүзәл һәм Камил!

Тәнкыйтькә һәм аның әһелләре теленә клише булып кергән баналь сүзләр бар:

—Менә бу төшен болай язмаган... Идея эчтәлеге ачылып җитмәгән... Сюжет линиясен югалткан... Әсәр артыгы белән озынга киткән...

Бу инде «әнә моның буе озынрак, колагы әрекмән яфрагыдай, чәче юкарак, аягы кәкрерәк» дигән кебек. Ә аның җаны нинди? Рухы ни дәрәҗәдә?? Бу турыда уйлаучы юк. Чөнки... Чөнкиме?

Дөньядагы һәркем гөнаһлы булган кебек, аның Иҗаты булган һәрбер эшеннән дә гөнаһлар, җитешмәгән яклар табарга була. Монда: «Нишләргә?»

Әдәби әсәргә бәя биргәндә хикмәт «нәрсәне әйтмәгән яисә әйтеп бетерә алмаган»ны эзләүдә түгел, ә иң мөһиме:

—Нәрсә турында әйткән... Ә төп критерий:—Ничек әйткән?! Гомумән... Язучыны ничек итеп язарга өйрәтү иң ахмак эшләрнең берсе. «Әсәрендә теге юк, бу җитми»—диюләр дә зур мәгънәсезлек. Юкны нигә эзләргә ди һәм әдип «җиткерә алмаган»ны ничек җиткерергә? Үзең роман язып күрсәтеп кенә. Бөек роман!

... Студент еллар...

Тулай торакның бер бүлмәсендә дуслардан берәү борсаланып ята:

—Җегетләр! Ничек бөек буласы, ә?!

—Моннан да пүчтәк эш юк,—дидем мин.

Егетем караватыннан ук сикереп торды:

—Ничек?

—Бөек роман язып!

... Бервакыт миңа бер мөхтәрәм генә әдәбиятчы:

—Синең язган эсселарың, тәнкыйть мәкаләләрең язучыларның иҗатын яктыртудан, аңа анализ ясаудан да бигрәк мактауга кайтып кала. Тәнкыйтьләүгә караганда тәнкыйтьләмәү сизелә аларда,—диде. Хак сүзләр! Мин—хурлаучы түгел—мактаучы, җимерүче түгел—төзүче, күз йомучы түгел—булганны күрүче...

Без болай да күп хурлыйбыз, күп җимерәбез, күп күз йомабыз инде. Җитәр! Айныр вакыт: мактарга, төзәргә, булганны күрергә...

Елап-шыншып гомерләр уза:

—Елмайыйк, көлик!

—Тормышның кадерен белик!

—Юк эзләмик, башта барын күрик!

Һәр китап укучының яраткан язучылары булган кебек, һәр язучының да яраткан, хөрмәт иткән, хәтта... табынган язучылары була.

Әгәр дә без бәндәгез Мөхәммәт Мәһдиев, Аяз Гыйлажев, Шәукәт Галиев, Илдар Юзеев, Равил Фәйзуллин, Рәдиф Гаташ, Зөлфәт, Мөдәррис Әгъләмнәр турында эссемы, тәнкыйть мәкаләсеме язган икән—алар минем бүгенге татар әдәбиятындагы иң яраткан язучыларым. Һәм...

Алар гына да түгел, башка бик күпләр, хәтта XX гасырның иң серле вә сәер сөюле, тылсымлы шигырь остасы Федерико Гарсия Лорка турында да эссем бар минем. Яшьлек шагыйрем Лорка хакында... Ләкин...

Бар кешеләр кемдер турында нидер әйтә алса да, бер кеше барысы турында да нәрсәдер сүз ката алмый. Бу—хакыйкать! Шуңа берәм-берәм, көч килгәнчә...

Әйтик, менә бүген «Проза Ахуны» Гариф Ахунов турында бернична хуп сүз...

Кемдер турында язганда—бигрәк тә яраткан-ошаткан әдипләр хакында—минем яхшы юлдашларым күп:

—хисслелек;

—фәлсәфилек;

—пафос;

—афоризмнар.

«Аш кашыгы—ашка, чәй кашыгының эш башка». Һәр кошның—үз биеклеге, һәр корабның—үз дәрьясы. Шуның кебек һәр әдипнең үзенчә уйланулары, яраткан үз темалары һәм аларны ачу-чишү ысул-алымнары. Әдәбиятка карата үз концепциясе. Бу начармыни? Һич тә юк. Барлык иҗадиларны, абзарга куып кертелгән сарыклар кебек, бер рамкалар арасына куеп карау начар. Монысы тома сукырлар һәм наданнар, саңгыраулар вә җан-рухлары өшегәннәрнең эше.

Шагыйрь—бөркет, прозаик—дала аргамагы, публицист—судагы балык ул. Ә Олуг—Чын Язучы—бер үк вакытта бөркет тә, аргамак та, судагы балык та. Ул күктән дә карый ала, җиргә дә төшеп чаба, тирәнрәк кереп—дәрьяларны да иңли...

... Сүзебезне дәвам итеп, бүлек башындагы фикер сөрешен үстерә төшик:

—безнең тагы бер гөнаһыбыз бар әле! Әйе, әй!

Язучыларның язганнарына бәя биргәндә...

Үзебез дә сизми-белми генә тагы бер гөнаһка чумып алабыз. Монысы «Тема» дигән әдәби категория белән нык бәйләнгән. Конъюктура дигәне дә бар...

Борылыш җилләре генә иссен—ай-һай, сизгер дә соң борыныбыз! Чып-чын «волчий нюх». Кичә кочаклаганны, әйдә дөмбәсләргә! Кичә мактаганны, әйдә хурларга! Кичә күтәргәнне, әйдә тибеп төшерергә! Чын-чын флюгерлар без. Колгага эленгән уенчыклар. Койрыкны, кирәк икән, хәзер борабыз...

1973 елны «Хәзинә» романы һәм «Чикләвек төше» повесте өчен Гариф Ахуновка Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясе бирелә. Менә шуның «Чикләвек төше»нә тешләре үтмәсә дә, «Хәзинә»сенә бәгъзе адәмнәр кизәнмәк була. Имеш, бериш язучылар Татарстанда нефть чыгаруны мактап чыктылар, ә җир мае республикага акча-валюта алып килмәсә дә, күпме басу-кырларны, болыннарны харап итте, табигатебезне корытты. Шул хакта чаң сугарга тиеш иде әдип. Фәрештәләр дә сөенеп пичәт басар шәп вә гакыллы сүзләр! Ләкин...

Ул көннәрдә шул хакта чаң сугып кара әле, үзенә шулай итеп китереп өрырлар ки, урының:

—Йә психушкада, йә төрмәдә...

Без барыбыз да—«задним умом сильны».

Хәзер була бу хакта ораторлык итәргә, ә бит ул заманда, шагыйрьнең уч төбе кадәрле нәни генә китабында «Партия», «Ленин» сүзләре күзгә чалынмаса да, цензорлар «вето» куя алдылар. Бер әрмән шагыйре кебек:

> Я о партии мало пишу,
> Я еще не спешу,—

дип, котылсаң гына инде...

Булганнан барысы да була, хөсетле бәндәләр генә һәрчак гаеп эзләүчән. Үзләрен кимсетелгән итеп тойгангамы? Яисә психик яктан караганда, үзендә житешсезлекләр комплексын тоюмы? Унышка ирешеп бетә алмауның гаҗизләндерә торган чиреме?

Белмим, белмим...

Белмәгәнне белмим диярга кирәк!

Мина калса, үзе дә нефтьчеләр шәһәре Әлмәттә яшәп алган автор «Хәзинә»гә нык уйланып тотынган, чөнки шулай булмаса, ул аны трилогия итеп язарга теләмәс иде бит: «Хәзинә»дән соң «Хужалар», алга таба планда «Күңелдәге күперләр» торган...

Инде «кара алтын»га килсәк, ул чыннан да Татарстанга «кара» булып чыкты. Ләкин... Әлмәт кебек шәһәрләр төзелү, асфальт юллар салынуны да онытмаска иде! Болар бит «кара»ның ак эшләре. Язучының туган ягы Арча ул вакытларда асфальт юлларны төшендә дә күрмәде.

Әгәр Тукай премиясенә кагылсак... Аны—Аңа бер «Чикләвек төше» өчен дә ике куллап бирергә булыр иде.

## Котылу юлы

*Ахуныбыз безнең, фәрештәбез,*
*Коткар безне, коткар шайтаннан!*
И. Юзеев.

Вакыт коточкыч агышта...

Бу Дәһшәтле Агымны туктатыр бер генә көч тә юк дөньяда...

Кешелек Яңа гасырга аяк басып килә, аның серле-тылсымлы һәм бераз шикле-шомлы да булган ишеген сак кына шакый...

Ниләр бар ул Ишек артында?

Ни язмышлар, борылышлар көтә безне?

Бер ел эчендә кемнәр бу якта калыр, да, кайсылары «теге яр»га атлар?

Сораулар, сораулар, сораулар...

Аларга җавап эзләү—инсаният гамәле...

Шигъри фәрештәләребез Туфан, Хәкимнәр киткәч, әдәбиятыбызда шайтаннар арта төште бугай. Кемнәр аларны «Әгүзе...» дип куар өчен үз артыннан башкаларны да ияртер. Йөзъяшәр Бәширов, Еникилармы? Әллә алардан соңрак килгән, әдәбилекне алардан мирас итеп алган Ахунов, Гыйлаҗевлармы? Ни дисә дә, бу буын нык бит әле, бик актив «яшь картлар» бит алар...

Гариф Ахуновны гына алыйк...

Бармы аның әдәби процесстан бер генә вакыт булса да читтә калганы? Юбилейлармы, әдәби җыелышлар яисә бәхәсләрме, ул—төп уртада. Берәр каләмдәше әйбәт әсәр язган икән, шундук сөенеп, аны мактап язып чыга. Хөсетлеләр тәнкыйтьләп ташлап, талантның Иҗат Утын сүндермәсеннәр ди ахрысы ул. Аның үзенең «Чикләвек төше»нә кизәнүче тәнкыйтьчеләр яисә язучылар да булган бит. Белә-күрә-чамалый ул: «Барыбызга да мәгълүм: йолдызлар галәм тирәнлегеннән калка, талантлар халыкның гасырлар буена җыелган хәзинәсеннән үсеп чыга». ***(Г.Ахунов, «Йолдызлар калка» 350 бит.)***

Бу язучыга сабыйлык һәм сабырлык та, тырышлык вә үҗәтлек тә, яшәү көче белән хыяллар да сыйган. Әйтик, сабыйлык аның өлкән яшьтә дә чиста-саф күңелле, хәтта бераз беркатлы булуында күренсә, сабырлыгы—«кирәкмәс»тән тыела алуында, тырышлык, үҗәтлеге—ифрат актив иҗат итүендә, яшәү көче һаман да энергияле булуында ачык сизелә. Ә хыялларына килсәк...

Гариф Ахуновның хыялы—юкка чыккан туган авылы Өчилене яңадан торгызу. Әйтик, башта өч өйле Өчиле итеп булса да. Аның бу гамәлен тормышка ашыруда теләктәш кешесе дә бар иде. Ул бергә уйнап үскән дусты, бүгенге көндә Ленинград профессоры Мансур Ибәтуллин. Тагы кемдер кушылса, хет иң элек Өчиле жиренә өч дача йорты салып куйсаң да, ярар иде. Бәлки монда Арча районы хакимият башлыгы да катнашыр...

Әнә бит, Аяз Гыйлаҗевка Зәйдә һәм Югары Баграж авылында, ә Шәүкәт Галиевкә Кайбычта йорт-коттеджлар салып бирделәр. Шәпме бу? Хәйран әйбәт күренеш!

Кеше олыгая барган саен туган ягына тартыла. Шуның кебек Гариф Ахунов та үзенең Өчилесен сагына. Быел гыйнвар башында «Ватаным Татарстан» газетасында басылып чыккан «Казанбаш уңганнары» мәкаләсе шул хакта сөйли... Әйе, вакыт коточкыч агышта...

Вакыт агышы шатлык та, сагыш та...

Шатлык—балалар үсеп житә, оныклар туа, инде алары да балигъ булып, яна буын вакыт ишеген ача. Яна туган сабыйлар...

Сагыш—гомерләр узып бара, яшьлектән хатирәләр генә кала...

... Алдыбызда Яңа гасыр...

Ана икеләнеп тә карыйсың, өметләнеп тә карыйсың. Карап хыялланасың да, шиккә дә төшәсең, яна туган сорауларына җаваплар да эзлисең. Үзеннекен генә түгел, халкыннның да киләчәген чамалыйсың һәм уйлыйсың:

—Бу гасырга, Яңа Мең Еллыкка, «Прозабыз Ахуннары» белән бергә аяк басарга иде,—дисең... Милләтпәрвәрләр белән бергә...

Өметсез шайтан гына ди.

Өметләр дигәч тә... Хыяллар дигәч тә... Мин аксакал язучыбызның теге хыялына кире кайтам әле:

—Өчилене кабат торгызу?!



*«Казан утлары» редколлегиясе утырышыннан бер күренеш.*
*Утырганнардан уңнан өченче—Гариф Ахунов. 1998 ел.*

Һәм...

Күңелгә бер уй куна, дөресрәге бер чагыштыру, бер образ:

—Гариф Ахуновның—«Прозабыз Ахуны»ның—Туган Авылын торгызу хыялы халкыбызның мең елга ия булган дәүләтчелеген кабат тергезү уе белән аваздаш түгелме?

Монда хәтта ниндидер ым-ырым, Сер-Мистика да бар кебек...

И, Өмет! Зинһар югала күрмә, күбек кебек шартлый күрмә...

... Киләчәк XXI гасырга карыйм...

—Ниндирәк булыр анда әдәбиятыбыз?

—Ул халыкны тәүбәгә чакыру әдәбияты булырга тиеш. Иманга килү шул Иманга гомер буе йөз тоту әдәбияты. Әдәп мөнбәре булган әдәбият Чистарынуга чакырсын һәм әшкә ин беренче «Әдәбиятыбыз Ахуннары» кушылсын иде.

Тәүбәсез һәм Чистарынусыз—Алга юл юк! Алга юл—Аллага юл ул. Чиста Җан—Рух Алласына...

Һәр Йөрәк кагышыбыз шуны искәртсен иде.

*Киров өлкәсе,*
*Түбән Шөн, гыйнвар, 1999 ел.*

# ПОЭМА ТУРЫНДА СӨЙЛӘШӘБЕЗ

*Татарстан Язучылар берлегенең әдәби тәнкыйть остаханәсе һәм «Казан утлары» журналының әдәби тәнкыйть бүлеге күптән түгел поэма жанрына багышланган «Түгәрәк өстәл» сөйләшүе үткәрделәр. Журнал укучыларга шул сөйләшүдә яңгыраган кайбер чыгышларны тәкъдим итәбез.*

## Шамил Маннапов:

Белгәнебезчә, поэма жанрының тамырлары бик тирәндә, ул борын-борынгы фольклордан һәм Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» кебек әсәрләреннән үк килә. Башка халыкларда да шулай. Ошбу дөньяда һәр нәрсә хәрәкәттә-үзгәрештә булган шикелле, поэмалар да һәм форма, һәм эчтәлек җәһәтеннән үзгәрешләр кичерә-кичерә, безнең заманга килеп җиткәннәр. Борынгы чорларда алар халыклар тормышындагы зур тарихи вакыйгаларны («Илиада», «Идегәй» дастаны һ. б.) чагылдырсалар, тора-бара анда әхлак проблемалары, адәм баласының шәхси уй-тойгылары, социаль-фәлсәфи мәсьәләләр өстенлек ала башлаган.

Октябрь инкыйлабыннан соңгы совет поэзиясендә героик башлангычка, халык массаларының тарихтагы ролен калку күрсәтүгә, хезмәткә һәм халыклар дуслыгына дан җырлауга, тынычлык өчен көрәшкә чакыру кебек патриотик эчтәлеккә әһәмият бирелде. Бу хәл безнең татар шигъриятендә дә шулай булды. Ул чордагы поэмаларның күпчелеге сюжетлы булып, аларда тормыш-көнкүрешебез коммунистик идеология кысаларына яраклаштырылып, бизәп-матурлап, сыйнфый караштан чыгыбрак иҗат ителгәннәр. Заманында «Мокамай», «Җир уллары трагедиясе» кебек идеология кысаларыннан азат шедеврлар биргән Һади Такташ та чор куйган таләпләрдән читтә кала алмаган хәтта.

Инде илдә «идеология дилбегәләре» азмы-күпме бушый башлаган алтмышынчы еллардан соң, поэмаларда яңадан уңай якка үзгәрешләр башланды. Бу бигрәк тә реаль тормыш вакыйгаларын адәм баласының табигый хис-тойгылары аркылы чагылдыруда күренә. Андый әсәрләрдә инде вакыйгаларны эзлекле сюжет белән сурәтләүгә караганда лирик-фәлсәфи планда, фикер үстерелеше аша укучыга җиткерү хас. Сибгат Хәкимнең Тукайга багышланган «Кырыгынчы бүлмә», Әнвәр Давыдовның «Чорлар чатында», Шәрәф Мөдәрриснең «Тупчы Вәһаб» Илдар Юзеевның «Таныш моңнар», Марс Шабаевның «Сине эзлим», Роберт Әхмәтҗановның «Таш аргамак», Әхсән Баяновның «Сез аңларсыз мине», Хисам Камаловның «Күңелдәге язулар», Сажидә Сөләймpraвованың «Сузган ике кулым» һәм башка поэмалар бу жанрның бүгенге шагыйрьләр иҗатына уңай йогынты ясаучы карлыгачлары булдылар.

Хәзерге вакытта җиң сызганып иҗат итүче шагыйрьләребез үз әсәрләрендә халык бәгърендә әлегәчә томаланып яткан дини фәлсәфәләрне, Хозыр галәйһиссәлам, кылдан нечкә кылычтан үткен Сират күпере кебек образларны да иркен файдаланалар. Бу бигрәк тә Әхмәт Рәшит, Ренат Харис, Зөлфәт, Мөдәррис Әгъләмов, Зиннур Мансуров, Харрас Әюп, Лена Шагыйрьҗан, Эльмира Шәрифуллина, Ркаил Зәйдулла, Газинур Морат һ. б. иҗатларында ачык күренә.

Хәзерге поэмаларыбызда «Кыйссаи Йосыф»тан килгән, гасырлар сынавын уңышлы узган мораль-әхлак мәсьәләләре, фани һәм бакый дөнья турында фәлсәфи уйланулар калку чагылдырыла. Хәлбуки, идеологик кысалардан котыла барган чынбарлык адәм балаларының җанын кирәкмәс богаулардан акрынлап азат итә, бу процессның барометры булган шагыйрьләребез иҗатына уңай йогынты ясый, нәтиҗәдә, поэмаларыбыз да борын-борыннан килгән үз асылына кайта.

Ләкин күңелне борчыган бер нәрсәне дә әйтми булмый. Бүгенге шагыйрьләребезнең күбесе поэмаларында фәлсәфи фикерне, шигъри детальләрне артык тыгызлап тутырырга тырышалар. Нәтиҗәдә, аларны уку, аңлау кыенлаша. Такташ бабай әйткән бит, шагыйрьнең бурычы гади генә нәрсәләрне катлауландырып язуда түгел, ә катлаулы тормыш күренешләрен мөмкин кадәр гади итеп тасвир итүдә,

дигән. Поэмаларыбызда артык каш җыерып, кара якларны күбрәк яктырту гамәле өстенлек ала кебек. Шул ук Такташыбыз «Мәхәббәт тәүбәсе» кебек бик житди һәм монсу әсәрләрендә дә «өйләнә алмый калган, хатынсыз Ай», яки «ни булса да энисеннән тере туган» (аборт белән төшерелмәгән) песи малайлары турында сөйләп, укучыны аз гына елмайтып, «ял иттереп» ала белгән ләбаса. Бу алым әсәрдәге фаҗигале хәлләрне тагын да калкурак, җетерәк кабул итәргә дә булыша. Автор монысын да истә тоткандыр, әлбәттә. Ак төсләр янында кара таплар ачыграк күренә бит ул. Әйтергә теләгәнем шул: бүгенге каләмдәшләребез үз элгәреләренең иҗатларындагы уңышлы якларны кимчелекләре белән бергә ташлап калдырмасыннар, ә бәлки тагын да үстереп-тернәкләндереп җибәрсеннәр иде.

Сибгат ага Хәким: «Поэма ул шагыйрьне сыный торган жанр»,—диярге ярата иде. Шигърият мәйданына килүче яшь шагыйрьләребез дә иншалла сынатмаслар, киләчәктә поэмаларыбызның лирик-фәлсәфи сулышы тагын да киңәер, дип ышанасы килә.

## Әхмәт Рәшит:

Әдәбият сөючеләрнең кайберләре хәтерли торганнардыр: күренекле шагыйребез Әнвәр Давыдов үзенең Себер тракты турындагы мәшһүр әсәрен жанр ягыннан поэма-симфония дип билгеләгән иде. Бу нәрсә аның каләмдәшләрен дә, һәр әйберне калыпка салырга, бизмәндә үлчәргә күнеккән тәнкыйтьчеләрне дә ул вакытта шактый аптырашта калдырган иде. Чыннан да, сәнгатьнең ике тармагына караган бу ике төшенчә һич кенә дә тыңдаучылар түгел төсле, алар арасына тигезлек билгесе куеп булмыйдыр төсле. Ә икенче яктан карасаң... Симфонияләрдә барабаннар һәм литавралар тантана итә, скрипкалардан үзәк өзгеч моң һәм сагыш агыла, флейталар елап, сулкылдап-сулкылдап куя, виолончельләр һәм контрабаслар, бар нәрсәгә битарафлар шикелле, әсәрнең агышын ярлардан ташытып чыкмаска тырышып кирәккәндә генә саллы тавыш биреп бара. Фортепиано исә, тегеләренә дә, боларына да төп уй-фикерне төшендерергә һәм ахыр нәтиҗәне чыгарырга теләгәндәй, тыңлаучыга асыл мәгънәләрне ирештерә. Чү! Зур күләмле әсәрдә дә шулай түгелмени? Анда да тантана, матәм, борчылу шөбһә, сөенеч, кайгы, кырыс хөкем шулай ук аралашып, чиратлашып бара лабаса! Хикмәт фәкать шунда гына: поэмада, шигъри повесть яки романда, балладада, дастанда уен коралы аһәңнәре түгел, ә кеше тавышы, җанлы аваз яңгырый. Шул уңайдан бер кызыклы факт турында әйтми ярамас: проза әсәрләре элек-электән шыпырт кына, эчтән генә уку өчен язылса, поэма кебек катлаулы жанр кычкырып укуны, сәхнәдән, мөнбәрдән, трибунадан яңгыратуны өстен күргән. Мәдәният тарихының могҗизасы димичә, ни дисен: «Манас», «Алпамыш», «Юлбарыс тиресе ябынган витязь», «Идегәй», «Җиһангир», «Козы-көрпәч белән Баян—Сылу» кебек гаять озын әсәрләр телдән-телгә, бер чичәннән икенчесенә күчә-күчә бүгенге көнгә килеп житкәннәр. Алар күп кешеләр җыелган мәҗлесләрдә акыллы сүз, гыйбрәтле вакыйга буларак сөйләнгән, тормышка яңа аяк баскан яшь буынга сабак биргән. Антик дөньяның даһие Гомер безгә «Илиада»сын һәм «Одессия»сен, Һиндстанның бөек фикер ияләре «Махабхарата» һәм «Рамаяна» әсәрләрен мирас итеп калдырганнар.

Шул шедеврлар рәтендә Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» әсәре дә булу безнең көнелләрдә аеруча горурлык хисе уята. Бу, беренчедән, бабаларыбызда шундый киң пландагы әсәрләр тудырырга сәләтле иҗатчылар, шигъриятнең юл башы инде аңарчы ук салынып, тиешле старт мәйданы булу турында сөйләсә, икенчедән, соңрак аларның лаеклы дәвамчылары булачагын да искәртә. Котбның «Хөсрәү вә Ширин», Хәрәзминең «Мәхәббәтнамә», Хисам Кятибнең «Җөмҗөмә Солтан», Сәйф Сараиның «Сөһәйл вә Гөлдерсен», «Гөлстан бит-төрки», «Мөхәммәдъярның «Төхвәи мәрдән»(«Егетләргә бүләк»), «Нуры содур» («Күңелләр нуры»), Колшәрифнең «Кыйссаи Хөбби Хуҗа» юктан гына бар булмаганнар, инде сугарулы әдәби җирлектә барлыкка килгәннәр. Һәр милләт тә мондый рухи байлык белән мактана алмый—ул халыкның мәдәни тәрәккыяте турында сөйли торган фактор.

Мин мәшһүр әсәрләрне санауны ил-йортыбыз өчен фаҗигале көннәрдә шәһит киткән шагыйрь бабаларыбызны телгә алып туктаткан идем. Моның бер хикмәте бар. Казан ханлыгын Мәһдиш Иван гаскәрләре яулап алып, аның бар халкын

кылычтан үткәргәч, Европа ренессансы белән ярышырдай гүзәл мәдәниятыбыз да чәлпәрәмә килә: меңләгән китаплар ут хөкеменә тапшырыла. Әле ярый, аларның кайберләре Лондон, Париж, Каһирә, Варшава, Истанбул китапханәләрендә сакланып калган—югыйсә күпме милли хәзинәбездән колак каккан булыр идек.

Коточкыч золымнар татыган татар халкы яңадан чын-чынлап XIX гасыр ахырында, XX гасыр башында гына тернәкләнә башлый. Дөрес, 17-18 йөзләрдә дә кайбер шагыйрьләр ялтырап-ялтырап ала. Габдерәхим Утыз Имәнигә Әбелмәних Каргалый, Һибәтулла Салихов, Габделҗаббар Кандалый, Баһави, Шәмсетдин Зәки, Гали Чокрый, Акмулла кебек гаять үзенчәлекле шагыйрьләр килеп ялгана. Алар биеклегеннән старт алган Габдулла Тукай, Дәрдмәнд, Сәгыйт Рәмиев татар шигырь сәнгатен яңа баскычка күтәрәләр.

Сүземне нигә ерактан, «борын-борын заманнан» башладым соң әле?! Шагыйрь Мөдәррис Әгъләмовның:

Үз халкыңның киләчәген,
Үткәнен, бүгенгесен,
Кайгысының, шатлыгының
Зурлыгын белер өчен
Еракка китеп кара син,
Еракка китеп кара!—

дигән гаять гыйбрәтле, гаять акыллы сүзләре бар. Әгәр без бүген дөньякүләм шигырь бәйгеләрендә бил бирмибез икән, иң башта юл сабучыларыбызга рәхмәт әйтергә тиешбез. Кичә генә вәхши халыктан туган бәндәләрдән ни он суы, ни тоз суы!

Поэма—шигъри сүзнең олылыгын, илаһилыгын һәм хәтта яшәешен, саклаучанлыгын билгеләүче жанр. Грекларның poiema дигән сүзеннән килеп чыккан бу атама хикәяләүне яки лирик сюжетны үз эченә алган эре шигъри әсәрне белдерә. Аерым авторлар тудырган яки халык авыз иҗаты әсәрләре саналган эпослар, дастаннар да аннан аерылгысыз. Каһарманлыкны һәм каһарманнарны данлаган, лирик-психологик кичерешләрне, фәлсәфи фикерләрне, тарихи вакыйгаларны үзәккә куйган, дидактикага корылган, әкиятләргә һәм мифларга нигезләнгән, шаян, көлке хәлләрне сурәтләгән йөзләрчә поэмалар татар шигъриятенең алтын фондын тәшкил итәләр.

Мин Октябрь инкыйлабыннан соң поэма өлкәсендә нәтиҗәле иҗат иткән шагыйрьләребезне күздән кичереп чыктым. Бик күп түгел икән алар! Жанр таләпләренә төгәл буйсынып, поэтика дигән хикмәткә лаеклы өлеш кертеп, халык кызыксынып укырлык поэмалар язган сүз осталары шушы 80 нән артык елга 30-40 тан артмый. Күрәсең, бу жанр үзенчәлекләре белән дә, шагыйрьнең иҗат процессы гадәттәгедән озаккарак сузылуы белән дә аңлатыладыр.

Элекке заманнарда язылган поэмалар нигездә нинди дер вакыйга яки нинди дер шәхес турында сөйләүгә корылган. Аларда лирик чигенешләр, автор ремаркалары, этик һәм эстетик принциплар хакында уйланулар әсәр тукымасыннан бүселеп чыкмый, киресенчә, идея буларак шул вакыйга, шул каһарман үрнәгендә калку итеп күрсәтелә. Бөек Тукаебызда да ул тотрыклы сюжетка корылган. Һәммәбезгә таныш «Шүрәле»не генә алыйк. Менә Былтыр атлы егет урманга китә. Тирләп-пешеп утын кисә. Шүрәле килеп чыгып «кети-кети уйнарга» тәкъдим ясый. Ә егет исә тапкыр, чая. Ул Шүрәленең бармагын бүрәнә ярыгына кыстыра. Иртәгәсен шүрәлеләр надан иптәшләрен тиргиләр. Тукай сөйләмне әнә шулай баштан ахыргача эзлекле алып бара. Хәтта поэманы башлап җибәргән Кырлай урманы хозурлыклары да әсәргә бик табигый ялгана. Шагыйрьнең «Кәҗә белән сарык әкияте», «Яхуд яңа Кисекбаш» һәм башка поэмалары да традицион калыптан чыкмый. Мондый характердагы поэмалар Октябрь инкыйлабыннан соң да байтак иҗат ителделәр. Х. Туфанның «Урал эскизлары», М. Җәлилнең «Хат ташучы», Ф. Кәримнең «Аникин», «Кыңгыраулы яшел гармун», «Идел егете», Ш. Маннурның «Гайжан бабай», С. Хәкимнең «Бакчачылар», Ш. Галиевнең «Әткәйгә хат», И. Юзеевнең «Таныш моңнар», С. Сөләймානованың «Фал китабы», Ә. Баяновның «Мираж», М. Шабаевның «Җирән Конрад», Р. Фәйзуллинның «Сәйдәш», Р. Харисның «Рәссам», «Өч үбешү», Рәшит Әхмәтҗановның «Бишташ», Роберт Әхмәтҗановның «Уйна, улым», «Сәхибҗамал», Ә. Рәшитовның «Колшәриф», Э. Шәрифуллинаның «Тәмуг кисәве», Р. Шәриповның «Фатыйма» поэмалары жанр таләп иткән классик кысаларда иҗат ителгәннәр. Интонацион, публицистик, гадиерәк итеп әйтсәк, сюжетсыз поэмалар исә асылда

егерменче гасыр казанышы. Совет власте һәм коммунистлар партиясе хакимлек иткән елларда ул унай яклары белән беррәттән тискәре сыйфатларын да күрсәтте. Ул дәвердә шигърияттә гомумән сәяси агитациягә һәм пропогандага корылган декларация өстенлек итә иде. Массаларга жинел аңлаешлы, мобилизацион куәте гаять көчле булган бу төр шигырь бик тиз мәйдан яулады. В. Маяковскийның:

«Слушайте, товарищи потомки, Агитаторы, горлана-главаря»,—дию тикмәгә генә түгел—анын «Во весь голос», «Хорошо» кебек поэмалар язуы үзе үк ул чор өчен гыйбрәтле. Әдәбияттан елак лиризм түгел, ә какшамас оптимизм, сыйнфыйлык, партиялелек, халыкчанлык таләп итеЛә һәм әсәрләргә бөя социалистик реализм постулатларыннан чыгып куела иде бит! Сәнгатьчә эшләнеше ягыннан югары кретерийларга жавап биргән поэмалар да туды ул елларда. Ләкин бу күренеш кагыйдә булудан бигрәк анын искәрмәсе иде. Татар шигъриятендә интонацион башлангычның, публицистик характердагы сюжетсыз поэмаларның тууын, мөгаен, Һ. Такташ ижаты белән бәйләргә кирәктер. Анын «Гасырлар һәм минутлар» поэмасы да, «Киләчәккә хатлары» да аерым фрагментлардан, әмма гомуми бер идея белән берләштерелгән кисәкләрдән тора шикелле. Аларда өзлекле дәвам иткән вакыйга да, лирик каһарманнан башка персонажлар да юк диярлек. Ә. Фәйзинен «Флейталар»ы, С. Хәкимнен «Дуга», «Кырыгынчы бүлмә», «Васыятьләр», И. Юзеевнен «Тынлык белән сөйләшү», «Сонгы сынау», «Карурман», «Таш диварлар авазы», «Мәхәббәт китабы», Р. Фәйзуллинның «Көрәшчеләр», «Гадиләргә гимн», Р. Харисның «Мулланур», «Ант суы», Р. Мингалимнен «Минем дәүләт», «Күз карасы», «Иртәгә», «Ике авыл арасы», З. Мансуровның «Хозыр галәйһес-сәләмне эзләү», «Балкыш», «Кылдан нечкә, кылычтан үткен», Роберт Әхмәтжановның «Таш елады», М. Әгъләмовның «Онытма, Европа» һәм башка күп кенә авторларның кайбер зур күләмле әсәрләрендә борынгыча тәфсилле хикәяләү юк дәрәжәсендә. Ләкин бу нәрсә аларның әһәмиятен һич кенә дә киметми.

Поэма жанрында иң күп һәм нәтижәле эшләгән шагыйрьләр, мөгаен, И. Юзеев, Р. Харис һәм Ә. Рәшиттер. Аларның һәркайсының активында—андый әсәрләр уннан артып китә. Әлбәттә, аларның камиллеге төрлесендә төрлечәдер. Әмма бер нәрсәне билгеләп үтмичә булмый. Ул әсәрләр борынгы шигъри кануннар буенча язылса да яки киресенчә булса да, жәмгыятьтә бүген өстенлек иткән карашларны бәян итәләр, алар замананың үзенчәлекле, шигъри көзгедәге чагылышы буларак барлыкка килгәннәр. Ә көзгенен ачык, әйбәт күрсәтүе анын тонык, чатнаган булмавына ягъни ижатчының талантына бәйләнгән. Дөньяда бердәнбер поэмасы белән дә дан казанган шагыйрьләр бар. Рус язучысы Петр Ершов, мәсәлән, заманында шигырьләр, пьесалар, хикәяләр ижат иткән. Әмма без аны «Конек-Горбунок» әкият-поэмасы буенча гына беләбез. Калганнары күз уңыннан киткән, онытылган. Андый мисаллар безнен татар шигъриятендә дә бар.

Шигърият дигәннән, ни өчендер без аны рифма, ритм кебек атрибутлар белән генә бәйләргә күнеккәнбез. Мәрхүм язучыбыз Ә. Еники ижатын мин, мәсәлән, тулаем шигърият буларак кабул итәм. Кайсы гына әсәрен алма, аларда шигъри башлангыч ярылып ята. М. Горькийның «Песня о Буревестнике», «Песня О Соколе», «Старуха Изергиль» яки «Итальянские сказки» әсәрләрен шигърияттән аерырга мөмкинмени? Н. В. Гоголь мәшһүр «Үле жаннар» әсәрен «поэма» дип исемләгәнгә мин заманында бик гажәпләнгән идем—ә чынлыкта анда—сюжет агышы да, композицион төзелеш тә, төп каһарманның—Чичиковның «сәяхәтләре» дә шигъри канунnarга буйсындырылган икән ләбаса. Шуңа күрә жанр чикләрен билгеләгәндә, катгый, кагылмаслык формулалар белән эш итү һәрвакытта да тиешле нәтижәләргә китерми. Бу бер. Икенчедән, әдәбиятның чишмә башы шигырь булуын, башка жанрлар тууга нәкъ менә шигырь йогынты ясавын да онытмаска кирәктер.

Татар әдәбияты үзенен шигърияте белән көчле. Нәшриятчылар: халыкның шигырь китапларына исе китми, дип үз булдыксызлыкларын акларга маташса да, бу шигъриятнен бөек илаһи миссиясен һич кенә дә кимсетми. Менә шул илаһи арсенал, заманнар үтү белән булса да, үз кирәксенүчесен таба, кемнедер сөендерә, юата, уйландыра, кирәкле нәтижәләр ясата ала. Киң колачлы, тирән мәгънәле сүзләр симфониясе яшәешнен әллә нинди серләрен аңлатырга сәләтле. Шуна күрә анын, әлбәттә, инде чын мәгънәсендә камиллеккә ирешкәненен, кешеләргә теләсә кайсы заманда гыйбрәтле сүз әйтерлегенен, гомере озын—кайберсе хәтта күп гасырлар дәвамында хәтердә сакланып, һаман да рухи азык булып калырга сәләтле.

**Лена Шагыйрьҗан:**

Бу сөйләшү алдыннан үзем укып белгән күпсанлы поэмаларны күнелемнән кичердем һәм шундый нәтиҗәгә килдем: татар әдәбиятында, гомумән алганда, поэмаларга кытлык юк! Чыннан да, татар Поэзиясе ул үзе поэма жанрының иң борынгы традицияләренә барып тоташа һәм бүгенге көнгәчә, яна төсмерләр белән баетылып, үсүен дәвам итә. Әдәбиятыбызда бу жанрның гүзәл классик үрнәкләре энҗе-мәрҗән кебек тезелеп киткән, һәм аларны бер-бер артлы санап чыгуның хаҗәте дә юк. Татар поэмалары хакында сөйләшә башласаң, безгә бер-ике сәгать вакыт кына түгел, мең дә бер кичең дә җитмәс... Шуңа күрә сүзне гомумән поэмалар турында түгел, ә бәлки безнең көннәрдә, ягъни тарихи-психологик үзгәрешләрдән тетрәнеп торган туксанынчы елларда бу жанрның ни хәлдә булуы, аерым алганда, сюжетлы поэмаларның ни өчендер азрак языла башлавы хакында алып бару урынлырак булыр.

Нәрсә соң ул Поэма? Без аны ничек аңлыйбыз?..

... Менә, кызыксынып, төрле китапларны актарам. «Поэма—шигъри формада язылган лиро-эпик характердагы сюжетлы әдәби әсәр. Шигъри повесть, шигъри хикәя». «Поэма—шигырь белән хикәяләп язылган зур әдәби әсәр. Лирик поэма. Эпик поэма. Дидактик поэма...» Татар теленең аңлатмалы сүзлегендә исә Г. Гобәй тарафынан язылган шундый юлларны укыйм: «Поэмада, романдагы яки повестьтагы кебек үк, җәелеп-үсеп бара торган бердәм сюжет сызыгы булырга, әсәрнең башыннан ахырына кадәр дәвам иткән образлар булырга, эштә, хәрәкәттә ачыла торган характерлар булырга тиеш». Әдәбият белеме сүзлегендә исә: «Поэма—әдәбиятның лиро-эпик төрләреннән берсе, сюжетлы шигъри хикәяләү, шигырь белән язылган повесть яки хикәя»,—диелгән.

Алай булгач, безнең «сюжетлы поэмалар» дип сөйләнүебез «майны майлау» шикелле, тавтологиягә әйләнеп кала түгелме соң?.. Поэма жанры үзе үк инде сюжетлы хикәяләүне күз алдында тоткач, без нигә дип әле «сюжетлы поэма» дип сүз куертабыз соң? Сюжетсыз поэма булырга да тиеш түгел кебек ләбаса.

Аптырап та куям. Әллә без әдәбият белемен белеп онытканбыз, әллә дөньяда яңа бер жанр—ул да булса, сюжетсыз поэма барлыкка килгән?.. Дөресен генә әйткәндә, башка әдәбиятларда да бу турыда сүзләр барганлыгы мәгълүм.

Поэма турында олы сүзгә кушылып китәргә хакым бармы соң әле минем, дип тә сорап куям үземнән. Шөкер, биш-алты поэмам бар икән, дип тә акланам. Ләкин алар ниндидер бер катгый сюжетка корылмыйча, мәгълүм бер идея-төшенчә яисә предмет тирәсендә фәлсәфи-лирик уйланулар формасында язылган. Дөресен әйткәндә, аларның да күпчелеккә мәгълүм булган нинди дә булса вакыйга, күренеш яисә төшенчәгә кайтып калган «әзер сюжеты», халык аңында яшәгән таныш һәм уртак эчтәлеге булмый калмый. Һәм автор бөтен уй-кичерешләрен шул тирәдә йөртә, яки мәгълүм бер фәлсәфи фикердән чыгып эш итә. Мәсәлән, минем үземнең «Хәвеф», «Гүзәллек», «Йөрәк авазы», «Тукай тавышы», «Менә шундый Казан ул» поэмалары шундый дип уйлыйм.

Бу күренеш соңгы вакытларда башка кайбер шагыйрьләребездә дә күзәтелә, шулай ук бүтән халыклар поэзиясендә дә киң тарала бара. Нәкъ менә иркле формадагы, лирик яки программ характердагы музыкаль әсәрләр шикелле. Минем «Гүзәллек» дигән поэмам юкка гына «шигъри симфония» дип аталмагандыр, күрәсең.

Нәрсә, без инде сюжет төзергә, укып чыкканнан соң, эчтәлеген сөйләп бирерлек фабула уйлап чыгарырга да сәләтсез микәнни соң?.. Аның каруы, тормышта мине ал дип кычкырып торган сюжетлар да буа буарлык ич... Әллә соң бу «образлар, геройлар, типлар, персонажлар» һәм тагын әллә нәрсәләр романнар һәм пьесаларга күчеп беткәнме?! Уйлана башласаң, гаять кызыклы һәм гыйбрәтле күренеш бу...

Кабат кайтып, аңлатмалы сүзлектән менә бу юлларны да китерим әле (Болары Әхмәт Исхактан алынган): «Бүгенге көнне, аның героикасын, аны иҗат итүче кешеләрнең героик образларын тудыру буенча әдәбият алдына куелган бурычларны хәл итүдә зур күләмле поэтик әсәрләрнең—поэмаларның роле бик зур...»—Бу юлларны кисәкләргә бүгәләп, анализлыйм: бүгенге көн, аның героикасы, аны иҗат итүче кешеләр, шуларның әдәби образлары, әдәбият алдына куелган бурычлар, шул бурычларны хәл итүдә поэтик әсәрләрнең роле... Бүгенге көн, димәктән, бездә хәзер нәкъ менә шундый поэмаларның аз язылуы үзен нык сиздерә башлады да. Әхмәт Исхак сүзләренә таянсак, моның сәбәбе дә ачыклана башлый түгелме соң? Әйтик,

«бүгенге көн—бар, анын героикасы һәм анда катнашучылар—бар, әмма аларнын әдәби образлары юк дәрәҗәсендә. Чөнки әдәбият алдына куелган конкрет бурычлар да, шул бурычларны хәл итүдә поэзиянең роле дә юкка чыккан... Шулай итеп, бүгенге көн темасына багышланган поэмаларның һәм, гомумән, «сюжетлы» поэмаларның аз язылуына идеология дигән нәрсәнең юкка чыгуы төп сәбәп булып тора түгелме соң?!.

Яшерен-батырын түгел, соңгы елларда шагыйрьләрнең поэмалардан читләшә башлавы нәкъ менә идеаллар, идеяләр һәм идеологиянең юкка чыгуы белән бәйләнгән. (Әлбәттә, безнең ил, Россия кысасында). Әдәбиятта идеологик күрсәтмәләр белән генә эш итәргә күнегүчеләр, гомумән, аптырап калдылар. Алар поэма түгел, озын шигырьләр дә яза алмас булдылар. Мәңгелек идеяләр һәм төшенчәләр хакында тирәнтен уйланып, әдәбият дөньясына баш-аягы белән чумып яши алмау яисә яши белмәү кайберәүләрне бөтенләй язмас итте. Дин әле янадан ачылып кына килә, димәк, иман төшенчәсе дә хәзерге шагыйрьләрнең калебенә тәмам төшеп житмәгән. (Гәрчә бу темага шактый гына шигырьләр язылып өлгерсә дә.) Аннары, әдип-шагыйрьләрнең әдәбият белеме өлкәсендә бик сай йөзүен дә әйтми калып булмый. Шагыйрьләрнең күбесе, матди дөньядан «ваз кичеп», чын профессионалларча житдилек белән әдәбият тормышында кайнап, «шигырь сулап» яши алмый... Ә теоретик белемнәрнең житмәве яки көндәлек мәшәкатьләр арасында, баштан ук чыгып бетүе әдәби эшчәнлек процессында чагылмыйча калмый, әлбәттә.

Әмма да ләкин, иң мөһиме—әдәби тәнкыйтьнең бөтенләй сүрелеп калуы яки обьектив булмавы; кем әйтмешли, бу өлкәдә «бушлык» хасил булуы шагыйрьләрнең ижат стимулына нык сукты... Әле гасыр башында гына да шагыйрь-шогаралар кечкенә генә бер шигырь тирәсендә дә кызып-кызып бәхәсләр оештырганнар, матбугатта сүз күтәреп, чын мәгънәсендә профессионалларча әдәби тормыш белән яшәп ятканнар. Күрәмсең, әдәби эшчәнлекнең вак-төяк дөнья мәшәкатьләреннән өстенрәк булуын аңлап-тоеп яшәү, әдәби культура шактый югары булган. Бүгенге көндә исә нәкъ менә тәнкыйть камчысы житмәгәнлектән шигъри әдәбиятыбыз бер-берсе белән узышучы төрле үзешчәннәрнең шау-шуыннан тәмам чуәләнеп, эстрада жырлары мәйданына әйләнеп бара. Аларга сонет ни дә, газәл ни, такмак ни дә, поэма ни... Мондый мохит хәтта чын шагыйрьләргә дә тискәре йогынты ясамый калмый. Чөнки психология үзенекен итә: «Кемгә кем? Кем аңлый? Дуңгызларга сәйлән тезүдән ни файда?» дигән кебегрәк карашлар да туа, һәм теге мөтәшагыйрьләргә шул гына кирәк тә...

Нәкъ менә шундый кризис эчендә калган вакытта чын, житди тәнкыйтьнең, яклаучы һәм саклаучы тәнкыйтьнең кирәклеге аеруча нык сизелә дә. Ә бит әдәби тәнкыйть әле ул теге яки бу автор турында язу гына түгел, бәлки шуларның әсәрләреннән чыгып, гомумән, әдәбият өлкәсендәге тенденцияләр, житешсезлекләр яки унай яклар, яисә, була калса, яналыклар турында да сүз алып бару, дигән сүз.

... Урысның берсе эченә берсе оялаган матрешка-курчаклары шикелле, һәр сәбәпнең үз эченнән тагын әллә ничә төрле сәбәп килеп чыгып кына тора... Поэмалардан «бизүнең» дә бик күп эчке вә тышкы сәбәпләре тулып ята. Поэма бит ул шактый авыр, катлаулы, четрекле жанр. Аны ижат итү өчен киң колач һәм киң сулыш, фикер белән хисне берләштерү осталыгы, ижтимагый-тарихи һәм социаль вәзгыятьләрне аңлый белү, мөстәкыйль һәм оригиналь фикер йөртү дә кирәк. Чөнки поэма—ул инде шигъри мизгел генә түгел. Хисси мизгел халәтләре монда «бары тик» теге яки бу геройның психологиясен ачып бирүдә, яисә авторның лирик чигенешләрендә үзара органик үрелеп кенә кулланылырга мөмкин. Бу инде, рәссамнарча күзаллаcан, бер генә рәсем-сурәт ясап кую түгел, бу киң полотно ижат итү белән бер. Димәк, чын поэмалар тудырырга көч вә колач житми башлаган?.. Әллә соң бу жанрга теше үтәрлек каләм осталары бетеп барамы?..

Әйе, шәп шигырьне укуы гына рәхәт аны... Поэманы да... Житмәсә, әле аны чиләнеп язгач-язгач, тиз генә берәр гәжит-журналда бастырып булса икән!.. Юк шул, гәжитләр поэмага колач жәеп тормыйлар: урын житми. Журналларда басылу өчен дә айлар буе чират көтәргә кирәк. Әгәр берәр урында түрә булмасаң, басылуы да икеле... Хәтта басылып чыкканын укучылар да берән-сәрән генә кала бара. Ә инде китап чыгару—могжизага тиң. Кайда да булса басылган очракта да, ул әсәр хакында беркем бер сүз әйтми, ягъни мәсәлән, авторга шәхси эше төшмәгән бер генә тәнкыйтьче дә үзеннән үзе дәртләнеп, аңа бәя бирмәячәк, анализ ясамаячак һәм ул эзсез-нисез күмелеп калачак. Хәтта әйбәт әсәр булса да. Чөнки әдәби мохит вакланып, төссезләнеп беткән, әшнәлек чиренә баткан.

Без урысча «бери выше» дигән гыйбарәне беләбез. «Югарыга карап фикер ит» дигән үз мәкаләбез дә бар. Ул югарылыкка үз әдәбиятыбызда ук ирешелгән бит инде югыйсә. Идеология булса—булмаса, яки аның нинди булуына карамастан, әдәби җимешләребезнең иң затлы орлыкларын югалтмаска иде. Мәгълүм ки, Совет чорында татар әдәбиятында поэмалар бик күп язылган. Менә шул чорның идеологиясе дә бик зур йогынты ясады, чыбыркылап, әйдәп торды. Чөнки кешеләргә яшәү рухы бирә торган әдәби әсәрләр кирәк булган. Әллә хәзер «яшәү рухы» дигән нәрсә кирәксезгә чыкты микән? Ә бит рухсызлык, төшенкелек коточкыч дәрәҗәгә килеп җитте. Дөрес, кайберәүләр хәзер Совет чорында кириллица белән язылган әсәрләрне бөтенләй чүплеккә атып, «Авылым әтәчләре» дигән сыманрак җырлар белән мәңге-леккә кереп калу турында да хыялланалар. Ләкин бит, җәмәгать, һәрбер чорның үз «сволочьлары» да, «мокамайлары» да бетмәячәк... «Кыңгыраулы яшел гармуннар-ны» да чыгарып ташлап булмый... Шулай булгач, әдәбиятыбыздагы һәрбер гүзәл казанышны онытмыйча, алардан да әйбәтрәк әсәрләр иҗат итү хакында хыялланып яшәргә, ирешелгән биеклектән төшмәскә кирәк инде безгә. Үрнәкләр дә, өлгеләр дә җитәрлек. Ә темалар дөнья тулы...

Шулаен шулай да, әмма менә бүген-иртәгә ничек көн итәрбез, исән калырбызмы дип яшәгәндә, бертуктаусыз акча, власть алмашынып торганда, алар гына да түгел, хәреф хәтле хәрефең алмашынырга торган заманда, поэма-дастаннар иҗат итү түгел, дүрт юллык шигырь язарга да рухи көчең калмаса, нишләргә? Мондый рухи тетрәнешләрдән соң каләм-каурый «күтәрерлек» тә хәлең калмаса?... Ни өмет, ни ышаныч бетсә?.. Әйләнә-тирәне битарафлык томаны чолгап алганда, яшәү белән үлем ишеге арасында ятим Апуш кебек йөрәгең бозга катып басып калсаң?.. Ә бит кирәксезлек һәм кадерсезлек шул дәрәҗәдә ки, хәтта үҗәтләнеп тырмашырга, үрмәләргә көч бирә торган ноктасыннан да авышкан. Гади кешеләрнең генә түгел, шагыйрьләрнең дә рухы сынарлык чиккә килеп җит әле!

Мондый чакта мәңгелек темалар коткара, дибез. Әмма да ләкин темалар кытлыгы җәфаламый безне... Темадан һәм проблемадан күп нәрсә юк. Әдәбиятка изге бер терәк, ышаныч итеп карау кытлыгы куркыта. Әдәби сүзгә дә тел бистәләренең буш сүзе кебек итеп карау чәчәк аткан. Чөнки хәзер «сөйләүчеләр» бик күбәйде. Әмма «язучылар» сирәгәя бара... Ник дигәндә, язу процессы бик катлаулы, һәм күпләр, шәп сөйли белсәләр дә, язуга тотынса, сүзсез калалар...

Ярый, сүзгә мавыгып, читкәрәк киткәнмен. Шулай итеп, поэмалар язу өчен темалар да, сюжетлар да җитәрлек. Ә менә укучы йотлыгып укысын өчен, нинди темалар сайларга соң? Турысын әйтим, тарихи роман-повестьлар да күбәеп китте. Шунлыктан, үзебез яшәгән чорны чагылдырган, гади көнкүреш-тормыш хәлләрен сурәтләгән әсәрләр, аерым алганда, йөрәккә якын образлар белән баетылган поэмалар тансыклата башлады. Шигъри повестьлар, хикәяләр җитми. Бу турыда сүзгә керешүнең төп сәбәбе шул түгел микән әле? Ә моның өчен, әлбәттә, «безнең заман герое» кирәк! Ә кайда ул, нинди ул, нәрсәгә омтыла? Без белгән Совет чорында «безнең заман герое» шагыйрьләрнең үзләрен дә кузгатып, дәртләндереп торган. Ә безнең чорның героикасы бармы соң?.. Кемнәр турында язарга? Депутатлар турындадыр, бәлки?.. Ә бәлкем, кайсы якка борылырга белми йөргән, атнасына ике-өч төскә кергән кыйбласыз бәндәләр хакындадыр?.. Әлбәттә, болары да үзенә бер тема, үзенә бер заман типлары. Дәүләт һәм милләт темалары тирәсендә дә кызыклы образлар, хәтта геройлар тудырырга була... Шулай да, тормышта үзе үк сине әйдәп, рухландырып торучы каһарманнар, типлар булмаса, шагыйрь үз эченә йомыла, үзенә кайтып егыла, һәм нәкъ менә шуның нәтиҗәсе буларак, сюжетлы, эчтәлекле поэмалар урынына йөрәк авазы булып инрәп чыккан хисси әсәрләр барлыкка килә башлый. Монда инде сюжет урынына авторның җан хәрәкәте калкып чыга. Шул җан хәрәкәте образлы рәвештә үстерелеп, шәхеснең, ягъни авторның эчке каршылыклары яисә рухи камиллеккә омтылуы аша үзе бер сюжет сызыгы барлыкка китерә сыман. Шагыйрь үзенең бөтен уй-кичерешләрен сурәтләп, үз җанын—үзенең лирик героен ачып бирә. Бу очракта шагыйрьнең лирик герое үз заманының да «героена» әверелеп китә. Әйе, асты-өскә килгән четрекле, болганчык заманнарда, уйланып калган, мен төрле шик-шөбһәгә төшкән, җәмгыять белән дә, үз үзе белән дә каршылыкларга кереп беткән чын герой—ул фәкать чын шагыйрь генә булырга мөмкин. Чөнки ул хаким дә түгел, кол да түгел, бай да түгел, хәерче дә түгел! Ул фәкать ярлы гына... Ярлы Кәримнәр, Демьян Бедныйлар шикелле... Ә ярлылык—гаеп түгел. Рухы бай

кеше хәерче була алмый, һәм шуна күрә дә «шагыйрь» дигән сүз янында бу яман сүз янәшә йөрергә тиеш түгел!

... Шулай итеп, «сюжетсыз поэмалар» барлыкка килә, һәм әйтергә кирәк, мондый лирик-публицистик әсәрләр торган саен кинрәк урын ала бара. Алар шигъри монолог рәвешендә дә, кемгәдер яки нәрсәгәдер мөрәҗәгать итү рәвешендә дә, көндәлек яки хатлар формасында да язылырга мөмкин. Һәркемнен үз фантазиясе. Укучылар да мондый поэмаларны яратып кабул итәләр дип уйлыйм. Хәер, Такташның мәшһүр «Киләчәккә хатлар»ы нәкъ шундый бит инде... Дөресен генә әйткәндә, уйланырга яраткан укучыны хәзер сюжет-фабулалар артык җәлеп тә итми. Бөтен күнелен ачып салган шагыйрь белән сөйләшү, кинәшләшү, серләр уртаклашу җитди укучыга күбрәк ошый... Шагыйрьнен хисси халәте укучыга да тәэсир итә. Мондый поэмаларда тирән фәлсәфә, нечкә лирика бер берсе белән тыгыз үрелеп бара. Бу бит сүз тәмен һәм кеше психологиясен анлаучылар өчен үзе бер ләззәт чыганагы. Сүз унаеннан, әгәр теле гүзәл булмаса, озын-озын поэмаларның да поты бер тиен. Сүз һәм тел байлыгы, хис вә кичерешләр тыгызлыгы хикмәт белән өретелгән поэмалар гына үзләрен аклаячак. Аксак-туксак сүзләр тезмәсен озак укып булмый. Ул күнелгә дә, акылга да берни бирми, киресенчә, ачуны чыгарып, барлы-юклы гармониянне генә җимерергә мөмкин... Поэма җырлап торсын, көлеп тә, җылап та торсын. Укучыны төрле шигъри дулкыннарда тибрәтсен. Минемчә, бер үк поэмада төрле калыптагы, үлчәмдәге һәм формадагы шигырьләр дә файдаланырга тиештер: әлбәттә, хис-кичерешләргә карап. Поэма—ул шигъри симфония. Димәк, поэма язырга алына икән, шагыйрь әллә ничә төрле музыка коралында уйный белә торган музыкант шикелле булырга тиеш.

Җыйнап әйткәндә, татар әдәбиятында поэма жанры үз урынын күптән тапкан һәм ул аны югалтырга да җыенмый. Фәкать анын формалары гына үзгәрергә мөмкин. Темалар тормышның үзендә хәттин ашкан. Хәзерге вакытта әйтергә теләгән фикеренне дини образлар аша да бирергә була. Бу үзе әлегә башланмаган бер дөнья кебек. Дөньяви темалар да бик кызыклы һәм гыйбрәтле образлар, геройлар иҗат итәргә дәшеп торалар сыман. Сүз иреге булгач, яз да, яз—иренмә генә. Ләкин ничек әйтү, һәрвакыттагыча, төп проблема һәм талант сере булып кала... Шул үк вакытта, укучы, гел дә тарихи яисә мифик, дини яки фәлсәфи поэмалар гына укып ялыкмасын өчен, тормыш-көнкүрешнен төрледән төрле якларын чагылдырган «күнелле» поэмалар да бик кирәк. Без «таныш моннарга», «хат ташучыларга», янәшәбездә генә яшәп яткан кызык һәм гыйбрәтле язмышларга—шагыйрь йөрәге һәм аны аша узган үз заманыбыз геройларына бик тә сусадык...

## Эльмира Шәрифуллина:

Язма әдәбиятыбызның, шигъриятебезнен чишмә башы—поэмалар: «Кыйссаи Йосыф», «Хөсрәү вә Ширин», «Җөмҗөмә солтан», «Гөлстан бит-төрки», «Нуры содур» һ. б., һ. б. Аларның бик күбесе Коръәнгә нигезләнеп, Коръәннән нур алып иҗат ителгән. Гомумән, мөселман халкынын бу изге Китабы мен ел дәвамында төрки-татар әдәбиятын «тукландырып» торган. Ә ул әдәбият, нигездә, поэмалар халыкның әдәбен, әхлагын, динен саклауга хезмәт иткән.

Коръән үзе дә шигъри тел белән язылган. Ул ритм-рифмалы бик күп аятьләрдән тора. Көйгә салып мәкам белән укылуы, аерым догаларның аеруча җинел ятлануы, В. Порохова тәрҗемәсенен шигъри строфаларда бирелүе—монын тагын бер ачык дәлиле.

Аннан сон, пәйгамбәрлек вазифасы белән шагыйрьлек миссиясе арасында күркәм уртаклык бар.

Кыскасы, нинди генә очракта да шагыйрь—кеше күнеленә иман нуры иңдерүче, шәфкать орлыклары салучы. Нинди генә очракта да кешенен рухын күтәрергә, аңын үстерергә, матурлык, нәфислек тәрбияләргә тырышучы. Ана сөте һәм Ана теле, сугышларсыз ятим ителгән бала һәм тол хатын, туеп сикергән эшкуар һәм фәкыйрь зыялы... кан-яшь, рәнҗеш-каргыш... боларга битараф калмаска тиеш шагыйрь!

Бүгенге заман өчен изге канунннарыбызның кабаттан, кичекмәстән аякка басуы, кешеләрнен гөнаһтан арынуы шарт. Мондый зур таләпне мондый авыр һәм саваплы хезмәтне, минем уемча, поэма жанры колачларга тиеш. Димәк, үзеннән үзе бүгенге көн шагыйрьләренен поэма жанрына йөз белән борылуы сорала.

Тагын бер фикерем: киләчәктә шигъри драмалар, музыкаль поэмалар сәхнәгә менсен иде. XXI гасырга мин шуны телим.

## Сәгыйт Хафизов:

Миңа калса, соңгы берничә дистә елда безнең тәнкыйть поэзия өлкәсендә һәрчак та да акыллы сәясәт тота алмаган. Дөрес, Башкортстанның Халык шагыйре Мостай Кәрим икенче «шигъри шартлау» дип билгеләгән алтмышынчы еллар азагы поэзиянең үзенең дә, шагыйрьләр тәнкыйтенең дә чиксез активлашуы белән сыйфатланды. Интеллектуаль шигырь, верлибр, стиль формалары, эчтәлек тыгызлыгы турында матбугат дискуссияләре, буыннар иҗаты турында фикерләүләр һәм поэтик эзләнүләргә чакырулар—һәркайсы лириканың көчәюенә китерделәр. Болай гына түгел, лирик башлангыч һөҗүмчән төс алып, поэзиядәге эпик якны кысрыклый башлады. Заманчылык, новаторлык тойгылары белән әсирләнгән яшь шагыйрьләр дә, тәнкыйтьчеләребез дә лирика маршын алкышлап, традицион поэма, баллада, мәсәл, сюжетлы шигырь кебек лиро-эпик жанрларны мәйданнан кысрыклау сәясәтен үткәрә башладылар. Матбугат «хәзерге укучыны озын-озын тасвирлый поэмалар белән шаккатыруы кыен... Безне поэманың классик төшенчәсе канәгатьләндереп бетерми... Шигърият фикер һәм хис тирәнлегенә омтыла», кебек реформаторлык идеяләре һәм лозунглары белән тула.

Ләкин бу һич тә замана лиро-эпик жанрлар язмышына битарафлык күрсәткән дигән сүз түгел. Өлкән әдәбиятчыларыбыз Н. Фәттах, И. Нуруллин, З. Мәҗитов, хәтта Х. Туфан кебекләр поэзиядәге суллык әверелешләренә карата тирән борчылуларын белдерәләр, бигрәк тә эпиклык хасияте—сюжетның җуелуына карата чаң да сугыла. «Иң борчый торганы,—дип белдерә З. Мәҗитов 1967 елда язган әдәби күзәтүендә—безнең поэзиядә инде утызынчы еллардан ук яшәп килгән кимчелек—хисне гомуми абстракт формада сөйләп чыгу, сюжетсызлык». Поэзия бәхәсендә сүз алып И. Нуруллин әйтә: «Соңгы вакытларда «сюжетлы» шигырьләр кимеде. Һәрбер шагыйрь—һәм олысы, һәм кечесе—үзен тәкъдим итәргә, үзенең уй-фикер хәзинәсен укучыга тагарга тырыша. Ярый ла, ул кызыклы шәхес булса...»

Тик бу «консерваторлар» һөҗүмчән лирика басымын туктата алмадылар, поэзия традицион сыйфатларын югалтып, тәмам деформацияләнде. Хәзер безгә мәгълүм чор тәнкыйтенең поэзия мәсьәләләренә карата аналитик, акыллы сәясәт үткәрә алмавына, югалтуларга үкенү хисләре белдерергә генә кала. Хәер, бу дәгъваны үз вакытында З. Мәҗитов шактый кыю сиздерде. «Матбугатта бер фикер әйтелсә, кагыйдә буларак. Шул инде законга әйләнә, аңа каршы фикер әйтелми... Соңгы араларда чыккан тәнкыйть гомумән олы шагыйрьгә дә, яшь шагыйрьгә дә дифирамб төсен ала башлады». Әйе, үткәнне кайтара алмыйсың, ләкин анларга омтылу кирәк. Поэма, баллада кебек борынгы жанрлар нишләп безне канәгатьләндерми, ник үги итеlә алар?

Без бу вакыттагы иҗатның психологиясен болай күзаллыйбыз. Сталинизмның шомлы дәвере бетеп, «Хрущев җепшеклеге» дип аталган сәяси этап башлангач, рәсми идеология демократик юнәлештәге рухи янарыш-үзгәрешләрне күрсәтергә теләде. Сәнгать интеллигенциясеннән катгый таләпләр белән чор пафосын бирү, «матурлыкның яңа сынын» ачу соралды. Кыскасы, сәяси лидерларда шәүләләнгән коммунистик тормыш идеяләре белән халыкны ашкындыру, хәлиткеч «атакага» күтәрү кирәк иде. Бу абстракт бурычны әдәбиятның кайсы төре башкара ала? Драмамы? Юк, анда конфликтлар сурәтләү кирәк, ә замана һич тә болар белән шаярмады. Эпос, лир-эпик жанрлармы? Ай-һай, эпос-вакыйга, сюжет, бәрелешләр, типик характерлар, шартлар дигән сүз ул. Эпос кендегә белән тормышка береккән. Ә ачлы-туклы яшәгән, авызыннан үпкәсе күренеп торган халыктан яисә коллыкка корылган колхоз-совхоз тормышыннан нинди илһам алып повесть, сюжетлы поэма яисә тасвирый шигырь язасың! Сайланыш лирикага төшә. Монда, ичмасам, хөррият! Шагыйрь күнелендә зәмһәрир суыкларда да гөлләр чәчәк атарга мөмкин бит. Пафос, патетика дигәнең дә берни белән киртәләнмәгән анда. Бүлмәдә ятып та, күңелендә ни бар, шуннан әсәр әмәлләргә була... Бигрәк тә бүлмән җылы, күңелең көр, ә атың аранда булып, буранда кайгың булмаса...

Юк, чын лирик әсәр җиңел языла димим. Һ. Салиховның «Тәндә җаным», Дәрдмәнднең «Кораб», Х. Туфанның «Агыла да болыт агыла» сыман—бүлмәдән түгел, ә йөрәктән чыккан әсәрләрнең кадерен дә беләм. Тик тормыш белән бәйләнеш ягыннан карасаң, мөһим үзенчәлек бар: шагыйрь үз каләменә субъектив дөньясыннан килә, тормышка үз мөнәсәбәтен ача. Популярлашу шуннан дим.

Уены-чынын бергә кушып әйтелгән бу сүземне расларлык дәлил дә бар икән

бит. Әнә Зәет Мәҗитов «Заман сулышын тоеп» (1967) исемле китапта лирика тарафдары Нил Юзиевнын сүзләрен китерә: «Чорны, тарихнын прогрессын олы итеп әйтү өчен лирик эпоснын мөмкинлекләре поэмага караганда да зуррак. Биредә шагыйрьнең кул-аяклары характер иҗат итү белән бәйләнми».

Әйе, нәкъ өстенә китереп баса тәнкыйтьче. Лирик шагыйрьнең кул-аяклары сюжет кору, конфликт тасвирлау, характер иҗат итү кебек авыр мәшәкатьләр белән бәйләнмәгән. Тик китап авторынын репликасы гына безнен лирикларны зур шөбһәгә төшерергә мөмкин иде: «Сорау туа: характер иҗат итү белән бәйләнмәгән әдәби әсәр бармы? Ул әдәби әсәр буламы?.. Пушкиннын «Полтава»сы, Лермонтовнын «Демон»ы, Некрасов, Твардовский поэмалары, Байрон әсәрләре вакыйгага нигезләнмәгәнмени? Характер сурәтләү белән бәйләнмәгәнмени?»

Тик, кызганыч, безнен байтак шагыйрьләрне андый кисәтү борчымады. С. Хәкимнен «Язгы, жир уллары» кебек патетик-романтик әсәрләреннән башлап Н. Юзиев әйткән лирик эпос, ягъни сюжетсыз, конфликтсыз, күтәренке-фәлсәфи лирик герой монологлары конвейеры гамәлгә керде. Һәм безнен галим-голәмәбез аптырап калды, мондый әсәрләрнен жанрын ничек атарга?

Н. Юзиев, Т. Галиуллин лирик фәлсәфи, лирик-психологик монологларны авыз тутырып поэма дип атауны хупладылар. Р. Фәйзуллин исә нәкъ шундый әсәрләрне күздә тотып: «Ясалмарак поэмаларга караганда тәзек шигырь цикллары күбрәк ошый төшә»,—диде. Сер түгел, мәгълүм шигъри монологларнын традицион поэма жанры белән уртаклыгы юклыгын күпләр таный. Әйтик, күптән түгел Г. Гыйльманов замандаш шагыйрь Газинур Моратнын аерым шигъри язмаларына карап болай ди: «Түбә» дип аталган әсәр классик поэмалардан нык кына аерыла. Ул күбрәк шигъри циклны хәтерләтә». Ләкин мәзәк хәл: тәнкыйтьче әсәрнен циклга тартымлыгын күрсә дә, безнен күп әдәбиятчыларыбыз сыман, мондыйны «поэма» дип тәкърарлавын дәвам итә. Күрәмсен, рецензентларнын дус-ишне, агай-энене рәнжетәсе килми. Чөнки поэма—поэма инде, янгырашы нинди дә, абруе нинди! Ләкин халвә, халвә дип кабатлаудан гына авызга бал инми бит! Юк диярлек чын поэма! Чал тарих булып Кол Гали, Сәйф Сараи, Мөхәммәдъярдан килгән, Кандалый дәверендә мәхәббәт, кешене олылау хисләре белән сугарылган, Тукайлар тарафыннан йөз белән тормышка борылып халыкны көлдергән, елаткан, ә инде бирерәк заманда Ф. Бурнаш, Һ. Такташ Ф. Кәрим, М. Җәлил, И. Юзеев иҗатында яшәреп, хәятнен төрле-төрле социаль-рухи гамьнәрен гражданлык кыюлыгы белән янгыраткан поэманы—халык юанычын, танып-белүнен бер мөһим ачкычын без кадерләп саклый алмадык.

З. Мәҗитовнын сюжетсызлык «утызынчы еллардан килгән чир», дигән хәтергә сенде. Әйе, Сталинизмнын шомлы елларында калыккан конфликтсызлык күренеше һәм теориясе поэзиядәге эпик башлангычны акрынлап буды. Ә милли традицияләргә, гореф-гадәткә, халыкнын үзаныңа астыртын, мәкерле һөҗүм оештырган «җинүле коммунизм» еллары поэманын чын асылын да юкка чыгарды. Ә хәзерге «поэма» дип исемләнгән әсәрләрнен бик күбесе—тик күз буяу. Менә ышанмасагыз, күп еллар буенча мөгтәбәр «Казан утлары» журналында поэзия бүлеген житәкләгән Рәдиф Гаташ әфәндегә колак салыгыз. «Поэма жанрында үсеш, яналык юк... Шигырьдә дә күбрәк ачык капкаларны кагу», ди ул анкетага жавабында (1999, N6). Поэзия, бигрәк тә лиро-эпик жанрлар тирәсендә һаман да күз буяу, үз-үзебезне алдау һәм ялган юану дәвам итсә, унайга хәрәкәт булмас та шәт. Чөнки төпкә гади генә хакыйкать ята. Әдәби форма тик үзенә туры килгән эчтәлекне кабул итә, сыйдыра. Бары шул таләп үтәлгәндә генә чын сәнгать әсәре туарга, казаныш яуланырга мөмкин.

Димәк, безгә шигъри тәнкыйтьтәге сәясәт ялгышларын танырга һәм сюжетлы чын поэзия, баллада, мәсәл, шигырь жанрларын терелтү, аларны янә әдәбият мәйданына чыгару юлларын эзләргә кирәк!

## Нәҗибә Сафина:

Безнен бүгенгебезгә тарих тәхетеннән күренеп торган олуг кыйссалар—«Идегәй» һәм «Таһир кыйссасы». Күрәбез, кыйсса булырдай вакыйгалардан гына кыйсса, шундый вакыйгадан гына поэма туа. Тарих буйлап бүгенгә хәтле килеп житә алганнары үз эчләренә фани гына түгел, ә бакыйлык вакыйгаларын да алганнар. Ә безнен Такташ, Җәлил, Фатих Кәрим, Сибгат Хәким, Хәсән Туфан поэмалары

шундыйлармы? Ә Салих Батталның «Чирмешән буйлары» шигъри романы? Без, безнең яшьләребез аларны бүген беләме? Белмәгәннәр ник белми? Ә Демьян Фәтхинең «Себер трагедиясе», Әхмәт Фәйзинең «Флейталар»ы? Дистәләгән поэмалар авторы Хисам Камалның «Яну», «Туган җирдә», «Әнкәй истәлеге», «Бердәнбер ул», «Зәй буенда», «Тормыш дулкыннары», Марс Шабайның «Җикән камыш», Сибгат Хәкимнең «Гөбнә буенда», «Кырыгынчы бүлмә», «Пар-ат», Әхмәт Юнысның «Кирзе итек», Әнвәр Давыдовның «Кызыл таң», «Соңгы көз», Әхсән Баянның «Сез аңларсыз мине», Сафуан Муллагалинең «Бер өзелсәң туган җиреңнән» трилогиясе, Илдар Юзеевнең «Тынлык белән сөйләшү», «Таныш моңнар», «Язылмаган поэма» Флера Гыйззәтуллинаның «Яшеннәрнең күз яше» (һәм тагын ун поэма), Сажидә Сөләйманованың «Җырланмаган җырлар»ы?

Кыска гына чор эчендә күпме автор, күпме поэмалар! «Казан утлары» журналын укучылар бу мәкаләдән хет исемнәрен генә булса да исләренә алсыннар дигән өметтән, хәтеремдәгеләрен генә булса да, атап китәсем килде. Һәм башлагач туктый алмый дәвам итәм: Рәшит Әхмәтҗан—«Бишташ», «Аучылар кибетендә», Роберт Әхмәтҗан—«Йолдызстан», «Уйна, улым», «Таш аргамак», «Сәхипҗамал», Кадыйр Сибгатуллин—«Туфан белән сөйләшү», Рөстәм Мингалим—«Күз карасы», «Иртәгә», «Минем дәүләтем», «Ике авыл арасы», Равил Фәйзуллин—«Гадиләргә гимн», «Керәшчеләр», «Сәйдәш», Харрас Әюп—«Ат һәм гармун турында», Ренат Харис—«Мулланур Вахитов», «Камил Якуп» һәм тагын бик күпләр, Әхмәт Рәшит—«Колшәриф», «Мөхәммәдъяр», «Сөембикә» һ. б. Мөдәррис Әгъләм—«Тукайдан хатлар», «Акмулла арбасы», «Онытма, Европа», Зөлфәт—«Гасырлар дастаны», «Александр Ульянов», Ркаил Зәйдулла—«Күпер», «Хәсән Туфан», «Күлтәгин ташы», Эльмира Шәрифуллина—«Тәмуг кисәве», Зиннур Мансуров—«Хәертдин Мөҗәй»...

Флера Гыйззәтуллинаның поэмалары исә, алда аталып киткән күп поэмалардан аермалы буларак, сюжетка корылмаганнар. Мондый поэмалар элек тә булганмыдыр, әмма без бүген сюжетлы вә сюжетсыз поэмалар хакында да сүз алып барабыз, бүген сюжетсыз поэмалар күбрәк тә туалар... Ярый, ә кайсы шагыйрь, кайсы поэмалар замана кыйссасы булырлык әсәр югарылыгына күтәрелә алалар? Тәнкыйть шушы сүзне әйтергә тиештер. Ә ул сүз нинди булыр? Әллә поэзиябезнең дә, җаннарыбыз шикелле үк, агымы өзелеп, ташларга, комнарга таркалган чорымы?

Ә поэзия ул нинди булган? Сюжетлымы, сюжетсызмы? Нинди булырга тиеш? Поэма, гомумән, киң катлам укучы өчен язылган жанрмы? Әллә аерым бер катлам кешеләре өчен генәме?

Төрки халыкның поэмасыз чоры булмаган да шикелле. Ул үзенә тиешле бәясен алдымы?

Татар әдәбиятында поэмалар тарихы—үзе бер тарих. Ул халык язмышын поэтик күз алдына бастыра алган җан елъязмасы.

Тәнкыйть йоклаган арада шагыйрьләр тарихны узып китәләр. Бу юлы да шулай булмадымы? Тарих төпкеленә төйгечләп тутырылган халык җаны, милләт рухы бәлки бүген поэмалар ургылы булып атыладыр?

XX гасыр шагыйрьләргә дә, поэмаларга да бай булды. Әлегәчә төгәл санын гына да билгеләмәгән татар милләтенең җанын, аңын кабат терелтергә тырышучы шагыйрьләр үткән чорларда да булган, әлбәттә. Тик дистә, йөз еллар дәвамында йөкләп-йөкләп ташып Лука Канашевичлар, Берияләр, дәүләт башында торучылар туктаусыз китап яндырганнар икән—алар юк ителгәннәрдер. Шул шагыйрьләрнең китапларын (җаннарын) яндыру милләтебезнең җанын көйдергән, көчсезләндергәндер дә, дәүләтсез калдыргандыр... Бер Һади Атласины кулга алгач кына да Бөгелмәдән Казанга ике ат йөге белән китерелеп китап вә кулъязмалар яндырылган икән. Димәк, без янган милләт... Димәк, кабат көлдән-күмердән торып киләбез. Бәлки Йосыф Баласагуни, Кол Гали әсәрләре әле исән кала алганнары гынадыр? Ә исән калганнарына нинди кадер-хөрмәт күрсәткән бит халык! Утыз Имәни «Йосыф китабы»ның йөздән артык вариантын табып, утыз мәртәбә бастырып чыгарган. Бу сюжетлы поэманың халык җанына никадәр якын, ятышлы икәне аңлашыладыр.

Без Ш. Бабич, С. Рәмиев архивларын да югалтканбыз. Ә Галимҗан Ибраһимов үз вакытында Академик үзәк рәисе буларак аларның архивларын туплаган булган. Шуларны соңрак вагоны белән алып кайтып яндырганнар. Шул хакта Хәсән ага Туфан төрмә ишекләре аша да күреп торганлыгы турында сөйли торган булган. Чөнки җил белән кайбер кәгазь битләре төрмә тәрәзләре аша да кергән икән. Ә

үзебезнең чорның мәшһүр шәхесе Нәкый Исәнбәт «Идегәй» дастанынының дистәләгән вариантын табып, кырыгынчы елларда «Совет әдәбияты» журналында бастырган бит. Ә кая ул журналлар?

Ижаты югалган халык, милләт тарихтан үзе дә җуела. Бүген шул җан елъязмабызны язучы шагыйрьләребез, язучы, галимнәребез тагы яшәешнең төпкеленә ташланган хәлдә көн күрергә мәҗбүр. Чөнки бүген аларга гадел җылы бирүче бер кояш кына бар вә тагын җаннарында кояш йөртүчеләрдер... Хәер, җанын ягып яшәүче шагыйрьне бер генә заманда да дәүләт әһелләре чын күңелдән яшәтү чарасын күрмәгәннәр инде... Аларны фәкать шигъри җанлы халкы гына яшәткән. Бүген дә шагыйрь күзләрен шул халкына, милләтенә текәп тора.

Дөньялык кысасында милли яшәеш, халык рухын, хис хәрәкәтен күрсәткән олы поэма турында бүгенге уйлану әдәбият дөньясын сагайтыбрак калдырган икән, димәк, рухыбыз, җаныбыз халәте сагайта шагыйрьне, әдәбиятны. Чөнки Баласагуни, Сәйф Сараи, Мөхәммәдьяр чорларындагыдай мәдхия җырларлык ханнар, юлбашчылар—алары да кысылып, вакланып беттеләр лабаса. Хәтта алар алып бара торган сәясәтнең дә эче актарылды. Хәзер сәламәт акыллы һәр кеше кайда басып алу сугышы, кайда качып, кайда кысып алу сугышы барганын аңлый... Ә бит сәясәтче, юлбашчылар олы булганда ил халкын олырак максатларга, иҗади максатка юнәлтә. Кеше буларак горур яшәргә мөмкинлек бирә. Андый чорларда аның мәхәббәте дә зуррак, җыры да тирәнрәк, озын гомерлерәк була. Ягъни халык үз тормышы—иҗади тормыш белән яши һәм ил өстенә ишелгән афәтләр чорында гына сәяси сугышларга кушылырга мәҗбүр була. Инде кысылдык та, шуны аңлап алдык та, «ирек», «иркенлек» уены уйнарга тырышабыз, шигырь генә түгел, поэмалар да пачкалап-пачкалап языла. Тик күпчелек очракта алар ясалма булып чыгалар. Поэмалар да заманы үтеп киткәнче үк дигәндәй халыктан ераклаша. Поэманың үзенең дә төп билгеләмәсе тоныклана төште. Үтәр заман, монысын башкасы алыштырыр һәм инде безнең заман хакында ул заман үз сүзен әйтер: «җаннар соңгы чиккәчә кысылган заман булган ул», дияр. Минем моңа иманым камил. Чөнки бүген бөтен бер Язучылар оешмасы белән бергә утырып язсаң да, Кол Галинең «Йосыф кыйсса»сын дөньяга чыгарып булмас иде. Җан кысылганда хис ничек хәрәкәт итә алса, дөньялык кысылганда поэма да шулай ярала һәм яши, укучыны да яшәтә аладыр. Моның өчен әлбәттә, шагыйрь дә дөнья кысаларына сыйдырылырга, яшәргә тиештер. Әмма... Әмма... Җаннары әрнегән затлар санап караганнар: бүген шагыйрен, язучысын яшәтер өчен аның халкы үз кесәсеннән хәтта бер тиен дә чыгармый икән! Бик тырышып санаганда да ул сан 0,2 тиен чамасы гына тәшкил итә икән! Тик халык моны белми. Кайларга гына, нинди максатларга гына салмый ул үз сәмәнен, тик әдәбиятка гына түгел. Ә дөньялык кысасында безне нәкъ шул әдәб, әхлак тәрбиясе, әдәбият тәрбиясе җитмәү китереп кысты да бит инде! Мондый кысылу миллилекне дә кысрыклап чыгара. Матди, женси таләпләр генә кала кебек... Ә без бүген күп нәрсәләргә читтән генә карап торабыз. Безнең үз дәүләтебез дә, мәнфәгатебез дә юк кебек. Олы максатыбыз да... Бәлки әдәбияттагы олы жанрның менә шундый сәер халәт кичерүе шуның белән аңлатыладыр да... Бакыйлар вакланганда дөньялык кысаларында ничек чын олы жанр туа алсын икән?

Ә инде поэма сюжетлы яки сюжетсыз булырга тиешме?.. дигән сорау туарга да тиеш түгел. Чөнки поэма дигән кыйссаның яшәеш сюжетына корылган булырга тиешлеге көн кебек ачык бит! Ә яшәеш, барыбер, фанилыктан бакыйлыкка таба хәрәкәт итә. Тик менә безнең яшәүебез генә бер әрнүле кыйсса кебек...

*Рецензияләр конкурсы*

## ЙӨРӘК ТИБЕШЕ

Һәр сүзнен үз тәме бар... Синоним сүзләрдә тәмнәр бер-берсенә охшаш булсалар да тәм тойган кеше аны аера белә. Әгәр жанында телгә, сүзгә мәхәббәте булса! Шигырьләрдә дә шулай. Кайнар хис-тойгылы, үткен фикерле байтак шигырьләргә композиторлар көй язмаса да, шигырьнен эчендә көй үзеннән-үзе барлыкка килә, туа. Кыскасы, жырлап укыйсын андый шигырьләрне. Фәнис Яруллин, Зөлфәт, Мөдәррис Әгъләм, Роберт Миннуллиннарнын күпчелек шигырьләре шундыйлар. Андый шигырьләрдән тиз генә аерылып та булмый, кабат-кабат кайтып укыйсын... Жан үзенә азык сорый, янадан-яна һәм тагын да тәмлерәк сүзләрдән «пешерелгән» шигырьләрне эзли башлыйсын.

Сонгы елларда шигърият дөньясы умарта кучедәй гөжләп тора. Эшчән бал кортлары бал жыя, канатлары тузганчы оча алар... Алардан кала умарта оясында башка төрле эшләр белән мәшгуль булган кортлар да бар...

Гәжит-журнал битләрендә бер-берсенә су тамчысыдай охшаган, мен кат кабатланган фикерне мен дә беренче мәртәбә кабатлап язылган шигырьләр бәйләм-бәйләм булып чыгып кына тора. Шигырь язучылар елдан-ел күбәя, аларнын арасында берән-сәрән генә булса да шагыйрьләр күренгәли. Сирәк булса да—бар алар, бар, Аллага шөкер...

Ин мөһиме аларнын барлыгы, чөнки алар шигъриятькә үзенчә бер яналык алып килә. Андый әсәрләрне укыгач шигъри жанлы кешеләрнен күнелләре яктырып китә, хасталана башлаган күнелләр сәламәтләнә, рух ныгый терелә, тазара.

... Инде менә ничәмә еллар мин Рафис Корбан ижатын кызыксынып укып барам. Юк, укып кына калмыйм, күнелгә сендереп барам. Рафис Корбан—талантлы балалар шагыйре, анын басылып чыккан бөтен китаплары кул астымда, кабат-кабат алып укыйм мин аларны. Һәм менә, күптән түгел генә, анын яна китабын да укып чыктым. «Уян, татар» дигән исем астында басылган бу саллы гына китабы (Казан, «Новая идея» нәшрият үзге, 1999 ел) өлкәннәр өчен язылган шигырьләрдән тора. Укып чыккач уйга талдым...

Күз алдыма халык шагыйре Шәүкәт Галиев килеп басты, анын янәшәсенә Роберт Миннуллин, анын янына Рөстәм Мингалим һәм Ләбиб Лерон... Барысынын да уртак, охшаш яклары бар бу шагыйрьләрнен, шул охшашлыгы аларны бергә берләштереп тора да. Балалар өчен дә, өлкәннәр өчен дә һәм, шулай ук, жыр жанрында да ут уйнатып эшләүче оста куллы, талантлы шагыйрьләребез алар. Менә инде алар янәшәсенә Рафис Корбан да килеп басты.

Мин бу юлы Рафис Корбаннын китапта басылган лирик һәм публицистик шигырьләренә тукталып китмәкче булам. Кызыклы пародияләр, эпиграммалар, тәржемәләр һәм «Шәкүр карак» бүлегенә кергән әсәрләренә кагылмыйча, бары тик лирик һәм публицистик шигырьләрен генә күнелем аша берәм-берәм үткәрергә булдым. Алар мина ничек тәэсир итәрләр икән? Шәүкәт Галиевнен, Роберт Миннуллиннын нечкә хисле лирик шигырьләренә охшашмы алар? Ә кайсы яклары белән аерылып торалар? Хис-фикер тыгызлыгы бармы аларда? Күнел кылларын тибрәтерләрме алар, уйларны сискәндерерләрме? Уйланырга мәжбүр итәрләрме? «Хаста» уйлыларга жылы сүз әйтерләрме?..

Беренче шигырьгә тукталам:

Килсә кунак, түргә үткәргән дә,
Борынгылар башта дога кылган.
Килсә илһам, мин дә күнелемнән,
Шигырь укый башлыйм—дога кылам...

Юл чыкканда, изге сәфәр теләп,
Борынгылар тагын дога кылган.
Жырларымны сезгә юллаганда,
Шигырь укыйм мин дә—
дога кылам.

Шигырьне дәвам итәсе килә башлый, күңелемдә яна строфалар туа, шигырьне тагы да үстерәсе килә. Чөнки яхшы шигырь күңелгә керүгә үк үсә башлый, ә хиссез, фикерсез шигырь, киресенчә, кичерәйгәннән-кичерәя барып юкка чыга. Кат-кат укыйм бу шигырьне, җанга рәхәтлек инә. Чөнки фикерен кыска итеп, оста итеп әйтеп биргән Рафис Корбан.

Шигырь төзек, фикер төгәл һәм янача әйтелгән. Катлаулы чагыштырулар да юк, гап-гади сүзләр генә, әмма уйланырга мәҗбүр итә ул...

Янә бер шигырь:

Дәүләт эчләрендә дәүләт—
бик яхшылар, әйбәтләр.
Үз телен онытып барган,
Ике телле дәүләтләр.
Дәүләт эчләрендә дәүләт,
Шул мәзәкме—көлмәгәч!
Шулай яши икән халык—
Үз кадерен белмәгәч.

Бу—бүгенге безнен халәтебез, безнен яшәешебез. Шагыйрь борчыла, сине дә борчылырга мәҗбүр итә. Әйе, уйланмаган төшеннән уйланырсын... Дәүләт эчләрендә дәүләт булып яшәүләре авыр икәнен анлап аласын, авыр сулыйсын. Бу безнен язмыш, безнен милләт язмышы... Үз кадеребезне белергә вакыт!

Икенче шигырендә шагыйрь бу фикерне тагын да үстерә, күзгә бәреп әйтә:

Милләтем дип әйтсә берәү,
Милләтче дип чыкты сүзе.
Татар өчен кем көрәшсен,
Көрәшмәсә татар үзе!

Рафис Корбаннын менә бүген «Уян, татар!» дип кычкыруы—урман эчендә адашкан кеше кычкыруы гына түгел. Чөнки ул ялгызы гына түгел, анын тавышын ишетеп башкалар да ана якынлашырлар.

Әйе, еллар урманы карурманнан да көчлерәк шаулый, шомы бәгырьне телә. Әмма урманда Рафис Корбан ялгызы гына түгел! Меннәр, миллионнар адашып йөри анда, тик яктыга, иркенгә чыгу юлын гына таба алмыйлар. Рәсәй урманы—сазлыклы, баткак... Хәзер безгә бөтенебезгә дә бер якты аланга җыелырга кирәк. Кинәшләшергә кирәк, шулчакта гына, аннан чыгу юлын табып булыр. Рафис Корбаннын бөтен публицистик шигырьләре, шул максатны күз алдында тотып язылганнар. Шагыйрьнен шигырьләрен укыган кешеләр, минем белән килешерләр дип уйлыйм.

Әйе, киләчәккә өметләр бик зур, киләчәктә бәлки берләшербез дә. Ә нигә «бәлки» дип әйтәм сон әле? Чөнки халыкны берләштерү, мәҗлесләрдә сүз көрәштерү генә түгел әле ул! Халыкнын ышанычын яуларга, күнеленә үтеп керергә кирәк һәм анын, җанынын нықлы терәге булу сорала. Ә бу җинел эш түгел... Безнен татар шагыйрьләренә Ходай Тәгалә шундый көч бирсен иде.

Рафис Корбанга Ходай Тәгалә андый көчне биргән, юнәлешне үзгәртмичә алга таба барырга гына кирәк.

Инде хәзер, әйдәгез, Рафис Корбаннын туган як турында язылган шигырьләренә күчик.

Рафис Корбаннын туган як турында язылган шигырьләре күнелне сагышка күмә. Анын һәрбер шигырендә мона кадәр әйтелмәгән яна чагыштырулар очрый:

Каеннар бишек шикелле
Күренә туган якта.
Сары чыбылдык эчендә,
Көзге мон йоклап ята.

*(Уяттылар)*

Су сукмагы—салкын чишмә,
Агып килә каршыга.
Белгән юлда сусавымны—
Су бирергә ашыга.

*(Сагыну)*

Безнен якны Казан арты диләр,
Даны олы безнен якларның.
Еракларда йөри аның даны,
Даны булып йөри татарның!

*(Биектау)*

Туган як турындагы шигырьләрдән иләсләнгән җаным, яшьлек—мәхәббәт турындагы шигырьләргә килеп сыена. Кем үзенен яшьлеген, беренче мәхәббәтен сагынмый икән? Бигрәк тә нечкә күнелле кешеләр иза чигәләр—гел сусап яшиләр, гомер буена яшьлектән аерыла алмыйлар, яшьлеккә кайтып җаннарына дәва табалар. Рафис Корбан шигырьләрендәге кебек:

Яши идем туган ягымда мин,
Тыныч кына үскән тал кебек.
Талга оялаган сандугачтай,
Күнелемә урнаштың кереп.

Нурга тулы, моңга тулы хәзер
Минем өчен таннар-иртәләр.
Кешеләр дә мина карап, гүя
Сандугачлы тал дип үтәләр.

*(Гашыйк булгач)*

Сандугачлы тал—яна образ, күнелне сискәндереп җибәрә, үзеннен дә кинәт кенә шундый тал буласын килә...

Хыялда—йолдызлар чүпләп
Бирердәй кебек идем.
Күрешкәч, җылы апрель
Карыдай, җебек идем.
Һаман да шул мин—кыюсыз,
Ләкин кайбер кыюлар:
Сөю юк, дип кычкырганда,
Кабатлыйм: бар сөю, бар!

*(Мина да килде ул сөю)*

Яндырдын, көлгә калдырдын
Юк ләкин үпкә-үчем.
Бу җырым—бары рәхмәтем—
Кайчандыр мин кыюсызны,
Син шулай сөйгән өчен.

*(Үлгәнче, ахры онытмам)*

Пәйгамбәр дә үлгән. Коръән калган...
Берсен-берсе сөйгән ярларга
Килә җырлар язып калдырасы—
Изге дога итеп ятларга.

*(Мин тиеш)*

Шагыйрь үзен пәйгамбәр итеп хис итә һәм ул шулай булырга тиеш тә...

Китапнын зур өлешен сөю турындагы шигырьләр биләп тора. Рафис Корбан—моңлы шагыйрь. Анын сүзләренә язылган ике дистәдән артык җыр бар. Арада—җанны «пешерә» торганнары: «Кайларда йөрисен сөйгән яр», «Араларда озын юллар», «Мәңгелек мәхәббәт, «Калыр сөю йөрәктә». Бу җырларны яратып җырлыйлар, бу җырлар инде—халык җырлары...

Китапта берән-сәрән генә булса да тонык фикерле, җылымса гына хисле шигырьләр дә очраштыргалый, әмма алар китапның тулаем дәрәҗәсен төшерми. Чөнки, бөтен шигырьләрне дә бер үк югарылыкта, гел яхшы итеп кенә язып булмый. Кайсыларына кайта-кайта тукталасын, кабат-кабат алар өстендә эшлисен... Янабаштан йөрәк аша үткәрәсен... Әйтәсе сүзне тирәнгәрәк яшерергә дә кирәк була, чөнки тирәннән килгән фикер—тәмле бит ул!!

Рафис Корбаннын киләчәге бар—алда ул тагын да «тәмлерәк», кайнар шигырьләр язар әле. Бу анын олылар өчен язылган тәүге китабы—беренче коймагы.

Һәр шигырь китабын укып чыккач, китапны ябам да кулымны китап өстенә куеп күземне йомам. Шагыйрьнен йөрәк тибеше ишетеләме? Кайсыбер китап учымны пешерә башлый. Шул рәвешчә шагыйрьнен йөрәк тибеше күнелдәге уй-хисләремә, мон-сагышларыма барып сарыла.

Рафис Корбаннын да китабын ябып, кулымны китап өстенә куям, йөрәк тибешен тоя башлыйм. Димәк... димәк—китап бәхетле! Чөнки китап эчендә—йөрәк тибә, Шагыйрь йөрәге!

**Илгизәр СОЛТАН**

*Дин һәм тормыш*

# КОРЪӘН ТАТАР ТЕЛЕНДӘ

## 2—Бәкара (сыер) сүрәсе

**248**. Пәйгамбәрләре аларга әйтте:

—Аның *(Талутның)* хөкемдарлык галәмәте шул булыр: сезгә бер табут *(сандык)* килер, эчендә Раббыгызның тамгасы булыр вә *(сандыкта)* Муса нәселеннән, Һарун гаиләсеннән мираска калган нәрсәләр булыр. Фәрештәләргә шул эш тапшырылачак. Әлбәттә, анда сезгә катгый бер галәмәт (вә гыйбрәт) бар. Әгәр дә сез иманга килгән булсагыз.

*(«Алар сандык эчендә Мусадан калган карышкы-таяк, чалма-чапан күрделәр. Кайберләре әйтә: сандык эчендә Тәүрат китабының битләре дә була, ди. Алар Талутны хаким буларак кабул иттеләр. Талут җитмеш меңлек мөселман гаскәре белән кяферләргә каршы сугышка китә. Көн бик эссе була. Гаскәрдәгеләр Талуттан су сорый»).*

Хәсән Чантай тәфсиреннән.

**249**. Гаскәре белән Талут юлга чыкты. Ул әйтте:

—Шөбһәсез, бер инешкә тап китереп, Аллаһ сезне сынап карар. Шул ермактан берәрегез *(комсызланып)* су эчсә, минем белән баралмас. Эчмәгән кеше минем белән булыр. Бер уч кына су алып эчсә, ул да минем белән барыр,—диде.

*(Инешкә килеп җиткәч)* гаскәрнең күп кешесе туйганчы су эчте. Бик азы гына су эчмәде. Ниһаять, ул *(Талут)* үзенең мөселманнардан торган гаскәре белән ермакны кичте. Бәгъзеләре әйтте:

—Бүген Җалут гаскәренә каршы сугышырга безнең җегәребез юк,—диделәр.

Аллаһ белән һичшиксез кавышачакларын белгәннәр әйтте:

—Аллаһ ярдәме илә аз гына кеше белән дә күп санлы гаскәрне җиңгәннәр бар,—диделәр. Аллаһ чыдам кешеләр белән бергә булыр.

**250.** Алар *(Талут әмерендәгеләр)* Җалут гаскәренә каршы чыкканда әйттеләр:

—Йә, Раббыбыз, безгә түземлек бир. Аякларыбызга җегәр күндер, бу кяферләр гөруһына (өеренә) каршы сугышта безгә ярдәм ит,—диделәр.

*(Күбенгәнче су эчкәннәр сугыша алмады. Аз су эчкәннәр, су эчмәгәннәр, ягъни өч йөз дә ун кеше җегәрендә иде, алар Җалут гаскәрен тар-мар итте.)*

**251**. Шулай итеп, алар *(сугыш башланыр-башланмаста)* Аллаһ ярдәме илә аларны *(дошманнарны)* куып таратты. *(Мөэмин гаскәре белән килгән)* Даут Җалутны үтерде. Аллаһ аңа *(Даутка)* хөкемдарлык вә пәйгамбәрлек дәрәҗәсе бирде, ул өйрәнергә теләгәннәрнең бәгъзеләрен Аллаһ өйрәтте.

Әгәр дә Аллаһ кешеләрне бер-берләренә каршы сугыштан тыеп тормаса иде, Җир йөзендә, мотлакан, гел генә фетнә чыгып торыр иде. Аллаһ галәмдәгеләрнең барчасына мәрхәмәтле.

*(«Җалутны үтергәндә Даут җиде яшендә иде. Ул аны юлда килгәндә алган ташлар белән атып үтерде. Даут пәйгамбәр җиз калканнар ясый белүче тимерче, кулы эшләп тапкан керем белән генә тормыш итә иде. Аллаһ аңа кошлар телен өйрәтте. Зәбур китабын бирде. Аңа гаять гүзәл тавыш бирде. Ул җырлаганда кыргый җәнлекләр дә аның янына җыела иде. Кошлар канатларын җәеп, аның баш очында күләгә хасил итә иде. Аллаһ аңа сәясәт гыйлемен дә өйрәтте»).*

Хәсән Чантай тәфсиреннән.

**252.** Болар—Аллаһның аятьләредер. *(Ий, Мөхәммәд)* боларны сиңа хаклык белән укыйбыз. Син, әлбәттә, Безнең илчебез.

**253.** *(Бу сүрәдә зикер ителгән)* ул пәйгамбәрләрне Без бер-берсеннән өстен күрдек

---

Дәвамы. Башы журналыбызның 8 санында.

*(берсендә булган аерым сәләт икенчесендә булмас).* Аллаһ аларның берсе белән сөйләшә, икенчеләрен олуг дәрәҗәләргә күтәрә. Мәрьямнең углы Гайсәгә анлаешлы, ачык аятьләр индердек вә аны Рух-ел Котдус белән химая иттек. Әгәр Аллаһ ихтыяр итсә иде, алар артыннан килүче өммәтләр, үзләренә ачык китаплар килгәннән соң да, бер-берләрен үтермәгән булырлар иде. Ләкин алар дошманлаштылар. Нәтиҗәдә, аларның кайсысы иман китерде, кайсылары кяферлеккә китте. Аллаһ аларның бер-берләрен үтерүләрен теләмәсә, үтертмәс иде. Әмма шунысы бар, Аллаһ үз теләгәнчә гамәл кылыр.

*(«**Зикер**—хәтердә тоту, мактаулар белән, яхшы яклары белән искә алу. **Химая**—ярдәм, терәк. Аллаһ кешеләрне үз ихтыярларына куйды. Кешеләр бары тик Аллаһ кушканча гына гамәл кылмый, алар үз теләгәннәрен башкаручылар да, ләкин кешеләр үз ихтыярлары белән башкарган гамәлләре өчен җавап тотачак. **Рух-ел Котдус**—мөкатдәс рух, изге рух, Җәбраил»).*

Али Өзәк, Хәсән Чантай тәфсирләреннән.

**254.** И, иман китергән бәндәләрем, Без сезгә биргән ризыкларны Ахирәт көне килеп житкәнче үк *(Хак юлында)* сарыф итегез *(садәка бирегез, ятимнәргә булышыгыз, зәкят бирегез, хаҗ гыйбадәте кылыгыз).* Ул Көн килеп житкәч кенә алыш-биреш тә, әшнәлек тә, шәфәгать тә булмаячак. Кяферләр золым итүчеләрнен үзедер.

*(**Залим**, гаделсез кеше, әхлаксыз кеше—кяфер, дигән сүз. **Кяфер**—залим, гаделсез, әхлаксыз, дигән сүз.)*

**255.** Аллаһның үзеннән башка һичбер тәнре юк. Ул *(мәңге)* тере. Заты белән Ул һәрвакыт бар. Аны йокымсырау да, йокы да тотмый. Күкләрдәге, Җирдәге бөтен нәрсә Аныкы гына. Аллаһның рөхсәте булмаганда, беркем дә, беркемнен дә гөнаһларын ярлыкый алмый. Ул Үзе яралтканнарның алда ни күрәчәген, үткәнендә ни күргәннәренең *(кылганын, кылмаганын, кылачагын, белгәнен, белмәгәнен, яшергәнен, яшермәгәнен)* барысын да белеп тора. Кешеләр аның гыйлеменнән башка үзбелдекләре белән берни эшли алмас. Аның көрсие *(гыйлеме)* күкләрне вә Җирне үз эченә алган. Аллаһка күкләрне, Җирне саклап тору һич тә кыен түгел. Аллаһ гаять бөек, галәмәт тә олугтыр.

*(«Бу аять «Аятел Көрси» дип атала. Көрсине, гадәттә, тәхет дип тә аңлаталар. Ләкин ул без аңлаган сыйфаттагы тәхет түгел, әлбәттә. Аллаһның көрсие, Аллаһның тәхете. Ул күкләрне, Җирне үз эченә алырдай киң, олы, чиксез. Хәзрәти Мөхәммәд Пәйгамбәребез әйткән, имеш: көннәрнең иң олысы—Җомга. Сүзләрнең иң олысы—Коръән. Коръәннең иң олы сүрәсе—Бәкара. Бәкараның иң олуг аяте—Аятел Көрси булыр, дигән»).*

Хәсән Чантай тәфсиреннән.

*(«Көрси» сүзен тәрҗемәчеләр, тәфсирчеләр төрлечә яза: хөкемдарлык (Йазыр), «трон» (Порохова, Крачковский), «бушлык урыны» (Ногмани), «тәхет» (Уфа нөсхәсе). Болардан аермалы буларак, М. Али «знание» дип ала. Димәк «көрси» урындык, тәхет мәгънәсендә булса да, аның төп мәгънәсе «гыйлем, белем, акыл белән идарә итү хакимияте» икәнлеге ачыклана.)*

**256.** Диндә ирексезләү юк. *(Коръән иңгәч)* Хакыйкать белән ялган бер-берләреннән аерылды. Шайтаннан баш тартып, иман китергән кеше беркайчан да кубарып алып булмый торган тоткага *(дөреслеккә, Исламга)* ябышкан булыр. Хакыйкатән, Аллаһ барысын да ишетүче, һәрнәрсәне төгәллеге белән белеп торучы.

**257.** Аллаһ—иман китергәннәрнен ярдәмчесе. Ул аларны караңгылыктан коткарып, нурга алып чыгар. Көфер иткәннәрнең дусты исә шайтандыр. Ул нурдан аерып, кешеләрне караңгылыкка алып керер. Шайтаннар *(һәм аларга ияргән бәндәләр)*—җәһәннәм ияләре. Алар мәңгегә шунда калыр.

*(«Шайтан» сүзе урынына төп нөсхәдә дә, тәфсирләрнең күбесендә дә «Тагут» сүзе кулланылган. Тагут, Х. Караман тәфсирендәгечә, шайтан, Аллаһка тиңләштерелгән потлар, сыннар, ясалма «тәңреләр», дигән мәгънәләрне үз эченә ала.)*

**258.** *(Ий, Мөхәммәд)* Аллаһ биргән мөлкәт белән ансат кына баеган бер кешенең Ибраһим белән Раббы хакында ничек сүз куерткanын күрдеңме син? Ибраһим:

—Минем Раббым үтерер дә, терелтер дә,—дигәчтен, теге бәндә:

—Мин дә үтерә дә, терелтә дә алам,—диде. *(Бу бәндәнең исеме Нумруд падишаһ иде. Һәм ул ике адәмнең берсен үтерде. Икенчесен исән калдырды. Шуннан соң)* Ибраһим әйтте:

—Аллаһ Кояшны Көнчыгыштан чыгара. Һәйдә, син аны Көнбатыштан чыгарып кара,—дигәч, кяфер тотлыгып калды. Аллаһ гөруһларны *(залимнәрне, Илаһи хөкемнәр турында тартышырга азапланганнарны)* тугры юлга күндермәс.

**259.** Яки түбәләре ишелеп, диварлары җимерелгән бер бистә биналарының хәрабәләре яныннан узып баручыны *(Гозәерне)* күрмәдеңме? *(Ул үз алдына):*

—Аллаһ бу үле бистәне ничек итеп яңадан терелтер икән?—диде. Аллаһ аны үтерде. Йөз елдан соң терелтте.

—Син күпме вакыт монда яттың?—дип сорады. Тегесе әйтте:—Булса, бер көндер, бәлки азрактыр да,—диде Аллаһ аңа:

—Юк, син йөз ел үле килеш яттың. Менә ризыкларыңа, эчемлекләреңә бак, алар әле һаман бозылмаган. Аннан соң үзеңнең ишәгеңә кара. Инсаннарга гыйбрәт булсын дип, сине терелттек. Хәзер ишәгеңнең сөякләренә бак. Ничек итеп Без аның сөякләрен бергә җыеп, аңа ит кундырачакбыз,—диде. *(Ишәк, терелеп, әүвәлге рәвешен алды.)*

Моны күргәч, ул *(Гозәер)* әйтте:

—Мин белдем инде: шик юк, шөбһә юк, Аллаһның кодрәте бөтен нәрсәгә дә җитә икән,—диде.

*(М. Али язуынча, йөз елдан соң терелгән кеше ул—йөз елдан соң тернәкләнгән Израил халкының язмышына ишарә. Бозылмаган ризык, сөякләренә ит кунып, яңә терелгән ишәк турындагы хикәяне дә күчермә мәгънәсендә аңлау кирәк. Бу—төш һәм киналәле хикәят.)*

**260.** Ибраһим:

—Йа, Раббым, мәетләрне ничек итеп терелткәнеңне миңа да күрсәт, зинһар,—диде. *(Аллаһ аңа:)*

—Әллә Миңа ышанмыйсыңмы?—диде.

—Ышанамын,—диде Ибраһим.—Ләкин *(үз күзләрем белән күреп)* күңелемне тынычландырасым килә.

*(Аллаһ)* әйтте:

—Дүрт кош тот. Аларны үзеңә ияләштер. *(Соңыннан аларны суеп, ботларын-чатларын аерып, (һәрберсеннән) берәр кисәк алып)*, тау башына илтеп куй. *(Өеңә кайткач, кошларыңны)* чакыр. Алар синең янга очып кайтыр. Шуны белеп тор, Аллаһ—мотлак кодрәт иясе, хөкем вә хикмәт сахибедер.

*(Бөтен тәрҗемәчеләр, тәфсирчеләр дә шулай яза. Ләкин Корьән теле белгечләре арасында башкача аңлатулар да бар. Аллаһ Ибраһимга дүрт кош тотып, аларны өйрәтергә һәм дүртесен дүрт тауга илтеп куярга боера. Өйрәтелгән кошлар, Ибраһим Пәйгамбәр чакыргач, юлдан язмыйча, әйләнеп кайта.)*

**261.** Малларын Аллаһ юлында сарыф иткәннәрнең хәле, җиде башак үстереп, һәр башакта йөз бөртек орлык биргән бер данә орлыкның хәле кебектер. Ихтыяр иткән кешесенә Аллаһ кат-кат нигъмәт бирер. Аллаһ муллык иясе вә барысын да белеп торучы.

**262.** Малларын *(Аллаһ юлында)* сарыф итеп тә, биргән маллары өчен үкенеп, кешене рәнҗетмәгәннәр Аллаһның әҗеренә лаек. Аларга бернинди дә куркыныч янамас, алар өстенә кайгы килмәс.

**263.** *(Кешеләргә)* тәмле сүз әйтү вә *(аларның)* хаталарын кичерә белү рәнҗетеп, теләр-теләмәс бирелгән хәердән артыграк. Аллаһ *(колларының садакаларына)* мохтаҗ түгел, Ул бай һәм сабыр.

*(Башкаларга яхшылык эшләп, соңыннан: мин сиңа яхшылык эшләдем, дип атлаган саен бичараның исенә төшереп, битәрләп тору ул кешене савапка китерми. Андый яхшылыкны эшләмәскә генә кирәк. Андый яхшылык яманлыкка бәрабәр. Мин сиңа игелек кылдым, син дә миңа игелек кыл, дип, бугазга басу—ул ирексезләү, залимлек. Кылган игелегең турында башкаларга кычкырма. Белми калырлар, дип курыкма. Аллаһ барысын да белеп тора, лабаса. Мохтаҗ кешегә, фәкыйрьгә матди ярдәм итәргә хәлеңнән килми икән, син аны юат, аңа яхшы сүзләр сөйлә, изге теләктә бул.)*

**264.** Әй, мөэминнәр, кешеләргә күрсәтер өчен генә садака-мал бирмәгез. Аллаһка, Ахирәт көненә ышанмаган кяфер кебек, хөсетлек, рия белән, кешене рәнҗетеп садәка бирмәгез. Андый кешенең хәле, өсте туфрак белән капланган таш-кыяныкы кебек; коеп яңгыр яуганнан соң, кыя-таш шоп-шома булып кала *(таш өстендәге туфрак иген чәчсәң дә уңыш бирә алмый, аны яңгыр юып алып китә).* Андыйлар *(дөньялыкта)* кылган *(яхшы)* эшләреннең берсеннән дә *(саваn)* куәт ала алмаслар. Аллаһ кяферләр гөруһына *(өеренә)* һидаят бирмәс.

*(Хәер биргәндә: бирергәме, бирмәскәме, дип яки мохтаҗ кешенең авызына төртеп, кимсетеп бирү, игелекне юкка чыгара. Игелек ихлас күңелдән, сиздермичә генә эшләнсә—яхшы. Киресен кылганнар савап урынына гөнаһ җыяр.)*

**265.** Аллаһ ризалыгын алырга теләүчеләр вә рухларында булган иманны ныгытмак өчен, малларын сарыф иткәннәрнең хәле калкулыктагы гүзәл бакча кебектер. Бакча

өстенә янгыр яуса, ике кат уныш җыеп була. Янгыр мул яумаса да *(һич югында ул бакчада)* дым калыр. Аллаһ сезнең ни кылганнарыгызны күреп тора.

**266.** Хөрмәләр, йөземнәр шаулап үскән, чишмәләре агып торучы, җиләк-җимеш тулы бакчасы булган кеше картаеп, *(карт булса да)* бала-чагалары газиз сабый булып, утлы өермә чыгып, шул бакчаны яндырып китүен теләр идеме икән? Менә, Аллаһ сезгә аятьләрен шулай ап-ачык итеп аңлата. Ихтимал, сез уйлап багарсыз *(һәм бер нәтиҗәгә килерсез шәт).*

**267.** Әй, мөэминнәр, җыйган малларыгызның иң затлыларын гына вә сезнең өчен җирдән чыгарганнарыбыздан *(садака, хәер, зәкят биреп, Аллаһ юлында)* сарыф итегез. Күз йомып *(чыраегызны сытып, җирәнеп кенә, теләр-теләмәс кенә)* алырдай затсыз малны бүләккә бирмәгез *(үзегезгә ошамаган, гамәлгә яраксыз мал хәергә бирелмәс).* Белеп торыгыз, Аллаһ чиксез бай һәм мактауга лаек.

**268.** Шайтан сезне:

—Фәкыйрь булачаксыз,—диеп куркыта. Сезне ул фәхешлеккә чакыра *(сезне бозыклыкка, саранлыкка өнди).* Аллаһ исә сезгә үзеннән ярлыкау вә муллык вәгъдә итә. Аллаһ чиксез юмартлык иясе, барысын да тәгәл белеп торучы.

*(Кеше садака, зәкят, хәер бирергә уйласа, Иблис аны котырта башлый: үз малыңны үзең рәхәтләнеп тот, кешегә мал бирсәң, кулың китәр, фәкыйрь калырсың, ди. Кеше сафлык, игелек кылырга ниятләсә, Иблис аны харамга, фәхешлеккә өнди. Череп баеганнарның мохтаҗларга, ятимнәргә, Аллаһ йортларына-мәчетләргә сукыр тиен дә бирмәгәннәре бар. Менә шулар инде Иблис коткысыннан ычкына алмый. Сәрхүшлеккә кереп чумганнар бар. Алар һәр иртәдә чын күңелдән тәүбә итәләр: кабат эчмим, ташлыймын, дип җылый-җылый сүз бирәләр. Ләкин көн түгел, сәгать тә узмый, алар инде тагын Иблис кочагында аракы чөмерә.)*

**269.** *(Аллаһ Тәгалә)* хикмәтен теләгән кешесенә бирер. Кемгә хикмәт *(акыл, гыйлем)* бирелсә, хакыйкатән, аңа күп хәер бирелгән булыр. Сәламәт акыллы кешеләрдән башка моны бүтәннәр яхшы аңламас.

**270.** Садака малын кая куйганыгызны яки кемгә дә булса нәзер ителгән малыгызны кая сарыф иткәнегезне Аллаһ, хакыйкатән, белеп тора. Зиндикъләр өчен һичбер ярдәм булмас.

**271.** Садакаларыгызны ачык итеп бирсәгез, яхшы булыр. Садакаларыгызны фәкыйрьләргә яшертен бирсәгез, сезнең өчен тагын да хәерлерәк булыр. Шуна күрә, *(Аллаһ)* гөнаһларыгызның бер өлешен ярлыкар. Сез ни генә эшләсәгез дә, Аллаһ барысыннан да хәбәрдар.

**272.** *(Ий, Мөхәммәд)* аларны *(бәндәләрне)* һидаяткә ирештерү сиңа йөкләнми. Кемгә теләсә, Аллаһ һидаятне шунар бирә. Бирелгән хәер *(мал)* үз файдагызга булыр. Сез малларыгызны *(садакагызны)* бары тик Аллаһ ризалыгын алыр өчен генә бирәсез. Аллаһ юлында сарыф иткән малларыгыз *(садакалар, зәкят, хәер)* өчен сез артыгы белән бүләкләнәчәксез. Сез *(савап мәсьәләсендә)* хаксызга рәнҗетелмәячәксез.

**273.** *(Садака)* үзләрен Аллаһ юлына багышлаганнарга *(фәкыйрьләргә, галимнәргә)* бирелергә тиеш. Чөнки алар Җир йөзе буйлап йөри алмый. Аларның хәлен белмәгән тинтәкләр, аларның тыйнак һәм горур булганына карап, бу адәмнәрне бай диеп уйлыйлар. Син аларны (үзләренә генә хас) галәмәтләреннән танырсың. Алар *(кыен хәлдә булсалар да күзгә керә-керә)* хәер сорамый. Сезнең *(Хак юлында)* күпме мал сарыф иткәнегезне, шик юк ки, Аллаһ, хакыйкатән, белеп тора.

*(**«Фәкыйрьләр»** сүзе бары тик хәерчеләр, соранучылар төшенчәсен генә үз эченә алмый. Гыйлем эстәп, Аллаһ юлында йөрүче галимнәр мәгънәсендә дә кулланыла. Галимнәрнең мал артыннан чабарга вакыты тар, күп вакыт: галимнәрнең бар ягы җитеш, дип уйлыйлар. Ләкин алар ярдәмне үзләре сорап алмый. Акыллы бай моны үзе сизенеп, аңлап, галимнәргә ярдәм итәргә тиеш. Бу—саваплы эш.)*

**274.** Малларын иртә-кич, яшертен яки яшермичә *(Хак юлында)* сарыф иткәннәргә Аллаһ хозурында әҗерләр бар. Аларга һичбер куркыныч булмас, аларга кайгы килмәс.

**275.** Риба *(әҗәткә биреп торган акчадан-малдан арттырып алынган харам керем)* ашаганнар исә шайтан зәхмәте суккан тиләләр кебек, каберләреннән кубарлар Алар:

—Сәүдә итү дә риба кебек бит,—дигәннәре өчен шундый хәлдә калырлар.

Хәлбуки, Аллаһ алыш-бирешне хәләл итте, рибаны харам кылды. Әгәр дә кемдер Аллаһтан *(риба алмаска)* әмер килгәч, рибадан баш тартса, әмер килгәнгә кадәр алган рибасы гафу ителер, аның эше Аллаһ хөкемендә булыр. Кем кабаттан *(бу аять иңгәннән соң)* риба ала калса, андыйлар җәһәннәм әһелләре булыр һәм алар шунда мәңгегә калыр.

**(276)** Аллаһ рибаның бәрәкәтен җибәрер *(әҗәтне арттырып алган кеше, барыбер, ул
акчаның рәхәтен күрмәс)*. Садака биргән кешеләрнең малларын арттырыр. Аллаһ
*(рибаны, харамны хәләл дип таныганнарны)* кяферләрне, гөнаһкярларны сөймәс.
**277.** Мөэминнәр, игелек кылганнар, намазны дөрес укыганнар, зәкятен
биргәннәр Раббының хозурында әҗерләрен табарлар. Аларга һичбер куркыныч булмас,
аларга хәсрәт тә килмәячәк. **(278)** Иман китергән кешеләр! Мөселман икәнсез,
Аллаһның нәфрәтеннән куркыгыз, алынмаган рибаларыгызны алмагыз. **(279)** Шулай
эшләмәсәгез, Аллаһка һәм Пәйгамбәргә каршы сугыш ачкан кяферләр кебек буласыз.
Бу эшләрдән тәүбә итсәгез, малыгыз-байлыгыгыз—маягыз үзегезгә калыр. Шулай
кылсагыз, сез гаделсез булмассыз, үзегезгә дә гаделсезлек булмас. **(280)** Әгәр *(сезгә
бурычлы кеше әҗәтен кайтарырга)* кыен хәлдә калган булса, бурычын түләр өчен ана
унай вакыт бирегез. Садакага хисаплап, үзегез белеп, ул бурычны алмасагыз, сезнең
өчен тагын да хәерлерәк булыр.
**281.** Аң булыгыз! Аллаһ хозурына барачак Көн турында уйлап, куркып яшәгез.
*(Ул Көнне)* һәркемгә үзе кылганнар өчен түләү итеп, гаделлек илә таман өлеш *(җәннәт
яки җәһәннәм)* бирелер.
**282.** Һәй, иман китергәннәр! Килешенгән вакытта тәгәл кайтарылырга тиешле
бурычыгызны язып куегыз. Бу шартнамәне арагызда гаделлек белән танылган берәү
хилафсыз итеп язсын. *(Шартнамәне)* язучы Аллаһ ничек әмер иткән булса, шулай итеп
язсын, соныннан баш тартмасын. Ул язсын, бурычлы кеше әйтеп торсын. Раббысы булган
Аллаһның җәзасыннан курыксын, бирәчәк бурычын киметеп яздырмасын. Өстендә
бурычы калган кешенең акылы зәгыйфь булса яки хәлсез бичара булса, әйтеп торып
яздырта алмаса, аның гадел якын туганы бу эшне башкарсын. *(Телсез-чукрак, сакау булса,
рәсми тел белмәгән кеше булса, тоткында булса)* ир кешеләр арасыннан ике шаһит сайлап
алыгыз. Ике ир кеше табылмаса, ул чагында сез риза булырлык бер ир һәм тагын ике
хатын табыгыз. Хатыннарның берсе онытса, икенчесе бу шартнамәне хәтерендә саклар.
Чакырылган шаһитләр бу эштән баш тартмасын *(качмасын)*. Бурыч аз булса да, күп булса
да, кайтарылачак вакытын тәгәлләп язарга иренмәсеннәр. Бу—Аллаһ каршысындагы
гаделлеккә туры килә, шаһитлек зарури, шикләнерлек урын калдырмый торган эш. Мәгәр
ки, арагызда кулдан-кулга йөри торган алыш-биреш булса, Ул вакытта аны язып
тормасагыз да була. Гөнаһы булмас. Сәүдә эшендә дә шаһитләр яллагыз. *(Шартнамәне)*
язучыга да, шаһитләргә дә зарар китерелмәсен. *(Зарар салсагыз)* үзегезгә начарлык кылган
буласыз. Аллаһның нәфрәтеннән куркыгыз, Аллаһ сезне өйрәтеп тора. Аллаһ барча
нәрсәне чыны белән белеп тора.
**283.** Сез сәфәрдә булып, *(шартнамәне)* язарга кеше табалмасагыз, бурычлы
кешедән *(бурыч кыйммәтенә якын әйбер)* әманәт алып тору ярый. Бер-берегездән
шикләнсәгез, ышанычлы адәм Раббысы булган Аллаһның хөкеменнән курыксын,
әманәтен тәгәл кайтарсын. Шаһитлекне яшермәгез. Яшергән кеше, хактыр ки, гөнаһлы
булыр. Ни генә кылсагыз да, Аллаһ барысын да белеп тора.
**284.** Күкләрдә, Җирдәниләр бар—бөтенесе дә Аллаһныкы. Әгәр сез
күңелегездәгеләрне ачып салсагыз яки яшерсәгез, Аллаһ сезне яман уйларыгыз өчен
җавапка тартыр. Кемне ярлыкарга теләсә, Аллаһ шуны ярлыкар. Кемгә җәза бирергә
теләсә, шуңа җәза бирер. Аллаһның һәрнәрсәгә кодрәте җитә.
**285.** Ул пәйгамбәр дә Раббыдан үзенә төшерелгән *(Коръән)*гә иман китерде.
Мөэминнәрнең һәрберсе дә Аллаһка, аның фәрештәләренә, китапларына,
пәйгамбәрләренә инанды һәм әйттеләр:
—Аның пәйгамбәрләренә аермаенча ышандык, ишеттек *(кабул кылдык)*, итагать
иттек. Әй, Раббыбыз, ярлыкавыңны телибез. Соңгы йөрешебез синең тарафкадыр,—
диделәр.
**286.** Аллаһ беркемгә дә көче җитмәслекне йөкләмәс. *(Кеше)* игелек кылса, үз
файдасына; яманлык кылса, үзенең зарарына кылыр.
—Әй, Раббыбыз, онытсак яки ялгышсак, безне газапларга салма, *(зинһар)*. Йә,
Раббыбыз, бездән алда килеп-киткәннәргә йөкләгәнең кеби, безгә дә шундый авыр
газаплар йөкләмә. Раббыбыз, безне чыдый алмаслык хәлләргә ташлама. Гөнаһларыбызны
өстебездән ал, ярлыка безне, кичер безне, безгә рәхимле бул. Син безнең хуҗабыз,
хакимебез. Кяферләр өеренә каршы *(көрәшергә һәм җиңәргә)* безгә куәт бир!

آمين الله اكبر

*Фән*

# ЧИШМӘЛӘРДӘЙ ЧЫЛТЫРАГАН ИҖАТ

Ирексездән Ибраһим Газиның «Онытылмас еллар» романы искә килеп төшә. Һәр буынның һәм һәр шәхеснең күнел төпкелендә уелып калган үз яшәеш үзенчәлекләре, үз жуелмас хатирәләре бардыр ул.

... 1971 елның сентябрь ае. СССР Фәннәр Академиясенең Казан филиалы, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтына имтихан биреп йөргән чак. План-өметләр зурдан: аспирантурага кереп, олуг фән дөньясына аяк басу. Бәхет дигәне елмайса, галим булу, сайлаган юнәлешең буенча эзләнүләр алып бару, диссертация яклау һәм, ахыр чиктә, җиһанда эз калдырырлык китап чыгару. Инде тагын да зурдан купсак, фән дөньясында гыйльми куәтенә муафыйк урын биләү.



Тарих белгечлеге буенча («целевоен» санамаганда) ике урынга алты кеше туры килә. Конкурс шартлары артык әтәчләнергә ирек бирми, бар жегәреңне суыра, мөкатдәс эшкә «ат урынына жигелүне, сыер урынына савылуны» таләп итә. Тел белгечлеген дәгъвалаучылар да ишле генә. Коридор башы фән сәхнәсендә бәйге тотучыларның җанлы әңгәмәсеннән, фикер алышуыннан гөж килеп тора. Ләкин һәммәсенен арасында ыспайлыгы, төз-жыйнак гәүдәсе, үз дәрәжәсен үзе белүчән вәкарьлеге белән аеруча бер туташ игътибарны җәлеп итә. Күпләргә өлге булырдай затлы-камил прическа, жемелдәп торган мәгънәле күзләр, косметиканың ни икәнен дә белмәгән керфек-кашлар... Өстендә ул заманда модада булган, сорырак төстәге «строгий» лавсан костюм-юбка. Әлбәттә, чибәр. Хәтта артыгы белән. Чын авылча, шәһәр ясалмалылыгы бозмаган табигый матурлык. Ир-ат кына түгел, байтак хатын-кыз да аның артыннан кемдер яшерен, кемдер ярым яшерен күзәтеп кала. Гажәбе шул: һавалы түгел, үзен әллә кемгә куймый, тавышы азрак тоныграк, әмма төзек дикцияле, сүз каткан кешесе белән рәхәтләнеп сөйләшә. Бу бәхет минем өлешкә дә тигәли. Булачак яисә «коелып калачак» аспирантлар даирәсендә кыз ничектер бик тиз үзәк фигурага әйләнде. Белеме дә, әзерлеге дә «жилле» булып чыкты туташның. Тыйнак булса да, үтә һиммәтле, сыгылып төшә торган кешегә бер дә охшамаган. Барлык имтиханнарын да чатнатып «окей»га, ягъни «бишле»гә тапшыргач, без аның һәммәбезгә дә асыл үрнәк булачагына тәмам инандык.

Әлеге сылу кыз мәкаләбез каһарманы Фирдәүс Гарипова булып чыкты.

... 1975 елның декабре. Диссертацияләребез төгәлләнгән, инде хезмәтне яклау буенча Гыйльми советка тәкъдим итәсе генә калган. Ләкин бу «яклау» дигән гали стадиягә житү өчен әле кырыкмаса-кырык төрле мәшәкать, эреле-ваклы кәгазь шырлыгын ерып чыгасы бар. Монысы күпләр өчен тулгак газабына тиң. Бихисап өметле пишкадәмнәр шушы афәттән шомланып, фән тарантасыннан төшеп калучан («ә син меналмадың, калдың, югалдың»). Ничектер Филиал китапханәсенең уку залына керәм. Күзем алгы өстәл артында утырган таныш фигурага төшә. Әһә, Фирдәүс икән. Инде без аның белән яхшы ук таныш, хәтта дуслар да. Фәннең чуерташын бергәләп кимерәбез. Кыз һәрвакыттагыча басынкы, жыйнак, пөхтә. Бүген исә, гомумән, күз явын алырлык. Кыш һавасы килешкән, күрәсең. Житмәсә, өстенә шундый ак, күпереп торган кофта кигән ки, әкияттәге Кар кызы диярсең!

Агыйдел күбегедәй кофтасына кер кунмасын өчен беләкләренә чип-чиста җинсәләр элеп алган. Бер кулында—кайчы, икенчесендә—җилем, алдында аерым-аерым хәрефләр сугылган берничә бит кәгазь. Фирдәүсебез һәр хәрефне аерып кисеп ала да, текстның хаталы урынына микроскопик ямау сала. Бик чекрәеп карамасаң, «ямаулык» күзгә ташлан-мый да. Галимәбез, диссертацияне гадәти кара белән (башкалар кебек) бозмас өчен һәр нөсхәне менә шулай иренмичә, хәтта ки тәм табып, «имләп» утыра иде. Менә бу пөхтәлек, ичмаса! Шундый кара, котсыз эшне бәйрәмгә әйләндергән ич бу!

Ә коллегам озак та үтми, тәгәлрәге 1976 елның 9 гыйнварында, кандидатлык диссертациясен яклап та ташлады. Безнен эше яшь галимнәргә үрнәк булырдай гамәле булды инде бу Фирдәүснен.

... 1984 елның июне. Институтның бер төркем фәнни хезмәткәрләрен Спас районының А. Алиш исемендәге совхозына яфрак-азык әзерләргә җибәрделәр. Төркемдә тугыз-ун кеше, башлыклары мин. Фирдәүс тә шунда. Безгә балта, урак, пычак ише нәрсәләрне тоттырдылар да, машина белән урманга озаттылар. Арттан арбасы белән «белорусь» өстерәлә. Һава гаҗәеп саф, урманның хуш исе борыннарны ярып керә: бәлзәмдәй һава ихтыярына бирелеп үпкәләрне шәһәр тетененнән тазартабыз. Кыска җиңел аксыл блузка кигән, зәңгәрсу косынкасын ул гына булдыралганча килешле итеп бәйләгән Фирдәүс барыбыздан да уздырып эшлекле, хәтта ки бәйрәмчә кыяфәт белән эшләп йөри. Эш коралының ниндиен генә тоттырма, барысы да килешеп, мач килеп тора үзенә,—житезлегенә хәйраннар калырлык. Уңган, булган, кулында ут уйната, хәрәкәтләренә күз иярми. Хет киногә төшер. Сынын турайтып, кул сырты белән маңгай тирләрен сыпырып җибәрсә, гомумән, классик килбәткә керә. Кызганыч, кул астында фотоаппарат юк. Шунда коллегабызның тагын бер хикмәте ачыла. Бер мәлне Фирдәүс миңа болай ди: «Табигать корытабыз бит, Равил, ничек уйлыйсың, әллә берәр чара эзләп карыйбызмы? Алдагы елларда әзерләнгән яфрак та кибеп коелып беткән, быелгысының да сарык өммәтенә барып ирешүе шикле...» Нәкъ минем зиһенне бораулап йөргән уйны ярды да салды бит, ни әйтерсең. Гомуми эшкә шунда ук төзәтмә дә керттек. Инде кисеп аударылган, кабыгы мунчалага суеласы юкәләрне генә ботарлыйбыз, яшь үсентеләргә полный амнистия! Үлчәве ким чыкмасын өчен машина кузовына, трактор арбасына бүрәнәләр чөябез, өсләренә зәгъфран төсе керә башлаган ботаклар түшибез. Бүрәнәләр өйләренә кайтасы булгач, шофер, тракторчылар да киреләнми. Кыскасы, хәзер бүре дә тук, сарык та имин. Ә безнен күңелләр мәтәлчек ата. Һай бу Фирдәүсне!..

Менә шушы уңган, булган, табигать җанлы коллегабыз хәзерге көндә филология фәннәре докторы, профессор, Татарстанның атказанган фән эшлеклесе, ике дистәгә якын фәнни, фәнни-популяр китаплар, төрле шәкелләге берничә йөз мәкалә һ. б. төр хезмәтләр авторы. Фирдәүс Гарифҗан кызы Гарипова—зур галимә, җәмәгать эшлеклесе, гуманитар фәннәре үсешенә нәтиҗәле өлеш керткән һәм кертүче зат. Ләкин нинди генә үрләр яуламасын, Фирдәүс авыл кызы булып кала бирә. Инде ничә дистә ел калада гомер сөрсә дә, күңеле белән һаман авылда, аның рухын табигатькә ихлас соклану, аның язмышы өчен борчылу «сугара».

Шулай да үзеннән-үзе бер сорау килеп туа: чын галимнәргә генә хас максатчанлык, эзтабарлык, тәгәллек, пөхтәлек, эшне эш булсын дип җиренә җиткереп, бәйрәмгә әйләндереп эшләү сәләте, табигатьнең имгәтелә баруы өчен борчылу «оеткысы» Фирдәүс Гарипова күңеленә кайчан һәм ничек салынган сон?

Бу сорауга җавапны галимәнең бала чагыннан эзлибез. Гүзәл табигать кочагында үсү, агач яфракларының үзара пышылдап сөйләшүләренә колак салу, нәни агач үсентеләренен капыл буй үстереп җибәрүләренә шаһит булу, изге чишмәләр тирәсендә шикләнә-курка гына уйнаулар, кыр һәм урман нигъмәтләреннән авыз итү—боларның һәммәсе дә үзенең сихри эшен эшләгән, табигатькә булган самими соклануны үсендергән, хисләрне исә дөрләткән, ялкынландырган гына.

Ә хәтердән җуелмас мәктәп елларын искә төшерсән... Дүртенче-бишенче сыйныфларда укыганда, җәй көннәрендә укытучылар белән мари урманнарын кисеп ага торган Иллэт елгасы тирәләренә экскурсиягә барулар, бу урыннарның кабатланмас камиллеге, суларның сафлыгы, һаваның чисталыгы, агачларның күккә ашарга теләгәндәй ярышып үсүләре, урман үләннәрен купшы бизәкләргә төреп

үскән төрле чәчәкләр, үсемлекләр, күбәләкләр, бал кортлары —шушы оҗмах гүзәллеге аның күңел кылларын назлап чирткән илаһи музыкага тиң булган. География укытучысы, Зур Көек мәктәбе директоры Таһир Җамалетдиновның табигать турында, табигатьнең үз кочагында йөрәккә үткәреп сөйләүләре дә, күрәсең, уңдырышлы туфракка төшкәндер. Бала вакытта күргән, күзәнәкләргәчә сеңеп калган хатирәләр фәнни экспедиция-сәфәрләрдә йөргәндә яңарган, яңа хасиятләр белән баеган.

Әйе, үз-үзенә үтә таләпчән галимәбез вакытның чын бәһасен белеп эш итүчеләрдән булды. Башта ул (әйткәнебезчә, 1976 елның 9 гыйнварында) «Татарстан гидронимиясе (Ашыт, Казан, Мишә, Шушма елгалары бассейннары нигезендә)» дип аталган кандидатлык, ә 1991 елның 26 декабрендә—«Татарстан гидронимиясе» дигән темага докторлык диссертациясе яклый.

Әлеге гали, фәнни җәмәгатьчелектә югары бәя алган хезмәтләрне кабинет кысаларында гына язып булмый, мәсьәлә китапханә-архивларда казыну белән генә дә хәл ителми. Моның өчен бөтен җөмһүрият һәм аннан да киңрәк масштабта сәяхәткә чыгарга, дөнья гизәргә кирәк. Һәм Фирдәүс, биштәрен күтәреп, экспедицияләргә кузгала. Кар да боз да, яңгыр да аңа киртә була алмый, фәнгә, гыйлемгә сусаган күңел чигенүне белми. Ә. Ерикәйнең «Юл йөрүдән мәңге туймам мин» дигән юллары, әйтерсең лә, Гарифҗан абзый кызына атап язылган. Институтта эшләү дәверендә галимәбез, көннәр санын бергә кушсаң, тоташтан алты (!) елдан артыграк вакытын экспедицияләргә сарыф итә, җөмһүриятнең бихисап эреле-ваклы авылларын айкап чыга. Болын, кыр, алан, су буйларына үзенең эзләрен салып үтә, халыкны тынгысызлыгы, фәнни үҗәтлелеге белән «өнсез» калдыра. Авылларның өлкән буын вәкилләреннән барлык төр географик атамаларны тоташ (фронталь рәвештә) язып алуы белән ул һәм көндәлек, һәм киләчәк фәнни эше өчен бай җирлек әзерли. Үзенең гыйльми «биштәр»ен Фирдәүс авыллар оешу тарихларын, халыкның гореф-гадәтләрен, йола-кануннарын, фольклор материалларын һәм башка тел җәүһәрләрен җыеп та баета. Мәчетләр тарихын, халыкның күмәкләштерү һәм репрессия елларында күргән аяныч хәлләрен тасвирлаган, аерым шәхесләрнең язмышларын чагылдырган гыйбрәтле хәлләрне, мәгълүматларны туплый.

Фирдәүс Гарифҗан кызы үзен, беренче нәүбәттә, әзерлекле, төпле татар теле белгече итеп, ономастика фәнен (барлык төр географик берәмлекләр атамасы, кеше исемнәре, фамилияләре, кушаматлары һ. б.) елга, күл атамаларын, аларның килеп чыгышын, су чыганакларын, тирә-юнь экологиясен тирәннән актарып өйрәнүче галимә буларак танытты. Хәзерге вакытта ул Татарстан Фәннәр Академиясенең Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының баш фәнни хезмәткәре, бүлек мөдире урынбасары вазифасын башкаручы. Әмма шунысын аерым шәрехләргә кирәктер, Институтның алты дистә еллык тарихында Фирдәүс Гарифҗан кызы Гарипова хатын-кызларыбыз арасында төп белгечлек буенча докторлык диссертациясе яклап, профессор дәрәҗәсенә ирешкән бердәнбер галимә булды. Бер фәнни оешма кысалары белән генә чикләнмичә, Фирдәүс ханым 1976 елдан бирле әле тагын Казан дәүләт педагогика университетының татар филологиясе факультетында нәтиҗәле эш алып бара. Шуның өстенә Фирдәүс ханым Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының, Казан дәүләт университеты, Казан дәүләт педагогика университеты, Кабарда-Балкар дәүләт университетларының диссертация яклау буенча махсус советларының эшлекле әгъзасы да. Бер 1998 елда гына да галимә, оппонетлык кылуларны исәпкә алып, докторлык һәм кандидатлык диссертацияләренә, аларның авторефератларына егерме бәяләмә язган. Бәяләмә алган һәм оппонентлык ярдәменә «тиенгән» шәхесләр арасында татар, казакъ, үзбәк, төрекмән, украин, урыс, каракалпак, әзербайҗан, гагауз, караим, нугай, алтай, шор, якут, мари, удмурт, чуаш, мордва галимнәре бар.

Галимә фәнни докладлар белән халыкара, региональ, республика, шәһәр, институт күләмендә үткәрелгән 97 конференциядә катнашкан, гыйльми җәмәгатьчелекне тирән дәлилле чыгышлары белән куандырган. Яшь буынны тәрбия кылу кебек изге мәсьәлә дә Фирдәүс ханымның игътибар үзәгендә. Шушы максатны кыйбла итеп, ул радио һәм телевидениедән 314 тапкыр чыгыш ясаган... Ул—300 ләп фәнни һәм фәнни-популяр мәкаләләр авторы. Кыскасы, туктаусыз эш, эш, эш...

Халыкта «дүрт аякка басу» гыйбарәсе белән бәйле бер кызыклы әйтем бар. Янәсе, дүрт аякта басып тору—уныш, бәхетнең иң югары ноктасын гәүдәләндерә. Һәр нәрсәсе житеш, балда-майда йөзгән кешеләрдән ишеткәнем бар: «Юк, дүрт аякка басарга бирми...» Кем бирми, нәрсә бирми? Соң инде, Ходай Тәгалә, язмыш, тәкъдир... Бирми икән, димәк, иң шәүкәтле адәм дә дөньясы китеклектән хали түгел. Менә шулай... Фирдәүс ханымны «дүрт аякка баскан» шәхес итеп күз алдыма китерә алмыйм мин. Әмма тәгаен шунысын беләм: бер аякка калган тәкъдирдә дә (тфү! тфү! тфү!), ул берүзе ун кешелек «норманы» тутырырга сәләтле сирәк очрый торган иҗади каһарманнардан. Бер мисал китереп узыйк. Чираттагы, унбишенче китабы дөнья күргәч, мин аңа рецензия язарга алындым. Эшне озакка сузмадым, исемен «Унбишенче биеклек» дип куйдым. Бәяләмәм машинкада басылып, редакция папкасына керергә генә өлгергән иде, нәшрият «таба»сыннан коллегабызның уналтынчы китабы килеп төште. Мин дә өлгер инде, теге исемне тиз генә икенчегә алмаштырттым. Мондый өермәви темптан адәм хурына калуыңны көт тә тор!

Әйткәнебезчә, галимәнең кызыксыну-эзләнү, тикшеренү офыклары киң. Күп санлы житди хезмәтләре—иҗат муллыгының ышанычлы шаһитлары. 1984 елда Ф.Гарипованың «Татарстан гидронимнары сүзлеге»нең беренче, 1990 елда—икенче китабы һәм «Борынгы болгар шәһәрләре» дигән хезмәтләре Казанда дөнья күрде. 1991 елда Мәскәүдә «Татарстан гидронимиясе» дип аталган зур күләмле монографиясе «Наука» нәшриятында басылып чыкты һәм фәнни даирәдә унай бәя алды.

Фирдәүс ханым фәнни-нәзари эзләнүләрен гамәли эшчәнлек белән тыгыз бәглый белә. Ул болак, күл, елга-суларның табигый халәте, аларны карап һәм пакьләп, тәртиптә тоту хакында күп язды һәм язып килә. Хәзерге вакытта чишмәкизүләрне, су чыганакларын карауга игътибар арту, ихтимал, галимәнең шушы игелекле эшчәнлеге белән дә беркадәр бәйледер.

Автор төрле төр атамаларның килеп чыгышы, аларның калыплану һәм таралу жирлеге хакында да каләм тибрәтте. Күләмле хезмәтләренә нигезләнеп, байтак фәнни-популяр китаплар язды. «Инешләрдән ингән моннар бар», «Авылларны сөям жаным-тәнем белән», «Исемнәрдә—ил тарихы», «Авыллар һәм калалар тарихыннан» һ. б. исемдәге китаплар әнә шундыйлардан.

«Инешләрдән ингән моннар бар» дип исемләнгән китапта (1995) киләчәк буыннарга амәнәт булып ирешәчәк объектив тел-тарихи, географик, татар халкының рухи дөньясы, йола-кануннары, гореф-гадәтләре һ. б. турында мәгълүматлар тупланган, халык күңеленең жәрәхәтләнү сәбәпләре анализланган. Автор тасвирлап күрсәткәнчә, хәмер баткагына чуму, тоталитаризм чорында тырыш халыкның масса күләмендә читкә сөрелүе, төрлечә рәнжетүләр, сәяси, икътисади, рухи яктан изелү, типкәләнү, халкыбыз күңелен гажизләндерде. Инде бу мәсьәләләрне уртага салып сөйләшер вакытлар житте.

«Исемнәрдә—ил тарихы» дигән хезмәттә (1994) телебезнең ижтимагый үсеш тарихыбыз белән үрелеп үсеш кичерүе дәлилләнә. Әсәрдә гидронимнар бассейнлап урнаштырылган, атамаларның килеп чыгышлары, таралыш даирәләре, елгаларның кая агулары һ. б. якларына сыйфатлама бирелгән.

Ике китап булып нәшер ителгән «Татарстан микро-топонимнары сүзлеге»ндә (Казан, 1992—1993) республика авылларына хас жирле атамалар һәм гидронимнар бергә тупланган. Бирелә татар теле һәм татар халкы тарихы өчен зур әһәмияткә ия булган лексик берәмлекләр бер ноктага жыелган. Бу атамаларның кайберләре инде жуелган булуы да мөмкин. Шунлыктан бөтенләй онытылып беткәнче аларны теркәп калдыру зарур бер практик эш булып тора.

Белгәнебезчә, гидронимнар башка төр атамалар белән тыгыз, органик бәйләнеш саклый. Атамалар, гомумән, бер-берсенә нык бәгланышлы, алар берсе икенчесен тулыландыралар һәм баеталар. Фәнни жәһәттән эшкәрткәндә дә аларны бер-береннән аеру үзен һич тә акламый. Шул идеяне нигез итеп алган Фирдәүс ханым кулында тупланган материаллар жирлегендә зур күләмле «Авыллар һәм калалар тарихыннан» дигән китабын бастырып чыгарды (1997). Әлеге хезмәтендә галимәнең озак еллар дәвамында жанлы сөйләм теленнән, борынгы чыганаклардан, архивлардан жыйган материаллар бөтен бер туплама тәшкил итә. Әйе, татар авылларының тарихларын торгызу шактый кыен, чөнки ышаныч уятырдай тарихи мәгълүматлар

бик тә аз сакланган. Авыллар тарихыннан шактый хәбәрдар булган ак әбиләр һәм ак бабайлар вафат булган... Нәкъ менә шуңа күрә дә Татарстанны гына түгел, ерак төбәкләрне дә инләп чыккан, шунда кылган сәфәрләреннән рухи асылташлар белән кайткан, шулар нигезендә йөзләгән хезмәтләр ижат иткән галимәнең эшчәнлеге һәр җәһәттән хуплауга лаек. Бу китабы исә—халык хәзинәсен аның үзенә кайтару юлында кылынган игелекле галимнең бер өлеше.

1998 елда тынгы белмәс галимәнең чираттагы (575 битле) яна монографиясе дөнья күрде. «Татар гидронимиясе» дигән бу күләмле хезмәтнең яңалыгы һәм өстенлеге шунда, аның эчтәлеген татарлар яши торган барлык төбәкләрдәге халыктан язып алынган мәгълүматлар тәшкил итә. Әлеге төбәкләр хисабына Татарстан, Башкортстан, Мари иле, Чуаш һәм Удмурт республикалары, Нижгар, Пенза, Ульян, Сарытау, Волгоград, Әстерхан, Самара, Чиләбе, Ырынбур өлкәләре, Себер, Кырым яклары һ. б. керә. Китапта урын алган фактик материаллар шушы тарафлар турында язылган борынгы чыганакларга хас мәгълүматлар һәм архив материаллары белән ныгытылган. Мөһим яңалыкларның берсе буларак, авторның бу әсәрендә татар лексикасына, ягъни сүзләр җыелмасына өр-яңа лексик берәмлекләр «индерелә». Хезмәттә гидронимнар һәм топонимнарны тикшерү ысулы игътибарга лаек. Биредә һәр атаманың төрле төбәкләрдәге таралыш даирәсе барлана һәм шуннан соң гына, мәгълүматлар мөмкинлек биргән дәрәҗәдә, аның этимологиясе, ягъни килеп чыгышы турында сүз алып барыла.



*Фирдәүс Гарипованың төрле елларда басылып чыккан китаплары.*

Теоретик яктан китап татар тел белеменә һәм шул исәптән төрки телләр гыйлеменә яңача өлеш кертә. Практик яктан исә төрки һәм төрки булмаган галимнәр өчен энциклопедия, сүзлекләр төзү, монография-китаплар һ. б. язу өчен нигез булырлык әһәмияткә ия.

Егерме сигез елга сузылган хезмәттәшлегебез чорында Фирдәүс ханым белән күп аралашырга, утырдаш булырга, сөйләшергә туры килде миңа. Әлбәттә, сүз аның эшенә, үз вазифаларына мөнәсәбәте, рухи халәте тирәсендә дә аз бармады бугай. Характерының үзенчәлеге мәсьәләсен ачыклаганда аның мондыйрак «эч серләре» истә калган. Рәсми сурәттә генә дә 365 галимгә баганалы гыйлем юлына чыгарга ярдәм иткән, 23 ел буена яшь буынны олуг тормышка әйдәгән фән әһеле һәм педагогның түбәндәге сүзләренә, чыннан да, колак салмыйча мөмкин түгел.

—Беркайчан да, беркемгә дә начарлык эшләргә кулым бармады. Киресенчә, үземә яманлык кылучыларга игътибар күрсәтергә, яхшылык эшләргә тырыштым. Төп принципларымның берсе—«ни чәчсәң шуны урырсың» булды. Һәрхәлдә, шуның буенча гамәл кылырга омтылдым. Бервакытта да кешедән көнләшмәдем. Көнләшү уе хәтта башыма да килмәде. «Аныкы бар, нигә минеке юк» дигән фикер баш миемнең бер күзәнәген дә зарарлый алмады...

Профессиональ вазифалар темасына кагылган чакта Фирдәүс ханым үзенең позициясен болайрак бәян итә:

—Хезмәт урыннарында (ТӘСИ һәм КДПУ күздә тотыла) эшемне бик яратып, хуш күңел белән башкарам. Студентларны (кызлар булсынмы, егетләрме) кемнәрнеңдер газиз балалары дип укытам, һәрберсенә шәхес итеп карыйм. Фәнни бурычымны мөмкин кадәр гадел, объектив итеп үтәргә тырышам. «Үзгәртеп кору» дигән хикмәт куәт алгач та фәнни эшемнең сынар юлы да әрәмгә китмәде, бер генә хәрефе өчен дә кызарырга туры килмәде. Чөнки мин һәммә хезмәтләремне дә

бармактан суырып түгел, бәлки «кара тиргә батып», дистәләрчә экспедицияләргә йөреп, халыкның үзеннән язып алып, язылганнарны йөрәгем аша үткәреп гамәлгә ашырдым. Боларга хезмәтнең фәнни дәрәҗәсен күтәрердәй борынгы чыганаклар өстәдем, фаразларны нигезле архив материаллары белән ныгыттым, эшемнең сыйфатында шигем калмагач кына, халыкның үзенә кайтарырга җөрьәт иттем...

Сәфәрләрнең үзләре турында сүз чыккач, Фирдәүс ханым бу, бер яктан, бик зарур-игелекле, икенче яктан, үтә гыйбрәтле, мәшәкатьле гамәлнең эчке асылын чын профессиональлек белән аңлата, моңа кагылышлы башка уй-хисләре белән уртаклаша:

—Татарстан авылларын һәм татарлар яшәгән барлык төбәкләрне аркылыга-буйга гизеп чыккан кеше мин. Меңләгән кеше белән сөйләштем. Яхшысын да начарын да күп күрдем. «Бумеранг законы»ның барлыгына, ягъни үзең кылган яхшылыкның да, яманлыкның да үзеңә кире әйләнеп кайтуына мин халык арасында йөреп тәмам инандым. Экспедицияләргә йөрүнең кыенлыгына килгәндә, аны мондый юлда чыланган кеше үзе генә белә. Бозлы яңгырлар астында калулар, иртән-иртүк салкын сулы инеш-елгаларны яланаяк ерып чыгулар, ерак араларга җәяү тәпиләүләр, озынчы йөк машиналарында, җылытылмаган автобус-поездларда иза чигүләр һ. б.—берсе дә җиңел булмады. Аннан да аянычрагы шул булды: 1990 елларга чаклы күп урыннарда татар теле бик мескен хәлдә иде. Ана теленең бетәчәгенә тәмам инанучылар нык үрчегәнлектән, «юк нәрсә белән баш катырып йөрмәгез монда», дигән рәнҗетүле сүзләрне дә шактый ишетергә туры килде. Мондый мөнәсәбәтне сизгәннән соң мин, тешемне кысып дигәндәй, тагын да үҗәтләнебрәк эшли башлый идем («бетми генә торсын әле»). Шөкер, ялгыш юлдан кителмәгән... Экспедиция-сәфәрләрдән кайтканнан соң иҗат ителгән, экологиягә нисбәтле фәнни-популяр мәкаләләр үз эшләрен эшләде, дияргә була. Аларда мин инеш-елгаларны тукландыра торган чишмә-кизләүләрне карау хакында яза идем. Хәзерге көндә күп төбәкләрдә (Татарстаннан читтә татарлар утырган урыннарда да) чишмә-кизләүләр карала, матур чишмә «ызбалары» салына. Изге чишмәләргә махсус игътибар ителә. Ләкин әле каралмаганнары да бар. Бервакыт күренекле телчебез Фазыл абый Фәсиев: «Чишмәләр турында язуың бушка китмәде бит, Фирдәүс, боз кузгалды, алар карала, игелекле эш кылдың»,—дип күңелемне күтәрде...

Шушы экспедицияләр җирлегендә галимәнең фәнни багажы гына үсеп калмый, бәлки монарчы «гайре табигый» дип саналып килгән кайбер күренешләргә үзенчәлекле мөнәсәбәт туа, караш калыплана.

—Халык телендә, күңелендә, хәтерендә сакланган әйберләрне, күренешләрне кире кагарга ярамый. Бередә «булмас димә, дөнья бу» принцибына таяну үзен аклый. Әйтик, «су тоту», «бозу», «йорт иясе», «абзар иясе», «бичура» һ. б. күренешләрне мин юк дип әйтә алмыйм. Бар икәнлекләренә мисаллар күп,—ди Фирдәүс ханым.

Яшьлек елларында халык җырларын да, классик музыканы да бердәй хуш күргән, тыйб (медицина) фәненә ихлас кызыккан Фирдәүс ханым үзенең язмышыннан бер дә зарланмый, сайлаган сукмагының дөреслеген, хәтта изгелеген икърар итә. Студент елларында бик яратып әдәбиятны, тарихны, фәлсәфәне үзләштерсә дә, төп «мәхәббәте» Галиҗәнап АНА ТЕЛЕ була аның:

—Ана теле, Аллага шөкер, мине югарыга күтәрде, фәннәр докторы, профессор итте, Татарстанның атказанган фән эшлеклесе дигән мактаулы исемне бирде. Фатирлы булуым белән дә мин тулаем ана бурычлы. Квартирага «тиену» өчен миңа сигез ел буена биш урында эшләргә туры килде, чөнки унөч ел мине хезмәт хакы үтә чамалы булган кече фәнни хезмәткәр дәрәҗәсендә тоттылар. Кооператив фатирны үз акчама салдырдым. Ләкин күңелемдә берәүгә дә рәнҗү юк, әлеге дә баягы «бумеранг законы» беркем өчен дә чыгарма түгел.

Инде галимәнең фән өлкәсендәге һәм иҗтимагый юнәлештәге эшчәнлегенең күзгә аеруча ташлана торган үзенчәлекләренә орынып узарбыз. Әлешчә искәртелгәнчә, галимәбез татарлар яши торган күрше төбәкләрне, өлкәләрне Татарстан кебек үк үз итә. Шуның бер чагылышы буларак, 70 еллар уртасыннан башлап ук газета-журнал битләрендә аның «Милләттәшләребез авазы» дигән махсус сәхифәдә Татарстаннан читтә яши торган татарлар тормышын тасвирлаган язмалары даими чыгып килә. Әлбәттә, Фирдәүс Гарипованы күрше төбәк татарларының беренче чиратта теле, тормыш-көнкүреше, йола-кануннары, уй-фикерләре, узаннары, кыйблалары, мәсләкләре кызыксындыра.

Фирдәүс Гарифҗан кызы татар теле ономастикасының гидронимнары (су чыганаклары атамалары) өйрәнә торган фәненә яңа баштан нигез салды, аны фән тармагы буларак яна баскычка күтәрде, дип әйтсәк, һич тә хата булмас. Шуңа күрә галимәне атамаларны өйрәнүнең тормышыннан алып, алар барлыкка килүдә катнашкан номинация һәм мотивация принципларын, ясалыш-төзелеш калыпларын, аерым атамаларның килеп чыгышларын, кайсы-этноска, кавем-кабиләгә мөнәсәбәтле рәвештә дөнья күрүләрен, тарихи катламнарын, экологияләрен тирән яктырткан хезмәтләр авторы дип бәялибез. Фирдәүс ханым Татарстан гидронимиясен элекке СССРның төрле төбәкләрендә кайчандыр гомер сөргән яки хәзер дә яши торган төрки халыклар, шул исәптән, татарлар тарафыннан иҗат итеп калдырылган һәм шулай ук төрки булмаган халыкларга хас атамалар белән чагыштырма планда өйрәнә. Кыскасы, гидронимнар, топонимнар һәм гомуми ономастика турында фәнни җирлектә сүз алып барганда аның хезмәтләрен читләтеп үтү һич мөмкин түгел.

Фирдәүс Гарипованың иҗат һәм кызыксыну офыклары киң. Әйтик, көндәлек матбугатта анын татар телен саклап калу һәм үстерү, милли гимназияләрне күбрәк ачу, акылга зәгыйфь балалар өчен татарча мәктәпләр яки интернат-мәктәпләр булдыру, уку-укыту әсбаплары, күргәзмә материаллар чыгаруның зарурилыгын дәлилләгән язмалары еш очрый. Шулай ук өлкән буын вәкилләренә, ата-анага, тирәюньдә яшәгән кешеләргә, туганнарга карат шәфкатьле һәм миһербанлы булуның мөһимлеген күрсәткән мәкаләләре туып тора. Бу мәсләгенә тугрылык саклап, галимә милләтебезнең горурлыгы булган олуг шәхесләрне дә игътибардан читтә калдырмый. Мәсәлән, Бакый ага Урманче, Сара апа Садыйкова һәм башкаларга багышланган мәкаләләре әлеге шәхесләргә җәмәгатьчелек игътибарын тагын да киңрәк юнәлтү максатында язылган. Заманында «Социалистик Татарстан» газитәсендә аның «Сара апаны сагынам...» дигән мәкаләсе басылып чыккан иде (1989, 31 октябрь). Бу язмасында Фирдәүс Гарипова композиторга Тукай бүләге бирүнең зарурлыгын, гаделлеген беренче булып күтәреп чыкты. Җәмәгатьчелектә әлеге фикер кин яклау тапты һәм вафатыннан соң, сонга калып булса да, Сара апа бу югары һәм мактаулы премиягә лаек булды. Соңрак, тамырлары шунда барып тоташкан Тутай авылында (Апас районы) олуг композитор истәлегенә музей ачылды.

Фирдәүс ханымның бу юлдагы саваплы эшчәнлеге моның белән генә



*Фирдәүс Гарипова бер төркем кыргыз галимнәре арасында. 1992 ел.*

чикләнмәде, әлбәттә. 1999 елның 3 ноябрендә ул бер төркем артистлар, шагыйрьләр белән берлектә Сара Садыйкованың туган көненә Тутайга кайтты. Анда урта мәктәп укучылары, авыл халкы алдында чыгыш ясап, Апастагы музыка училищесына, Тутай авылында оешкан күмәк хуҗалыкка, Тутайның бер зур урамына композитор исемен бирү турында тәкъдим кертте. Шул ук елның 19 ноябрендә бу игелекле миссиянең дәвамы булды. Фирдәүс Гарипова да катнашкан артистлар, журналистлар составындагы абруйлы бер группа инде Сара апаның ире, беренче татар режиссеры Газиз Вәлитов (Айдарский)ның туган авылы Айдарга (Зеленодол районы) кайтты. Фирдәүс ханым биредә дә охшаш инициатива белән чыкты: авылдагы ике чишмәгә (чишмәгә йортлары корып) һәм шундагы ике урамга, истәлекләрен мәңгеләштерү йөзеннән, Сара Садыйкова һәм Газиз Айдарский исемнәрен бирү турында тәкъдим кертте.

Боларга өстәп тагын шуны әйтергә кирәк, фольклорчы галимнәр төзеп чыгарган унике томлык халык авыз иҗаты әсәрләрен Тукай бүләгенә тәкъдим иткәндә дә ул беренчеләрдән булып бу башлангычны хуплап чыкты (Социалистик Татарстан, 1989, 2 апрель). Кулы тагын җиңел булды: коллегалары Х. Ярми (вафатыннан соң), И. Надиров, Х. Мәхмүтов, Ф. Әхмәтова-Урманче һәм Л. Җамалетдинов Тукай бүләгенә лаек булды. Соңгы вакытларда галимә вафат булган хезмәттәшләре (М.Мөхәммәдиев, И. Абдуллин, Н. Зарипова), исәннәрдән—Н. Борһанова хакында мәкаләләр язу теләге белән яна. Иншалла, боларын да җиренә җиткерер әле.

Фирдәүс ханымның публицистик һәм фәнни-популяр язмалары, гомумән, кешегә, яшәеш тирәлегенә, тарихи планда алсак, борынгы бабаларыбызга, аларның гамәлләренә ихтирам вә мәхәббәт белән сугарылган. Гаҗәп түгел, аның бу тармакка караган хезмәтләре дә тирән мәгънәгә ия. «Борынгы болгар шәһәрләре» дип аталган китабы (1990) шушы юнәлештәге хезмәтләрнең асыл бер үрнәге. Фирдәүс Гарипова Болгар, Биләр, Шәмсуар, Кирмән, Тубылгытау, Җүкәтау, Ашлы, Тәтеш һ. б. шәһәрләрне топонимист-галим күзлегеннән карап сыйфатлый. Шунысы игътибарга лаек, бу күбесенчә онытылган тарихи исемнәрне ул яңа төзелгән шәһәр, бистә, авыл һәм башка яшәү урыннарына яңадан кайтару кирәклеге мәсьәләсен күтәрә, моның зарурлыгын фәнни яктан дәлилли.

Җыеп әйткәндә, Фирдәүс Гарифҗан кызы—киң колачлы галимә һәм туган халыкның язмышын үз язмышы белән тыгыз бәйләгән милләтпәрвәр зат. Аның эзләнүләре, табышлары, иҗат җимешләре фәнгә, тормышның практик һәм тәрбияви ягына көчле шытымнарын җибәрде инде. Хәзмәтләре төрле даирәләрдә киң файдаланыла һәм авторына торган саен зуррак шөһрәт китерә. Күрәсең, халык язучысы Гомәр ага Бәширов 1994 елда аңа: «Язган хезмәтләрегез нигезле һәм төпле, ышандыра торган, проблемаларны төбенә төшеп, чыганаклар ярдәмендә хәл итәсез»,—дип тикмәгә генә әйтмәгәндер. «Җидегән чишмә», «Туган ягым—яшел бишек» кебек җәүһәрләрне иҗат иткән олпат әдип бу мәсьәләдә үтә сизгер, таләпчән кеше иде...

Әйе, Фирдәүс Гарипова—табигатькә сабыйларча гашыйк һәм шушы гыйшкы аны гүяки катлаулы вә сикәлтәле тормыш юлыннан житәкләп алып бара. Шушы хиссияте анар кыен мизгелләрендә терәк булган, эреле-ваклы афәтләрдән, абынулардан саклаган. Ә табигать үзе?! Үзен сөюче затка ул ничек җавап биргән яисә бирә соң? Табигатьне битараф, аның өчен хаклылар да, хаксызлар да юк, диләр... Булмас, моңа күңел ышанмый. Табигать иманлы, пакь күңелле затка битараф түгел, ул бөтен гүзәллеген һәм бөек мәгънәсен үзен ихластан сөйгән кешегә генә ача.

Дөбъяз ягы кызы әнә шундый бәхтияр затларның берсе.

Чыннан да, Фирдүс ханымның иң житди хезмәтләрендә дә көмеш чишмәләр челтерәве, талгын җилдә яфракларның лепердәшеп, үзара серләшүе, күзгә күренмәс тургай җыры ишетелә һәм шушы аһәң, моң, эчкәреге музыка, укучының зыялылык дәрәҗәсе нинди булуга карамастан, аның күңел төпкеленә үтеп керә, сүз белән аңлатып булмаганны рух белән төшендереп бирә сыман.

Хәзерге көндә Фирдәүс Гарипова фәнни һәм фәнни-педагогик эшчәнлегенең иң челлә ноктасында. Исеменә муафыйк рәвештә (Фирдәүс—фарсыча «бакча», «оҗмах», «җәннәт» дигәнне аңлата), галимәбезнең җәннәт бөстанында яңа фәнни шытымнар тамыр җибәрсен, гыйльми идеяләр бөреләнсен, газиз халкына хезмәт итү белән сугарылган игелекле иҗаты шау чәчәк атсын иде.

**Равил ӘМИРХАН,**
*тарих фәннәре докторы.*

# TARİXİ XƏTEREBEZ İLÇESE

Süzem zamandaşım, adaşım, Tatarstan respublikasınıņ Ministrlar kabineti qarşındağı Baş arxiv idarəse naçal'nigı Damir Rəüf ulı Şərəfetdinov turında.

Baqsaņ, səbəbe də bar. Baş arxivçıbızğa 60 yəş tula. Əmma bəten tabiğəte belən yəş əle ul. Qızu-qızu atlap yaq-yaqqa awa-awa baruları da yəş waqıtında keləmgə kerəşkə çığuların xəterlətə. Bəten qolaçına qulların bolğap səyləşkəndə ul qanatların qağınıp oçarğa torğan laçınğa oxşap quya. Küzlərе də laçınnıqıday ütken, oçqınlanıp, ut çəçep tora. Tik alarda eçke ber moņ, sağış toyımlana. Nərsəgəder yərəge sızlana buğay. Künelenen iņ türendə cərəxət bulıp qalğan açısı-təçese tulı yıllar eze maņğayında tirən buraznalar bulıp tışqa bərep çıqqan.

İnde şaqtıy yuqarğan çal çəçlərе qoyıla barıp, anıņ maņğayın kiņəytə təşep, bəten yəzenə aqıl iəse qiəfəten birgən. Şulay da yegetlərçə kileş-kilbəte belən ul—haman da berençe kürgəndəge Damir Şərəfetdinov.

Min anı küptənnən, altmışınçı yıllar axırında «Sotsialistik Tatarstan» gəzitendə eşləgən çağınnan beləm. Annan soņ ul partiənen əlkə komitetında instruktor bulıp eşləde. Sarman rayonındağı kul'tura-ağartu, arxiv eşlərе eçen də ul cavaplı ide. Min, partiənen rayon komitetında propaganda həm agitatsiə bülege mədire bularaq, anıņ belən gel aralaşıp eşlədem. Ul çaqlarda awıllarda, kolxoz həm sovxozlarda sovet yolaların tormışqa kertü belən mawığular keçle ide. Qayda yaņa tuğan balağa klubqa cıyılıp isem quşalar, qayda qışqı saban tuye uzdıralar, qayda mexanizatorlar, terlekçelər kennəren ütkərələr, qayda ucım saqlanışın tikşerep bəyrəm itələr, qayda yaņa çəçelgən bərteklərnen tişeleşen sanap küņel açalar, qayda kolxoz, sovxoz yubileyları şawlap uza...



*Damir Şərəfetdinov həm Tərkiə dəwlət arxivının general' direktorı İsa Uzkul. İstanbul, 1998 yıl.*

Damir alar belən qızıqsına, soraşa, kiņəşlər birə, yış qına borçıluın belderə. Borçıluı tabiği, aņlaşıla: bez yola dip uzdırğan «bəyrəme-bez»neņ kübese uylap qına çığarılğan bəyrəmnər, alarğa xalıqçan asıl citmi. Şuņa, kübese tamır da cibərə almadılar. Ə tamırsız ber genə ağaç ta, ber genə üsemlek tə üsmi. Bolın-alannarda bəyrəm uzdırğanda küləgə yasaw eçen kisep alıp «utırtılğan» ağaçlar qorığan kebek, awıllardağı yəzləgən bəyrəmnərnen də kübese üseş almadı.

Ə bəyrəmnər belən Damir Şərəfetdinov çınlap qızıqsındı. Ul alarnı gəmere buyına əyrənde, «Tatarstanda xalıq bəyrəmnərenen barlıqqa kilüe

həm üseşe tarixı» buyınça kandidatlıq dissertatsiəse yaqladı. Dimək, rayonnardağı bəyrəmnərne, kiçələrne, Saban tuyların uzdırularnı citəkləwe buşqa kitməgən. Ə bit əle ul armıy-talmıy milli sportnı da propagandaladı. Telənçe Tamaqta yəşəwçe, ataqlı tatarça kərəş batırı Zəfər Xanov kebeklərnen warisların buldıruğa əhəmiət birde. Əmma anın bu xezməten kürep tə kürməmeşkə salındılar disəm, xata bulmastır. Anın tatar xalqının keləmdəge kərəşen yaqlawın millətçelekne yaqlaw dip bəyələrgə omtıluçılar da bulmadı tügel. Şunlıqtan, tatar kərəşe batırları turındağı kitapları da nəşriat kiştələrendə qunaqlar qaldı, men məşəqətlər belən basılıp çıqqanı da millətçelekne alğa sərgən kitap bularaq tamğalandı. Nişlisen, ul çaqta mondıy xəllərgə teşenne qısıp tüzərgə genə qala ide. Şuna da qaramastan, ul bilen birməde, üzen aqlap süz quyırtıp yərmәde, ə tora-bara üze cinüçe bulıp çıqtı. Ul tuplağan xəzinə əle xəzer də respublikada sportnın milli həm xalıq tərlәre üseşenə xezmət itə. Tatarça-başqortça kərəş buyınça ul təzegən əsbaplar haman da aktual'legen saqlıy.

Turıdan-turı Damir Şərəfetdinov qatnaşı belən monnan 40 yıllar elek «Sotsialistik Tatarstan» gəzitenen Musa Cəlil isemendəge zur prizına oyıştırılğan sport yarışlarının bəten respublikada tatarça kərəşne üsterügə yərdəm itüen əytergə kirək.

Oluğ bəyrəmebez bulğan Saban tuyın fənni əyrənep, anın yıraq ğasırlardan kilgən abruy-dərəcəsen xəzergəçə təfsilləp, bu bəyrəmnen tatarlar belən aralaşıp yəşəgən başqa millətlərgə də tatulıq, berdəmlek həm ictimağı totrıqlılıqnı saqlap yəşərgə, buınnar arasındağı dəwamçılıqnı tə'min itərgə yərdəm itüen kürsətüne də Damir Şərəfetdinov iseme belən xaqlı bəylibez.

Saban tuyların ozaq yıllar əyrənde ul. Xətta 1988 yılda «Saban tuyı— xezmət bəyrəme» digən kitap ta çığarğan ide. Bu kitap əstendə eşləwen ul haman dəwam itte. Monnan ber-ike yıl elek Saban tuyı turında bik sallı yana kitap çığardı həm ul İkençe Bətendənya tatar kongressında qatnaşuçılarğa da taratıldı.

Rəsəy Prezidentı apparatı həm xəkümət tarafınnan nəşer itelə torğan dərəcəle «Родина» jurnalında da anın milli bəyrəmebez Saban tuyı turında oçerkı basılıp çıqtı.

1993 yıldan Damir Şərəfetdinov Respublika arxivında eşli. Baş arxivçıbız ul bula inde. Arxiv digəç tə, iskelek anqıp torğan bülmələrdə tuzan belən qaplanğan, sarğayıp betkən kəğəzlər belən tulı tartmalarnı yəki şkaflarnı, əyem-əyem papkalarnı küz aldına kiterergə yaramıydır. Tatarstan arxivının təp binası bik tə zamança. Dəres, elek anın işeklәre küplər əçen yabıq buldı, küp kenə dokumentlarğa qağılırğa yaramadı. Şuna kürə əle də anda bixisap açılmağan serlər yata.

Damir Şərəfetdinov arxiv eşenə baş-ayağı belən çumdı. Əytersen, ul ğəmere buyı şuşı arxivqa yul yarğan, əytersen, arxiv anı əzelep kətep torğan.

Əye, alar ber-bersen tabıştılar.

Min Qazanğa yul təşkəndə arxivqa da yomış belən kerep çığam. Millət yazmışına, xalıq ullarının tormışına bəyle ütə yəşeren bulğan dokumentlarğa «küz salırğa» rəxsət birelə başlağan yıllar ide bu. Şuna kürə idənnən tüşəmgəçə tərle dokumentlar şıplap tutırılğan timer stellajlardan bik kirəkleləren tabıp ta birgənnəre bar. Eskerttən enəne tabıp bulmıy dilər. Bula ul! Əgər də enə eskert eçendə ikən, anı tabıp bula, monın əçen enənen də salamnan bulmawı ğına kirək.

Damir Şərəfetdinov xalqıbıznın ğorurlığı bulğan ulları, qızları turında

dokumentlar papkaların üze də əyrənə başlıy. Xalqı, ile turında uylap, canın fida qılgan millətpərwərlərebeznen isemnəren xalıqqa qaytaru buyınça tırışlıq quya.

Tatarnın faciğale yazmışqa duçar bulgan bəyek ulı Mirsəyet Xəydərgəli ulı Soltanğəlievne arabızğa qaytaruda ul in gayərlərebeznen berse buldı. Mirsəyet Soltanğəlievne ul Stalinnın bəyek derjavaçıl şovinistik səyəsəten faş itüçe in asıl zat bularaq bəyələde, anın turında əle kitaplar yazılırğa, əsərləre tuplanıp basılırğa həm, şulay itep, anın arabızğa qaytaçağına ışanuçılarnın in əüwəlgelərennən berse ide. Ul xalqıbıznın bik küp qaharman ulların şəxes kul'tı çorında suğılgan qara məherdən arındırdı. Ber ük waqıtta Tatarstan arxivına tatar xalqının tarixına qağılışlı dokumentlarnı tuplaw buyınça da eş cəyelderelde.

Məglüm bulgança, tatar xalqı üz dəwlətçelegen yugaltu belən bergə üzenen faciğale yazmışına bəyle arxiv dokumentlarınnan da məxrüm itelə. Ni qızganıç, Bolgar dəwləte, Qazan xanlıgı çorına qaragan arxiv dokumentları da üzebezdə saqlanmağan. Doşmannar ul çor xəteren onıttırırğa uylağannardır. Ə bit arxiv ul dəwerlərdə də bulgan. Əytik, Bolgar xərabələre arasında əleşçə saqlangan «Qara palata», minemçə, nəq arxiv binası bulgandır. Bu fiker belən Damir Şərəfetdinov ta kileşə. Ni disək tə, bu binanın arxitektura yagınnan qorılışı qayber şəreq illərendəge arxiv binaların xəterlətə. Dəwlət kəgəzləren, başqa məmləkətlər belən xatlar alışıp toru xaqındagı məglümatlarnı həm kitaplarnı saqlarğa qalın stenalı bu binadan da qulay urın yuq. Anın urını da şəhər üzəgendə, məydan eçendə, yəgni abruylı urında bulgan. Nişlisen, bətenese cimerelgən, yandırılgan, dokumentlar isə hiç tə bulmağanday yuqqa çıqqannar.

Şulay da dənyanın bik küp illərendə bezgə ütə də kirəkle dokumentlarnın saqlanıp qaluına ul ışanıp yəşi. Aziə, Afrika illərendə, bigrək tə Ğiraqta, İranda, Misırda, Süriədə, Tərkiədə babala-rıbıznın xalıqara elemtələ-ren isbatlawçı dokumentlar saqlanuı ixtimal, di ul. Məmlüklər Misırı belən Altın Urda arasında bulgan mənəsəbətlər, Misır-Qahirə-Bolğar-Saray-Qazan arasında diplomatik ilçelər belən aralaşu ezləren saqlağan dokumentlarnı tabu niətennən Damir Şərəfetdinov arxivlarnın xalıqara konferensiələrendə qatnaşa, tatar xalqının tarixi mədəni mirasına bəyle dokument-larnın küçermələren qaytaru buyınça maxsus mərəcəgətlər belən çığa, alarnı üzara faydalı xezməttəşlekkə çaqıra.



*Damir Şərəfetdinov run yazulı borıngı taş yanında. Şvetsiə, 1998 yıl.*

Ul Tərkiə arxivları İdarəse general' direktorı İsa Uzkul, Şvetsiə milli arxivının general' direktorı Erik Norberg həm başqalar belən dustanə

mənəsəbəttə.

Pol'şa, Əzərbəycan, Qazaqtan, Ukraina, Başqortstan, Amerika, Gollandiə, Avstriə arxivları belən xezməttəşlek urnaştırui da, təcribə urtaqlaşui da cinel genə bulmaǵandır. Hərxəldə, arxiv anıņ stixiəse diərgə də bula. 1996 yılnıņ iyün ayında Respublikanıņ Dəwlət Sovetında qabul itelgən «Tatarstan Respublikasınıņ arxiv fondı həm arxivları turında qanun»nı eşləwdə qatnaşa. Ministrlar kabinetı qarawına arxiv eşləre, respublikada arxiv xezməten taǵın da üsterü buyınça distələgən qarar proyektların ul xəzerləp kertə.

1995 yıldan anıņ citəkçelegendə tarixi-dokumental' «Ǵasırlar awazı»—«Эхо веков» digən jurnal çıǵıp kilə. Bu jurnalnı prezidentıbız Mintimer Şəymiev Kiçüçat awılında məşhür ǵalimebez Rizaetdin Fəxretdin ulına muzey açılu tantanasında bik cılı iskə aldı həm aņa xalqıbız tarixın torǵızuda zur əmetlər baǵlawın əytte. Ul bu fikeren soņraq, Qazanda jurnalistlar belən oçraşuında da qabatladı.

Yazmam geroyınıņ yegeremeləp fənni, publisistik kitaplar, cıyıntıqlar avtorı ikənlegen də əytü bik urınlıdır. Ul Tatarstan tarixı buyınça moņarçı bilgele bulmaǵan 400 dən artıq dokumentnı tabuda həm qaytaruda aktiv qatnaşqan keşe. Əytik, Tərkiədən genə də XII-XVII ǵasırlarga qaraǵan yəzgə yaqın qəber taşlarınıņ yazuları, Bolǵar məçetləre rəsemnəre, yarlıq, şartnamə, kileşü həm xatlarnıņ küçermələre Tatarstanǵa qaytarıla.

Şvetsiə milli arxivınnan da şaqtıy küçermələr Tatarstan arxivına alına. Əlbəttə, bolarnı eşləw məmkinlege Dəwlət arxivıbız UNESKOnıņ xalıqara arxivlar Sovetına qabul itelgəç tua. Şulay şul inde: bakça yasamıy, alma bulmıy. Yuqqa ǵına Tatarstan Baş Arxiv İdarəse internet sistemasına kertelməgənder. Əle bit Damir əfənde, arxivçı bularaq, «Tatar ensiklopediəse», «Xəter» kitabı redaksiələrenen kollegiə sostavında da daimi eş alıp bara. Tatarstan Respublikasınıņ tarix həm mədəniət xezmətkəre, «Maqtawlı arxivçı» isemen yərtüçe zamandaşım xaqında əytergə teləgənem menə şular. Moņa əstəp anıņ Gumanitar fənnər Akademiəsenen «Şərəfle əǵzası», yəǵni akademigı ikənlegen də əytü kirəkter. 2000 yılǵa çıqqaç ul Tatarstan Yazuçılar berlegenə qabul itelde...

Tatarstanda arxiv xezməte kamilləşə bara. Bu kiləçək əçen iņ məhime. Çənki illər, xalıqlar onıtqannı arxiv iskə təşerəçək, «arxivtaǵı—tarixtaǵı» dip tiktomalǵa əytelməgən. Arxivnıņ küze borıņǵını, ütkənne kürə.

Bügenge zamannı da tora-bara tarixçılar, səyəsətçelər, ədəbiatçılar ber təsle genə bəyələməyəçək. Xəzerge bolǵawır çornı yaņa buınnar əyrənəçək. Şuņa da arxivlarda tarixi xəterebez saqlanırǵa tieş. Kiləçək əçen bəten arxivlar tuplaǵan hər kəǵəz XX yəz axırınıņ dokumental' şahədətnamələre bulıp xezmət itərlər, şulardan başqa cəmǵiət qaya barǵanın belə almas.

Ütkəne barnıņ kiləçəge bar, dip əytkən borıņǵılar. Süz, əlbəttə, yaqtı kiləçək, bəxetle kiləçək xaqında bara. Menə ni əçen «Ütkəne barnıņ arxivı da bulırǵa tieş»,—di baş arxivçıbız Damir Şərəfetdinov həm üze belən bergə eşləwçe distələgən keşelərnen isemnəren ohlap iskə ala.

Arxivnı tarixi xəterebez didek. Şul tarixi xəterebeznen tulı vəkalətle ilçesenə 60 yəş tulu uņayınnan aņa taǵın da uņışlar, nıqlı sələmətlek, ǵailə bəxete telik. Arxiv kügebeznen yaqtı yoldızın sələmləwebez, ohlawıbız şul bulsın.

**Damir ǴARİFULLİN**

Китап күзәтү

# БӨЕК ТӨРКИЛЕКТӘ БЕЗ ОЛУГ

Әдәбиятыбызның чыганагы—чишмә башын каян, кайсы гасырдан исәпләргә? Бу сорау риторик һәм бик гади тоелса да, заманында байтак акыл ияләрен моназара мәйданында «кылыч уйнатырга», саташырга һәм саташтырырга, хәтта ки баш шәрифләреннән дә мәхрүм калырга мәҗбүр иткән идеологик мәсьәлә. Без, гадәттә, татар әдәбиятының мең еллык тарихы бар дип сөйлибез. Ә ни өчен мең? Күрәсең, Болгарда ислам динен кабул итү дә бер дәлил булып торадыр. Ә бит дин кадәр дин кабул иткәнче илдә язма мәдәни җирлек булмаганмы? Ә V-VII гасырлардан килгән Урхун-Енисей язмаларын, Күлтәгин ташларындагы шигъри язуларны кая куясың?




Тарихыбызны шактый бутаганнар. «Гел бер телдә язылган тарих—әнкәсенең унган кызы» дигәндәй, үткәнне безгә ничә гасырлар буе нигездә бер телдә: урыс руханиларының летописьлары (елъязмалары) буенча өйрәтеп килделәр. Аларда, әлбәттә, бүтән халыкларның, әйтик төркиләрнең, бигрәк тә, татарларның тарихы ерак томан эченә яшерелде. Тирәндәге тамырларны кисү, оныттыру төп сәяси факторларның берсенә әйләнде. Татар тарихын Болгар тарихына гына кайтарып калдыру әнә шул сәясәтнең бер нәтиҗәсе булды. 1944 елдагы мәгълүм карар татар шәҗәрәсен, нигездә, Идел буе төбәгенә генә бәйләп аңлату өчен кирәк иде. Өстәвенә, бернichә имля алыштыру да халык хәтерен яхшы ук томалап куйды. Хәтта шундый абсурдка барып җителде, кайбер мөтәгалимнәр, мөтәҗитәкчеләр татар язма әдәбиятын Октябрь инкыйлабы белән бәйләп, башлангычын шуннан эзли башладылар. Уйласаң—уйланырлык. Дөнья—куласа, XX гасыр ахырында дөнья галимнәре Казан шәһәренең кимендә мең еллык тарихы барлыгын исбатлыйлар. Шәһәр кадәр шәһәре булган халыкның үзенчә дәүләте, язмасы, әдәбияты булмаганмы?

Тагын шунсы да бар: ерак гасырлардан берән-сәрән сакланып калган язма үрнәкләрне дә, шактый ук шартлы бүленгән социаль-иҗтимагый дәверләргә яраклаштырып, аларга сәяси-сыйнфый төсмер биреп, тарихыбызның аерым чорларын бер-беренә каршы куеп, һәркайсын күпмедер дәрәҗәдә аерымланган итеп күреп өйрәнеп килгәнбез. Дөресрәге, ихтыяри яки ихтыярсыз, мәҗбүр ителгәнбез. Галим Ш. Абилов сүзләре белән килешми мөмкин түгел. «... ул вакытта мең елдан да артык вакыт эчендә дәвам итеп, колач җәеп, тоташ бер тәсбих тасмасы рәвешендә сузылып

[1]**Ул дәрья да бу дәрья:** Борынгы әдәбият. - Казан: Мәгариф, 1999. - 343 бит. Төзүче-редактор—Л. Шәрифуллина.

үсә барган әдәбиятыбызның бербөтен чылбырын танымаска дучар ителәчәкбез. Бу— урта гасырларны эченә алган татарның бербөтен әдәбиятының үзәген тәшкил иткән Алтын Урда дәверендәге ядкарьләрен кисәкләргә аерып, төбәкләргә бүлгәләү, аның дөнья классикасы рәтендә торган әсәрләреннән колак кагу булыр иде.»

Ни кызганыч, халык, интеллигенция, хәтта без, язучылар, үз әдәбиятыбыз тарихын белмибез. Без, асылда, үтеп баручы егерменче гасыр әдәбиятының символы Тукайны беләбез.

Татар әдәбиятының фәлән гасырлык тарихы дигәндә, шиксез, бәхәсләшерлек нәрсәләр дә юк түгел. Менәр еллык үлчәмнәргә китсән, әлбәттә, уртак төрки тамырларга кайтып төшәсен. Шулай булуы табигый да. Бер уйласаң, нәрсә ул мең ел! Тарихның бер тирән сулыш алуы гына. Әйтик, сиңа 50 яшь, ди. Димәк, мең еллык тарих—нибары егерме тапкыр илле. Гомумән, төркиләр—карт халык, карт милләт, карт ыру. Тарихы да озын. Димәк, безнең тарих та шулай. Сүз сәнгате тарихы да шуңа тоташа. Бик ераккарак карап уйлансак, ерак шумерларга, бик-бик ерак Океан арты континентларына барып житеп эридер әле ул...

Татар әдәбиятын системалы өйрәнү һәм аны халыкка житкерү ыргымнары булмады түгел, булды, дөресрәге булган. Үткән гасырда Мәрҗанинең олуг хезмәтләре шуңа дәлил. 20 нче елларда гыйлем дөньясында бер күтәрелеш—татар тарихын фәнни өйрәнү чоры булып алды. Сугыш алдыннан (чын тарих урынына, фольклор чыганакларын—эпосларны идеаллаштыру төп принцип итеп куелса да) кайбер дастаннар чыгып калды. 60 нчы еллар башында янә беркадәр жанлылык сизелде. Миңа калса, илле-алтмыш ел эчендә әдәби мирасыбызны житкерүдә төп хезмәтләр: «Идегәй» дастаны чыгу (берничә мәртәбә, шулай ук әдәби әсәрләр рәвешендә дә), Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф», Сәйф Сараи, Мөхәммәдьяр әсәрләре басылу, соңрак чорның бөек шагыйрьләре Утыз Имәни, Кандалыйларның томлыклары дөнья күрү... Эшләнмәгән үк түгел, беркадәр эшләнгән, әмма аз.

Мәгълүм булганча, «Мәгариф» нәшрияты «Хәзинә» дигән гомуми исем белән татар әдәбиятының иң яхшы әсәрләрен туплаган унбиш китаптан торачак сериядән томлыклар чыгара башлады. «Сүз эчендә хикмәт бар» дип аталган беренче томлык моннан ике ел элек дөнья күргән иде инде. Олуг әдибебез Әмирхан ага Еникинең кереш сүзе белән (бу хезмәт аның соңгы язмаларыннан берсе булды бугай) ачылган ул томда халык ижаты жәүһәрләре—экиятләр, мифлар, дастаннар, мәкаль-табышмаклар, әйтемнәр, мәзәк һәм мәзәкчәләр, бәет-мөнәжәтләр, жырлар бирелгән иде.

Менә, шөкер, бу сериянең икенче китабы да безнең кулларыбызда. Полиграфик яктан югары кимәлдә эшләнгән бу томлык дүрт бүлектән тора. «Тузга язганны ташка уйган» исемле беренчесендә Күлтегин истәлегенә куелган таштагы Кече Язма һәм Мәхмүд Кашгарыйның «Диване лөгатет-төрек» (төрки телләр сүзлеге) тәкъдим ителсә, «Коръән нигезенә корылган әсәрләр» дигән икенче бүлеге Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф»ы, Хисам Кятибнең «Жөмжөмә дастаны», Мәхмүд бине Галинең «Нәһжел-фәрадис»е, Мәүлә Колый «Хикмәтләр»е, Кол Шәриф һәм Мөхәммәдьяр шигырьләре, поэмаларыннан гыйбарәт. «Легендага нигезләнгән әсәрләр»дә исә (III бүлек) Котбның «Хөсрәү-Ширин хикәяте», Сәйф Сараиның «Гөлестан бит-төрки», «Сөһәйл вә Гөлдерсен», Сайадиның «Таһир-Зөһрә» (Бабахан дастаны), дүртенче бүлектәге «Тормыш вакыйгалары сурәтләнгән әсәрләр» тулысынча «Идегәй» дастанын эченә ала. Кызыксынган кеше өчен никадәр хикмәт, никадәр байлык!

Язучы-галим А. Яхин тарафыннан һәр бүлек алдыннан бирелгән аңлатма-аннотация характерындагы кереш сүзләр дә тирән мәгънәле һәм урынлы. Ул теге яки бу чордагы әдәби үрнәкләр аша шул заманнарның рухын, яшәеш эволюциясенең характерлы якларын ачарга тырышкан. Һәрхәлдә үз халкының тарихын зур итеп күрергә теләп, яратып язган. Әлеге кыска эссе-мәкаләләрнең тирән мәгънәсе исемнәреннән үк күренеп тора: «Осталык, батырлык, акыл», «Татулык», «Мәхәббәт һәм хикмәт», «Горурлык».

Ахыргы сүз шул: «Хәзинә» сериясендә чыга торган бу китап—ифрат та кирәк басма. Әсәрләрнең бүгенге укучы өчен аңлаешлы бирелүе дә максатка бик тә ярашлы. Тарихта эз калдырган әдәби ядкарьләрне укып, гыйбрәт алып, бәлки, безнең халык та беркадәр «тураеп куяр», милли үзаңы үсәр.

**Равил ФӘЙЗУЛЛИН**

*Фән*

# МИРАС БӨРТЕКЛӘП ҖЫЕЛА

*«Әй, Ырынбур кала, сахра-дала,*
*Куккә тиеп тора манара...»*

Мәгълүм жырчы башкаруындагы үзәк өзгеч моңлы бу жыр «уазик» тәрәзәләреннән тышка бәреп чыгып, жәйге челләдә әлсерәп яткан сөзәк таулар арасына китеп тарала. Машинабыз бер тау төшеп, бер күтәрелеп, эреле-ваклы ерганак, чишмәләр кичеп алга ыргыла. Әнә теге борылышта тагын бер авыл күренә!.. Мәчетле авыл, димәк безнеке, ягъни татар авылы. Без әнә шулай, авылдан—авылга, каладан—калага күчеп дигәндәй, Оренбург якларында ил гизәбез. «Без» дигәнебез Казан дәүләт университетының татар факультетында белем алучы тарихчы студентлар һәм республикабыз Милли китапханәсенең Сирәк китаплар һәм кулъязмалар бүлеге хезмәткәрләре. Максатыбыз—халкыбызның язма мирасын жыю, саклап калу, өйрәнү.

Казан дәүләт университетының күп еллар дәвам итеп килгән традицион археографик экспедициясе 1992 елдан алып Татарстан Милли китапханәсе белән бергә оештырыла башлады. Күмәк экспедиция соңгы сигез ел эчендә Түбән Новгород, Пенза, Самара өлкәләрендә, Башкортстанның милләттәшләребез яши торган төбәкләрендә эшләде. Соңгы ике елда эзләнүләр Оренбург өлкәсендә дәвам итте.

1998 елда Казан дәүләт университеты, Татарстан Милли китапханәсе һәм Татарстан Фәннәр академиясе Тарих институтының берләштерелгән фәнни-тикшеренү экспедициясе Оренбург өлкәсенең Абдуллино, Пономарев, Әсәкәй, Матвеевка, Переволоцки, Новосергеевски, Сорочински, Тоцки, Ташлы, Северный районнарына кергән 26 татар авылында һәм Оренбург, Бозаулык, Богырыслан калаларында эзләнүләр алып барган иде. Нәтижәдә, күпгасырлы тарихыбызны һәм гомумән мәдәниятебезне өйрәнү өчен фәнни әһәмияткә ия 235 берәмлек тарихи, әдәби һәм дини кулъязма ядкәрләр тупланды. Болардан тыш, илледән артык гарәп язулы иске басма китап һәм атаклы «Шура» һәм XX йөз башында нәшер ителгән башка бик күп татар журналларының төпләмәләре дә табылды.

1999 елда исә тикшеренү эшләре өлкәнең Сакмар, Саракташ, Куандык, Гай, Беляев, Шарлык, Александр районнарындагы 27 авылда һәм шулай ук Оренбург, Орск калаларында алып барылды. Узган елда, асылда, жырларда жырланган алкын сулы Сакмар елгасының ике ягына урнашкан татар авылларын тикшердек. Алар арасында элеккеге «казачи» авыллар да бар иде. Сәфәребезнең иң ерак ноктасы өлкәнең көнчыгышындагы Орскидан Гай шәһәренә таба 30 чакрымда Гөберлә суы буена сыенган Гайнулла авылы булды. Аны икенче төрле Дүрткүл дип тә атыйлар, анда хәзергә кадәр классик әдибебез М. Фәйзинең туганнары яши. Шулай итеп, 1998 елгы табышларга 192 берәмлек кулъязма һәм 185 иске басма китап өстәлде. Нәтижәдә, күпме кыйммәтле чыганаклар тарих тузаннары арасында мәңгелеккә югалудан саклап калынды. Алар арасында ниләр генә юк! Хәер, төп максатыбыз булган кулъязмаларга күзәтү ясаганчы, бер-ике чигенеш ясау тиешле. Беренчедән, безнең сәфәрләрне Оренбург өлкәсенә оештырылган беренче экспедицияләр дип әйтү дөрес булмас иде. Чөнки, моннан 37 ел элек, ягъни 1963 елда Казан дәүләт университеты галимнәре тарафыннан оештырылган беренче археографик экспедиция нәкъ менә шушы өлкәдә эш алып барган. Һәр ел саен милләттәшләребез яшәгән төбәкләрне тикшерү белән шөгыльләнгән археографик экспедиция чирек гасырдан артык күренекле тарихчыбыз, Татарстан Фәннәр академиясе академигы Миркасыйм ага Госманов житәкчелегендә эшләп килде. Әмма, бер экспедиция дәвамында гына Оренбург өлкәсенә сибелгән берничә дистә татар авылын җентекләп тикшереп чыгу мөмкин түгеллеген искә алып, без эзләнүләрне

шушы төбәктә дәвам иттерүне максатка ярашлы дип таптык. Шунын өстенә элек һәм хәзер археографик эш методларында аз гына булса да аермалар барлыгын да искә алырга кирәк. Әгәр элегрәк экспедиция әгъзалары, асылда, «адрестан-адреска» ысулы белән эш итсәләр, хәзер исә «йорттан-йортка» принцибы белән авылларны тоташтан тикшерү ысулы унай нәтиҗәләр бирә.

Экспедицияне Оренбург якларына оештыруның тагын бер сәбәбе шунда ки, мәгърифәт учакларына бай бу төбәк мәдәниятебезгә кемнәрне генә бирмәгән дә, кемнәр генә бу якларда үзенен бәрәкәтле эшчәнлеген башлап җибәрмәгән. XX йөз башы татар мәдәниятенен кайсы тармагына күз салсак та без, һичшиксез, Оренбург төбәге белән бәйле шәхесләр, вакыйгалар, төрле оешмалар эшчәнлеге белән очрашабыз. Биредә заманынын атаклы хәйрия ияләре Хөсәеневләр тарафыннан оештырылган җәдид мәдрәсәсе «Хөсәения» эшләгән, халык китапханәләре ачылган, татар профессиональ театры орлыклары шытып чыккан. Губерна үзәге булган Оренбург—XX йөз башында, Казаннан кала, татар китабын нәшер итүче икенче үзәккә әверелә. Калада беренче татар басмаханәсен оештырган Ибраһим улы Гыйльман ахуннын эшен улы Фатих Кәрими дәвам итә. Дәрдмәнд, Х. Хөсәенев һәм башкалар да бу өлкәдә бөек хезмәт күрсәткән шәхесләр. Мәдәниятебез, иҗтимагый-сәяси тормышыбызда тирән эз калдырган «Вакыт», «Шура» кебек ин саллы газета-журналлар да биредә нәшер ителеп, Россия империясе кинлекләренә сибелгән милләттәшләребезгә таралган. 1897—1917 еллар аралыгында бу төбәктә төрле юнәлештәге 50 дән артык хәйрия, мәдәни-агарту һәм иҗтимагый-сәяси характердагы милли оешмалар эшләп килгән.



*Габдерәхим Утыз Имәнинең «Горбәтнамә» поэмасы. 1786 елгы кульязма*

Әйткәнебезчә, бу төбәккә бәйле шәхесләребез арасында кемнәр генә юк! Шагыйребез Акмулла тарафыннан «Хөрмәтле Ризаэтдин—бер камил зат!»—дип олыланган Р. Фәхретдин биредә «Шура» журналы һәм башка бик күп китапларын нәшер итеп, милләтебезгә фидакярләрчә хезмәт итә. «Корыч өслүбле» әдәбиятыбыз шонкары Дәрдмәнднен шигъри җәүһәрләре дә биредә иҗат ителә. Классик әдипләребез Ш. Камал, М. Фәйзи талантлары шушы төбәктә канат җәйгән. Күренекле журналист, әдип һәм җәмәгать эшлеклесе Фатих Кәрими Оренбургнын гына түгел, гомумән XX йөз башы татар доньясынын ин могътәбәр вә күренекле әһелләреннән берсе. Яна Белагор авылы халкыбызга милләт хадиме Габделбарый Батталны бирсә, Хөсәен, Кондызлытамак, Бәшир авылларында язучылар Гыйззел Габит, Зәйни Шаһиморат, рәссамнар Байназар Әлминев һәм Рауза Якуповалар доньяга килгән. Соныннан музыка сәнгатебез күгендә якты йолдыз булып балкыячак Җәүдәт Фәйзи дә беренче булып Оренбургтагы Ивановлар тыкрыгынын бәбкә үләннәренә аяк баскан. Шушы ук тыкрыктагы тыйнак кына бер йортта Ш. Мөхәммәдев яшәп иҗат иткән. 1918 елда калада Шәрык музыка мәктәбе ачылып, 1920 елнын көзендә биреgә С. Сәйдәшев килә һәм сонрак әлеге уку йортынын директоры булып эшли. XX йөз башында язучы Әсгать Айдарнын әтисе Харис ахун Сорочинск шәһәрендә билгеле шәхесләрнен берсе була. Унынчы елларда ул Иске Белагор (Искеавыл) янын-дагы зур җимеш бакчасы мәйданында, Оренбург, Бозаулык, Орскилардан кунаклар чакырып, зурлап сабантуйлар уздырган. Искеавыл суы буендагы ул бакча урынын халык хәзергә кадәр «Хәзрәт сады» дип атап йөртә.

Инде килик сәфәребезнен төп максаты булган кулъязмаларга. Табышларыбыз гадәти, традицион характердагы ядкарьләрдән гыйбарәт. Аларнын мәгълүм өлешен дини язмалар, кулъязмалар алып тора. Коръән Кәрим, һәфтияк, төрле күләмдәге догалыклар, пәйгамбәрләр тарихына багышланган язмалар, дини васыятьнамәләр, бәтиләр, салаватлар—әнә шундый ядкарьләр. Мондый кулъязмалар халкыбыз яшәгән һәр төбәктә табыла һәм бу табигый да. Икенче зур төркем—әдәби мирасыбыз үрнәкләре. Алар арасында Әбелмәних Каргалый, һибәтулла Салихов, Гаделжәббар Кандалый, Мифтахетдин Акмулла, Муса Жәлил кебек татар әдәбиятында тирән эз калдырган күренекле каләм ияләренен әлегә кадәр билгеле һәм билгеле булмаган әсәрләренен күчермәләре, аларнын тәржемәи хәлләренә кагылышлы башка язма чыганаклар да бар. Алар барысы да әдәбиятыбыз тарихын тагын да тәфсилләбрәк тикшерергә, яктыртырга ярдәм итәчәкләр. Мәсәлән, күренекле шагыйрь һәм фикер иясе Габдрәхим Утыз Имәни Әл-Болгарыйнын «Горбәтнамә» поэмасы мона кадәр XIX йөзгә караган 5 нөсхәдә билгеле иде. Безнен табышлар арасында исә бу әсәрнен шактый элгәреге, 1786 елга караган нөсхәсе бар. Киләчәктә әдип мирасын тагын да тирәнтенрәк өйрәнгәндә, бу табылдык текстолог-галимнәргә ныклы бер таяныч булыр дип уйлыйбыз. Мәгълүм XVIII йөз татар шагыйре Габдессәлам һәм анын оныгы—мәшһүр шагыйрь Әбелмәних Каргалыйларнын нәсел шәжәрәсе дә 1999 елгы әһәмиятле һәм сирәк очрый торган табышлардан. Шәжәрә шул ук нәселдән булган Мотаһһар Әбелләес углы Әбелфәезов кулы белән 1922 елнын 3 март көнендә язылган. Анын нәсел шәжәрәләренен әһәмияте хакындагы шунда ук теркәлгән фикерләре игътибарга лаеклы. Шәжәрә «Олуг бабамыз Колаб би тау йирендә ватан тот[кан] ... [ка]льгәсендә хан булган заманда. Колабнын угылы Колчура. Анын угылы Колмөхәм-мәд. Анын угылы Уразмөхәммәд, ләкабе Урай мулла. Уразмөхәммәднен угыллары Габдессәлам, Габбас. 1744 нче ел Каргалы шәһәренә бина кылынган Габдессәлам ахунд шунда беренче мәхәлләгә имам һәм ахун булган. Габдессәлам ун угыл...» дип башлана һәм, шул рәвешчә, нәсел-нәсәп жепләре 1922 елга кадәр язып дәвам ителгән. Әмма шәжәрәдә кайбер бутальчыклар да юк түгел.

Шәжәрә тексты Оренбург өлкәсенен Татар Саракташы авылында Габделгазизова Мәгърифә апа кулында сакланган. Бу табылдык та күренекле татар әдипләренен тормыш юлларын һәм иҗатларын өйрәнү өчен, һичшиксез, кызыклы чыганак. Табышлар арасында жыр, бәет, мөнәжәтләр дә шактый зур урын алып тора. Классик бәетләрдән «Сак-Сок» һәм солдат бәетләре аеруча күп очрый бу төбәктә. Төрле эчтәлектәге язмаларны үзенә туплаган шәкерт дәфтәрләре әдәбиятчыларыбыз өчен үзе бер хәзинә.

Экспедиция табышлары кулъязмалар, төрле документлар белән генә чикләнми, әлбәттә. Басма китап-журналлар да зур әһәмияткә ия, чөнки, мәгълүм сәбәпләр аркасында, 1917 елнын октябренә кадәр дөнья күргән күп кенә басмалар фәнни китапханә, архив фондларында аз тупланган. Бигрәк тә, 1905-1907, 1917-1918 елларда цензурасыз нәшер ителгән китаплар начар сакланган. Экспедиция тарафыннан жыелган басма китаплар арасында да уникаль дип әйтерлек басмалар бар. Шуларнын берсе Абдуллино районынын Яна Тирес авылында табылды. Әлегә кадәр дәүләт китапханәләрендә теркәлмәгән бу брошюра 1918 елнын 1 гыйнварында Германиянен Берлин шәһәрендә төзелгән «Русияле ислам шәкертләренә ярдәм жәмгыяте»нен татар телендә дөнья күргән уставы һәм программасы. Мона кадәр билгеле булган китапларнын яна нөсхәләре табылу да әһәмиятле, бу үз нәүбәтендә, китапнын файдаланылу даирәсен кинәйтүгә, аны киләчәк буыннарга саклап калуга ярдәм итәр.

Борынгы, үткәндәге ядкарьләрне эзләү, табу һәм туплауны максат итеп куйган археографик сәфәрнен асыл жәһәте—яналыкка омтылыштан гыйбарәт. Ягъни, һәр иске кулъязманын табылуы—фән өчен яналык. Археографиянен төп кызыксындыру хасияте менә шушы капма-каршы ике полюс—искелек һәм яналыкны берләштереп торуында.

Археографик экспедиция халкыбызнын үткәнен генә түгел, бүгенгесен дә өйрәнү, күреп белү өчен бик файдалы. Экспедиция барышында, әйтик, йөзләгән гыйбрәтле вакыйга һәм язмышлар белән очрашырга туры килә. Әйе, археографик сәфәр үзе бер дөнья. Һәр елгы сәфәрләр дә яна коллектив, яна юллар, яна жирләр һәм яна жырлар, яна табышлар... Экспедициядә көндәлек эш тә, яна табышларга

куану да, яшәү-көнкүреш мәшәкатьләре дә—һәммәсе бергә алып барыла. Әлбәттә, экспедиция муафыйк дәрәҗәдәге, археографик экспедиция өчен генә хас, күп еллык тәҗрибә нәтиҗәсендә калыплашкан, кайбер очракларда кырысрак та тоелган, эчке тәртипләр буенча оештырыла. Табигый, һәр эштәге кебек үк, монда да эреле-ваклы кыенлыклар булмый тормый. Табигать кырыслыклары, һава шартлары, юл михнәтләре һ. б. Әйтик, үзләре энә очы кадәрле генә һәм нәзек кенә тавыш белән «энем-м, энем-м» дип көйләп, татар факультетының пәһлевандай студентын, дискотекадагыча, килбәтсезрәк хәрәкәтләр белән биетә торган озынборыннар һәр елгы экспедициянең аерылгысыз юлдашлары. Шул безелдәвек вак мәхлукларга, гадәттә, күп сәфәрчеләрнең хәтерләре калучан була. Әмма экспедиция ахырына һәркем изге максатлардагы олуг нәтиҗәләргә вак кыенлык-киртәләрне җиңгәндә генә ирешеп булуына инаналар.

Һәр төбәктә туган ягының, туган авылының тарихы белән кызыксынучы милләттәшләребез яши. Оренбург якларында да бар алар. Сакмар районының Югары һәм Түбән Чебенле авыллары тарихына багышланган аерым китап бастырып чыгарган Рәшит ага Искәндәрев, Куандык районы Мөхәммәдъяр авылы китапханәсендә авыл музее оештырган китапханәче Рәйхан ханым Галиева әнә шундыйлардан. Алар һәм исемнәре биредә телгә алынмаган бик күп милләттәшләребез безгә эшебездә эчкерсез ярдәм иттеләр. Экспедицион сәфәрләребезнең унышка ирешүендә аларның да өлеше бар.

Май кояшы кебек балкып торган мөлаем йөзле, һәм дини, һәм дөньяви мәсьәләләрдә дә төпле әңгәмәдәш булган Орск шәһәре мәчете имамы мөхтәрәм Рәсим хәзрәт Әхмәтевнең самими ярдәме турында аерым билгеләп үтәргә кирәк. Әнә шундый йөзләгән милләттәшләребез булганда, киләчәк сәфәрләребезнең дә унышка ирешүенә өмет бар. Һәр ике сәфәребездә дә без Оренбургта яшәп иҗат итүче фидакяр милләт хадимәсе Мәдинә ханым Рәхимкулова янына кереп хәл-әхвәл белешеп чыгуны үзебезнең бурычыбыз санадык. Инде тугызынчы дистәне ваклаучы Мәдинә ханым һаман эштә: яза, тикшерә, китап артыннан китап нәшер итә...

Хәзерге заманда экспедиция кебек гыйльми сәфәр оештыруның химаячеләрдән, ягъни спонсорлардан башка тормышка ашырып булмаганлыгы күпләргә аңлашылса кирәк. Шуна күрә соңгы дистәгә якын ел дәвамында экспедиция унышлы эшләп килә икән, биредә республикабыз Милли китапханәсенең элеккеге директоры, күренекле язучы, Татарстан Республикасы Дәүләт Советының фән, мәгариф, мәдәният һәм милли мәсьәләләр даими комиссиясе рәисе Разил Исмәгыйль улы Вәлиевнең дә зур өлеше бар. 1998 елгы сәфәребезгә матди ярдәм күрсәткән «Татхимэнергогаз» ябык акционерлык җәмгыятенең генераль директоры Илдар Зыя улы Хәмидуллин исә тумышы белән Оренбург өлкәсенең Матвеевка районы Олы Котлымбәт авылы егете. Милләтебезнең шундый асыл ир-егетләре күбрәк булсын иде!

Язмабызны мәшһүр галим Ризаэтдин Фәхретдин сүзләре белән тәмамлыйсы килә: «...Сахраларда йөрдек. Кымыз эчтек. Урыннардан-урыннарга күчтек. Күк берлә ябылган яшел паласлар өстендә ятып йокладык. Чыңгыз хан чатырлары мисалында чатырларда китап укып яттык, урманнарда, болыннарда гиздек. Түгәрәкләнеп тезелеп утырып ашадык. Күргән берлә ишеткән бер түгел. Дөнья бу җирләрне күрсәтте вә шул урыннарда йөрергә, унбиш көннәрдән артык вакытлар уздырырга форсат бирде. Моны нигъмәт белергә вә шөкер кылырга тиешле. Инде бу көннәр гомеремнең ядкаре булып калды. Шушы вакыйгаларны онытмыйм. Һаман сагынам» дип, 1913 елда Р. Фәхретдин тарафыннан язылган юлларда гүя, безнең экспедициянең яшәү шартларыннан алынган хозурлыклар да тасвирланган.

**Җәүдәт МИҢНУЛЛИН,**
*археографик экспедиция җитәкчесе, КДУ доценты.*

**Раиф МӘРДАНОВ,**
*филология фәннәре кандидаты.*

# ТЕЛ ДӘРЬЯСЫНЫҢ ИКЕ ЯРЫНДА

Ике кардәш—татар һәм төрек телләренең, күп кенә уртаклыклар белән беррәттән, тарихи-иҗтимагый шартлар, тел үсеш-хәяты һәм сәясәте, шулай ук башка сәбәпләр белән дә бәйле рәвештә, кабатланмас үзенчәлекләргә ия булулары билгеле. Әлеге уртаклык һәм аерымлык сыйфатлары, әлбәттә, мәкаль һәм әйтемнәрдә дә чагыла.

Төрек телендәге *atasözü* (ата сүзе) төзелеше белән һәм гамәли ягыннан татар телендәге мәкаль төшенчәсенә якын булса, *deyim (*дейим) исә әйтем мәгънәсен белдерә. Төрек телендә "Atasözleri sözlüğü", "Deyimler sözlüğü" рәвешендә аерым-аерым сүзлекләр төзелгән һәм нәшер ителгән. Соңгы елларда төрек галимнәреннән Рашит Куру (Türkçe Deyimler Swzləgə—1988), Якуп Кавас (Deyimler ve Atasözleri Sözlüğü—1991), Фетхи Гөзлер (Türkçe Deyimler... Sözlüğü—1991), Акиф Ордулу (Deyimler Sözlüğü—1993) һәм Нуретдин Кочның deyimнәрне тел күренеше буларак тикшергән (Dilbilgisi—1990) хезмәте игътибарга лаек.

Сәяси-икътисади күперләр торгызылгач, галимнәребез арасында да "тел, ләгать алмашу" көчәйде. Мәскәүдә 1997—1998 елларда татарча-төрекчә (Ф. Ганиев, Р. Әхмәтьянов, Х. Ачыкгөз) һәм төрекчә-татарча (Р. Әхмәтьянов, Р. Мөхәммәтдинов, Ф. Нуриева, Ф. Ганиев) сүзлекләр басылып чыгу зур вакыйга булды. 1999 елда Истанбулда төрек, рус, татар, инглиз телләрендә фразеологик сүзлек дөнья күрде (З. Гатиатуллина, Х. Адыгүзел, Д. Салахова).

Төрек-татар тарихи-мәдәни бәйләнешләрын, шул җөмләдән "deyim" нәр белән әйтемнәрне чагыштырып өйрәнү эше дә инде башланып килә. Бу юнәлештә эзләнүләрнең киләчәге зур. Бер яктан, татар һәм төрек халыкларының, алар аша гомумтөрки кавемнең тарихи тамырларын һәм уртак фольклор, ягъни, акыл-фәлсәфә хәзинәсен барлауны тотрыклы тел фактлары ярдәмендә дәвам итү дигән сүз ул. Икенче яктан, нәкъ менә шул материалга нигезләнеп, татар һәм төрек телләре төзелешен тарихи грамматика, стилистика, лексикология тармаклары кисешкән ноктада чагыштырмалы өйрәнү мөмкинлеге ачыла. Мәсьәләнең гамәли ягын игътибар үзәгенә алсак, икътисади-сәяси аралашу көчәйгән шартларда әлеге табышларны тәрҗемә практикасында куллану, сөйләм һәм язма тел байлыгыбызны арттыру максатында файдаланып булачак.

Еш кына бер үк әйтемнең башка халыклар хәзинәсендә дә актив әйләнештә йөрүе мәгълүм. Deyim-әйтемнәрне кардәш халыклар хәзинәсе белән чагыштырып, тарихи яктан күзәтү кызыклы фаразларга этәргеч бирә.

Мисалга "*Bal tutan parmağını yalar*" дигән төрек мәкален алыйк. Шул ук мәгънәдә без "*Бал тоткан бармак ялар*" дигән әйтемне кулланабыз. Башка төрки телләрдә дә шуңа аһәңдәш әйтем бар икән (мәсәлән, кыргызларда "*Май кармаган бармагын жалайт*". XIV йөзгә караган "Кодекс Куманикус" (Коман мәҗмугасы) җыентыгында ук "*Бал тутан бармак йалар*" дигән борынгы тезмә теркәлеп калганлыгы мәгълүм. Димәк, әлеге әйтемнең тамырлары бик тирән, ул төрки бабаларыбыз Ауразия киңлекләрен иңләп гомер кичергән шанлы заманнарда тугандыр, ә соңыннан зирәк хәтер орлыгы булып күп кенә төрки кардәшләребез күңеленә сибелгәндер дип гөман кылырга нигез бар.

Шул ук вакытта килеп чыгышы махсус өйрәнүне сорый торган кайбер әйтемнәр дә бар. Мисалга төрекнең "*Boynuz isterken kulaktan olmak*" мәкален (сүзгә-сүз тәрҗемәсе—мөгез теләп колаксыз калу) һәм Н. Исәнбәт тарафыннан теркәлгән "*Мөгезен саклыйм дип, колагыннан язган*" дигән әйтемне алыйк (татар әйтемнәре һәм мәкальләре, нигездә, ул туплаган гаять зур хәзинәдән китереләчәк)[1]. Лексик яктан үзара бик якын булса да, бу тәрдәш гыйбарәләрнең мәгънәләре беркадәр үзгә. Төрек телендә ул—тагын нәрсәдер теләп, кулындагысын ычкындыру,

татар телендә исә—бик үк әһәмиятле булмаган нәрсәне саклыйм дип икенче берәр әһәмиятлерәк әйбердән колак кагу. (Сүз унаеннан, *"колак кагу"* дигән әйтелмәнең дә килеп чыгышы шуннан булса кирәк). 1341—1431 елларда яшәгән төрек шагыйре Шәйхинең (Йосыф Синан Гермиянинын) "Ишәк турында поэма"сы нигезенә нәкъ менә әлеге мораль салынган:

*...Ишәк диде:*
*Юкка гына язмышыма мин юылмас яла яктым,*
*Мөгезле булырга теләп, колактан да колак кактым*[2].

(Тәрҗемә безнеке—А. В.).

Урта гасырлар шагыйре инде булган әйтемне файдаланганмы? Әллә аның әсәрендәге иҗади табыш шул әсәрдән соң канатлы сүзгә әверелеп киткәнме? Һәр икесе дә бик ихтимал.

Н. Исәнбәт тупланмасында ишәкне дөя белән "алыштырган" үрнәкләр дә бар: *Дөя үзенә аккош муены, болан аягы, киек койрыгы, әзер иляр сорап, бар матурлыкны алып бетермәкче булган да, барысын да алгач, шундый шыксыз булып чыккан. Дөя ике мөгез сорады, ике колактан коры калды.* Соңгысына карата галим "Артык тәкәллефле тышкы форманы таләп итеп асыл кирәктән коры калуга мисал итела", дип аңлатма бирә.

Нәфес азынудан кисәтүгә мисалдан *"Kafesteki serçe damdaki kazdan iyidir"* (читлектәге чыпчык түбәдәге каздан яхшырак), *"Kırk serçeden bir kaz iyi"* (кырык чыпчыктан бер каз яхшы), *"Bügünkü tavuk yarınkı kazdan iyidir"* (бүгенге тавык иртәгәге каздан яхшырак) дигән deyimнәр дә билгеле. Татар телендә боларга мәгънәви аһәңдәш буларак *"Күктәге торнага караганда, кулдагы чыпчык яхшырак"* мәкале кулланыла. Әлеге мәкаль телебездә күптән кулланышта булса кирәк. Чөнки күренекле тарихчы һәм дин галиме Ризаэтдин Фәхретдин, Мөхәммәд пәйгамбәр тарафыннан әйтелгән бер хәдискә аңлатма-тәфсир китергәндә: "*Һавадагы торнага була кулдагы чыпчыкны җибәрү гакылсызлыктыр*",—дип үзеннән өсти[3].

Кайбер төрек әйтемнәренең бездәге төрдәшләрен табу, аларның мәгънәләрен турыдан-туры тәрҗемә аша гына түгел, хәтта гадәти этимология һәм тарихи лингвистика кануннарына нигезләнеп тә аңлатуы җиңел түгел. Мәсәлән, *"Eski çamlar bardak oldu"* (сүзгә-сүз тәрж.: иске нарат агачлары стакан булды) беренче карашка **çam**lar (нарат агачлары) сүзе чынлыкта **cam**lar (пыялалар) булырга тиештер кебек тоелган иде. Һәрхәлдә нарат агачыннан бигрәк пыяланың стаканга әверелүе табигый һәм аңлаешлырак бит. Әмма чынлыкта ул алай түгел икән. Төрек телендә әлеге әйтемнең риваяте бар. Имештер, бер егетне патша хезмәтенә алганнар. Солдат хезмәте бик озак еллар барган. Егет армиядән әйләнеп кайткач, үзенең туган авылы янындагы наратларның юкка чыгуын күреп, әтисеннән моның сәбәбен сорый. "Иске наратлар стакан булды, улым. Сиңа җибәреп торган акчаларны кайдан алдык дип уйлыйсың",—ди әтисе. Бу deyimgә төрек сүзлекләре "Devir değişti—дәвер алмашынды"[4], "Zaman değişti, eski hükümlerin değeri kalmadı—заман-вакыт алмашынды, иске хөкемнәрнең кыйммәте-бәясе калмады"[5] дип аңлатма бирәләр. Шуңа күрә, аның татардагы мәгънәви (ягъни күп вакытлар узу турындагы) төрдәше *"Үткәндәге—сүткән, өстенә үлән үскән"* рәвешендәге әйтем булырга тиеш дип расларга мөмкин. *"Аннан соң күп сулар акты"* дип тә әйтәбез. Шундый ук мәгънәне аңлату өчен төректә мондый deyim бар: *Köprülerin altından denizler geçmişti* (Күперләрнең астыннан күп диңгезләр яки диңгез сулары акты инде).

Шулай да бер үзенчәлекне аерып күрсәтергә кирәк, төрек "deyim"нәре белән татар әйтемнәрендә аерым сүзләр туры килмәү тел яки яшәү-көнкүреш үзенчәлеге белән генә бәйләнмәгән, бу—аларда тарихи тамырларның саклану дәрәҗәсен дә күрсәтә торган билге. Әйтик, *"Авызын ачса үпкәсе күренә"* дигән әйтемнең төректәге ишен эзләп сүзлекләргә мөрәҗәгать итсәк, аны тиз генә табу мөмкин булмас. Шулай да төрекләр андый "deyim"не беләләр һәм кулланалар. Ул *"Ağızını açsa midesi görünüyor"* (Авызын ачса ашказаны күренә) рәвешендә билгеле. Бездә аның *"Авызын ачса күче теле күренә"* дигән төрдәше дә бар. Кардәш халыклардан балкарлар да *"Авузун ачса өпкелери көрүне"* диләр. "Коман мәҗмугасы"нда бу гыйбарә "Аузым ачсам өпкәм көрүнер. Ол—эшик ачса от көрүнгәнидер" рәвешендә теркәлгән[6]. Аңлашыла ки, борынгы заманда ул табышмак буларак әйтелгән. Күчмә тормыш заманындагы киез тирмәнең ишеген ачуга, тирмә эчендәге (авызындагы) кызыл

ялкын күзгә ташланган. Вакытлар үтү белән әлеге табышмак әйтемгә әйләнеп кала, һәм инде ул кешенең артык ябык, арык булуын яисә бик ярлы, хәерче тормыш кичерүен белдерә. Күргәнебезчә, бу әйтем-табышмак бездә тарихи формасында сакланып калган, төрек телендә "ашказаны" дип тәрҗемә ителә торган "midesi" сүзе белән яши башлаган.

Гаять саран кешене аңлатучы "*Кыш көне кар алып булмый*" дигән әйтемнең төректәге ише—"*Ateşe vursan duman vermez*" (утка ташласаң, төтен бирмәс). Бу deyim уңаеннан төрек һәм татар телләрендәге лексик параллельләрнең бер кызыклы ягына игътибар итик. "Duman" сүзенең хәзерге татар теленә "төтен" дип тәрҗемәләнүе, "томан"ның—төрекчә "sis", ә "tütün"нең чыннан да "төтен", әмма "тәмәке төтене" булуы телләребезнен "кылдан нечкә, кылычтан үткен" тарих сиратын кичүләре турында сөйләүче бер мисал түгелмени?! "Борынгы төрки сүзлек"кә таянып, тарихи яктан TUMANның "туман, мгла, мрак" (томан), ә TÜTÜNнең "дым" (төтен) мәгънәсен аңлатуын искә төшерик[7]. Күрәбез ки, бу очракта борынгы тел асылы татар телендә тотрыклырак сакланып калган.

Мондый мәгънә үзенчәлекләрен тоймау яки исәпкә алмау кайчакта аралашу-аңлашу һәм тәрҗемә практикасында буталчыклыклар тудырырга да мөмкин. Әйтик, *Denize düşen yılana sarılır*—төрекчә-русча сүзлекләрдә бу әйтемнең эквиваленты итеп "*Утопающий хватается за соломинку—Бата башлагач саламга тотыну/ябышу*" гыйбарәсе китерелә. Әмма бу тәрҗемә әйтемнең мәгънәви асылын дөрес үк чагылдырмый. Төрекләр аны бер хәтәр хәлгә төшкән кешенең котылам дип, аны-моны белештермичә, тагын да хәтәррәк бәлагә дучар булуына мисалдан әйтәләр. Бата башлагач саламга тотыну/ябышу исә авыр ситуациядә калгач, гомумән аптырап-югалып калу аркасында юк чарага ябышуны аңлата. Ассоциация ягыннан караганда да, әлбәттә, елан һәм салам образлары бик нык аерыла. Бу әйтемнең татар телендәге лексик-семантик яктан тулысынча тәңгәл төрдәше Н. Исәнбәт тупланмасында теркәлгән: "*Диңгезгә төшкәч еланга сарылу*".

Яисә менә мондый deyim: *Denizi geçip çayda boğulmak*. Мәгънәсе: зур эшләрне башкарып чыкканнан соң кечкенә генә каршылыклар алдында югалып калу. Бу әйтемне "Диңгез кичеп чәйгә баткан" дип тәрҗемә итәргә дә була кебек. Әмма төрек телендә "çay" сүзенең, "чәй"дән тыш, икенче мәгънәсе бар: ул—"инеш". Хәер, "çay" сүзе кайчандыр татар телендә дә, башка төрки телләрдә дә инешне белдергән. Кайбер төрки халыкларда, мәсәлән, әзәрбайҗан телендә "чай", каракалпакча "сай"—"елга", якут телендә "сай"—әле дә "агым" дигәнне аңлата[8]. Без игътибар үзәгенә алган төрек әйтемендәге "çay" да нәкъ менә инеш мәгънәсендә кулланылган. Аның сүзгә-сүз туры килә торган һәм мәгънәдәш пары Н. Исәнбәт тупланмасында китерелә: *Диңгез(дән) кичеп инешкә баткан.*

Әйтем һәм "deyim"нәрдәге лексик аерымлыклар, алда китерелгән мисаллар раслаганча, тел күренеше булудан узып, халыкларыбызның төрле мохитта көн итү тәҗрибәсен дә чагылдыралар.

Бер генә халык та башкалардан изоляцияләнгән хәлдә тереклек итә алмый. Үзара аралашу нәтиҗәсендә төрле халыкларның уртак әйтемнәре, теге яки бу телдән алынма булараk кергән әйтемнәр барлыкка килә. Шундыйларның берсе: "*Bir bardak suda fırtına koparmak—Бер стакан суда давыл чыгару*". "Fırtına"—итальян сүзе. Русча "*Буря в стакане воды*" дигәнне дә яхшы беләбез. Н. Исәнбәт әлеге әйтемне татар теленә калька рәвешендә рус теле аша кергән дип саный. Төрек теленә ул, билгеле тарихи вакыйгалар аркасында, бәлки турыдан-туры итальянчадан алынгандыр.

Шундый нюанс-төсмерләр кайчакта аерым бер сүзнең генә чит телдән алынган булуы аркасында да килеп чыгарга мөмкин. Мәсәлән, "*Baston yutmuş gibi*"не без "*Уклау йоткан [төсле]*" дип тәрҗемә итәр идек. "Baston"—итальянча "таяк" дигәнне аңлата. Туп-туры, бөгелмичә торучы, асылда тәкәббер берәр кемсә хакында әйтәсе булганда төрекләр чын төркичә итеп "*Kazık yutmuş gibi*" дип тә әйтергә мөмкиннәр, аларда әлеге әйтемнең мондый варианты да бар. Әмма, күргәнебезчә, төрекнең тәкәбберлеге безнекеләр кебек "уклау йотып" түгел, ә baston/таяк яки kazık/казык йотмыш кыяфәттә сурәтләнә.

Төрекләр белән аралашу киңәя, үзара тәрҗемә итешү активлаша барган шартларда бу үзенчәлекләрне һәм төсмерләрне истә тотарга кирәк булачак. Әйтик, "*Bir ayağı çukurda olmak*" дигәнне "бер аягы чокырга төшкән" дип тәрҗемә итсәң,

бик унайсыз хәлдә калырга мөмкин. Бу әйтем картайган, үлеме якынлашкан кешене сыйфатлый һәм бездәге *"[Бер] аягы кабер якасында [гүрдә]"* дигәнгә туры килә. Хәер, хәзер "mezar" сүзе ешрак кулланылса да, төрекчә "çukur" сүзе шулай ук "кабер" дигәнне аңлата. Төрек телендә бу сүзнең өченче синонимы—"kabir" дип әйтелеше дә гамәлдә. Әлеге әйтемнең гомумтөрки булуы да ихтимал, чөнки, мәсәлән, карачай-балкарлар да: *Бир аягы төрде, бир аягы көрде* (*Бер аягы түрдә, икенчесе гүрдә*), дип әйтәләр[9].

Әйе, мәгънәви яктан тиңдәш әйтем/deyimнәрдә тел аерымлыгы аркасында туган лексик үзгәлекләр, хәтта бер сүзнең икенче сүз-төшенчә белән алышынуы да әлләни зур роль уйнамый кебек. Әмма, игътибар беләнрәк карасаң, кызыклы нәтиҗәгә киләсең: тулы яки өлешчә мәгънәви эквивалент булган әйтемнәрдә кечкенә генә лексик үзгәлек тә телләр һәм халыклар арасындагы тарихи уртаклык һәм якынлыкны ассызыклап, яңа төсмерләр белән баета.

Төрек deyimнәрен тәрҗемә иткәндә, мәсәлән, ике мәгънәдә кулланылган әйтемнәр, ягъни фразеологик омонимнар күренешен дә искә алырга кирәк булачак. Әйтик, татар телендәге *"Күңел төшү"* ике мәгънәне—кәеф китү һәм теләк (нәфес) уянуны белдергән кебек, төрек телендә *"İçim gitti"* дигәне *күңел төшү*нең икенче мәгънәсен (теләк тууны) аңлата. Ә менә *"İçi dar"* (күңеле тар)—татар телендә "сабырсыз" дигәнгә туры килә.

*"Ağzı ile kuş tutmak"* дигән deyim белән *"Авызы белән кош тоту"* гыйбарәсе тулысынча тәңгәл кебек. Гаять уңган, барлык эшне дә башкара алган кешене төрек тә, татар да шулай сыйфатлый. Әмма кайбер татар сөйләшләрендә әлеге әйтемнең "аңгыра, ачыгавыз" мәгънәсендә йөрүе дә мәгълүм. Моны очраклы хәл дип бәяләр идең, чагыштырып карау өчен, казакъ телендәге шул ук әйтем *"Аузымен кус устап атыр"* ялганчы, мактанчык, шапырынучы мәгънәсендә. Казакъ кардәшләребез, теле белән генә барын да булдыручы кешеләргә үткен һәм үтергеч бәя бирү өчен *"Аузымен кус тістеген, жел жете алмас жүйриғин"* дип тә әйтәләр (авызы белән кош эләктергән, җил куып җитә алмаслык йөгергән). Шулай ук карачай-балкар телендәге *"Авзу кушу тут"* әйтеме дә мактанчык кешегә карата әйтелә.

Кыска формада булсалар да, "ачы тәҗрибә авазы" буларак, әйтем/deyimнәрдәге юмор-сатира уты мәзәкләрдәгедән ким түгел. Кыска итеп әйтелү исә аларның көйдереп алу сәләтен бер ноктага туплый һәм тагын да көчәйтә. Мисалга *"Teyzesinin komşusu"* дигән әйтемне алырга мөмкин ("апасының күршесе"). Бу deyim чыбык очы туганнарны яки туганлык җебе бөтенләй бәйләнмәгән кешеләрне аңлату өчен, яисә шундый "туганлык"ны күпертеп күрсәтүчегә карата ирония белән кулланыла. Татардагы ише: *Без синең белән бик якын туганнар бит: синең тәтәңнең тәтәсе белән безнең кәҗә тәкәсе бертуган.* Шул ук мәгънәдә төрек теленнән тагын бер мисал: *Dış kapının dış mandalı*—"тышкы ишекнең йозагы".

Йомшак кына көлеп чагыштыруга мисал итеп *Fasulye sırığı gibi* (фасоль терәге кебек)—озын, ябык кешегә карата әйтелә торган гыйбарәне искә алырга мөмкин. Татар күзаллавында, үзе яшәгән мохитка мөнәсәбәтле рәвештә, әлбәттә, "фасоль терәге"нә ассоциация уяна алмый, бездәге озын, арык кешеләрнең барысы да *колга кебекләр*...

Ялгызлык исемнәре белән ясалган әйтем-deyimнәр дә күп вакыт юморга төрелгән була. *Sarı çizmeli Mehmet Ağa* (сары итекле Mehmet Ağa)—кем, кайда яшәгәне билгеле булмаган кеше. *Benim adım da Yakup, ama o kadar uzun değil* (Минем исемем дә Якуп, әмма [мин] ул кадәр озын түгел). Ягъни минем хәлем дә аныкыннан яхшырак түгел, әмма аның кебек кешегә күрсәтеп йөрмим. *Bulunmaz Hint kumaşı olmak*—(табылмаслык һинд комачы булу) дигән әйтем үзе кирәксез булып та каршыга килеп чыккан яисә калмыйча ияреп, тагылып йөрүче кешегә карата кулланыла. Без бу очракта *Кирәкле кишер яфрагы* дияр идек. Тәрдәшләре: татар телендә *Сыңар башмак кебек хаҗәт*, төрек телендә—*Fasulye gibi kendini nimetten saymak* [үзен] фасоль төсле кирәкле нигъмәт дип санау. Ризык әзерләгәндә төрекләр фасоль борчагын күп һәм еш кулланалар. Соңгы әйтемдә әнә шул үзенчәлек чагылган.

Төрек deyimнәрендә телгә алынган исемнәр дә—гомумиләшкән образ, билгеле бер мәгълүмат салынган код кебек. Аларның хикмәтен, мәгънәсен ачыклау өчен шул кодның "ачкычын" табарга кирәк. Мәсәлән, нәрсә дә булса эшләргә соңга калдың мәгънәсендәге бер әйтем—*Ati alan Üsküdar'ı geçti* (атны урлаган [адәм]

Үскүдарны узды инде). Үскүдар—Истанбулдан Анатолиягә таба чыгу юлында шәһәрнең чик районы. Әлеге әйтемнең тарихыннан эчтәлеге аңлашыла: угрылар (мәсәлән, ат каракдары) Истанбулдан качып чыга алса, Анатолиядә яклау тапканнар.

Ялгызлык исемнәре ярдәмендә кешенең гамәленә, эчке һәм тышкы сыйфатларына бәя бирү үзенчәлеге табигать күренешләренә карата да кулланыла. Аларга бу очракта аерым киная салына яки хәтта метафора вазифасы йөкләнгән кебек була. Әйтик, төрекнең *Ayaz Paşa kol geziyor* (Аяз Паша кул изи) дигәне—урамда жил исә, янәсе. Татарның *Дәңгер бабай камчысын шартлата* дип әйткәне кебек (яшен яшенләү), борынгы ышануларга ишарәле һәм кинаяле-образлы сөйләм мисалы бу. Борынгы төрки телдә AJAS сүзе саф, чиста һаваны, күк йөзен белдергән (Древнетюрк-ский словарь.—27 б.). Аяз сүзе татар телендә әле дә болытсыз күккә (һавага) карата кулланыла. Төрек телендә исә ул "салкын" мәгънәсен белдерә. Сүз уңаенда искәртик: "kol" төрек телендә "el" (кул) сүзе белән беррәттән кулланылышта йөри. Ләкин алар арасында мәгънә аерымлыгы бар. El—кул чугын, kol—кулның бармак очларыннан алып иңбашына кадәр булган бөтен өлешен белдерә.

Яшәү мохитындагы, телдәге үзенчәлекләр аркасында, мәгънәсе уртак әйтемнәрнең дә кайбер аерымлыклары булу табигый. Әйтик, ***Armut** piş ağzıma düş*—***Алма** пеш, авызыма төш*. (Шунысы кызык, төректәге кебек үк, элгәрләребез *груша* мәгънәсен белдерү өчен *армут* сүзен кулланганнар).

Мәгънәви яктан "игезәк" deyim вә әйтемнәрдәге сүз-тел аерымлыгы борынгы төрки тамырларны яңартырга да ярдәм итә. Мәсәлән, *Eti senin **kemiği** benim—Ите сиңа, **сөяге** миңа* тәңгәллегендә күзгә ташланган ***kemik*** сүзе ятрак яңгырый кебек. Шул ук вакытта *Кирәкмәс балта **кемик** чабарга ярый* дигән татар әйтеме мәгълүм, һәм ул Мәхмүт Кашгарый сүзлегендә үк теркәлгән. Ягъни бүгенге татар телендә актив кулланылмый торган сүз берәмлеге әйтем составында сакланып калган.

Тулаем алганда, әйтем һәм deyimнәрдәге тәңгәллек һәм аерымлыклар, алда китерелгән мисаллар раслап торганча, тел күренеше булудан узып, кардәш халыкларыбызның тарихи үсешендәге, мохит, яшәү һәм фикерләү рәвешендәге үзенчәлекле якларны чагылдыралар. Уртак жирлеккә чигелгән үзгә бизәкләрне күзәтү төрек һәм татар халыкларының, бер үк фәлсәфи сөземтәне чагылдырганда, гүяки үзара ярышуын күрсәтә. Шул рәвешле, халыкларыбыз Галәм Акылы хәзинәсенә үзләре иҗат иткән байлыкны кушып-өстәп яшиләр, төркиләр фикеренең дөнья мәйданындагы мәртәбәле урынын ныгыталар.

**Айсылу ВӘЛИЕВА**

---

[1] Исәнбәт Нәкый. Татар халык мәкальләре. Өч томда.—Казан: Татар. кит. нәшр., 1959—1967. Аның ук. Татар теленең фразеологик сүзлеге. Ике томда.—Казан: Татар. кит. нәшр., 1989—1990

[2] Шейхи. Поэма об осле // Литература Востока в средние века.— Москва: "Сиринъ".—С. 163.

[3] Ризаэтдин бине Фәхретдин. Жәвамигуль кәлим шәрхе.—Казан: "Иман", 1995.—47 б.

[4] Kuru R. Türkçe Deyimler Sözlüğü.—İstanbul, 1988.— S. 103.

[5] Gözler H.Fethi. Türkçe Deyimler ve Edebiyat Terimleri Sözlüğü.—İstanbul, 1991.— S. 62.

[6] Татар теле һәм әдәбияты. Бишенче китап.—Казан, 1976.—265 б.

[7] Древнетюркский словарь.—Ленинград: Наука, 1969.—С. 585, 601.

[8] Гарипова Ф. Исемнәрдә ил тарихы.—Казан: Татар. кит. нәшр., 1994.— 43-44 б.

[9] Tavkul U. Karaçay-Malkar Türkçesinde Deyimler.—Kırım, 1999.—№7.—S. 26.

*Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан*

### КАЗАННЫҢ МЕҢ ЕЛЛЫГЫНА

Татарстан Республикасы Президенты Минтимер Шәймиев Казанның тарихи үзәген саклау һәм үстерү, 2006 елга кадәр Татарстан Республикасының социаль-икътисади үсеше юнәлешендәге ике максатчан Программа проектын карап тикшерде. Бу документларның дөньяга килүенә 2005 елның 30 августында билгеләп үтеләчәк башкалабызның 1000 еллык юбилее сәбәпче булды.

Казанның тарихи үзәген саклау һәм үстерү юнәлешендәге шәһәр программасын предприятиеләр һәм оешмалар катнашында башкала хакимияте подразделениеләре төзеде.

### ДАНЛЫ АНСАМБЛЕБЕЗ ЕВРОПАДА

Татарстан дәүләт җыр һәм бию ансамбле чит илләргә ай ярымлык гастрольләрен башлады. Мондый озын турне бу коллектив тормышында беренче генә әле. Алар башта Франциядә узачак бик мәртәбәле Халыкара фольклор Консолан фестивалендә катнашып, җырлы-биюле «Сабантуй» һәм «Аулак өй» программаларыннан аерым фрагментлар күрсәтәчәкләр. Ансамбль бу фестивальдә 10 көн, ә гомумән Франциядә бер ай булып, аның төрле шәһәрләрендә, провинцияләрендә концертлар куячак.

Аннары коллектив Германиянең Ганновер шәһәренә юл тота. Анда ул «ЭКСПО-2000» күргәзмәсендә Татарстан Республикасы көннәрендә катнашып, безнең ил-җиребезне сәнгати, мәдәни яктан танытачак.

50 яшьлек ансамбльне аның яңа художество җитәкчесе Ринат Вәлиев җитәкли.

### ӘДӘБИЯТ КӨННӘРЕ

Июль аенда Ульяновскида Татар әдәбияты көннәре булып узды. Күрше өлкәдә үткән бу әдәби бәйрәмдә Язучылар берлеге рәисе Ф. Галимуллин, аның урынбасары Ш.Мостафин, язучы С. Шәмси, шагыйрьләр Ә. Рәшит, Ш. Җиһангирова, драматург Д.Салиховлар катнашты. Очрашулар 17 нче милли китапханәдә, Ленин мемориаль үзәгендә үткәрелде. Бу бәйрәмгә өлкәнең төрле районнарыннан татар теле укытучылары, милли хәрәкәт активистлары җыелган иде. Казан кунаклары «Өмет» газетасы редакциясендә, төбәкне өйрәнү музеенда да булдылар.

### КДУда ЯҢА ИНСТИТУТ

Казан дәүләт университеты каршында яңа институт—шәрыкны өйрәнү институты ачылды. Ул татар филологиясе, тарихы һәм көнчыгыш телләре факультетындагы көнчыгыш телләре кафедрасы җирлегендә оешты.

Яңа уку елына беренче студентлар кабул ителде. Алар әлегә өч төрле белгечлектән белем алачаклар: гарәп, кытай, төрек телләреннән. Киләчәктә фарсы, япон һәм грек телләре бүлекләрен ачу да күздә тотыла.

### ДӨНЬЯГА ТАНЫЛАБЫЗ

Прагада чыга торган «Нумизматика басмасы» журналының бер саны Казанның 1000 еллыгына багышланган.

Журнал битләрендә мәркәзебезнең тарихи урыннары, һәйкәлләре, мәдәният йортлары... Шунда ук археолог Ф. Хуҗинның Кремльдә табылган чех тәнкәсе турындагы язмасы да бирелә.

### ӘНИЛӘРГӘ БАГЫШЛАНГАН БӘЙГЕ

Җырчылар, шагыйрьләр һәм композиторлар арасында «Әни турында җыр» бәйгесе игълан ителде. Бәйгедә катнашырга теләүчеләргә җырларның яңа булуы һәм монарчы башкарылмавы бердәнбер таләп итеп куела. Бәйге 28 сентябрьдән 26 октябрьгә кадәр районнарда, аннары, 25 ноябрьдә, Казанда үткәрелә. Иң оста җырчылар халыкка ошаган җырларны 26 ноябрьдә—«Ана көне»ндә башкарачак.

### «ХӘЛФӘ БАБАЙ» ЮБИЛЕЕ

Балык Бистәсе районының Котлы Бөкәш авылында күренекле дин белгече, фәлсәфәче, шагыйрь һәм табиб И. Зәлмөхәммәтовның тууына 350 ел тулуга багышланган «Татар халкы тарихында суфичылык карашының әһәмияте» дигән фәнни-гамәли конференция узды. Аны район хакимияте башлыгы Равил Хәйруллин ачты. Конферен-

циядә Казаннан килгән галимнәр Ф. Хужин, Р. Галләмов, Р. Әмирханов, Н. Нәккаш, Н.Гарипов һ. б. докладлар белән чыктылар. Конференция эшендә, шулай ук, Татарстанның халык шагыйре Равил Фәйзуллин катнашты һәм чыгыш ясады.

### ЯҢА ГАЗЕТА

Удмуртиядә туган телебездә ике газета («Янарыш» һәм «Саф Ислам») чыгып килә иде инде. Быел менә «Татар рухы» дигән өченче газета чыга башлады.

Газета әлегә татарча-урысча чыга. «Әдәби сәхифә»дә татар теле һәм әдәбияте мәсьәләләре күтәрелә. Оештыручысы—Удмуртия дәүләт университетының татар филологиясе бүлеге укытучысы Вәсилә Хәкимова. Газетаның мөхәррире—Ирек Хисаметдинов.

### БАШ МӨХӘРРИРГӘ— ПРОФЕССОР ИСЕМЕ

Россия Федерация халыкларының күпгасырлык тарихи-мәдәни мирасын барлау, тикшерү, фәнни өйрәнү һәм пропагандалау өлкәсендәге гыйльми хезмәтләре өчен «Мирас» һәм «Сабыйга» журналларының баш мөхәррире, филология фәннәре докторы, Россия һәм Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы Миңнәхмәт Җәмил улы Сәхаповка Россия Федерациясе Мәгариф Министрлыгының 2000 елның 12 июлендә игълан ителгән Карары нигезендә профессор гыйльми дәрәҗәсе бирелде.

### ИНТЕРНЕТТА—МИЛЛИ КИТАПХАНӘ

Татарстан Милли китапханәсе Интернетта үз сайтын ача, адресы: htpp: // kitap. kch. ru. Анда 1995 елдан бирле китапханәгә кителгән барлык материал теркәлгән электрон каталогның күрсәтмә варианты бирелгән. «Китапханә буйлап сәяхәт» бүлегендә Милли китапханәнең барлык бүлекләре һәм бүлекчәләре эшен чагылдыручы фотосурәтләргә гаять бай булган материал да урнаштырылачак.

### ЯЗУЧЫЛАР—«СӘЛӘТ»ТӘ

26 июньнән 13 июльгә кадәр Раифа табигать ядкаре урманлыгында сәләтле татар балаларының җәйге лагере эшләде. Анда Татарстаннан һәм Рәсәйнең дистәләгән төбәгеннән килгән яшьләр кибернетика, математика, татар һәм инглиз телләре, логика, психология, сәнгать дәресләрендә катнаштылар. Балалар күренекле язучылар—Ф. Латыйфи, Р. Батулла, Мөд. Вәлиев, Ж. Сөләйман һәм композитор М. Шәмсетдинова белән очраштылар.

### ТӘКЪДИР ИТҮ КИЧӘСЕ

Баулының мәдәният сараенда күренекле язучы Фәнис Яруллинның «Яралы язмышлар» китабы чыгу унаеннан әдәби кичә узды. Өч телдә—татарча, русча, инглизчә чыккан бу китап ятим балалар язмышына багышланган.

### АТКАЗАНГАН ИҢ ЯШЬ АРТИСТКА

Президент М. Шәймиев Указы нигезендә 16 яшьлек Алсу Сафинага (Бөгелмәдә туган бу кыз хәзер Лондонда укый) музыка өлкәсендәге уңышлары өчен «Татарстан Республикасының атказанган артисты» дигән мактаулы исем бирелде. Быел Алсу Стокгольм шәһәрендә үткән «Евровидение—2000» җыр конкурсында икенче урынны яулаган иде.

### КОТЛЫЙБЫЗ!

Татарстан Президенты Указы нигезендә хәзерге заман әдәбиятын үстерүдәге уңышлары өчен Татарстан Язучылар берлегенең әдәби консультанты **Корчагин Владимир Владимировичка** «Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре» дигән мактаулы исем бирелде.

* * *

2000 елның 23 июлендә Татарстан телевидениесенең өлкән редакторы, язучы **Хәйдәр Гайфетдин улы Гайнетдинов** 48 яшендә вакытсыз вафат булды.

*Тышлыктагы сурәтләр*

**Тышлыкның беренче битендә:** «Чишмәләр—чыганаклар». Шамил Нигъмәтуллин триптихыннан фоторепродукция.

**Тышлыкның дүртенче битендә:** язучы Әхәт Сафиуллин.

# ЯҢА КИТАПЛАР




**Фатыйх Кәрими**: фәнни-биографик җыентык. Казан: «Рухият» нәшрияты. 2000. —320 бит. Тиражы—3000 данә.

Китап күренекле татар әдибе, журналист, педагог һәм тәржемәче, җәмәгать эшлеклесе Фатыйх Кәриминең 130 еллык юбилее уңаеннан нәшер ителгән. Җыентыкта Гыйльман ахун һәм Фатыйх Кәримиләрнең тәржемәи хәлләре, иҗтимагый эшчәнлекләре буенча документаль материаллар, хатлар, фоторәсемнәр һәм мәкаләләр тупланган. Ф. Кәриминең «Истанбул мәктүпләре» китабыннан (үз вакытында бу хезмәт журналыбызда басылган иде) өзекләр дә бирелгән.

Китап милли тарихыбыз белән кызыксынучы киң катлау укучыларга тәкъдим ителә.

Басманың төзүче-авторлары—Р. Мәрданов, Р. Миңнуллин, С. Рәхимов, фәнни мөхәррире—академик М. Госманов.




**Татар мөселман календаре.** Төзүчеләре—Шәех Зәбиров, Фәния Хуҗиәхмәт.—Казан.—320 б. Тиражы—100000 данә.

Яңа гасырның беренче елы—2001 ел өчен календарь чыкты. Календарь Татарстан мөселманнарының Диния нәзарәте президиумы әгъзасы, Балтач районы баш мөхтәсибе Җәлил хәзрәт Фазлыевның мөрәҗәгате белән ачыла.

Календарьдә Татарстанда һәм Русиянең төрле төбәкләрендә кояш чыгу һәм бату, намаз, ураза вакытлары, сәламәтлекне саклау, бакча эшләре буенча файдалы киңәшләр, укучыларыбызны кызыксындырган күп кенә сорауларга җаваплар урнаштырылган. Мөселман кардәшләребез бирелә шулай ук үзләренә кирәкле догалар, Коръән сүрәләре һәм аятьләренең гарәпчә, татарча транскрипцияләрен укый алачак.

Индекс 73210



Әхәт Сафиуллин

КАЗАН УТЛАРЫ
QAZAN UTLARI
ОГНИ КАЗАНИ

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
(на татарском языке)